ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
ЯЗМА ҺӘМ МУЗЫКАЛЬ МИРАС ҮЗӘГЕ

«МИРАСХАНӘ КОЛЛЕКЦИЯСЕННӘН» сериясе

Шиһабетдин Мәрҗани

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Казан
2018

УДК 28+2-335
ББК 86.38-4
М 90

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә

Проект ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

Басма Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең матди ярдәме белән нәшер ителә

Редколлегия:
И.Г. Гомәров (проект җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррир), А.М. Ахунов, З.З. Рәмиев, Л.Ш. Гарипова

Мәрҗани Ш.
М 90 Сайланма әсәрләр. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 450 б. – («Мирасханә коллекциясеннән» сериясе).
ISBN 978-5-93091-280-7

«Мирасханә коллекциясеннән» сериясенең икенче китабында узган гасырның алтмышынчы елларында Х. Хисмәтуллин тарафыннан төзелгән «Шиһабетдин Мәрҗани. Сайланма әсәрләр» хезмәте укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

УДК 28+2-335
ББК 86.38-4

ISBN 978-5-93091-280-7

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2018

КЕРЕШ

«Мирасханә коллекциясеннән» исемле сериянең икенче китабы укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Әлеге сериянең төп максаты – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге – Мирасханәдә сакланган һәм үз чорында төрле сәбәпләр белән нәшер ителми калган фәнни хезмәтләрне, тарихи-мәдәни текстларны гыльми әйләнешкә кертү. Беренче китапта татар профессиональ музыка сәнгате туу һәм үсеше тарихына багышланган «История татарской музыки» – «Татар музыкасы тарихы» (авторлары – Я.М. Гиршман, З.Ш. Хәйруллина, Ә.Х. Абдуллин) хезмәте урын алган иде. Икенче китапта олуг татар рухание һәм галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең узган гасырның алтмышынчы елларында бер төркем галимнәр тарафыннан төзелгән «Сайланма әсәрләр»е укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Шиһабетдин Мәрҗанинең өч дистәгә якын дини, фәлсәфи, тарихи темаларга язылган хезмәтләр калдырганы мәгълүм. Аларның күпчелек өлеше гарәп телендә язылган. Әлбәттә, Октябрь инкыйлабына кадәр мәктәп-мәдрәсә гыйлемнәрен үзләштергән татар зыялылары өчен бу хезмәтләрне уку-өйрәнү җәһәтеннән артык читенлек күрелмәгән. XX гасырның урталарында исә гарәп-фарсы телләрендәге язмаларның татарча яки русча тәрҗемәләренә ихтыяҗ барлыкка килә. Әлеге ихтыяҗны исәпкә алып, ул чордагы СССР Фәннәр академиясенең Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөкатдимәте китабе «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф», «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» хезмәтләренең аерым бер өлешләрен гарәп теленнән татарчага тәрҗемә итәләр, «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрен шул чор татар әдәби теленә күчерәләр һәм «Сайланма әсәрләр» исемендә (төзүчесе, кереш сүз авторы – Х. Хисмәтуллин; тәрҗемәчеләре: С. Исәнбаев, В. Ильясов, З. Максудова, С. Ногманов, Х. Хисмәтуллин) басмага әзерлиләр.

Мәгълүм булганча, XX гасырның утызынчы-илленче еллары – тарихи мираска карашның каршылыклы, хәтта тискәре булуы белән билгеләнгән чор. Кызганыч ки, бу тенденция татар тарихы фәненә нигез салучы буларак бәяләнгән Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлегенә мөнәсәбәттә дә үзен ачык күрсәтә. Х. Хисмәтуллин җитәкчелегендә төзелгән «Сайланма әсәрләр» хезмәте дә, Я. Агишев, К. Фасеев кебек галимнәр тарафыннан уңай бәяләнүгә карамастан, «Ш. Мәрҗанинең «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгару коммунизм төзергә керешкән татар халкының интернациональ һәм милли культурасын үстерүгә өлеш кертми» дип табыла һәм басмага кабул ителми.

Дөрес, әлеге җыентыкның тарихы шуның белән тәмамлана дип әйтеп булмый. Бүгенгә кадәр ул төрки-татар тарихы, Шиһабетдин Мәрҗани иҗаты белән кызыксынучылар, галимнәр өчен мөһим һәм файдалы чыганак рәвешен үтәп килде, фәнни хезмәтләр, диссертацияләр язылганда, аңа еш мөрәҗәгать иттеләр. Әйтик, галим Әнвәр Хәйри, Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан, 1989) әсәрен китап итеп чыгарганда, «Китапның хәзерге телгә тәрҗемәсе өстендә эшләгәндә, Х. Хисмәтуллин, С. Ногманов, С. Исәнбаев, В. Ильясов тарафыннан әзерләнгән материаллар да файдаланылды. Бу бертомлыкны төзүче һәм тәрҗемәче аларның якты образын ихтирам белән искә ала»[1], – дип билгеләп узды.

* * *

Бүген Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге Ш. Мәрҗани шәхси фондында (ф. 22) саклануучы 565 битлек бу хезмәт (сак. бер. 20) берникадәр кыскартылып һәм редакцияләнеп басмага тәкъдим ителә. Астөшермәләрнең бирелеше төзүче һәм тәрҗемәчеләр язган шәкелдә калдырылды. Шиһабетдин Мәрҗани сүзләре астөшермәләрдә курсив белән «Ш. Мәрҗани искәрмәсе» дип бирелде.

И. Гомәров

[1] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 37.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ
(1818–1889)

Һәрбер тарихи шәхес билгеле җирлектә, билгеле тарихи-иҗтимагый шартларда туа, формалаша һәм тормышның барышына актив тәэсир итә ала. Аларның эшчәнлегенең әһәмиятен дә үзе яшәгән тарихи-иҗтимагый шартларны истә тотканда гына дөрес аңларга мөмкин. Башкача карау шәхес эшчәнлегенә ялгыш бәя бирүгә илтә.

Шиһабетдин Мәрҗани – XIX йөз уртасында Россия татарлары арасында җитешкән галим. Димәк, аның эшчәнлегенең әһәмияте дә иң башлап шул чордагы татар иҗтимагый-фикри хәрәкәте торышы белән билгеләнергә тиеш.

XVIII йөзнең соңгы яртысы, XIX йөзнең башы гомуми Россия күләмендә иҗтимагый-фикри хәрәкәтнең һәм инкыйлаби омтылышның күтәрелә баруы белән характерлы. Россиядә барган фәнгә, культурага, азатлыкка таба көчле хәрәкәт татар халкы арасында да үзенең тәэсирен күрсәтә башлый. Татарлар арасында күп гасырлар буена хөкем сөргән һәм төрле дин галимнәренең карашлары һәм бәхәсләре тәэсирендә артык дәрәҗәдә тарайтылган ислам идеологиясенең кысынкылыгына чик кую юлларын эзләргә кирәклек бик нык сизелә башлаган иде. Шул шартларда XVIII гасырның ахырында, XIX гасырның башында дөньяга яңача карау, прогресска юл ачу хәрәкәте башланды. Бу хәрәкәтнең көчле бер фигурасы Габденнасыйр Курсави (1770–1813) булды.

Дөньяга карашы һәм динне аңлавы ягыннан Курсави рационалист һәм стихиячел диалектик иде. Вакытыннан элегрәк җитешкән бу галимнең кыю фикерләре үз чорында шау-шуга сәбәп булды. Бохара галимнәре аны зиндикъ, динсез, кяфер

дип игълан иттеләр. Бохара әмире Мәгъсүм бине Даниал аны таш белән атып үтерергә хөкем итте, ләкин ул, дусларының ярдәме белән, Россиягә качты. Мәчкәрә авылында мәдрәсә ачып, берничә еллар дәрес укытса да, аңа тыныч яшәргә ирек бирмәделәр. 1813 елда үзе оештырган мәдрәсәсен ташлап, хаҗга (Мәккә шәһәренә) чыгып китәргә мәҗбүр булды, юлда Истанбул шәһәрендә чума авыруыннан үлде.

Гомумроссиядә яңарыш һәм шуның көчле тәэсире астында татарлар арасында промышленность капитализмының үсүе, шуның законлы нәтиҗәсе буларак, феодаль мөнәсәбәт өчен характерлы булган туңлык, йомыклыкның җимерелә, азатлыкка омтылышның көчәя баруы Габденнасыйр Курсави һәм аның аз санлы фикердәшләре башлаган бу хәрәкәтне җәеп, киңәйтеп җибәрү өчен җирлек хәзерләде. Ул хәрәкәтне дәвам иттерүче, тирәнәйтүче кешеләр мәйданга килде. Шуларның берсе Шиһабетдин Баһаветдин углы Мәрҗани иде.

Ш. Мәрҗанинең кыскача биографиясе. Шиһабетдин Мәрҗани 1818 елның 3 (15) гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасы Тукай районы[1] Ябынчы авылында туган. Бабалары шул ук районның Мәрҗән авылында яшәгәннәр. Мәрҗани дип Мәрҗән авылына нисбәт бирелү шуннан килә. 1824 елда атасы Баһаветдин хәзрәт Ташкичү авылына күчеп килә һәм андагы мәдрәсәдә укыта башлый. Шиһабетдин дә атасы мәдрәсәсендә укый. Ташкичү авылында таза гәүдәле батыр егет булып үсеп җитә, Сабан туйларында көрәшеп, күп батырларны егып, халык телендә «көрәшче Шиһаби» дип дан казана.

Шул вакытның гадәтенчә, үзенең белемен төгәлләү өчен, 1838 елда Бохарага китә. Бу сәфәр байлык сәбәпле түгел, бәлки белемгә сусаудан килә. Озак юл үткәндә ул, тамак туйдырырлык һәм Бохарага барып урнашырлык акча табу өчен, төрле нәрсәләр белән сату да итә, китаплар укуын да дәвам иттерә. Бохарада һәм Сәмәркандта торганда, яшәрлек акча табу өчен, шәкертләр укыта, килере аз булганга күрә, бик күп китапларны үз кулы белән күче-

[1] Бүген бу авыл Әтнә районына керә.

реп алырга мәҗбүр була. Элек, беренче барган елында, ул төрле мөдәррисләрнең дәресләрен тыңлый, ләкин болар аны канәгатьләндермиләр. Иске ысулда һәм дини схоластика белән сугарылган бу мәдрәсәләрдән кул селки, һәм Бохара әмире тарафыннан читкә кагылган, ачык фикерле, аек карашлы галимнәр белән таныша. Алар да Мәрҗәнидәге сәләтне, гыйлемгә омтылышны тиз сизеп алалар һәм төрле фәннәрне эченә алган бай китапханәләреннән файдалануга тулы ирек бирәләр.

Ш. Мәрҗәнинең Бохара һәм Сәмәркандта белем алган, китапханәләре белән файдаланган кайбер кешеләр: Хөсәен бине Мөхәммәд бине Гомәр әл-Кирмани. Киң карашлы, гыйлемгә ихласлы кеше. «Вафиятел-әсляф...»ны да шуның киңәше буенча язарга керешә. Казый Әбү Сәгыйд бине Габделхәй бине Әбелхәер Сәмәрканди. Тарихны, дөнья хәлләрен, математика, астрономия, география h.б. фәннәрне яхшы белгән. Мәрҗани Бохарада Низаметдин әл-Илһами исемле кеше белән дүрт ел бергә яши. Аның медицина, геометриядән яхшы белеме булган. Менә шундый кешеләр белән утырдаш булу, алардан уку, китапханәләре белән файдалану Мәрҗәнигә киң карашлы галим булып җитешүгә ярдәм иткән.

Мәрҗани Бохарада чакта югарыда исеме телгә алынган Габденнасыйр Курсави әсәрләре белән таныша. Курсавиның догматизмга, хәреф ятлаучылыкка, борынгылар сүзенә сукырларча иярүгә каршы кискен чыгышлары Мәрҗәнинең дөньяга карашларында, фәнгә мөнәсәбәтендә, тикшерү-эзләнү методларында кискен борылыш тудыра, үзеннән элеккеләрнең сүзләренә тәнкыйть белән карарга өйрәтә.

Мәрҗани, Бохара һәм Сәмәркандта яшәгәндә, зур тырышлык күрсәтә. Аның тәүлеккә берәр генә сәгать йоклаган чаклары була, кирәксез кешеләр белән очрашып вакыт үткәрмәс өчен, урамда барганда, битен берәр нәрсә белән каплап йөрергә ярата.

Бохара һәм Сәмәркандта ул борынгы грек философларының гарәп теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре, атаклы галимнәрдән Әбү Насыйр Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Тархан бине Әвезләгъ әл-Фәраби, Әбүгали Ибне Сина, XIV йөз галиме һәм

тарихчысы Ибне Халдун, XVI йөз галиме Ибне Хиллякян һ.б. бик күпләрнең әсәрләре белән таныша. Мәрҗани тарихка, генеологиягә (нәсәп гыйлеме, биобиблиография) бик зур әһәмият бирә, үзе укыган китапларның авторларын бөтен нәсел-нәсәбе белән язып ала, ошаган китапларны, я бөтенләй яки кирәкле урыннарын күчерә һәм аларны җыя бара. 1849 елда Бохарадан кайткач, Казанның беренче мәхәлләсенә мулла итеп сайлана. Мәдрәсә ачып укыта башлый. Дәресләре тирән эчтәлекле, кыю фикерләргә бай булалар, шәкертләр күп җыела.

Ул вакытта Казан мәдрәсәләре Бохара мәдрәсәләре ысулында, шул ук тәртип белән укыталар. Андагы ысул һәм программаларны яратмаганга күрә, Мәрҗани үз мәдрәсәсен яңа нигездә үзгәртеп корырга уйлый, башка дәресләр укытырга тели. Ләкин, икенче мәдрәсә шәкертләре алдында надан булып күренүдән куркып, шәкертләр моңа каршы киләләр һәм Мәрҗани бу өлкәдә алдан уйлаганнарының бик азын гына тормышка ашыра ала. Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов белән бергәләп, Россия мөселманнары өчен зур һәм күптөрле фәннәр укытуны күз алдында тота торган мәдрәсә ачарга уйлыйлар, әмма аларның бу планнары да эшкә ашмый кала. Ниһаять, Казанда татарлар өчен рус теле укытучылары хәзерләүче мәктәп (Русско-татарская учительская школа) ачу хәзерлеге күрелә, һәм Ш. Мәрҗани бу мәктәпнең ачылуына нык булышлык итә, ачу тантанасында беренче сүзне ул сөйли, 9 ел дәвамында бу уку йортының Педагоглар советында әгъза була һәм аңа татарча яхшы белгән, татар халкына хезмәт итәрлек кешеләр сайлап алу юлын тота.

Ш. Мәрҗанинең «Татарская учительская школа» ачылуга ярдәм итүенең икенче сәбәбе дә Россиядә яшәүче кешеләр өчен рус телен, аның законнарын белү важиб дип каравында иде[1]. Ул гына да түгел, Мәрҗани рус теленә зур ихтирам да саклаган. Казан мөдәррисләреннән мәшһүр Шиһабетдин әл-Мәрҗани мәрхүм хәзрәтләре таләбәләренә даимән: «Алтын чыга торган

[1] Икенче бер халык астында яшәүче халыклар өчен өч нәрсәне: телен, язуын, мәмләкәтне идарә итү өчен куелган законнарын белү важиб. (Мокатдимәте «Вафиятел-әсляф»дә, 1883, 390 б.)

тауны никадәр казыр исәңез, шулкадәр мәгъдән хасыйль идәсез. Иштә, рус лисаны да буңа мөтәбигъдер» – дидеке мәрвидер[1].

Ш. Мәрҗәнинең Русско-татарская учительская школа ачылуга ярдәме ул еллардагы реакцион көчләргә бер дә ошамаган. Аның турында: «Шиһаб мулла – миссионер. Ул сатылган кеше. Русча укырга баш сәбәп ул гына булды. Кыямәттә кулыбыз якасында булсын», – дип сөйләгәннәр.[2]

Казанга урнашуның беренче елларында ук Мәрҗәни Ибраһим бай Юнысов (Озын Ибрай) белән каршылыкка керә. «Гыйлем байлыктан өстен, галимнәр байлар алдында түгел, байлар галимнәр алдынга тез чүгәргә тиеш», – дип караган Мәрҗәни Озын Ибрайга да баш ими. Казанның бөтен байларын, муллаларын, хөкүмәт чиновникларын үз кулында тотарга өйрәнгән бу кешегә горур Мәрҗәни ошамый. Мәрҗәнинең гыйлеменә һәм гади халык арасында авторитетына көнләшеп, аңа дошманлык саклап йөргән муллаларга бу җитә кала. Мәрҗәнидән гаеп эзләргә, аның өстеннән доносларяудырырга тотыналар. Нәтиҗәдә Мәрҗәнинең ике мәртәбә указы алына, ләкин һәр икесендә дә ул хаклы табылып, указын кайтарып бирергә мәҗбүр булалар.

Оренбург духовное собраниесенә мөфти кую мәсьәләсе кузгалгач, фикердәшләре Ш. Мәрҗәни кандидатурасын куярга телиләр. Ләкин эчке эшләр министрлыгының югары дәрәҗәле чиновнигы реакционер Победоносцев, миссионер Ильминскийның киңәше буенча, аның кандидатурасын кире кага.

Мәрҗәни Казанда рус галимнәре акад. Радлов, Н.Ф. Катанов, Ю.Ф. Готвальд, Е. Малов, профессор Казимбәк һ.б. белән якын мөнәсәбәттә була. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең әгъзасы буларак, 1877 елда Казанда үткәрелгән IV археологик съездны җыю комитетының эшендә актив катнаша. Шул съездда Болгар һәм Казан тарихына карата доклад ясый (докладны ул татарча сөйли

---

[1] Нәвадире нәфисә. Бакчасарай, 1897.

[2] Мәрҗәни мәҗмугасы, 1915, 132 б.

дә, акад. В.В. Радлов аны рус телендә сөйләп үтә һәм бу доклад һәр ике телдә «IV археология съезды материаллары» арасында басылып чыга). Ш. Мәрҗанинең гыйлем дөньясы белән бәйләнеше Казан белән генә чикләнеп калмаган. Үзенең элекке шәкерте һәм Петербург университеты укытучысы Хөсәен Фәезханов (1821–1866) аркылы Петербург университеты галимнәре белән дә бәйләнеш тоткан. Аның исеме көнбатыш һәм көнчыгыш галимнәренә дә билгеле булган. Ул көнчыгыш тарихын яхшы белүче һәм аны өйрәнүдә яңа чыганаклар табучы зур мөстәшрикъ (востоковед) булып танылган. Башка илләрдән яки башка шәһәрләрдән килгән мөстәшрикъләрне акад. В.В. Радлов, проф. Ю. Готвальд һ.б. Шиһабетдин Мәрҗани янына алып бара һәм аның белән очраштыра торган булганнар. Ул үзенең «Мөстәфадел-әхбар» исемле китабының беренче кисәген Ю. Готвальдка бүләк итә. Казан университеты гыйльми китапханәсенең көнчыгыш бүлегендә шул китап һәм Мәрҗанинең автографы саклана. Анда гарәп телендә түбәндәгечә язылган: «Олы, хөрмәтле Йосыф җәнапларына миннән бүләк. Аллаһ аны һәртөрле кайгы һәм үкенеч китерерлек эшләрдән сакласын. Мин, фәкыйрь Шиһабетдин Мәрҗани, Аллаһ аңа сәламәтлек бирсен. Бу – Мөхәррәм аеның 15 дә, 1804 нче елда».

Ш. Мәрҗанинең рус галимнәре белән катнашуы аңа каршыларның ачуын тагын да кабарткан, аны хурлап, бәетләр чыгарылган.

Ул бәеттә:

Һәм дә даны кяфер илә ихтыйлатың бик кави;
Ихтыйлатта фаидәдән шәр – фәсаде кави[1].

(Кяфер белән бик еш катнашасың.
Бу катнашуның файдасыннан зарары көчлерәк.)

Ш. Мәрҗани Казандагы башка иҗтимагый эшләргә дә катнашкан. Мәсәлән, ул «Хайваннарны яклау җәмгыяте»нең үтенүе буенча татар халкына мөрәҗәгать язып биргән. Ул мөрәҗәгать 800 данә басылып, авылларга, мәктәп-мәдрәсәләргә таратылган.

[1] Мәрҗани мәҗмугасы, 1915, 343 б.

Ваба авыруына каршы көрәш юлларын күрсәткән мөрәҗәгать тә шулай ук басылып таратылган.

Ш. Мәрҗәни, авылларга чыгып йөреп, зиратлардагы иске кабер ташларын тикшергән, авылларның тарихларын өйрәнгән, төрле борынгы кулъязмалар җыйган. Болгар хәрабәләрен дә ике тапкыр барып тикшереп кайткан. Аның бай китапханәсендә борынгы Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Урта Азиядә яшәгән төрле мәмләкәтләрдә барлыкка килгән әдәби ядкярләр, документлар күп булган. Шиһабетдин Мәрҗәни гомеренең иң соңгы көненә чаклы иҗат эше белән шөгыльләнә. Үзенең илле ел дәвамында буе эшләнеп килгән 7 томлык «Вафиятел-әсляф...» исемле тарихи-генеологик әсәре өстендә эшләүдән үләренә ике көн кала гына туктый. Менә болар үзләре генә дә Мәрҗәнине гади бер мулла итеп түгел, бәлки гыйлемгә ихласлы, иҗтимагый эшләргә актив катнашучы зур бер шәхес итеп күз алдына китерәләр.

Мәрҗәнинең дөньяга карашы һәм гыйльми-әдәби эшчәнлеге. Шиһабетдин Мәрҗәнинең гыйльми-әдәби эшчәнлеген тикшергәндә, аның ислам дине исеме астында йөртелә торган тәгълиматка мөнәсәбәтен читләтеп үтеп булмый. Чөнки Мәрҗәни нәкъ әнә шул бәхәсләрнең татар дөньясында яңадан кыза башлаган дәверенә туры килде. Аның күп китаплары да шул бәхәсләргә бәйле рәвештә язылган. Ул бәхәсләр һәм аларга бәйләнешле китапларны җентекләп тикшерүнең бүгенге көн өчен әһәмияте булмаса да, алар үз заманы өчен бөтенләй файдасыз булмаганнар. Ул китаплардагы кыю фикерләр кешеләрне уйланырга, әйләнә-тирәгә тәнкыйть белән карарга мәҗбүр иткәннәр.

Мәрҗәни дәверендә татар һәм, гомумән, мөселман көнчыгышында унынчы гасырлардан соң «иҗтиһад мөнкариз» – аның заманы инде үткән, кеше үз акылы белән түгел, бәлки үзләреннән алдагыларның күрсәтмәләре артыннан гына барырга тиеш дигән караш хөкем сөрә, ә икенче яктан инде Г. Курсави тарафыннан моңа каршы беренче һөҗүм ясалган иде. «Иҗтиһад мөнкариз» дип карау акылны уйлау көченнән мәхрүм итеп тоткынлыкка төшерү, тормыш үсеше белән бергә бару һәм аңа тәэсир итүдән

кешене читкә тибәрү, дөньяви фәннәрне, ниһаять, тормышның үсешен, үзгәрешен танымау өчен теоретик бер нигез иде. Ислам дине тәгълиматы кеше тормышының күп якларын кодификацияләргә тырышканга күрә, «иҗтиһад мөнкариз» дип ышануга каршы көрәш тә дини өйрәтүләрне аңлау, аның чикләрен билгеләү белән бәйләнештә генә мөмкин иде. «Иҗтиһад мөнкариз» дигән караш татар һәм, гомумән, мөселман көнчыгышындагы иң консерватив, иң реакцион төркемнәрнең интересларына туры килә иде. Ә бу карашны, бу «теоретик нигезне» алып ташлау, акылны азат итү ул дәвердә прогресс өчен иң әһәмиятле, иң кирәкле чараларның берсе иде. Мәрҗани һәм аның фикердәшләре «иҗтиһад»ка юл ачып, акылга ирек биреп, тормышның бөтен якларын үз тәэсирендә тотарга омтылучы дини тәгълиматның көчен киметү, чикләүгә ярдәм иттеләр, кеше акылын коллыктан коткарырга тырыштылар.

«Пәйгамбәрләр, дип язды Мәрҗани, хакыйкать һәм табигать законнарын ачу өчен түгел, бәлки шәригать хөкемнәрен бәян итү өчен җибәрелделәр»[1]. Шулай итеп, ул дини хөкемнәрне тормыш, табигать һәм фән өйрәтүләреннән аерып ала. Ул заманындагы реакцион катлауларның бөтен яңалыктан куркып, шикләнеп карауларына, бөтен нәрсәне хәрам дип, кяфер эше дип бәяләргә әзер торуларына каршы, Ш. Мәрҗани һәр эштә асыл-хәләллек, бернәрсәне хәрам дип әйтү өчен яки кемне дә булса «кяфер» дип атау өчен көчле, катгый дәлил кирәк, дип карый. Аның карашынча, «акыл белән Коръән яки хәдис бер-берсенә каршы килгәндә, Коръән һәм пәйгамбәр сүзләре үзгәртелеп аңлатылырга тиеш», чөнки «акыл һәм тормыш кирәк тапканнарга хак шәригатьнең каршы килүе мөмкин түгел»[2].

Шулай итеп, Ш. Мәрҗани Коръән һәм пәйгамбәр сүзләрен акылга, зарурәткә буйсындырырга, каршы килгәннәрен үзгәртеп аңларга кирәк дип саный.

---

[1] Хаккыл-мәгърифәт, 1880, 24–25 б.

[2] Шунда ук, 63 б.

Мәрҗәнинең бу фикерләрен, заманына, шартларына бәйләмичә алганда, динне тормышка яраштырырга омтылу, шуның белән аның яшәвен озаграк дәвам иттерергә теләү дип, реакцион караш дип бәяләргә мөмкин. Әмма аны XIX гасырның уртасына куеп, андагы шартларны күздә тотып караганда, алар, һичшиксез, гаҗәп кыю һәм прогресска юл ачучы фикерләр иде. Шуңа күрә замананың реакцион элементлары Ш. Мәрҗәнигә каршы зур шау-шу күтәрделәр. «Мозһирел-кәлиматил җәрудәти, әлләти һия фин-Назурә» («Назурә» китабындагы шомлы фикерләрне фаш итүче) исемле, 1874 елда чыккан китапта Ш. Мәрҗәни шундый кыю фикерләре өчен «динсез», «кяфер» дип аталды.

XIX йөздә генә түгел, XX йөз башында да әле реакцион элементлар һәрбер яңа фәнгә, фәндәге яңа ачышларга каршы шикләнеп, куркып карадылар, дөньяви гыйлемнәрне өйрәнүне бөтенләй читкә тибәрергә тырыштылар. Ш. Мәрҗәни бу өлкәдә дә үзенең замандашларыннан гына түгел, бәлки XX йөз башында яшәгән һәм галим исеме алган кешеләрдән бик күп алда торды һәм гыйлем-фән өчен ишекләрен бик киң ачты: «Һичбер гыйлем, – диде ул, – яраксыз (батыйль) түгел. Әгәр гыйлем белән шөгыльләнүченең берәр эшендә хата килеп чыга икән, бу әле фәннең яраксызлыгын күрсәтми, бәлки шул галимнең үз ялгышы булып кала»[1]. Андый ялгышулар һәрбер галимдә булырга мөмкин. Мәрҗәни карашынча, бер галим ялгыша икән, аңа тикшеренү–эзләнүе өчен бер савап, әгәр шул эзләнү нәтиҗәсендә дөреслекне ача икән – ике өлеш савап була[2]. Эзләнү-тикшеренү эшләренә Ш. Мәрҗәни һәрвакыт зур бәя биреп килде. Ул: «Берәр фикерне аңламыйча, төбенә төшенмичә, хакыйкатенә ирешмичә кире кагу – сукыр килеш ук ату, наданлыкка бату», – дип язды. Мәрҗәни карашынча, «Гыйлем –

---

[1] Хаккыл-мәгъриф әт, 1880, 53 б.

[2] Шунысы кызыклы: Мәрҗәни казыйларны өч төркемгә бүлә: 1) дөреслекне белә алган һәм дөреслек белән хөкем итүче. Бу – оҗмахлык; 2) дөреслекне белә, ләкин дөреслек белән хөкем итми; 3) дөреслекне белми – болар икесе тәмуглык. Шунда ук, 6 б.

хакыйкатьнең нәкъ үзе. Гыйлемнән өлеше, хәбәре булмаган кешенең аны хурларга хакы юк»[1].

Гыйлемгә бик югары бәя биреп, Ш. Мәрҗани «Мөкатдимәте Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» исемле китабында (1883) үз вакытында мәгълүм булган барлык гыйлемнәрне диярлек санаган, аларның кыскача эчтәлекләрен, тарихларын, тормыштагы урыннарын бәян иткән. «Бу таснифе голүм кебек мөһим бер мәсьәләне күтәрүе белән, – диде проф. Г. Гобәйдуллин, – туачак татар фәлсәфи әдәбияты Мәрҗани хәзрәтләренә бурычлы»[2]. Ш. Мәрҗани бу классификациясендә күбрәк XIV йөз тарихчысы Ибне Халдунга таянып эш иткән, әмма аның карашлары белән генә чикләнеп калмаган, күп мәсьәләләргә үзенчә аңлатмалар биргән, өстәгән, Ибне Халдун вакытында билгеле булмаган яңа ачышларны тупларга тырышкан. Мәсәлән, галәм төзелеше турында борынгыдан килгән легенда бар. Аның буенча, галәмнең үзәге – Җир. Ул үзе – үгез мөгезендә, үгез – балык мыегында, балык – су өстендә, су – караңгылык өстендә. Бездә бу легендага ышанучылар XX йөз башында да юк түгел иде. Борынгы астрономиядә галәмнең үзәге – җир, ә кояш җир тирәсендә әйләнә дип уйлана иде. Ибне Халдун да «Мокатдимәте тарихы ибне Халдун» исемле әсәрендә шул карашта тора. Ш. Мәрҗани исә соңгы заман астрономнарынча, «бу галәмнең» үзәге кояш, җир кояш тирәсендә һәм үз күчәрендә әйләнә, үзәгендә кояш булган «бу галәмнең» үзенең янә бер хәрәкәте булырга мөмкин дип карый.

Менә бу яңа астрономия мәсьәләсе татар дөньясында XX йөз башында да бик актуаль булып торган. Архангельск шәһәрендәге мәктәптә мөтәвәлли Мөхәммәдгариф Габделвәли мулла углы Түнтәр Ишмөхәммәд муллага язган хатында (1908 ел) болай ди: «Хәзерге мөселман мәдрәсәләрендә яңа география укыту дөрес булыр микән? Рустан алып тәрҗемә кылганнар. Гыйбарәтләре болай: «Күк юк, Кояш күчәрендә

[1] Хаккыл-мәгъриф әт, 1880, 24–25 б.
[2] Мәрҗани мәҗмугасы, 1915, 325 б.

генә әйләнә. Җир белән ай йөриләр. Һәркайсы кояш тирәсендә мөстәкыйль хәрәкәт итәләр. Көн һәм ай хисабы җир хәрәкәте белән була. Җирнең ике хәрәкәте бар: 24 сәгатьтә бер-бер мәртәбә хәрәкәт кыла. Моннан көн һәм төн хасил була. Икенче хәрәкәте – кояш әйләнәсендә 365 көн 6 сәгатьтә бер мәртәбә хәрәкәт итә. Бу хәрәкәттән бер ел хасил була. Җирдә булганнар – ай яктысыннан, айдагылар җир яктысыннан файдалана...» – дип язалар. Мөтәвәлли шушы карашның ислам тәгълиматы белән сыеша аламы, юкмы икәнен сорый[1].

Ишмөхәммәд Түнтәри бу мәсьәләгә «тирәнрәк» керергә тели. Мондый китапларны русчадан тәрҗемә дип түгел, бәлки француз дәһриләренең[2] яңа астрономия буенча төзегән китапларының төрекчә яки гарәпчәгә тәрҗемәләрен файдаланып язылган», – ди. «Бу француз астрономиясеннән алынган китапларны кирәк тискәрелек, кирәк җиңелчә сөеп, кирәк ышанып булсын, укыту кешеләрне үзләре сизмәстән үк мөселманлыктан тышка чыгара, «кяфер» итә, – ди[3]. «Вафия иясенең» (Мәрҗанинең дигән сүз) җир һәм кояш хәрәкәте турында язганнары Коръәндәге бик күп аятьләргә каршы килә, шуңа күрә ул кяферләр рәтендә, – ди шул ук «Икамәтел-борһан» китабының алтынчы кисәгендә Ишмөхәммәд Түнтәри Г. Курсавины мактаган өчен Мәрҗанине Марк (динсез) дип атый һәм «Вафия»дә (Ш. Мәрҗани китабы) җир һәм кояшның хәрәкәте турындагы фикерләрнең наданлыктан, вөҗдансызлыктан, инглиз иблисләре коткысыннан килгән саташулар», – дип бәяли.

Ш. Мәрҗани әдәбият һәм сәнгатькә зур ихтирам белән караган. Культураның төрле өлкәләре турында үзенең карашларын язып калдырган. Әсәрләрендә шигырь кулланырга һәм аларны үз фикерләренә дәлил итеп китерергә дә яраткан. Фән һәм сәнгать өлкәсендә атказанган кешеләрнең биографияләрен туплаган.

---

[1] Өземтәләрнең телләрен хәзергечә күчердек.

[2] Дәһри – динсез, динне танымаучы.

[3] Өземтәләр Ишмөхәммәд Түнтәринең «Икамәтел-борһан галя әрбабиссәбли вәл-әүһам» исемле (1907–1908) әсәренең икенче һәм сигезенче кисәкләреннән алынды.

Әдәбиятыбызның тарихын да фәнни нигездә тикшерә. «Нәһҗелфәрадис», «Башлагали», «Йосыф китабы», «Нәсыйхәтессалихин» исемле китапларны, «Шәһәре Болгар газилары бәете», «Нәүруз бәете» кебек әсәрләрне болгар әдәбияты әсәрләреннән саный һәм язуларының бу өлкәдә табылган иске язуларга нык ошауларын, бу өлкәләрдә күпләп табылып та башка якларда бер дә очрамаганлыкларын, теленең дә шул чорларда язылган кабер ташларына якын, ә госманлы төрекләре, чыгтай, төрекмән, казах телләренә башка булганлыгын әйтеп, үзенең карашын ныгыта. Аның бу фикерләре әдәбият тарихын тикшерүче хәзерге галимнәр өчен дә ышанычлы чыганак булды. Түбәндә китерелгән кечкенә эпизод та Ш. Мәрҗанинең әдәбиятка мөнәсәбәтен билгеләү өчен әһәмиятле: «Әхмәд Хаҗи исемле бер ахун Мәдинә шәһәрендә китапханәдә Һиндстанда ташбасмада басылган «Сөбхәтел-Мәрҗан» исемле 297 битлек бер китап күрә. Фарсы һәм гарәп телләрендә югары художестволы шигырьләрне эченә алган һәм Һиндстанда «Хөсанелһинд» («Һиндстан күрке») дип дан алган бу әсәрне Әхмәд Хаҗи күчереп ала. Шул турыда Ш. Мәрҗанигә Мәдинәдән хат белән хәбәр итәләр. Әхмәд Хаҗи Казанга кайтып керү белән, Мәрҗани, аның номерына барып, әлеге әсәрне сорый[1].

Ш. Мәрҗанинең музыка һәм рәсем сәнгатенә карашы да бик әһәмиятле. Мәгълүм ки, XIX йөздә генә түгел, XX йөз башында да әле бу мәсьәлә бездә чишелеп бетмәгән иде. Бу турыда реакцион руханилар гына түгел, хәтта үз вакытында бик кыю фикерләр белән танылган «Өлфәт» газетасы да («Өлфәт», № 6, 1905 ел) «Музыка эштән калдыра, юлдан туктата, балаларны әварә итә» дип, аның яраксыз, гөнаһлы эш булуын күрсәтергә тырышкан. Ш. Мәрҗани исә XIX йөзнең соңгы яртысында ук «музыка гыйлеме» дип аталган бер гыйлем булуын әйтте һәм музыканың кайбер теоретик положениеләрен язып чыкты, төрле музыка коралларының исемнәрен санады һәм музыканы тыюның дөрес түгеллеген күрсәтте.

---

[1] Мәрҗани мәҗмугасы, 1915, Р. Фәхретдинов мәкаләсеннән.

«Бу гыйлемне гыйлем хәленә башлап Фисагурис (Пифагор) китерде, аннан соң Аристоталис (Аристотель) орган дигән корал уйлап чыгарды. Музыкадан төп максат – төрле тавыш һәм көйләрне бер-берсенә яраштырып, күркәм һәм матур итеп төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү; ә моның нигезе – ритм һәм метрика. Шатлану яки кайгыга төшү, йокымсырау яки көлү һәм бию, ритмга туры китереп кул-аяк, баш һәм башка әгъзаларны хәрәкәтләндерү нинди дә булса бер мәгънә аңлау сәбәпле түгел, бәлки уен коралы кылларындагы хәрәкәт тәэсирендә хасил була. Бишектәге бала хуш аваздан юанып елаудан туктый һәм игътибарын шул авазны тыңлауга юнәлдерә. Дөя, аңгыра булуына карамастан, хуш аваздан әсәрләнә, авыр йөкләрне җиңел күтәрә һәм ерак юллар да аңа якын булып күренә. Яз һәм аның чәчәкләре, музыка һәм аның хуш авазы кемнең дә булса йөрәген хәрәкәткә китермәсә, ул кешенең табигате бозык, ул төзәлмәслек авыруга дучар булган кеше», – ди Мәрҗани.

Ш. Мәрҗанинең рәсем сәнгатенә карашы да игътибарга лаеклы. Бу мәсьәләне чишүдә ул «Һәр эштә хәләллек асыл» дигән үзенең төп положениесеннән чыгып эш итә. Рәсемнең Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан тыелганлыгын, ә бу тыюның сәбәбе – ул чорда сурәткә табыну икәнлеген, хәзер исә сурәткә табыну беткәнлектән, аны тыярга сәбәп тә калмаганлыгын әйтә. Бу мәсьәләдә дә Ш. Мәрҗанинең «иҗтиһад мөнкариз түгел» дигән позициядә торып эш итүе ачык[1].

Галим үзенең хезмәтләрендә сәнгатьнең кайбер теоретик якларына да тукталган. «Бел: бер нәрсәнең ләззәтле яки ачы булуы кешегә ошау-ошамау белән билгеләнә. Кешенең күңеленә ошаган, мөлаем булып күренгән әйбер аңа ләззәтле һәм матур булып, әгәр ошамаса, кәефенә туры килмәсә, җирәнгеч һәм ачы булып тоела. Ашамлыкның тәме ашау, тотыла торганның

---

[1] Ш. Мәрҗанинең үзенең хәзерге көндә өч рәсеме саклана. Боларның икесе 1845 һәм 1886 елларда алынган. Берсенең датасы билгесез. Ул рәсемнең полиция надзоры тарафыннан алынган булуы ихтимал дип уйлана.

ләззәте – тоту, иснең ләззәте – иснәү, көйнең ләззәте ишетү әгъзаларының кәефенә туры килү белән беленә». «Бер-берсенә капма-каршы тавышларны бергә тәртипсез кушу (кинәт сузу, шунда ук озынайту, кинәт өзү һ.б.) белән матурлык хасил булмый. Тәртипсез кушылган тавышлар җыентыгы көйнең тәртибен боза. Колакны рәнҗетә... моны инде музыка галимнәре тулы итеп бәян итәрләр», – ди.

Мәрҗани рәсем сәнгате турында да төзеклек һәм мәгълүм тәртиплелек кирәклеген сөйли: «Күреп торганнарның рәсемнәре, сызыклары төгәл һәм үзара ярашулы булсалар, күркәм һәм матур күренсәләр, андый рәсемнәрне караудан җан рәхәтләнә», – ди. Шигырьнең матурлыгы өчен дә ритм һәм рифмаларның сакланырга кирәклеген яза.

Димәк, сәнгать әсәрләрен бәяләүдә субъектив моментларның ролен инкяр итмәү белән бергә, Мәрҗани алар алдында объектив шартларның хәлиткеч роль уйнаганлыгын нык төшенә. Көй, җыр һәм биюнең кеше өчен табигый сыйфат булуын әйтү белән бергә, аның махсус өйрәнү аркылы камилләшүен, бер һөнәр булып китүен яза. Музыка сәнгатенең, югарыда әйтелгәнчә, эшне җиңеләйтү, кешене генә түгел, хайваннарны да дәртләндерүен күрсәтү белән бергә, аның кайбер очракта зарарлы һәм эшлексез кешеләр эшенә әйләнеп китү мөмкинлеген дә Мәрҗани истә тота: «Әгәр илнең яшәеш һәм төзеклек дәрәҗәсе акыл һәм камиллек өчен зарур булган чиктән узып китсә, сәнгать осталары күбәеп, барлык эш һәм хәрәкәтләрдән бушаган кешеләр ләззәт сөючелек юлына керәләр. Бу хәл элегрәк гаҗәм патшалары сараенда диңгез ташкыны кебек күп булды», – ди.

Мәрҗанинең медицинага карашы да бик киң һәм бик әһәмиятле булган. Ул «Һәр авыруга дәва бар, тик картлыкның гына дәвасы юк» дип санаган һәм «оста врачлар ул даруларны беләләр» дип, һәркемне, хәтта ул вакыт өчен гаҗәпләнерлек фикердә – хатын-кызларны да врачлар дәваларга тиеш дигән карашта торган. Врачтан файдалануга чакырып өндәмәләр тараткан, медицина гыйлеменең, фармацевтиканың тарихын язган.

Ш. Мәрҗәниненең кызының кызы Нәгыймә абыстайның бу елның (1962 ел) язында безгә сөйләвенә караганда, ул үзенең хатынын да, авырган чакта, врачка күрсәтә торган булган.

«Изгеләр» каберенә барып дога кылуларның, им-том итүләрнең файдасыз хорафат икәнен сөйләп, язып калдырган.

Мәрҗәни тарих фәненә аеруча зур әһәмият биргән, аны илнең, халыкның политик, социаль-экономик һәм культура дәрәҗәсен, тарихта исемнәрен калдырган кешеләрнең тормышын эченә алучы гыйлем дип караган. Мәрҗәни фикеренчә, тарих – тормыш мәктәбе. Кешеләр үзләренең үткәндәге хәлләрен тикшереп, бабаларының нинди уңышлы һәм ялгышлар эшләгәнлеген белергә, ялгышларыннан сакланып, уңышларын үстерергә өйрәнәләр. Тарихын оныткан халыкның киләчәге дә өметсез.

Мәрҗәниненең тарих фәненә мондый карашы оригинал түгел: ул аны XIV йөз тарих галиме Ибне Халдуннан һәм «Мифтахес-сәгадәт»[1] исемле әсәрдән алган булса кирәк. Ләкин без Ш. Мәрҗәниненең коры күчерүче генә түгеллеген, бәлки үзе дөрес дип санаган фикерләрне генә шулай, бер дә бәхәссез алганын беләбез. Шуңа күрә дә бу бәяне без Ш. Мәрҗәни яклый торган караш дип кабул итәбез.

Ш. Мәрҗәни тарих һәм генеалогия (нәсәп гыйлеме) белән Бохарада һәм Сәмәркандта ук шөгыльләнә башлаган. Казанга килеп урнашкач, бу хезмәтен тагын да тырышыбрак дәвам иттергән. Ул чорда Казан университеты янында Көнчыгышны өйрәнү бүлегенең актив эшләве, аның тирәсенә рус галимнәренең җыелуы, IV археология съездының Казанда үтүе, Археология һәм этнография җәмгыятендәге активлык – менә болар Мәрҗәнигә тарих өлкәсендә эшләүгә зур дәрт һәм булышлык иткәннәр. Ул дәвердә Казан көнбатыш белән көнчыгыш культурасының очрашу урыны булган. Көнчыгышны өйрәнүче рус галимнәре күбрәк көнбатыштагы чыганаклар белән эш итсәләр,

---

[1] Биредә сүз тарихта Ташкибризадә исеме белән танылган галим Әхмәд бине Мостафаның «Мифтахес-сәгадәт вә мисбахес-сийадәт фи мәүзугатил-голюм» исемле хезмәте турында бара.

Ш. Мәрҗани аларның хезмәтләренә көнчыгыш чыганакларын, хәтта тарихка турыдан-туры бәйләнеше булмаган китаплардагы мәгълүматларны өстәгән. Ш. Мәрҗани үзе дә русча чыганаклардан (рус телендәге летописьлар, докладлар, рус галимнәренең әсәрләре) беркадәр файдаланган[1]. Шулай итеп, Көнчыгышны өйрәнүче галимнәр арасында матур бер хезмәттәшлек мәйданга килгән, профессор Е. Маловның язуына караганда, башына ак чалма, өстенә яшел чапан кигән Мәрҗанине Казан университеты бинасында Археология һәм этнография җәмгыяте утырышларында бик еш очратырга мөмкин булган.

Мәшһүр тарихчы галим Газиз Гобәйдуллин: «Мәрҗани хәзрәтләренең басылган әсәрләрендә никадәр шәрекълелек вә бер урта дәрәҗәдә генә торып гареб мәдәниятен[2] мөселман мәдәнияте рәвешендә итеп татар эченә жәяргә тырышуы күренеп торса, шул ук кадәр курыкмыйча, шиддәтле рәвештә аның «гаребче» икәнен дә күрсәтә торган урыннары бар. Болар басылмаган таркау кәгазьләрдә, мәҗмугаларындагы сәтырларындадыр. Мәрҗани хәзрәтләре бу кәгазьләрендә чын-чыннан бер гареб кешесе, гади кеше генә түгел, бер гареб галиме: дөньядагы ул вакыттагы сәяси хәлләр, фәнни ачышлар, гаҗәеп вакыйгалар, төрле мәсьәләләрдәге, бигрәк тә һәйәт[3] һәм тарих фәннәрендәге рус галимнәренең фикерләре – һәммәсе дә кергәннәр, һәммәсе дә бер Европа кешесен искә төшерә торган рух белән язылганнар»[4], – ди. Шул рәвешчә, Ш. Мәрҗанидә югарыда әйтелгән көнчыгышлык белән көнбатышлык очрашканнар, Мәрҗани шул ике культураны, ике фәнне үз эшчәнлегендә чагылдыручы бер фигура булган.

---

[1] Рус телендәге чыганаклардан файдалануда Ш. Мәрҗанигә Хөсәен Фәезханов, Гали Мәхмүдов, Мөхәммәҗан Аитовлар ярдәм иткән. (Бу мәгълүмат «Мәрҗани мәҗмугасы»ндагы Г. Газиз (Гобәйдуллин) мәкаләсеннән китерелә.)

[2] Гареб мәдәнияте – Көнбатыш (рус һәм Көнбатыш Европа) культурасы.

[3] Һәйәт – астрономия.

[4] Мәрҗани мәҗмугасы, 1915, 324 б.

Ш. Мәрҗәни, үзенең тарих мәсьәләсенә бәйләнешле хезмәтләрендә гареб һәм иран сәйяхларының, рус галимнәренең күптөрле язмаларыннан файдалану белән бергә, кабер ташларын, төрле дәвердә төрле мәмләкәтләрдә сугылган акчаларны, халык телендәге хәбәрләр – истәлекләрне ныклап өйрәнгән. Кайда гына бер әһәмиятле фактны күрсә я ишетсә, язып барган (шундый язмаларны саклау өчен, аның махсус капчыклары булган). Менә шундый тикшеренүләр нәтиҗәсендә аның берничә тарихи әсәре барлыкка килгән. Боларның беренчесе – «Горфәтел-хәванин ли горфәтил-хәвакыйн» (1864) исемле 32 битлек әсәр, Казанда басылган. Аның бу әсәре уйгур төркеләренең IX–XI йөзләрдә яшәгән дәүләтләрендәге хаканидлар династиясе турында әһәмиятле мәгълүматны эченә ала.

«Гыйляләтез-заман...» исемле һәм 1874 елда IV археология съездында ясаган доклады, шул ук нигездә 1880 еллар тирәсендә язган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле ике томлы тарихи әсәре көнчыгыш Европа һәм Урта Азиядә яшәгән төрки халыкларының, алар төзегән дәүләтләрнең һәм Идел буе татарларының Россия составына кергәннән соңгы тарихларын эченә ала.

«Мөстәфадел-әхбар...»ның кереш өлешеннән күренгәнчә, Мәрҗәни заманында татарларның һәм, гомумән, Россия составындагы төрки халыкларның тарихлары әле бөтенләй диярлек язылмаган. Безнең тарихчы галимебез шуңа бик борчылган һәм, фәнни нигездә эшләнгән тарихны башкалардан көтеп эш чыкмас дигән уйга килеп, «Мөстәфад...»ны язарга керешкән. Әлеге өлкәдә беренче тәҗрибә буларак язылган бу әсәрне тулы бер фәнни тарих дип әйтү дөрес булмас. Ләкин автор үзенең хезмәтенә чын мәгънәсендә намус эше дип караган, ул нинди дә булса тенденцияләргә бирелүдән сак булырга, төрле вакыйгаларны, төрле халыклар арасындагы мөнәсәбәтне сурәтләгәндә, объектив рәвештә «акны – ак, караны – кара» дип әйтергә тырышкан. Өстән караганда «Мөстәфад...»ның беренче томы ханнар тарихы кебек күренсә дә, асылда шул илләрнең төзелү, күтәрелү һәм җимерелүләрен кыска, ләкин ачык күрсәтүче бер әсәр булып чыккан.

Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...»да Көнчыгыш Европа һәм Урта Азиядә яшәгән дәүләтләрнең, халыкларның тарихын язса да, ул аны «Болгар һәм Казан турындагы әсәр» дип атаган. Чөнки аның төп максаты да Болгар һәм Казан дәүләтләренең, алар җимерелгәч, татар халкының тормыш рәвешен яктырту булган.

«Мөстәфадел-әхбар»ның беренче кисәгендә Ш. Мәрҗани IX–XII гасырларда Идел-Кама буйларында яшәгән Болгар дәүләтенә, болгар халкының чыгышы, формалашуына, андагы тормыш, культура, төрле илләр белән мөнәсәбәтенә, ниһаять, Болгар дәүләтенең җимерелү мәсьәләләренә озак туктала. Болгарның ни өчен «болгар» дип исемләнүе турында да төрле гипотезалар куя.

Мәгълүм ки, болгарларның этногенезы мөстәшрикъларны нык кызыксындырган. Бу турыда төрле караш һәм фикерләр булган һәм бар. Берәүләр болгарларны – төрек, икенчеләр – фин-угор, өченчеләр славян дип атаганнар. Бу мәсьәләне чишүдә X йөз башында хәлифә әл-Моктәдир биллаһ тарафыннан Болгар патшасына җибәрелгән илчеләр һәйәтендә секретарь булган Ибне Фазлан язып калдырган әсәрнең[1] зур әһәмияте бар. Мондый әсәрнең булганлыгы күптән билгеле булса да, бу язманың тулырак нөсхәсе Иранда Мәшһәд шәһәрендә, 1924 елда табыла. «Мөстәфадел-әхбар...» ның I томында Ш. Мәрҗани Ибне Фазланнан озын-озын, берничә биткә сузылган өземтәләр китерә. Яшь вакытында Ибне Фазланнан күп нәрсә күчереп алганын, тик аларны кайда куйганын белмәгәнен яза. Димәк, бу өземтәләрне ул хәтер буенча яза. Шулай да алар 1939 һәм 1956 елларда проф. Ковалевский тарафыннан бастырылган текстлар белән туры киләләр. Бер урында Мәрҗани бер үк сүзнең төрле нөсхәләрдә төрлечә язылуын да әйтеп үтә. Шулай булгач, XIX йөзнең беренче яртысында Бохара һәм Сәмәрканд китапханәләрендә яки аерым галимнәрнең кулларында Ибне Фазлан язмаларының ике-өч данә булганлыгы турында уйларга

---

[1] Бу әсәр «Китаб Әхмәд бине Фазлан бинел-Габбас бине Рәшид бине Хаммад рәсүл Әл-Моктәдир иля мәлик әс-сәкалибә» дип атала.

юл ачыла. Профессор Ковалевский да бу әсәрнең XVII йөздә Бохарада булганлыгын әйтеп уза.

Ибне Фазлан үзенең хезмәтендә әлеге һәйәт – илчелекнең Сәкалибә патшалыгына килгәнлеген яза. Сәкалибә нинди халык?

Бу – Ш. Мәрҗәниненең «Болгар һәм хәзәр мәмләкәте кешеләренә гарәпләрнең «сәкъләби» һәм «хәзәр» исемнәрен бирүләре иң әһәмиятле тышкы сыйфатларына карап булыр», «Бу киң мәмләкәт һәм төрле-төрле халыклар элек «сәкалибә иле» һәм «сәкъләб» халкы, соңрак «Дәшт Кыпчак» һәм «кыпчак халкы», тагын да соңрак «Болгар иле» һәм «болгар халкы»... дип йөртелеп киткәннәр дигән сүзләренә дә, профессор Ковалевскийның, төрле халыклар яшәгән көнчыгыш Европада ул чорда Болгар иң көчле мәмләкәт булганга, Ибне Фазлан Болгар патшасын «Сәкалибә патшасы» дип атаган булыр дигән фикеренә дә туры килә. Әмма профессор Ковалевскийның «Сәкалибә» һичшиксез «славян» дип әйтүе Ибне Фазлан дәверенә түгел, бәлки соңгы заманга карый булса кирәк[1].

Ибне Фазлан килгән Болгар патшасының исеме ничек? Бу да кызыклы мәсьәлә. Мәрҗани аны «Алмас бине Сәлки» дип атый. Әмма Мәшһәд нөсхәсендәге «болтавар» сүзен «белеквар» яки «белегевар», ягъни белекле, күп белә торган мәгънәсендә һәм патшаның титулы дип карый. Кайбер нөсхәләрдәге «بلطوار» формасын Ибне Фазлан заманында гарәпләрдә күфи язуы кулланылып, күфә язуында «بلكوار» формасында язылган бу сүзне күчерүчеләр ялгыштырып, «ك» не «ط» дип «بلطوار»га әйләндергәннәр дип уйлый. Ак. Крачковский редакциясендә

[1] «Камус Кәбир» дип йөртелә торган энциклопедик сүзлектә: «Сәкалибә – махсус бер кавем исеме. Илләре Болгар мәмләкәте белән Константиния (Истанбул дигән сүз) арасында, хәзәр мәмләкәте белән чиктәш. Географиядә «сәкалибә» поляк, чех, венгерлар яшәгән илгә әйтелә. Кайбер географлар китабында «сәкалибә» дип болгарларны атыйлар. Грек сүзеннән гарәпләштерелгән» диелә. Борынгы дәвердә төзелгән энциклопедиядән алынган бу юллар да болгарларны «сәкалибә» дип атау булганлыгын күрсәтә. «Камус Кәбир» – Мәждетдин Әбү Таһир Мөхәммәд бине Ягъкуб (729–816, 1326–1413) әсәре. Иранда Фәйрүзабад шәһәрендә туганга, «Фәйрүзабади» дип йөртелә.

чыккан китапта болгар патшасы «Әлмүш бине Шәлки» дип, «بلطوار» сүзе «балтавар», ә профессор Ковалевский аны «йылтавар»га әйләндерә. Көнчыгыш галимнәре язган тарихи әсәрләрне күп тикшергән Әхмәд иптәш Булатов бу сүзне «балта» тамырыннан килә торган сүз дип уйлый. Бу чакта ул «балтавар», ягъни «балтасы бар кеше» мәгънәсендә була. Без «балтавар» яки «йылтавар» сүзләренең мәгънәләрен таба алмадык.

Әгәр без төрки халыкларының бик борынгы заманнарда ук үзләрен «Билге каган» дип йөрткән булуларын да искә алсак, бу сүзне Мәрҗанинең «белеквар» яки «белкевар» дип укуы дөресрәк булыр дип уйлыйбыз.

Тарихи чыганаклардан күренүенчә, бу һәйәт Болгар патшасының чакыруы буенча килгән. Аның максаты да Болгар иле белән Гарәп хәлифәлеге арасындагы бәйләнешне ныгыту, Болгардагы гыйльми һәм идеологик эшләрне көчәйтү, Болгар илен хәзәрләрнең һөжүменнән саклауны оештыру булган. Чөнки хәзәрләр Иделнең түбән агымында яшәгәннәр, аларның югары идарәче катлавы яһүд динендә булган. Гарәп хәлифәлеге өчен Болгарлар белән бәйләнешне ныгыту Иделнең түбән агымын үз идарәләре астына кертү өчен дә кирәк булган. Бер яктан болгарлар, икенче яктан гарәпләр уртасында калган хәзәр иле, табигый, зәгыйфьләнергә, көчсезләнергә мәҗбүр булган. Әмма болгарларның ислам кабул итүләрен, хәтта аны рәсми дәүләт дине итеп билгеләүнең тарихын бу һәйәт белән бәйләү дөрес түгел. Ислам дине инде бу һәйәт килгәнче үк Болгарда тамыр жәйгән, мәчетләрдә Болгар патшасы исеменә хөтбәләр укыла торган булган.

Ибне Фазланның Мәшһәд нөсхәсе һәм аны тикшерүчеләр белән Ш. Мәрҗани арасында һәйәтнең составы һәм кайбер детальләр турысында бүтән каршылыклар да бар. Ш. Мәрҗани бу һәйәттә «Сәфир – Бәдер әл-Хәрәми, рәсүл – Сәһсән – әр-Расиби, ә секретарь – Ибне Фазлан иде», – ди. Ул «сәһсән» сүзенең гарәп сүзе түгеллеген әйтә. Без төрле сүзлекләрдә «сәһсән» сүзен таба алмадык. Әмма Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» исемле әсәрендә «сусин-төрек биге» диелә. Ибне Фазланның Мәшһәд нөсхәсендә дә бу сүз «сүсин» рәве-

шендә килә. Гарәп хәрефләре белән язылган «сүсин» сүзенең дә «сәһсән» дип укылуы мөмкин.

Ш. Мәрҗәни язганча, Ибне Фазлан башкортлар белән тәрҗемәче аркылы, әмма Болгар патшасы белән тәрҗемәчедән башка сөйләште. Габбаси хәлифәләр дәверендә Багдадта төрекләрнең күп булуын һәм Ибне Фазланның, шулар белән аралашып, төрки телен өйрәнгән булуын мөмкин дип саный.

Ш. Мәрҗәни, Ибне Фазланга һәм башка бик күп гарәп, иран һәм төрек галим һәм сәйяхларының күрсәтмәләренә таянып, болгарларны төрки кабиләләренең берләшмәсе дип исбат итә. Шул ук вакытта ул боларның бер халык булып формалашуында Идел – Кама буйларында борынгыдан яшәгән төрле фин-угор кабиләләренең катнашы барлыгын да инкяр итми. Идел – Кама буйларына Батый гаскәрләре белән килгән монгол-татар гаскәрләренең дә озак вакыт үтмәстән җирле халыкның телен, гореф-гадәтен кабул итеп, шулар арасында югалып калганлыкларын күрсәтә.

Мәрҗәни болгарлардагы төрле гореф-гадәтләр, кием-салым, ашау-эчү, дәүләт идарәсе мәсьәләләренә дә туктала. Аның әсәрендә Болгар халкының культурада түбән дәрәҗәдән һаман югары күтәрелә барып, Болгар иленнән күп галимнәр чыккан-лыгы күренә.

Ш. Мәрҗәни Идел-Кама буенда яшәүче татарларны Болгар токымының дәвамы һәм аның культурасының варисы итеп карый. Казан ханлыгы да туздырылган Болгар дәүләтенең дәвамы итеп күрсәтелә. Әмма Мәрҗәни Казан дәүләтенең эчке тормышы турында күп нәрсә яза алмаган.

Казан ханлыгы яшәгән чорда Гарәп хәлифәлеге бик нык зәгыйфьләнгән һәм гарәпләрнең активлыклары бик түбәнәйгәнлектән, гарәп сәйяхлары Казан ханлыгына килеп йөри алмаганнар, аның турында нәрсә дә булса язып калдыра алмаганнар булса кирәк. Казанда булган сугышлар нәтиҗәсендә андагы китапханәнең, китапларның яндырылуы да Казан турындагы чыганакларны юк иткән. Шулай итеп, Ш. Мәрҗәни үзе өчен бик якын булган чыганаклардан мәхрүм калган: хәтта ул XIX йөздә

үк мәгълүм булган «Төхфәи мәрдан» (Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы әсәре) ядкәрен дә күрмәгән булса кирәк. Юкса ул бу әсәрне телгә алмый калмас иде. Әмма Урта Азиядәге ханлыклар турында Мәрҗани кулында бай материал булган һәм алар турында күп мәгълүмат бирә алган.

Тарихи вакыйга һәм шәхесләр турында сөйләгәндә, аларның эшләренә бәя биргәндә, Ш. Мәрҗани халыкны, төрле илләрне изеп, талап йөрүчеләргә каты нәфрәт белдерүче, аларның явызлыкларын фаш итүче гуманист булып күз алдына килә. Ул Чыңгыз ханның, Аксак Тимернең, башка бик күп шундый патша һәм ханнарның халыкка күрсәткән җәбер-золымнарын ача бара. Чыңгыз хан улларының Бохара, Сәмәрканд, Багдад кебек культура учакларын туздыруларын, Көнчыгыш Европага килеп чыгып, лан, кыпчак, рус халыкларын талап, үтереп, илләрен яулап алуларын, Аксак Тимернең бар эше «кисү, өзү, вату, үтерү, золым һәм алдаудан» гыйбарәт булып, һичбер төрле яхшылык эшләмәгән булуын фаш итә. Аның мондый характеристикалары башка бик күп патшалар, ханнар һәм әмирләр турында язганда да ачык һәм конкрет фактларда күрсәтелә бара.

Ш. Мәрҗани Көнчыгыш Европада һәм Урта Азиядәге ханлыкларның җимерелү һәм бетүләрен алардагы эчке каршылык һәм тәхет өчен көрәштә күрә. Нинди дә булса башка бер дәүләт яки халыкны гаепле дип санамый. Иван Грозныйның Казан һәм Әстерхан ханлыкларын яулап алуы да, Урта Азиядәге ханлыкларның Россия гаскәрләре кулына төшүе дә эчке ызгыш һәм талаш аркасында тәмам зәгыйфьләнеп яшәү сәләтен югалткан мәмләкәтнең табигый язмышы булып килеп чыга. Дөрес, бу эчке көрәшнең социаль-экономик сәбәпләрен Ш. Мәрҗани ачмаган, ул аны ача да алмас иде. Шулай да ул бу турыда бер дә уйламаган дип әйтү дөрес түгел. Мәрҗани әсәрләреннән күренгәнчә, төрки халыкларда власть оештыруның билгеле бер традициясе, ныклы законы булмаган. Тәхет я көч белән тартып алынган, яки «ил агалары» – эре феодаллар җыелып, берәүне хан итеп күтәргәннәр, яки бу халыклар икенче бер илгә вассал булып торганда, ханнар шул ил тарафыннан куелганнар (мәсәлән, Кырым,

Касыйм, өлешчә, казах ханнары). Әгәр хан халыкка ошамаса, аны куып та җибәргәннәр. Кайбер чакларда көчле ирекле кеше хан була, таркау кабиләләр аның тирәсенә җыелалар, көчле бер мәмләкәт барлыкка килә. Көчле хан үлә яки үтерелә, мәмләкәт тагын таркала башлый...

Әлбәттә, XIX гасырда яшәгән һәм төрки халыкларының тарихын беренче тапкыр язган кешедән шуннан артыкны сорый да алмабыз. Ләкин Мәрҗани күрсәткән сәбәпләр дә нигезсез түгел: марксистик тарих гыйлеме бер илнең яшәү, үсү яки таркалуында социаль-экономик хәлнең, илдәге җитештерү көчләренең дәрәҗәсен төп сәбәп итеп алу белән бергә, аерым шәхесләрнең, мәгълүм традицияләрнең ролен дә инкяр итми.

«Мөстәфадел-әхбар»га Казандагы рус галимнәре зур әһәмият биргәннәр. Аның турында Археология һәм этнография җәмгыяте утырышында проф. Н.Ф. Катанов болай дигән: «Казан галиме Шиһабетдин Баһаветдин углы Мәрҗанинең китабы тарихи һәм этнографик мәгълүматларга байлыгы сәбәпле, рус теленә генә түгел, Европадагы башка телләргә дә тәрҗемә ителергә лаек. Автор Болгар һәм Казан турындагы мәгълүматларын чын галимнәрчә яза. Китапның баш өлешендә Россиядә сәяхәт иткән, Болгарда булып, аның турында язып калдырган гарәп сәйяхларын: Ибне Фазланны, Ибне Баттутаны, Мәсгудине, Шәмсетдин Димәшкыйне, Санаине, ягъни X–XIV йөз галимнәрен санап чыга. Автор Болгар һәм Казан патшалыклары турында озак сөйли, аларның тарихларын гына түгел, телләрен, гореф-гадәтләрен дә күрсәтеп үтә. Бу ике патшалыктагы халыкларның билгеле өлеше, һичшиксез, төрки халыклары булганлыгы турында күп төрле тарихи дәлилләр китерә, болгарларның Казан дәүләте составына керүләре дә аларның Казан дәүләте халкы белән тел, дин, аң берлеге сәбәпле генә була алганлыгын исбат итә»[1].

---

[1] Известия общества археологии, истории и этнографии. Т. XII, вып. 4. Казань, 1898. С. 470.

Рус галимнәре Ш. Мәрҗанинең «Гыйляләтез-заман...», «Мөстәфадел-әхбар...» исемле китапларын төрле елларда кат-кат тикшерәләр, алар турында күптөрле фикерләр әйтәләр, аларны Болгар-Казан тарихын өйрәнүдә әһәмиятле бер чыганак дип таныйлар. «Мөстәфадел-әхбар»ның рус теленә тәрҗемә ителеп тә басылмый калуының сәбәбе дә башта икенче томының әзер булмавы, ә соңрак тюркология буенча эшләүнең Казаннан күчерелүе була.

Ш. Мәрҗанинең тарихи әсәрләреннән «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» («Элеккеләрнең үлүе, соңгыларның аларга бүләге») дип аталганы – зур тырышлык, озак вакыт биреп эшләнгән әсәр. Зур форматта дүрт йөз битлек «Мөкатдимә»се (кереше – 1883) белән бергә бу әсәр барлыгы җиде том. Алты томы кулъязма хәлендә Казан дәүләт университеты янындагы гыйльми китапханәнең көнчыгыш бүлегендә саклана[1]. Бу әсәрне төзү һәм язу эшендә Мәрҗани шәкертләреннән Хөсәен Фәезханов һәм Борһанетдин бине Габдерәфигъ Шәбкәви һ.б. катнашканнар: әсәрнең соңгы томы Ш. Мәрҗани үләренә 2 көн калганда язылып туктала, шулай да томнарның барысы да тулы түгел. Кайбер урыннарда язылып бетәргә тиешле ачык калган битләр бар. Күрәсең, болар өчен материалны автор җыеп өлгермәгән булса кирәк. Китапны язганда, Ш. Мәрҗани Ибне Халдуннан, Ибне Хиллякяннең «Вафиятел-әгъян», Хаҗи Хәлфә дип мәшһүр Мостафа бине Габдулланың «Кәшфез-зонун ган әсамиел көтеби вәл-фөнүн» исемле әсәреннән һ.б. күп чыганаклардан файдаланган, бигрәк тә соңгырак чорга караганнарын үзе туплаган, шәкертләре дә җыешкан булырга тиеш.

Тарихи шәхесләрнең биографиясен һәм эшчәнлеген кыскача сөйләп бирүгә багышланган бу әсәр 1 нче һиҗри (622) елда Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәдинәгә күчүе белән башланып китеп, 1306 һиҗригә (1889) кадәр вакыт эчендә узган тарихи шәхесләр (барысы алты меңнән артык кеше): хәлифәләр, пади-

---

[1] Гыйльми китапханәгә бу әсәр Галимҗан Баруди китаплары арасында алынган.

шаһлар, галимнәр, әдип һәм шагыйрьләр турында кайсы шактый озын, кайберләре кыска-кыска язылган мәгълүмат-белешмәне эченә ала. Боларның иң зур күпчелеге гарәп, иран, төрки һәм татар эшлеклеләре турында, Һиндстан һәм европалылардан берничә кеше (Петр I, Карл XII, Александр I, Наполеон I, Николай I, Александр II) турында да мәгълүмат бирелгән. Бу әсәрнең безгә бер генә нөсхәсе билгеле. Газиз Гобәйдуллин әсәрнең «мокатдимәсе»нә зур бәя бирә, «Вафиятел-әсляф»ларның башка җилдләре тарихе әшхаска гаид[1] әсәрдер. Монда төрле фәннәрдә төрле адәмнәрнең хезмәтләре вә ул адәмнәрнең тәрҗемәи хәлләре язылган... Бу әсәр тарихи лөгатьләр кебек язылмыйча, чын-чын тарихи әдәбият кебек язылган. Бу җилдләр әле һаман да табгы кылынганнары юк. Кулдан кулга берничә нөсхәсе йөри...»[2] – ди. Менә шул нөсхәләр кайда? Баруди китапханәсе аркылы гыйльми китапханәгә кергән нөсхә – беренче нөсхәме? Беренче булса, ул ник Барудига килеп кергән? Мәрҗани, үзе үлгәндә, бу китапны күчереп, бер нөсхәсен Мәдинәдәге Гариф бәй китапханәсенә җибәрергә васыять итеп калдыра. Шул васыять үтәлгәнме? Йосыф Акчура Истанбулдагы «Хәмидия» китапханәсендә «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф»ны тапканын язса да, бу «Вафиятел-әсляф...»нең үзе түгел, бәлки шуның бик нык кыскартылып язылган һәм 32 битлек булып Казанда басылган китап булырга тиеш. Ш. Мәрҗани «Рихләтел-Мәрҗани» исемле сәяхәтнамәсендә үзенең Истанбулга ул китапны алып баруын язган. Болар әле, әлбәттә, өстәмә эзләнүне сорыйлар. Һәрхәлдә, «Вафиятел-әсляф» көнчыгышны һәм татар культурасы тарихын өйрәнүдә әһәмиятле бер чыганак булып тора. Без бу җыентыкка аның «Мөкатдимә»сеннән гыйлемнәрне классификацияләүгә караган өлешен, ә «Вафият»нең үзеннән, үрнәк өчен, берничә тарихи шәхес турында язганнарны кертү белән чикләндек.

---

[1] Тарихе әшхаска гаид – аерым кешеләр тарихына караган.

[2] Мәрҗани мәҗмугасы, 1915, 334 б.

Үзенең дөньяга карашы, дөньяны аңлавы буенча Ш. Мәрҗани – идеалист. Аның идеалистлыгы – рухны, Аллаһны беренчел итеп тануында. Мәрҗани карашынча, бөтен дөньяны яратучы бер Аллаһ бар. Ләкин бу мәсьәләдә дә ул, заманының ислам галимнәреннән үзгә буларак, «дөньяның юк вакыты булганмы, ул бетәчәкме?» дигән мәсьәләләр белән шөгыльләнүне кирәк тапмаган, ул турыда сүз озайтырга яратмаган. Киресенчә, «Дөнья бетәчәк, кыямәт якын» дип ышануларны ул «зararлы һәм кешеләрне өметсезләндерүче ышану» дип санаган.

Шул ук вакытта Мәрҗанинең материаль дөньяны тануы, тормышны туктаусыз үзгәреп тора дип аңлавы, фән һәм техникага зур бәя биреп, аны таратырга тырышуы галимнең эшчәнлегендә материалистик тенденцияләрнең дә көчле булганлыгын раслыйлар. Мәрҗанинең, югарыда әйтелгәнчә, «иҗтиһад гасыры үтмәгән» дип каравы, акылны азат итәргә өндәве, тормыш һәм табигать күренешләрендә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешенә игътибар итүе аның методында диалектиканың өстенлек итүен күрсәтә.

Болар Ш. Мәрҗанигә кайдан килгән соң? Моның чыганагы кайда?

Мәрҗани әсәрләрендә без борынгы грек галимнәреннән: Аристотель, Платон, Сократ, Фалес, Анаксимен, Анаксиминдр, Пифагор, Эвклид Диоскорид, Гален, Птоломей h.б исемнәрен, караш һәм фикерләрен очратабыз.

Көнчыгышның урта гасыр галимнәре (Әбү Насыйр Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Фәраби, Әбүгали Ибне Сина h.б.) үз чиратларында грек философларының карашларын киңәйттеләр, үстерделәр. Ә борынгы грек философларының күпчелеге стихиячел материалистлар булганнар. Менә шулар Ш. Мәрҗани дөньяга карашының, дөньяны аңлавының методологик нигезендә ятканнар.

Мәгълүм ки, Европада Яңарыш эпохасы галим һәм әдипләре иң башлап борынгы грек, рим, гарәп һәм иран философларының, галим һәм әдипләренең әсәрләрен казып чыгардылар. Шуларны өйрәнү нигезендә буржуаз, ләкин буржуаларча

чикләнмәгән (Ф. Энгельс) фәнне, культураны иҗат иттеләр. Ш. Мәрҗәни да шуңа якын юл белән китте, ул да шул ук чыганаклардан үзенә азык тапты. Зур тырышлык белән алган белемен үз миендә яңадан эшләп чыгарып, яңа заман Европа һәм рус галимнәре ирешкән уңышлар белән аларны баетып, үз вакыты өчен алдынгы, кирәкле һәм яңа булган фикерләрен алга сөрде.

Заманының реакцион көчләре кыю фикерле галимгә каршы зур шау-шу күтәрделәр. «Мозһирел-кәлиматил-җарудәти, әлләти һия фин-Назурә» («Назурә» исемле китаптагы шомлы фикерләрне фаш итүче») исемле әсәрдә 1874 елда ук Ш. Мәрҗәни «динсез», «дингә каршы» дип аталды. XIX йөздә башланган бу көрәш XX йөз башында да дәвам итте һәм аның башында Түнтәр авылыннан Ишмөхәммәд мулла торды. Ул яңалыкка, прогресска каршы язган һәм 8 данә зур форматлы брошюралардан торган «Икамәтел-борһан галя әрбабис-сөбли вәл-әүһам»[1] исемле әсәрләрендә һәрберсендә диярлек Ш. Мәрҗәнине хурлый, аны «чынлыкны бутаучы» итеп күрсәтә. Гәрчә үзенең тарихтан һичбер хәбәре булмаса да, «Мөстәфадел-әхбар...»ны да «ялган чыганагы» дип атый. Галәм төзелеше, җир һәм кояш хәрәкәте турында фәнни дөреслекне яклаганы өчен аны зиндикъ, динсез дип бәяли.

Ш. Мәрҗәнине прогресс яклы кешеләр нык ихтирам иткәннәр. XIX йөздә дә, XX йөз башында да аңа багышлап күпсанлы шигырь һәм мәкаләләр чыга.

Мәрҗәни шәкертләреннән Мостафа Чутаи дигән кешенең шигырендә түбәндәге юллар бар:

Бүген Болгар илендә кемдер әгъләм?[2]
Аңа хасит[3] уланларый диям һәм.

---

[1] «Ялгыш юллар, буш хыялларны юк итү өчен дәлилләр китерү» дигән сүз.

[2] Әгъләм – иң галим.

[3] Хасит – көнче.

Фәкыйһ[1], моктәдабиһ[2] белгел, и җан:
Шиһабетдин мәнсүп би-Мәрҗан[3].
Хәким, җамигыль-голүм, фөнүн[4] ул,
Шәремдә мисле инсанел-гоюн ул[5].
Дәкаикъ хәллидә чөн мөшкяфи[6],
Идәр фәһеме аның би шик кяфи[7]
Әфләтуны заман, мәрде кямил[8],
Ирер галим, дәхи гыйльмилә гамил[9].
Ки һич вакытыны тәзъигъ итмәеп ул[10],
Тәсаниф тәәлифе илә мәшгуль[11].
Имәс максуды ул фазыйльнең илля
Җиһан эчрә мәгәр хәкъ заһир ула[12].
. . . . . .
Чү, белмәз кадрен аның һәрбер инсан,
Мәгәр гариф ула, ул әһле гыйрфан[13].
Ки кадре гәүһәр кыйммәт бәһане
Мәгәр сарраф уланлар белер аны[14].

Каюм Насыйри Мостафа Чутаиның шушы шигырен үзенең кулъязма дәфтәренә аз гына кыскартып күчереп алган[15] (бу

---

[1] Фәкыйһ – теолог.

[2] Моктәдабиһ – башкаларны иярткуче.

[3] Мәнсүп би-Мәрҗан – Мәрҗан авылына нисбәт бирелгән (Мәрҗани дип танылган).

[4] Җамигыль-голүм, фөнүн – гыйлем һәм фәннәрне үзендә туплаган.

[5] Тыйнаклыкта бөтен кешелек сыйфатын эченә алган чишмә кебек.

[6] Нечкә мәсьәләләрне чишкәндә үткен тәнкыйтьче.

[7] Аның аң көче (нечкә мәсьәләләрне чишүгә) һичшиксез җитәрлек.

[8] Заманның Платоны, камил ир кеше.

[9] Үзе галим һәм гыйлеме күрсәткәнчә эш итә.

[10] Һич вакытын бушка уздырмый.

[11] Һаман китап язу белән шөгыльләнә.

[12] Ул бөек кешенең бар максаты – дөреслекне дөньяга тарату.

[13] Бөтен кеше дә аның кадрен белеп бетерми, аның кадрен дөньяны дөрес танучы гына белә ала.

[14] Кыйммәтле ташларның бәясен бары шул ташлар белән сәүдә итүче генә белә.

[15] Казан Гыйльми китапханәсенең көнчыгыш бүлеге. Каюм Насыйри кулъязмалары. Шигырьнең төп нөсхәсе шунда ук 749 томда саклана.

урында без аның кайбер өлешләрен генә китердек). Бу – әлбәттә, Каюм Насыйриның Мәрҗәнигә уңай мөнәсәбәтен күрсәтүче бер факт. XIX йөздә шагыйрь Гали Чокрый һ.б. шагыйрьләрнең дә Мәрҗәни турында күп кенә мәрсияләре була. Шагыйрь Акмулла Мәрҗәнигә багышлап язган шигырендә аны «Галим, фазыйль, сәламәтлек чыганакларына юллар ачып, дөреслек елгаларын агызучы» дип бәяли. Аңа дошманнар, көнчеләр күп булуын, аның өстенә төрле пычрак ташлауларын яза да болай ди:

«Саф алтынны нәҗескә буяу белән,
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс...
Котырган эт һава карап өргән белән,
Асьманда[1] торган айның нуры китмәс».

XX йөз башында Ш. Мәрҗәнинең популярлыгы тагын да көчәя. Габдулла Тукай, аңа багышлап, «Шиһап хәзрәт» исемле шигырен яза. Тукай бу шигырендә Шиһабетдин Мәрҗәнине мәгърифәт ишекләрен беренче ачучылардан, башкалардан буй җитмәслек югары торучы кеше итеп бәяләде. Фатих Әмирхан Ш. Мәрҗәнигә багышланган махсус мәкаләсендә аны бөек галим һәм вакытыннан элек җитешкән каһарман итеп сурәтләде.

XIX йөз урталарындагы әдәби-иҗтимагый хәрәкәтне бик яхшы белүчеләрдән атаклы шагыйребез Мәҗит Гафури Каюм Насыйрига багышлап язган «Чулпан йолдызы» исемле мәкаләсендә болай ди: «Казан ягында, Казан каласында кемнәрдер дәһрилек, динсезлек тарата, диләр, татар дөньясы эченә явызлык салу нияте белән хыяллана, диләр.

– Динне бозучылар, кяферләр! – дигән тавышлар чыга башлый.

– Шиһап, диләр, «Сукыр Каюм», диләр. Тагы да берничә кешенең исемен кушып, боларның эт кадерләрен калдырмый сүгәргә керешәләр...

Дин һәм иске тормыш җимерелергә, тузарга якынлашкан кебек күренә.

---

[1] Асьманда – күктә.

Халыкка исемнәре мәгълүм булып та бетмәгән Шиһап, «Сукыр Каюм»нарны динсезлектә һәм кяферлектә гаепләп, халык күзеннән төшерергә бөтен көчләрен сарыф итәләр. Булмый... искелек терәкләре үзләрендә көчсезлек хис итәләр»[1]. [...]

Октябрьгә чаклы чорда Шиһабетдин Мәржәнинең эшчәнлегенә, биографиясенә бәйләнешле зур күләмле җыентык чыгарылды, әмма аның хезмәтләрен халкыбызга җиткерү чаралары күрелмәде. Безнең бу сайланма җыентык әнә шул юлда беренче тәҗрибә булып тора.

Х. Хисмәтуллин

[1] Мәкалә 1922 ел (№ 85) «Башкортстан хәбәрләре» газетасында басылган. Текст Мәҗит Гафури әсәрләренең VI томыннан алынды (Уфа, 1957 ел).

«МӨКАТДИМӘТЕ КИТАБЕ «ВАФИЯТЕЛ-ӘСЛЯФ ВӘ ТӘХИЯТЕЛ-ӘХЛЯФ»ТАН КЫСКАРТЫЛГАН ТӘРҖЕМӘЛӘР

Фасыл[1]

Гыйлемнәр һәм аның бүлекләре, фәннәр һәм аның төрләре, сәнгать һәм аның тармаклары, мәгариф һәм аның төркемнәре, аларны белүчеләрнең иң олылары, иң белгечләре турында.

Бел: культуралы кешелек җәмгыятендә гыйлемнәр ике төркемгә бүленәләр.

Беренче төркеме – гакли гыйлемнәр.

Гакли гыйлемнәр кеше өчен табигый: кеше аларга табигый рәвештә юнәлә, уйлау аркылы ирешә, кешелек сәләте ярдәмендә аның темаларына, мәсьәләләренә, дәлил китерү һәм нәтиҗә чыгару юлларына төшенә, хәтта аның карашы һәм бәхәсе әлеге гыйлемнәрнең күрсәткечләренә, өйрәтү юлларына туктала; дөресне хатадан аеруга фикер иясе – кеше хикмәт фәннәре, фәлсәфә гыйлемнәре аркылы ирешә.

Икенчесе – нәкъли, ягъни күчерелмә гыйлемнәр. Болар вазыйг – авторитетлы – кешеләр тарафыннан әйтелгән, ишетелгән хәбәрләргә таянып торган эш һәм хәлләрдән гыйбарәт. Бу гыйлемнәрнең төркемнәре күп, мөселманнарда болар Коръән яки хәдисне дәлил итү, шуларга таянып гомум мөселманнарның чыгарган карарын – иҗмагны, ул дәлилләрнең сәбәбе табылган бүтән очракларга да шул хөкемнәрне җәю аркылы билгеләнәләр. Үзенә, үзе кебекләргә Аллаһ тарафыннан йөкләнгән хөкемнәрне белү һәрбер акылы сәламәт кешегә вәҗиб. Моның өчен китаптагы хөкемнәрнең ничек хәбәр ителгәнлекләрен, пәйгамбәргә ничек барып җиткәнлеген белергә кирәк. Чөнки Коръән Аллаһтан пәйгамбәр аркылы килгән; аның ничек укылышы, хәбәр ителү юллары, галимнәр һәм риваять итүчеләр арасында бу турыдагы ихтиляфлар турындагы гыйлем – кыйраәт гыйлеме була. Коръән аятьләренең тәртибе һәм максатлары, иңүенең сәбәпләре, нәсех ителгәннәре (көчләре бетерелгәннәре), грамматик төзелеше, максатка ярашулы рәвештә мәгънә аңлатуда тел һәм өслүбенең югарылыгы турындагы гыйлем – тәфсир гыйлеме була.

---

[1] Мөкатдимәте Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф. Казан, 1883. 210 б. Бу бүлектә фәннәргә классификация мәсьәләсе тикшерелә.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең сүзе, эше рәвешендә килгән хөкемнәрнең, шулай ук сәхабәләр[1], табигыйннәр[2], дин галимнәре тарафыннан аларга өстәлгәннәрнең дөреслегенә, алар белән гамәлнең вәҗиб булуына ышаныч хасил итү өчен, аларны күчереп риваять итүчеләрнең гаделлекләре һәм төп чыганакларына ничек барып тоташканлыкларын бәян итү – хәдис гыйлеме эше була, һәм ул бик күп тармакларга бүленә.

Шулай ук гарәп теле гыйлемен белү зарур, чөнки ул шәригатьне тарату һәм ислам милләтен дөньяга чыгаруда төп корал булган. Чөнки Коръән гарәп телендә, шул тел өслүбенең югары дәрәҗәсендә килгән; хәдис тә шул телдә сөйләнде. Гарәпләр элек, беренче гасырның баштагы елларында укый-яза белмәгәннәр; тәҗрибә юклыктан, бар тәҗрибәне гомумиләштерүнең азлыгыннан аларда медицина һәм йолдызчылык гыйлеменнән генә бик аз нәрсә бар иде. Шул ук вакытта болар югары фикерле, үткен хәтерле, матур телле иделәр. Болар кинәттән шигырь төзергә сәләтле булганнар, шуның белән алар максатка ирешүдә, файдалы эшләрне күбәйтүдә иң матур сөйләм һәм иң өстен сүз тәртибенә ирешәләр, башкалар исә төн йокламый тырышып уйласалар да, аңа көчләре җитмәслек булган. Аларның бүтән эшләре булмаганлыктан, бөтен көчләрен телләрен үткенәйтүгә, бизәүгә, аны нигезле рәвештә өйрәнүгә сарыф иттеләр, хәтта алар бу турыда төрле караш һәм агымнар тудырдылар, аларны гаять камилләштерделәр. Моңа үзләрендә булган үткенлек, табигый сәләт ярдәм итте; алар телдәге һәрбер кагыйдә өчен, акылга муафыйк дәлилләр төзеделәр һәм телләре сүз ягыннан традицион, ә кагыйдәләре ягыннан акылга туры килә торган булды.

Ислам килеп чыккангача эш шулай дәвам итте. Аннан соң гаҗәмнәр, ягъни төрле чит кабиләләр белән аралашу көчәйде. Сүзләр катнашу башланды, гарәп теленең бозылу куркынычы туды. Бу арада гарәп дәүләте ныгыды, башка халыкларда булмаган уртак һәм культуралы тормышка күчелде. Телне саклау өчен

---

[1] Сәхабә – пәйгамбәр белән бергә булган мөселманнар.

[2] Табигыйн – пәйгамбәрне күрмәгән, сәхабәләр белән бергә булган мөселманнар.

дә тиешле чаралар күрелде, аның төгәл кагыйдәләре, төзелеп, системага куелды.

Сүзләрне грамматик үзгәртмичә, мәгънәләрен белдерә торган гыйлем – лөгать гыйлеме, тел гыйлеменең мәтене[1]. Сүзләрнең мәгънәне үзгәртерлек рәвештә грамматик үзгәрешләрен тикшерә торган гыйлем сарыф гыйлеме – морфология була. Мәгънәле сүзләрне кушу-теркәүне тикшерә торган гыйлем – игъраб гыйлеме – синтаксис була. Сүзләрнең теркәү-кушу аркылы максут булган мәгънәгә ярашуларын тикшерүче гыйлем мәган гыйлеме була. Бер-беренә башка-башка юллар белән бер үк мәгънәне белдерүне тикшерә торган гыйлем – бәян гыйлеме. Сөйләмне матурлату, сурәтле итүне тикшерә торган гыйлем бәдигъ гыйлеме дип атала. Тезмә сөйләмнең юл ахырлары килешеп тикшерә торган гыйлем – кафия гыйлеме. Шигырь үлчәүләрен тикшерүче гыйлем гаруз гыйлеме була. Шулай итеп, этимология, синтаксис, шигырь төзелеше, чәчмә сөйләм, тезмә һәм чәчмә сөйләмнең художестволылыгы, сөйләү, хәрефләрнең әйтелеше, язу, әдәбият гыйлеме һәм аларга бәйләнешле, озын итеп сөйләнгән хөкемнәр барысы да ислам дәверендә барлыкка килделәр һәм аңа махсуслар[2]. (210–212 б.)

Гыйльме лөгать – лексикология – сүзләрнең төп куелышлары буенча нигез сүзләрнең һәм кисәкләрнең асыл мәгънәләрен белдерә торган гыйлем. Утрак тормышка күчү, гарәп түгел халыклар белән катнашу сәбәпле, гарәп телендә сөйләгәндә һәм язганда, сүзләрнең ахырларын дөрес кулланмау нигезендә грамматик төзелеш бозыла башлады, бу бозылу хәтта сүзләргә синтаксик үзгәрешләр кертүдән үтеп, аларның мәгънәләренә дә тәэсир итте. Гарәпчәне яхшы белмәстән, гарәпләшкән булып сөйләтүчеләрнең кимчелекләрен искә алмаганда да, күп кенә гарәп сүзләре куелган мәгънәләреннән башка мәгънәдә кулланыла башлады. Шуннан соң телнең бөтенләй югалуыннан һәм

[1] Мәтене – конспекты, башы.

[2] *Искәрмә:* Ш. Мәрҗанинең мәган, бәян, бәдигъ гыйлеме дип исемләгәннәре хәзер әдәбият теориясенең стилистика дигән бүлегенә керә һәм болар гарәп теленә карата бик җентекле эшләнгәннәр.

шуның аркасында Коръән һәм хәдисне аңлый алмаслык хәлгә килүдән куркып, сүзләрнең мәгънәләрен язып, кагыйдәләр төзеп телне саклау ихтыяҗы туды. Шуннан халыкның атаклы кешеләре, тел белгечләренең күбесе ашыгыч рәвештә шушы эшкә керештеләр, диваннар төзеделәр[1].

Гыйльме сарыф – морфология. Бу гыйлемдә мәгълүм системадагы сүзләрнең төрләре, мәгънәләре, уртак булган нигез формалары, үзгәреш рәвешләре, төп формалардан күчүләре һәм бу күчүнең сәбәпләре, мәсьәләләре тикшерелә.

Бу гыйлемне иң элек башлап җибәрүче – Мәгазь әл-Һәреә кайбер – риваятьләргә караганда, Әбү Госман әл-Мазини. Бу өлкәдә нигез әсәрләр – әл-Мазини, әл-Мәлүки һ.б. китаплары.

Нәхү гыйлеме – синтаксис – тел гыйлемнәренең иң бөеге, хөрмәтлесе, чөнки ул, кариларның олы юлы һәм баручыларга юлны яктыртучы шәм; мәгънәнең аныклануы һәм сүзләрнең төрләнеше дә аннан килә. Сүз һәм мәгънә уйнату да шуның аркасында. (256 б.)

Шигырь сәнгате гыйлеме. Шигырь ул – гарәпләрнең диваны. Анда аларның гыйлемнәре, хәбәрләре, фәлсәфәләре тупланган; шигырь аларның олылык һәм юмартлыкларының, турылык һәм хаталарының шаһите. (261 б.)

Тарих гыйлеме. Бу гыйлем узгандагы халыкларның хәлләрен[2] сөйләп, аларның күркәм эшләрен белдерергә, элеккерәк заманда яшәп тә дөрес һәм изге юлдан баручыларга иярергә өнди. Чөнки тарихта кешеләрнең исемнәре, кушаматлары, нәсел-нәсәпләре белән беркетелеп сөйләнә, язмалары, әсәрләре,

---

[1] *Искәрмә:* Моннан соң Ш. Мәрҗани гарәп лөгате өстендә эшләгән төрле галимнәрне һәм аларның тел белеменә нинди өлеш кертүләрен санап китә. 254–256 б.

[2] «Үткән заманнарда яшәгән халыкларны, аларның сугышларын» мәгънәсендә. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

гыйлем дәрәҗәләре, төрле халыкларның һөнәрләре, зарарлы һәм файдалы эшләре күрсәтелә. Ул – төрле халык һәм кабиләләрнең башларыннан үткәнне, патшалар һәм, гомумән, җитәкчеләрнең дуслашу һәм ызгышуларын сөйли торган гыйлем; гади кешеләр һәм ваемсызлар да аны белергә телиләр; аны галимнәр дә, наданнар да аңлыйлар; атлылар да, җәяүлеләр дә аңа омтылалар; чөнки ул, тыштан караганда, көннәр һәм дәүләтләр турындагы хәбәрләрдән, әүвәлге еллар һәм гасырларда булган вакыйгаларны хикәяләүдән гыйбарәт; анда төрле сүзләр күп була, үткәндәгеләрнең үрнәк булырлык хәлләре һәм мәкальләре китерелә; зур җыелышларда, тантаналы утырышларда тарих сөйләнә. Ул безгә табигатьнең, тормышның хәлен, аның үзгәрешен, дәүләтләрнең киңәюен сөйли. Тарих гыйлеменең әүвәле – мөмкинлек (көч җитү), дәвамы – яшәү һәм үлем хәбәре килеп, бетү вакыты якынлашканчы төзү эшләре белән шөгыльләнү. Болар өстән караганда шулай. Әмма эчтән, ныклап уйласаң, тарихның төбе – тирән хикмәткә ирештерә торган тикшерү һәм җентекләү. Чөнки ул вакыйгаларның ни рәвешле булганлыкларын, тирән сәбәпләрен, барның ник бар булуын һәм аның иң нечкә нигезләрен ача. Шуның өчен дә аны барлык нәрсәне белдерүче уку йорты, алай гына да түгел, бәлки гыйлем һәм мәгарифнең чын анасы дип атадылар.

Ислам галимнәренең иң олылары бу фәндә күп китаплар яздылар, алар көн дә булып торган хәбәрләрнең барысын да җыйдылар, күп дәфтәрләргә теркәделәр, аларга элекке һәм яңа булган вакыйгаларны беркеттеләр, китапларны күбәйттеләр, борынгы халыкларның тарихларын бәян иттеләр; болардан иң мәшһүр һәм ышанычлылары – Мөхәммәд бине Исхак бине әл-Кәләби, Мөхәммәд бине Гомәр әл-Вахиди, Әбү Җәгъфәр әт-Табари, Сәеф бине Гомәр әл-Әсәди, әл-Мәсгуди, әл-Хатыйп Әбү Бәкер әл-Багдади, Әбү Нәгыйм әл-Әсбәһани, Әбү әл-Касыйм бине Гасакир, Әбү Сәгыйд әс-Сәмгани һәм болар дәрәҗәсендә шөһрәткә ия булмаган тагын бик күпләр.

Боларның кайберләре милләт, яки дәүләт, яки төрле шәһәрләр турындагы хәбәрләрне тупладылар. Кайберләре дин яки мәзһәб

башлыклары, тарикатъ һәм идеологик яки сәяси юнәлеш ияләре турында язды. Кайберләре гыйлем һәм сәнәгать кешеләре турында яздылар, яки эш башындагы дәүләтле кешеләр турындагы хәбәрләрне җыйдылар ки, анда дәүләт тә, шәһәр дә, мәзһәб ияләре, җәмәгать, гыйлем һәм сәнәгать, фән һәм тарикать – берсе дә төшеп калмыйча, әсәр тулы тарих һәм барлык шушы хәлләрне эченә алган китап булды. Мәсәлән, Багдад, Күфә, Басра, Васит, Кодес, Димәшкъ, Хәләб, Шам, Мисыр, Ямән, Хиҗаз, Мәккә, Мәдинә, Һәмәдан, Әсбәһан, Казвин, Мәрвә, Нишапур, Һират, Бәлех, Бохара, Сәмәрканд, Кәш тарихлары; хәлифәләр, солтаннар, патшалар, вәзирләр, аларның хөкем һәм карарлары тарихы; тәфсирчеләр, карилар, фәкыйһләр[1], хафизлар[2], шагыйрьләр, грамматика, лексикология һәм әдәбият белгечләре тарихы; хәнәфиләр, шәфигыйләр, маликиләр, хәнбәлиләр; тәсаувыфчылар, могтәзиләләр, шигыйлар тарихы; хариҗиләр[3] турындагы хәбәрләр; Басра казыйлары; Мисырдагы идарә тәртипләре һ.б. (265–266 б.)

Нәсәп гыйлеме – генеалогия – кадере һәм файдасы бик зур булган гыйлем. Гарәпләр аңа исламга чаклы да, исламнан соң да зур әһәмият бирделәр. Мөселманнар бу фәннән бик күп китаплар, атаклы җыентыклар төзеделәр. Нәсәп фәненең имамы, бу өлкәдә беренче ишекне ачучы һәм беренче китапны төзүче кеше Һәшам бине Мөхәммәд бине әс-Саибе әл-Кәләби (Аллаһ аңа рәхмәт кылсын); кешеләр аның үрнәгендә эшләргә тырышсыннар. Аның нәсәп турында «Мөнһәл», «Җәмһәре», «Вәҗиз», «Фәрид», «Мөлүки» исемле биш китабы бар. Аның бу өлкәдәге белеме турында акылларны хәйран калдырырлык хәбәрләр бар. Әбү Мөхәммәд Габделмәлик бине Һашим бине Әюп әл-Химьяри әл-Мәгафири Химьяриләр[4] нәсәбе турында, Әбү әл-Хәсән Әхмәд бине Яхья әл-Бәлазири – Әшраф нәсәбе турында, Әбү әл-Фәрәҗ әл-Әсбәһанинең һәм бу турыда язган берничә китабы бар.

---

[1] Фәкыйһ – дин галиме, теолог.

[2] Хафиз – Коръәнне күңелдән белүче.

[3] Могтәзилә, шигый, хариҗи – ислам динендәге аерым бер юнәлешләр һәм төркемнәр.

[4] Химьяри – Йәмәндә исламга чаклы булган дәүләт.

Мөселманнарда бу гыйлемнең тармак һәм төркемнәре күп һәм мәшһүр, хәтта кайберәүләр аның дүрт йөз утыз жиде төркеме бар дип саныйлар.

Тәфсилләп сөйләү сүзне озайта, кызыксынучылар өчен шушысы да житә... (267–268 б.)

Гакли гыйлемнәрнең төркемнәре

Күп тармаклы бу гыйлемнәрне кеше үзенең табигый фикере, уй көче белән төшенә. Кеше бу гыйлемнәрнең темаларын, мәсьәләләрен, аларга кирәкле дәлилләрне табигать теләгән нәрсәләрне булдыру юлында эшләп килгән фикер иясенә үзлекле булган акыл көче белән таба. Шуңа күрә фикер иясе үзе белмәгәннәрне белү белән кызыксына; ул я үзеннән элек булган ачышлар белән шөгыльләнә, яки алардан алгарак китә, яки аларга үз тикшерүләре белән ирешә, яки үзеннән элекке галимнәрнең хезмәтләреннән ала, шул рәвешчә, гыйльми мәсьәләләрне аңларга, белергә тырыша; аның уе-фикере төрле хакыйкатьләргә бер-бер артлы юнәлә, аларга бәйләнешләрне торган саен күбрәк күрә бара, тикшерү сәләте үсә, мәгълүм хакыйкатькә өстәмә ачышлар ясарга өйрәнә; яңа ачылган хакыйкатьләр һәм аңа өстәлмәләр махсус гыйлем булып житешәләр, бу кешедән соңгылар ул гыйлемне өйрәнергә омтылалар, аны белүчеләргә мөрәжәгать итәләр һәм, шулай итеп, ул укыту предметы булып әверелә.

Бу гакли гыйлемнәр, фикер иясе, кешеләрнең табигате, табигый сәләте белән ирешелгәнгә күрә, бер милләткә генә хас түгелләр, аларны тикшерү, иҗат итүдә барлык милләтләр тигез хокуклы. Гакли гыйлемнәр кеше барлыкка килгәннән бирле яшәп килә һәм үсә.

Сирьянилар, кәлданилар, аларның гасырдашлары булган төрекләр, кыйбтыйлар төрле фәннәргә игътибар белән карадылар; алардан бу фәннәр юнан[1] һәм фарсыларга күчте. Аларның хөкүмәтләре көчле, тормышлары культуралы, иркен һәм мул булганлыктан, бу гыйлем базары аларга зур файда бирде. Гыйлем диңгезләре шәһәрләренә һәм илнең ерак өлкәләренә чаклы

[1] Юнан – грек.

ташып актылар. Бу гакли гыйлемнәрнең алар арасында урыны киң булды, һәммә җиргә җәелеп таралды.

Боларның тәгълиматы Даут галәйһиссәламнән, Локман хәкимнән, аларның шәкертләре Фисагурс[1] һәм Сократтан, аның шәкерте Аристотель, аның шәкерте Искәндәр әл-Әфридуси һәм Самстыюн һ.б. килә. Аристотель юнан патшасы Искәндәрнең укытучысы иде. Искәндәр, фарсыларны җиңеп, аларның дәүләтләрен үз кулына алды, фарсы патшаларыннан Дара ибне Дараны үтерде, ул бу гыйлемнәрне үзләштерүче патшаларның алдынгысы, даны бик еракларга таралганнарның элгәрегесе иде. Аристотель беренче мөгаллим дип аталды һәм хөрмәт белән сөйләнүче, олылык белән дан тотучы булды.

Аннан элек «Әсатыйн әл-хөкәма» дип дан алган җиде хәким бар иде. Болар: Салис, Анбаз Кылес – Мәлтыя кешеләре; Фисагурс бине Мәсархс – самиялеләрдән; Сократ бине Сускыюс – Афина кешеләреннән; Әфләтун[2] бине Әрстын бине Әрстуфилс әл-Иляһи – бу – философлыгы, бер Аллаһны тануы һәм мәгърифәте белән танылган һәм Ксатыйнның соңгысы, өлкән буын хәкимнәрнең ахыргысы, Әршин бине Дара заманында аның падишаһлыгының 16 нчы елында туды, Сократның шәкерте иде. Үз халкының ышануларына каршы чыккан өчен Сократ агу биреп үтерелгәч, Әфләтун аның урынын алды, аның тәхетенә утырды[3].

Юнан дәүләте җимерелеп, кайсарлар дәвере һәм христианлык килгәч, бу хикмәт гыйлемнәрен (антик философияне) тыйдылар, уку-укытуны туктаттылар. Ул гыйлемнәр китап хәзинәсендәге китапларда гына сакланып калды. Шам шәһәрләре кайсарлар мәмләкәтенә, Гыйрак һәм гарәп шәһәрләре фарсы мәмләкәтенә кергән иде. Бу хикмәт гыйлемнәренең китаплары да шушы якларда сакланып, шунда таратылды.

Соңыннан Аллаһ тарафыннан ислам килде, һәм ул дин ияләре тиңдәшләре булмаган рәвештә күтәрелеп чыктылар.

---

[1] Фисагурс – Пифагор.

[2] Әфләтун – Платон.

[3] Тәхетенә утырды – шәкертләренең җитәкчесе булды.

Румнарны, фарсыларны җиңеп, башка халыклардан басып алган җирләрен, мөлкәтләрен тартып алдылар. Хөкүмәт һәм патшалык ныгып көчәйде. Алар утраклыктан һәм культурадан башка халыкларга караганда күбрәк файдаландылар. Гыйлемдә, һөнәрдә киң һәм тирән белемле булдылар. Аңарга чаклы белмәгән, әмма кеше фикерен үстерә торган гыйлемнәрне өйрәнү белән кызыксындылар. Әмирел-мөәминин Әбү Җәгъфәр әл-Мансур, төрле фәннәрдән китаплар сорап, Рум патшасына илчеләр җибәрде. Рум патшасы аңа Эвклид әсәрләрен, табигать гыйлеменнән кайбер китапларны биреп, илчеләр җибәрде. Мөселманнар бу китапларны укыдылар һәм калганнарны да кулга төшереп уку теләкләре артты. Җәгъфәр әл-Мансур урынына аның оныгы Рәшид әмирел-мөәминин булды. Аның заманында грек философларының китаплары белән кызыксыну, аларны табу, үз итү чараларын күрү тагын көчәйде. Рәшиднең улы әмирел-мөәминин Мәәмүн гыйлем сөюче, тырыш, зирәк һәм үткен, сәламәт табигатьле, төрле фәннәрдән мәгълүматлы кеше иде. Ул зур дәрт белән төрле гыйлемнәрне тергезергә кереште. Греклардагы гыйлемнәрнең табылганнарын гарәп язуына күчерү һәм гарәп теленә тәрҗемә итү өчен[1], грек патшаларына

[1] Гаҗәм (гарәпкә башкалар) теленнән гарәп теленә беренче тәрҗемә ителгән китаплар: «Кәлилә вә Димнә» һәм «Сәнд һинд» китаплары булды. Мантыйктан һ.б. Аристотель китаплары, Бәтъләмиюсның «Әл-мәҗсәти» исемле китабы, «Әл-әртиматыйкый» һәм Әкълидс китабы, юнан, рум, пәһләви, фарсы, сирьяни телләрендәге башка китаплар тәрҗемә ителделәр. Болар кешеләр каравына чыктылар, аларны карадылар, андагы гыйлемнәрне өйрәнделәр, шул көннәрдә Мөхәммәд бине Исхак «Китабел-мәгази вәс-сәер вә әхбарел-мөбтәда» китабын язды. Моңарчы җыентыклар юк, андыйларны төзү гадәте дә юк иде. Ул (әл-Мәәмүн) үзенең малын, хезмәткәрләрен иң әһәмияттәләрен файдаланды, аларны гарәпләргә тәкъдим итүче беренче хәлифә булды. Моннан соңгы хәлифәләр бу эшләрне моның улы кулыннан алдылар, нәтиҗәдә гарәпләр түбәнәюгә, һәлакәткә йөз тоттылар, гыйлемнәрнең көче зәгыйфьләнде, мәртәбәсе бетте; шуннан хәлифәлек яңадан аңа кайтты, ул гыйлемнәрне тикшерде, мәзһәбләрне өйрәнде, төрле карашларны чагыштырды, төрле хәбәрләр һәм хәдис китапларына төшенде, һәм аның заманында төрле риваятьләр күбәйде, гыйлемнәре киңәйде; Кәһир: «Мәсгуди рәхмәтуллаһи галәйһи мәзһәбен өйрәттем, күркәм таптым, аңлатып бәян иттем һәм таралуына булыштым», – диде. *Китапның кырыена өстәлгән белешмә.*

илчеләр җибәрде. Тәрҗемәләр өйрәнелеп ядка алынды, тулысынча үзләштерелде. Бу эшне мөселманнар берөзлексез тикшереп, күзәтеп тордылар. Шулай итеп, алар грекларның барлык фәннәрендә киң, төпле гыйлемгә ия булдылар һәм бу гыйлемнәрне тикшереп өйрәнүләре тәмам булды. Алар бу гыйлемнәрне алдан килеп үткән галимнәрнекенә караганда үстерделәр, соңгылардан өстен булдылар. Әүвәлгеләрнең карашларына каршы чыгып, фикерләрен кире кагып, җитешмәгән якларын күрсәттеләр. Бу гыйлемнәр бик күп төрле, ул өлкәдә эшләүчеләр дә күп төркемнәргә бүленгән. Мөселманнар арасында аларның олылары – көнчыгыш шәһәрләреннән, Иран һәм Хорасаннан – Әбү Насыйр әл-Фәраби һәм Әбү Гали Ибне Сина; Көнбатыш шәһәрләреннән, Африка һәм Әндәлестән – казый Әбү әл-Вәлид Мөхәммәд бине Әхмәд, Мөхәммәд бине Рөшд, вәзир Әбү Бәкер бине әс-Саег.

Юнан, рум, пәһләви, фарсы, сирьяни, нәбатыя, һинд һ.б. телләрдән хикмәт гыйлемнәре гарәп теленә тәрҗемә ителделәр. Бу китапларны тәрҗемә иттерүчеләрнең беренчесе әмирелмөэминин әл-Мансур булды. Бу тәрҗемәләр таратылдылар, кешеләр андагы гыйлемнәр белән таныштылар, ләкин бу тәрҗемәләр каршылыклы, чуалчык, рәтләп язылмаганнар, нәтиҗәләр чыгарылмаган иде. Әбү Насыйр әл-Фәраби (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) килде, ул бу гыйлемнәрне яхшы белә иде; шушы тәрҗемәләрне җыйды, аларны хикмәткә һәм вакыйгка муафыйк рәвештә кыскартып, дөресләп, кирәксезләрен оста гына ташлап, иң кирәкләрен сөзеп алды һәм аның китабы – «Икенче өйрәтүче» дип, үзе «Икенче мөгаллим» дип исемләнде.

Мансур, Рәшид, Мәәмүн һәм алардан соңгы башка хәлифәләр кушуы буенча грек теленнән тәрҗемә итүчеләр: әл-Бәтрыйк һәм аның улы Яхъя, әл-Хоҗҗаҗ бине Мәтыр, Сәлам әл-Әбрәш, Габделмәсих бине Нагыймә әл-Хәмсый, Хөсәен бине Бәтрыйк, Һилал бине Әбү Һилал – әл-Хәмсый, Ибне Үәй, Әбү әл-Фәрәҗ бине әс-Саләт, Яхъя бине Гали, Ибне Рабига, Гыйса бине Нух, Кыста бине Лука әл-Бәгальбәки, Хәнин бине Исхак, Сабит бине Коррә, Ибраһим бине әс-Саләт.

Фарсы теленнән: Габдулла бине әл-Мокаффә, Муса һәм Йосыф бине Халит, Хәсән бине Сәһел һәм әл-Бәлазури.

Һинд теленнән: Минкәт әл-Һинди, Кәбтыя теленнән: Әбү Бәкер Әхмәд бине Гали, ибне әл-Вәхшия h.б.

Мөхәммәд бине Габделкәрим әш-Шәһрестани үзенең «Әл-миләлә вән-нөхәл» исемле китабында Ягъкуб бине Исхак әл-Кәнди, Хәнин бине Исхак, Яхъя ән-Нәхәви, Әбү әл-Фәрәҗ әл-Мөфәссир, Әбү Сөләйман әс-Сәҗзи, Әбү Сөләйман бине Сәгыйд әл-Мөкаддәси, Әбү Бәкер Сабит бине Коррә әл-Хәрани, Әбү Тәмам Йосыф бине Мөхәммәд ән-Нишапури, Әбү Зәед Әхмәд бине Сәһел әл-Бәлхи, Әбү әл-Харис, Хәсән бине Сәһел бине Мөхариб әл-Комми, Әхмәд бине әт-Таиб әс-Сәрхәси, Тальхә бине Мөхәммәд ән-Нәсәфи, Әбү Хәмид Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Әсфәраини, Гыйса бине Гали әл-Вәзир, Әбү Гали Әхмәд бине Мөхәммәд бине Мәскуя әл-Хазин, Әбү Зәкәрия Яхъя бине Гали әс-Саймәри, Әбү әл-Хәсән әл-Гамири, Әбү Насыйр Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Тархан бине Әвезләгъ әл-Фәраби h.б. торган бер төркемне санады.

Ислам хәкимнәрен шул рәвешчә санагач, Шәһрестани болай ди: «Халыкның иң атаклы белгече Әбү Гали Хөсәен бине Габдулла Ибне Сина булганга, аның юлы халык тарафыннан кабул ителгәнгә, аның карашлары хакыйкатькә тирәнрәк чумганга, мин аның китапларындагы фикерләрнең каймагын, нәкъ үз сүзләре, үз максатлары кебек итеп күчерергә уйладым, ә башкаларның юлларын һәм мәзһәбләрен күчермәдем. «Һәр олылык – яхшылыкта».

«Ике мөгаллим» – аларның беренчесе: юнанлы Аристотель, икенчесе – Әбү Насыйр әл-Фәраби. Ямәндә хикмәт мөгаллиме – әс-Сәед Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Исбәһани[1], гыйлемнәрне һәм тарикатьләрне[2] ачучы һәм киңәйтүче.

---

[1] Ш. Саминең «Камус»ында иранлы «Мөхәммәд Бакыр Домод (Мир бине Сәед, 1040 елда үлгән) күрсәтелә. Ләкин аның Ямәндә булганлыгы әйтелми. Монда шул кеше күздә тотыламы, түгелме – ачыклана алмады.

[2] Тарикать – дин өлкәсендә агым, юнәлеш.

Ике шәех – Әбү Насыйр һәм Әбү Гали[1] һәм Әбү әл-Фөтүх әс-Сөһрәварди[2]; икенчеләр карашынча, бу шәехләрнең икенчесе – шәехле ибне Рөшд Әбү әл-Вәлид Мөхәммәд бине Мөхәммәд. Бу кеше «Мөрабитыйн»нар дәүләтендә; аның шул ук исемдәге улының улы – «Мөвәххидин»нәр дәүләтендә казый булган.

Бел: наданлык һәм гыйлем ияләренә дошманлык һәм көнчелек сәбәпле генә хикмәтне инкяр иткән, мәгърифәткә дошман, акылга каршы киткән кешеләр бар. Алар – кабахәтләр, аларның аз-маз һөнәренә һәм белеменә ышаныч һәм игътибар юк. Чын мәгънәсе белән гыйлем дип аталырлык һичбер нәрсә инкяр ителә һәм хурлана алмый.

Бер-бер нәрсәне ясаучылар яки күзәтүчеләр ялгышалар икән, бу әле әйбернең үзенең кимчелеген, аңа бәйләнешле фәннең дөрес түгеллеген күрсәтми, бәлки эшләүчеләрнең ялгышуы дип каралып, шуларга ук кире кайтарыла; нәкъ шуның кебек, берәр хөкемне шәригатькә нисбәт бирүчеләр һәм шуны белүчеләр ялгышалар икән, аннан шәригатьнең кимчелеге яки ярамсызлыгы килеп чыкмый. Ибне Мәсгут (Аллаһ аннан разый булсын) әйткән: «Әгәр минем сүзем дөрес икән, ул – Аллаһдан, әгәр ялгыш икән – ул минем үземнән һәм шайтаннан».

Барлык гыйлемнәр дә шуның кебек. Бер гыйлемне белүченең шул гыйлемгә нисбәт биреп сөйләгән сүзләрендәге яки аңа нисбәт бирүдәге хаталарын гыйлемнең үзенә сылтарга ярамаган кебек, гыйлемнең үзен дә хурларга ярамый. Бер фәнне белгән кешенең үзе белмәгән фәнне кимсетүе дә дөрес түгел: гыйлем өйрәнүчегә юлны киң кылып, аның күңелен табарга, хәтерен сакларга кирәк, гыйлемне барлык кешеләр дә яратып бетермәгән

---

[1] Әбү Гали – Әбү Гали Ибне Сина истә тотыла булса кирәк.

[2] Әбү әл-Фөтүх әс-Сөһрәварди – Ш. Сами бу кешене бер урында «Яхъя бине Хөсәен», икенче урында «Яхъя бине Хәбәш» дип исемли. Сөһрәвард – төньяк-көнбатыш Иранда кечкенә бер шәһәр. Әбү әл-Фөтүх (549–585 һижри) – зур галим, азат фикер иясе. Аның шөһрәтеннән көнләшкән галимнәрнең шикаяте сәбәпле, солтан Сәлахетдин Әюби боерыгы белән Хәләб шәһәрендә үтерелгән.

кебек, бер гыйлемне яратучыдан башка гыйлемнәрне дә яратуын таләп итеп булмый. Чөнки гыйлемнәр төрле булган кебек, аларның максатлары да төрле. Кешеләрнең аларны аңлаудагы сәләтләре дә төрле-төрле.

Гыйлемдәге башкалар ялгыш дип санаган карашларны белү дә файдасыз түгел: иң азында ул әлеге карашларны яклаучыларны кире кагу һәм шул ялгышның авына эләкмәү өчен кирәк. Хөзәйфә бине әл-Еман (Аллаһ аннан разый булсын) әйткән: «Кешеләр пәйгамбәр галәйһиссәламнән нинди эшләрнең изге булулары турында, ә мин, гөнаһ эшләүдән куркып, нинди эшләрнең явызлык икәнлеге турында сорый идем. Мин белә идем: изге эш миңа зарар китерми, һәм явызлыкны белмәгән изгелекне дә белми...» (302 б.)

Бер фикерне аңлап, нигезенә төшенеп җитмичә кире кагу – сукыр килеш ук ату һәм наданлыктан килгән аңсызлык ул.

Йолдызчылар сүзен берәү инкяр итә икән, ул аны фәкать чама белән генә әйтелгәнгә һәм алар сүзенең туры килүе бик сирәк булганга күрә инкяр итә. Чөнки йолдызчы үзенең бу һөнәрендә кайбер чараларга ия булса да, ләкин әле йолдызларны өйрәнү һәм алар буенча нәрсәдер әйтү өчен кирәкле, әмма кеше көченнән тыш булган бик күп сәбәпләр, шартлар бар. Кеше болытның җыелганын, хәрәкәтен күрсә, яңгыр явар дип уйлый, ә болыт булу гына яңгыр явар өчен җитәрлек сәбәп түгел, ә бүтән сәбәпләрне ул белми, ә күп вакыт болытлар тарала, кояш чыккач, көн яктыра; диңгезче үзе ияләнгән җилгә ышана, көймәсе гадәт буенча сәламәт йөзәр дип уйлый; ә монда тагын бик күп яшерен сәбәпләр бар ки, диңгезче аларны белми, шуңа күрә кайчакта аның уе туры, ә кайчакта ялгыш була. Димәк, аның бу ялгышуы шулай дип белүдән түгел, бәлки белмәүдән килеп чыга... (303 б.)

Исламның надан дуслары гакли гыйлемнәрне кире кагудан дин көчәя дип уйлап, бөтен гакли гыйлемнәрне инкяр иттеләр һәм гакли гыйлем ияләрен наданнар дип дәгъва кылдылар, хәтта ай һәм кояш тотылуның сәбәпләрен инкяр итеп, боларны тик-

шерүне шәригатькә хилаф санадылар; ә ай һәм кояш тотылуның сәбәпләре – дәлилләр белән исбат ителә торган нәрсәләр, ул дәлилләрне аңлагач һәм белгәч, каршы килергә һич юл калмый; ә алар турында һәндәси дәлилләр китерелгәч, шик–шөбһәләр бөтенләй тамырыннан йолкынып ташланды. Шәригатьтә боларга һичбер каршылык юк. Әгәр шәригатьтә аңа каршылык була икән, дөреслеге ачык мәгълүм нәрсәне инкяр итүгә караганда, шәригать күрсәтмәсен үзгәртеп аңлау яхшырак. Бик ачык булган дәлилләрнең дә мантыйкка каршы булганлыгы өчен икенче мәгънәдә аңлатылганы азмыни? Мантыйк – гыйлемнәрнең һәм фикерләр-карашларның үлчәгече. Чөнки мантыйк дәлил һәм чагыштыруларның юлларын, мокатдимә һәм чикләрнең шартларын, аларның тәртип һәм бәйләнешләрен тикшерә; чөнки тәсаувыр[1] чикне аңлауга юл салса, тәсдыйк[2] – дәлилне аңлау һәм тирәнтен өйрәнү юлы. Мантыйкта исбатның үрнәге, формуласы: әгәр һәр «а» «б» булса, кайбер «б»ның «а» булуы лязим. Шуңа күрә әйтәләр: көллиянең[3] лязим булуы кире жөзьиянең лязим булуын китерә. Моны инкяр итүгә диннең нинди бәйләнеше бар да, инкярдан нинди файда бар? Бу бары кешенең үз акылына, хәтта диненә ышануны зәгыйфьләтә, чөнки анда дин логикага каршы һәм аны танымауга нигезләнгән дигән уй туа; бу логик төзелмәнең кайсысы: икенче мокатдимәнең (положениенең) әүвәлгесенә бәйләнешеме яки аны болай атау һәм формалаштыру инкяр ителәме дигән шик тудыра. Ничек инде хикмәт инкяр ителсен һәм мәгърифәт кире кагылсын?! Ул бит – Аллаһның сыйфаты һәм Коръәннең үзенчәлеге, пәйгамбәрләрнең бүләге. Кемгә хикмәт гыйлемнәре бирелгән булса, ул бик күп изгелек һәм яхшылык бирелгән кеше була, аны бары иң бөек акыл ияләре генә истә тоталар.

---

[1] Тәсаувыр – күзаллау.

[2] Тәсдыйк – төшенү, раслау.

[3] Көллия – «һәрбер кеше – хайван» дисәк, бу «көллия була». Моның дөреслеге кире жөзьиянең, мәсәлән, «һәрбер хайван кеше булмый»ның дөреслеген китерә.

Гакли гыйлемнәр – дүрт төркем. Боларның һәркайсы төрләргә, төрчәләргә (кыйсемнәргә) бүленә. Без аларны шушы урында тәртип белән сөйләрбез. Мантыйк гыйлеме. Мантыйк – белемдә дөресне ялгыштан аера белүгә, раслау өчен файдалы дәлилләрне билгеләргә ярдәм итүче кануннар һәм үлчәүләрдән гыйбарәт. Бу бик борынгыдан килә. Ләкин элек ул аерым-аерым положениеләрдән торган, аның юллары өйрәнелмәгән. Тик Аристотель аның бәхәсләрен өйрәнде, бүлекләрен, мәсьәләләрен тәртипкә салды, аны хикмәт гыйлемнәренең башы һәм ачкычы ясады; шуңа күрә ул беренче мөгаллим булып танылды. Мантыйк турындагы аның китабы – «Ән-нәсъ»[1] дип исемләнә. Бу үзе 8 китап итеп төзелгән: Беренче китап – «Китабел-мәкулат...» – сизү органнары белән беленгәннәрне абстракцияләүнең чиге булган гали җенесләр – категорияләр турында[2]; икенче китап «Китабел-гыйбарәт» – бер хөкемне раслау рәвешендә дөрес төзелгән казияләр – фикер йөртүләр һәм аларның төркемнәре турында[3]; өченче китап – «Китабел-кыяс...» – кыяс (силлогизм), аның төрләре, нәтиҗә чыгару юллары турында; бу, гомумән, сурәт – форма ягыннан тикшерүнең соңы[4]; дүртенче китап – «Китабел-борһан...», дәлил – ышандырырлык нәтиҗә бирүче кыяс һәм аның шартлары турында (шунда ук белемнәр һәм кеше беле-

---

[1] Ән-нәсъ – дәлил, беренче чыганак мәгънәсендә. Бу – Аристотель китабының Көнчыгыштан килә торган исеме. Көнбатыштан килә торган философиядә бу китап «Органон» дип исемләнә. Рус телендә «Орудия (знамя)» дип тәрҗемә итәләр.

[2] Бу китап «Категория» – о высших родах сказуемых или о высших родах бытия» исемендә А.В. Кубицкий тарафыннан тәрҗемә ителгән китап (1939 ел, Мәскәү) булырга тиеш.

[3] Бу – Э. Радлов тарафыннан «Об истолковании» – о высказываниях (суждениях) исеме белән рус теленә тәрҗемә ителеп, «Журнал министерства народного просвещения» (1891, № 1–2) да басылган китап булырга тиеш.

[4] Бу – «Первая аналитика – о доказательствах» дип йөртелә. Үзе ике китаптан торган. Н. Ланге рус теленә тәрҗемә итеп, «Журнал министерства народного просвещения»дә (1892–1894) һәм С.-Петербургта, аннан соң Б.А. Фохта 1952 елда бастырган әсәрләр булырга тиеш.

менең чикләре турында сөйләнә)[1]. Бишенче китап – «Китабел-жәдәл» (Бәхәсләшү турында китап) – бәхәс итүчене сүздән туктату һәм чуалтырга маташучының сүзләрен кисү өчен файдалы кыяслар турында. Шунда ук кире казыялар турында да сөйләнә[2]. Алтынчы китап – «Китабес-сәфсәта» – үзеңне саташудан саклау яки каршы сөйләүчене саташтыруга ярдәм итәрлек буташтырып сөйләүнең төрләре турында[3].

Җиденче китап – «Китабел-хитабәт» – сөйләү осталыгы турында, сөйләү осталыгы, сөйләгәндә тыңлаучыларны кызыктыру, хисләрен кузгату өчен файдалы кыяслар турында[4] фикерләрне бернәрсәгә юнәлдерү. Сигезенче китап – шигырь китабы; яки аннан нәфрәтләндерү өчен кирәкле чагыштыру формаларын белдергән кыяслар – охшатулар турында[5]. Моннан соң аның шәкертләре «көллияте хәмс» турында тәсаувырны аңлау өчен файдалы бер китап эстәделәр. Шулай итеп, тугыз китап булды. Болар ислам дәүләтләрендә тәрҗемә ителделәр һәм кешеләр алардан файдаланды.

Шәехләрнең башлыгы Әбү Гали Ибне Сина, «Шифа» һ.б. китапларын язып, Аристотель өйрәтүләрендәге барлык фәлсәфи гыйлемнәрне тулысы белән шунда җыеп теркәде. Аннан соңгы галимнәр – бу өйрәтүләргә үзгәрешләр керттеләр, үзләре

---

[1] Бу «Вторая аналитика» дип йөртелгән ике китап булырга тиеш. (Б.А. Фохта 1952 елда русчага тәрҗемә иткән).

[2] Бу «Топика» исеме астында берләшкән 8 китап (диалектик фикерләүләр турында) булырга тиеш.

[3] Бу – «О софистических опровержениях» дип йөртелгән әсәр булырга тиеш. Софистик фикерләүләрне тикшерүгә багышланган; «Топика»га өстәмә әсәр, аның 9 нчы китабы булып та саналырга мөмкин.

[4] Бу урында Аристотельнең «Риторика» исемле китабы күздә тотыла булса кирәк. А.С. Ахманов бу әсәрне Аристотельнең «Практик әсәрләр» сериясендә өч китаптан торган 6 нчы китабы санаса да, аның мантыйкый (логик) әсәрдәге тезмәсендә саналуы да мөмкин икәнен әйтеп китә. «Риторика», Н. Платонова тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, «Журнал министерства народного просвещения»дә 1892–1894 елларда басылган.

[5] Бу урында Аристотельнең «Поэтика» (рус телендә В.Г. Аппельрот – 1893 тә, Н. Новосадский – 1927, В.Г. Аппельрот – 1957 ел тәрҗемәләре бар) исемле әсәре күздә тотыла булса кирәк. А.С. Ахманов бу әсәрнең аерым кисәкләре генә сакланганын әйтә.

теләгәнчә тәртипләделәр. «Дәлил» китабыннан алып, «Көллият» китабына хәдләр һәм рәсемнәр турында бүлекчә өстәделәр. «Китабел-мәкулат» дигән беренче китапны мантыйк мәсьәләсе түгел дип төшереп калдырдылар. «Китабел-җәдәл»дән «Гокүс» («кире казыялар») турындагы бәхәсләрне «Китабел-гыйбарәт»кә күчерделәр һ.б. шундый зарар китерми торган үзгәртүләр керттеләр. Ләкин болар биш китапка («Китабел-борһан», «Китабел-җәдәл», «Китабел-хитабәт», «Китабеш-шигырь», «Китабес-сафсата») кергән кыясны, теләгән нәтиҗәне ачык яки беркадәр шикле рәвештә күрсәтүче матдә булу ягыннан карауны төшереп калдырып[1], бу матдәне биш китапның (Борһан, Җәдәл, Хитабәт, Шигырь, Сафсата) эчтәлегенә керттеләр; кайберләре моңа җиңел төшенделәр, ә кайберләре бөтенләй аңламадылар, ә бу (кыясның матдәсе) фәндә бик мөһим һәм ышанычлы.

Әүвәлге өчесе (Борһан, Җәдәл, Хитабәт) Аллаһы Тәгаләнең: «Раббың юлына хикмәт, күркәм вәгазь ярдәмендә чакыр, алар белән күркәм рәвештә бәхәсләш» дигән аятенең төп максаты шул. Әмма Аллаһ шигырь һәм сафсатадан файдалануны күздә тотмый: «Без аңа шигырь һәм аңа охшашлыны өйрәтмәдек» ди Аллаһы Тәгалә. Мөтәәххириннәр, ягъни соңрак чор галимнәре, күп сүзләр күтәрделәр, мантыйкны гыйлемнәрне ачу өчен корал дип түгел, бәлки үзен бер фән итеп карадылар, сүзләр озайды. Бу юлга керүчеләрнең башлыгы Фәхретдин бине Хәтыйк әр-Рази, аннан соң Әфзалетдин Мөхәммәд бине Намуар бине Габделмәлик әл-Хүнеҗи шул турыда «Кәшфел-әсрар» китабын язды, аннан кыскартып «Әл-муҗиз» һәм «Әл-җөмәл» китапларын язды. Нәҗметдин әл-Казвини әл-Кятиби «Китабеш-шәмсия»не, Сиражетдин Әбү әс-Сәнаэ Мәхмүд бине Әбү Бәкер әл-Әрмәви «Китабел-мәталигъ»ны яздылар; болар хикмәтнең хакыйкатеннән ерак иделәр. Кешеләр шушы китаплар белән кулландылар, борынгы галимнәрнең китапларын һәм карашларын ташладылар, ә алар ныклы тикшеренү һәм мантыйк җимешләре

[1] «Мөкаддимәте Ибне Халдун»да бу – башкачарак бирелгән, анда: «Соңгы галимнәр «Кыясны матдәсе ягыннан түгел, бәлки гомуми теләнгән нәтиҗәне бирүе ягыннан тикшерделәр» диелә.

белән тулы иделәр; бу – өйрәтү эшен начарайтуның бер күренеше, гыйлем өлкәсендә торгынлыкның, артка китүнең сәбәбе булды. Аллаһ – туры юлга күндерүче.

Гыйльм әт-тәгалим – риязият гыйлеме. Үзе дүрт төркемгә бүленә: беренчесе – иртиматыйкый. Моңа математиканың һәндәсә – геометриядән башка бүлекләре керә[1] .

Икенчесе – һәндәсә – геометрия[2].

Өченчесе – һәйәт гыйлеме – астрономия.

Бу фән буенча борынгы галимнәрнең башлыклары галәмнең мәркәзе Җир дип санадылар. Җир бер урында тик тора, хәрәкәт итми; аны күк төрле яктан чолгаган, хәрәкәтчел һәм хәрәкәтсез йолдызлар күк тыгызлыгы эчендә беркетелгәннәр, күк белән бергә хәрәкәт итәләр; күкләр үз урыннарында, бәян иткәнемчә, ярылу һәм яңадан ябышуны кабул итмиләр; анда йөрүче җисемнәрдә алга бару, артка китү, кайтып килү, бер урында тору, шашкынлык шикелле төрле хәлләр була; менә шулар төрле кешеләр тарафыннан, төрле вакыт һәм төрле урыннарда төрле кораллар ярдәмендә күзәтелделәр, яклары, микъдарлары, ераклыклары билгеләнде һәм алар хәрәкәтчел йолдызлар санынча, һәм аларның хәрәкәтләренең төрлечә булуына нигезләп, үзләре танылган сәйярәләр (хәрәкәт итүче йолдызлар) санынча җиде фәләк – күк барлыгын һәм болардан һәрберсенең күге калынлыгы эчендә янә бер-берсе өстенә куелган кече фәләкләр барлыгын исбат иттеләр. Моны алар фәләкләрнең төрле авышлыкларда булуларыннан белделәр. Хәрәкәтсез йолдызларның көнчыгышка таба йөрүләрен күзәтеп, сәйярәләр өстендә сигезенче күк барлыгын исбатладылар, һәм бу сигезенче фәләк өстендә дә күктәге җисемнәрне көнбатышка таба кысрыклап үзенә ияртүче беренче хәрәкәтнең урыны булган иң олы фәләк барлыгын исбат иттеләр. Бу хәрәкәтләр барысы да – фәләкнең үзеннән килгән хәрәкәтләр.

---

[1] Бу бүлектәге фикерләр тәрҗемә ителмәде.

[2] Бу бүлектәге фикерләр дә тәрҗемә ителмәде.

Алар моның белән барлык фәләкләрнең саны тугыз гына һәм хәрәкәтчел йолдызларның саны да шулай гына дип расларга уйламыйлар, бәлки шуннан ким түгеллеген генә белдерәләр. Ул галимнәр һәрбер хәрәкәтсез йолдызның үзенә бер фәләк белән хәрәкәт итүен дә мөмкин саныйлар. Кайбер хәрәкәтсез дип уйланган йолдызларның урыннарын үзгәртүләре сизелгәч, галимнәрдә андый йолдызларның хәлләрен беләсе килү, хәрәкәтләрен билгеләү, хакыйкатьне ачыклыйсы килү теләге туды. Соңгы заман астрономнарының исбатлаганнары да шушы хәрәкәтчел йолдызлар булуы бик ихтимал.

Бу гыйлем турында мисырлылар һәм кәлданилардан алып беренче сүз кузгатучы кеше Иберхес хәким, аннан соң Бәтләмиюс әл-Колузи булдылар.

Ислам галимнәре, бу фәнгә керешкәч, башкалардан күп алга киттеләр: тригонометрия, җир йөзенең, башка шарсыман җисемнәрнең, фәләкләрнең өсләрен сызып, бүлеп күрсәтүдә, еллар, айлар, көннәрне билгеләүдә, кояшның чыгыш һәм батыш вакытларын, сәгатьләрдәге төрлелекне ачыклауда греклардан каткат өстен булдылар. Бу гыйлем башта аерым галимнәргә генә хас иде; соңыннан аны халык арасына тараттылар. Шул ук галимнәр ул дәвердә яз айларының һәм яңа елның төрлечә килү, кояш юлының һәм биеклегенең авышып үзгәрүе сәбәпләрен төшенеп, кояш елында кулланыла торган ай-көн исәбендәге кимчелекләрне ачтылар. Җир шарының җиңел, йомшак җилдән (эфирдән) дә ләтыйфрак һәм сулау өчен яраксыз матдә белән чолганган булуын h.б. шундый күп нечкә, искиткеч яңа ачышлар ясадылар, боларны бу фикергә каршы кешеләр дә танырга мәҗбүр булдылар.

Әмирел-мөәминин Мәәмүн гыйлем һәм тикшеренү эшләре белән кызыксынучы иде. Ул җирнең түгәрәклегенә һәм әйләнү микъдарына төшенергә теләде. Габдулла Мөхәммәд бине Муса бине Шакирне, ике туган Әхмәд белән Хәсәнне, Әхмәд бине Касыйр әл-Фәрганине, сүзләре һәм бу эшне белүләре ягыннан ышанычлы бер төркем галимнәрне чакырды һәм бу мәсьәләне ачыклау өчен җибәрде. Алар кайда тигез җирләр барын сорадылар. Андый җирләрнең Сәнҗар сахрасы, Күфә иңкүлеге икән-

леге әйтелде. Ул галимнәр шушы ике урыннан төньяк котыпның күтәрелешен – биеклеген билгели алдылар. Алар бу эшне туры сызык буенча төрле нокталарда көньяктан да, төньяктан да берничә мәртәбә үткәрделәр һәм тукталышлар арасын үлчәделәр. Бу ара алтмыш алты һәм өчтән ике (66 $\frac{2}{3}$) миль булды. Шуннан фәләкнең дә һәрбер дәрәҗәсе шуңарга тигез булганлыгы, ә барлыгы 24 мең мильгә, димәк, 8 мең фәрсәхкә[1] тигез булуы беленде. Ике санның бер-беренә туры-тигез булуы борынгы галимнәр сүзенең дөреслеген күрсәтте. (310 б.)

Һәйәт гыйлеме бүлекчәләреннән – зәиҗ гыйлеме – астрономик календарь

Айларны, көннәрне, үткән тарихларны белү өчен махсус һәм өйрәнергә теләүчеләргә җиңел булсын өчен (планеталарның) иң югары, иң түбән нокталарын һәм авышлыкларын, хәрәкәтләренең төрләренең берсеннән файдаланып икенчеләрен табу өчен, бу һөнәрнең кирәкле, карарлашкан ысуллары һәм таблицалары бар. Болар зиҗләр дип атала. Кайсы йолдызның кайвакытта кайда буласын билгеләү тәгъдил – тәкъвим (дөресләү – календарь) дип атала. (310 б.)

Фән ияләре күпчелегенең тоткан юлы – соңгы гасыр галимнәренең карашы

Эрстархх, Фисагурс, Әфләтун әл-Илаһи h.б. борынгы заман хәкимнәренең, шулай ук аерым нечкә фикерләрдән чыгып аларга кушылган беренче дәвер ислам галимнәренең карашларына соңгы дәвер галимнәре бер-бер артлы каршы төшеп, аларны яманлап, ул карашның дөрес булмаганлыгын күрсәттеләр. Без күргән һәм белә торган галәмнең үзәге – Кояш, һәм борынгыдан ук яки соңгырак чорда ачылган хәрәкәтчел йолдызлар барысы да кояш тирәсендә, аның табигый тарту көче белән әйләнәләр, диделәр.

Кояш тирәсендә әйләнеп йөрүче йолдызлар ике төркемгә бүленә.

---

[1] Фәрсәх – озынлык үлчәве. Миллер сүзлегендә 6–7 км чамасы дип күрсәтелә.

Беренче төркем – төп планеталар: болар Готард (Меркурий), Зөһрә (Венера), Җир, Миррих (Марс), Катабигъ, Мөштәри (Юпитер), Зөхәл (Сатурн), Уран, Нибтун (Нептун);

Икенчесе – төп планеталарга иярен йөрүчеләр: боларның берсе Җир тирәсендә әйләнә – Ай; дүртесе – Мөштәри тирәсендә әйләнә; сигезе – Зөхәл тирәсендә әйләнә: ул (Зөхәл) бер-берсенә керешкән хәлдә урыннарын алмаштырып тора торган ике алка белән чолганган; алтысы – Уран тирәсендә, берсе Нептун тирәсендә әйләнә.

Асыл планеталар да, иярченнәре дә үз күчәрләрендә әйләнәләр, шуның белән көн һәм төн, ә галәм үзәге тирәсендә еллык хәрәкәт белән елның дүрт фасылы – яз, җәй, көз, кыш була.

Үзләре иярген планеталар тартуы сәбәпле, иярченнәр шул планеталар тирәсендә дә әйләнәләр; шуның белән аларның үз айлары, кояш һәм ай тотылулар хасил була. Боларның барысы да көчле күзләр белән тырышып күзәтүләр ярдәмендә ачыкландылар, шәп һәм яңа рәсадлар – телескоплар ярдәмендә расландылар; галәм киңлегендәге җисемнәр арасындагы аермалар, хәрәкәт чикләре, ераклык микъдарлары, торышларының үзгәреше, урыннарындагы, хәлләрендәге төрлелеклер бик ышанычлы рәвештә беркетелделәр.

Кояшның үз күчәрендә 25 көн һәм 12 сәгать эчендә әйләнеп чыкканлыгы ачылды. Ачык, эзлекле дәлил булмаса да, Кояш үзе дә бөтен иярченнәре һәм иярченнәренең иярченнәре белән бергә, олы бер үзәк тирәсендә, шулай ук хәрәкәтсез саналган йолдызлар да шундый ук олы үзәкләр тирәсендә хәрәкәт итмиме дигән караш туды һәм аны раслау көчәйде. Уйларга мөмкин ки, иң югары офык һәм кояш үзе карар табарга тиеш урынга таба хәрәкәт итә, һәм аның бер көне илле меңь ел булырга тиеш, дигән сүзләр шуны аңлаталардыр (311 бит).

Ислам мәмләкәтендә төзелгән рәсадханәләрнең – обсерваторияләрнең беренчесе – әмирел-мөәминин Мәәмүн төзегән рәсадханә. Ул аны Димәшкъта Касиюн тавы өстенә 214 (829) елда бина кылды. Икенчесе Багдадта Шәммасия дигән урында – 215, ә кайберәүләрчә 218 (833) елда төзелде. Бу мөһим эшнең

башында торыр өчен, үз эшләрендә иң ышанычлы һәм хаклыкны күзәтүче, тырыш хәкимнәрдән Шакир угыллары Әхмәд бине Касыйр әл-Фәргани, Габбас бине Сәгыйд әл-Җәүһәри, Сәгыйд бине Гали һәм Яхъя бине Әбү әл-Мансур, Халит бине Габделмәлик әз-Зуди һ.б. чакырылды.

Моннан соң Шәрәфетдәүле әт-Дәйләми исемле патшаның кушуы буенча, 377 (987) елда аның Багдадтагы бакчасында тагын бер рәсадханә эшләнде. Бу рәсадханә Әбү Сәһел Яхъя бине Рөстәм әл-Күһи җитәкчелегендә төзелде. Аның белән бергә, Әбү Исхак Ибраһим бине Һилал әс-Саби, Әбү Фазыл Сәгыйд бине Бүлес әш-Ширази, Әбү Вафа Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Хасип, Әбү Хәмит Әхмәд бине Мөхәммәд әс-Сагани әл-Әстарлаби, Әбү Хәсән Мөхәммәд әс-Самири, Әбү Хәсән әл-Мәгъриби һ.б. бар иде.

Моннан соң 591 (1164) елда «Мөвәххидин»нәр дәүләте солтаны әл-Мансур Ягъкуб бине Йосыф бине Габделмөәмин дәверендә хәким Әбү әл-Ләес әс-Секли һ.б. җитәкчелегендә Әндәлес мәмләкәтендә Севилья шәһәрендә рәсадханә төзелде. Якынча 50 еллар үткәч, Испанияне яулап алган христиан патшаларының берсе аны юкка чыгарды, ә бинасын чиркәүгә әйләндерде.

Янә татар патшаларыннан Чыңгыз ханның Тули исемле углының углы Илихан Һелакү рәсадханәсе. Ул Насыйретдин Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд бине Хөсәен әт-Туси җитәкчелегендә 657 (1259) елда Азәрбайҗанда Морага шәһәрендә фән галимнәреннән Мөэйедетдин әл-Гаразый, Нәҗметдин әл-Кятиби, Фәхретдин әл-Морагый һәм әл-Хәлатый ярдәме белән бина ителде; бу рәсадханә аңа нисбәт бирелеп, «Насыйретдин Туси Рәсадханәсе», һәм «Яңа рәсадханә» дип танылды. Моннан соң Олугбәк рәсадханәсе. Бу – Тимер нәселеннән, Тыргай бине Шаһрух бине Тимер бине Тыргай әт-Төрки. Бу рәсадханәне бина итү хәким Гыясетдин Җәмшид бине Мәсгут бине Мәхмүд әл-Кяши җитәкчелегендә 832 (1428) елда Сәмәркандта башлана. Ләкин аны тәмам итә алмыйча, ул үлә. Аннан соң остазы Казый-задә дип мәшһүр Салахетдин Муса бине Мәхмүд бине Мөхәммәд әр-Руми дәвам иттерә, ул да тәмам итә алмыйча үлеп

китә. Һөмаметдин Мөхәммәд бине Дәмшид әл-Кяши, Галлямә Гали бине Мөхәммәд әл-Кушчи («Тәҗрид» исемле китапка яңа шәрех язган кеше) һиммәтләре белән бу рәсадханә тәмам була. Үзбәк патшаларыннан Мөхәммәд хан бине шаһ Бидаг бине Әбү әл-Хәер әш-Шәйбани, 907 (1502) ел ахырында Сәмәркандны сугышып алгач, Олугбәк шушы рәсадханә астына үзенең хәзинәсен күмеп калдырган дигән сүзгә карап, рәсадханәне ваттыра.

Солтан Морад бине Сәлим әл-Госмани 987 (1582) елда Истанбулда Тәкыетдин Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Мәгъруф бине Әхмәд Димәшкый исемле астроном җитәкчелегендә рәсадханә бина итәргә керешә. Ләкин кайбер мөфтиләрнең каршы килүе сәбәпле, аны тәмам иттерми, эшләнгәнен ваттыра, кешеләрне хикмәт гыйлемнәре укудан тыя, нәтиҗәдә «Һидайә» һәм аның шәрехе «Гыйнайә» дәресләре белән чикләнәләр. Бу хәл гыйлемнең югалуына, дәүләтнең төшүенә, патшалыкның зәгыйфьләнүенә, көченең кимүенә сәбәп булды. Моннан соң бәни Бабур рәсадханәсен Нәҗметдин Мөхәммәд шаһ бине Могаззам бине Әүрәңзиб әт-Төрки 1131 (1718) елда Һиндстан шәһәрләреннән Дәһлидә бина итте...[1] (315 б.)

Бу фәннең атаклы кешеләре. Мәәмүн (хәлифә) хезмәтендә булган һәм үткәндә исемнәре саналганнардан тыш, Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Җабир бине Синан әл-Хәррани әл-Бетани; аның һәйәт гыйлемендә зур белеме булып, моны аның яклылар да, аңа каршылар да шулай дип таныйлар иде.

Әбү Рәйхан Мөхәммәд бине Әхмәд әл-Бируни – аның йолдызлар һәм география гыйлемнәре турында мәшһүр әсәрләре булып, алар французчага да тәрҗемә ителгәннәр.

Әбү әл-Хәсән Гали бине Габдерахман бине Әхмәд бине Юныс әл-Мисрый; моның дөресләнгән мәшһүр зиҗе – астрономик календарь таблицасы бар. Әбү Гали Хәсән бине...[2] – һава катлавы өстендә аннан җиңелрәк һәм ләтыйфрак матдә барлыгын ачкан кеше.

---

[1] Моннан соң рәсадханә өчен нәрсәләр һәм нинди кораллар кирәклеге санала.

[2] Нәселе артык дәвам иттерелмәгән.

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Идрис әс-Сәбти – Африка турында күп мәгълүматны эченә алган «Нәһзәтел-мөштак» исемле китап язган кеше; бу китапка ул Африка хәлләреннән Европадагы һәйәт һәм география галимнәренә хәзергә чаклы билгесез[1] күп мәгълүмат керткән. (315 б.)

Дүртенчесе – музыка гыйлеме – тавыш һәм мотивларны бер-берсе белән чагыштырып, аларны сан белән үлчи белү. Бу фәндә шулай ук көй төзү – иҗат эшенең ничек булганын белү өчен, көйләрдәге яраша һәм ярашмый торган хәлләр, үлчәү һәм көй булу ягыннан ярашу яки каршылыклы – аның ударлары арасындагы вакыт микъдарларының хәлләре турында сөйләнә.

Шәех Әбү Насыйр әл-Фәраби әйткән: ул (көй) үзе хасил була торган җисемдә сизелерлек тоткарланучы бер вакыт, бер тавыштан гыйбарәт. Ә ул сизү дәрәҗәсендәге тавышның иң азы исә тигез генә (ашыгып та, әкрен дә түгел) әйтелә торган хәрәкәле ике хәреф арасына төшкән тавыш. Бу – көйнең композициясенә төшенергә юл ача. Композиция исә – ягымлы рәвештә тәртипләнгән югары һәм түбән тоннарның берләшмәсе ул.

Бу гыйлемне гыйлем хәленә башлап Пифагор китерде, аннан соң Аристотель орган дигән корал уйлап чыгарды, музыкадан төп максат – төрле тавыш һәм көйләрне бер-берсенә яраштырып, күркәм һәм матур төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү. Аның кайберләре шатландыра, кайберләре кайгыга төшерә, кайберләре йоклата, кайберләре көлдерә, җанландыра һәм биетә. Болар исә нинди дә булса бер мәгънә аңлаудан түгел, бәлки уен коралы кылларындагы хәрәкәт сәбәпле хасил була. Бишектәге бала хуш авазга юанып елаудан туктый һәм игътибарын шул авазны тыңлауга юнәлдерә. Дөя, аңгыра булуына карамастан, хуш аваздан әсәрләнә, авыр йөкләрне җиңел күтәрә һәм ерак юллар да аңа якын булып тоела. Яз һәм аның чәчәкләре, музыка һәм аның хуш авазы бер-бер кешенең йөрәген хәрәкәткә

[1] Сүз XIX гасырның уртасы турында.

китермәсә, аның табигате бозык, аңа дәва юк дип, шуның өчен әйтелде[1].

Бел: бернәрсәнең ләззәтле яки ләззәтсез булуы кешегә ошау-ошамау белән билгеләнә. Әгәр бер нәрсә кешенең күңеленә ошаса, мөлаем булып күренсә, ул – аңа ләззәтле, матур була; әгәр ошамаса, кәефенә туры килмәсә, аңа җирәнгеч һәм ачы булып тоела. Ашамлыкның тәмлелеге – ашау, тоту органнары аркылы беленә торган әйбернең ләззәте – тоту, иснең ләззәте – иснәү, көйнең ләззәте тыңлау әгъзаларының кәефенә туры килү белән билгеләнә. Күз белән күренә торганнарыныкы рәсемнәре, сызыклары төгәл һәм үзара ярашулы булсалар, күркәм һәм матур күренәләр, андый нәрсәләрне күрүдән җан рәхәтләнә. Бер-берсенә капма-каршы тавышларны бергә тәртипсез кушу (кинәт сузу, шунда ук кыскарту, өзү һ.б.) белән матур көй хасил булмый; тәртипсез кушылган тавышлар җыентыгы көйнең тәртибен боза, колакны рәнҗетә. Көйнең матурлыгы түбән һәм югары, йомшак һәм каты, тибрәнүчән һәм кысылучан һ.б. тоннар арасындагы ярашучанлык һәм уйганлыклар, тавышларның яртысын, өчтән, дүрттән, биштән берен һ.б. тәртипле төзү бер тавыштан икенчесенә күчүдә, тавышларны кайтарып алуда, тәртип һәм эзлеклелекне саклау аркасында була; тавышларның теләсә нинди җыелмасы ишетүчегә ләззәт бирми, бәлки мәгълүм тәртиптәге тезмәсе генә тыңлаучыны ләззәтләндерә. Моны инде музыка гыйлемен белүчеләр ачык бәян итәләр. Труба, фәтатыйт, флейта, бубен, курай, ләгәнгә охшаган металл уен коралы, кыллы инструмент кебек, органик булмаган материаллардан ясалган коралларга сугу яки өрү сәбәпле чыккан башка

---

[1] Фатих Кәрими «Музыка-әдәбият» исемле җыентык (Оренбург, 1918) чыгара. Шунда музыка укытучысы Роберт Ланкевич дигән берәүнең лекциясен кертә. Лекциядә мондый сүзләр бар: «Гарәп халкында музыкага мәхәббәт бик көчле булып, иске гарәп мәкальләрендә «музыка белән әсәрләнмәгән, чәчәк исенә хушланмаган кешеләр адәм рәтендә саналмаганлык бәян ителә. Музыка сөт кебек ләтыйф, шәраб кебек сәрхушләндерүче; ул ерткычларны юашландыра, адәмнең күңелен нурландыра» дип тасвир ителә.

Күрәсең, Мәрҗани бәяләмәсенең чыганагы шуңа барып тоташа.

тавышлар, киселә-киселә чыга торган көйләр музыкага салынганда, бу тавышлар бер-берсенә мөнасиб, ярашулы булсалар, тыңлаучыга матур, ләззәтле булып ишетеләләр. Бу ярашуның гади һәм катлаусыз булганнары кешеләрнең күбесе өчен табигый, катлаусыз булалар һәм махсус өйрәтүгә мохтаҗ түгелләр. Әмма кайберләре, шигырь үлчәүләренә, бию ритмнарына карата тезелгәннәре, һәм кариларның үз тавышлары композициясен яхшырту шикелле, һөнәр булганнары да бар. Аларның көйләрендәге мелодияләрнең ярашуларыннан һәм бу көйләрне яхшы итеп үтәүләреннән ишеткән кешенең җаны рәхәтләнә, күңеле күтәрелә. Шуңа күрә: «Коръәнне үз тавышыгыз белән зиннәтләгез», – диелде. Әгәр илнең яшәеше һәм төзеклек дәрәҗәсе акыл һәм камиллек өчен зарур булган чиктән узып китсә, барлык эш һәм хаҗәтләрдән бушанган кешеләр ләззәт сөючеләр юлына керәләр. Бу хәл элегрәк гаҗәм патшаларында диңгез ташкыны кебек күп булды.

Элек гарәпләрдә шигырь хәрәкәтле һәм сәкенле кисәкләре тигез, мөстәкыйль мәгънәләргә ия булган өлешләргә бүленгән сөйләм рәвешендә тезелгән һәм ул «бәет» дип атала иде.

Сөйләмнең максут булган мәгънәгә туры килеп, төгәл мәгънә аңлатуы, өлешләренең киселү һәм бүленүдә ярашуы аркасында, шигырь кеше табигатенә мөлаем килә. Шуңа күрә гарәпләр теләгәннәрен шигырь белән аңлатырга яратканнар. Шигырь аларның сөйләмнәрендә иң кадерле урын алып, башкалардан аерылып торды, шигырьне алар үзләренең тарихларын, хөкемнәрен, олылыкларын аңлату өчен мәхкәмә, грамматик төзелештә, стильнең һәм мәгънәне төгәл аңлатуның сынау ташы итеп кулландылар. (318 б.)

Ислам килеп, гаҗәм солтаннарын җиңгәч, фарсы һәм румнардан булган җырчылар таралдылар, гарәпләр кулына керделәр. «Гыйдан, танбур, мәгазифләр, мәзамарларга» кушылып җырлый торган булдылар. Бу һөнәр, Габбасилар чорына чаклы үсә барып, алар чорында Ибраһим бине Мәһди, Ибраһим Мусыйли, аның углы Исхак, аның углы Хаммат тарафыннан камилләштерелде. Болар уен-көлкене тирәннән аңлап, туй, килен кертү һәм

ял мәҗлесләре өчен күптөрле уен кораллары уйлап чыгардылар. Болар Багдадка һәм Гыйракның башка шәһәрләренә таралдылар. Мусыйль шәһәрендә Зәрьяб исемле егет бар иде; шул егет, югарыда әйтелгән кешеләрдән җыр һәм музыка өйрәнеп, аны камилләштерде. Аның бу осталыгыннан көнләшеп, егетне Көнбатышка сөрделәр. Ул Андалусиягә (Әндәлескә) китте. Өммия нәселен башлап җибәрүче Хәкәм Һишшам улы исемле патшага килде. Хәкәм аны искиткеч хөрмәт белән ат өстендә каршы чыгып алды, җир, утар, төрле бүләкләр бирде. Зәрьяб үз һөнәрен башкаларга да өйрәтте. Бу һөнәр Андалусия дәүләте бүлгәләнгән, һәм болар Африканың көнбатыш ярларына, Марокко илләренә күчкәнче дәвам итте...[1]

Кеше хуш, үлчәүгә салынган, мәгънәле, күңелләрне хәрәкәткә китерә торган көйне тыңлый. Сандугач һәм башка кошларның тавышын тыңлау тыелмаган. Тавышта (көйдә) асыл – хайваннарның тамакларыннан чыккан авазлар; уен кораллары башлап шуңа ияртелгәннәр. Беренче үрнәкләре Аллаһ тарафыннан табигатьтә иҗат ителгән нәрсәләргә таянган һөнәрнең һичбер куркынычы юк. Бер тамак белән икенче тамак арасында, җансыз җисемнәр белән хайваннар арасында (бу мәсьәләдә) һичбер аерма юк. Кереше һәм дәвамы үзара яраша торган, үлчәүгә салынган хуш авазларны хәрам дип әйтү гаҗәп. Әгәр бертөрле дә мәгънәсе булмаган тавышларны тыңлау дөрес була икән, хикмәт һәм дөрес мәгънә бирә торган тавышларны тыңлау ник дөрес булмасын? Шулай булгач, кеше кулы белән ясалган төрле инструментлардан, шулай ук тамактан килгән хуш авазларны тыңлау да дөрес булырга тиеш, ләкин моңа тыелган уеннар, эчү-исерү, мыскыллаулар кушылмасын. Бүтән сизү әгъзалары аркылы алына торган ләззәтләр кебек, тыңлау ярдәмендә алына торган ләззәт тә үзенә махсус бер ләззәт була...

---

[1] Алга таба Мәрҗани шигырь һәм музыканы уйнау, тыңлау шәригатьтә дөресме, түгелме турында төрле кешеләрнең фикерләрен китерә.

Моның бүлекләре – гонаҗ[1] гыйлеме һ.б. (320 б.)

Әл-гыйльмет-табигый – табигать гыйлеме. Бу гыйлемдә җисем хәрәкәт һәм хәрәкәтсезлекнең башлангыч урыны булу ягыннан тикшерелә. Ул сигез бүлеккә бүленә.

Беренче бүлек – сәмгыль-киян, ягъни барлык табигать көе, аны сәмгыт-табигый (табигать гармониясе) дип тә йөртәләр, чөнки ул бу фәндә беренче буларак тикшерелгән. Җисемнең бүленә алмый торган кисәкләрдән оешкан булмавы, андый кисәкләрнең фактта юклыгы, бүленми торган кисәктән генә торган барлыкның булуы мөмкин түгеллеге, һәр җисемне чиксез бүленүче итеп уйларга мөмкинлеге һәм андый җисемнең куәт, ягъни һәюла (аерым алганда уйда гына булган матдә) һәм аның билгеле сурәттән, формадан оешкан булуы, җисемнең шәкеле, урыны, хәрәкәте һәм хәрәкәтсезлеге, аларның сәбәпләре, хәле һәм төрләре турында бәхәс итә торган фән.

Икенче бүлек – күк һәм галәм турында. Бу фәндә галәмдәге исемнәрдән һәм аларның түгәрәк сызык, авыш түгәрәк сызык буйлап хәрәкәте, ертылу һәм ямалуны, бүлү һәм бетүне, үсү һәм шиңеп тузуны, сирәкләнеп тишекләнүне, бәйләнешсез тәэсир итү һәм әсәрләнүне кабул итмәүләре турында сөйләнә.

Өченче бүлек – бар булу һәм бетү турында. Бу фәндә кушылма нигезләренең берсенең икенчесенә әверелеп, икенче бер хәлгә килүе, катнашу сәбәпле гади әйбернең үз формаларын югалтмаулары; хайваннарның, үсемлекләрнең, мәгъдәннәрдәге[2] башлангычларның барлыкка килүе тикшерелә.

Дүртенче – Асәре голүвия – җирдән югарырак тора торган нәрсәләр һәм күренешләр турында. Бу фәндә атмосферада булган болыт, яңгыр, кар, җил, күк күкрәү, яшен яшьнәү һәм яшен сугу, кырау, чык, томан, йолдыз атылу, җир тетрәү, чишмәләр чыгу, айның киртәләнүе, метеор төшү, йолдыз күчү, салават күпере һ.б. шундыйлар турында сөйләнә.

---

[1] Гонаҗ – көязлек, кыланчыклык. Артистлык һөнәре күздә тотылмыймы?

[2] Мәгъдән – минерал, металл.

Бишенче – җир эчендә бикләнеп, тотылып торган парларның һәм төтеннәрнең катышуыннан мәгъдәннәрнең барлыкка килүләре турында. Җир эчендә төрле заманнарда, төрле урыннарда төрле матдәләрдән оешып, һәр якка таралган аралашма – катышмалар бар. Әгәр бу катышмаларда пар өстенлек итсә, терекөмеш, нефрит, хрусталь, әмма төтен өстенлек итсә, күкерт, купорос, тоз, мышьяк, нашатырь кебек матдәләр барлыкка килә. Аларның болганчык яки сафлыкларына, катышу һәм куерып кату дәрәҗәләренә карап, катышмалар төрле була: саф күкерт белән саф терекөмешнең тулы катышуыннан, кызыл күкерт булса – алтын, ак күкерт булса, көмеш барлыкка килә. Әгәр күкерт белән терекөмешнең катышуы тулы булмаса – ак кургашын, әгәр күкерт белән терекөмеш саф булмасалар, әмма катышулары нык булса – тимер, катышулары нык булмаса – кара кургашын, әгәр инде терекөмеш саф, ә күкерт саф булмаса һәм өлгереп җитмәс борын суынса (катарлык салкынга очраса – харсини (җизсыман металл), әгәр күкерт аны яндырса, бакыр хасил була.

Алтынчы – үсемлекләр турында. Үсемлек азыклана, туа, үсә. Анда ирлек һәм хатын-кызлык сыйфаты да бар. Анда ана карынына охшашлы урын да бар. Җимешләнү һәм тудыруда аталануга мохтаҗ, әмма кушылу-аерылуга мохтаҗ түгел. Боларда бер җенестән икенче җенес килеп чыгуы да мөмкин. Мәсәлән, намамнан – мәктән мәк орлыгы, бадруждан[1], шаһсперем[2] үсеп чыгуы да мөмкин.

Җиденче – хайваннар турында. Хайваннар туалар, тудыралар, ашыйлар, үсәләр. Боларда сизү һәм үз теләкләре белән хәрәкәт итү сыйфаты бар. Болардан һаваны яки судагы һаваны суларга мохтаҗ булганнары, булмаганнары да бар. Болар арасында бик симезлектән кышын бөтенләй ашамый яши алганнары (аю, керпе кебек) бар. Күренеп тора торган колаклары булмаган хайваннар, күбесенчә, йомыркадан чыгалар.

---

[1] Бадруж – бәдрүҗ – Урта Азиядә бер үсемлек.

[2] Шаһсперем – базилик – үсемлек.

Сигезенче – җан хакында. Тән табигый яктан төгәлләнү, төзек хәлгә килү чорында аның сурәте күркәмләнә, анда үсүгә сәбәп булган җан пәйда була. Моны табигый җисемнең ашау, үсү, камилләнү, нәсел үрчетү ягыннан беренче кәмаләте дип таныйлар. Ул шәхес яшәве дәвамында ашау, үсү, төр бүленеш һәм нәсел үрчетүне тәэмин итә.

Төзеклек һаман үсә барып, аңлый торган җан пәйда була. Бу – табигый җисемнең сизү, үз теләге белән хәрәкәт итү, хайван дәрәҗәсенә ирешүе. Моның бер төре – кеше. Бу – сөйли торган шәхес һәм абстракт карашлары, уйлап табуларны аңлау ягыннан табигый җисемнең иң төгәле...

Табигать гыйлеменең бүлекчәләре медицина, анатомия, хирургия, фамацевтика, ветеринария, аучылык, игенчелек, метеорология, география[1] h.б.

Медицина ул пәйгамбәрнең «Һәр авыруның дәвасы бар, кирәкле даруны кулланганда, һәр авыру Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән сәламәтләнә», һәм «И Аллаһның коллары, дәваланыгыз, чөнки Аллаһ шифасы булмаган һичбер авыру бар итмәде, тик бер авыруның – тирән картлыкның гына дәвасы юк» дигән сүзләрендә ачык әйтелгән.

Имам Газали (Аллаһ аңа рәхмәт итсен): «Дәвадан баш тарту тәвәккәллек түгел, бәлки үлем куркынычы булганда, ул хәрам. Авыруны җибәргән зат аның дәвасын да җибәрде, аны куллану юлларын да өйрәтте, кирәкле чараларын хәзерләде», – диде. Шулай булгач, дәваны кулланмау аркасында һәлакәткә төшү дөрес түгел. Оста врач авыруның белмәгәннәрне таң калдыра торган серләренә төшенә. Кайбер чакта бер әгъзаны дәвалыйлар, ә авыру аннан ерак урында була; яки кайчакта даруны бер кулга сөртәләр, ә икенче кул авырган була. Димәк, медицина үзенә бер һөнәр, белгечлек: ул кеше тәненең авыру яки сәламәт икәнен

[1] Мәрҗани, бу бүлекне язганда, «Мөкатдимәте тарихы Ибне Халдун»нан файдаланган. Ләкин Ибне Халдунда «Гыйльмет-тыйб» дигән бүлек кыска. Анда терапия, хирургия, тире авырулары, фармацевтика дигән бүленешләр юк. Мәрҗани исә медицина (гыйльмет-тыйб) ны шулай берничә мөстәкыйль гыйлемгә бүлеп саный.

тикшерә. Бу белгечлек иясе – табиб – сәламәтлекне саклау, бер-бер әгъзада авыру килеп чыкса, аның сәбәпләрен, кайдан килеп чыгуын белгәннән соң, төрле ашамлыклар һәм дарулар белән савыктырырга тырыша. Моның өчен ул иң элек авыруның натурасын, канын, сидек һәм тизәкләрен, йөрәк тибешен тикшерә. Аның табигате көчен дә истә тота, чөнки яшьнең, сезонның һәм матдә табигатенең соравына күрә һәр ике хәлдә (исән чакта да, авырганда да) тәнне идарә итүче – шул көч. Авыруның дәрәҗәсен, аның даруны кабул итүен күрсәткән билгеләргә карап, кирәкле даруларның көчен һәм үлчәвен билгели.

Кайбер очракта бер әгъзаны, мәсәлән, күзне аерым карап, аның авыруын, дәвалау юлларын тикшерүче махсус гыйлем тудырылды һәм кешенең бу әгъзасының ни өчен яратылганлыгын, аның файдасын күзәтү дә шул гыйлемгә кушылды.

Гыйльмет-тәшрих – кеше һәм аның әгъзаларының: сөякләр, буыннар, сеңгер, тамырлар, кимерчәкләр, боларның ничек һәм нинди тәртиптә төзелешләрен тикшерә. Тумыштан һәм яратылыштан шундый гаҗәп төзелешне өйрәнү шәригать каршында важибе кифәя[1], бөтен кешеләр өчен файдасы уртак, максаты мактаулы; бу – олы гыйлем һәм хөрмәтле казаныш; шуңа күрә имам Газали: «Астрономияне һәм тән төзелеше гыйлемен (хирургияне) белмәгән кеше Аллаһы Тәгаләне тану ләззәтеннән мәхрүм», – диде.

Гыйльмел-җәрахәт – тәндәге төрле җәрәхәтләр, аларның төрләре, дәвалау ысуллары, тышкы авыруларга китә торган сылама дарулар (төрле пластырьлар), бинтлар, гомумән, бәйләү материаллары, кисеп ташлау, яру, алар өчен кирәкле кораллар турында тикшерә торган гыйлем[2].

---

[1] Важибе кифәя – кеше өстенә йөкләнә, кеше аны үтәргә тиешле бурычлар ике төрле: 1) һәркем үтәргә тиешлеләр; 2) кайберәүләр үтәү белән, бүтәннәрнең дә өстеннән төшә торганнар. Важибе кифая шуның икенчесенә керә.

[2] Мәрҗани «Гыйльмет-тәшрих» һәм «Гыйльмел-җәрахәт» дигән ике гыйлем турында яза. Боларның беренчесе – хәзерге анатомия һәм физиологиягә, ә икенчесе хирургия һәм тире өсте авырулары турындагы фәнгә туры килә.

Фармацевтика даруларның хасиятләре, төрләре, тышкы яктан бер-беренә ошаганнарны, яхшысын начарыннан аера белү; кырда, бакчада кайсы вакытларда өлгерүе, кайсы илләрдә табылуы h.б. турында сөйли. Бу һөнәр дә ислам мәмләкәтендә барлыкка килде һәм ул – үткәндәге олыларның хезмәте; шуңа чаклы дару әзерләү һәм аны сату эшләре исле нәрсәләр (исле май h.б.) белән сату итүче, төрле чүп-чар белән шөгыльләнүче булдыксызлар кулында иде. Мондый кыйммәтле нәрсәләр белән ничек эш итәргә белмичә, бер-берсеннән аера алмыйча саталар һәм алар биргән даруларның файдасыннан зарары күбрәк иде.

Дарулар белән сату итүче беренче аптека, Көнчыгыш һәм Көнбатышны бергә алганда, 184 (800) елда Һарун әр-Рәшид хәлифәлеге[1] вакытында Багдад шәһәрендә ачылган.

Ветеринария – медицина кебек, атларның сәламәт һәм авырулыгы, аларның авыруларын бетерү һәм саулыкларын саклау турында сөйли торган гыйлем[2].

Аучылык – ау аулау юллары, аулаганда файдаланыла торган хайваннар: атланып йөри торганнар, ерткыч кошлар, этләр, киекнең хәле, табигате (характер үзенчәлеге) турында сөйли торган гыйлем. Ислам галимнәре бу фәннән күп китаплар яздылар. Европа галимнәренә бу фәнне Гайсә Гали улы Гарнатыйның өч йөз илле бүлектән торган китабы төшендерде. Бу китапны бик мактадылар һәм үз телләренә озак еллар тәрҗемә ителмәгәненә үкенеч белдерделәр.

Игенчелек – үсемлек өстеннән күзәтү һөнәре. Ул үсемлекнең тишелүен, сугару, эшләү-эшкәртү h.б. чаралар белән аны үстерү, үсемлекләрдә була торган төрле авыру һәм бәлаләрдән саклау, тишелеп чыгып, үсеп җиткәнгә чаклы җиргә су биреп аны күпертү, вакытына һәм урынына карап аны ашлау, игүчәчү, төрле зararлы нәрсәләрдән саклау һөнәре. Бу – тереклекнең яшәве һәм нәселе бетмәү өчен зарур, шуңа күрә аның исеме

---

[1] Мәрҗани «әр-Рәшид» дип кенә яза, ә сүз нәкъ шул елларда хәлифә булган мәшһүр Һарун әр-Рәшид турында бара.

[2] Гарәпләрдә ул заманда хайваннарның иң әһәмиятлесе ат булганга, сүз ат турында бара булса кирәк.

дә «яшәү, дәвам итү» мәгънәсендә булган «фәллах» сүзеннән алынды. Пәйгамбәрдән дөрес ишетелгән сүз: «Бер-бер мөселман агач үстерсә яки иген иксә, аларны кошлар, кешеләр яки хайваннар ашаса, бу садака була». Шул сәбәптән мөселманнар аның белән кызыксындылар, аны һөнәр дәрәҗәсенә күтәрделәр. Алар заманында иген сәүдәсе тәрәкъкый итте, хәлифә, вәзир һәм аннан түбәнрәк дәрәҗәле кешеләр дә игенчелек эшләрен үз куллары белән башлап җибәрүне мактаулы эш рәтендә саныйлар, олылап, еракларга баралар иде. Болар су ага торган арыклар, багурат, җир асты су юллары һәм фонтаннар казыдылар. Болар суларны үлчәүне уйлап таптылар, Европа шәһәрләренә дөге, зәгъфран, ефәк корты һәм ефәк, инбир, агачтан сыгыла торган яшелсыман су, келәй агачы, хөрмә һ.б. керттеләр. Ә Европада моңарчы болар юк һәм барын да белмиләр иде. Гарәпләрнең олылары исламга чаклы мондый эшләр белән шөгыльләнүдән тартыналар һәм аны хурлыклы, дәрәҗәне төшерүче дип саныйлар иде. Ислам галимнәре бу фәннән күпсанлы кадерле китаплар яздылар, зур күләмле әсәрләр калдырдылар. Ләкин боларның күбесе ислам дөньясына ваемсызлык аркасында килгән кайгылар, һәлакәтләр сәбәпле әрәм ителделәр.

Әбү Гавам Зәкәрия углы Әндәлеси (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) утыз алты бүлектән торган китап язды, анда игенчелек гыйлеме, иген кораллары, иген хәлләре һәм аның табигате, орлыкларның һәм хайваннарның, агач һәм үләннәрнең төрләре, аларны тудыру һәм саклау юллары, боларга ирешә торган авырулар һәм аларны дәвалау юллары сөйләнгән; кешеләр ул китаптан күп файда алганнар.

Сахрада яшәүче бәдәвиләрдә табигать законнарына түгел, бәлки үз тәжрибәләренә, картлар белүенә нигезләнгән медицина бар һәм боларның кайберләре дөрес иде. Гарәпләрдә исламга чаклы ук шундый табиблар бар иде. Ибне Халдун әйткәнчә, шәригать китапларында телгә алынган тыйб исламнан элек булган тыйб кебек бер нәрсә, әмма ул вәхи белән өйрәтелмәгән. Бу – гарәпләр өчен гади бер хәл. Шулай булгач, хәдис китапларында әйтелгән дәвалау ысулларын нәкъ шулай булуы мәҗбүри дип

исәпләргә ярамый. Әгәр болар хөрмәт һәм иман ныклыгы йөзеннән кулланылсалар, иман сүзләре булу ягыннан аның тәэсире булырга мөмкин, әмма табигать кануннарына туры килә торган табиблык ягыннан боларның файдалары юк. Чөнки пәйгамбәрләр шәригать өйрәтү өчен җибәрелгәннәр, ә фән-һөнәр өйрәтү өчен түгел.

Аристотельнең табигать гыйлемнәре турындагы китаплары да, башка китаплары белән бергә, Мәәмүн хәлифә заманында тәрҗемә ителде. Шуларга ияреп, бүтәннәр дә китаплар яздылар. Ислам галимнәре арасында Аристотель китапларын тулысынча үзләштергән шәехләрнең башлыгы Әбү Гали[1] булды. Боларны ул «Шифа», «Нәҗат», «Ишарат» исемле әсәрләрендә күрсәтте; ул күп кенә мәсьәләләрдә Аристотельгә каршы китте, аның фикерләрен кире какты һәм үзе дөрес дип белгәнчә алды...

Әмма ибне Рөшд Аристотель китапларының сөземтәсен бирде, аларга комментарийлар язды, ләкин аның фикерләренә каршы китмәде; шул рәвешчә, күпләр китаплар яздылар, фәнне камилләштерделәр, югары дәрәҗәгә күтәрделәр.

Тыйб гыйлемен билгеле кагыйдә астына куючы юнан хәкимнәреннән Бократ әлдән, аннан соң Дискуридус, аннан соң Гален һәм Орибоз һ.б. булды. Болар христианлыкка чаклы чорда фәнне үстерделәр. Христианлык килгәч, гыйлем базары түбәнәйде, хәтта бөтенләй бетү дәрәҗәсенә килде. Төрле авыруларны дәвалау өчен, дөрес һәм кирәкле дарулар урынына тылсымнар, им-томнар, сихернең төрлесен кулланып терелтергә керештеләр.

Дискуридус әсәрен Багдадта хәлифә Мөтәвәккил галәл-Аллаһ заманында гарәп теленә тәрҗемә иттеләр, ислам галимнәре бу һөнәрне югалган җиреннән тергезделәр, күп яңа нәрсәләр ачтылар һәм югары дәрәҗәгә күтәрделәр.

Бу өлкәдә шундый күп галимнәр килеп чыкты ки, аларның санын Аллаһ үзе генә белер. Болардан: Әбү Бәкер Мөхәммәт бине Зәкәрия әр-Рази. Ул йөздән артык әсәр язды. Шулардан

[1] Әбү Гали Ибне Сина.

чәчәк һәм кызамык авырулары, эчке авырулар һәм нерв авырулары турындагылар бу авырулар хакында беренче китаплар иде. Һинд хөрмәсенең, сәнаи мәкки (коссия), кияр шәнбәр (корица) h.б. чистартучы һәм дезинфекцияләүче майлар турында, аларның хасиятләре турында язды. Әмирел-мөәминин әл-Мөктәфи биллаһ хәлифәлеге чорында элек Рей, аннан соң Багдадта хастаханә мөдире булды. Аның әсәрләре, төрле телләргә тәрҗемә ителеп, Европа табиблары каршында кабул ителде.

Болардан Әбү Гали Хөсәен бине Габдулла бине Сина – галимнәрнең башлыгы, врачларның җитәкчесе, хәкимнәрнең патшасы; каршы килүчеләр дә, яклаучылар да аңа хөрмәт белән карадылар. Ул бу фәнне камилләштерде, чиктән тыш күтәрде һәм медицина турында «әл-Канун» исемле китабын язды. Европа табибларыннан берәү аны 600 (1203–1204) елда латинчага тәрҗемә итте; ул кешене Җирар Гармон[1] дип атыйлар иде. Шуннан соң бу кадәрле китап Европа шәһәрләренә таралды һәм барлык телләренә тәрҗемә ителеп, төп һәм иң ышанычлы чыганак булып әверелде. Аның язган китаплары күп, әмма шуларның күбесе европалыларга билгесез булып калды.

Бу галимнәрдән Әбү әл-Касыйм Хәләф бине Габбас Кортыби хирургия һәм тире өсте авырулары турында «әт-Тәгъриф» исемле китабын язды. Бу китап Европа телләренә тәрҗемә ителде, алар өчен төп чыганак һәм гыйлемнәре өчен төп таяныч булды, хәтта кайберәүләр аны бу фәннең нигезе дип атадылар. Ул бу фән өчен кирәкле кораллар уйлап чыгарды. Төрле кушылмаларны, үсемлекләрнең хасиятләрен һәм бүтән химик әйберләрне анализлау өчен, ислам галимнәре осталыгы белән табылган кораллар ярдәмендә, бер генә яки берничә матдәдән торган дарулар кулланып, сидек капчыгындагы ташны ваклауэретү мөмкинлегенә иң элек төшенгән кеше ул иде.

Болардан – казый Әбү әл-Вәлид Мөхәммәд бине Әхмәд бине Рөшд җитмешләп китап язды. Шулар арасында җелек авы-

---

[1] Җирар Гармон (Герард Кремонский) – XII гасырда яшәгән математик, астролог, врач һәм тәрҗемәче.

руы турындагы китап Европалылар тарафыннан хөрмәт белән кабул ителгән һәм күп телләргә тәрҗемә ителгән.

Болардан – берсе Зыяэтдин Әбү Мөхәммәд Габдулла бине Әхмәд әл-Малыкый ат докторы углы дип танылган, шул турыда күп китаплар язган. Бу китаплар арасында бер генә матдәдән торган дарулар турындагы мәгълүматны җыйган китабы борынгы грек хәкимнәре язган китаплардан тулырак та, төгәлрәк тә; китап үзеннән соңгылар каршында хөрмәт белән кабул ителгән.

Болардан – Әбү Яхъя Зәкәрия бине Мөхәммәд бине Мәхмүд әл-Казвини «Гаҗаибел-мәхлүкат вә гараибел-мәүҗүдат» исемле китабын Күфәдә язды. Бу китапта табигать күренешләренең хакыйкатьләре, үсемлекләрнең хасиятләре, хайваннарның, борынгыдан килгән әйберләрнең, мәгъдәннәрнең[1] хәлләре турында сөйли.

Болар Казвининең бу фәндә тирән белемле, әйберләрнең үзлекләрен һәм табигатьләрен тирәнтен белүче икәнен күрсәтә. Бу китап турында ул үзе: «Бу китапны ватаннан аерылып торган чакта, надан, гафил кешеләрнең аңына сыймый, ә үткен һәм акыллы кешеләр кире какмый, инкяр итми торган нәрсәләр турында яздым, чөнки болар, гадәттәге хәлләр һәм күренешләр белән килешеп бетмичә, алардан ерак торсалар да, Аллаһның кодрәте белән чагыштырганда, берсе дә авыр, олы нәрсәләр түгел, ул китапта язылганнарның барысы да, Аллаһ тарафыннан бар ителгән һәм акыл белән уйлап яки сизү белән беленә торган гаҗәп нәрсәләр. Яисә башкалардан күчереп сөйләүчеләр тарафыннан сөйләгәннәрне нәфис хикәяләр яки сынап, тәҗрибә итеп карау өчен гомер җитмәү сәбәпле генә төшерелеп калдырылуы мәгънәсезлек булган ят һәм гаҗәп хәлләр, хасиятләр. Әгәр боларның ышанычлылыгын беләсең килсә, сынап карарга ашык. Ләкин бер яки ике тапкыр сынау белән дөрес чыкмый икән, саклан, күңелең кайтмасын, дәртең сүнмәсен, чөнки ул кирәкле шартлар җитәрлек булмаудан яисә берәр уңайсызлаучы

---

[1] Мәгъдән – металл, минерал.

хәлдән булырга да мөмкин. Моңа мисал итеп магнитны һәм аның тимерне үзенә тартуын күрсәтергә мөмкин. Әгәр аңа сарымсак сыгынтысы тиерсәң, тарту сыйфаты югала. Әгәр аны яңадан серкә белән юсаң, әлеге хасият тагы кире кайта. Шулай булгач, әгәр тимерне тартмый торган магнит күрәсең икән, аның тарту хасиятен инкяр итмә, бәлки аның хәлен ныклап тикшер ки, дөреслек мәгълүм булсын».

Европалылар бу китапның кайбер урыннарын сайлап тәрҗемә иттеләр һәм кыйммәтен таныдылар, дөресенә Аллаһ ирештерер.

География гыйлеме. Моңа Аллаһы Тәгаләнең «Ник алар, Җир йөзен гизеп, сездән элек яшәгәннәрнең тормыш нәтиҗәләре ничек булганын күзәтмиләрме?»[1] яки: «Сездән элекке-ләрнең дә тоткан юллары бар иде. Җир йөзен гизеп карап күрегез...», яки пәйгамбәрнең «минем өммәтемнең сәяхәте Аллаһ юлында сугыш ул» дигән сүзләрендә география фәненә күрсәтү ясалган.

География – җирнең хәлен, континентларын, тау, елга, коры җир, диңгезләрен, яшәүче халыкларны, аларның лөгатьләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен, табигать һәм холыкларын, эш һәм һөнәрләрен, ризыкларын, ерткыч җанварларын, йорт һәм кыргый хайваннарын, кошларын, балыкларын, үләннәрен, агачларын, янар тауларын, нинди орлыклар җитешүен, төрле бөҗәк һәм кортларын, чокыр җирләрен, һава, жил, эсселек-суыклык, сирәк очрый торган әйберләрне, кием-салымнарын h.б. белдерә торган гыйлем. Грек хәкимнәре заманында бу гыйлем бишектәге бала кебек кенә иде. Моны ислам галимнәре тәрбияләп үстерде һәм җитлеккән, көчле кеше дәрәҗәсенә ирештерделәр. Бу өлкәдә беренче китап язучы Бәтләмиюс Клузи[2], үзенең китабында

---

[1] «Җир йөзендә йөрегез һәм күзәтегез...» дигән сүз йөрү белән боеру түгел, бәлки үткәннәрнең хәлен өйрәнүгә өндәү. Шуңа күрә әгәр үткәннәрнең хәлен өйрәнү бүтән юллар белән ирешелә икән, максут хасил, теләк үтәлгән була... *Ш. Мәрҗани искәрмәсеннән.*

[2] Бәтләмиюс Клузи – Клавдий Птолемей, борынгы чорларда яшәгән математик, астроном, географ.

дүрт мең биш йөз утыз шәһәр, ике йөздән артык тау, утраулар, мәгъдәннәр, җәүһәрләр, хайваннар һәм аларның микъдарларын санады.

Бу китап Мәәмүн хәлифә заманында гарәпчәгә тәрҗемә ителде, аннан соң бу фәнне ислам галимнәре үстерделәр.

Болардан – Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Идрис әл-Әндәлеси «Нәзһәтел-моштак» исемле китабында Европа галимнәренә хәзергә чаклы билгеле булмаган, Африканың төрле урыннарындагы хәлләр турында язды. Мең ике йөз илле икенче ел һиҗридә (1836–1837) бу китапны бер француз галиме, француз теленә тәрҗемә итеп, Европа шәһәрләрендә бастырып чыгарды. Бу китап алар каршында бик игътибарлы, бу өлкәдә нигез һәм хөрмәтле санала.

Болардан – тарихта Ибне Фазлан исеме белән танылган Әбү Габбас Әхмәд бине Фазлан бине Рәшид бине Хаммад. Әмирел-мөэминин әл-Моктәдир биллаһ Сәһсән әр-Расиби һәм аңа юлдаш Сәфир Бәдрәл-Хәрәми җитәкчелегендә Болгар шәһәренә өч йөз тугызынчы елда (921–922) илчеләр һәйәте җибәрә. Ибне Фазлан шул төркемнең секретаре итеп билгеләнә. Шул кеше юлда очраган, күргән һәм ишеткән төрле кабиләләрнең хәлләре, гореф-гадәтләре, эшләре, холык һәм табигатьләре, коры җир һәм елгалар, хайваннар, агачлар, үлән һәм чәчәкләр, авыл һәм шәһәр халкы арасындагы мөселман һәм кяферләргә, төрле төркемнәргә хас булган торак урыннары, кием-салымнары, ашау-эчүләре, ышану һәм гыйбадәтләре, яхшы һәм начар гадәтләре һ.б. турында язып барган.

Әбү Сәгыд әс-Сәмгани, әл-Истахри, әл-Идриси, Әбү Касыйм бине Хәүкаль, Шәмсетдин Димәшкый, Якут әл-Хәмәви һ.б. да – географиядәге бәйләнешле әсәрләр язучылардан.

Табигать гыйлеменнән саналалар: фирасәт гыйльме – физиогномика, гыйльме кыяфәт – тышкы билгеләргә карап белү, гыйльме рияфәт, гыйльме симия – магия, гыйльме фаль – фал ачу, күрәзәлек итү, гыйльме зәҗер – кош очуы буенча күрәзәлек итү, гыйльме рәмел – тактага цифрлар сугып күрәзәлек итү, гыйльме җәфер – сызыкларга карап күрәзәлек итү, гыйльме

хавассыл-хоруф вәл-әсма – хәреф һәм исемнәрнең төрле хасиятләренә карап күрәзәлек итү, таласим – тылсым, шәгъбәзә – фокус күрсәтү, кәһанәт – алдан хәбәр бирү, кимиа – алхимия, тәнҗим – йолдызларга карап хәбәр бирү һ.б.[1]

Кимиа – бу фәндә алтын һәм көмеш составына керә торган матдәләр һөнәрчелек юлы белән тикшерелә һәм аларны эшләү юллары өйрәтелә. Бу матдә җисемнәрне төп элементларына таркатып табыла. Ул болай эшләнә: җисемнәр парга әйләндерелеп куылалар. Эрегәннәре известьләп катырыла. Шуннан соң эликсир дип аталган җисем барлыкка килсен өчен, бу каты җисемне тагын да катырак таш яки башка берәр нәрсә белән чүкеп төелә. Аннан соң ак кургашын, кара кургашын яки бакыр кебек, якынча алтын яки көмеш сурәтен алырга сәләте булган металларны утта эретеп, аның өстенә әлеге эликсирны салалар, менә шул саф алтын яки көмеш булып әверелә. Кинаяләп, бу эликсирны җан, җисемне тән дип атыйлар.

Ислам җәмәгатеннән бер төркем шушы гыйлемнең белгечләре булдылар, кушылмаларны анализларга, яңадан кушарга һәм шуңа бәйләнешле эшләргә остардылар, хәтта кайбер хайваннарны, мәсәлән, балчыктан чаян, кылдан елан, богаудан умарта корты кебекләрне ясарга җыендылар. Тояклы хайваннарның мөгезләреннән камыш ясау һәм, эчләренә бал тутырып, аннан исерткеч хәзерләргә өйрәнделәр. Боларны алар крестьяннар алдында кирәкле матдә һәм даруларны әкренлек белән, аерым-аерым хәзерләп эшләсәләр дә, аларның асылы, хакыйкате бөтенләй мәгълүм түгел иде. Аларның сүзләренең күбесе табигать фәнендә күрсәтелгәннәргә туры килми, табышмакка ошаган серле, башваткыч сүзләрдән гыйбарәт иде. Аны бер фән буларак инкяр итүчеләр һәм хата санаучылар да, табигать законнарыннан тыш булган кайбер очраклы хәлләрнең (мәсәлән, һавада җәяү йөрү, каты һәм тоташ җисемнәрдә тишекләр булу һ.б.) булуын мөмкин санадылар, мәсәлән,

[1] Ш. Мәрҗани болар турында шактый озын сөйли, әмма без аларны алырга уйламадык.

мөтәкәллиминнең[1] мондый хәлләрнең барлыгын раслаулары шушы юнәлештә иде.

Бу фәндә иң күп шөһрәт казанучылар Ибн Хәйян, аннан соң әл-Мәҗритый һәм Әбү Бәкер бине Бәшрүн иде.

Әбү Насыйр әл-Фәраби, әт-Тограи исеме белән мәшһүр Әбү Исмәгыйль Хөсәен бине Гали әл-Әсбәһани моны мөмкин санадылар һәм көнбатыш хәкимнәре шуларга иярделәр.

Шәехләрнең башлыгы Әбү Гали Ибне Сина моны мөмкин түгел санады, көнчыгыш хәкимнәре, соңгы чор Европа галимнәре шуңа иярделәр. Аларның бу терминны кулланулары да югарыда әйтелгән мәгънәдә түгел, бәлки җисемнәрне анализлау һәм бер-берсенә кушу мәгънәсендә иде.

Табигатьтән тыш булганнарны инкяр итүчеләр әйберләр дүрт элемент җыелмасыннан тору белән бергә, ул элементларның кайберләре башка элементлардан өстен була; җисемне шул рәвешчә төзүче, билгеле сурәттә саклаучы – табигый эсселек, ә эсселекнең үзгәрүе һәм заманның үтүе процессында әйбер төрле стадияләрне кичерә, хәтта чигенә җитә; шунда инде табигать тарафыннан эшләнгәнне химик үтеп китәргә тиеш була; төрле юллар, төп көчне ике өлешләтү һәм башка төрле чаралар аркылы металлны йомшарта, ә икеләтелгән көч вакыт үтү белән кими һәм эшне башлаганда бер дәрәҗәдә булса, тәмамлаганда бүтән дәрәҗәдә була.

Хәкимнәр арасында йөри торган мәкаль бар: эшнең башы – уйның ахыры, эшнең ахыры – уйның башы. Димәк, һәрбер эшне эшләүдән элек аннан максат билгеле булырга тиеш. Максат итеп куелган нәрсәнең төрле хәлләре төрле стадияләрдә нинди мөнәсәбәтләрдә булалар; табигый эсселекнең төрле хәлләрдә төрлечә үзгәрешләре, һәрбер стадиянең күпме вакыт дәвам итүе; көчне арттыру сәбәпле, бернәрсә урынына икенче нинди нәрсә хасил булуы; икмәк өчен кирәкле ачыткы алдан ук хәзерләнгән кебек, кайбер матдәләргә катыштырылырга тиешле

[1] Мөтәкәллимин – урта гасырда көнчыгышта таралган Кәлям фәлсәфи юнәлеше вәкилләре.

нәрсәләр дә алдан исәпкә алынып хәзерләнгән, ул нәрсәләрнең чиксез күптөрле хәлләрдәге төрле үлчәүләренә һәм көчләренә яраштырылып эшләнергә тиеш. Матдәләрнең хәлләрендәге төрлелек шулкадәр күп, аларның барлыгын кеше гыйлеме чолгап бетерә алмый.

Табигать үзенең эшләрендә иң якын юлны сайлый. Юлында ясалма тоткарлыклар булмаганда, иң якын юлдан чыкмый, ерак юлларга керми.

Аллаһның хикмәте сирәк очрый торган ике ташта[1], чөнки болар кешеләргә кәсеп итеп байлык җыю өчен кирәк. Әгәр боларны ясарга мөмкин булса, алар бик күбәерләр, аларны берәү дә алмый башлар һәм әлеге хикмәт юкка чыгар иде. Тограиның бу кыйммәтле ташлар турында кимиачылар белән бәхәсләшү тәртибендә бик яхшы һәм мәгънәле итеп язылган шигырьләре бар. (332 б.)

Гыйльмес-сәясәт – тормыш гыйлеме. Бу өч төркемгә бүленә: беренчесе – дәүләт сәясәте; икенчесе – гаилә сәясәте; өченчесе – кешенең үз, шәхси сәясәте. Бу – кешелеклелекне нормальләштерү, зиһенне сафландыру, фикерне яхшырту, акылны күркәмләү, дөрес карашлы, кечелекле, турылыклы, сабыр, тыйнак, хәмиятле, йөкләмәне үтәүче, күркәм холыклы, канәгатьле, вәкарьле, намуслы, вәгъдәле, якыннарына рәхимле, изгелекле, Аллаһ мәхлукларына шәфкатьле, үзара гадел, ышанычлы, инсафлы, тәвәккәл, кешеләр арасын төзәтүче, ихлас белән гыйбадәт кылучы булу, оят саклау, бидгать һәм бозыклыклардан, бозык кешеләр белән аралашудан сакланып, турылыклы кешеләргә юлдаш булу кебек, шәригатькә һәм хикмәткә муафыйк рәвештә кешенең үз хәлен төзәтүе һәм кәмаләт хасил итүе – болар барысы да әхлак китапларында тәфсилләп сөйләнгәннәр.

Икенчесе – монда дүрт эш карала: ир һәм хатын, балалар, хезмәткәрләр, малларга бәйләнешле мөнәсәбәтләр: аларның хәл-

[1] Сүз алтын белән көмеш турында бара.

ләрен белеп тору, эшләрен күзәтү, аларга күркәм мөгамәлә итү, керем-чыгымны тигезләү h.б.

Әүвәлгесе – солтан, вәзир, идарә башындагы кешеләрнең, патша табибының, утырдаш һәм киңәшчесенең, азык-төлек белән идарә итүчеләрнең, гаскәр һәм сугыш коралларының торышы, культура һәм ярдәм эшләренең хәле, каләм ияләренең, кылыч ияләренең, гыйлем ияләренең хәлләренә карата гадел мөнәсәбәтне күзәтеп тору, Аллаһның боерыкларын үтәп, тыйганнарыннан тыелу, ил чигендәге ныгытмаларны саклау, гаскәрне кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү, гаделлек һәм инсаф белән халыкның хәлен яхшырту; эшлексез һәм җинаятьчеләрне тыю, чит илләр белән бәйләнешне җиңеләйтү, юлларның тынычлыгын тәэмин итү, төзәтү h.б.

Ислам галимнәре уйлап чыгарган яңа гыйльми үзәкләр

Болардан – гомуми мәктәпләр. Мөселманнар берәр шәһәрне сугышып алсалар яки берәр авыл төзесәләр, анда мәчет, ә аның янында мәктәп салалар иде. Шуңа күрә мәчетләр, мәктәпләр һәм мәдрәсәләр шул урынның таләбенә карап күбәя бардылар; анда шәкертләр туплана, төрле гыйлемнәрдән дөрес әйтә торган мөдәррисләр билгеләнә иде: Мисырда бик күп кешене сыйдыра ала торган олы мәдрәсә, Искәндәриядә зур-зур егерме мәдрәсә булып, анда, хикмәт гыйлемнәрен өйрәнү өчен, дөньяның төрле почмакларыннан күп кеше җыела иде.

Болардан – гыйлем мәҗлесе һәм фәннәр йорты. Аны фарсыда «әнҗәмәи данәш» дип, грекча «академия» дип атыйлар иде. Болар һиҗрәттән икенче гасырда (милади VIII гасырда) Басра, Күфә, Багдад h.б. шундый зур шәһәрләрдә төзелделәр. Шуннан гарәп теле һәм әдәбияты гыйлемнәре «басри», «күфи», «багдади» дигән юнәлешләргә бүленделәр.

Болардан – нәфис китаплар белән тулган китап хәзинәләре – Багдад, Басра, Күфәдәге китапханәләр. Болар барысы да элекерәк заманда ислам әсәрләренә ваемсыз караган агрессорлар тарафыннан мөселман мәмләкәтләренә озак вакытлар

китерелгән бәлаләр аркасында һәлак булдылар. Риваятьләргә караганда, татар патшаларыннан Һәләку (Аллаһ аны һәлакәткә хөкем итте) һөҗүме вакытында Диҗлә (Тигр) елгасы фәнни китаплар белән бөялеп, агудан туктады, суы кара булып акты. Толедо[1] шәһәренең епископы да ислам галимнәре язган яхшы китаплардан сиксән меңнән артыкны яндырды.

Әфрәнҗ[2] тарафыннан Гарната шәһәре сугышып алынгач, меңәрләгән-меңәрләгән китапларны яндырдылар. Башка бик күп урыннарда шундый хәлләр булды. Шуңа күрә ислам галимнәренең кыйммәтле, иң яхшы, нәфис әсәрләреннән бик азы гына сакланып калды.

Болардан – аптека ачу. Дөньяда беренче тапкыр аптека Багдадта 184 (800) елда Рәшиднең хәлифәлеге дәверендә ачыла.

Болардан – күп сандыкларда кабатлану сәбәпле барлыкка килә торган җил ярдәмендә хәрәкәт итүче җил тегермәне төзеделәр. Бу – 29 (649–650) елда Госман разый Аллаһу ганһе заманында булды.

Болардан – Европа халыклары гарәп цифрларын алдылар, бу аларның шәһәрләренә 40 (660–661) елда керде.

288 (900–901) елда әл-Мөтәвәккил хәлифә заманында шикәр кулланыла башлады.

Болардан – механика; көпчәкләрне хәрәкәткә китерә торган кораллар (механизм) уйлап чыгару. Шушы юл белән беренче сәгать 143 (760–761) елда Күфә шәһәрендә Мансур хәлифә заманында эшләнде. Европа шәһәрләренә ул беренче тапкыр 184 (800) елда Һарун әр-Рәшид тарафыннан Франция короле Шарлман Бибин углына җибәрелгән бүләкләр арасында иде. Моны күреп, алар бик гаҗәпләнделәр һәм аптырашка төштеләр. Аларның кайберсе бу кеше кулы белән эшләнгән

---

[1] Толедо – Испаниядә Толедо шәһәре Мадридтан 61 километр ераклыкта. Испания ярыматавында гарәпләр хөкүмәте яшәгәндә, атаклы гыйлем үзәге булган. 1085 елда Альфонс VI тарафыннан сугышып алынган.

[2] Әфрәнҗ – француз. Бу урында испанлылар дип аңларга кирәк.

нәрсә түгел, бәлки күктән иңгән, диде. Кайберсе бу сихер белән эшләнгән эш дип карады. Алар арасында хәрәкәтне булдыру өчен эчендә нинди дә булса хайван булырга тиеш дип уйлаучылар да булды[1].

Алар сәгать һәм аны йөртү өчен гаҗәп кораллар уйлап чыгардылар. Ибне Җөбәйрү Хахам Биньямин әл-Яһүди сәяхәт вакытында очраган гаҗәп нәрсәләрен искә ала. Ул, Димәшкъка кергәндә, капка төбендә өй стенасындагы уентык эчендә бакырдан эшләнгән ике түгәрәк пластинка өстендә бер сәгать күргән. Бу ике пластинканың һәрберсендә көндезге сәгать хисабы белән унике кечкенә ишек бар икән. Анда янә унике бакыр түгәрәк. Ул түгәрәкләрнең һәрберсенә хрусталь батырылган, ә аларның артларына, йолдыз сәгатьләренә туры китереп, тәртипле рәвештә яктырткычлар тезелгән. Көн башлану белән, бу ишекләрнең берсе ачылып, аннан бакырдан эшләнгән каракош күренә; аның борын очында кечкенә бакыр шар. Ул кош, муенын сузып, борын очындагы бакыр шарны үзе чыккан тишек төбендәге тазга ташлый, шулвакыт таздан бик матур тавыш яңгырый. Читтән килгән кеше аны сихер эше дип уйлый. Бакыр кош әлеге тишектән кире кереп югала, ишек ябыла, ә бакыр шар таздагы бер тишектән яшертен генә алына. Көндезге унике сәгать үткәнче, һәрбер ишектә шушы хәл дәвам итә. Кояш баткач, тагын икенче төрле гаҗәп хәл күренә башлый, югарыда әйтелгән яктырткычлар тәгәрмәчләр өстендә сәгатьләр тәртибенчә дөрес хәрәкәт итә башлыйлар. Бер сәгать үткән саен, түгәрәк өстендәге хрусталь турысына

---

[1] Рәшид тарафыннан Франция патшасы Карл Великийга 184 елда җибәрелгән бүләкләр арасындагы бу сәгать Европада беренче сәгать иде. Бу сәгать бик пөхтә итеп эшләнгән, анда вакыт бакыр савыт эченә бер-бер артлы сугу ярдәме белән белдерелгән. Бу савытта һәрберсе ике ат рәсеменнән торган 12 сурәт булып, суккан саен алар ачылып, соңыннан ябыла торган булганнар. Моңа халык бик гаҗәпләнгән һәм сихер белән эшләнгән дип уйлаган. Әгәр патша үзе булмаса, бу сәгатьне шайтан эше дип карап, ватып ташлаган булырлар иде. Европаның кайбер олылары шулай дип әйтәләр, Аллаһ аларны дөрес юлга күндерсен. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

киләләр. Яктырткычның шәүләсе хрустальгә төшә, аннан бүтән хрустальләргә чагыла һәм гаҗәп матур җемелдәү, ялтырау хасил була. Түгәрәкләр тәртибенчә бу хәрәкәт төне буе, унике сәгать үткәнче дәвам итә.

Болардан – тәгәрмәчләр өстендә үз-үзеннән хәрәкәт итүче бүлмәләр һәм башка шундый гаҗәп нәрсәләр.

Болардан – туп, дары, мылтык кебек төрле кораллар (Европа осталарының һәм француз галимнәренең һ.б. тануынча).

Болардан – кәгазь эшләп чыгару һөнәренең мәгълүм булуы, таралуы, күбәйтү, яхшырту һәм ефәктән, мамыктан, киндер сүсеннән кәгазь эшләп чыгару. Йосыф бине Гомәр әл-Мәкки, Хиҗазда һиҗрәттән 88 (707) елда мамыктан кәгазь ясауны, ә Муса бине Насыйр көнбатыш (гарәп) шәһәрләрендә җитен һәм киндер сүсеннән кәгазь эшләп чыгаруны уйлап чыгарды. Бу һөнәр элек кытайлар кулында иде, ә мөселманнар аны яхшырту чараларын күрделәр, сыйфатын бик нык күтәрделәр, төрле илләргә тараттылар, шәһәрләрдә аны күбәйттеләр. Шуннан кәгазь Европага күчте. Исламга чаклы ак тирегә язалар иде. Бу тире аз һәм бәясе кыймәт булганга күрә, күпләр аннан файдалана алмыйлар иде. Мөселманнар кәгазь ясау һөнәрен белгәч, аңа бик зур әһәмият бирделәр, ул эшне шул дәрәҗә алга җибәрделәр ки, хәтта кәгазь өстендә караучының сурәте күренә торган булды. Кәгазь, аның төрле төстәгеләре, бик матур бизәкләр төшерелгәннәре, тагын шундый нечкә һөнәрләр ярдәмендә эшләнгәннәре булды. Моннан башка да бик күп яңа, сирәк булган ачышлар ясалды, боларның барысын санасаң, күпкә китәр һәм истә тоту да кыен булыр.

Болардан – мохит диңгезендә яңа утраулар табу. Шәриф Идриси (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) һәм башкаларның хикәясенә караганда, галимнәрдән бер төркем белемгә омтылышлары, астрономия, геометрия һәм, гомумән, хикмәт гыйлемнәренең өндәве нигезендә мохит (океан) диңгезенең хәлләренә төшенү, анда яңа утраулар һәм башка гаҗәп нәрсәләр табу теләге белән шушы диңгезгә чыгып китәргә батырчылык иттеләр. Аңа кадәр әле бу эш кеше көченнән килә торган түгел иде. Моның өчен

алар мөкәммәл, нык эшләнгән көймәләр һәм яшәр өчен кирәк нәрсәләрдән: ашамлык-эчемлекне, кием-салымны һәм башка кирәкле коралларны алып юлга чыктылар. Бу – һиҗрәттән 433 (1041–1042) елда иде. Гарәп олыларыннан 80 ләп кеше, көймәгә утырып, Әндәлеснең Лишбүнә[1] шәһәреннән көнбатышка карап юлга чыктылар. 11 көн эчендә җил аларны Сәрәтан[2] йолдызы юнәлешенә алып китте; алар һаваның караңгылыгыннан, суның болганчыклыгыннан, көчле агымыннан курка башладылар.

Шуннан көньякка таба борылып, унике көн бардылар һәм кеше яшәми торган утрауга килеп чыктылар. Анда елга кырыенда хөрмә агачлары һәм көтүчесез бер төркем куйдан бүтән нәрсә юк иде. Куйны суеп пешерделәр. Ләкин ите бик ачы булганга күрә файдалана алмадылар. Әмма тиресенең кайбер кисәкләрен алдылар һәм утрауны «Куй утравы» дип исемләделәр. Аннан китеп янә 12 көн баргач, тагын бер утрауга килеп җиттеләр. Анда игенчелек һәм кешеләр яшәү билгеләре бар иде. Болар утрауга якынлашкач, кечкенә көймәләрдә утрау кешеләре килделәр, аларны яр буендагы шәһәргә китерделәр дә өч көн буе бер өйдә ябып тоттылар. Бу утрауда яшәүчеләрнең йөзләре бакыр кебек кызгылт, ә хатыннары бик матур һәм күркәм иде. Дүртенче көнне гарәпчә яхшы сөйләшүче бер кеше килде, хәлләрен, кайдан килеп, кая баруларын һәм ник баруларын сорашты; соңыннан иртәгесен шәһәр хакименә илттеләр. Ул тәрҗемәче аркылы боларның хәлен сорашты. Аңа бу диңгезнең хәлен өйрәнү өчен чыкканлыкларын, караңгылыкка барып җиткәч, кире борылганлыкларын сөйләделәр. Хаким аларны ябылган өйләренә җибәрде, алар анда көнбатыштан уңай җил искәнгә чаклы калдылар. Шуннан соң бу утрау кешеләре, үзләренең кем икәнлекләрен, кайда торганлыкларын яшерү өчен, юлчыларның күзләрен бәйләп, кечкенә көймәләргә утыртып, аларның үз көймәләренә алып киттеләр.

---

[1] Лишбүнә – Хәзерге Португалиянең башкаласы Лиссабон шәһәре.

[2] Сәрәтан – Кысла.

Алар көймәсендә өч тәүлек баргач, яр кырыена төшереп, агачка бәйләп, үзләре киттеләр. Юлчылар күзләре һәм куллары бәйләнгән килеш төн үткәрделәр. Таң вакытында болар кеше тавышы ишеттеләр һәм барысы да кычкырып, аны чакырдылар. Болар янына бәрбәрләрдән[1] бер төркем килеп, чишеп, бәйдән коткардылар һәм хәлләрен сораштылар, ә болар ни хәлләргә очраганлыкларын сөйләп бирделәр. Шуннан бу урында яшәүче берәү: «Лишбүнә белән бу урын арасы еракмы?» – дип сорады. «Белмибез», – дип җавап бирделәр. Теге кеше: «Ике айлык юл», – диде. Шуннан бу утрауның Көнбатышта иң чиктәге порт икәне мәгълүм булды һәм аннан Лишбүнәгә ике айда кайтып життеләр.

Ибне Әсир (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) үзенең китабында шулай дип язган.

Шаять Европаның соңрак халыкларына бу хәбәр ирешкән яки алардан калган китапны кулга төшергән булсалар кирәк. Чөнки Европалыларның бу диңгезгә чыгу һәм бару юллары ислам галимнәре юлы буенча булды һәм шул юл белән барып яңа җир – Американы ачтылар[2], дөресен Аллаһ белә. Мөселманнарның беренче чорларын, андагы күркәм эшләрне сурәтләгәндә, каләмнең матур юлы шушы чиккә килеп җитте.

Гыйлем-мәгърифәтнең, һөнәр-сәнәгатьнең барлыкка килүе һәм хәле, чикләренең диңгезләр кебек ярларыннан ташып киңәюе, җимешләренең үсеп җитешүе, алга китү омтылышлары, гаделлекнең торышы, төзелешнең күркәмлеге, илләрдә шәһәрләр үсүе – ислам килеп чыгуның беренче чорында әнә шулай булды; болар укыту, төрле һөнәрләр һәм гыйлемнәр уйлап табу, мәсьәләләрдән, төрле кагыйдәләрдән нәтиҗәләр чыгару, гакли һәм нәкъли мәсьәләләргә бәйләнешле атамалар төзү, аларның кагыйдәләрен билгеләү, аларны тәртипләү юлы белән үзләреннән элеккеләргә караганда тирән

---

[1] Бәрбәр – хәзерге Мароккодагы төп халыкның бабаларыннан.

[2] Мәрҗанинең бу сүзләрендә дөреслек юк түгел. Чөнки европалылар, Американы ачканда, иң элек Гренландиягә барып чыгалар.

белемле, соңгылардан да өстенрәк булдылар һәм билгеле максат белән хәрәкәт иттеләр.

Хәлифәлек һәм Багдад тәртипләре зәгыйфьләнү белән, бу хәлләр дә бетүгә йөз тотты, картлык килү, фикер көрәшләре башланып бердәмлек бетү сәбәпле, ислам бу күркәм хәленнән түбәнәюгә йөз тотты, мәгариф, һөнәр һәм сәнәгать бер-бер артлы югала барды; укыту эшләре түбәнгә китте, килешеп эшләүләр кул тимәгәндәй онытылды, гыйлем һәм һөнәрләрне өйрәнү, үстерү дөньяга кояш кебек нур һәм яктылык сипкәннән соң, бетүнең чигенә килде. Аның эзләрен өйрәнү һәм күркәм рәвештә өйрәтү юллары, наданлык сәбәпле, яшерен калды. Аңа төшенү, эзләрен табу, белем һәм осталыкка ия булу кыенлыкның чигенә җитте. Әгәр һөнәрчелек, культура һәм уку-укыту эшләре сүнә барып, түбәнге, наданлык чокырына, югалту һәм җимереклеккә таба төшә баруында дәвам итсә, бу гасырдан яки киләчәк гасырдан соңгы кешеләрнең янә наданлык дәверенә һәм мәҗүсилек гадәтләренә кайтуы куркынычлары бар... (336 б.)

Бел: һәрнәрсәгә афәт килергә мөмкин. Ә гыйлемгә исә күптөрле афәтләр килә ала. Безнең арабыздан гыйлемнең күтәрелүенә, кәмаләтнең сүнүенә китерә торган афәтләрнең берсе – урынга – шартларга туры килми торган эшләрнең таралып һәм тиешле чикне үтеп китеп, гореф-гадәтләрдә ныгуы, вакыйга-тормышка каршы барганнарның кешеләр аңында оя табуы, Аллаһ хөкеменнән һәм гакыл чикләреннән узып китү.

Бу афәтләрдән берсе – иҗтиһад[1] гасыры үтте, мөҗтәһидләр бетте[2], ә дәлил китереп сүз сөйләү, фикер әйтү бары мөҗтәһидләр эше, мөҗтәһидлек дәрәҗәсенә ирешү юллары киселгән, китап язучылар арасында, сүзләрендә һич ялган һәм ялгыш булу ихтималы булмаган, гөнаһлардан пакь булган пәйгамбәр дәрәҗәсендәге кешеләр юк. Хәзерге заман галимнәренә мондый пакь, олы юлга керү мөмкин түгел. Әгәр кем дә булса шундый юлга керергә батырчылык итсә, ул кеше ялганчы, яла

---

[1] Диалектик уйлау чоры.

[2] Диалектик уйлаучылар бетте, догматиклар гына калды, дигән сүз.

ябучы, аның сүзләре дөрес булу ихтималы юк, шуңа күрә кире кагылырга тиеш дип карау.

Бу афәтләрдән берсе – хикмәт гыйлемнәрен, аның төрле тармакларын инкяр итү, аны белүче, шуңа таянучы һәм саклаучыларны хурлау һәм кимсетү; кыйбланы һәм иман сүзләрен таныган кешене, бик кечкенә мәсьәләләрдә дә фикер йөрткән, үзенчә караган өчен кяфер дип читкә кагу; «Кәшшаф», «Әнвар», «Фосус», «Ишарат», «Шифа», «Нәҗат» китапларын гына түгел, бәлки хөҗҗәтел-ислам Газали, Кәмалетдин бине әл-Һөмам һ.б. төзегән әсәрләрне кулланган өчен хурлау, шуның аркылы бу мактаулы китаплар эчендәге нечкә тикшеренүләр, хакыйкатьләрдән, чиксез күп файдалардан мәхрүм итү.

Бу афәтләрдән янә берсе – наданнарның галим, бозыкларның яхшы булып танылулары, шул исем белән дан алулары. Бу кешеләрнең шулай галимнәрчә кыланулары тәкәбберлекнең иң әшәкесе, гөнаһларның, зарарларның иң авыры. Мондый кешеләр гыйлем алу мәйданнарын тарайталар, киңәйтү һәм тирәнәйтүгә ирек бирмиләр, хаклык һәм тирәнтен тикшерү ягындагы галимнәр тарафыннан язылган китаплардагы нечкә мәсьәләләрне, дәлилләрне өйрәнүдән шәкертләрне тыялар, аларга нәфрәт тудыралар, юлларын биклиләр. Үзләре уйлап чыгарган төрле ялалар белән андый китапларның һәм ул китаплардагы мөһим мәсьәләләрнең әһәмиятен киметәләр, төшенүе читен булган авыр мәсьәләләрдә, фикер тоткарланган урыннарда андый кешеләрнең аңнары чуала. Бу эш аларның күзләренә пәрдә, аякларына богау була. Укуга каршы торучылар барысы да шундый кешеләр. Аллаһ аларны дөрес юлга күндерсен иде. Менә шул хәлләр, гомумән, кешеләрне укуөйрәнүдән читкә тибәрделәр, нәфрәт тудырдылар, тырышлыкларын гыйлем-мәгърифәткә ят булган нәрсәгә сарыф кылдырдылар. Белеме, изгелеге булмаган, хәдискә иярмәгән, билгеле юлы булмаган бер надан кеше шәехлек дәгъвасы кыла башлый, кешеләрне ялган тыныч лануга, дөнья тормышы киң, дәрәҗәсе югары кешеләргә тиешсез хөрмәт күрсәтү һәм шулар артыннан

котырган эт кебек чабып йөрү рухында тәрбияләргә иҗазәт-рөхсәт ала: садә халык шуларга иярә, алар тирәсенә эшлек-сезләр туплана. Мондый кешенең дәрәҗәсе күтәрелә, кадере зурая, аркасы ныгый, турая; кешеләр аңа киләләр, баш ияләр, уйлары, фикерләре аңа юнәлә, башкаларның сүзен исә ялганга чыгаралар.

Әмма чын галим гыйлемнең дәрәҗәсен олы дип тануы һәм буш вакытының булмавы сәбәпле, андый надан шәехләргә баш ими, түбәнчелек күрсәтә алмый. Шуның аркасында кешеләрдән ераклаша, һиммәт ияләреннән, байлардан килә торган ярдәмнән аерылып читтә кала, хәле начарлана, белемендә һәм күркәм сыйфатларында торгынлык килеп туа. Гыйлемгә килә торган зур афәтләрнең берсе дә менә шул.

Үз халкыбызга килгәндә, аның гыйлемнән бизүенең сәбәп-ләре: уку өчен кирәкле һәм файдалы нәрсәләрнең, укырга кы-зыктырып өндәүчеләрнең булмавы; укуны тәмамлагач, уйланган дәрәҗәгә ирешү өметенең киселгән булуы, чөнки бездә укыган-нар белән укымаганнар арасында бер төрле дә аерма юк, укыган кешеләрнең тормышларын рәткә салырлык килерләре һәм аны кайгыртучылар юк; укыган кеше гыйлем ярдәмендә киң тормыш төзерлек мал таба алмый, властька яки дәрәҗәгә ирешә алмый. Иң ахыргы чиктә аның ирешкән нәрсәсе – җитәрлек тәэмин ителмәгән муллалык һәм мөдәррислек. Ләкин бу урыннар да хәзер гыйлем һәм фазыйльлек юлы белән түгел, бәлки варислык юлы белән күчә башлады.

Болардан – галимнәрнең дәрәҗә һәм хәлләре, тораклары, йөрү чаралары, гомумән тормыш шартлары байлар һәм сәүдә-гәрләрнекенә караганда түбән булуы. Нәтиҗәдә, кешеләр, бик сирәкләреннән башкалары, балаларын гыйлем юлына өндә-миләр, бәлки сәүдә һәм бүтән төрле кәсепне алда күрәләр. Бел: гыйлем һәм мәгарифтән торган ике өлеш, аларның тууы, диңгез булып ташуы, фикерләрнең, гыйлем базарларының киңлеге, дәрәҗәсенең гаять югары күтәрелүе, гыйлем яктылы-гының, культура нурларының җир йөзендә көнчыгышка һәм көнбатышка җәелүе, дәрәҗә-дәрәҗә күтәрелеп кәмаләткә

ирешүе – болар барысы да Габбасилар хәлифәлеге чорында, аларның җир йөзендә өстенлеге ярдәмендә, алар хакимлегенең кадере, көче бар чакта булды.

Европа галимнәре гарәпләрнең бу хезмәтен таныйлар һәм аның ияләренә тиешле хөрмәт күрсәтәләр иде. Инсафларын югалткан тискәре кешеләр, моның белән килешмәүчеләр киреләнделәр, аларны гарәпләрнеке түгел, бәлки юнан галимнәренеке дип санадылар. Ә юнан галимнәре бүләк иткәннең һәрберсен яшь бала хәленнән зур кеше хәленә килгәнче тәрбияләп үстерүче, камилләштерүче ислам дәверендәге гарәп галимнәре түгелмени? Кайбер инсафсыз кире кешеләр ислам галимнәре хезмәтләренең дәрәҗәсен төшереп, кимсетеп, бу культураны үстерүчеләрне Әндәлестәге Өммия нәселеннән килгән патшалар исеме белән бәйлиләр. Борынгыдан килгән иске йолалар белән сикерә-сикерә мактану, үз-үзенә исе китеп тәкәбберләнү, потларына дошманлык итүчене хурлап, потлары алдында ялагайлану, яхшы атлы булу, аларны сөймәүченең бәхетсезлегенә шатлануда зирәклек күрсәтү – менә болар барысы да искелек гадәте.

Илләрендәге кешеләрнең саны, дәүләтләре чәчәк аткан дәвердә 20 миллионнан да артмаган бу кечкенә мәмләкәтне халкы 500–600 миллионнан артып киткән Габбасилар хәлифәлеге белән ничек чагыштыру мөмкин[1]. (345 б.)

Бел: чын падишаһлык кеше өчен табигый булган югары дәрәҗәле урын, чөнки ул табигате белән культуралы, җитәкчелек итү һәм үзенә буйсындыру, хөкемнәрендә гаделлек һәм җәбер-золымның булмавы – моның югары максаты. Чөнки кешенең тереклеге һәм яшәве, үзенә кирәк нәрсәләрне һәм көчне булдыруы фәкать җәмгыять төзеп үзара ярдәмләшү белән генә хасил була. Менә шул кирәклек, зарурәт, кешеләрне бергә, бер коллектив булып эшләшергә, үзара ярдәмләшергә өнди. Үз шәхси кирәкләре өчен иптәшләренекенә кул сузу,

[1] Бу урында Мәрҗани Багдад хәлифәлегенең Әндәлестән өстенлеге, гыйлем-мәгърифәтнең үзәге Багдад икәнлеген сөйли.

үзләштерү, ачу, тәкәбберлек һәм көч кулланып бер-берсенә аркылы төшү, бер-берсен тоткарлау, үзара дошманлашу – хайванлык табигатеннән килгән сыйфатлар. Шуның аркасында кешеләр арасында үтерешләргә, кан коюларга, нәсел киселүләргә китерә торган талашлар була. Шулай итеп, кеше тормышында тәртипсезлек, анархия, мәгънәсезлек, бушлык килеп чыга. Шуларны булдырмас өчен, кешеләр бозыклыктан тыючы, араны төзәтүче бер кешегә мохтаҗ булалар. Илне һәм аның тынычлыгын саклый алсын өчен, мондый кешенең тулы ирекле хаким булуы кирәк. Бу исә аның ил халкын буйсындырып, тиешле салымнарны җыеп, илчеләр җибәреп, чикләрне саклый алырлык гайрәте, ватанына көчле мәхәббәте аркасында гына була ала. Аның кулыннан өстен һәм көчле кул булмый, бөтен илләр аның кулына күчәләр, хәтта барысы бер ил-ватан булып әверелә; башкаларга караганда аның көче өстен була, ул җиңә һәм халыклар, дәүләтләр бергә җыелалар. Бу – мактаулы һәм ләззәтле урын; ул дөньядагы барлык изгелекне, тән таләпләрен, җан ләззәтләрен эченә ала, шунда инде узышу, конкуренция, көнләшү туа.

Әйт: җиңелми торып, бу югары урынны берәүнең икенче берәүгә бирүе сирәк була. (349 б.)

Әхмәд бине Фазлан һәм башкаларның хикәят итүенә караганда, әгәр Болгарларда җаһилият[1] заманында бер галим яки оста кеше килеп чыксса, әйтә булганнар: «Бу Аллаһка якын булырга лаек, безнең арадан Аллаһка күтәрелергә тиеш», – дип һәм, үтереп, кабергә күмгәннәр, каберен кыйбла ясап, аңа зиярәт итә булганнар[2]. Шулай булгач, аларда ничек гыйлем үссен дә, үзен үлемгә, күмеп куюга сәбәп була торган эш белән кем шөгыльләнсен? Шуңа күрә, болгарлар ислам динен кабул итүдә

---

[1] Җаһилият – караңгылык, наданлык; исламга кадәрге чор.

[2] Ибне Фазлан әсәренең Мәшһәд нөсхәсендә һәм «Мөстәфаделәхбар»нең I кисәгендә язылуынча, галим кешене үтерсәләр дә кабергә күммиләр, бәлки агач ботагына асып куя булганнар. Шунда мәетнең гәүдәсе кибеп, таралып юкка чыгып бетә булган. Бу китабында Мәрҗани «кабер» сүзен, бәлки үлек гәүдә мәгънәсендә йөртәдер.

элгәре һәм культурада алга киткән булсалар да, алардан гыйлем дип исемләнерлек бик аз нәрсә калды. Мин бу фикерне Гаяз бине Хәбиб һәм башкалар булган бер мәҗлестә әйткән идем, ул: «Безнең халкыбыз – борынгыдан ук гыйлемгә каршы һәм гыйлем ияләренә дошман инде», – диде.

Шәех Хәсән бине Гомәр әл-Болгари (ул «Садр әш-шәрига»нең[1] шәехе һәм аны үзенә иярткән кеше) Болгар шәһәрендә иде. Аңа төрлечә яла яктылар, аңа каршы күтәрелделәр, явызлык тарата дип, манарадан ташлап үтермәкче булдылар, ләкин аны Аллаһ саклады, аңа явызлык ирешмәде, Урта Азиягә китеп котылды. Бохарада, аннан соң Тәбриздә яшәп, 699 (1299) елда үлде. (357 б.)

[1] Садр әш-Шәрига – Хәнәфи мәзһәбенең күренекле факиһләреннән Гобәйдулла бине Мәсгуд әл-Мәхбуби (?–1344 яки 1346).

«ВАФИЯТЕЛ-ӘСЛЯФ ВӘ ТӘХИЯТЕЛ-ӘХЛЯФ» ӘСӘРЕННӘН ТӘРҖЕМӘЛӘР

Әбү Гали Сина

Һиҗри дүрт йөз егерме сигезенче (1036–1037) елда үлгән кешеләр: Әбү Гали Хөсәен бине Габдулла бине Хәсән бине Гали әл-Бәлхи әл-Хәнәфи «Шәйхе рәис ибне Сина» дип атаклы. Рамазан аенда җомга көн Һәмәдан шәһәрендә вафат булып, кальга астында күмелде. Кайберәүләр гәүдәсе Исфаһанга күчерелде дип тә әйтәләр. Өч йөз җитмешенче (980) ел сәфәр аенда туган иде. Анасы Сарә исемле, атасы Бәлех шәһәреннән. Атасының тормышы еш үзгәрүчән булып, төрле район-аймакларда солтанның казыйсы, әмире булып хезмәт итте. Мавәраэннәһергә күчеп, Харматин авылында дәүләт эшләрен башкаручы вәли – башлык булды, шунда өйләнеп, алардан шәйхе рәис туды. Бу кеше җәмәгать олыларының берсе, ислам философларының корифее, гыйлемдә, зирәклектә, уй һәм акылның киңлегендә, мәгърифәтенең тулылыгында үз чорының сирәк очрый торган кешеләренең берсе булган Ибне Сина иде. Бу бала, нигездә, шәригать белемнәре белән сугарылган, хикмәтнең, фәннең барлык тармакларын үзләштергән, ярыш баскычының иң югарысына ирешкән, аның әйткәннәре мәкаль буларак йөртелә торган зур бер галим булып җитеште. Иң алдынгы галимнәр аның тирәсенә туплана торган булды.

Әз-Зәһәби исемле бер галим үзенең «Тарихе ислам» исемле китабында, Әбү Гобәед Габделвахид бине Мәхмүд әл-Җузҗани исемле галимгә таянып, аның турында түбәндәгеләрне язды:

Минем атам Нух бине Мансур исемле хөкемдар заманында Бохарага күчте. Мине Коръән һәм әдәбият укытучы мөгаллимгә тапшырдылар; ун яшем тулганда, мин Коръәнне һәм әдәбияттан күп нәрсәләрне укыган идем, хәтта мин бераз масая башладым. Әткәм ... Исмәгыйлия мәзһәбеннән санала иде. Алардан җан һәм гакыл хакында күпләрне ишеткән һәм үзе дә сөйләгән иде. Шулай ук үзем белән бертуган ир кардәшем дә шуны сөйли иде. Алар сөйләгәннәрнең байтагын мин дә тыңлый һәм әйткәннәрен аңлый идем. Әмма алар сөйләгәннәрне үземә кабул итми идем. Алар исә мине шуңар өндиләр, телләрендә «философия», «гео-

метрия», «математика» дигән сүзләр йөри иде. Миндә дә хисап өйрәтүче укытучыга йөрү теләге туды. Әбү Габдулла ән-Натили исемле бер философны безнең өебезгә китереп куйды. Мин, ул килгәнгә чаклы, фикъһе белән шөгыльләнә, ә шәех Исмәгыйль Заһидкә карата икеләнебрәк – шикләнебрәк тора идем. Мин гыйлем-мәгърифәт юлына керүчеләрнең яхшыракларыннан, юмартракларыннан санала, һәм моназарә-бәхәсләшүгә күнеккән идем. Ән-Натилидә дәресне «Исагуҗи» китабын укудан башладым. Миңа, җенеснең чиге дип, төрле нәүгыләрдән булганнарны берләштерүче як әйтелә икәнен үзенчә җентекләп аңлата башлады. Моңарчы мин ишетмәгән нәрсәләрне сөйләп, бик гаҗәпкә калдырды. Әтиемә мине гыйлемнән башка белән шөгыльләнүдән сакларга кушты. Ул нинди мәсьәләне әйтсә, мин аны үземчә аңлый идем, ул мантыйкның ачык билгеле мәсьәләләрен генә укыта, әмма нечкәрәк мәсьәләләрен яхшы белми иде. Аннары мин, күп китапларны үзлегемнән укып, шәригать кануннарын тикшерә башладым, хәтта мантыйк гыйлемен дә өйрәндем. Шулай ук Эвклид «Хикмәт»ләреннән баштагы биш-алты шәкелгәчә булган барлык параграфларны укып үзләштердем. Аннары калган матдәләрне дә аңларга тырыша башладым. Шуннан соң Мәҗсәтыйга күчтем. Аның мокатдимә – кереш сүзләрен өйрәнеп, геометрия шәкелләренә килеп җиттем. Шулчакта Натили миңа: «Ул мәсьәләләрне үзең мөстәкыйль рәвештә хәл кыл, аннары миңа күрсәт, мин ачыклармын», – диде. Аңлашылмаган бер шәкел дә булмады, әгәр андый берәр шәкел булса, аңар күрсәтеп аңлаша идем. Ахыр ул китте. Мин табигать һәм илаһият (теология) гыйлемнәрен өйрәнергә керештем, минем өчен гыйлемнең төрледән-төрле баблары ачыла башлады. Мин тыйб – медицина фәне белән дә кызыксынып киттем, ул фән буенча озак вакытлар эшләдем, күтәрелдем, хәтта табиблар үзләре миңа килеп укыйлар, миннән өйрәнәләр иде. Мин авыруларны да карый идем, шул арадагы тәҗрибәләремнән миңа сүз белән генә аңлатып булмаслык нәфис дарулау юллары да ачылды. Ләкин мин шушы эшләрем белән бер үк вакытта фикъһе – ислам хокуклары белән дә мавыга, тирәнәя, күп мәсьәләләр буенча

бәхәсләшә идем. Уналты яшькә җиткәч, яңадан мантыйк укырга, философиянең барлык өлешләрен тирәнтен өйрәнергә керешеп, бер ел ярым тырыштым – эшләдем, бер генә төнне дә тулысынча йокламадым, бер генә көнне дә бүтән фәннәр белән шөгыльләнмәдем. Алдыма чыганаклар куеп, һәрбер дәлил кирәк булган саен шуларга карый һәм алдан кыяс кылып уйлаганнарны исбатлый идем. Шул ачышларны тәртипкә куеп, аларның нәтиҗәләрен көтә идем, өйрәнелә торган мәсьәләнең хакыйкате тәмам ачылганга чаклы, куелган гипотезаларның барлык шартларын җиренә җиткереп, шуңар ригая кыла идем.

Әгәр берәр мәсьәләдә аптырауда калсам, яки үземнең чамалаганымча уртача гына булса да уңышка ирешә алмасам, мәчеткә барып намаз укыйм, барлык мәхлүкатны барлыкка чыгаручыга – Аллаһга юнәлә, төшенә алмаганнарымны ачуын, авыр эшләремне дә ансатлаштыруын сорый идем. Төн булгач, өемә кайтып, яңадан уку-язу белән шөгыльләнә башлыйм, әгәр инде үземне бик каты йокы басса, яки үземнең беркадәр хәлсезлегемне, арганымны сизсәм, гөнаһлы булып, берәр касә шәраб эчә идем. Шунда миңа көч кереп, яңадан укырга тотынам, аз гына йокым килсә, әлеге мәсьәләләр беленгән дип хөкем итәм, хәтта бик күп мәсьәләләрне йокларга яткач ачыклый идем. Йокы арасында ачыкланган мәсьәләгә көндез бернәрсә арттырылмый иде. Шулай итеп, мантыйк, табигыять, математика фәннәрен дә өйрәндем, белемемне ныгыттым. Аннары өлүһият гыйлеменә кайтып, табигыятьтән соң, илаһият мәсьәләсендәге китапларны укыйм, алардагы кайбер мәсьәләне аңламасам, шул мәсьәләне куючының максатына каршы киләм, хәтта шуны кырыгар тапкыр кайта-кайта укый идем. Ниһаять, гыйбарәне ятка алган булам, ләкин максутны һаман да аңламаган хәлдә, аннан ваз кичәм һәм «бу китапны аңларга мөмкин түгел» дип ант итәм. Алай да көннәрдән бер көнне икенде вакытлары җиткәндә мин бер төркем китапчылар арасына килеп чыктым, бер дәллялның[1]

[1] Дәллял – борынгы чор базарларында әйберне кычкырып, димләп сатып йөрүче.

кулында бер төп китап бар, аны сатарга теләгәнен белдереп кычкырып йөри. Ул китапны миңа күрсәтте, ләкин мин әле икеләнә калдым, кире кайтардым. Ул миңа: «Китап арзан, өч дирһәм[1] генә тора», – диде. Мин дә аны сатып алдым, бу китап исә, Әбү Насыйр Фәрабиның «Фи әгъразый китаби ма бәгъдә әл-хикмәти әт-табигыяти» дигән китабы булып чыкты. Өемә кайтып, аны укырга ашыктым. Шунда ук миңа бу китапның максатлары ачыла башлады, мин дә бик сөендем. Аллаһка шөкер итеп, күп кенә садака бирдем.

Бервакыт шундый хәл булды: солтан Нух бине Мансур бик каты чирләгән булган, имче, табиблар аны дәвалаудан гаҗиз калгач, аның алдында минем исемемне телгә алганнар. Шул уңай белән мине дә китерделәр, дәвалауда мин дә катнаштым. Шулчакта мин солтаннан үзенең китаплар хәзинәсенә кереп укырга, кайберләрен язып алырга миңа рөхсәт бирүен сорадым. Ул рөхсәт бирде. Керсәм, анда барлык фәннәрдән санына-хисабына чыкмаслык күп китап икән. Шундый китаплар күрдем ки, күп кешеләргә аларның исемнәре белән генә дә очрашырга туры килмәгәндер. Мин ул китапларны укыдым, андагы белемнәрне казандым, һәр кешене гыйлеменә карап мәртәбәсен аера алдым – таныдым. Унсигез яшем тулганда, мин бу гыйлемнәрнең барысын өйрәнеп бетергән идем. Ул чакта мин гыйлемне тиз отып алучан һәм хәтердә саклый алучан идем, ә бүген гыйлем алу өчен мин тагын да өлгергәнрәк, юкса гыйлем үзе генә миндә бер яңалык та тудырмый. Минем күршем Әбү Хөсәен миннән гаруз гыйлеме хакында сорап, шул хакта тулы – мөкәммәл бер китап язуымны үтенде, мин аңар шундый китапны төзедем, шуның исеме белән үк атадым, анда математикага башка гыйлемнәрдән күп мәгълүмат тупладым. Ул чагында миңа егерме бер яшь тулган иде.

Шулай да күршебез Әбү Бәкер әл-Берканый әл-Харәзми дигән фәкыйһ тә миңа үзенең үтенечен белдерде. Ул үзе фикъһе һәм тәфсиргә, зөһедкә (хәрам эшләрдән, бозыклыклардан

[1] Дирһәм – гарәп илләрендә акча берәмлеге.

саклануга) бик бирелгән кеше иде, шулар хакында бер китапка шәрех-аңлатма язуымны сорады. Мин дә аңар егерме томлык чамасында зур бер китап төзедем, исемен «Әл-хасыйль вә әл-мәхсул» дип атадым, шулай ук аның өчен «Китабел-бирри вә әл-исм» («Изгелек һәм явызлыклар турында китап») исемле китап төзедем. Бу ике китап аннан башка кешедә юк, һәм ул аларны һич берәүгә биреп тә тормый.

Аннары атам үлде, ул чакта миңа егерме ике яшь иде, минем дә хәлләр үзгәрде, мин солтанның кайбер хезмәтләрен башкара торган булдым. Тормышның кушуы буенча мин Керкәнежгә күчәргә тиеш булдым. Бу гыйлемнәрнең дусты Әбү Хәсән әс-Сәһли анда вәзир булып тора иде. Мин шәһәрнең әмиренә – Гали бине Мәәмүн бине Мөхәммәд янына килдем. Тамак астыннан тайласан[1] бәйләгән хәлдә фәкыйһләр җыелышында булдым. Миңа җитәрлек айлык һәм йорт билгеләделәр. Бер кадәр вакыт үткәч, Нәсаэ (Нәхшәб, Карши) шәһәренә, аннан Урду белән Тус шәһәренә, аннары Җаҗеремгә (Хорасанның таулык өлкәсе), аннан Җөрҗанга күчтем. Теләгем Кабусның әмиренә бару иде. Әмма шул арада гына Кабус ул әмирне тоткынлыкка алган икән. Мин Дәһистанга уздым, анда бик каты авырып, Җөрҗанга кайттым. Шунда миңа Әбү Гобәед әл-Җүзҗани килеп җитте». Ибне Синаның үз сүзләре бетте.

Аннан соң Рәй шәһәренә күчте, әл-Мәсидәгә һәм аның углы Мәҗдеддәүләгә хезмәт итте, аны сәүда – үт шеше авыруыннан дәвалады. Шәмседдәүлә, Һилал бине Бәдерне үтереп, Багдад гаскәрен тар-мар иткәнче, хәл шулай торды. Аннан соң Ибне Сина Казвин һәм Һәмәдан ягына чыгып китте. Шәмседдәүләне куланҗ[2] хастасыннан дәвалап, аның хезмәтендә, якыннарыннан булып, Һәмәданда калды. Аңа вәзир булырга тәкъдим иттеләр, ул хезмәтне дә йөкләде, гаскәр аннан куркып баш күтәрде, йортын талады, аны үтерүне әмирдән таләп итте. Әмир моңа күнмәде, шәһәрдән сөрергә сүз биреп, гаскәрне тынычландырды.

---

[1] Тайласан – гарәпләрнең тамак астыннан бәйләп куя торган озынча шарфсыман баш ябулыклары.

[2] Куланҗ – эч авыртуы, кату.

Ибне Сина шәех Әбү Сәгыйднең йортында кырык көн яшеренеп ятканнан соң, Шәмседдәүләнең чире яңадан көчәеп китү сәбәпле, шәех Ибне Синадан бик нык гафу үтенеп, аның кайтуын сораган. Шәех Ибне Сина аны тагын дәвалаган, икенче тапкыр вәзирлек хезмәтен өстенә алган. Әбү Гобәед әйткән: «Бервакыт мин аннан Аристотельнең китабына шәрх язуын сораган идем, ул миңа буш вакытым юк, әгәр риза булсаң, бер китап язармын һәм шунда бу гыйлемнәрдән һич бәхәссез дөрес булган барлык мәгълүматны китерермен», – диде. Мин дә шуңа риза булдым. Шулай итеп, ул «Китабеш-шифа» исемле хезмәтенең «табигыять» бүлеген яза, шул ук вакытта, миннән башкаларга «әл-Канун»нан дәрес әйтә иде. Буш вакытларда аристократларның шәраб мәҗлесләре җыела, уен коралларын алып киләләр, без дә шуның белән шөгыльләнеп, көннәребезне уздыра идек. Әмир үлгәч, аның углын әмир итеп, аңа бәйгать иттеләр, шәех Ибне Синаның вәзир булып калуын сорадылар. Ләкин ул аннан баш тартты. Галяэтдәүләнең секретаре аның килүен үтенеп барса да, шәех күренмәде. Әбү Галиб әл-Гаттар исемле берәүнең йортында яшеренеп калды. Шул чагында да китап төзү эше белән шөгыльләнде, «Китабеш-шифа»ның һәр көн иллешәр битен язып, табигать һәм илаһият гыйлемнәреннән тулы мәгълүмат бирә торган бөтен бер әсәр итеп төгәлләде. «әл-Хәйван» һәм «ән-Нәбат» исемле әсәрләренә кермәгән барлык мәгълүмат шул хезмәттә тупланды.

Аннары Таҗел-Мөлек аңа Галяэтдәүлә белән бәйләнеш тота дигән яла ягып, әмирне аңа каршы котыртты, аны табып китертергә өндәде. Ахырда шәехне җиңделәр: китертеп, Фазарҗан каласында зинданга салдылар. Аның хакында язылган мәшһүр касыйдәдә шушы сүзләр язылган. Шигырь[1]:

Керүем, күргәнеңчә, ачык билгеле,
Тик чыгуым гына шикле.

Зинданда дүрт ай ятты, шуннан соң Галяэтдәүлә Һәмәданга гаскәр белән килде. Аны алгач, Таҗел-Мөлек качып китте. Аннары Шәмседдәүләнең углы Һүд Һәмәданга кайтты,

[1] Шигырь – гарәп телендә. Монда тәрҗемәсе бирелә.

Галяэтдәүлә киткән чакта, болар белән шәех Ибне Синаны да һәмәданга күчергәннәр. Анда Галәвинең йортына төшкән. «Китабеш-шифа»ның мантыйк бүлеген яза башлаган. Шул ук кальгада «Хәй бине Якъзан» рисаләсен, «Китабел-һидая», «Китабел-кулинҗ»[1] исемле әсәрләрен язды. Шуннан соң үзен һәм киемен үзгәртеп, Исфаһан ягына чыгып китте. Мин һәм хезмәтче ике егете суфыйлар киемендә Тәһранга – Исфаһан капкасына җиткәнче бергә булдык, бик каты авырлыклар кичердек. Безне анда шәехнең дуслары, әмир Галяэтдәүләнең яраннары каршы алдылар, шәехкә киемнәр, утырыр өчен атлар, арбалар китерделәр. Галяэтдәүлә аны зур хөрмәт белән каршы алды, үзенең хас яраннарыннан итеп билгеләде. Шәех аның сохбәтендә һәм хезмәтендә егерме биш ел калды. Бер бәхәсләшү вакытында тел белгечләреннән кайберәүләр аңар: «Син телне белмисең», – дип чыктылар. Шәех бу искәрмәгә игътибар итте, өч ел буе тел өйрәнүгә бик күп вакытын бирде һәм зур тел белгече дәрәҗәсенә иреште. Аннан соң «Гарәп теле» исемле китабын төзеде, ләкин аны акка күчерергә өлгермәде.

Шәех Ибне Сина бик таза иде. Җенси мөнәсәбәткә омтылышы аеруча көчле иде. Күбесенчә, аның белән шөгыльләнмәсә, табигатенә начар тәэсир итә иде, үзенең табигате көченә кирәгеннән артык таянуы сәбәпле эш, кулинҗ чире белән авыру чигенә барып җитте, ләкин ул үзен дарулауга да бик комсыз – мавыгучан иде, хәтта үзенә үзе көнгә сигез тапкыр укол ясап, эчәкләренең кайбер өлешләре яраланган, санҗеҗ (кату-чәнчү) авыруы башланган вакытта, Галяэтдәүлә белән бергә, Инҗ-Идҗ ягына ашыктылар. Анда кулинҗ авыруы белән бергә була торган баш авыртуы башланды. Шулай булса да, ул үзен терелтү чараларын күрә, үзенә үзе уколлар ясый иде. Көннәрдән бер көнне карафс[2] орлыгыннан ике данк[3] чамасы алып укол ясый торган даруга катнаштырырга кушкан. Эчке газларны бетермәкче булган, шул ысул белән элегрәк дарулаучы бер

[1] Кулинҗ – эч авыруы, спазм.

[2] Карафс – сельдерей дип йөртелә торган бер яшелчә.

[3] Данк – ярты грамм чамасы авырлык үлчәве.

табибка киткән. Ике данк урынына биш дирһәм карафс орлыгын салган. Белмим, ул аны белеп эшләдеме, әллә ялгыш эшләдеме икән, чөнки ул чакта мин аның янында булмадым. Орлыкларның күплегеннән чәнчүләр тагын артты. Ул баш авыртуына каршы да дару куллана иде. Хезмәтче егете торган да ул даруга күп кенә әфьюн салган. Шәех, белешмичә, аны да ашап-кабып җибәргән. Моның сәбәбе егетләрнең шәехкә карата хыянәтләре, аны үтереп, хәзинәсендәге малларын үзләренә алу иде. Шуннан соң шәех Ибне Сина Исфаһанга күчте, хәлсезлеге артканнан-арта барды, шулай да үзен дәвалауда дәвам итте, хәтта җәяү йөрерлек хәлгә килде, ләкин җенси мөнәсәбәтләр белән күбрәк мавыгуы аркасында өзлегә иде. Аннары Галяэтдәүлә Һәмәдан шәһәренә каршы сугыш ачты. Шәех тә аның белән китте. Юлда ук чире яңадан көчәеп, Һәмәданга җиткәнче дәвам итте, шунда ул үзенең көче беткәнен белде, терелергә мөмкинлеге юклыгын аңлады, үзен дәвалауга игътибар итмәс булды. Миңа ярдәм итүче инде үзенең ярдәмен кисте, хәзер дару файда итми инде, дип сөйли башлады. Шул хәлдә берничә көн кичергәннән соң вафат булды».

Казый Әбү Габбас ибне Хиллякян шәех хакында: «Юынды, тәүбә итте, җыйган мал-мөлкәтен ярлыларга садака итеп бирде, рәнҗетелгән кешеләргә белгәненчә хакларын кайтарды, колларын азат итте, һәр өч көндә бер хәтем[1] чыгып, савабын үлекләрнең җаннарына багышлый иде», – дип әйтә. Шәех Кәмалетдин бине Юныс сөйли иде: «Ибне Сина үз углына ачулы иде һәм аның зинданында үлде. Аның хакында түбәндәге шигырь бар:

Ибне Синаны күрдем,
Кешеләрнең хәлен белә, килеп йөри иде;
Зинданда бик начар үлем белән үлде;
«Шифа»[2] белән дә шифа насыйп булмады;
«Нәҗат»[3] белән дә үлемнән котыла алмады»[4].

---

[1] Хәтем – Коръәнне укып чыгу.

[2] «Шифа» – Ибне Сина китабының исеме. «Савыктыру» дигән сүз.

[3] «Нәҗат» – икенче китабының исеме. «Котылу» мәгънәсендә.

[4] Шигырь гарәп телендә, монда тәрҗемәсе бирелде.

Ибне Сина шигырьләр дә язган. Алардан иң атаклысы үзе хакында иҗат иткән касыйдәсе булып, күп кешеләр аны ачыклау, кинаяле фикерләрен, тирән серләрен ачу эшендә бик мавыгып эшләгәннәр иде. Ул касыйдә – менә шушы шигырь[1]:

Сиңа бик югары урыннан төште
Гыйззәт һәм көч иясе булган ак күгәрчен;
Һәр белекленең күз карашыннан оялып торучы,
Ул сәфәр итсә дә пәрдәләнмәде, яшеренмәде,
Сиңа охшамаган хәлдә, ул килеп җитте,
Күп чакта синнән аерылу аңа охшамый,
Ә ул тыныч кала.

Шәех Ибне Сина йөзгә якын исемдә төрле фәннәрдән бик күп зур һәм кечкенә күләмле әсәрләр, рисаләләр язды. Алардан түбәндәгеләрне санап үтәргә мөмкин: «Китабел-мәҗмуг» I том – җилд; «әл-Хасыйлә вә әл-мәхсул» – егерме том; «әл-Бирре вә әл-исм» – ике том; «әш-Шифа» – унсигез том; «әл-Канун» – ундүрт том; «әл-Ирсадә – әл-көллия» – бер том; «Китабен-нәҗат» – өч том; «әл-Һидая» – бер том; «әл-Ишарәт» – бер том; «әл-Мохтасар» – бер том, «әл-Кулинҗ» – бер том; «Лисанел-гарәб» – ун том; «әл-Әдвиятел-кальбия» – бер том; «әл-Муҗид» – бер том; «Бәгъзыл-хикмәтеш-шәркыя» – бер том; «Бәяне зәвател-җиһат – бер том; «Китабел-мигад» – бер том, «Китабел-мәбдәә вәл-мигад» – бер том.

Рисаләләрдән шуларны күрсәтергә мөмкин: «әл-Казаэ вә әл-кадәр», «әл-Аләте әр-расадия», «Гарзы катигорьянс», «әл-Мантыйк биш шигырь», «Раһде касыйдәтин фил-гыйддәти вә әл-хикмәт»; «Тәгакыйбел-мәвазыгыл-җәдәлия», «Мөхтасары Эклидес», «Мохтасар фи ән-набзый бил-гаҗәмия», «Фин-ниһаяти вә әннә ля ниһая». Үзендә саклаган китаплары: – «Хәй бине Якъзан», «Фи әннә ибгадел-җисми гайре затиятин ләһү», «Хәтбөл-кәлями фил-һинди», «Фи әннәш-шәй әл-вахидә ля якүне җәүһәриян вә гарзыян», «Фи әннә гыйльме Зәйдин, гайре Гайни Гомәрин», «Китабес-салат», «Китабе фи әл-озхия», «Риса-

[1] Шигырь гарәп телендә, монда тәрҗемәсе бирелде.

лате фил-хәдәс», «Ишарәте фи исбатин-нәбәват», «Ишарате фи гыйльмил-мантыйк», «Рисаләтет-тайр», «Рисаләте Саляман вә Әбсаль», «Тәфсире сурәти «Сәббих исмә раббикил-әгъля», «Рисаләте фи әкъсамил-хикмәт».

Ибне Синаның гыйлеме өчен миннәтдар – рәхмәт әйтергә тиешле остазлары Әбү Бәкер Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Бәрканый әс-Суфи; Исмәгыйль бине әл-Хөсәен әз-Заһит; Әбү Габдулла ән-Натили – философ иде.

Ибне Синаның үзеннән укып белем алган кешеләр – Сәед Әбү Габдулла Мөхәммәд бине ... әл-Илакый, Әбү Гобәйдулла әл-Җурҗани, Мәһмәняр бине Мәрзебан иделәр.

(II том, 528–533 б.)

Гомәр бине Исхак әл-Һинди

Һиҗрәттән җиде йөз җитмеш өченче (1371–1372) ел керде. Бу елда үлде Әбү Хәфәс Гомәр бине Исхак бине Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Һинди әл-Газнәви әл-Хәнәфи-фәкыйһ Сираҗетдин. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Туган елы җиде йөз бишенче яки җиде йөз җиденче ел (1305, 1307) иде.

Тәрҗемәи хәл иясе бик галим, имам, фәкыйһ, төрле гыйлем һәм фәннәрдә танылган, күп китаплар төзегән иде. Мисыр илендә казыйлар казыйсы булып торды. Заманының хәнәфия мәзһәбенең олуг имамнарыннан буларак, үз илендә хезмәт итте, аннары тормыш интересларын калдырып, күп илләрдә сәяхәт кылды, күп галимнәр – фазыйльләр белән очрашып, алардан гыйлем алды, кырык яшендә Мисырга килеп, хәнәфия мәдрәсәләренә йөрде. Аның белеме, яхшы сыйфатлары халык арасында танылды, күп кешеләрдән хәдисләр тыңлады, үзе һәм риваять итеп башкаларга ирештерде, байтак китаплар төзеде. Хаким Җәмалетдин Төрекмәнинең урынбасары булды; Илбоганың ярдәмчесе буларак, гаскәри казый булып торды. Бу исә хәнәфия мәзһәбе галимнәре арасыннан гаскәри казый булганнарның беренчесе иде. Ибне Төрекмәни үлгәч, алтмыш тугызынчы ел шәгъбан аеннан башлап, Гомәр бине Исхак мөстәкыйль казый булып беркетелде.

Шәех Мөхитдин әл-Гарәби хакында һәм Гомәр бине әл-Фарыйз турында яхшы карашта, аларны яклый иде, хәтта ибне Фарыйзны артык җентекләве өчен Шиһабетдин бине Әбү Хәҗләне шелтәләгән иде. Бу хакта Ибне Гаттар: казыйларыбызның казыйсы Сираҗетдин имам Әгъзам мәзһәбен энҗе белән бизәде, ибне Фараз өчен ибне Әбү Хәҗләне шелтәләде, зур уңышларга тиң булды, Аллаһ өчен яшәде, дигән иде.

Аның гаҗәп сыйфатларыннан шул иде: үзенең яклаучысы бөек әмир властька килгәч, аның алдында да нык һәм туры сүзле булды. Әмир вәкыфләрне тикшергәч, фәкыйһләргә катылык күрсәтте, аларның дәрәҗәләрен түбәнәйтте, өлешләрен киметте. Сираҗ шул хакта сөйләшеп караса да, әмир кабул итмәде, ачуланды. Сираҗ әйтте:

– Синең мең-мең көтүләрең бар, ә фәкыйһнең булса биш яки ун баш кына, аны да күпсенәсең. Әмир: «Мин аларны үзем өчен түгел, тик сугыш өчен һәм туганымның хакы өчен генә асрыйм», – дигән. Сираҗ фәкыйһ: «Халыкның җыеныысында ике йөз дирһәм бар икән, шуңа бер кол сатып алыныр да, синең урыныңа куярлар, җиһадның, исламның нәрсә икәнен кайдан белерсең? Әгәр без булмасак, сез мөселман да булмас идегез», – дип ачуланган, күзләрен текәп караган һәм кайтып киткән. Түбәнчелекле, халыкны дус күрүчән, кешеләрнең үтенечләрен – кирәкләрен үтәүдә нык торучы иде. Күп кенә китаплар төзеде. Аларның исемнәре: «әл-Горрәтел-мөнирәте фи тәрҗихи мәзһәби Әбү Хәнифә»; «Шәрхе таияти ибне әл-Фариз»; «Шәрхе гакыйдәтет-Тахави»; «әл-Китабе фит-тәсаувыф»; «әш-Шамил фил-фикъһе»; «Зөбдәтөл-әхкями фи әхлакыйль-әиммәтил-әгълям»; «Шәрхе-бәдигъ ли ибниссагаб»; «Шәрхел-моганни лил-хаббаз»; «әт-Тәршихе шәрхил-Һидая»; «Шәрхе ахирил-һидаяти галя тарикыйль-җәдәли фи ситтәти әҗ заил кибар»; «Шәрхез-зиадат»; «әл-Җамигыссагыйрь»; «Әл-җамигыль-кәбир».

Тәрҗемәи хәлнең иясе имам Вәҗиһетдин Разидән, Рөкыетдин әл-Бәдәватидән, Сираҗетдин әс-Сәкъфидән фикъһе гыйлемен алды, Әхмәд бине Мансур әл-Җәүһәридән һәм

башкалардан хәдисне, Мәккәдә Рибатес-сидрә шәехеннән дәрес тыңлады.

(IV том, 26 б.)

Кяфияче

Һиҗри сигез йөз җитмеш тугызынчы ел (1474–1475) керде. Ул елда вафат булды...

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сөләйман бине Сәгыйд бине Мәсгут әр-Руми әл-Бәргами әл-Хәнәфи – бөек галим Мөхитдин әл-Кяфияче (Аллаһның рәхмәтендә булсын) җөмадиел-әүвәл аеның дүртенче җомга кичәсендә Каһирә шәһәрендә үлде. Җиде йөз сиксән сигезенче (1386) елда туган иде. Үзе хәнәфия мәзһәбенең соңгы дәвер галимнәренең тирән белемле, олыларның да атаклы һәм күренеклеләреннән иде. Бу галим гарәп нәхүе буенча «әл-Кяфия» исемле китапны бик күп укучы һәм аның шәрехләрен тикшертүче булганга күрә, «Кяфияче» дигән кушамат белән аталган. Сөютый исемле галим үзенең «Хөснел-моназара» исемле китабында аны гүзәл табигатьле, саф күңелле, дошманнарының җәфаларына да чыдамлы, рәнҗешләргә түземле, киң гыйлемле, күркәм холыклы бер кеше иде. Шәех Кяфияче шулвакыт халкының хакыйкатьне эзләүче галиме, мәгъкүлат – фәлсәфә гыйлемнәрендә дөньяның остазы иде, бүтән гыйлемнәрне дә, иң югары дәрәҗәсенә җиткәнче өйрәнде, шул юлда тырышты», дигән. Аннан соң гаҗәм[1] һәм татар илләрендә сәяхәт кылды, бик күп бөек галимнәр белән очрашып, аларның гыйлемнәреннән файдаланды, шуннан соң Каһирәгә килеп җитте. Каһирәнең фазыйльләре, күренекле олуг кешеләре моннан укып гыйлем хасил иттеләр. Алар арасында шәехләр шәехе булып саналды. Алар арасында бөек имам, гыйлемнәр буенча юлбашчы иде. Кәлям, фикъһе һәм ысуле фикъһе, нәхү, сарыф, игъраб[2],

---

[1] Гаҗәм – бу урында иранлылар мәгънәсендә.

[2] Нәхү, сарыф, игъраб – грамматиканың төрле бүлекләре (игъраб – килеш белән төрләнү – склонение).

мәган, бәян[1], җәдәл[2], мантыйк[3] , фәлсәфә, һәйәт[4] гыйлемнәрендә, шулай ук тәфсир[5], хәдис[6] гыйлемнәрендә киң колачлы, тирән йөзүче зур галим иде. Бу мәсьәләләр буенча бик күп китаплар төзеде, гакълият гыйлемнәре[7] буенча төзегән китапларының саны да бик күп. Бервакыт мин аңар баргач, барлык язган китапларының исемнәрен атап чыгуын үтендем, аларның тәрҗемәи хәлен дә язарга теләдем. Ләкин ул миңа җавабында: «Булдыра алмыйм, чөнки минем төзегән китапларым шулкадәр күп, хәзер мин аларның исемнәрен дә белмим, күбрәге мохтәсарлар[8]», – диде. Шәех Кяфияче дин мәсьәләләрендә дөрес игътикадлы, суфыйлык турында дөрес карашлы, хәдис галимнәренә дус, бидгатьчеләргә нәфрәтчән, олы яшькә җитүенә карамастан, күп гыйбадәт кылучан, күп садака таратучан, хәтта үзенә һичнәрсә калдырмыйча, булган малын мохтаҗларга өләшүчән иде. Моннан соң ундүрт ел вакыт эчендә мин аны бер генә тапкыр күрдем, шул чагында мин аннан моңарчы һич ишеткәнем булмаган искитәрлек тирән тикшеренүләр, нечкә хакыйкатьләр ишеттем. Ул беркөнне: «Зәйден каимун» тезмәсенең игърабы[9] ничек?» – дип сорады. Мин әйттем: «Инде без балалар урынына ирештекме? Шуны сорыйсың», – дидем.

Ул әйтте: «Зәйден каимун» җөмләсенең төзелеш һәм үзгәрешендә бер йөз унөч бәхәс бар». Мин әйттем: «Шул кагыйдәләрне ишетеп аңлашмыйча, бу утырыштан кузгалып китмәячәкмен», –

---

[1] Мәган, бәян – стилистика мәсьәләләрен тикшерүче фәннең төрле бүлекләре.

[2] Җәдәл – бәхәсләшү, дискуссия.

[3] Мантыйк – логика.

[4] Һәйәт – астрономия.

[5] Тәфсир – Коръәнгә киң аңлатмалар.

[6] Хәдис – пәйгамбәр сүзләре.

[7] Гакълият гыйлемнәре – кеше үзе тикшереп, нәтиҗә ясап табыла торган гыйлемнәр.

[8] Мохтәсар – кыскартма. Элеккерәк заманда я үз китабын яки башка бер галимнең китабын кыскартып язу гадәте булган. Шундый китап мохтасәр – кыскартма дип аталган.

[9] Игъраб – җөмлә эчендә сүзләрнең үзгәреше. Элеккерәк заманда шундый артык нечкәләп, ваклап бәхәс тудыру гадәте булган.

дидем. Шунда ул үзенең истәлек дәфтәрен чыгарды. Шушы дәфтәрдән мин аларны язып алдым. Бу соңгы очрашуыбыз булды. Ул эч китү чиреннән үлеп шәһид булды. Шиһабетдин әл-Мансур аңар түбәндәге сүзләр белән мәрсия язды:

«Шәйх Мохитдин Кяфияче өчен
Күзләребез йөрәктән килгән яшьләр белән елады»[1].

Әл-Бәдер Хәсән Ибраһим әл-Халиди, шулай ук аны мактап, шушы сүзләрне әйтте. Шигырь:

Кергән кеше чыга алмаслык
Тирән белемнәр, яхшылыклар
Диңгезе – Мохитдин! Аллаһ синең белән булсын.
И син, ике диңгезне[2] җыйган галим,
Син Хатәмне[3] җиңдең,
Фазыйләт, мәгърифәт ягыннан син
Ногманның[4] гүя бер туганысың[5].

Ул әйтә: «Шәех Кяфиячене, миңа күрсәткән шәфкате һәм ярдәмнәре күплектән, атамнан соңгы атам – икенче атам дип саныйм. Минем атам белән аның арасында нык дуслык булды, минем атам, үз шәһәрендәге халыкның күпчелегенең киресенчә, аңа карата бик инсафлы – ярдәмле булды», – ди.

Әс-Сәхави дигән галим үзенең «әз-Зүәл-лямиг» исемле китабында Кяфиячене искә алып, бигрәк тә артык мактап куя да: «Хәтта казый Борһанетдин бине Заһәйрә үзе, фазылы, асыл затлыгы, кадеренең олылыгы белән бергә, аңа баш ия, аның кулын үбә, утырдаш була, аның гыйлеменнән файдалана иде», – ди. Кешеләр белән күркәм тормыш алып барып, дуслары, яраннары арасында уен-көлке ярата һәм мәзәкләрнең иң эчтәлеклесен ул сөйли иде. Хафиз бине Хәҗәрдән бүтән берәүне дә галим дип танырга теләми иде. Бу икәве берсе икенчесен мактый һәм

---

[1] Шигырь гарәпчә. Монда тәрҗемәсе китерелде.
[2] Ике диңгез – гыйлем һәм юмартлык диңгезе.
[3] Хатәм-тай – үзенең чиксез юмартлыгы белән дан тоткан шәхес.
[4] Ногман – имам әгъзам Әбү Хәнифә дигән мәшһүр галим.
[5] Шигырь гарәп телендә. Без тәрҗемәсен бирдек.

гыйлеме, фазылы белән игътираф итәләр иде. Шулай ук шәех Мохитдин бине Гарәбигә мәхәббәт баглый, аның фикерләрен яклый, ләкин моны кешеләр алдында ачык әйтергә теләми иде. Кяфияченең каләме, язма теле сөйләү теленнән ачыграк иде. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә табылган хакыйкатьләрне ул бик гүзәл рәвештә хәтерендә саклый иде. Җыеп әйткәндә, заманының иң бөек белгече, кордашларының сирәк очрый торганы, ике асылның: тәфсир, нәхү, сарыф, мәган, бәян, мантыйк, һәйәт, һәндәсә, хикмәт гыйлемнәрендә остаз, шулай ук фикъһе һәм тыйб мәсьәләләрендә иптәшләрчә кызыклы бәхәсләр алып баручы иде. Әдәбияттан да күп кенә әсәрләрне күңелдән белә иде; кайбер гыйлемнәр буенча үзе дә яңа нәрсәләр уйлап чыгарган, шөһрәт күтәрелгән, дәрәҗәсе зурайган. Олуг патшалар, хосусән Төркия хөкемдары Ибне Госман белән араларында дусларча язышу булды. Ибне Госман аны кадерле бүләкләр белән бүләкләде. Ул үлгәч, халык аны югалтуга бик кайгырды, моннан соң аның тиңе булырлык кеше туганы юк» дип сүзен бетерә Сәхави. Кяфияченең төзегән китаплары: «Әт-тәйсир фит-тәфсир» – кыскача өч кисәк чамасы, бу гыйлемне мин уйлап чыгардым, миннән элгәре аны эшләүче булмады, дип әйтә торган булган, чөнки ул Зиркашинең «әл-Борһан» исемле китабын һәм Җәлял әл-Бәлхининең «Мәвакыйгыль-голүм» исемле әсәрләренең барын белми иде. Ә бу китаплар исә аның әсәренә караганда зуррак та, файдалырак та иде: «Шәрхе кавагыйдел-игьраб»; «Шәрхе кәлимәтеш-шәһадәт»; «Мохтасар фи голүме хәдис»; «Рисаләтен фи мәсьәләтил-истисна» (чыгармалар хакында) исемле гүзәл рисаләсе бар. «әл-Мохтәсарел-мөфид фи гыйльмет-тарих» («Тарих гыйлемендә файдалы кыскача рисалә»); «Хашияте галя шәрхил-һидает» («Һидая шәрхенә өстәмә»); «Тәлхисел-җамигыль-кәбир вә әл-мәҗмәгъ»; «Шәрхел-мәвакыйф»; «Шәрхет-тәлхыйсыль-Җәгъмини филь-һәйәт» («Һәйәт – космография фәнендә Җәгъмини китабына ачыклама») исемендәге китаплар һәм башкалар иде.

Кяфияче үзе Шәмсетдин Мөхәммәд бине Хәмзә әл-Фәннаридән, Борһанетдин Хәйдәр бине Мөхәммәд әл-

Хавафидән, Габделлатыйф бине Габделгазиз ибне Мәликтән, Хафизетдин Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Харәзми ибне әл-Бәззаздан укып гыйлем хасил итте. Кяфияченең үзеннән исә Юныс бине Хәлил әл-Миһәндар, Сәриетдин, Габделбәр бине әш-Шихнәт әл-Халәби әл-казый, Әхмәд бине Исмәгыйль әл-Җәүһәри, Ибраһим бине Мөхәммәд бине Танбуга әл-Гоззи укып – шәкертләре булып гыйлем алдылар.

(IV том, 174 б.)

Галишир Нәваи

Һиҗрәттән тугыз йөз алтынчы (1500–1501) ел керде. Ул елда вафат булдылар.

Әбү ...[1] Галишир бине Кечкенә бине Габдулла әт-Төрекмәни, кушаматы Низаметдин. Үзе вәзир Нәваи дип мәшһүр. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Шәгъбан аеның башларында Һират шәһәрендә вафат булып, шул ук шәһәрдә үзе салдырган мәчет янында күмелде. Тууы һиҗри сигез йөз кырык дүртенче (1440) елда иде. Хорасан илендәге галимнәрнең иң бөекләреннән – мәшһүрләреннән, үз заманындагы әдипләрнең иң югары идеалы – үрнәге иде. Һират шәһәрендә Тимур балаларыннан Хөсәен (Байкара) исемле хөкемдарның иң ышанычлы кешесе буларак, бу дәүләттә мохтаҗларга булышучы, олы галимнәрнең таянычы, атаклы әдипләрнең ярдәмчесе иде. Күп кенә вакытлар Астрабад өлкәсендә вәли – җитәкче булып торды, аннары шул ук илнең бүтән өлкәләрендә дә хөкемдарның иң әһәмиятле эшләре белән кием-салымда, йөреш-торышта, атында һәм аның өчен кирәкне сайлауда бик купшы һәм көяз иде. Аның хакында Хорасан илендә мәсәлләр дә йөри, хәтта берәр кешенең яки әйбернең яхшылыгын, гүзәллеген, тазалыгын сурәтли башласалар, иң югары дәрәҗәне белдерәчәк сүз урынына «Галишир кебек», «Галиширчә» дигән сүзләрне өстәп мактыйлар, чагыштыралар иде. Хәтта берәр кеше бер иярчегә килеп, үзенең атына

[1] ... (исем әйтелмәгән).

яки ишәгенә бик яхшы ияр эшләргә кушканда, «Галиширнеке» кебек эшлә дип куша торган булган. Шулай ук матур язуны Галиширгә нисбәтләү аның язуы үтә матур булганга күрә иде. Аның үз язуы бик нәфис, бик гүзәл булган кебек, язучы булып хезмәт итүчесе Гали әл-Мәшһәри дигән кеше дә атаклы хәттат – каллиграф иде.

Галишир Нәваи үтә юмарт, кешеләр өчен һиммәтле, тырыш, сөхбәте – утырышы татлы, мәҗлесләре әдипләр, галимнәр, шагыйрьләр белән шыгрым тулы була иде. Үзе гаять зирәк, тапкыр, үткен, яхшы фикерле, гүзәл тәдбирле, дөрес аңлаучан иде. Бик күптөрле гыйлем һәм фәннәрне өйрәнеп, алардан зур белем хасил иткән. Үз гомерендә бик күп яхшы эшләр эшләп, матур истәлекләр калдырган, бик күп мәчет һәм мәдрәсәләр салдырган, аларны яшәтер өчен, шулай ук гыйлем ияләрен тәрбияләү, үстерү, күбәйтү, ярлыларның, юксылларның, ятимнәрнең моң-зарларын китерү, кирәкләрен тәэмин итү өчен вәкыфлар, ягъни җир-су һәм махсус байлыклар билгеләгән.

Галишир Нәваи фарсы һәм төрки телләренә дә бик оста иде, бик тирән эчтәлекле касыйдәләр, нечкә хисләр белән сугарылган шигырьләр язды. Гомерендә нәфис китаплар булдыру, аларны тикшерү-төзәтү эше белән дә бик мавыга иде. Хәтта Сәед Җамалетдин Ширази дигән бер галим аның өчен «әл-Җамигъ әс-сахих әл-Бохари»[1] исемле китапны төзәтеп чыккан һәм китапның азагында шушы сүзләрне язган: «Бу «әл-Җамигъ әс-сахих»ны көчем җиткәнчә, булдыра алганымча төзәтеп тәмам иттем, каләм сизми калган, күз адашкан җирләре калса, алары буйсынмый калган куйлар кебек каралсын; боерган эшләрнең үтәлүе тәмам булыр, ягъни Аллаһның күк көчләре белән, мәңгелек бәхетләр белән хаслаган кешесенең, ягъни күпләр тарафыннан бөек хөрмәт күрүче, олы әмирләр башлыгы, кушканнары һич карулыксыз, каршылыксыз үтәлүче, җәмгыятьнең мөһим мәслихәтләренең кәфилә (җәмгыятьнең мөһим эшләрен үтәүче),

[1] Исмәгыйль Бохари исемле кеше тарафыннан җыелган хәдисләр мәҗмугасе.

чырае ачык, йөрәге таза, кадере олы, белеме тирән, шәфкате күп, яхшылыклары бик югары, изгелекләре сөйләп бетергесез, чөнки алар замананың күзе алдында ачык, көннәрнең битләрендә сәгать саен рушан булган олуг әмир Низаметдәүләти вә әт-дөнья вә әт-дин – дәүләтнең, дин һәм дөньяның кануны – әмир Ширгали өчен эшләдем. Шигырь:

Диңгез ул – юмартлык һәм яхшылык орлыклары,
Аның ярларына кайдан килгән икән;
Кайчан гына килсәң дә, аны яңа туган ай кебек
Балкыган күрәсең, гүя аңа күптән көткәнен бирәсең.

Ярдәм сорап килсәң, гәрчә син сораган нәрсә
Аның бармак очлары җитмәслек җир булса да,
Аның кулында җаныннан башка бер нәрсәсе булмаса да,
Ул шуның белән юмартланыр иде,
Сораучысын Аллаһ сакласын.

Син мәңге яшәрсең, чөнки синең яшәвең
Заман өчен гүзәллек һәм хушлык.
Килешсез эшләргә синең тирәндә урын булмады,
Ә заманыңдагы начар гадәтләр өчен син гаепле түгел.

Бүтән бик күп башка шагыйрьләр дә аңар – Нәваигә мәрсияләр яздылар. Шулар арасында Фәсыйхетдин ән-Низамины аерып күрсәтергә мөмкин.

Нәваиның әсәрләре: 1. Шигырьләр диваны; 2. «Бәдаигыль-васәт»; 3. «Лисанет-тоюр» («Кошлар теле»); 4. «Мохакәмәтел-логатәйн» («Ике телне чагыштырып карау»). Бу китабында фарсы теленә караганда төрки теленең өстенлеген исбат итә; 5. «Нәвадиреш-шәбаб» («Яшьлек хикәятләре»); 6. «Гараибес-сыйгыр» («Яшьлекнең кызыклары»); 7. «Фәваидел-кибар» («Олылыкның файдалары»); 8. «Мизанел-әвзан» («Шигырьләрнең үлчәүләре хакында»).

Галишир Нәваи тәсаувыф ияләреннән булып, Нуретдин, Габдеррәхман әл-Даминең яраннарыннан иде.

(IV том, 212–213 б.)

Шәйбани хан

Тугыз йөз уналтынчы (1510–1511) ел керде – ул елда үлде... Әбү Мөхәммәд бине Шаһбодаг бине Әбү әл-Хәер бине Дәүләт Төрки әл-Үзбәки. Шәйбани хан дип мәшһүр – Аллаһ аны ярлыкасын...[1] айның җомга көнендә Хорасан шәһәрләренең анасы Мәрв Шаһҗиһанда, Иран шаһы Исмәгыйль Сәфәви белән ике арадагы каты сугышта үтерелде. Башын шаһка җибәрделәр, гәүдәсен Сәмәркандка илтеп күмделәр. «Шаһ-Бәхет хан», «Шәйбәк хан» исемнәре белән дә атала иде, үзе бик батыр – алып кеше, эшнең азагы ничек бетәрен уйлап тормыйча, дошман өстенә күп сугышлар белән йөргән иде. Мавәраэннәһердә һәм Хорасанда хөкеме йөргән үзбәк ханнарыннан иң элгәресе, даны белән дә иң олысы, мәмләкәте киңрәге, телләрдә иң күп йөргәне – атаклысы иде.

Бабасы Әбү әл-Хәер үлгәч, аның балалары һәм оныклары Дәштнең[2] төрле аймакларына, төрле илләргә таралып беткәч, шушы Шәйбани хан да Тимур балаларыннан Әбү Сәгыйд морзаның углы Солтан Әхмәд янына барып сыенды, аның сохбәтенә кереп, байтак еллар аерылмас яраны булды. Соңыннан тагын сахрага кайтып гаскәр җыеп, күп илләргә, хәтта Мавәраэннәһергә, Хорасанга хуҗа булып алды, шәүкәте зурайды, дәүләте көчәйде, аннары үзе дә масаеп, явызланып китте, хәтта Иран шаһы Исмәгыйль Сәфәвигә бик тупас сүзләр белән хат язды, патшалар арасында сакланырга тиешле кагыйдәне – чикне узды. Менә шушы хәлләр Иран патшасының Хорасан иленә һөҗүм итүенә сәбәп булды, Шәйбани ханның башына җитте, дусишләренә хурлык-түбәнлекләр генә калды. Ахырда алар элекке хәлләренә, күчмә казах хәленә кайттылар, Шәйбани ханның Тимур балаларыннан Габир бине Гомәр белән дә байтак мажаралары, сугышлары булган, хәтта Габирны куып чыгарган иде.

(IV том, 221 б.)

---

[1] Күп нокта оригиналдан.

[2] Дәшт – дала, сахра (Урта Азия һәм Казахстан сахралары күздә тотыла).

Надиршаһ

Һиҗри бер мең бер йөз алтмышынчы (1747) елда вафат булды.

Әбү әс-Сәеф Гали бине Сафдәр бине Нәдер бине ... әл-Гаҗәми әт-Төрекмәни әл-Әфшари әл-Абивәрди, әс-Солтан Надиршаһ, Аллаһның рәхмәтендә булсын – җөмадиел-ахир аеның соңгы унбер көненең сишәмбе көнендә Фәтехабад шәһәрендә (Хорасан иле шәһәрләреннән Хабушан дигән җирдән ике фәрсәх ераклыкта) үзенең туганының углы Гали бине Ибраһим тарафыннан алдап үтерелде. Аның янына Мөхәммәд Каҗар исемле бер кеше кереп, кылыч белән сугып имгәткән, аннары Муса әл-Әфшар дигән икенче бер кеше тагын сугып, башын чабып төшергән. Бу ике кеше үзләре шаһның ишек төбендәге сакчылары булганнар. Шушы хәлдә шаһның соңгы сүзе: «Мине үтерүче кеше мөлеккә – патшалыкка да, мал-дәүләткә дә ирешә алмас» сүзләре булган. Кичтән аның башы дөньяның киң мәйданы сыйдырмаслык бер тау, күзенең бер карашы барлык падишаһларны тетрәтеп торган булса, таңга кергәндә, таяклар белән сугыша торган балалар тубы-уенчыгы кебек тәгәрәтеп йөртелә торган хәлгә керде.

Надиршаһ һиҗрәттән бер мең бер йөз унынчы (1698–1699) елда мөхәррәм аеның соңгы унынчы көне шимбә көнендә Хорасан илендә Абивәрдкә якын Истҗард каласында туган; башта Гали исеме белән аталган булса да, соңыннан Надир исеме белән йөртелде. Төп нәселе төрекмән халкыннан, караклу буынныннан, әфшар кабиләсеннән – ыругыннан иде. Борынгы вакытларда алар Төркестанда торганнар, магуллар дөньяга таралып, Чыңгыз хан килеп чыккач, болар борынгы урыннарыннан күчеп, Азәрбайҗанга килеп җирләшкәннәр. Исмәгыйль Сәфәви фетнәсе башлангач, аннан Хорасан иленә күчеп, анда якын Күйкян инеше буена утырганнар. Җәйләрен анда җәйләп, кышларын Истҗард тирәләрендә кышлаганнар. Бу тәрҗемәи хәлнең иясе гаҗәм – фарис хөкемдары үзе дөньяның атаклы батырларыннан, олы солтаннарыннан, заманының җитезләреннән берсе буларак, күп илләр, күп шәһәрләрне сугышып алып,

мәмләкәтен киңәйткән, тыныч вакытта да кешеләрне өркетеп торучы дәһшәтле падишаһ та, күркәм холыклы, зур изгелекләр кылучы да иде. Аллаһ аңа турылык насыйп итте, бөек кәмаләткә ирештерде. Анда турылык, ныклык, акыллылык, бозыклыктан саклана белү кебек яхшы сыйфатларның билгеләре күренде. Олы эшләр, бөек мәҗаралар башкарды. Аннан соң әфшар кабиләсе башлыкларыннан Габа Гали бәк исемле берәүнең кызына өйләнде. Һиҗри бер мең бер йөз утыз беренче (1718–1719) ел иде. Бу хатыныннан Риза-Колый исемле углы булды. Ул хатыны үлгәч, аның сеңлесенә өйләнде, анысыннан Насрулла һәм Имам-Колый исемнәрендә ике углы булды. Үзе кабилә башлыгы булып алды, төрекмән, үзбәк һәм көрдләр арасыннан каршылык күрсәтүчеләр белән каты көрәш алып барды, бик күп көч куйганнан соң, аларны үзенә баш иргә, буйсынырга мәҗбүр итте. Бу чакларда Иранда Сәфәвиләр дәүләтендә чуалышлар соң дәрәҗәгә килеп җиткән, дәүләт бетәргә йөз тоткан, патшаның власте югалган, хуҗалыгы тик исемдә генә калган иде. Бик күп өлкәләр дәүләткә буйсынудан чыгып, үзара төрле аймакларга бүленгәләп, ыруг башлыклары, вак бикләр күбәеп киткән иде. Эшләрнең тәртибе бозылган, халык арасында золым, дошманлык, бозыклык таралган иде. Бу илнең Кандәһардан алып Исфаһанга хәтле булган көнчыгыш якларын әфган халкы арасыннан Галҗә таифәсе җиңеп алган. Аларның көчләре үскән, дәүләтләре зурайган иде. Шулай ук Һиратта да әфган юлбасарларының Әбдалия фетнәсе көчәйгән, Ширванны һәм шуңар якын Лазыя тарафларын яулап алган иде. Шул чакларда Иранда билгесез бер кеше мәйданга чыгып, үзенең исемен Әбү әл-Мәгъсүм Сафи бине Шаһ Хөсәен әс-Сәфәви дип игълан иткән. Кирмәндә (Иран иленең көньягында) Сәед Әхмәд бине Даут, Бәнадердә солтан Мөхәммәд Харсевар, Киландә Исмәгыйль, Җеванкидә Габбас исемле кешеләр мәйданга чыкканнар. Бу өчесе дәүләткә, хөкемдарлыкка мөнәсәбәтләре барлыгын даулый башлаганнар, чөнки алар үзләрен гүя Хөсәен Сәфәвинең углы яки туганы дип атаганнар. Хорасанга мәлик Мәхмүд Систани килеп хуҗа булган, Мәшһәдне һәм аңар якын

өлкәләрне шуңа кушкан Госманлы дәүләтенең гаскәр башлыклары Азәрбайҗан иленең Солтания һәм Әбһәргә хәтле, Гыйрак ягыннан Кирмәншаһтан алып Кәззазга хәтле булган җирләрен Төркиягә кушканнар: Бабел-әбваб (Дәрбәнд) тирәсендә руслар, чикне бозып, Мазендарак тирәләренә чатырлар корып җирләшкәннәр, Астрабадта төрекмәннәр һәм көрдләр, Җәзаир, Бәнадер тирәләрендә күчмәле гарәпләр килеп җирләшкәннәр. Хәтта бөтен тау һәм сахра халыклары, чатыр һәм хайван көтүләре хуҗалары, һәртөрле әшәкелекләр кылып, игеннәрне таптап һәлак итәләр, халыкны кыралар, кан түгәләр, шәһәрләрне харап итеп йөриләр иде.

Менә шушы шартларда Надиршаһ мәйданга чыкты, иң элгәре Истҗардны, Килатны, тагын бу яктагы берничә бүтән калаларны алып, Килат кальгасен ныгытты, аны Дәүләтнең башкаласы – хөкемдар йорты итеп билгеләде. Мәйданга чыгуыннан башлап хөкемдарлыкның югары дәрәҗәсенә җиткәнче, әфшарлар һәм көрдләрнең ярдәменә таянып эш кылды, алардан файдаланды. Аннары Мәлик Мәхмүд Систани өстенә һөҗүм итеп, монда сөйләсәң бик озакка китәчәк бик күп вакыйгалар, хәйләләр белән аннан мөлкәтне – патшалык итә торган җирләрен тартып алды. Бу эшен төгәлләгәч, әфганнар белән сугышып, һәр сугышта аларны җиңеп, аларны мәмләкәттән, шәһәрләреннән сөреп җибәрде, патшаларын үтереп, Сәфәвиләрнең һәм Әфган патшаларының пайтәхетләре – башкалалары булган Исфаһан шәһәрен алды. Бу вакыйга һижрәттән мең бер йөз кырык дүртенче (1731–1732) ел рабигыль-әүвәл аенда булды. Шуннан соң Госманлы дәүләтенең наместникларын Нәһавәнд, Һәмәдан, Кирмәншаһ, Тәбриз һәм башка шәһәрләрдән куып чыгарды. Хорасанда акчаны Гали бине Муса әр-Риза исеменә суктырды. Шаһ Таһмасиб белән кодалашып, аның Фатыйма бинте Хөсәен исемле кыз туганын үзенең олы углы, варисы Риза Колыйга никахлап алып бирде.

Икенче төнне, үзенең яраннарын җыеп, шаһ Таһмасибны урыныннан төшерде, җыйган мөлкәтен үзенә кайтарып, ышанычлы, тугры булуына ант иттерүне тиешле бер кешесенә

тапшырды. Бу эш һиҗрәттән мең бер йөз кырык бишенче (1732–1733) елның рабигыль-әүвәл аеның бишенче көне пәнҗешәмбе көнне булды. Шуннан соң аны Мәшһәдер-Ризавига җибәрде, үзе гаскәре белән Кәркүк һәм Багдадка юнәлде. Гыйрак өлкәләреннән Багдад һәм тирәләрендәге шәһәрләрне алып, Муса әл-Кәзыймның каберенә зиярәт кылды, Багдадка якынайгач, анда имам Әбү Хәнифәнең каберен зур ихтирам, чын әдәп һәм олуглау белән зиярәт кылды. Гаскәрдәге кайбер башбаштак кешеләр кадерсезләмәсеннәр, халык арасыннан да бу имамга карата хөрмәтсезлек эшләнмәсен, аңа тиешле хөрмәт күрсәтелсен, төрле хәкарәт яки мыскыл итүләрдән саклансын өчен, кабер янына сакчылар калдырды. Бу эш бер мең бер йөз кырык бишенче елның (1732–1733) шәгъбан аеның чәһәршәнбе көнендә иде.

Аннан соң Госманлы дәүләте наибләре белән ике аралар-ында күп сугышлар, зур эшләр, авырлыклар кичте, аннары госманлылар тарафыннан җиңелеп, Гыйрак иленнән бик боегып, төшенке күңел белән Иранга борылды, алар белән солых – килешү шартларын төзергә кереште. Иран солтанлыгы төшәргә, зәгыйфьләнергә йөз тоткан, Сәфәвиләрдән Шаһ Таһмасибнең һәм углы Габбасның исемнәре Иран акчаларында язылмас, хөтбәләрдә дә искә алынмас булган иде. Хөтбәләр шаһ исеменә укылса да, бу инде солтанлыкның коры исеме генә, шул мәмләкәтнең хөкемдары дигән мәгънәдә генә була иде.

Менә бервакыт Надиршаһ Моган сахрасында илнең олыларын, мәмләкәт башлыкларын, төрле фиркаләрнең (сөнни, шигый һ.б.) галимнәрен, гаскәр җитәкчеләрен мәмләкәттә хөкемдарлык вазифасын кемгә тапшырырга дигән мәсьәләне ачыклау өчен җыйды: әллә хөкемдарлыкка Шаһ Таһмасибне яки углын, яки Сәфәвиләрдән башка берәүне кайтарыргамы яки халыктан берәүне билгеләргәме дип сорады. Уйлаштылар да әйттеләр: «Без синнән башка һичкемне дә теләмибез, чөнки син безнең эшләребезне төзәттең, халкыбызның хәлен яхшырттың, олуг һәм кечкенә, югары һәм түбән катлауны, көчлене һәм көчсезне – безнең өстебезгә төрле яктан ташланып, шәһәрләребезне басып алган дошманнар күрсәткән төрле хурлыклардан,

мескенлектән коткардың», – диделәр. Шушы хәлдә бер ай вакыт узды. Ул әле һаман баш тарта иде. Бара-тора үтенүләр күбәеп, соңгы чигенә җиткәч, Надиршаһ халыкка әйткән: «И шигый мәзһәбе кешеләре, һәм рәсүлнең өй җәмәгатенә дуслык ияләре! Әгәр сез минем сезгә баш булуымны чын күңелдән теләсәгез, минем хөкемдарлык итүемне, эшләрегезгә хуҗа булуымны теләүдә тугры булсагыз – белегез: минем шартыма күнсәгез генә патшалыкны өстемә йөкләячәкмен һәм эшләрегезне җиренә җиткерермен-үтәрмен. Ул шартым шул: Сез әһле сөннәт вә әл-җәмәгатъ мәзһәбенә керегез һәм ул мәзһәбне сүгү, хурлау кебек эшләрне ташлагыз. Чөнки дүрт бөек имам Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали – алар хаклык юлында булдылар, бер-бер артлы рәсүл галәйһиссәламнең хәлифәлек эшен башкардылар. Рум, һинд, төрек илләрендәге барлык ислам халкы рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһиссәламнең заманыннан шушы заманыбызга чаклы бу мәзһәбтә нык торалар, Габбаси хәлифәләре дә шул ук мәзһәбтә иделәр, безнең Иран халкыннан булган кадерле борынгыларыбыз, олуг бабаларыбыз унынчы гасырның башларына чаклы барысы да шул мәзһәбтә иделәр. Рафизыйлар агымына, бозык юлга – мәзһәбкә кермәделәр. Фәкать Исмәгыйль Сәфәви, дәүләтенең башында һижрәттән тугыз йөз алтынчы (1500–1501) елда гына, ул хаклыкны ташлап, бозык юлга керде. Хурлау, аерылу кебек яман мәзһәбләр, төрле кабахәт эшләр тудырды, исламга бик зур хәкарәт-рисвайлыклар ыргытты, начар фетнә, авыр бәла уятты. Менә бу хәл – әһле ислам арасында килеп чыккан бозыклыкның, дуслык югалуның һәм сүздә тискәреләнүләрнең төп тамыры. Халыкның аерылышуына, дәүләтнең таркалуына, көче азаюына, халык арасында тынычлык бетүгә сәбәп булган бик күп эшләрнең төбе-тамыры да шул. Инде минем җитәкчелегем астына кергән, миңа буйсынуны үзенең өстенә йөкләгән һәркем шушы хак юлны, әһле сөннәт вә әл-җәмәгать мәзһәбен тотсын. Сәхабәләрне сүгү, хурлау, кимсетү кебек начар эшләрдән кайтсын, тәүбә итсен. Әйе, диннең төрле тармактагы мәсьәләләрендә, иҗтиһад хөкемнәрендә рәсүлнең нәселеннән килгән күренекле бөек

имамнарның берсе булган Җәгъфәр бине Мөхәммәд Садыйкның ижтиһады буенча рөхсәт ителгәнчә файдалансын, аның күрсәтүенчә гамәл кылсын. Һәртөрле яманлыктан сакланган, пакь, югары сыйфатлы бу галимне иранлылар белергә, мәзһәбен танырга, аңа иярергә тиешле. Бу тугры эшне, нык хөкемне яхшы аңлап, аңар буйсыныгыз. Бу хакта беркетмә язылып, дәүләт олыларының мөһерләре, өлкән түрәләрнең, бикләрнең язмалары белән ныгытылды. Шуннан соң бу беркетмә дәүләтнең нык саклана торган махсус урынына куелды, аннары шул хакта аңлатмалар язылып, илнең бөтен өлкәләренә, иң ерак чикләренә чаклы таратылды. Тагын берничә тапкыр кабатланып, бу беркетмә госманлылар дәүләтенә дә солыхка – килешүгә ирешер өчен, шулай ук бердәмлек, дуслык хасил итү, арадагы тискәрелекне, кирелекне, явызлыкны бетерү өчен җибәрелде. Дәүләтнең олылары, хөкүмәтнең ирләре арасында тугры юлга басулары һәм әһле сөннәт вә әл-җәмәгать мәзһәбе буенча гына гамәл кылырга сүз биргәнлекләре, рафизыйлар юлыннан ваз кичүләре – бу рисвайлыктан кайтулары хакында язу белән дә, илчеләрнең теле белән дә госманлыларга белдерелде. Солых маддәсе дуслыкны ныгыту, сүз берлеген булдыру, халык арасында таркаулык – аерылыш һәм кирелекне бетерү теләкләренә юнәлдерелгән биш эшкә нигезләнгән иде. Берсе – Румның галимнәре һәм төрле гыйлемнәрдә танылган казыйлары тарафыннан Җәгъфәр бине Мөхәммәд Садыйк мәзһәбен дөрес итеп тану; бидгатьчеләр чыгарган гакыйдәдән – догмалардан кире кайту; бу мәзһәбне моңарчы дөрес итеп танылган дүрт мәзһәб янында бишенчесе итеп санау; икенчесе – хәрәмдә (хаҗ кылу көннәрендә) бу бишенче мәзһәб өчен урын билгеләү; өченчесе – Мисыр һәм Шам хаҗиларының әмирләре кебек, хаҗ әмирләре арасына Иран мәмләкәтеннән дә бер кеше билгеләү. Госманлы дәүләте ягыннан бу эш өчен билгеләнгән кешегә Мисыр, Шам хаҗиларының әмирләре белән бер дәрәҗә гыйззәт, хөрмәт күзе белән каралырга, аның мәсләген дә бер үк дәрәҗәдә күрергә. Дүртенче – һәр ике дәүләтнең тоткыннары азат ителергә, аларны сату һәм сатып алу рөхсәт ителмәскә.

Бишенче – һәр ике дәүләттән вәкилләр булдырып, бер илнең вәкиле икенчесенең башкаласында торырга.

Аннары һиҗрәттән мең бер йөз кырык сигезенче (1735–1736) ел шәүвәл аеның соңгы пәнҗешәмбе көнендә Моган даласында тәхеткә патшалык урынына күтәрелде. Шушы хөкемдарның үз исеменә мөнбәрдә хөтбәләр укылды, алтын-көмеш акчаларда аның исемнәре, кушаматлары язылып бизәкләнде. Шушы вакыйгалар хакындагы тарихи хәбәрләрдә шулай әйтелгән: Надиршаһның илчесе күренекле түрәләреннән Габделбакый хан Константиниягә килеп, хөкүмәтенең теләген аңлаткан, Надиршаһның тәхеткә күтәрелү, иленең мөстәкыйль патшалык булып әверелү хәбәрен белдергән. Аның белән бергә вәзирләрдән Әбү әл-Касыйм әл-Касани, галимнәр башлыгы Гали Әкбәр дә бар иде. Ике дәүләт арасындагы илчеләр бу мәсьәләдә икеләнә калдылар, ике төркем-груһ галимнәр арасында моназарә – бәхәсләшүләр китте. Бишенче мәзһәбкә буйсыну хакында солтан Мәхмүд Госманиның бик ачык аңлашылмаган һәм икенче шартны кабул итүдә кайбер гозерләрен эченә алган хаты укылды. Дүрт мәзһәбнең барысы да – бик борынгы заманнардан бирле үк дүрт имамга иярү белән билгеләнде, аны үзгәртү бозыклыкка, фетнәгә сәбәп булачак, иран ягыннан Шам юлына махсус хаҗилар түрәсенең килүе халыклар арасында тынгысызлык – фетнә чыгуга сәбәп булыр. Дөрес, аларның Багдад өлкәсе карамагында булган Нәҗәф юлына килеп торуларында зарар булмас. Хаҗиларга кирәкле әйберләрне хәзерләп җитештереп тору аларның бурычы булыр.

Шушы ике дәүләтнең илчеләре арасында икеләнү, ике якның галимнәре арасында бәхәсләшүләр барган чакта, Надиршаһ Кандәһар, Бәлех шәһәрләрен, Һиндстан өлкәләрен, Мавәраэннәһер һәм Харәзем дәүләтләрен җиңеп, үзенең мәмләкәтенә кушып өлгерде, Һиндстан хөкемдары Мөхәммәдшаһ бине Могаззам әт-Тимури Надиршаһка буйсынганын, хөкүмәт һәм гаскәр белән җитәкчелек итү эшен аңар тапшырганын күрсәтеп, Надиршаһны каршы алырга чыкты. Шулай ук Бохара һәм Мавәраэннәһер илләреннән аңар якын өлкәләрнең

хөкемдары булган Әбү әл-Фәез хан бине Собхан-Колый хан әл-Чынгызи дә буйсынып каршы алдылар. Соңыннан Надиршаһ үзе билгеләгән шартларны җиренә җиткерү шарты белән боларның икәвен дә үз урыннарына хөкемдар итеп кайтарып җибәрде.

Исфаһаннан Мәшһәдер-Ризавига килде, аннары Һиратка килеп, аны алды, Кандәһарны алды, Кабулга килде, хәтта Һиндстанда Тимур балаларының пайтәхете – башкаласы булган Дәһли шәһәрен алды.

(VI том, 68–73 б.)

Бикчәнтәй хәзрәт

Һиҗри бер мең ике йөз унбишенче (1800–1801) ел керде. Бу елны вафат булдылар... Әбү Габдулла Бикчәнтәй бине Ибраһим бине... Әл-Газани әс-Сабави әл-хәнәфи (Аллаһның рәхмәтендә булсын) шәгъбан аеның соңгы ун көненең дүшәмбе көнендә Бәрәскә авылында алтмыш яшендә вафат булды. Болгар иле фазыйльләренең атаклыларыннан, галимнәренең дә олугларыннан иде. Яхшы холкы, йомшак күңеле, дин төзеклеге, халык өчен күркәм теләге белән танылган иде. Төп чыгышы Олы Саба (Байлар Сабасы) авылыннан булып, Бәрәскә авылында егерме сигез ел хатыйп һәм мөдәррислек итте, шәкертләре күп, исеме югары, яхшы исеме еракларга таралган иде. Шуңар күрә аннан уку теләге белән шәкертләр бик ерак илләрдән киләләр иде. Мөфти Мөхәммәд[1] бине Хөсәен Борындыкый аны үзенә ярдәмче һәм Мәхкәмәи исламиядә шәригате Мөхәммәдия хөкемнәрен үтәүче казыйлык диванына әгъза итеп, Оренбург каласына алдырды. Бикчәнтәй бине Ибраһим, анда барып, шушы мәхкәмә яңа ачылган чакларда өч ел казыйлык хезмәтен үтәде. Күркәм холыклы, киң күңелле, хуш табигатьле, сүздә тәкәллефле, сөйләшкәндә, төрки сүзләрне дә аз гына охшашы булса да гарәп теле сүзе белән алмаштырып

[1] Мөфти Мөхәммәд – Мөхәммәҗан мөфти.

сөйләшә иде. Мәсәлән, «лапас» сүзен – «лябәәс-лябас», «камзол» сүзен – «көмме заил», «Әлдермеш» сүзен – «Әльдәрвиш» (каралты, кием, авыл исемнәре) дип алмаштыра иде. Бикчәнтәй бине Ибраһимнан гыйлем алган кешеләр арасында: үзенең углы Габдеррәхим, Сөбхан бине Габделкәрим, аның углы Баһаветдин[1], Ибраһим бине Арслан әл-Кимеви; Хәмит бине Солтан Бәрәскәви, Габдессәттар бине Сәгыйд Шырдани, Габид бине Габделгазиз, аның энесе Фәез бине Габделгазиз Кенәри, Рәхмәтулла бине Сөбхан бине Йосыф бине Арслан Балтай әл-Җәбәли (Тау ягы Балтай авылының) иделәр.

(VI том, 134 б.)

Габделхаликъ бине Әгъзам

Һиҗри мең ике йөз уналтынчы (1801–1802) елда үлгәннәр...

Әбү Мөхәммәд Габделхаликъ бине Әгъзам бине Габдеррәхман бине Габделбакый әл-Казани әт-Тәнәки әл-хәнәфи әл-казый (Аллаһның рәхмәтендә булсын) Мәхкәмәи исламиянең яңа гына ачылган чакларда Мөхәммәҗан мөфти әл-Борындыкый тарафыннан Оренбург каласына чакырылып китерелгән өч казыйның берсе иде. Икенчесе Әбү Бәкер бине Ибраһим әл-Казани, өченчесе Бикчәнтәй бине Ибраһим әл-Бәрәскәви иде. Габделхаликъ бине Әгъзам шул заманның зур галимнәреннән, үз чорының атаклы мөдәррисләреннән булып, Мамадыш өязендә Тәкәнеш авылында имамлык итте, мәдрәсә тотып шәкертләр тәрбияләде, дәрес әйтте. Аның тирән гыйлеменнән файдалану өчен, төрле яклардан – өязләрдән укучылар килә иде.

Бу галим китаплар язу эше белән дә күп шөгыльләнде. «әт-Тәүзыйх», «әт-Тәлвих» китапларына хашияләр, өстәмәләр һәм алардан башка байтак китаплар төзеде. Габделгалләм бине Габделкадир әс-Сабавиның аны мактауларын, төрле фәннәрдә тирән йөзүче зур галим иде дип сөйләгәнен ишеттем. Тагын берәү: Габделхаликъ бине Әгъзам Оренбургка киткәч, аның шәкертләре Габдеррәхим бине Йосыф әл-Ашытыйга килделәр,

---

[1] Баһаветдин – Мәрҗанинең атасы.

ләкин аның гыйлемен түбән таптылар, дип сөйләде. Габделхаликъ бине Әгъзам башта үзенең атасыннан укып гыйлем хасил итте, ә үзеннән углы Кәмалетдин Мөхәммәд, Һибәтулла бине Динес әс-Салавычи, Сәйфетдин бине Әбү Бәкер әш-Шәнкәри һәм башкалар укып гыйлем алдылар.

(VI том, 136 б.)

Сәгыйтъ бине Ибраһим

Һиҗри мең ике йөз егерме тугызынчы (1813–1814) ел керде, ул елда үлделәр...

Әбү Шәмес Сәгыйд бине Ибраһим бине Габдулла бине Габделгафур әл-Казани әл-Барыши әл-хәнәфи (Аллаһның рәхмәтендә булсын) Кышкар авылында имам мөдәррис һәм хатыйп буларак күп еллар хезмәт иткән иде, шул ук авылда зур янгын булган елны вафат булды. Үзе бик галим, фазыйль, тугрылыклы булып, шул заманның алдынгыларыннан иде. Аның атасы Ибраһим бине Габдулла да гыйлеме белән танылган, укучылары, шәкертләре күп иде. Төп чыгышлары тау ягы (Иделнең уң ягы) кешесе булып, үз илләреннән чыккач, күп урыннарда имамлык итте, дәрес әйтте, күп кешеләр аннан укыдылар. Сәгыйд бине Ибраһимның бер хатын да күрдем. Үзенең дусты Мөнасип бине Габдерәхимгә аның хатыны үлү кайгысын уртаклашып язган тәгъзия хаты икән. Бу эш исә аның фазыйләте югарылыгын, белеменең тирәнлеген күрсәтә. Бу галим үзе бик канәгатьчел, риязатчы[1] иде. Чәй эчмәс, ашаган азыгы күбесенчә икмәк белән сөт иде. Шулай ук шәех Фәезхан бине Хызыр хан Кабулидән аңа язылган хатны да күрдем. Аның язган хатына каршы җавап хаты иде. Хатта Оры авылындагы шәех Хәбибулла белән утырдаш булырга киңәш биргән, аңа сәлам әйтергә, яхшы теләкләрен ирештерергә кушкан. Сәгыйд бине Ибраһим китаплар язу белән дә шөгыльләнгән. Язганнары арасында җирнең түгәрәклеген исбат иткән рисалә дә бар. Бу рисаләдә күбрәк бүтән галимнәрдән алынган мәгълүмат тупланган. Пәйгамбәр-

[1] Риязатчы – ашаудан сакланучы.

нең хәдисе дип йөртелә торган «Гүя җир үгез мөгезе өстендә тора, үгез үзе худ балыгы аркасы өстендә тора, имеш» дигән әкият һич хәдис түгел, бәлки бер җирәнгеч яла ябу гына ул, дип аңлаткан.

Сәгыйд бине Ибраһим яшьлегендә атасыннан укып, аннары Ишнияз бине Ширнияз әл-Харәзмидән укып гыйлем алган.

(VI том, 149 б.)

Габдулла бине Габделхәй Сәмәрканди

Һиҗри мең ике йөз алтмыш биш (1848–1849) ел керде. Бу елда вафат булдылар... Әбү Сәгыйд Габдулла бине Габделхәй бине Әбү әл-Хәер бине Әбү әл-Фәез әс-Сәмәрканди әл-хәнәфи әл-казый (Аллаһның рәхмәтендә булсын) – яше җитмештән узып шәүвәл аеның соңгы ундүртенче көне чәршәмбе көнне вафат булды. Үлгән елының саннарын хәрефләргә күчергәндә, «заманының остазы» дигән сүзләр килеп чыга. Асылы – чыгышы кыргыз халкыннан булып, бабасы Әбү әл-Фәез Кеш шәһәренә күчеп, шунда яшәгән, кабере анда. Якынрак бабасы Әбү әл-Хәернең кабере һәм атасы Габделхәйнең кабере Сәмәркандта. Әбү Сәгыйд Габдулла үзе – шул йөздә Мавәраэннәһердәге олы галимнәрнең берсе, заманасы фазыйльләренең иң ышанычлысы. Зур галим булуы белән бергә, язучы, эшен нечкәләп тикшереп эшләүче, хакыйкатьне эзләүче иде. Борынгы заманның тикшеренүче галимнәренең бик күп китапларын күргән, укыган, алардан гаять күп мәгълүмат туплаган. Тарих гыйлемен, җәмгыять тормышын, дөньяның хәлен, барышын, хисап, алгебра, топография, астрономия, география, гомумән, гакли һәм нәкъли гыйлемнәрдән (фәраиздан[1] башкасын) бик тирән үзләштергән зур галим иде. Әмма фәраиздан һичнәрсә белми иде һәм аңар карамый да иде. Үзе бик түбәнчелекле, гадәттән тыш юмарт һәм киң күңелле иде. Холкы гүзәл, күршелеге хуш, ягымлы, сүзе йомшак, инсаф – тугрылык иясе иде. Һәрбер олылык иясен эшенә күрә таный белә, һәрбер дәрәҗә иясенә дәрәҗәсенә күрә урын

[1] Фәраиз – мирас бүлү мәсьәләсе турындагы гыйлем.

бирә иде. Бу хәл исә – Мавәраэннәһердә булмаган, табылмый торган эш. Чөнки алар, күбесенчә үзләрен генә зурлап, чиксез мактанып, башкаларны кимсетеп, шаулаучан булалар. Аның түбәнчелекле булуы шунда да күренә: әгәр зиярәт итүчеләрдән берәү, сәетлек дәгъвасын кылучы булып, үзенең нәсәбен – ыругын Гали бине Әбү Талипка илтеп җиткерсә, гәрчә һичнәрсәдән хәбәрсез, надан булса да, яки бүтән бер аз-маз гына гыйлеме булган кеше булса, ул үзенең урыныннан аягүрә тора, килүчене үз янына утырта, яки үзенең урынын бирә, аның алдында түбәнчелек күрсәтеп, аны хөрмәтли, сыйлый иде. Казый Габдулланың бер имамы бар иде, ул инде казыйның даими имамы булып, аның сөхбәтендә картайган Лотфулла исемле кеше иде. Мин Сәмәркандта яшәгәндә, аның янына һәрбер барганымда, ул мине имам итә иде. Күп вакытта без бакчада яки юлда булганда намаз вакыты керә иде, намазлыкларыбыз булмый, өстендә бер генә кат җөббәсеннән бүтән киеме дә булмый иде. Шунда үзенең җөббәсен салып имам өчен җәя, үзе коры җир өстендә калып намазын үти иде. Бер вакыт Сәмәрканд хакименә мине мактаганда, галимлегем турында артыккарак китеп: «Бу егет борынгырак китапларның язучы – төзүчеләренә караганда, бер буын югарырак тора», – дигән.

Казыйның төрле фәннәрдән башка бер җирдә дә очрамый торган бик күп китаплары бар иде. Шулай булуга карамастан, үзенә күрсәтмичә һичбер китапны сатмаска шәһәрендәге китап сатучыларны мәҗбүр итеп куйган. Әгәр китапчыда булган берәр китап моның китапханәсендә табылмаса, ул китапны ике өлеш кыймммәт бәя биреп булса да сатып ала иде.

Суфилык шәехләренә, тарыйкать ияләренә, бигрәк тә шәех Шәфигыйга ышанган иде. Әгәр алдына әһле сөннәттән (сөнни мәзһәбеннән) яки шигый мәзһәбеннән берәр горбәттә – чит илдә калган кеше килеп керсә, аңар булдыра алганча яхшылык итә, булыша, аны кунак итә, аның шәһәренең хәлләрен сораштыра, галимнәре, шәехләре, шагыйрь һәм әдипләре, патшалары, аларның тормыш хәлләре хакында сораштыра торган иде. Шунлыктан ул күп илләрнең хәлләре, төрле шәһәрләренең шәехләре,

төрле яклардагы галимнәрнең хәлләре хакында хәбәрдар булып тора иде. Ул: «Һинд патшасы Тимур шаһ, Хорасан иленә килеп, Бәлх шәһәренә төшкән. Аның белән бергә галимнәр башлыгы дип атаклы бөек галим Хөсәен бине Мөхәммәд Әкбәр әл-Кабули дә утырдаш булган. Мин дә, шуңар барып, аның гыйлемнәреннән азмы-күпме нәрсә алырга теләп ант итсәм дә, миңа насыйп булмады, мин алар янына барганчы, теге галим үлде. Шуның өчен минем өстемә кәффарәт (кол азат итү, яки күп садака биреп түләү) бурыч булып йөкләнде. Мавәраэннәһердә гыйлем ягыннан аңа тиң булырлык кеше юк», – дип сөйли торган иде. Төрле гыйлемнәре буенча аның осталыгы хакында шәех Шәмсетдин әл-Бәлхи үзенең атасыннан ишеткәненчә: «Әгәр әмир Мәгъсүм Шәйхелислам Гатаулла әл-Бохарины Тимур шаһка илче итеп җибәрү теләгендә нык торып, шуны барлыкка чыгарган булса, һичшиксез, безне рисвай иткән булыр, безнең оялырга тиешле эшләребез ачылган булыр иде» – дип, тыңлаучыны аптырашта калдырырлык, күзләрдән яшь китерерлек нәрсәләр сөйли иде. Бу исә Хөсәен әл-Кабули һәм Һинд иленең бүтән галимнәре белән чагыштырганда, Гатаулла Бохариның Мавәраэннәһер халкы арасында шөһрәте һәм дәрәҗәсе югары булуга карамастан, аның фазыйләте азлыгы, гыйлеме бик йомшак булганы өчен әйтелгән сүзләр иде. Әмма Шәмсетдин Бәлхи зур шөһрәтле дә түгел, дәрәҗәсе дә бөек түгел иде: бәлки, Һинд халкы безнең илебездә (Сәмәркандта) аңар караганда гыйлеме күбрәк, эрудициясе киңрәк кешеләр күп дип уйлаган булырлар иде.

Габдулланың атасы Габделхәй дә китаплар язу белән шөгыльләнгән. Ул үзенең язган әсәрләрендә шушы баласы хакында да кайбер нәрсәләрне, аның кайбер сүзләрен хикәят кылган. Ул миңа китапларны биреп торды һәм әлеге хикәяләрне күрсәтте.

Атасының күп җир-сулары булган. Аларны балаларына вәкыф итеп калдырмакчы икән. Ләкин Габдулла моңа каршы килгән: «Шул җир-су белән балаларың арасында дошманлык салырга телимсең», – дигән. Шул сүзгә карап, атасы бу эштән

кайткан. Атасы үлгәннән соң, бу казый калган мирастан ваз кичкән, һичнәрсә алмаган. Бөтен мирас малы бүтән балалары арасында өләшенгән. Бу – Габдулла казый – Сәмәркандтагы «Ширдар» һ.б. берничә мәдрәсәләрдә дәрес бирү белән шөгыльләнгән, мохтәсиблек вазифасын да үтәгән, иң югары белгеч дәрәҗәсенә дә ирешкән. Атасы үлеп байтак еллар үткәч, казый булып торган, шул урыннан төшерелмәгән, фәкать ике генә ел бушатылып торса да, яңадан кайтарылып, шул хезмәтендә вафат булган. Аның үзенең дә мөлкәте зур, җир-суы бик күп, бакчалары – бостаннары берничә иде. Шулай булуга карамастан, үзе бурычтан бушамый, һаман өстәлеп бара, бурыч ияләре күбәя бара иде; бу исә аның юмартлыгы һәм мохтаҗларга һәрвакыт ярдәм биреп торуы сәбәпле иде. Мин Сәмәркандта торган чакта, аннан һәрвакыт китаплар алып тордым, башка китапларда очрамый торган күп нәрсәләрне күчереп алдым.

Шулай ук бу галим минем тарих гыйлеме белән кызыксынуыма, шул хакта язылган китапларны укып-тикшерә башлавыма да беренче сәбәпче булды. Гомумән, бу галимнең яхшылыкларын, юмартлыкларын санап бетергесез. Мавәраэннәһердә аның кебек киң гыйлемле, фазыйләтле, йомшак күңелле, инсафлы икенче берәүне күргәнем юк.

Бервакыт Мәхдүм әл-Бохарый дигән дивана кеше Габдулла бине Габделхәйгә сукты, начар сүзләр белән аны сүгеп кыерсытты, ләкин ул шуңар каршы һич явызлык белән кайтармады, бәлки аны хөрмәтләп, күп яхшылыклар итте.

Тәсниф иткән китаплары: 1. «Әш-Шәрхе әр-рисаләтел-җәдидәтел-җәлалия». 2. «Әр-Рисаләте фи ысулил-фикъhe» h.б.

Габдулла бине Габделхәй үзенең атасыннан һәм Гатаулла әл-Бохаридан укып белем алды. Үзеннән исә углы Әбү Таһир, Мөхәммәд Зәман Сәмәрканди, Габид әл-Күляби һәм башкалар укып белем алдылар.

(VI том, 212–214 б.)

Хөсәен Фәезханов

Һиҗри мең ике йөз сиксән өченче (1866–1867) ел керде. Бу елда вафат булдылар... Әбү Мөхәммәд Хөсәен бине Фәезхан бине Фәйзулла бине Биккенә бине Исмәгыйль бине Тәңребирде әл-Җәбәли әс-Сабаи әл-хәнәфи (Аллаһның рәхмәтендә булсын) рабигыль-ахир аеның соңгы дүшәмбе көнендә вафат булып, тау ягы авылларыннан Сабажа (Сафа җае – «рәхәт ял итү урыны» мәгънәсендә) авылында күмелде. Яше кырык биштә иде. Җеназасын Әбү әл-Габбас Әшрәф бине...[1] укыды. Үзеннән соң Гайшә, Зәйнәп, Әминә исемле өч кызы калды, ир баласы калмады.

Хөсәен бине Фәезхан гүзәл холыклы, саф күңелле, дөрес аңлы, тирән акыллы, олы һиммәтле, һәр эштә дикъкатьле, фазыйләтле, күп уйлаучы, оста язучы, зур галим иде. Гыйлем өлкәсендә бик күп тикшеренү ияләренең китапларын укып зур белем туплаган, үзе дә күп лекция һәм докладлар белән чыгышлар ясаган кеше иде. Гомуми тарихтан, кешелек җәмгыятенең тормыш хәлләреннән, төрле хөкемдарларның хәл һәм эшләреннән хәбәрдар иде. Шулай ук фикъһе һәм ысулда тирән гыйлем иясе иде. Мөселман халыклары өстенә килгән авырлыкларга, аларның зәгыйфьләнүләренә, шәүкәтләре төшүгә, үзара ярдәмләшү азаюына, гыйлем-фән китүенә бик ачына иде. Гыйлем-мәгърифәттә, гүзәл сәнгать һәм төрле фәннәрдә, кирәкле коралларны эшләп чыгаруда борын заманнарда ирешелгән югары дәрәҗәләрен югалтып, шул заманнарда белгән һәм тормышта кулланган белемнәрне дә онытуга бик уфтана торган иде. Үткәндәге галимнәр калдырган белем хәзинәләрен дә аңлама-уга, бигрәк тә хәзерге заман укучыларының ялкаулыгына, эшлексезлегенә, гыйлем-фәнне үзләштерүдә аларның фикерләре таркаулыкка, күп вакытларын файдасыз нәрсәләргә әрәм итүләренә, мөдәррисләренең дә тормышларында һәм эшләрендә тәртип булмавына бик кайгыра торган иде. Гакли һәм нәкъли гыйлемнәрне үзләштерүдә мөселман халыкларының борынгы

[1] «...» – исем язылмаган.

чорларда ирешкән югары дәрәҗәсен яңадан кайтару өчен бик тырыша, шуның юлларын эзли иде. Гыйлем-мәгариф эшендә халыкның алга китүе өчен, гүзәл биналы мәдрәсәләр торгызу, фәннәрнең һәр тармагын укыту өчен, аерым белгечләр (мәсәлән, бер мөдәррис фәкать фикъһе генә укытыр, башка эш белән булышмас, икенчесе гарәп теле, әдәбияты фәннәре укытыр, башкасына керешмәс, өченчесе хикми – фәлсәфи мәсьәләләрне укытыр, шулай башка фәннәргә дә аерым укытучылар) билгеләргә кирәк. Аларның һәркайсысы өчен җитәрлек чамада айлык эш хакы билгеләнсен, мәдрәсәдә шул мәдрәсәнең бөтен кешеләренә хөкеме йөрерлек, аларны гакыл һәм шәригать нигезендә билгеле бер кагыйдә-канун чигендә тотарлык мөдире булсын. Укучы бер китапны яки бер фәнне укып, өйрәнеп төгәлләп, тиешле сынауны биргәч һәм шул сынау эшләрен башкаручыларның рәисе тарафыннан ул укучының өлгергәнлеге хакында таныклык бирелгәч кенә икенче китапны, икенче фәнне өйрәнергә керешер. Шулай ук мәдрәсәнең яшәве өчен кирәкле булган ягу, җылыту, яктырту, җылы су белән тәэмин итү чыгымнарына җитәрлек килере – хуҗалыгы булырга тиеш. Шулай ук мәдрәсәне себереп, җыештырып, суларын җылытып торырлык, утын һәм башка кирәкләрен сатып алып өзлексез тәэмин итәрлек кешеләре дә булырга тиеш. Әлбәттә, мондый мәдрәсә Казан шәһәрендә булырга тиешле, чөнки монда халыкның галимнәре, мәмләкәтебездәге мөселманнарның фазыйльләре күбрәк тупланган. Монда зур байлык ияләре дә күп. Бу мәдрәсәне идарә кылуда һәм мәдрәсә халкын ашамлыклар белән тәэмин итүдә аларның шактый булышлыклары тиергә мөмкин. Әгәр һәр мөдәррискә ел буенча рус акчасы белән елга икешәр йөз сум хезмәт хакы бирергә билгеләнсә, алар укыту һәм дәрес бирүдә үзләренә йөкләтелгән бурычларны тиешле тәртиптә үти алырлар иде. Әмма мәдрәсә Мәскәү хөкеме йөри торган бүтән бер шәһәрдә булса, анда мөселман галимнәре һәм фазыйльләре булмас, галимнәрне һәм укытучыларны тулы вазифалар – айлык хезмәт хаклары билгеләп һәм җитәрлек тормыш шартларын тәэмин итеп, читтән китерергә кирәк булыр. Бу эшне барлык-

ка чыгару читенләшер. Шулай ук бу эшләрне оештыру Россия дәүләтенең ризалыгы – санкциясе һәм ярдәме белән генә мөмкин булачак. Аның ризалыгын алу өчен, кирәкле эшләр белән шөгыльләнүдә мәмләкәт әһленең ышанычын казаныр өчен, мәдрәсә халкының һич булмаганда кайберләренә генә булса да рус каләмен, рус язуын өйрәнү, рус телен үзләштерү кирәк булачак. Чөнки безнең халкыбызның бөтен кирәк эшләрен булдыру Россия дәүләтенә бәйләнгән. Барлык кануннар, хөкемнәр, беркетмәләр шул телдә йөргәнгә күрә, ул телне өйрәнү һәм белү зарури булып кала. Шулай ук төрле хәйләләрдән имин булу өчен дә – ул бик кирәкле белем. «Бер телне белгән кеше, ул телдә килүе мөмкин булган мәкерләрдән имин булыр» дигән мәкаль дә бар. Шуннан соң барлык кирәкле эшләрен тормышка ашыру өчен җитәрлек сумма туплау мәсьәләсе бар. Аның өчен мәдрәсәнең үзенә махсус матбагасы булырга, мөселманча китаплар фәкать шунда гына бик зур игътибар белән яхшы кәгазьдә, гүзәл хәрефләрдә, ачык кара белән бик дөрес итеп басылырга тиешле. Болардан тупланачак сумма мәдрәсәнең кирәкләре өчен тотылыр. Шуның белән бергә, хәзерге көндә Оренбург җәмгыяте шәргыясе карамагында, аның ук кушуы буенча мөселманнардан никах укылган саен билгеле бер чамада алына торган акчалардан да шактый сумма җыелган. Ул исә ел саен арта бара. Духовное собрание бинасын салдыру өчен бирелгән акчадан да байтак артып калды. Әгәр җитмәсә, мәһәрнең күп яки аз булуына карап, никахтан алына торган салым бераз арттырылырга да мөмкин, ләкин болар, әлбәттә, хөкүмәтнең рөхсәте белән генә эшләнер. Ул хакта тиешле оешмалар белән язышулар, үтенүләр кирәк булыр. Бу мәдрәсәне оештыру, торгызу өчен, хөкүмәт тарафыннан рөхсәт алу менә шушы юллар белән генә мөмкин булачак», – ди торган иде Хөсәен Фәезхан углы...

Тәрҗемәи хәл иясе бу мәсьәлә хакында күп олылар белән киңәште, байтак мәшһүр кешеләргә, шулай ук гыйлем-мәгърифәтне аңлаучы, киләчәкне ерактан күрә белүче дип уйлаган һәрбер кешегә үзенең шушы максатларын – идеяләрен

сөйләп күрсәтте. Чөнки рәсүлебез дә: «Яхшылыкны эзләгән буш булмас, киңәш белән эшләгән үкенмәс» дип боерган. Пәйгамбәрнең үзенә дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан: «Эштә аларга, ягъни халыкка киңәш ит», – дип боерылган иде. Ләкин аның алдына дошманнарның көнчелекләре, яла ягулары килеп басты. Аның теләкләренә каршы тордылар, халыкны аннан биздерергә тырыштылар, аның көткән өметләренә хыянәт иттеләр, төрле бәлалар яктылар, мөселманнарга каршы начар теләктә йөри дип ялган яла яктылар. Алар арасында бигрәк тә тискәресе, аның хакында һич булмаган нәрсәләр, ялган хәбәрләр кабартып йөрүче кеше Кышкар авыл имамы Исмәгыйль бине Муса иде... Дус-ишләребез һәм башкалар арасыннан берничә кешедән бу тәрҗемәи хәл иясе белән шул имам арасында булып узган түбәндәге хикәяне ишеткәнем бар: Исмәгыйль Муса углы, Казанга килеп, кияүләре Габдерәшид бине Йосыф өенә туктаган чакта, аның янына тәрҗемәи хәл иясе килеп кергән. Мәдрәсә ачу хакында, аның идарәсе, анда уку-укыту рәвешләре хакында үзенең уйлаган фикерләрен аңар сөйләп биргән. Шул чагында Исмәгыйль Муса углы бөтен көче белән бу фикергә каршы төшкән, рус теле өйрәнү кирәклеге хакында сүз чыккач, бигрәк тә, тискәреләнеп, хәтта «аны өйрәнү хәрам» дияр дәрәҗәгә килгән. Тәрҗемәи хәл иясе: «Ул гыйлем мәдрәсә ачарга хөкүмәттән рөхсәт алу өчен кирәкле бер чара, максат исә – югалткан гыйлемнәрне тергезү; хәзерге көндә рус теле гыйлеме дә бик кирәк, чөнки безнең эшләребез шул дәүләт белән бәйләнгән», дип аңлаткан.

(VI том, 246–250 б.)

ӘЛ-КЫЙСМЕЛ-ӘҮВӘЛЕ МИН КИТАБИ «МӨСТӘФАДЕЛ-ӘХБАР ФИ ӘХВАЛИ КАЗАН ВӘ БОЛГАР»

Бу, кимчелеге күп фәкыйрь кол Шиһабетдин бине Баһаветдин әл-Мәрҗани әйтә: гыйлем һәм мәгърифәт кәсеп итү, кәмаләт һәм хикмәт хасил итү һәр сәламәт акыл, төзек аң каршында һичшиксез кирәкле, бу өлкәдә тырышлык һәм киң ярдәм берсүзсез күркәм эш. Аң, фикер иясе кешеләр алдында бик ачык: гыйлем ул – сыйфатларның иң күркәме, кәмаләтнең иң мактаулысы; аны хасил итү ләззәтнең һәм сәгадәтнең югары дәрәҗәсе, чиге. Пакь ислам шәригате гыйлем алу һәм мәгарифне камилләштерүгә кыскача да, озын-озын да өндәп һәм кызыктырып, гомумән гыйлем турында – «Белгәннәр белән белмәгәннәр бертигез булырмы?», «Хода үзенә ышанучыларның һәм гыйлем ияләренең дәрәҗәләрен күтәрә», «Берәү хикмәтле бер сүз әйтсә, күп изгелек кылган булыр», «Акыл ияләре генә телгә алыныр» дигән аятьләр бар һәм телләр аңлатып бирүдән гаҗиз булган илчелек, пәйгамбәрлек хәзинәсеннән килеп чыккан нәфис, кыймәтле энҗеләр – «Хикмәт – мөәминнең югалткан нәрсәсе, аны ничек тапса да файдаланырга хаклы була», «Белемне Кытайга барып булса да алыгыз», «Гыйлем эстәү һәр мөселманга фарыз» шикелле хәдисләр бар. Укучыларга, бигрәк тә укучы балаларга ярдәм күрсәтүчеләрнең һәм укучыларның ата-аналарының әҗерле-сәваплы булулары хакында никадәр Коръән аятьләре һәм пәйгамбәр хәдисләре китерелгән. Бөек ислам галимнәре тарафыннан язылган тирән хикмәтле китаплар һәрбер төрле гыйлемнең файдалы булуын исбат итү белән тулган... Болар Ходаның бөек хикмәтләрен өйрәнүне боерган шикелле, тарих, халык һәм шәһәрләрнең тормышы, география, топография һәм этнография фәннәренә дә кызыктыра...

Бу тарих фәне һәрбер милләт вә кабиләләрнең хәлләрен эченә ала, гыйльми тармакларны һәм фәнни бәхәсләрне тикшерә, гади халык аны белергә тели, география һәм тарих галимнәре аны өйрәнергә кызыгалар. Тышкы яктан караганда ул бер хорафатка, төпсез бер хикәягә ошаса да, чынбарлыкта, эчке ягын тикшереп караганда аның һәрбер сүзе мәгълүм бер төшенчәне эченә ала; аның һәрбер җөмләсендә яшерен хикмәтләр, яшерен серләр ачыла. Тышкы яктан ул заман һәм дәүләт-

ләрне, эчке яктан, аларның борынгы хәлләрен, эшләрен нечкәләп тикшерә; галәмнең башлап барлыкка килү серләреннән хәбәр бирә, вакыйгаларның нинди рәвештә булганлыкларын һәм аның тирән сәбәпләрен ачып күрсәтә, мөселманнарның тарих галимнәре заманнар хәленнән тулы хәбәр бирү, халыкның тормышын аңлату бурычын үтәү теләге белән мәмләкәтләр, хәлифәләр, патшалар, галимнәр, суфиларның төрле катлаулары, тарикать әһелләре, борынгы акыл ияләренең тоткан юллары, аларның табигать һәм йөреш-торышлары, фән һәм сәнәгать[1] ияләре, сугышлар, дини оппозицияләр һәм баш тартучылар тарихыннан күп хәбәрләр тупладылар, күчерделәр. Әмма безнең болгарлар, монгол һәм татарлар бу бөек тарих гыйлеме һәм халыклар тормышы белән аз кызыксынганлыктан, тарих фәненнән өлешсез калып, дөньядагы хәлләр, вакыйгалар һәм мажараларны беркетеп бармаганнар. Шуңа күрә бөек галимнәребез, патшаларыбыз һәм олы хакимнәребез турындагы хәбәрләр, ата-бабаларыбызның һәм туганнарыбызның хәлләре үз халкыбызга һәм башка милләтләргә дә мәгълүм булмыйча, бөтенләй наданлык пәрдәсе астында капланып калган; хәтта халкыбызның күбрәге борыннан бирле шулай Россия хөкүмәте астында торабыз дип уйлыйлар. Болгар һәм Казан хәлләре хакында Болгардагы әүлияләр һәм изгеләр каберләреннән, хан мәчетеннән һәм, борынгылыкны белдерү өчен: «һай ул хан заманында булган эш!» дип әйтүдән башканы белмиләр, ул сүзнең дөрес мәгънәсен аңламыйлар. Гомумән, үз кавемнәренең үткәннәреннән, аларның яшәгән җирләре һәм ни рәвештә яшәүләреннән хәбәрләре юк. Үз кавемнәреннән никадәр патшалар һәм бөек эшлеклеләр килеп киткәнлеген белмиләр. Чиктән тыш наданлыкларыннан, Мавәраэннәһердә булган сарт[2]

---

[1] Сәнәгать – һөнәр, промышленность.

[2] Сарт, чирмеш, мукшы, ар – үзбәк, мари, мордва һәм удмурт халыкларының элекке, революциягә чаклы булган исемнәре. Бу халыклар үзләре бу исемнәрне хурлыклы санап, хәзер алмаштырдылар һәм, югарыдагыча, «үзбәк, мари, мордва, удмурт» дип йөртәләр. Без дә һәр урында ул исемнәрне Ш. Мәрҗанинең үзенчә сакладык.

халкына ияреп, дөреслеккә каршы, үзләренә «нугай» исемен алып, үз араларындагы сөйләшү-утырышуларда шул исемне йөртеп һәм үзләрен шул халыктан дип санасалар да, россия-леләрнең аларны кимсетү, мәсхәрәләү урынында «татар» дип әйтүләреннән кайсыберләре татар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән чирканып, без татар түгел, мөселман дип тавышҗәнҗәл чыгаралар; ләкин бу исемнәрнең арасында Нил белән Фөрат елгалары арасындагы ераклык кадәр аерма бар бит. И мескин! Әгәр дә синең «мөселман»нан башка бер исемеңне алар белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип нәфрәт иткән булырлар иде. Татар булмасаң, гарәп, тажик һәм нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың? Яхшы ки, әле сарт халкы, чирмеш, мукшы һәм ар халыкларының барлыкларын белмәгәнлекләреннән, сине ул исемнәрнең берсе белән атамаганнар. Нинди хәмиятсез[1], аңсыз син. Әгәр дә шулай булган булса, үзеңне чирмеш я мукшы санап разый булып йөрер идеңме? Менә шул рәвештә гыйлем һәм мәгариф рәваҗсыз[2], игътибарсыз калып, тарих вә нәсел-нәсәпләрне өйрәнү гыйлеме бөтенләй онытылган – ташланган булганлыктан, гайрәтләре сүнеп, зәгыйфьлектә калган халкыбыз «Хуҗа Насретдин», «Бүз егет», Мөслиминең «Тәварихе Болгария»се һәм «Сәед Баттал» шикелле ялган хәбәрләр, игътибарсыз сүзләрдән торган китаплар белән гомерләрен әрәм итәләр. Галимнәр дип аталган төркеме Ибне Кәмал паша китабы һәм шуннан алынган ялгыш-йолгыш кыска хикәяләргә ябышып алып, олы галимнәрнең, мәшһүр бөек әдипләрнең әсәрләреннән хәбәрләре юк. Инде шәһәрләр вә борынгы вакыйгалар турында язылган борынгы галимнәрнең әсәрләреннән дөрес төзелгән, күп аңлатмаларны эченә алган һәм теләккә муафыйк булган тарих китабын көтеп торсак, Аллаһ белә, теләккә ирешә алмабыз. Аерым галимнәр яки аерым кешеләр генә түгел, бәлки мәдәниятле бөек дәүләтләр игъланнар таратып, ислам мәмләкәтләреннән тарих

[1] Үзенең кадерен белмичә, башкалардан ким, түбән санауга риза булып йөрүче кеше.

[2] Рәваҗсыз – таралмыйча.

әсәрләре сорасалар һәм эзләсәләр дә, хәзергә кадәр теләкләренә ирешә алганнары юк. Галимнәрен шул эшкә утырткан, халкын шул юлга салган дәүләттә гыйлем, һөнәр өйрәнелер, хикмәт һәм мәгариф артка калмас.

Болгар халкы, Хода белә, сәяхәт һәм сәүдә максаты белән һәм төрле надан таифәләрне туры юлга күндерү, бозык юллардан коткару теләге белән төрле илләрне йөреп, ислам диненә керергә өндәгәннәр. Шул арада, эшнең барышына карап, кирәк табылса, сугышлар да булгалап алганлыктан, аларның китаплар язарлык буш вакытлары булмаган булса кирәк. Гәрчә ул чакта китаплар бераз язылган булсалар да, ул заманда китап басу техникасы булмаганлыктан, аларның нөсхәләре күбәйтеп таратылмаган, булган нөсхәләре дә Болгар һәм Казан өстенә килгән бәлаләр, бәхетсезлекләр аркасында һәлак булып, югалып киткәннәр булырга кирәк. Шуның белән бергә, башка илләр галимнәренең китаплары эчендә язылган, кайбер китаплар һәм рисаләләрдә телгә алынган һәм ата-бабалардан ишетелеп, халык авызында сөйләнеп килә торган таркау хәбәрләр бар. Бу хәбәрләргә бер дә тикшерүсез ышанырга ярамаса да, һичбер дәлилсез ялган дип тә хөкем итеп булмас, бәлки замананың хәлләрен, аның мажараларының нинди икәнлеген белеп, хәлләрнең агышына, замананың теләгенә яраштырып, вакыйгаларның күрсәтүләрен шаһит итеп фикер йөртә белергә кирәк булыр. Бер хәбәрнең ялган икәнлеге беленеп торса да, ләкин ялган булуы катгый рәвештә билгеле булмаса, аны да язарга һәм ышанычлы түгеллеген күрсәтергә кирәк. Ул сурәттә бу хәбәр һәркемнең игътибарын һәм дикъкатен җәлеп итеп, шул турыда фикерләр туплану белән ул хәбәрнең ялган яки хаклыгы ачыкланыр. Бер хәбәрнең шиксез ялганлыгы ачыкланса һәм язылып исбат ителсә, ул хәбәргә ышанып йөргән кешеләрне хатадан котылдыруга сәбәп булыр. Без инде хәбәрдар булганыбыз хәтле Болгар һәм Казан хәлләренә бәйләнешле булган хикәятләр, хәбәрләр, риваятләр һәм сүзләрне кулыбызга төшкән кадәр китаплардан, язмалардан җыештырып, бу китапны төзибез; чөнки тарихчының вазифасы – үзе хәбәрдар булган һәм игътибарга лаеклы

булган сүзләрне, хәбәрләрне арттырмый, киметми, ничек бар, шулай китерү, эчтәлегенең төп өлешен төшереп калдырмыйча һәм берәүнең файдасына, ә икенченең зарарына тарафдар булмыйча аңлатып бирү. Әмма берәү үз белдеге белән генә берәүне мактап, берәүне яманлап, берәүнең яхшы, берәүнең начар эшләрен генә сөйләсә, ул кеше Ходаның боерыгына буйсынмыйча, гөнаһлы була, ялган һәм хаксыз сүзләр сөйләп, Ходага һәм аның рәсүленә хыянәтче була.

Бу китапны мәмләкәтебезгә руслар кергәнче һәм алар хакимлеге астына кереп калганнан соң булган ике төрле хәлгә карап, ике бүлек итеп тәртип ителде. Болгар илендә элек тә һәм татарлар килгәч тә, төрле кавемнең һәркайсының үзләренең башлыклары һәм хөкемдарлары булса да, бөек бер хөкүмәткә бәйле, олы бер патшаның хакимлегенә буйсынган булып, ахырда, бәгъзе бер сәбәпләр аркасында, бигрәк тә Аксак Тимер фетнәсе нәтиҗәсендә, Туктамыш ханның патшалык көннәре төгәлләнеп, Дәште Кыпчак, Җуҗи улусы һәм Бәриятел-Бәркәдәге кабиләләр арасында таркалу һәм илгә гомуми зәгыйфьлек килеп, Олуг Мөхәммәд хан илнең башкаласы Сарайдан чыгарылганнан соң, Җуҗи хан нәселе шаһзадәләре арасында бер-берсенә каршылык-гауга чыгуы аркасында төрле кабилә дәүләтләренә охшаган аерым вак-вак дәүләтләргә бүленеп беттеләр.

Беренче – Казан дәүләте, Казан шәһәренең үзендә Олуг Мөхәммәд хан балалары дәүләте төзелде.

Икенче – Сарай дәүләте – татар дәүләтенең төп үзәге булып, Кече Мөхәммәд хан балалары идарәсендә калды.

Өченче – Хаҗитарханда[1] Кече Мөхәммәд хан балаларының кайберләре.

Дүртенче – Кырым дәүләте, Кырым ярыматавында Бакчасарай шәһәрендә Хаҗигәрәй хан бине Гыясетдин бине Таштимер һәм балалары хөкүмәт төзеделәр.

---

[1] Хаҗитархан – Әстерхан.

Бишенче – Нугай урдасы. Җаек суы буенда Сарайчык шәһәрендә мангыт халкыннан үзләренең мөстәкыйль биләре була иде.

Алтынчы – Казахстанда казах ханнары – Барак хан бине Коерчык хан бине Ырыс ханның ике углы – Җанибәк һәм Гәрәй исемле шаһзадәләр, үзләренә бер дәүләт оештыра алмаганлыктан, төрле яшь-җилбәзәк һәм бозык юлда йөри торган бүтән кешеләрне иртеп, туры килгән авыл-шәһәрләрне басып, талап, башбаштаклык кылып йөреп, һичбер җирдә нигезләнмичә, качып йөреп, казах дип аталдылар, ягъни «качак»[1] мәгънәсендә була. Берзаман Әбү әл-Хәер хан үлгәч, баш күтәреп, Мангулиялән кайтып, сигез йөз җитмешенче (1465–1466) елның ахырларында үзләренә хан исемен күтәреп, Дәштнең көнчыгышында борынгы Ак Урда тирәсендә күчеп йөреп, хөкүмәтне балаларына калдырганнар. Бер заман куәт табып, Төркестан, Ташкент шәһәрләрен яулап алганнар; бигрәк тә Тәвәккәл хан бине Шигай хан бине Ядик хан, Сәмәркандны яулап алып, Бохарага барып, Пирмөхәммәд ханны чолгап алды. Ул вакытта бер генә хан хөкүмәте астында яшәп, нәселләре күбәйгәч, үзләреннән көнбатышта яшәүче башкортларны тагын да көнбатышкарак куганнар. Пәйгамбәрнең һиҗрәтеннән мең дә бер йөз (1658–1659) ел ахырларында Түкә хан бине Җиһангир хан гасырында Казахстанны өчкә бүлеп, Олы йөз, Урта йөз һәм Кече йөз дип атап, Олы йөзне Түлә-би, Урта йөзне Кузы-би, Кече йөзне Әйтек-би исемле өч хакимгә тапшырган. Бераз вакытлар һәр йөз үз-үзенә ханнар сайлап, ахырда рус хөкүмәте астына кергәннәр. Олы йөзнең бер кабиләсе әле дә Кытай карамагында яши.

Җиденче – Себер дәүләте – хаҗи Мөхәммәд хан бине Гали һәм аның балалары дәүләте. Башкалары Тубыл (Тобольск) шәһәреннән 12 чакрым җирдә «Искер», яки икенче исем белән «Себер» исемле шәһәр иде.

---

[1] «Казак (яки казах)» халкының ни өчен бу исем белән аталганлыгы әле дә ачылып җитмәгән. Ш. Мәрҗани моны сүзнең этимологиясенә карап билгеләргә тырышкан. Бу – Мәрҗанигә генә хас алым түгел.

Югарыда сөйләнгәннәр барысы да Җуҗи улусында хөкүмәт төзеп, араларында берлек булмау сәбәпле дәүләтләре бетеп, читләр кулы астына кереп калдылар. Болар һәркайсы аерым фасылларда сөйләнеп, аннары Харәземдә һәм Мавәраән-нәһердә хөкемдарлык иткән Җуҗи балалары һәм Харәземдә Коңгратия, Бохара һәм Сәмәркандта безнең заманга чаклы дәвам иткән Мангыт хөкемдарлары телгә алынырлар, чөнки боларның күбрәге ана ягыннан булса да, нәсел-нәсәпләре белән Җуҗи ханга барып тоташалар һәм Җуҗи балаларының патша-лык варислары булып торалар. Шулай ук Фирганә җирендә оешкан Бабурин дәүләте «Тардел-ләбаб»та сөйләнер, инша Аллаһ. Әмма төп максат – Болгар һәм Казан хәлләре булып, башкаларның да барлыкка килү һәм төп нигезләре шул тирәдә булганлыктан, «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дип исем куелды.

I нче бүлек

«БОЛГАР, АНЫҢ ҮТКӘН ХӘЛЛӘРЕ ҺӘМ ШУҢА БӘЙЛӘНЕШЛЕ ХӘБӘРЛӘР ТУРЫНДА»

Бу беренче бүлек ике бабка салып төзелде.

I нче баб. Болгар шәһәре, аның патшалары, милекләре, әсәрләре һәм аның хәлләре турында.

«Болгар» «б» хәрефенең даммәсе, «гъ» хәрефенең фәтхәсе[1], әлиф («а») һәм «р» белән. Камус иясе аны «Бргр» формасында беркеткән һәм «халык аны «болгар» формасында куллана» дип, телебездәге мәшһүр әйтелешне гади халык әйтелешенә генә кайтарып калдырган. «Л»ны «р»га алмаштырып һәм «а»ны төшереп «бргр» рәвешендә әйтү исә кайбер диалектларда гына булган. Борынгы галимнәрнең әсәрләрендә «Болгар» сүзе тау исеме, халык исеме, өлкә исеме, мәмләкәт исеме һәм шәһәр исеме дип тә йөртелгән. «Сез кайсы кавемнән, ә болгарлар кемнәр?» дип сорау биргәндә: «Сәкалибә белән төрек халкы арасында туган бер халык без», – дип җавап биргәнлекләре язылган.

Борынгы заманда һәм хәзер дә «Болгар» сүзенә «шәһәр» дигән сүзне кушып, гүя аның бер кисәге итеп, «Шәһре Болгар» дип йөрткәннәр һәм йөртәләр.

«Әгәр кайчан да булса Шәһре Болгарга барсаң, аның дусларыннан сәлам әйт» дигән фарсы шигырендә дә «Шәһре Болгар» диелгән. Бу шәһәрнең газилары турындагы касыйдәдә һәр бәетнең ахыры «шәһре Болгар газыйлары» дип тәмамлана. Бу да

---

[1] Даммале «б» – «бо», фәтхәле «гъ» – «га» дип укыла. Болай аңлату гарәп теле язылыш һәм укылышына нигезләнгән.

Болгар дигән сүзнең өч нәрсә арасында уртак булып йөргәнен күрсәтә.

Бу шәһре Болгар Идел елгасының төньягына, Чулман елгасының Иделгә кушылган почмагына утырган. Ул урын экватордан илле биш градус төньяк киңлектә, Канар утрауларыннан алтмыш җиде градус көнчыгыш озынлыкта һәм төшлек ноктасыннан унбиш градус кадәр көнбатыш ягында тора. Халык телендә моны Искәндәр әл-Макидуни бинасы дип йөртәләр. Гайсаның тууыннан ике гасырдан артыграк элек төзелеп, зурлыгы уртача гына булса да, утырган урыны тармаклары күп булган ике зур елганың бер-беренә коя торган ноктасына якын бер урында булганлыктан, төрле яктан, чит илләрдән зур сәүдәгәрләр килеп катнаша торган мәшһүр һәм зур базарлы бай мәмләкәтләрдән санала иде. Зур пристане, сәүдәханәсе булган бу төзек шәһәрнең халкы борынгы вакыттан бирле бай культуралы, сәүдәгәр, күп сәфәр һәм сәяхәтләре белән дөньяга мәшһүр иде. Монда ерак илләрдән галимнәр, сәүдәгәрләр килеп, гарәп галимнәреннән казыйлары, мөдәррисләре һәм хатыйплары[1] булган.

Шуннан соң өстенә килгән һәртөрле бәла, фетнәләр сәбәпле, ул күркәм хәлләре түбәнәеп, әкренлек белән Казанга күчә башлый һәм ахырда үзе бөтенләй харап булып, югарыда әйтелгән мактаулы хәленә Казан варис булып калды.

Шәһре Болгар – Җир йөзенең өч яки дүрт кисәгеннән берсе булган Европа өлешендәге Рум иле һәм Истанбулдан кала, иң элек культурасы үскән, Әндәлес мәмләкәтеннән соң, бәлки, шул ук гасырда беренче булып ислам диненә кергән шәһәр.

Хәзерге заманыбызда да Болгар хәрабәләренең калдыгы булган кайбер биналар, аның як-якларында казылган канаулар, урлар һәм каберләр бар. Мәсәлән, олы мәчетенең нигезе, аның почмакларындагы манаралары һәм җирдән чыгарып салынган бер манарасы бар. Манараның кырык өч баскычы бар, һәрбер баскычының биеклеге бер карыш та бер бармак буе. Янә олы мәчетнең алгы ягында биек бер манара булып, мең ике йөз алт-

[1] Хатыйп – өндәүче, вәгазь сөйләүче, оратор.

мышынчы (1844) ел рамазан аеның егерме тугызына кадәр урынында торса да, шул көн сишәмбе кичәсе ярты төн булганда җимерелеп төшүе мәрхүм Фазлулла бине Бохарай исемле кешенең мәҗмугасында беркетелгән. Бу зур манараның биеклеге астролябия һәм башка астрономик кораллар белән үлчәнгән булмаса да, баскычларның саны, мелла Ибраһим әфәнде мәҗмугасында күренүенчә, һәм Габделваһһаб бине Иманколый әр-Рәҗәбинең телдән сөйләвенчә, җитмеш өч баскыч икән. Мәчетенең иңе ундүрт, буе уналты багга[1] туры килә. Манараның калдыгы әле хәзер дә бар, мөселманнардан күп кеше җәй көне шуны зиярәт итәргә баралар. Кечкенә манараның күршесендәге бер-ике каберне Әхтәм, Хәнтәм сәхабә, шулай ук Балымхуҗа кабере дип, манара төбендә «кыз балага» дип, халык зиярәт кыла. Фәкыйрь[2] мең ике йөз җитмеш җиденче (1860–1861) елның зөлхиҗҗә аенда, 87 нче елның рабигыль-ахир аенда барып, манарага менеп, аның азан әйтә торган җиренә бу бәетләрне язды:

Гүяки бу манарада мөәзин булмаган,
Ходаның исемен телгә алмаган,
Гүяки Болгарда мөселманнар тормаган,
Аның җирендә самирләр[3] йөрмәгән.
Әйе, алар үз вакытында булганнар,
Әмма аларны караңгы төн һәм явыз язмыш һәлак иткән,
Хуш һавалы Болгарга сәлам!
Кайгы дулкыннарын күтәрә ул мөсафирлар күңелендә[4].

Гомумән, шул шәһәр каберлекләрендә күмелгән мөселманнарга зиярәт кылды. Кайбер урыннарда, яр буйларында күп үлекләрнең сөякләре ачык яталар. Ходага мәгълүм, сугыш вакытында үлгән кешеләрнең сөякләре булса кирәк.

Болгар хәрабәләренең бер почмагында «Болгар» исемендә бер рус авылы бар. Болгар шәһәренең кайчан һәм нинди

---

[1] Баг – 130 сантиметр чамасы озынлык үлчәве.
[2] Фәкыйрь – Ш. Мәржани үзен шулай йөртә.
[3] Самир – хикәяләр сөйләп йөрүче (халык акыннары).
[4] Шигырь – гарәп телендә, монда тәржемәсе китерелде.

сәбәпләр белән харап булганлыгын һичбер мәҗмугада күргәнебез юк, ләкин югарыда телгә алынган мелла Габделваһһабның телдән сөйләвенә караганда, Россия кулына күчкәннән соң, бу көнге тарихтан өч йөз ел элек икенче меңгә керү алдында су агымы – елга күчүе сәбәпле харап булган, имеш.

Бу Болгар халкының мәмләкәте борын заманнарда көньягыннан Бабел-әбваб[1], ягъни Дәрбәнд, Тифлис һәм Ширван шәһәрләре, Кавказ таулары, Каспий диңгезе буе һәм Дагстан тарафларына, хәтта Әрмәнстан иленә хәтле сузылган иде. Көнбатышта Нократ елгасыннан, Дон, Самара, Сур һәм Ука елгаларының башлары, Көнчыгышта Урал таулары, Харәзем, Сыгнак һәм Шаш, төньякта Россия белән чикләнә иде. Болгар мәмләкәтендә булган һәрбер нәсел кабилә бер урынга, яки бер суга нисбәт бирелеп, төрле исемнәр белән исемләнеп йөртелгәннәр; мәсәлән, «Чирмешән болгарлары», «Нократ болгарлары», «Бәхре хәзәр[2] болгарлары», «Түбәнге болгарлар», «Тимтүче болгарлар» дип аталып йөртелгән. Күп төркем кабилә, нәсел һәм сыйныфлар булып, кабилә, ыру патшалары формасында һәркайсының әллә никадәр хакимнәре булса да, алар тагын олы бер патшага таянып һәм буйсынып, күп исемнәрне эченә алган Сәкалибә, Кыпчак, Хәзәр, Болгар, Җуҗи улусы, Үзбәк иле исемнәре белән, мәмләкәтләре исә төрле вакытта Сәкалибә иле, Дәште Кыпчак, Хәзәр һәм Болгар иле, Татар иле, Җуҗи улусы, Бату урдасы, Бәриятел-Бәркә[3] вә Үзбәк иле исемнәре белән аталып йөргәннәр. Бу мәмләкәттә булган шәһәрләр – Олы шәһәр, ягъни Шәһре Болгар, Нократ Болгары, Сувар, Сунгар[4], Биләр, Ашлы, Хизан, Туфҗын, Собәкүл, Кашан, Чылматы, Ибраһим кальга, Кызлар, Исбел, Кирмәнчек, Басыф мирза, Керчь, Жуко-

---

[1] Бабел-әбваб – ишекләрнең ишеге. Гарәпләр Каспий диңгезе белән Кавказ таулары арасындагы тар юлны шулай дип атаганнар.

[2] Бәхре хәзер – Каспий диңгезе.

[3] Бәриятел-Бәркә – Бәркә сахрасы. Бату ханнан соң гарәп әдәбиятында Алтын Урда, Бәркә хан исеменә нисбәт бирелеп, шулай «Бәриятел-Бәркә» дип йөртелгән.

[4] Яки: Сонфар.

тин, Аклан, Саксын, Фису, Гамик, Шабран, Зингәран, Сәмандар, Хәмлич, Бәләнҗәр һәм Бәйза шәһәрләре. Әүвәлдә кыпчак вә Хәзәр ханнары хөкүмәтендә булып, моннан соң Болгар әмирләре хөкүмәтендә, аннан соң инде Татар ханнары хөкүмәте карамагында булып, хәзерге вакытта өч йөз елдан артык инде Россия хөкүмәте идарәсендә. Сәүдәләре: кол, кәнизәкләр, бал, кеш, сусар, тиен, төлке, куян, карсак[1], куян тиреләре, Болгар күне һәм сәхтияннәр, балык җилеме, балык мае, мамонт теше, шәм, кәҗә тиресе, саури, чикләвек, куй, сыер, сугыш киеме, кылыч, ук, каен агачы, бүрек, кәләпүш, гәрәбә һәм башка шуның шикелле нәрсәләр белән булган.

Болгар халкының нәсел-нәсәпләре турында

Тарихны өйрәнгән мөселман галимнәренең ачык итеп билгеләүләренә һәм башка шуны күрсәтүче хәлләргә, сүзләргә караганда, болгар халкы – төрек кабиләләреннән. Ибне Фазлан да аларны төрек дип әйтә. Шулай ук Ибне Халдун, Шәриф Идрисигә иярен, аларны төрекләрнең бер тармагы саный. Тарих галимнәренең иң олыларыннан Гали бине әл-Хөсәен әл-Мәсгуди әл-Багдади: «Алар төрекләрнең бер төркеме, алардан һәм аларга кәрваннар һаман йөреп тора; әмма алар бүтән төрек кабиләләреннән өстенрәк», – ди. Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Әндәлес иясе аларны, ягъни хәзәр һәм болгарларны төрек халыклары арасында санады», – ди. Ә икенче бер урында берәү алардан: «Сез нинди халык? Болгарлар кемнәр алар?» – дип сорагач, «Төрек белән сәкалибәдән туган халык», – дип җавап бирделәр», – ди. «Рисаләтел-интисаб» исемле китапта: «Болгар җире – мөселман төрекләр иле. Алар Габбасилар хөкем сөргән заманда Мәәмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытында мөселман булдылар; икенче мәртәбә әл-Каиме би Әмириллаһ хәлифәлегендә утыз мең гаилә мөселман булды», – диелә.

Хәким Синаи аларны түбәндәге шигырендә төрек дип атый.

---

[1] Карсак – төлкенең бер төре.

Шигырь:

«Минем бөтен күргән җәфаларым болгарлардан, әмма монда аларның гаепләре юк, чөнки мин хәсрәт чигәргә тиеш булганмын, я Ходай, бу бәла-фетнәләрнең барысы да синнән, ләкин моңа беркем дә каршы тора алмый, һәркем төрекләрне болгарлардан саный. Кешенең белем белән яктыруына тоткарлык беткәнгә күрә, ул гүзәлләрнең теш кырыйлары ай кебек ялтырап, мондый матур итеп ярату кирәкмәс иде. Аларның теш читләренә гыйшык тотудан барысы да иреннәрен тешләргә мәҗбүрләр»[1].

Мәүләви Габдерахман әл-Җами (аңа изгелек булсын) «Нәфәхател-әнәс» исемле әсәрендә бу бәетләрне Гайнел-Казат әл-Һәмәдани тәрҗемәсендә китергәнлектән, «Нәфәхат»кә язган аңлатмасында Мәүләви Габдел-Гафур бине Гали әл-Лари: «Болгар – Төркестан[2] шәһәре. Анда гүзәлләр бик күп», – ди.

Шул ук мәгънәдә гарәпчә бер шигырь дә күргән идек. Истә калганы болай:

«Әгәр күңелдә Болгар гүзәлләренең мәхәббәте булмаса иде, ике күздән аккан яшьтән чокыр хасил булмас иде».

Аларның телләре, калдырган әсәрләре, гореф-гадәтләре дә төрки. Телләре турында Истахри, Ибне Хәүкаль һәм Гарнатый: «Болгар теле хәзәр теле кебек», – диләр. Хәзәр теле, – әлбәттә, төрки теле. Мәмләкәт һәм шәһәрләрнең исеме, «Болгар» төрки шивәсендә «Болгамак» сүзеннән алынган киләчәк заман фигыль, ә «болгады» – үткән заман фигыль. «Эшне болгады», «Суны болгады» диләр. Бу урында исемләштерелеп, «катыш» мәгънәсендә алынган. Шәһре Болгарда сугылган кайбер тәңкәләрдә «у» хәрефе белән «Булгар» дип язылган булуы моны артыгы белән куәтли. Димәшкый язуында да шул мәгънәгә ишарә бар.

Моннан башка тагын патшаларына «хан», «белеквар» дигән исем бирүләре дә төрки булганлыкларын күрсәтә, чөнки «хан», асылда, төрки сүзе булып, «к» хәрефе белән «кан» дип языла.

---

[1] Шигырь фарсы телендә. Тәрҗемәдә эчтәлеге бирелде.

[2] Төркестан – хәзерге мәгънәсендә түгел, бәлки «төрек иле», «төрки халыклар иле» дигән сүз булырга тиеш.

«Белеквар» сүзенең «к» хәрефе белән булуы ачык. «Белек» сүзе – «белмәк» фигыленнән – исем, «гыйлем» һәм «гакыл» мәгънәсендә. «Вар» сүзе икенче диалектта «бар» рәвешендә «б» хәрефе белән языла, төрләнми торган фигыль. Димәк, «белек вар» – ике сүздән кушылып ясалган, ягъни «галим», «акыллы» дигән мактау сыйфаты, мактау исеме. Шуңа күрә Ибне Фазлан (аңа Ходаның рәхмәте булсын) Ходаны олылау урынына әйтелә торган «Мәлик» исеме белән атауның мөнасиб булмаганлыгын бәян иткәч, «белеквар» сүзен дә бу урында әйтү мөнасип түгел дип, аны искә алуны ташлаган булыр. Чөнки Ибне Фазланның бу аңлатмасыннан соң укылган хөтбәләрдә «белеквар» сүзе телгә алынмаган, бары тик «әл-Әмир Җәгъфәр бине Габдулла» дип кенә телгә алынып үтелә торган булган.

Болгар патшаларына болай «Белеквар» исеме бирү кечек Әрмәнстанның Сивас шәһәрендә Төрекмен патшаларыннан әмир Әхмәд бине Гали бине Мизраб әт-Төрекмәни һәм үзеннән соң аның балаларына, өй әһелләреннән булган әмирләргә «Данешмәнд» исеме биреп, аларны «Данешмәнд патшалар» дип атап йөртү шикелле генә була. «Данешмәнд» нәкъ «белеквар» дигән мәгънәдә. Бәлки, бу төрекмән ханнары, асылда, шул як халкыннан булып, бу исемне Болгар иленнән калька рәвешендә күчереп алган булулары ихтимал.

Бу рәвешле, «белке» сүзендәге «е» – кушымчасын төшереп калдырып, өтер белән әйтеп чикләү хәзерге телебездә дә бар: «китаб бар», «әүлад бар», «акыл бар», «хатын бар» дибез. Дөрес, язуда һәм төрки телендәге кайбер диалектларда әлеге «е-ы» кушымчасын саклап, «китабы вар», «әүлады вар», «акылы вар», «хатыны вар» формасында кулланыла.

Күфә язуында «к» хәрефе «тъ» хәрефенә бик охшаган булганлыктан, Ибне Фазлан сүзеннән алып кайбер нөсхәләрдә «тъ» хәрефе белән телгә алынса да, нөсхәне язучының ялгыш охшатуыннан гына булырга кирәк. Ибне Фазлан вакытында Багдадта вә башка мөселман шәһәрләрендә күфә язуы кулланыла иде. Әбү Гали бине Мокыйлә нәсех язуын уйлап тапканчы гамәлдә булды.

Ибне Фазлан: «Болгарда балдан ясалган эчемлекләре бар, аны сөҗү» дип әйтәләр, – ди. Ягъни сөчү – ләззәтле, тәмле мәгънәсендә, татарлар лөгатенчә хәзерге заманыбызда кулланыла торган «кәречмә» дип йөртелә торган мәшһүр эчемлек шул була инде.

Байтак кына китапларда ошбу мәмләкәттә «судык», «сарук» яки «сардык» формалары белән әйтелә торган сүзләр бар. Моның дөресе «сардык» булып, «сарыдаг» һәм «сарытау» мәгънәсендә хәзер мәмләкәт мөселманнары Сарытау дип йөртә торган шәһәр һәм аның өлкәсе була.

Мең ике йөз туксан (1873–1874) елда вафат булган мелла Сәлим бине Дуст әл-Кавали нөсхәсендә: «Белгел, и аңлы кеше, кояш елының өч төрле хисабы бар. Беренә «Фарсия хисабы» диләр. Аны Болгар халкы кулланган. Беренә «Румия хисабы» диләр, аны христианнар куллана һәм беренә «Хәмәл хисабы» диләр, барлык шәһәрдәге мөэмин-мөселман шул хисапны куллана. Бәс шулай булгач, барлык мөселманнарга «Хәмәл хисабын» белү лязим була, чөнки намаз вакытлары, төш вакыты һәм кояш баю вакытлары шуның белән беленә. Янә мәгълүм булсын ки, әүвел фарсия нәүрузы, аннан ун көннән соң румия нәүрузы, аннан ун көннән соң хәмәл нәүрузы була. Шуның өчен шәһре Болгар галимнәре, «бала нәүруз», «карт нәүруз» һәм «шешек нәүруз» дип ишарә кылдылар, һәрбер нәүруз бәрде гажуз[1] хисабы була дип исәпләделәр», – дип яза.

Габбасия хәлифәлеге гасырыннан калган кайбер сүзләр хәзер дә халык телендә, хәтта бик эчтәге авылларда яшәүчеләр телендә дә йөриләр, мәсәлән:

«Һай, мин фәлән эшне эшләгән булсам, хәлфә буласы икәнмен «яки» хәлфә булган булыр идем» (монда хәлфә «хәлифә» дигән сүз), тагын «фәлән кешене хәлфә иткәннәр», ягъни иң югары дәрәҗәгә ирештергәннәр, «фәләнне бик зурлап кадерхөрмәт иткәннәр» дигән шикелле сүзләр кулланалар. Бу сүзләр,

---

[1] Март аеның ахырларында була торган салкыннар. Аны «бәрде гажуз» – «карт-карчыклар суыгы» дип йөртәләр.

әлбәттә, хәлифәләр гасырыннан калган, чөнки болар – ул сүзләр нинди мәгънәне аңлаталар, хәлфә нәрсә, моның кайдан, кайсы лөгатьтән алынганын белмиләр һәм уйламыйлар да. Хәлифәлекләр бетерелеп, аларның матур исемнәре дә онытылганнан соң, бу сүзләрне алмаган булырлар. Бу гасырда хәлифәлекнең дөньяда иң югары дәрәҗә һәм бер генә кешегә хас, аннан өстен һичкемнең булмавы, «хәлифә» һәм «әмирел-мөэминин» дигән исемнәрнең «әмирләрнең әмире», «әмирел-мөслимин», хәтта «баш әмир»дән дә югарырак икәнен күп заманнан бирле белүче бигрәк тә безнең мәмләкәтебездә бик аз. Хәлифәлек дәрәҗәсенең башка солтаннар, зур патшалар дәрәҗәсеннән өстен икәнен, һәркемнең аңар буйсынуы лязим икәнен белмиләр, «әмирел-мөэминин» белән «әмир»не аермыйлар. Шулай булгач, гади халык, бигрәк тә хатын-кызлар аны ничек аңласын?!

Дунай буена күчеп киткән болгарилар, хәзәр һәм болгар телләрендә сөйләшсәләр дә, исемнәрендә төрки сүзләр күп диләр. Мостафа бине Шәмсетдин үзенең «Әхтәри» дип йөртелә торган сүзлегендә «хәфҗаг» сүзен: «татар биге, асылы – кыпчак» дип аңлатуы «Болгар әмире» дигән сүз булып, аларның кыпчак кабиләсеннән булуларын күрсәтә. Кыпчак, әлбәттә, төрек кабиләләреннән, ләкин бу мәмләкәт халкы үз гасырында татар исемендә булганлыктан, борынгы халкын да «татар» дип тәгъбир кылган буладыр. Менә болар һәммәсе дә Болгар халкының барысы да төрки икәнлегенә дәлил булалар.

Әсәрләреннән, мәсәлән, «Нәһҗел-фәрадис», «Башлагали», «Йосыф китабы», «Нәсыйхәтес-салихин», «Бәдәвам» китаплары кеби төрки китаплар, «Нәүруз» бәетләре, «Шәһре Болгар газилары» бәетләре бар. Кайберләре күбесенчә бик иске язу белән, бер карашта өч-дүрт йөз ел элек язылган диярга мөмкин, һәм язулары Болгар шәһәрендә табылган кабер ташларындагы язуларга бик охшаганнар. Бу китаплар бу мәмләкәттә басма вә язмалары күп табыла, ләкин башка мәмләкәтләрдә бер дә күрелгәне юк, һәм бу китапларның теле госманлы (Төркия төрекләре), чыгтай, төрекмән һәм казах телләренә башка төрле тел.

«Нәһҗел-фәрадис»нең башында, бисмиллаһдан соң, Ходага мактау, пәйгамбәргә сәлам әйткәч, болай диелә: «Габдулла Гомәр углы пәйгамбәрдән риваять кылып әйтә ки, бер мөэмин-мөселман минем хәдисләремнән[1] кырык хәдисне ишетмәгән кешеләргә җиткерсә, белмәгәннәргә өйрәтсә, Хода ул кешене галимнәр дәрәҗәсенә язар, Кыямәт көнендә шәһитләр җөмләсеннән кубарыр. Әгәр дә кеше мин әйтмәгән сүзне, белә торып, пәйгамбәр әйтте дип ялганласа, тәмугда утырырга үзенә урын хәзерләгән булыр...

Бу китапка «Нәһҗел-фәрадис» дип исем куелды, оҗмахларның ачык юлы дигән мәгънәдә була. Өмет тә шул». Ахырында: «Яздыгы ... икенче көнендә елга йите йөз иллик тукызда Сарай шәһәрендә ирде... кылгучы ел-галим әр-рәббани вә әл-гамилес-самәдани әл-остазел-мотлак Мәхмүд бине Гали бине ... әс-Сараи мәншәән вә әл-Болгари – мөвәлләден вә әл-Кәрдәри», – дип язган. Гыйбарәтләре бу ачыкларда улан кәлимәләр нөсхәдә мәхү улдыгыннан тәхтел-хәфадер[2]. Беренче бабы пәйгамбәр галәйһиссәламнең сыйфатлары турында, икенче бабы хәлифәләр, аларның якыннары һәм дүрт имамның[3] сыйфатлары турында.

Бу тел аларга Җужи һәм Бату урдасыннан кермәгән булса кирәк, чөнки бу аларның телләренә башка һәм алар кул астында мөселманнар бик аз һәм бик көчсез иделәр.

Бәркә хан алты йөз кырыгынчы (1242–1243) елларда исламга кергән булса да, аның халкы арасында ислам дине

---

[1] Хәдис – Мөхәммәд пәйгамбәр сүзе.

[2] Текстны Мәрҗанинең үзенчә китердек. Мәгънәсе болай: китапның ахырында: «... икенче көнендә җиде йөз илле тугызынчы (1357–1358) елда Сарай шәһәрендә язылды. Язучысы галим һәм гыйльме белән гамәл итүче, бөтен кешеләрнең остазы Мәхмүд бин Гали бин ... Сарайда иҗат итте, тууы буенча Болгари ... Кәрдәри» – дип язылган. Кайбер сүзләре нөсхәдә югалган. Алары ачык калдырылды. Нинди сүзләр икәне яшерен калды.

Без андый «ачык» калган урыннарына өч нокта куйдык. «Гали бин» һәм «Әл-Кәрдәри» сүзләре алдыннан ачык калган урыннар булмаса да, өч нокталар куйдык. Чөнки ул урыннарда да сүзләр төшеп калган.

[3] Дүрт имам – ислам динендә дүрт юнәлеш – имам Әгъзам, имам Шафигый, имам Малик, имам Әхмәд бине Хәнбәл.

ныгып урнашканы юк иде. Күбрәге мөселман хан гасырында мөселман булып, мөселман түгел хан булса, аңар ияреп, аныңча булып яшиләр иде. Татар кабиләсендә ислам дине Үзбәк хан һәм аның углы Җанибәк хан заманында куәт тапты һәм ныгып урнашты. Шуңа күрә нугайларда «дин Үзбәктән калды» дигән сүз бар, имеш. Аз заманда алар шул мәмләкәттә яшәүче төрле кабиләләргә үз телләрен кертә алмаслар. Бәс, шулай булгач, бу лөгать Болгар халкының үз теле булырга тиеш.

Спас өязендә Шәһре Болгардан алтмыш чакрым җирдә Иске Рәҗәп исемле авылда «Ташбилге» дип йөртелә торган иске бер зират бар. Моның күбрәк өлешенә йорт-җир, ындырлар салынып, аз гына җире зират булып калган һәм хәзер аны канау белән әйләндереп алганнар икән. Анда бары тик өч таш калган, башкалары ватылып-бозылып беткәннәр. Хәрефләр җыючы[1] бу фәкыйрь[2] мең ике йөз сиксән тугызынчы (1872–1273) ел, рабигыль-ахир аеның җидесендә чәршәмбе көн бу ташларны тикшереп укыдым. Берсе нәсех язуы белән бик оста кеше тарафыннан шәп итеп язылган. Башында ярым түгәрәк рәвештә «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт» дип язылган. Шуннан соң биш юл итеп, беренче юлда – «Әнбал углы Хөсәен», икенче юлында – «зиярәти торыр, Рәхмәтуллаһи», өченче юлда – «Галәйһи рәхмәтән васигатән», дүртенче юлда – «тарих җиде йөз кырык бишенчедә», бишенче юлда «рәҗәп аеның өченче көне ирде» дип язылган.

Икенче таш күфи язуы белән аермачык, ярым түгәрәк рәвештә, «Әлхөкме лилләһил-галиил-кәбир» дип, аннан соң дүрт юл итеп; беренче юлда – «Әҗнәб углы», икенче юлда – «Әхмәд Бәләви», өченче юлда – «рәхмәтуллаһи галәйһи», дүртенче юлда «рәхмәтән васигатән» дип язылган. Шуның белән язуы тәмам булды. Башка җирләрендә бер сүз дә язылмаган, таш үзе сынмаган, ватылмаган, кителмәгән.

Өченче таш. Бусы да күфи язуы белән бик яхшы итеп, аермачык язылган, ләкин ташның түбәнге өлеше сынып югалган,

---

[1] Хәрефләр җыючы – бу әсәрне язучы дигән сүз.

[2] Фәкыйрь – үз-үзен кечерәйтеп әйтү урынында кулланыла. Мәржани үзен шулай дип атый.

калганы дүрт юлда болай дип язылган, беренче юлда – «Әл-хөкме лиллаһил-галиил», икенче юлда – «әл-кәбир Әхмад улы», өченче юлда – «Җәгъфәр улы хаҗи Юныс», дүртенче юлда «билкиви вафат». Ләкин ул «Әхмад»не шулай әлиф (а) белән хата язган. Дәхи «тарих» дип әйтә башлаган сүзе чама белән укылды. Бу ике таш бик каты һәм сүзләре дә әүвәлге таштагы сүзләргә башка. Әүвәлге таш йомшаграк. Чама белән әйткәндә, бу ике таш ияләре беренче таш иясеннән күп алдан булган булуларын күрсәтә. «Юныс» дигән исемдә бераз шөбһә бар. Һәр ике ташта – «Бәләви, Билкивы» дигән сүзләр соңында S рәвешендә бер хәреф бар. Күфи язуының «к» хәрефенә охшаган. Болай булганда хәзерге телебездә юнәлеш килешен белдерүче кушымча «кә/ка»[1] була: «(фәлән кешегә) укытырбыз яки укытырлар» мәгънәсендә. Яки бу хәреф чыгтай теле лөгатенчә өтерле «д» булып, безнең хәзерге телебездәге «дер» кисәкчәсе булып, «билкивидер», «билливидер», ягъни «бик зур белгеч» мәгънәсендә килергә мөмкин[2].

Бу мәмләкәтне «Дәште Кыпчак» дип, аның халкын да «кыпчак» дип йөртү борынгыда таралган һәм шулай ук киләчәктә бәян ителгәннәрдән күрелгәнчә, бу мәмләкәт «Хәзәр иле» дип аталган, аның халкына «хәзәр» исеме бирелгән. Бу кыпчак һәм хәзәрләр хәзерге халык булмаганда, андый куәтле һәм күп сандагы батыр халыкның кая китеп югалуы мөмкин? Казахстанда, Мавәраэннәһердә һәм Кырым мәмләкәтләрендә хәзердә дә «кыпчак» исемле кабиләләр бар. Кыпчак вә хәзәрнең исә төрки булуларында һич шик-шөбһә юк. Әмма Ибне Фазлан язган гадәтләр: ашаганнары күбрәк ит, эчкәннәре балдан ясалып «сөҗү» дип йөртелә торган эчемлек булу, болгарлар һәм хәзәрләрнең озын кафтан, ә русларның кыска кафтан киюләре, мунчага һәм суга

---

[1] Ш. Мәрҗанидә бу мисал гарәпчә «Ләногаллиме әү ләйөгаллимү фәлалән» формасында китерелгән, һәм «хәзерге лисаныбызда мәфгулен биһ мәгънәсендә «к» фарсы мәмдүдә, ягъни «кя» ула диелгән. Шуңа күрә без дә «юнәлеш килеше» дип бирдек. Юкса югарыдагы гарәпчә җөмлә татар теленә «фәлән кешене укытырбыз...» дип әйтелергә тиеш иде.

[2] Хәзерге телебездә һәм «белки» дибез. *Ш. Мәрҗани аңлатмасы.*

пәрдәсез керүләре – барысы да төрек гадәте булып, бу хәлләр хәзерге татарларыбызда да шулай ук сакланып калган.

Ибне Фазлан: «Ислам хәлифәлеге мәркәзе вәкиле Сәһсәнәр-Расибине мәҗлесендәге башка әмирләргә тәкъдим итеп, сул ягына утыртты. Аштан, башлап, үзе авыз итеп, аннары Сәһсәнәр-Расибигә бирде, шуннан соң башкаларга һәм биреп, барыбыз да аерым табыннарда ашап, калганын өйләребезгә алып кайтып киттек», – дип яза. Болар бары да төрек гадәтеннән булып, казах халкының «асатуы» (согындыруы) шикелле, хәзерге заманыбызга кадәр калып килгән гадәтләр бар. Шулай ук үз күзебез белән күргән хәлләрдән, мәсәлән, Казан арты «Алат юлы» ягында һәрбер йортта пешкән итне табак белән шул йортның олысы алдына китереп куялар. Йорт башы кеше итне үзе турап, ара-тирә берәр калҗасын үзе капкалап, турап бетергәч, ашарга өй җәмәгатен чакыра торган булган. Шунда бер ахмагы, бу эшкә кызыгып: «Әти үлсә, итне мин турар идем», – дип ычкындырган. Татарлар арасында таралган «Итне таба алсаң – турарсың» дигән мәшһүр сүз әнә шундый уйламый сөйләгән ахмакларга җавап урынында йөртелә.

Ибне Фазланның сүзеннән аңлашылуына караганда, ул Болгар патшасы белән сөйләшкәндә турыдан-туры, башкортлар белән исә тәрҗемәче аркылы сөйләшкән. Ибне Фазлан Багдадтагы төрки гаскәрләр һәм башка төрек төркемнәре белән аралашканлыктан, төрек телен белеп, Болгар әмире белән төркичә сөйләшеп, башкорт теленең башка төрек телләреннән аермасы күп булуы сәбәпле, тәрҗеман аркылы сөйләшергә мәҗбүр булган булса гаҗәп түгел.

Хәзер дә Шәһре Болгар һәм Казан якларындагы мөселманнар телләрендә «къ», «к» һәм «р» хәрефләре бик күп очрый. Бигрәк тә төсне белдергән сүзләрдә көчәйткеч кисәкчә булып та килә. Асыл үз сүзләрендә каты һәм йомшак әйтелешле «х» бик аз, бәлки бер дә юк. Хәтта гарәп, фарсы һәм башка телләрдән кергән сүзләрдәге хәрефләрне дә гавам халкы «къ», «р»га алмаштырып, мәсәлән, «Әхмәд, Хәсәншәех, Касыймшәех, Әбү әл-Хәер, Хәерби, Бәхтияр, Сәрхыбад» дигән сүзләрне «Әкъмәт,

Кәсәншикъ, Касыймшикъ, Болгаер, Каерби, Бакътияр һәм Сәркыват» дип әйтәләр. Болар бары да төрки гадәте һәм борыннан калган тел үзенчәлеге. Гомумән, Шәһре Болгар һәм аның өлкәләре халкының теле төрки теле булуында һич шик-шөбһә калмый.

Әмма гарәп галимнәренең аларны сәкалибә дип атауларыннан, Ибне Фазлан рисаләсендә: «Гадәтләре буенча патша алдына кергән һәркем бүрекләрен салып, култык асларына кыстыралар, башларын ияләр, патша базарга чыкса, һәркем башыннан бүреген алып, култык астына кыстырып, үтеп китми торып башларына кимиләр», – дип язылуыннан, аларда борыннан ук мунча булуыннан, кайберәүләр «сәкалиб» сүзен «славян» дип, югарыда күрсәтелгән гадәтләрне славян гадәте һәм Болгар халкын «славян» дип уйласалар да, аларның китергән сәбәпләре бу дәгъваларына дәлил була алмый. Чөнки бу гадәтләрнең һәм мунчаның славянга хас булуына бер дәлил дә юк, бәлки, киресенчә, аларга хас булмавына дәлил була. Гарәп галимнәре сәкалибне ике төрле мәгънәдә йөртәләр. Бердән, төреккә, башкортка, әфрәнҗгә һәм славян кабиләсеннән саналган руска башка булган бер халык бу исем белән атала. Мәсәлән, «Руслар – бер халык, аларның илләре сәкалибә һәм төрек илләре белән чиктәш». «Аларның үз телләре бар. Сәкалибә белән сугышалар, Болгар һәм Хәзәргә сату өчен аларны әсир итеп алалар, алардан әсирләр сатып алалар. Әмма аның[1] җаһилият заманындагы шәһәрләрендә төрле җенестән халыклар бар, шулардан сәкалибә һәм рус[2], болар шәһәрнең бер як читендә яшиләр. Сәкалибә, рус һәм бүтән мәҗүсиләр өчен бер казый бар. Алар җаһилият заманындагыча хөкем ителәләр, ул – акылга[3] таянган хөкем. Без телгә алган сәкалибә – мәҗүсиләр, патшаның гаскәрләре һәм коллары. Алар-

[1] Аның – «руснын» мәгънәсендә булырга тиеш.

[2] М.И. Артамоновның «История хазар» (Ленинград, 1962 ел) исемле әсәреннән күренүенчә, гарәп сәйяхларының һәм шулар эзе белән баручы Ш. Мәрҗанинең «рус» дип атаган халкын хәзерге рус халкының бабалары дип карау дөрес булып бетми. Бу исем астында күп кенә очракта Скандинавия ярым атавыннан килгән норманнар (шведлар) аңланырга да мөмкин.

[3] Акылга – «шәригатькә түгел» мәгънәсендә.

ның киемнәре – кыска кафтан, әмма хәзәр һәм болгарларның киемнәре озын кафтан», – ди. Болай булганда, сәкалибә чуваш, чирмеш, ар кебек фин халыклары була. Икенче бер йөртелештә бу сүз, гомумән, шушы илдәге халыкны эченә ала. Мәсәлән, «Бу әкълимдә, ягъни Болгарда, төрек, хәзәр, әфрәнҗ, әрмән, башкорт һәм шулар кебекләр яшиләр, алар «шокыр» дип исемләнәләр», – ди. «Шокыр» – «әшкар» сүзенең күплеге, «кызгылт-ак йөзле» мәгънәсендә. «Сикълаб» та шул мәгънәдә йөртелгән. Бу тәкъдирдә гарәп галимнәре бу мәмләкәт кешеләренең күзгә иң бәрелеп тора торган сыйфатларына карап, бу исем белән атаган булыр. Камуста да «сикълаб» сүзен «әквәл»[1], «әбъяз»[2], «әхмәр»[3], «әш-шәдиде минәр-рәәси вә минәл-җәмал»[4] ди. Әбү Габид әл-Бәкри: «Сәкалибә – бик сугышчан, өлгер халык. Әгәр аларның үз араларында аерылышу һәм дошманлык булмаса иде, бер халык та аларга каршы тора алмас иде» ди. Бу сыйфат, – әлбәттә, төрек һәм хәзәр сыйфаты.

Әмма олылау йөзеннән баштан бүрек салу һәм баш ию гадәтләре славян халкына хас гадәтләр булуына бер дәлил дә юк, бәлки, киресенчә, бу гадәт фин һәм төрекләрдә булган булса кирәк. «Сәбгы сәйяр»да: «Бер кеше хан алдында булганда, магул гадәтенчә, башыннан калпагын чыгарып...» – дигән сүздән бу гадәтнең борында төрек халкында да булганлыгы аңлашыла, ләкин алардан бу гадәтне ислам бетергән булыр.

Мавәраэннәһер халкында олылау, хөрмәт күрсәтү вакытында шәригать буенча харам булган, тыелган иелү гадәте бик таралган булганлыктан, Бохара патшасы узып киткәндә алдан кычкырып баручы: «Иелми генә сәлам бир» – дип, халыкны кисәтеп барганын үзебез күргән идек.

«Славян халкы мунчаны үзләре финнардан алдылар» дигән сүз дә исбат ителгән. Шулай ук хәзәрне лөгать китабында хәзәр халкы кечкенә һәм кысык күзле халык дип бәян итә. Бу сыйфат

---

[1] Әквәл – күп ашаучы.

[2] Әбъяз – ак.

[3] Әхмәр – кызыл.

[4] Әш-шәдиде минәр-рәәси вә минәл-җәмал – каты чәчле һәм күркәм.

бу мәмләкәт халкының барында да шундый ук хәлдә, чөнки шигырьдә дә: «Төрекләрдән кирәгеңне сорама: аларның күзләре кысык күз» дип әйтелә.

Ибне Дасә[1] «Хәзәр – күл артындагы киң бер ил, аның шәһәрләре Болгар, Сәмәндәр һәм Суар дип аталалар. Моннан башка, Бәләнҗәр, Хәмлиҗ һәм Бәйза шәһәрләре дә Хәзәр шәһәреннән саналалар», – ди. «Камус»та: «Бәләнҗәр[2]/газәнфәр» үлчәвендә әйтелә) – Хәзәр шәһәрләреннән, «Бабел-әбваб»[3] ның артында», Хәмлиҗ һәм Бәйза – Бабел-әбвабның артында», диелгән.

Габбаси хәлифәләрдән Могтамид Галәллаһ хәлифә булып торган чакта гаскәр башлыкларыннан әмир Исхак бине Киндаҗык әл-Хәзәри дә хәзәрләрдән иде. Әбү Гыйбадәт әл-Вәлид бине Габид әл-Бәхтәри бу шигырьләрне иҗат итте:

Әгәр Киндаҗык углы Исхак берәр нәрсәгә ук атса,
Бөтен ау аның эчендә (кулында) булыр;
Таҗ кияргә теләүчеләргә таҗны я милек итеп бирер,
яки кияргә кушар.
Бәйзада[4] яки Бәләнҗәрдә вәгъдәләшкәннәрнең дәрәҗәләре
Гыйракта тагын да күтәрелер[5].

Кайберәүләрнең әйтүенә караганда: «Хәмлиҗдә һәм Бәләнҗәрдә», – ди.

Әбү Исхак әл-Истахри: «Хәзәр теленә бүтән телләр катнашмаган», – ди дә, үзе үк: «Болгар теле хәзәр теле кебек»,

---

[1] Бу Сәйяхның дөрес исеме – ибне Рөстә. Ш. Мәрҗани аны ибне Дасә яки ибне Дастә дип йөртә.

[2] «Бәләнҗәр»не Якут әл-Хәмәви h.б. «н» һәм «җ» белән язган булсалар да, «Болгар»ның үзе түгелме? Гарәпләштереп яки үзгәртеп, «Болгар»ны «Былхәр» яки «Бәләнҗәр» дип гарәпләрнең атавы гаҗәп түгел. «Уратәбә», «Нәхшәби», «Ташкәнд»не гарәпләштереп, «Струшнә», «Нәсәф», «Шаш» дип язган кебек. *Ш. Мәрҗани аңлатмасы.* Ләкин соңгы чор галимнәре «Бәләнҗәр»нең башка шәһәр булганын раслыйлар.

[3] «Бабел-әбваб» – Дәрбәнд шәһәре. Гарәпләргә көнчыгыш Европага үтеп керү юлы булганга, аны шулай, «Ишекләр ишеге» дип атаганнар. «Дәрбәнд» сүзе фарсы телендә «тау арасындагы юл» мәгънәсен дә аңлата.

[4] Бәйза – Иранда булган шәһәр. Урта гасырда зур гыйлем мәркәзе булып, соңыннан харап ителгән.

[5] Шигырьләр тәрҗемә итеп алындылар.

«Аларның үз телләрендә патшалары «белек» һәм «бакь» дип атала», – ди.

Әбү Габдулла әл-Гарнатый да: «Телләре бер үк», – ди.

Габбасия хәлифәләре дәүләтендә Хәзәрдән һәм башка кавемнәрдән бик күп ир һәм кыз коллар булып, аларга әдәп-әхлак, тарих, шигырь, география, математика, алгебра, шәрык телләре һәм башка фәннәрдән белем биреп, Коръәнне яттан өйрәтеп, кадерләрен күтәреп, зур бәяләр белән сата торган булганнар. Күп җарияләр хәлифәләр һәм башка олы дәрәҗәле кешеләр түшәгендә, аларның балаларының аналары булып китәләр иде. Шул тәртиптә җитешкән егетләрнең күпләре китаплар иҗат итеп, дәүләт хезмәтендә зур эшләр башкарып, зур хезмәт урыннарына ирешәләр иде. Хәтта Мәһди хәлифәнең җариясе, Һарун әр-Рәшид һәм Һади хәлифәләрнең аналары булган Хизран[1] асылда бу мәмләкәттән килгәнгә күрә, шул исем белән аталган булуы ерак бер ихтимал түгел; Камуста да ул «хәзәр» сүзен аңлатканда искә алына. Шулай ук Моктәдир биллаһ хәлифәнең Болгарга Сәһсән әр-Расибине илче итеп җибәрүе дә нәсел-нәсәп берлегенә нигезләнгән булуы гаҗәп түгел. «Сәһсән» сүзе гарәпчә түгел, төрек лөгатенә охшаган. Бу Сәһсән әр-Расиби әмир Әбү әл-Хөсәен Гали бине Әхмәд әр-Расибинең кул астындагы кеше булса кирәк. Бу әмир өч йөз дә беренче (923) елның урталарына якын вакытта «Дәүре Расиби» дигән урында вафат булды, һәм бик күп малы, олы һәм кече яшьле кол егетләре, өлкән коллары җөмләсеннән эш башында торучылар калды. Варислары фәкать бер кызы һәм бер ир туганы иде. Мирас малны бүлгәндә, туганы белән кияве Әбү Гаднан арасында җәнҗәл чыгып, олы һәм кече хезмәтчеләр икегә бүленеп сугыштылар, ике яктан да үлүчеләр булды. Әмир Хамит бине әл-Габбас, хәлне аңлатып һәм Әбү Гаднанның Багдадтагы Әбү Сахрат исемле берәүгә хөкүмәт алдында эшне төзәтү өчен дип,

---

[1] Укыянуста Гасыйм әфәнденең Хизранны Һарун әр-Рәшид җариясе диюе һәм шул турыда аңа нисбәт биреп шигырь китерү ялгыш һәм «Камус» авторының аны «Хәлифә җариясе» дип кенә әйтеп үтүе кимчелекле. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

егерме мең алтын акча белән җибәргән хатын кулга төшереп, Багдадка җибәрде. Моктәдир биллаһ хәлифә, бу хәбәрне алу белән, атлы һәм җәяүле гаскәрдән бер төркем җибәреп, әлеге мирас малны саклата һәм бер килештерүчене җибәреп, җәнҗаллашучыларны килештерә. Бу вакыйганың тәфсиле «Мөгъҗәмелбөлдан» китабында һ.б. урыннарда сөйләнгән.

Шулай итеп, гарәпләрнең Болгар һәм башка Хәзәр шәһәрләре халкына сәкалиб һәм хәзәр исемнәрен бирүләре аларда өстенлек алып торган сыйфатларына карап булырга кирәк. Болай булуы Испанияне, Португалияне һәм Франциянең кайбер өлкәләрен яулап алганнан соң, гомумән, ул мәмләкәткә Әндәлес, халкына әфрәнҗ дип, «Гакабәтел-Хилван»нан Ерак Көнчыгышка хәтле булган җирне «Хорасан» дип, Һиятылә шәһәре, ягъни Урта Азия дип йөртелә торган мәмләкәтнең бер өлешен «Мавәраэннәһер» дип атаулары кебек була.

Ислам галимнәре сәкалиб һәм сәкалибәне фин, төрек һәм славянның барысын бергә җыя торган мәгънәдә йөрткән кебек, аны рус һәм төректән башка халык дип йөртүләре дә бар һәм расланган сүз. Бу очракта сәкалибә финнарны, ягъни чуваш, чирмеш, ар, мордва һәм мукшы кебек халыкларны аңлата булып чыга. Әгәр хәзәр һәм сәкалиб исемнәре нәсел-нәсәп тарихын кайбер тикшерүчеләрнең бәян итүләренә караганда, «кыпчак» сүзе кебек, элек мәгълүм кешеләрнең исемнәре булып, соңыннан аларның балаларына һәм нәселләренә күчеп, кабилә исеменә әйләнгән булса, бу мәмләкәтне «Сәкалибә мәмләкәте», патшаларын «Сәкалибә патшасы» һәм Шәһре Болгарны «Сәкалибә патшасы йорты» дип йөртүләре, ул җирләрнең, хәзәр һәм кыпчак яки башка төрек халыклары килүдән элек, «сәкалиб» дип йөртелгән бер кабиләнең урыны булып, соңрак төрекләр аларны җиңеп, үзләрен куып җибәреп, урыннарын яулап алуларыннан гына булса кирәк, чөнки тарихларда: «Угыз хан Кыпчакны Идел һәм Дон елгалары арасына җибәреп, ул анда рус, әфлак[1], мажар һәм башкорт кабиләләре белән сугышты», – дип

[1] Әфлак – Валахия – хәзерге Румыниянең бер өлешендә яшәгән халык.

телгә алына. Димәк, монда «сәкалибә» исеме белән йөртелү, Румда патшалык кылганлыклары өчен Сәлҗукый патшалыгының бер тармагы булган Котлымыш бине Исраил бине Сәлҗук бине Дәкак әт-Төрекмәни әс-Сәлҗукый балаларыннан Рум илләрендә патшалык иткән затларга Рум Сәлҗукыйлары һәм Госманлы кабиләсенә Рум илендә патшалык иткән өчен Рум солтаннары дип исем бирү кебек кенә була. Хәтта Госмания солтаннарының дүртенчесе булып, «Елдырым» исеме белән танылган солтан Баязит Мисырда Габбасия хәлифәлегеннән калган Мөтәвәккил Галәллаһ хәлифәгә үзенең буйсынуын белдереп, аңар зур бүләкләр җибәреп, ул хәлифәдән рәсми рәвештә «Рум солтаны» дигән мактаулы исем алган иде. Инде бу сүзләрнең нәтиҗәсе һәм шаһите булып түбәндәге хәл тора: Болгар җиренең борынгы халкы гарәпләр тәгъбире белән «сәкалиб» дип йөртелгән финнар булганнар; җиңеп һәм хакимлекне үз кулларына алып килүче гарәпләрнең «хәзәр» дип атаганнары – кыпчак төрекләре гарәпләр тарафыннан кат-кат җиңелгәннән соң, Идел буенча югары күтәрелеп, үзләреннән йомшак булган финнарны җиңеп, аларның йортларына хуҗа булып патшалык итә башлаган булырлар. Финнар һәр хосуста, мәсәлән, күркәм холыклы, фикерле һәм акыл иясе булуда, шулай ук сәяси куәттә, батырлыкта, мәгърифәттә һәм дәүләт мәсьәләсендә төрекләрдән түбән, бик түбән булулары сәбәпле, финнарда патшалык кылырлык һәм төрекләр шикелле гайрәтле батыр халыкка каршылык күрсәтә алырлык көч булганы юк.

Төрек таифәсе гәрчә чүлләрдә яши торган күчмә халык булсалар да, эшләрендә мөстәкыйль булып, халкына яраклы әмирләре һәм бикләре була килгән. Хәтта төзек илләрне яулап алып, аларга хуҗа булып тота белгәннәр, үз хөкемнәрен йөрткәннәр, культурада үзләреннән өстен халыкларны да куркытканнар.

Бу Болгар төрекләре нәсел-нәсәп ягыннан башка төрекләргә якын булулары, Гыйрак, Хорасан, Мавәраэннәһер һәм Харәзем мәмләкәтләре белән аралашулары һәм алар белән сәүдә итү һәм башка мөгамәләләрдә булулары сәбәпле, икенче тарафтан гыйлемдә, һөнәр-сәнәгатьтә югары дәрәҗәдә булган

гарәп пропагандистлары гыйлем тарату һәм авыруларны дәвалау кебек чаралар аркылы халыкны ислам диненә керергә өндәү юлында бик зур тырышлык күрсәтүләре сәбәпле, төрек таифәсе ислам динен фин халыкларыннан элегрәк кабул иткәннәр. Шуннан соң инде финнар төрекләрдән, әкренлек белән, дин һәм тел алып, аралашып, тәмам төрекләшкәннәр, хәтта төреклекнең үзәге булган шәһре Болгарга якынрак кабиләләре бөтенләй төрек һәм Болгарлар белән бер кабилә булып киткәннәр. Әбү Хәмид әл-Әндәлесинең «аларны дәваладылар һәм алар мөселман булдылар», Шәмсетдин әд-Димәшкыйның – «төрек белән сәкалибә арасында туган кавем» дигән сүзләре бу фикерне куәтлиләр. Шәһре Болгарның көнчыгыш ягында башкортлар яшиләр. Ибне Фазлан, Ибне әл-Әсир һәм Шәмсетдин әд-Димәшкый, Ибне Халдун һәм башкалар аларны да төрек нәселеннән дип саныйлар. Болар да фин таифәсеннән булсалар да, үзләре башка финнарга караганда терерәк, гайрәтлерәк һәм хәмиятлерәк булганга, Болгарга бик якын булмасалар да, бер яктан, кыпчаклар белән чиктәш, икенче яктан, телләре төрек теленә якын булып, төрекләрдән җиңеллек белән тел һәм дин алып, тәмам төреккә әйләнгәннәр, хәтта телләрендә җиде-сигез сүзгә бер генә фин сүзе табыла дигән сүз дә бар. Ике кавем, ягъни башкорт һәм чирмеш халыклары, Казанда һәм аның тирә-ягында яшәүче мөселманнарны чуваш диләр, ләкин башкорт хурлау һәм кимсетү урынында «Казан чувашлары» ди, әмма чирмеш халкы бер-бере белән үз телендә яки башкалар белән сөйләшкәндә мөселманнарны суас, ягъни чуваш дип сөйли, башка исем белән атамый. Моннан уйларга мөмкин ки, чуваш халкы Болгар халкына һәм теле һәм урыннары якын торганлыктан, фин лөгате белән сөйләшсәләр, сүзләренең яртысыннан артыгы төрки сүзләре, шуңа күрә аларны «гүя төрекнең бер тармагы» диләр. Бу сәбәпләр белән чувашлар исламны чирмеш һәм башка фин кабиләләреннән элегрәк кабул иткәннәр, чирмешләр, урман, тау араларында яшәп, дөнья күрмәгән, халык танымаган булганлыктан, мөселман таифәсе чуваш кына дип белеп, «чуваш» дигән сүзне «мөселман» дигән

сүз урынына йөрткәннәр, хәтта соңрак вакытларда үзләреннән мөселман булганнарны да «мөселман» дигән сүз мәгънәсендә «суас» исеме белән йөрткән булырлар.

Безнең татарлар-мөселманнар арасында да «урыс» дигән сүзне «христиан» мәгънәсендә йөртәләр, ягъни «фәлән кеше урыс булган», ягъни христианлыкка чыккан, диләр. Немец һәм французларны да урыс диләр, ягъни христиан, я кяфер дигән сүз була.

Хәзер дә шәһре Болгар һәм Казан тирәсендә төньягында чирмеш һәм ар, көнбатышында чуваш һәм мордва халкы, көнчыгышында башкортлар яшиләр.

Казанның тирә-ягында элек тә финнардан бер кабилә яшәп, соңыннан алар киткән, яки мөселман булган, яисә арадаш утырган һәм чирмешчә яки чувашча исемнәр белән аталган авыллар бар, Мәсәлән, «Шинбер», «Киме», «Мәңгәр» һәм «Күәм» исемендә мөселман авыллары бар. Чирмешчә мәгънәләре – «Каракан», «Итек», «Зират»; «Ачасыр» – чувашча «угылсыз» дигән мәгънәләрдә булалар. Шулай ук «Чирмеш иле», «Чуваш», «Чувашлар орысы», «Маҗар», «Бортас», «Ар», «Күшәр», «Мукшы», «Мукшы күле» исемле авыллар бар. «Мамыш» авылы, асылда, «Мәмеш» исемле бер чирмеш исеме белән аталган. Кайбер фин авыллары мөселманча исем белән аталган; мәсәлән, Царёво-Кокшай[1] өлкәсендә «Мирзалар» исемле чирмеш авылы бар. Югарыда әйтелгән «Мукшы» авылы соңгы заманнарга чаклы Күшәр һ.б. авыл кешеләренә кол булып сатылып-алынып йөртеләләр иде. Күшәр имамы мәрхүм мулла Габбас бине Габдерәшид үзе, асылда, Күшәр мирзаларыннан иде. «Күшәр» «Куш ар» булып, әле безнең гасырыбызда да елганың икенче ягында ике йорт ар яши иде. «Бәрәскә» авылы да асылда «Барский» мәгънәсендә дип әйтә иде, ләкин кайдан алып әйткәндер, уйлапмы, уйламый гынамы әйтә идеме![2]

Казан сәүдәгәрләреннән Исмәгыйль бине Апанайдан калган иске бер язуда мондый юллар бар:

---

[1] Царёво-Кокшай – хәзерге Мари Эл республикасы башкаласы Йошкар-Ола шәһәре.

[2] Ш. Мәржани моны кемнән дә булса ишеткән генә булырга кирәк.

«Тарих мең дә җиде йөз сиксән сигезенче елда гыйнварның сигезенче көнендә мин, Казанның Иске Бистә йомышлысы Йосыф Динмөхәммәд углы, үземнең өлешемә тигән колымны Казанның Иске Бистәнең Исмәгыйль Апанай Хафиз углына йөз сум хак белән саттым, ошбу колларым: Алат юлында Арча округында Күшәр авылында йорт белән торучылар, алар – Бикбау Сәедки углы, хатыны Нәсыйхә, бер сабый кызы һәм бер углы Бикчәнтәй Бикбау углы белән; икенче колымның углы Мортаза Мөәмин углыны һәм шул Күшәр илендә били торган җирләрем һәм печәнлегем барысы да Исмәгыйль агайгадыр». Шулай ук Дунай буйларына күчеп киткән болгарларда да финлык әсәрләре бар, диләр. Мәрхүм хаҗи Сөләйман бине Ибраһим әл-Бәрәскәви: «Истанбул урамында бер адәм күрдем, киеме, кыяфәте нәкъ безнең мондагы чирмеш кебек иде, кулында куыктан ясаган чирмеш сыбызгысы булып, шуны сызгыртып уйнап бара. Чирмеш телендә эндәшеп, бер-ике җөмлә чирмешчә сүздер әйткән идем, әйләнеп бераз карап торды да, һичбер сүз әйтмичә, сыбызгысын сызгыртып китеп барды. Теле чирмеш теле түгел икән дип уйлап: «Бу кеше нинди халыктан була?» – дип сорадым. «Болгар халкыннан», – дип җавап бирделәр. Аларның киемнәре, бигрәк тә хатын-кызларының киемнәре, хәзер дә нәкъ чирмеш киеме шикелле диләр», – ди.

Бу юлларны язучы әйтә: кайбер мөселман авылларында да «Чирмеш зираты», шулай ук «Кирәмәт елгасы» дигән елгалар, бәгъзе татарларда финнарда булган ялган ышанулар, келәү салу шикелле гадәтләр булган. Чирмеш Тимергали, Чуваш Ибрай, Вотяк Исмәгыйль исемле кешеләр бар. Моннан башка, «Ходай колы»[1] авылында мең ике йөз кырыгынчы (1824–1825) елларда Җаныбәк, Ишмәмәт, Ишбулды исемле өч туган чирмеш килеш вафат булып, үз гадәтләренчә күмелгәннәр. Алар үз араларында һәрвакыт чирмешчә сөйләшәләр иде. Ишбулды исемлесе патша хезмәтеннән кайтып, өйләнми үлгән, мөселманнар белән очраш-

[1] Ходай колы – Кудайгулово – Арча районы Ташкичү авылы. Ташкичү белән Ашыт авыллары арасында ташландык, иске зират бар. Халык телендә «Чирмеш зираты» дип йөртелә.

канда сәлам биреп, телендә «Әлхәмдүлиллаһ», «Аллаһы Тәгалә боерса», «Аллаһга шөкер», «Аллаһ теләсә» шикелле сүзләр йөртә иде. Әмма намаз укуы, ураза тотуы мәгълүм түгел. Җанибәктән Бәйрәмгали исемле бер угыл, Ишмәмәттән Биктимер, Гобәйдулла һәм Хәбибулла исемле өч угыл булып, бу исемнәрне аларга үз аталары биргән булган һәм һичкемнең өндәве, кызыктыруыннан һәм өйрәтүеннән башка, үзләре мөселман булып, Бәйрәмгали 30 яшьләрендә үзен сөннәт кылдырган. Болар да мөселман булып үлеп, мөселман каберлегенә күмелделәр. Бәйрәмгали, Биктимер һәм Гобәйдулладан балалар бар. Ишмәмәт хатыны, иреннән тол калып, чирмеш киемен ташлап, мөселман булып, намаз укып, ураза тотып, корбан чалып, ислам динендә үлгән һәм мөселман каберлегендә күмелгән. Шулай ук ар халкыннан да якын заманда мөселман булган авыллар һәм галимнәре бар. Төп мөселманнар белән телләре, кыяфәтләре, гадәт һәм әхлаклары арасында аермалары юк. «Аллаһ дигел бәдәвам» китабында фин гадәтләренә каршы мондый сүзләр бар:

Һәркем җенгә табынса,
Я суга нәрсә салса,
Агачка нәрсә чалса,
Аллаһ дигел бәдәвам.
Я зиннарны багласа,
Я ул келәү күтәрсә,
Хәрамны хәләл белсә,
Аллаһ дигел бәдәвам.
Пәйгамбәр бөйлә диде,
«Кяфердер анлар» – диде,
«Тәмугда җаны» – диде,
Аллаһ дигел бәдәвам.

Бу «Бәдәвам» китабы – борынгыдан калган бик иске китап. Утыз Имән авылының Габдерәхим мулла язган китап дип йөрү нигезсез. Гомумән, Болгар илендә яшәгән финнар ислам хөкүмәте вакытында һәм шәһре Болгар төзек чакта, һәрбер таифәсенең күбрәге исеме белән дә, рәсми яктан да барысы да мөселман булганнар. Ләкин Болгар иле харап булып, ислам хөкүмәте бетерелгәч, кайберләре арасына ислам тамырлана алмаган, аларның наданлык һәм аңсызлыкларын җиңә алмаган, алар арасында ислам хөкемнәре югалып, әкренләп асылларына кайтканнар. Сигезенче (14 нче) йөздә яшәгән Җужи улусында ислам нык таралган булса да, аларның күбрәге финнарны, гарәпләр һәм Болгар халкы шикелле, нык итеп берләштереп исламда

тота алмаганнар. Алатыр һәм Нижний[1] халкында исламның тамырланып калуы тышкы сәбәптән булса кирәк, мәсәлән, диндар хакимнәр, яхшы галимнәр килүе сәбәбеннәнме? Аллаһ белә: Олуг Мөхәммәд хан, Сарайдан чыкканнан соң, гомеренең күбрәк вакытын шунда кичергәннән түгел микән?

Финнарның күбесен руслар ахырда христианлыкка керткән булсалар да, исламнан берәр файдалы нәрсә ала алмаганнары шикелле, христианлыктан да, йөз елдан артык вакыт үтеп китүгә карамастан, исемнән башка бернәрсә дә ала алмадылар. Финнарда исламнан калган кайбер гореф-гадәт һәм ышануларның күренүләре шул сәбәптән булса кирәк. Мәсәлән, алар, мөселманнар кебек, эшнең башында «бисмиллаһ» дип әйтәләр һәм «Аллаһ бәрәкәт бирсен» диләр. Җомга көнне олылап, ул көндә һич эш эшләмиләр, мөселманнарны үзләреннән дә, руслардан да алдын күреп хөрмәтлиләр...

Бу юлларны язучы әйтә:

– «Мин, фәкыйрь, мең ике йөз сиксән тугызынчы (1872–1878) ел, җөмадиел-ахир аеның икенче көнендә бер чирмеш белән сөйләштем. Ул Ташкичү авылының берәүгә ялланып, аны Бәрәңге авылы ягыннан китергән иде. Дөнья күргән, шаярган, кыю гына бер кеше булырга кирәк, сораган нәрсәләремне бер дә баш тартмыйча аңлатып бирде. Аларның күбесе, алдар яки сихерләр дип куркып, ачык итеп сөйләшмиләр иде. Әүвәл хайванны ничек суюлары турында сорадым, нәкъ мөселманнарча суюларын сөйләде. Бугазлаганда, гомумән, һәрбер эшкә керешкәндә: «Пестмелайму пиркем пу», – дип әйтәбез, ди. Моның мәгънәсе: «Бисмиллаһ, я Аллаһ, бәрәкәт бир» дигән сүз була. Икенчесе, нинди ит ашаулары турында сорадым: «Дуңгыз, эт, мәче һәм бүре итләрен ашамыйбыз, ат, аю, куян, тиен шикеллеләрнең итләрен ашыйбыз», – диде. «Аю ите яхшымы, тәмлеме?» – дип сорадым. Ул: «Юк, тәмсез, җир тәме килә», – диде. «Алай булса, ник ашыйсыз?» – дигәч, «бала-чагага ярый инде шунда», – диде.

– Бүре итен ашамыйсызмы? – дидем.

---

[1] Нижний – Нижний Новгород шәһәре.

– Юк, ашамыйбыз, – диде.

– Аю итен ашагач, бүре итен ник ашамыйсыз? – дидем.

– Аны ашасаң, эт итен дә ашарсың, – диде.

Өченче – өйләнү, кыз алу хәлләрен сораштым.

– Авылдан да, башка авылдан да алабыз, – диде. Мин:

– Юк, мин аны түгел, кардәшегезне аласызмы? – дип сорыйм дидем.

–Ике яктан да берәр буын аерылган булса, алабыз, аннан якынракны алмыйбыз, – диде.

Дүртенче – кирәмәт һәм келәүләре турында сорадым. Җавабыннан өч кешегә якынлашуны теләп, хәер, ихсан бирәләр икәне беленде.

– Ул өч кеше кемнәр соң? – дидем.

– Берсе Ему. Сезнеңчә Аллаһ дисәң дә, Ему дисәң дә икесе бер сүз. Аннан, нәрсә кирәк булса, шуны сорыйбыз. Икенчесе – пәйгамбәр. Аннан, «безгә булыш» дип, ярдәм сорыйбыз, өченчесе – «Кыямәт түрәсе». Аннан безнең якыннарыбызны иркенгә, яктыга чыгар дип сорыйбыз, – диде.

– Ул өч шәхес хәзер дә бармы, алар кайда торалар, өчесе дә бергәме яки аерым торалар микән, яки алар электә генә булып, хәзер инде юклар микән? – дидем.

– Анысын белмим, – дип җавап бирде.

Димәк, моннан мәгълүм булганча, алар Аллаһтан һәрни кирәкләрен, пәйгамбәрдән шәфәгать-яклауны сорыйлар икән. Әмма кыямәт түрәсе дип кемне атый торганнардыр, Ходаның үзенме, Газраилнеме, Исрафилнеме, җәннәт сакчысы Ризваннымы, тәмуг сакчысы Маликнымы? – мәгълүм булмады. Боларның нигезе исламнан алынган: «Ему пу» дигән сүзләре үзләренчә «Аллаһ бар» мәгънәсендә булып, «бисмиллаһ», «бәрәкәт бир», «кыямәт түрәсе» һәм «пәйгамбәр» дигән сүзләрне исламнан алып кулланалар икән.

Бишенче: «Җомга көнне эш эшлисезме?» – дидем. «Юк, бер дә эшләмибез, безгә ул көнне эшләргә ярамый, әмма шимбә, якшәмбе һәм башка көннәрне эшлибез», – диде.

Алтынчы: «Чукынганмы?» – дидем.

– Әйе, чукынган. Башта безнең бабай чукынган. Бездә чукынмаган чирмешләр дә бар, алар теләсәләр, ислам динен тотарга мөмкиннәр һәм тота торганнары да бар, безне урыс куймый, – диде. Алай булгач, сезне поп ат ите ашаудан тыймыймы соң? – дидем.

– Аңар кем карый? – дип җавап бирде.

Җиденче – ислам динеме яки христиан динеме, кайсы күңелгә ошый төшә? – дидем.

Сүзне күп озайтмыйча:

– Поп азрак тезләндерә, – диде.

Казан губернасы Тәтеш өязендә «Хужа Хәсән» дигән исемнән бозылып, «Хуҗасан» дип йөртелә торган бер чуваш авылы бар. Телләре ар һәм төрки, ә киемнәре һәм гадәтләре чувашча икән. Хәзер христиан исемендә йөриләр, шул яктагы татарларның сүзләренә караганда, моннан 80–90 еллар элек бу авылның ташланган иске мәчете бар икән. Шул ук якта «Байтирәк» исемле бер чуваш авылы бар. Шул авылның чиркәве янында түбән ягы сынып төшкән бер таш бар, озынлыгы биш чирек кадәр, киңлеге аршыннан бер илле ярым ким. Икенче кисәге – икенче бер урында. Болгар ташлары шикелле күфи һәм нәсех язуларын аралаштырып казып язылган. Язуы болай: «Әлхөкме лилләһил-галиил-кәбир. Юныс углы Хаҗи Бәдәвигә рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән, вафат Бәлкәви тарих жият жур жерем жити жал сәвер аек жирем биш күәнәт»[1].

Бәлкәви сүзе «к» белән булмыйча, «ты» белән язылган булса, ул, нигездә, «булды» дигән сүз булып, чуваш теленә кереп киткән булуы ихтимал. Ләкин бу очракта ул күчемсез фигыль булып, эш икенче берәүгә күчмәгәнгә күрә, «кә» кушымчасы урынсыз булып кала. «سور » дигән сүзне « س » хәрефе белән хата язган, дөресе «ثور », кояш елының икенче ае була. Димәк, бу зат жиде йөз егерме жиденче (1326–1327) елда вафат булган була. Ләкин бу таш авылдан бер чакрым кадәр түбән, суның икенче ягындагы

[1] Бөек дәрәжәле Ходаның хөкемедер. Юныс улы Хаҗи Бәдәвигә Ходаның рәхмәте булсын. Тарих жиде йөз егерме жиденче ел, сәвер аеның 25 нче көнендә вафат булды.

борынгы зираттан китерелгән икән. Шул Байтирәкнең «Кече Буа» дигән суында авылдан өч чирек чакрым түбән җирдә бер тегермән бар. Буасы өстеннән икенче ягына үтеп, юл белән төньякка таба йөз колач кадәр баргач, юлдан алты-җиде колач кадәр көнчыгыш ягында «Олы Ялчек» дигән чуваш авылы басуында бер каберлек бар. Әлеге Байтирәк авылының каберлеге булса кирәк. Бер ышанычлы кешенең сүзенә караганда, югарыда әйтелгән таш шул каберлектә булган. Тагын бер таш күфи һәм нәсех язулары белән аралаштырып казып язылган. Беренче юлында – «Һу әл-Хәйҗү әл-ләзи лә йәмүт»[1], икенче юлында «Салавыш углы Муса углы Бәйрәм Хаҗи углы Биккенә» дип язылган. Тагын шул ук якта «Олы Әтрәч» дигән мөселман авылының Иделгә таба ягында авылдан өч-дүрт чакрым ераклыкта «Шунгаты өсте» дигән урында егерме биш данә таш бар, бере-береннән аралары бердән ун колачка кадәр. Боларның кайберсе саф татар телендә, кайсылары чуваш сүзләре белән аралаштырып язылган һәм җиде йөз ике (1302–1303), җиде йөз өч (1303–1304), җиде йөз ундүрт (1314–1315), җиде йөз егерме дүрт (1323–1324), егерме биш (1324–1325) һәм кырык җиденче (1346–1347) елларда вафат булган кешеләр өстенә куелган ташлар икән. Авыл халкының сүзләренә караганда, борын заманда монда мондый ташлар күп булган. Моннан җитмеш еллар элек «Әтрәч» дигән авылдан биш чакрым көньякта «Җанбакты» исемле рус авылы алпавыты шул авылга чиркәү салдырганда, нигезенә таш кирәк булгач, мөселманнарның хөрмәтләп тоткан ташларыннан егерме-утыз кадәресен агач чиркәүнең нигезенә, идәненә һәм бусагасына куйдырган. Шул авылның яше сиксәннән узган мөәзине:

– Мин бала чагымда атам белән шул авылга бер йомыш белән барган вакытымда шул ташларны төзәтеп куйганнарын карап тордым. Атам елап:

– Менә безнең авылыбыздагы газизләрнең каберләре өстенә куелган ташларны чиркәү бусагасына куялар, – дип әйтте, – диде. Шул ук урында мең өйле «шунгаты» дигән халык булган,

[1] Һу әл-Хәйҗү әл-ләзи лә йәмүт – ул терек, һич үләчәк түгел.

Болгарлар белән кыз бирешеп, кыз алышып торганнар. Тагын бер таш күфи һәм нәсех белән аралаштырып калкытып язылган: «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт. Йосыф улы Мөхәммәд улы Исмәгыйль зиярәте торыр, Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән, фани дөньядан бакый ахирәткә рихләт тындуй[1]. Тарих җият җүр вә ан туато»[2].

Тагын бер таш – «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәйүүн сә-йәмүт Мостафа улы Мөхәммәд улы Ибраһим Бәләви рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән»[3]. Тагын Спас өязе Ташбилге авылы имамы Хаҗи Мелләхмәт бине Габбас үзләренең каберлекләрендә булган ташларыннан алып җибәрде. Каберлекнең көнчыгыш ягында бер таш калкытып язылган. «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәйүүн сә-йәмүт Гомәр улы Исмәгыйль улы Хәсән улы Рәхбәзбай тарих җият җүр жур, жу в жу жал.[4] Көнбатыш ягында бер ташта – «Әлхөкме лилләһил галиил-кәбир[5] Ирек улы Мөхәммәд шәрих альчи», икенче ташта «Әлхөкме лиллаһил галиил-кәбир Ильяс улы Исмәгыйль улы Мөхәммәд бәлвик рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән тарих җият җүр олтыш җыл аех эшзаҗ чермиш шүз бәр сәрвәт»[6]. Лаеш өязе Тау иле авылы каберлегеннән мелла Сәлах бине Исхак язып алган. Тарих сигез йөз туксан җидедә шәгъбан аеның унбишенчесе иде кем, Тәвәккәл Мәүла Сәед Әхмәд егерме өч яшендә шур даре дөньядин даре бәкага рихләт әйләде[7], Хак

---

[1] «Ул терек, һич үләчәк түгел, Йосыф улы Мөхәммәд улы Исмәгыйль зиярәте, Хода аңар рәхмәт итсен, бу фани (бетәчәк) дөньядан мәңгелек ахирәткә күчте. «Тарих җиде йөз ундүрттә».

[2] Тындуй, ягъни тәгъриф вә игъламе, хәзерге телебездә «танытуы» диербез. *Ш. Мәрҗани аңлатмасы.* Бу очракта «рихләт тындуй – күчеп, үзен танытуы» дигән сүз була.

[3] «Ул терек, һич үләчәк түгел, башка һәрбер терек җан үләчәк. Мостафа улы Мөхәммәд улы Ибраһим Балви (яки Беләви), Хода аңар рәхмәт итсен.

[4] Җиде йөзенче елда.

[5] «Әлхөкме лилләһил галиил-кәбир – бөек Аллаһның хөкеме.

[6] Ходаның аңар рәхмәте киң булсын, җиде йөз алты ел («эшзаҗ чермиш шүз бер сәрвәт» дигән сүзләрнең мәгънәләрен белә алмадык).

[7] Даре дөньядин даре бәкага рихләт әйләде – дөнья йортыннан мәңгелек йортка күчте.

Тәгалә рәхмәт кылсын». Янә бер таш: «Тарих тукыз йөз егерме тукызында җөмадиел-ахир иде Кәбир Хажи Хәсән углы». Тагын Казан өязе Иябашы каберлегендә мондый ташлар бар. Янә Казанда күл башында архиерей чиркәве янында икегә сынган бер таш бар, Әхмәд исемле кешенең каберенә куелган булган. Тарих вафаты: «Алты туштан алтыш җыләт зөлхиҗҗә аех сәкөр көан ирнә күәнәт, әл-мәүте бабен вә көллен-наси дахиләһү[1]». Казанның ышанычлы бер кешенең хәбәренә караганда, ул урында моннан башка ташлар да булган. Төзелеш вакытында эшчеләр юнып, тигезләп, биналар астына салганнарын күреп, ул вакыт Казанда епископ, соңыннан архиепископ булган Григорий дигән кеше бу хәлне күреп тыйган, шул сәбәпле, бу таш сәламәт калган. Тагын епископ йорты капкасының тышкы ягында тау башында буе биш ярым терсәк, киңлеге биш чиректән артык, калынлыгы да ярты терсәк буена якын булып, язуы сөлес белән бик яхшы итеп калкытып язылган. Укырга уңайсызлыклары: беренче, ташка язучы кайбер сүзләрнең арасын казып, бүләргә кирәк урында бүлми калдырган. Бу сәбәптән язылмый калган калку җирләре хәрефкә ошап тора. Икенче – бик вак, бик еш язылган һәм сүзләре берберсе белән бик чорналган. Өченче – бу ташның язуын төшереп алыр өчен, типография карасы белән буяганнар, һәр мәртәбәсендә буяу ташка ябышып катып калган. Аны уку өчен, ташны берничә кат эссе су белән юып, хәтта бик саклык белән генә кырып алырга, аннан соң калкып тора торган җирләренә – хәрефләр өстенә бер ак сыекча белән язып чыгарга кирәк иде. Шулай булганда укып булачак, язма юллары кырылмаган – ватылмаган иде. Ләкин бу кадәр сүзләр укылды. Башта өчпочмаклы итеп эре хәрефләр белән язылган: «Һу әл-Хәйәү әл-ләзи лә йәмүт». Моннан соң тугыз юл итеп болай язылган:

1. Һәза мәркаде әс-солтанел-әкбәри әл-әкрәми гаусиссәлатыйн[2].

---

[1] Әл-мәүте бабен вә көллен-наси дахиләһү – үлем бер ишек ул, һәрбер кеше аңа керәчәк.

[2] Солтаннарның ярдәмлерәге, олырагы, хөрмәтлерәге.

2. Әл-әмирел-мөкәррәми вәли[1].
3. Әл-мозаффар[2].
4. Әл-кирами вәл-җәмилел-гыйзамил-гыйльми[3].
5. Иля әл-мозаффари[4].
6. Әш-шәрәфәйни мөфәххәрен әл
7. Вә әд-дини зыйллүллаһи лил-галәмәйни
8. ...
9. Хәсән бик бине Мәхмүд

Ләкин беренче юлдагы «әл-әкрәм» сүзен «әл-кәрим» дип укырга мөмкин. Дүртенче юлда «вәл-җәмил», тугызынчы юлда «Хәсән бик бине Мәхмүд» сүзләре бераз шиклерәк. Бу юлларны язучы фәкыйрьнең уенча, бу кабер иясе гади бер кеше булмыйча, үзе хөкем йөртә торган бер патша булып, татар ханнарыннан түгел, бәлки Болгар әмирләреннән берәү булырга кирәк, чөнки сүзнең барышы шуны күрсәтә. «Әс-солтанел-әкбәре гаусес-сәлатыйн, зыйллуллаһи лил-галәмәйни»[5] – ди. Татар рәсемендә мөстәкыйль патшаны «хан» дип, шаһзадәләрне «солтан» дип йөртәләр.

Байтирәк, Шонгаты һәм аннан башка бик күп урыннарда булган ташларда да гарәп, төрки һәм чуваш телләре аралаштырып язылган. Шәһре Болгар ташлары без күргән урыннарда һәркайда ике төрле күренде. Берсе гүзәл сөлес язуы белән калкытып язылган, башында күбрәк очракта «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт»[6] дип язылган, ташы калын, күләме зур. Икенче төрлесе күфи белән нәсех арасындагы бер төрле язу белән казып язылган һәм башында «Әлхөкме лилләһил-галиил-кәбир»[7] дип язылган була. Кайсыларында «фәлән улы фәлән» дип, алдан

---

[1] Хөрмәтле әмир.

[2] Әл-мозаффар – жиңүче, өстен чыгучы.

[3] Әл-кираме вәл-җәмилел-гыйзамил-гыйльми – хөрмәтле, бөек, бик галим.

[4] Иля әл-мозаффари – жиңүчегә.

[5] Зыйллуллаһи лил-галәмәйни – һәр ике дөньяда Аллаһның күләгәсе, шәүләсе.

[6] Һу әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт – ул (хода) терек, һичбер үләчәк түгел.

[7] Әл-хөкме лилләһил-галиил-кәбир – хөкем бөек Аллаһныкы.

атасының исемен язган, кайсында «фәлән фәлән улы» дип, аермачык язылган. Мәрхүм мелла Хөсәен югарыда әйтелгән Байтирәк авылының Шәммас исемле кешедән ишетеп әйтте. Бу авыл чувашлары кулында Иван IV тарафыннан бирелгән грамота бар икән. Ул грамота мөселман мирзалары исеменә бирелгән булган, анда күп мөселман исемнәре бар. Бу чувашлар шуларның балалары икән. Хәзер үз милекләрендә булган җирне шул язу нигезендә билиләр икән. Бу хәбәрне Шәммастан ишеткәч, аны алып, күреп укырга күңелем җилкенгән иде, әмма, беренчедән, кызу эш вакыты – август аеның алты-җиделәре иде; икенчедән – ул язуның кем кулында булуын эзләп табу кыенлыгы бар иде һәм табылган тәкъдирдә дә мондый бер юлаучы мөселманга укырга бирүе мәгълүм түгел иде, ә җәберләп алып укырлык тәгълимат юк иде. Өченчедән – үземнең дә вакытым тар иде, шул сәбәпләрдән бу кадәр хәбәр белән канәгать иттем. Бу – һәркемнең дикъкатен үзенә җәлеп итә торган гаҗәп бер хәбәр. Кыскасы, финнар бу илдә ислам хөкүмәте вакытында барысы да яки күбрәге ислам диненә кергәннәр, ләкин кайберләре кабилиятләре һәм мөселманнар белән мөгамәләләре аз булганлыктан, ислам аларда тамырлана алмаган, наданлыкларын җиңә алмаган. Ислам хөкүмәте беткәч, наданлыклары сәбәпле, әкрен-әкрен үзләренең асыллары булган чувашлык, чирмешлек һәм арлыкларына кайтканнар. Менә Җәбәлстанда һәм кайбер Болгар вә Казанның иске каберлекләрендә табылган ташларда чуваш, чирмеш лөгатьләре булу һәм алардан кайбер мөселманчылык гореф-гадәтләре дә табылу шул сәбәптән булырга кирәк. Бәс, уйлап кара: Шәмсетдин әд-Димәшкыйның – «Каумен, мөтәвәллидүнә бәйнәт-төрки вә әс-сәкалибә»[1] дип әйтүе никадәр дөрес, Казан һәм аның тирә-ягында яшәүче мөселманнарның күбесендә, гомумән Казан артында һәм бигрәк тә Алат юлындагыларның гадәт һәм тормышларында, каберстанга куелган ташларның язуларында финлык әсәрләре һич беленми, бу исә аларның, асылда, төрек, кыпчак яки татар булуларыннан,

[1] Төрек белән сәкалибә арасында туган бер кавем.

яки алардагы мөселманчылык куәтеннән, яки галимнәренең халыкны ислам хөкемнәре буенча тотарга тырышканлыкларыннан яки сәүдә мөгамәләләре аркылы тормышта һәм динлелектә тәрәкъкый иткән халыклар белән аралашуларыннан булса кирәк. Хатын-кыз җәмәгатенең бу кадәр динле булулары, намаз һәм башка гыйбадәтләрне үтәүдәге тырышлыклары бүтән һичбер мәмләкәт халкында күренгәне һәм ишетелгәне юк. Аларның башларына ураган өрпәкләре, күкрәкләрен каплар өчен кигән күкрәкчәләре, озын җиңле күлмәкләре – хатын-кызлар өчен иң муафыйк киемнәр. Ләкин хәзерге заманда калфакны озак вакыт киеп йөрү гадәте кереп, иргә баргач та, хәтта чәчләре агарганчы калфак кия торган булып, өрпәк сару гадәте бетәргә якын булып калды.

Безнең гасырыбыздан элек хатын-кыз күлмәгендә итәк бер дә булмаган. Безнең гасырыбызда әүвәлдә күлмәкләре асылдан, ефәктән, комач яки ситсадан булып, күлмәк җиңнәре бик озын һәм киң, култык астында ягъни җиң төбендә икенче төсле нәрсәдән дүрт почмаклы итеп кештәк («хөштәк»[1] тән үзгәртелгән сүз) куя иделәр. Хәтта бер хатын көштәге бала юрганына җитәрлек булганлыгын сөйлиләр. Бай хатыннары итәкләренә ике рәт итеп яхшы кыйммәтле бәяле тасмалар тоталар, аның югарыдагысы тар, түбәндәгесе киң иңле була иде. Урта дәрәҗәләләр яшел, сары яки кызыл төсле бер яки ике катлы лента тоталар иде. Фәкыйрьләр һәм гади халык шулай итеп комачтан яки ситсадан тар гына итеп тоталар иде. Бай хатыннарының башларында ак калфак, аякларында читек-башмак, колакларында көмештән алка, беләкләрендә беләзек, бармакларында йөзек, чәчләрендә толым буенча тезгән – алтынчылар суккан тәңкә, очында көмештән койган чулпы, муеннарында укадан эшләнгән яка, аңар көмештән биш буйлы, кайберсе өч буйлы челтәр, фирәзә һәм башка төсле асыл ташлар утыртып койган була иде. Моннан соң инде саф ефәк, яки ефәк белән аралаш эшләнгән калфаклар чыкты, алар да калдырылып, бүрекләр барлыкка

[1] Хөштәк – фарсыча; киемгә куела торган ялгау.

килде. Аны энҗе һәм кыйммәт бәяле якут, зөмрәт, фирүзә, алмаз шикелле ташлар һәм алтын тәңкәләр белән бизәкләп кияләр, бәясе ике мең сумга һәм артыграк бәягә барып төшә иде; моннан соң төрле төстәге хәтфәләрдән юл-юл итеп тегелгән калфаклар кияләр, кайчакта чалма да кияләр иде. Моннан энҗе тирәле калфаклар таралды. Инде болар барысы да бетеп, хәзер бик кечкенә хәтфә калфаклар чыгарып, аңа энҗе тезеп кию бик мәгъкуль булып таралды. Күлмәкләрен төрле асыл, йон материяләрдән һәм ситсадан киң һәм ике катлы итәкле итеп тегеп кияләр, шул ук күлмәкләре белән бер төсле материядән камзул да тегеп кияләр. Хәзерге тарихтан илле ел элек чәч тезмәсенә, никадәр бай булсалар да, суккан тәңкә белән канәгатьләнгәннәр, соңыннан инде рус тәңкәләренең утыз, илле тиенлекләрен, тора-бара бер сумлыкларны, Екатерина тәңкәләрен тезәләр, аннан соң биш сумлык һәм ун сумлык алтын тәңкәләр тезә башладылар. Ике толым буенча ун сумлык тәңкәдән барлыгы 34 данә тәңкә тезеп, авырлыгыннан башлары авыртканлыктан, җилкәләренә салып утырып, мәҗлестән кайткач, башлары авыртудан зарланалар иде. Хәзер инде болар бетүгә якынлашып, җәтмәләп энҗе тезеп, толымнары өстенә тегү формасы чыкты. Моның да игътибары калмады, фәкать чәчләренең очларына һәм төпләренә икешәр алтын тәңкә тагып куялар. Беләкләренә энҗе тезеп тагалар. Кайберләре биш сум, ун сумлык алтын тәңкәдер, кайберләре Истанбулдан алдырып, төрек алтын тәңкәсен (мәҗидияне) тезеп тагалар, муеннарына берничә катлап тезеп, тапас яки мәрҗән яки мәрвәриттән берничә кат асалар иде.

Инде элек мөселман булып та, соңыннан кайбер сәбәпләр белән көчләп христианлыкка кертелгән һәм «керәшен» дип йөртелә торган татарлар хәленә килик. Бу халыкның телләре һәм ирләренең киемнәре мөселманнарныкы кебек булып, хатыннарының икенче төрле киемдә булуларының сәбәбе нәрсә икән? Яки мөселманнарныкы да элек шундый булып, әкренлек белән генә үзгәрә килгән булып, керәшен хатын-кызларында искечә калдымы, яки бу халык, асылда, төрек булмыйча, фин халкыннан иделәрме?

Казан халкында финнарга охшашлык булмаса да, Казаннан ераграк урыннарда аларның рәсемнәре, гореф-гадәтләре, киемнәре һәм башка якларында бер-берсенә охшаулар күп табыла. Мәсәлән, илле еллар чамасы элек Сембер[1] тирәсендә хатыннар ак киндер күлмәкне тар гына итеп тегеп, җөй буйларына бер генә илле киңлектә комач тегәләр, җиң һәм җилкәләренә кызыл яки яшел тегеп, ике-өч бармак киңлегендә ике кат киндер яки асыл чүпрәк өстенә көмеш акча тезеп, хәмаил[2] итеп киеп, исемен «муен томар»дан үзгәртеп, «путмар» дип йөрткәннәр. Өйләре чуваш өйләре кебек кара, төтене өй эченә чыга торган булган. Хәер, бу хәмаилне, асылда, алар башкалардан алганнар, чөнки ул гарәп халкында һәм Казан халкында булган. Казан хатын-кызы аның исемен үзгәртеп, «эмайли» дип, кайберләре «бөти» дип тә атаганнар. Ләкин алар алтын тәңкәләр яки кыймметле ташлар, иң кимендә көмеш әйберләр һәм тәңкәләр белән бизәлгән булганнар.

Хәзәрләр турында әйтелгәннәр

Әбү Исхак әл-Истахриның «Китабел-әкалим»дә әйтүенә караганда, «Хәзәр» бер икълим[3] исеме булып, аның башкаласы «Ител» дип атала. «Ител» үзе – бер суның исеме ул. «Ител» шәһәре ике бүлектән – көнчыгыш һәм көнбатыш бүлекләрдән гыйбарәт булып, патшалары көнбатыш бүлегендә тора. Үз телләрендә патшаларын «белек» һәм «бәк» дип атыйлар. Шәһәрнең бу бүлегенең озынлыгы бер фәрсәх[4] булып, ихатасы, ягъни чолгап алган крепосте бар. Аларның өйләре – тәбәнәк киез өйләр. Балчыктан салынган өйләр, мунча һәм базарлары бар. Шәһәрнең эчендә сигез меңнән артык мөселман, утызлап мәчетләре бар. Патшаның тора торган җире ярдан ерак булып, аның сарае кирпечтән салынган. Башка кешегә таштан өй салырга рөхсәт

[1] Сембер – хәзерге Ульяновск шәһәре.

[2] Хәмаил – хәситә.

[3] Икълим – өлкә мәгънәсендә.

[4] Фәрсәх – озынлык үлчәве. Бу төрле очракта төрле озынлыкны белдергән. Шуңа күрә төрле белешмәләрдә моны 2–3, 6–7, 7–8 километрдан билгелиләр.

юк. Крепостеның дүрт капкасы Иделгә, башкалары кырга ачыла. Патшалары яһүди булып, үз ягында дүрт мең кешесе бар. Хәзәрләрнең азчылык халкы яһүди, күбрәге мөселман һәм христиан, ә беразы – потка табынучылар. Хәзәр теле башка телләр белән уртак түгел». Икенче урында ул: «Болгар теле хәзәр теле кебек», – ди. Әбү Габдулла әл-Гарнатый: «Болгар теле хәзәр теле кебек, бортас һәм рус телләре башка»; Ител шәһәреннән болгарга корыдан барганда бер айлык, судан менгәндә ике айлык, төшкәндә егерме көнлек юл», – ди. Шәмсетдин әд-Димәшкый: «Хәзәр дәүләте урнашкан урын Хәзәр диңгезе буенда. Аның Хәмлиҗ, Бәләнҗәр, Сәмәндәр һәм Ител дигән дүрт шәһәре бар. Халкы ике төркем булып, берсе гаскәр, алары – мөселманнар, икенчесе – гражданнар, алары – яһүдиләр. Алар Һарун әр-Рәшид хәлифәлегендә яһүдилеккә керделәр. Константиния патшасы Кайсар үз мәмләкәтендәге яһүдиләрне иленнән чыгарып җибәргәч, алар, Хәзәр мәмләкәтенә килеп, үзләренең диннәрен хәзәрлеләргә күрсәттеләр. Хәзәрлеләр буш һәм надан булып, яһүдиләр динен үз диннәреннән артык күреп, яһүди диненә күчтеләр. Берникадәр вакыт үткәч, Хорасан тарафыннан бер гаскәр килеп, боларның илләрен яулап алды, һәм бу халык мөселманнар кул астында калды», – ди.

Ибне әл-Әсир: «Ике йөз илле дүртенче (868) елда аларга төрекләр һөҗүм иткән. Болар Харәзем халкыннан ярдәм сораганнар. Алар: «Сез кяферләр бит, мөселман булсагыз, без сезгә ярдәм итәр идек», – дигәннәр. Алар исламны кабул итеп, мөселман булганнар, мәгәр патшалары үзенчә калган. Мөселман гаскәре аларга ярдәм биреп, дошманнары булган төрекләрне куганнар. Шуннан соң патшалары да мөселман булган. Аларның хаканнары бер гаиләдән генә була һәм гаилә эченнән чыкмый. Патшалыкка хуҗа булса да, исемнән башка нәрсәсе юк. Аннан түбән дәрәҗәдә бер зур хаким булып, аны «мәлик»[1] дип йөртәләр.

Хакан алдына шул мәлик һәм аннан башка олылардан тагын берничә кеше генә керә ала, башкалар керә алмыйлар. Аның

---

[1] Ибне Дастә (ибне Рөстә) – «Шиа» дип атыйлар, ди.

алдына кергәч, туфракта ауный, сәждә кыла, аннан аяк өстенә басып, хакан якын килергә һәм сүз әйтергә рөхсәт биргәнче көтеп торалар. Әгәр зуррак берәр вакыйга булса гына, хакан чыга. Аны һәркем күрсә олылап, каршы килмичә, кире кайтып китә. Хакан үлгәч, аның кабере яныннан хайванга атланган килеш узмыйлар, җиргә төшеп, сәждә кылып, аның кабере күздән югалганчы җәяүләп китәләр. Әгәр дә берәү үтерелергә тиеш булса, ул кеше, өенә кайтып, үзен үзе үтерә. Берәүне патша итеп куярга булганда, ул кешене тотып, бугазыннан буалар. Үләр хәлгә җиткәч: «Дөньяда озак яшисең киләме?» – дип сорыйлар. «Күпме вакытны әйтсә, шулкадәр вакыт үткәч, үзе үлмәсә, халык үзе үтерә», – ди. Ибне әл-Әсир һәм Якут әл-Хәмәви «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китапта әйтәләр: «Йөз кырык җиденче (769) елда Әстерхан хәзәрләре, төрек хәзәрләре белән берлектә, Әрмәнстанга һөҗүм итеп, талап, аннан Тифлис шәһәренә кереп, Мансур хәлифәнең гаскәр башлыкларыннан Хәрәб бине Габдулла әр-Равәндине үтерделәр». Тәрҗемә итүче фәкыйрь әйтә: бу вакыйга Мансур хәлифәгә Галәвиядән Нәфсе Зәкия һәм борадәре Ибраһим каршы чыгып, алар фетнәсен бастыру белән шөгыльләнгән вакытына туры киләләр. Моннан башка Һарун әр-Рәшид хәлифәлегендә Фазыл бине Яхъя бине Халид-әл-Бәрмәки, хакан кызына өйләнеп, аны Багдадка алып китеп барганда, тәкъдире җитеп, юлда үлеп калгач, хакан, үчлек белән хыянәт итеп үтергәннәр дип уйлап, бик каты ачуланган һәм зур гаскәр белән ислам йортына һөҗүм итеп күп һәлакәт китергәндә, ислам гаскәре килеп, аларны Бабел-Әбвабтан куып чыгардылар.

Әбү Гали бине Дастә әйтә: «Хәзәр диңгез артындагы киң бер мәмләкәт булып, Болгар, Сувар, Сәмәндәр, Бәганд, Файсой, Хәмлиж, Бәләнҗәр һәм Бәйза – шуның шәһәрләре», – ди. Шулай ук Сәрир, Керчь, Хизан, Аклан, Бәрзәңгәран, Шабран, Гамик һәм Дәрбәнд тә шул илнең шәһәрләреннән санала. Алардан бер төркем халык аерылып китеп, Хәзәр белән Рум арасында булдылар. Ул урын аларның борынгы ватаннары түгел, алар «Бахтакия» дип атала».

Ител турында әйтелгәннәр

Безнең телебездә үзгәртелеп «Идел» дип, ә рус телендә «Волга» дип атала торган зур елга – шушы Кара Идел. Әмма хәзерге заман телебездә мәгънәсе киңәйтелеп, гомумән олы елгаларга «Идел» исемен биреп, «Кара Идел», «Ак Идел», «Чулман Иделе», «Ука Иделе», «Нократ Иделе» h.б. дип, ә кайберләрен шәһәр исеме белән «Вятка Иделе», «Уфа Иделе» дип тә атала. Якут әл-Хәмәви: «Ибел» сүзе – үлчәвендә итеп, Хәзәр илендә «Дәждә» елгасына ошаган бик зур бер елганың исеме. Икенче бер сүзгә караганда, «Ител» Хәзәр иленең бер шәһәр исеме булып, бу зур су шуның исеме белән аталып, ерак төньяктан килеп, Болгар, рус һәм хәзәр илләреннән үтеп, Хәзәр диңгезенә коя», – ди. Әбү Исхак әл-Истахри: «Иделнең башы хирхиз[1] җиреннән чыгып, Кимакия һәм Газия[2] арасын аерып торучы чик булып, аннан көнбатыш ягына борылып Болгарга килә, янә Бортас һәм Хәзәр иленә борылып кайтып, Хәзәр диңгезенә коя», – ди. Тагын мондый сүз дә бар: Иделнең җитмештән артык тармагы булып, суының күплегеннән һәм агымының тизлегеннән диңгезгә коелгач та ике көнлек ераклыкка кадәр суы кушылмый бара, төсе белән диңгез суыннан аерылып тора һәм татлы булганга, кыш көне ката икән. Мәхмүд бине Сөләйман әл-Көффәви «Игълам әл-әхбар»да: «Озын, киң, тирән, анда батучыларның бик азы котыла», – дип сыйфатлады. Тәрҗемә итүче фәкыйрь әйтә: «Ител» шәһәре дигәннәре, – әлбәттә, хәзерге гасырыбыз теле буенча «Хаҗитархан» шәһәре дип әйтелә торган шәһәр. «Әштерхан» шәһәрен ясалма рәвештә «Хаҗитархан» дип атаганнармы яки икенче бер кешегә бәйләп шулай дигәннәрме? Аны тагын «Әждәрһан» дип тә йөргәннәр.

«Болгар» дигән исемгә каршы куеп, «хәзәр» дип аталганда, Хаҗитархан, Кызлар һәм Кубан якларында булган нугай кабиләләре һәм башкалар күздә тотыла булса кирәк. Дөресендә

---

[1] Хирхиз – кыргыз. Кайбер гарәп галимнәре елганың башын Кама елгасыннан дип исәпләгәннәр.

[2] Газия – уз-угыз – төрек кабиләләре.

болгар һәм хәзәр теле бер булса да, бу ике өлкәдә яшәүчеләрнең телләре арасында байтак кына аерма да бар. Шул җәһәттән телләре бер дип әйтелү дә яки башка-башка дип әйтелү дә дөрес булыр. Болар һәр икесе татар теле булсалар да, казах һәм чыгтай төркиләре телләрендәге кебек, аермалары байтак күренә.

Бортас турында әйтелгәннәр

Бу исемне ноктасыз «т»[1] хәрефе белән, кайбер очракта «Бордас» дип «д» белән дә әйткәннәр. Камуста: «б»ның заммәсе белән[2], исем һәм бер кавемнең исеме, аларның киң мәмләкәтләре бар, Рум җире белән чиктәш», – диелә. Шәмсетдин әд-Димәшкый: «Бортаслар Иделгә килеп кушыла торган «Бортас» елгасы буена утырган аерым бер кавем булып, аларның өйләре агачтан, ә чатырлары киездән эшләнгән була, тора торган җирләренең бер чигеннән икенчесенә 15 көнлек юл, үзләренә махсус телләре бар», – ди. Әбү Габдулла әл-Гарнатый: «Бортас – бер кавемнең исеме, Идел елгасы буенда киң мәмләкәтләре бар. Хәзәр белән чиктәш, араларында башка халык юк. Үзләренә бәйләп илләре дә «Бортас иле» дип атала. Телләре болгар һәм хәзәр телләренә башка. Гарәп илләрендә бортасларга бәйләнешле исем белән эшләнгән бортас туны кияләр. Бортасларда бертөрле бик күркәм кызыл йонлы төлке бар. Бортас туны әнә шул төлкедән эшләнә. Үзләре мөселман булып, җомга укыла торган мәчетләре бар», – ди.

Әбү Гали бине Дасә әйтә: «Бортас Хәзәр белән Болгар арасында утырган, Хәзәр патшасына буйсыналар. Аралары унбиш көнлек юл, алар Болгар чигеннән өч көнлек юлда тигез җирдә яшиләр. Җирләре болын, тугай, тыгыз агачлык, күбрәге каен агачы. Аларда ун мең атлы гаскәр җыела. Аларда корал, игенчелек һәм хайван асрау бар, болгарлар, алар белән сугышып, аларны әсир итеп алалар. Сәүдә өчен мөселманнар көймәсе

[1] Ноктасыз «т» – гарәп әлифбасында «т» һәм «з» авазлары бер үк төрле сызыклар белән бирелеп, бер-берсеннән өске нокта кую белән аерыла. Ноктасы булмаса – «тъ», ноктасы булса, «зъ» укыла.

[2] «Б»ны заммә белән әйтү «бо» дип әйтү була.

килсә, алардан гошер[1] алалар, акчалары юк, акча ислам йортыннан гына килә, күбрәк маллары «дылк»[2] дигән кечкенә бер җәнлек. Алар патшаларына хайваннар бирәләр. Киемнәре һәм каберләре мөселманнарныкы кебек, һәр мәхәлләләрендә бер шәехләре була, аңар хөкемгә киләләр, шуннан башка хакимнәре һәм башлыклары юк». Бу юлларны язучы фәкыйрь әйтә: «Хакимнәре юк, патшаларына хайван бирәләр» дигән сүзнең мәгънәсе – «үзләреннән хакимнәр юк, Хәзәр яки Болгар патшаларына хайван бирәләр» дигән сүз булыр. Ибне Дасәнең сүзеннән аларның мөселман булмаулары һәм хәзәргә буйсынганлыклары аңлашылды. Бу сүз аларның исламга кереп, Болгар әмиренә буйсынуларыннан элекке хәлләре турында әйтелгән булыр[3]. Яшәгән җирләре Болгарга бик якын урында, Казаннан түбән, Саратовтан югары була. Якут әл-Хәмәви Бортасны бер шәһәр һәм өлкә исеме, алар мөселманнар, зур мәчетләре бар, алардан ерак түгел «Сувар» дип атала торган бер шәһәр бар, аларның телләре төрки, хәзәр һәм болгар телләре шикелле түгел, – ди. Әбү Исхак әл-Истахри әйтә: «Аларның ике шәһәрләрендә ун мең кадәр халык бар дип хәбәр бирде миңа хатыйплары. Аларның өйләре агачтан булып, кыш көнендә шунда торалар, җәй көнендә чатырларда, ягъни киез өйләрдә торалар, мәмләкәтләренең бер ягыннан икенче як чигенә кадәр унбиш көнлек юл, Хаҗитарханга егерме көнлек юл», Мәсгуди аларны «төрки кавеменнән», – ди. Әбү Габдулла әл-Гарнатый: «Болгар – шәһәр исеме, анда җомга укыла торган мәчет бар, якында «Сувар» исемле икенче шәһәр бар, аның да җомга укыла торган мәчете бар, бу ике шәһәрдә ун мең өй бар», – ди. Бу юлларны җыючы фәкыйрь

---

[1] Гошер – уннан бер (малның, игеннең уннан бер өлеше).

[2] Дылк – сусар.

[3] Ш. Мәрҗанинең бу фикере тарихи яктан караганда дөрес булырга тиеш. Чөнки ибне Дасә (ибне Рөстә) бу тирәләрдә IX йөз ахырларында, әле ислам таралып өлгермәгән чакта йөргән. Әбү Исхак әл-Истахри исә Ибне Дасәдән бераз соңрак, X йөздә йөри. Монда инде бортас халкы ислам кабул иткән, әмма болгарлар белән аралашып, уртак телгә күчеп өлгермәгән булырга мөмкин.

әйтә: Бу бортас халкының нинди халык икәнлеге безгә мәгълүм булмады, без белгән «Сувар» шәһәренең хәрабәсе Спас өязендә шәһре Болгарга бик якын бер җирдә. Шул тирә мөселманнары әле дә «Сувар» дип йөртәләр. Әйләнәсендә урын бар, җимерелгән шәһәр урынында бер рус авылы утыра, аны үзләренчә «Иске Курсиха» дип атыйлар. Тирә-ягында күчмә халыклар яшәгән, алардан калган иске каберлекләр бар, каберләре бик беленеп торалар, аларны «нугай халыклары» диләр. Аллаһ белә: бортас халкы шул тирәдә яшәгән халык түгелме икән диясе килә, аларның телләре хәзер дә Казан мөселманнары теленә бераз башка. Тау ягында Тәтеш өязендә «Олы Бортас», «Кече Бортас» исемле ике авыл бар. Хайваннарда була торган бертөрле авыру хәзерге татар телендә «бортас» дип йөртелә. Шуңар охшатыпмы, яки башка берәр сәбәп беләнме, симез, тулы, тыгыз итле, таза кешене һәм хайванны да «бортас кебек» дип атау бар. Дөресен Аллаһ белә.

Башкортлар турында әйтелгәннәр

Ибне Фазлан әйтә: «Болгарга сәфәр кылган вакытыбызда төрекләрдән бер кавемнең йортына кердек, ул кавемне башкорт диләр. Без алардан бик сакландык, чөнки алар төрек халкының усалрагы һәм батыррагы. Бер ир бер иргә очраса, бүреген салып исәнләшеп китә... Аларның кайберләре унике тәңрем бар, ягъни кыш тәңресе, җәй тәңресе, яңгыр тәңресе, җил тәңресе, агачлар тәңресе, кешеләр тәңресе, хайваннар тәңресе, көн тәңресе, төн тәңресе, тереклек тәңресе, үлем тәңресе һәм җир тәңресе бар, ә күктәге тәңре боларның иң олысы булып, ул аларны бергә җыя, алар берләшеп, һәркайсы икенче иптәшенең эшләгән эшеннән риза булып, киңәшеп эшлиләр дип уйлый». Безнең тәңребез залим һәм тискәреләрдән гаять дәрәҗәдә бөек. Янә болай ди: «Без алардан җыланга табынган, балыкка табынган һәм торнага табынган кавемнәрне күрдек. Аларның сәбәпләрен миңа болай дип аңлаттылар. Бервакыт дошманнары белән сугышканда, дошманнары, боларны җиңеп, качарга мәҗбүр иткәннәр. Шул вакытта артларыннан бер торна кычкырган. Шуны ишетеп кире

кайтканнар да дошманнарын җиңеп качырганнар. Шул вакыттан бирле: «Ходабыз дошманыбызны качырды», – дип, торнага табына башлаганнар».

Якут әл-Хәмәви «Мөгъҗәмел-бөлдан»да «ш»ның сәкене һәм калын әйтелешле г (гъ), кайберәүләрчә, «башҗрт» дип «җ» белән, ә кайберәүләрчә «башкорт» дип калын әйтелешле к (къ) белән әйтелүен сөйли дә, Константиния белән Болгар арасында булган ил дип әйтә. Ибне Фазлан сүзләрен китергәннән соң болай ди:

– «Хәләб шәһәрендә мин байтак кешеләрне күрдем. Аларны «башкорт» дип йөртәләр иде. Җирән төкле, йөзләре кызыл төсле, имам Әгъзам мәзһәбе буенча дин гыйлеме өйрәнәләр иде. Аларның бер акыл иясеннән йорт-җирләре, хәлләре турында сораштым, ул болай диде: «Безнең илебез Константиния артында, әфрәнҗдән[1] бер «һәнгәр» дип йөртелә торган халык мәмләкәтендә. Без – мөселманнар, аларның патшаларына буйсынган халык, мәмләкәтнең бер ягында безнең утызлап зур-зур авылларыбыз бар, һәркайсы кечерәк бер шәһәр булырлык, ләкин Һәнгәр патшасы, баш тартырлар дип куркып, шул авылларга ихата эшләргә безгә рөхсәт бирми. Без христиан шәһәрләре уртасында яшибез. Төньягыбызда сәкалибә иле, көньягыбызда Баба Румия[2] шәһәрендә әфрәнҗләр башлыгы. Алар фикеренчә, әмирел-мөәмининнең[3] барлык ислам патшалары һәм солтаннарына хөкемнәре йөргән шикелле, әлеге баба да Гайсаның[4] җирдәге вәкиле булып, аларның диннәренә бәйле бөтен эшләрдә аның боерыклары йөри икән. Көнбатышыбызда Әндәлес мәмләкәте, көнчыгышыбызда Рум, Константиния иле. Безнең телебез дә, киемебез дә шул әфрәнҗләрнеке шикелле, алар белән бергә гаскәрдә хезмәт итәбез, алар белән бергә сугышабыз, чөнки алар һәрбер кавем белән түгел, бәлки ислам

---

[1] Әфрәнҗ – европалы.

[2] Баба Румия – Рим папасы түгелме? Ш. Мәрҗани «п» урынына «б» куллана түгелме? Хәзер дә гарәпләр Рим папасын «баба» дидер.

[3] Әмирел-мөәминин – хәлифә.

[4] Гайса – Гайсә пәйгамбәр (Иисус).

диненә каршы килгән кавемнәр белән генә сугышалар», – ди. Мин тагын кяферләр эчендә мөселман булып утыруларының сәбәбен сорадым. Ул әйтте: «Мин бабаларыбыздан калган сүзне ишеткән идем: борын заманда Болгар иле мөселманнарыннан җиде кеше безнең илебезгә килеп, шунда торып калганнар. Алар безнең ялгыш юлда яшәвебезне күреп, безне дөрес һәм туры булган ислам диненә күндерделәр; алар ярдәмендә Хода безне хак юлга күндерде, күңелләребезне иманга ачты, әлхәмдүлиллаһ, барыбыз да мөселман булдык, инде без бу шәһәргә килеп, дин гыйлеме өйрәнеп кайткач, кавемебез безне хөрмәт белән каршы алалар һәм дин эшләрен безгә тапшыралар», – диде. «Сакалыгызны да әфрәнҗ кебек кырасызмы?» – дип сорадым. «Гаскәри хезмәттәгеләребез кыралар һәм корал кияләр, башкаларыбыз болай эшләмиләр», – дип җавап бирде. «Безнең ил белән сезнең илегезнең арасындагы ераклык күпме?» – дип сорадым. Ул: «Моннан Константиниягә ике айлык юл, аннан безнең илебезгә тагын шулкадәр», – дип җавап бирде.

Әмма Әбү Исхак әл-Истахри әйтә: «Башҗырттан Болгарга егерме биш станция. Пәчнәккә[1] – ун көнлек юл; алар да – төрек халкының бер төркеме, башкорт халкы үзе ике төркем булып, берсе Болгар артында, Болгарга буйсынган ике йөз меңләп кеше, урыннары бик мәхкәм,[2] икенче төркеме – Пәчнәккә чиктәш», – ди.

Әбү Гали ибне Дастә әйтә: «Әл-Мәҗгария[3] бәхтакия[4] иле белән Болгариядән әшкәл[5] арасында төрек нәселеннән бер халык булып, рәисләренә «кәндә» дип исем бирәләр. Егерме мең атлы гаскәре бар. Якын тирәләрендәге сәкалибәнең барын

---

[1] Пәчнәк – бәҗнәк – бәҗәнәкләр (шул вакыттагы бер халык).

[2] Мәхкәм – ныгытылган, таза.

[3] Әл-мәҗгария – маҗар – венгер.

[4] Бәхтакия – бәхтакия – бәҗәнәкләр.

[5] Әшкәл – Д.А. Хвольсон текстында бу – «әскәл» формасында. «Әшкәл» формасын ул әл-Бәкридән китерә. Күрәсең, Ш. Мәрҗани моны әл-Бәкри текстыннан алган. Галимнәр бу кавемне көньяк болгарлар яки венгерлар булырга кирәк дип уйлыйлар.

да яулап алып, аларны әсир хөкемендә тоталар, үзләре утка табыналар», – ди.

Әбү Хәмид әл-Әндәлеси: «Болгар, хәзәр һәм бәхтаклар озын кафтан, руслар кыска кафтан кияләр, башҗырт болгар кул астында», – ди.

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: югарыда әйтелгән «Мәҗгария» башкорттан бер җәмәгать булса кирәк. Гасырыбызда руслар тарафыннан билгеләнеп куела торган рәисләрен «кантон» дип атау «кәндә» дигән сүздән алынган булса кирәк. Бәләбәй өязендә Ирәктай кабиләсеннән Чокыр[1] авылы имамы мулла Гали бине Салихның әйтүенә караганда, аларның нәсел-нәсәпләре болай икән: Гали бине Салих бине Габдулла бине Шәриф бине Киек бине Барак бине Исәнхан бине Дәүләтбай бине Дәүләтьяр би бине Ходаяр би бине Ходайколый би бине Дүрмән би бине Кылман би бине Чулман би бине Абдал би бине Әхмәдшәех би бине Каратабын би бине Болгаер би бине Вальҗак би бине Иләк би бине Майкый би. Кара Табан бине «Кара Газиз» дигәннәр, Әхмәд Шәех бине «Ирәктә» дигәннәр, безнең ыруыбыз ошбу затка бәйләнә. Әүвәлдә Урал тарафында «Миядәк» дигән урында «Мияҗ» елгасы буенда булып, соңыннан Чулман буена килгән. Чулман би әнә шунда дөньяга килгән. Бабаларыбыз үзләренең нәсел-нәсәпләрен Чыңгыз ханның юлдашы Майкый бигә тоташтыралар. Ул, Чыңгыз ханга аның анасыннан йөзек алып барып тапшырганы өчен, Чыңгыз ханга бик ошаган, аның белән бер арбада утырып йөргән, аны уешин[2] Майкый би дигәннәр.

Исән хан Казан ханнарыннан Чуртмак ханга буйсынган булган, йорты «Җиремче» авылында диелә. «Чокыр» авылында

---

[1] Чокыр авылы мелла Гали Салих углы – шагыйрь Гали Чокрый булырга тиеш. Ш. Мәрҗанинең «Мәҗгария»не башкорт халкыннан бер төркем дип санавы башка чыганаклар буенча да раслана, «Мәҗгария» – мажар, мадьяр, венгер. Венгерлар үзләренең башкортлар белән бер нәселдән булганлыкларын инкяр итмиләр. Ләкин бу очракта «кәндә» сүзеннән «кантон» килеп чыгу ихтималы ераклаша. Төрле тарихи чыганакларда бу «кәндә» сүзен төрлечә аңлатканнар.

[2] Уешин – кушылган, дуслашкан.

«Чырганкол» дип аталган урында икәве чырганга, ягъни уздырышырга, төбәлгән нәрсәгә ук атышып һәм батыры белән көрәшеп, һәрберсендә Исән хан өстен чыккач, Чуртмак хан, хурланып: «Өстегезгә гаскәр белән киләмен», – дип куркытып киткән. Моннан Исән хан һәм халкы, куркып, кайгырып, Чуртмак ханны юлда хәйләләп үтереп, соңыннан Казанлыларның үч алуларыннан куркып, руслар белән килешкән, ахырда бөтенләй Россия кул астында калган. Ул урын хәзергә кадәр «Чырганкол» дип, тагын икенче бер билгеле урынны «Исән хан угы төшкән җир» дип атыйлар. Аллаһ белә, бу Чуртмак Казан ханы булмыйча, Казан ханы тарафыннан бу җәмәгать өстеннән карап торырга куелган бер кешесе генә булырга кирәк. Сүзе шушы. Бу вакыйга Казанда мөселман хөкүмәте вакытында була, ләкин Казан ханнары арасында мондый исемле хан юк. Исән ханга барып тоташканчы саналган бабалары аз, ул заманга кадәр күбрәк булырга кирәк иде. Ләкин башкорт халкының Казан ханнары хөкүмәтеннән аерылып, Россиягә буйсынуны ихтыяр итеп, җирләре, мал-туарлары һәм башка милекләре үзләрендә калып, салым түләүдән бөтенләй азат ителүләре халык телендә сөйләнә һәм аларның «Без – гасабә»[1] дип мактанулары билгеле, хәтта әлегә кадәр алар – татарлар, мишәр һәм башкалар биргән шикелле – Россия хәзинәсенә бернәрсә дә бирмиләр; фәкать кайбер вакытларда рус гаскәренә кушылып сугышларда булгалаганнар. Наполеон Бонапартның Россияне җиңеп Мәскәүгә кергән вакытында «Россиягә дөрес хезмәт күрсәткәннәр» дип сөйләнә. Чынлап та алар гайрәтле, оста ук атучы, мал-туар һәм киң җир хуҗалары, ләкин унбиш еллап инде, җирләре сатыла башлап, башкалардан алган шикелле болардан да имана ала һәм 21 яшенә җиткән егетләрен гаскәри хезмәткә ала башладылар... Икенче бер риваятькә караганда, Россия халкы Казан мәмләкәтен яулап алганнан соң, тугыз йөз туксан беренче (1583) елда Чулман елгасының икенче ягындагы татар, башкорт мөселманнардан үз мәмләкәтен саклау сылтавы

[1] Гасабә – патшага якын кеше, кавем.

белән Минзәлә шәһәрен корды һәм әкренләп үз ирке белән буйсынган башкорт иленә керде һәм Чулман елгасын үтеп, яулап алды...

Кыпчак турында әйтелгәннәр

Икенче төрле итеп бу исемне «Хыфшаг», «Хыфшах» һәм «Хыфчаг» дип тә йөриләр. «Әхтәри» исеме белән мәшһүр булган Мостафа бине Шәмсетдин әл-Акхасари: «хыфчак» – тәрҗемәдә «татар биге» дигән сүз булып, асылы «кыпчак», – дидер. Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Аларның тора торган җирләре Дәрбәнд – Ширван артында Бәхре руска[1] якын тауларда, урманнарда булган. Аларның шәһәрләре «Сердык» исемле булып, бу диңгез дә шуларга каратыла. Аннан ашлык китерәләр, сәүдәгәрләр анда үзләре алып барган киемлекләрне һәм башка нәрсәләрен сату, кол, кәнизәк һәм кондыз сатып алу өчен баралар. Мисырда, Шамда алардан бик яхшы гайрәтле кешеләр бар. Мисырда булган төрек патшалары күбрәге алардан. Кыпчак таифәсе барысы да төрек, алар «бәркева», «туксыба», «исба», «бәрт», «әрс», «Бәрех углы», «Мәңгү углы» һәм «өмәк» – болар харәзми булдылар. Тагын кыпчакның «тыйг», «башкут», «каләнҗ», «бизанге», «бәҗна», «кара бүклү», «аз», «җыртын» h.б. вак-вак төркемнәре күп».

Гыйззетдин Әбү әл-Хәсән бине әл-Әсир әйтә: «Кыпчак илендә кышын һәм җәен хайваннар утлый торган җирләр, көтүлекләр бик күп. Җәй өчен салкынча, кыш өчен җылы урыннары, диңгез буенда урманнары бар. Аларның шәһәрләре – «Сердык» шәһәре – Хәзәр диңгезе буенда утырган. Татарлар аларны әүвәл алдалап, соңгарак басып алып, тәмам һәлак итеп бетерделәр», – ди. Бу фәкыйрь әйтә: «Кыпчак гәрчә Болгар халкы белән карендәш һәм ватандаш булсалар да, руслар белән берләшеп, аларга ярдәм итеп, болгарларга бик күп зарар иттеләр, ләкин татарлар күтәрелеп чыкканда, бу эшләрнең җәзасын бик нык татыдылар. Бу кыпчаклардан таралган Кырым,

[1] Бәхре рус – бу исем астында Кара диңгез күздә тотыла булса кирәк.

Урта Азия һәм Казахстанда әле дә шул исем белән йөргән кайбер кабиләләр бар. Мең ике йөз утыз җиденче (1821–1822) елда алар, Мөхәммәдрәхим хан әл-Харәзминең өндәве сәбәпле, «кытай», «кара-калпак» һәм «кинәгәс» кабиләләре белән берләшеп, Бохара әмире Хәйдәр бине Мәгъсүм бине Даниял әл-Мангытыйга каршы күтәрелеп, байтак кына фетнәләр, авырлыклар эшләделәр, әмир Хәйдәрне тынычсызлыкка, куркуга салдылар. Мең ике йөз илленче (1834–1835) елда Бохара патшасы әмир Насрулла бине әмир Хәйдәр, аларның Фирганә өлкәсендәге таифәләренә – Хоканд мәмләкәтенә һөҗүм итеп, патшаларының сараена кереп, Мөхәммәд Гали ханны һәм аның энесе Мәхмүд ханны үтереп, Фирганә патшалыгын үз дәүләтенә куштым дип уйлап, анда «мангыт» кабиләсеннән Ибраһим Пәрванәчене вәли[1] итеп билгеләп, Бохарага кайтты. Аның Бохарага кайтуы соңында ук кыпчактан Мөселманкол чулак, үз кабиләсе белән аякка басып, үтерелгән ханның ир кардәшләреннән Ширгали бине Хаҗи бик исемле бер кешене хан итеп билгели һәм зур шау-шу белән Хокандка килеп керә, Ибраһим Пәрванәче, көч-хәл белән качып котылып, Сәмәркандка кайта. Мөселманкол Ширгали хан исеменнән Фирганәне тәмам кулга алды. Шуннан соң әмир Насрулла, икенче мәртәбә Хокандны кайтарып алу теләге белән барса да, кырылып кайтудан башка эше булмады. Бер мәртәбә ул, Мөселманколның мәкер-хәйләсеннән бик каты куркуга төшеп, Хүҗәндтән бик ашыгып кайтып килде. Мәсьәлә болай була: Мөселманкол әмиргә ике кешелек илче җибәрә һәм боларга әйтә: «Мин сезгә тагын ике кеше кушам, сез әмир белән очрашкач та, без ике кеше илче, әмма бу ике кеше безгә юлда кушылдылар, без аларның кем икәнлекләрен белмибез дип әйтегез. Әмир шунда ук аларны тикшерергә кушар», – дигән. Әмир тотып тикшергәч, бу кешеләрнең яннарыннан Мөселманкол кулы белән ханның гаскәр башлыкларына: «Сез вәгъдәгез буенча эш кылып, әйткән вакытта әмир гаскәренә эчтән, без тыштан һөҗүм итеп, әмирне һәм иярченнәрен һәлак

[1] Вәли – өлкә башлыгы, губернатор.

итәрбез», – дип язылган хатлар табылган. Әмир, бу бичараларны үтереп, гаскәрен артта калдырып, үзе качып кайткан.

Бу мәмләкәттә булган халыкларны, күп төрле кавемнәрне эченә алган киң ил, аларга нисбәт бирелеп, «Дәште Кыпчак»[1] дип аталды. Алар белән бәйләү – әүвәлдә бу мәмләкәттә яшәүче халыкларны кыпчаклар яулап алып, аларны моннан куып җибәреп, үзләре шул ватанның иясе булып калулары сәбәпле булса кирәк; чөнки тарих китапларында «Яфәс бине Нухның Идел, Җаек елгалары арасында урнашып, шунда нәсел-нәсәбе таралды, Угыз хан кыпчакны Идел буена җибәреп, ул башкорт, маҗар, рус, борҗан һәм әфлак таифәләре белән сугышты» дип сөйләнә. Гомумән, бу мәмләкәттә булган сәкалибә, хәзәр һәм болгар халыклары кыпчакка буйсынган булып, боларның күзгә иң бәрелеп торган сыйфатларына карап, аларга сәкалибә һәм хәзәр исемнәре биреп, ул мәмләкәттә булган бикләр, рәисләр барысы да әүвәлдә хәзәр хаканы, соңыннан болгар әмире хөкүмәтендә булып, әкренлек белән генә болгар әмирләре исламга кереп, хәлифәгә таянып, хәлифәнең мәгънәви ярдәмнәре аркасында сәяси куәт табып, ислам аркасында яхшы холык һәм күркәм сыйфатларга ия булып, хәзәр патшасы хаканга өстен була, ә хакан дәүләте зәгыйфьләнеп, бара-бара бөтенләй юкка чыгуы моннан алда һәм моннан соң сөйләгәннәрдән беленә. Гарәп сәяхәтчеләренә башта чиктәшләре, янәшә күршеләре булган Сәмәндәр, Хәмлиҗ, Бәләнҗәр һәм Идел тарафларында хәзәрләр күренеп, шул илдә булган халыкның барын да «хәзәр» исеме белән атыйлар. Шуннан соң шәһре Болгарны һәм аның хәлен белеп алгач, аны хәзәргә каршы куеп сөйләгәннәр. Кыпчакны Хәзәр һәм Болгарга каршы куеп сөйләүләре төрле вакытта булган үзара бәрелешләр яки төрле-төрле мәмләкәтләр төзүләре сәбәпле булса кирәк.

---

[1] Дәште Кыпчак – кыпчак даласы.

Руслар турында әйтелгәннәр

Шәмсетдин әд-Димәшкый һәм башкаларның сөйләүләренә караганда, руслар, асылда, бер атауда[1] яшәп, аларда җир, игенчелек булмыйча, кеш, тиен, сусар аулап, шуларның тиреләрен сатып кәсеп иткәннәр. Сәкалибәгә каршы сугышып, алардан әсир алып, болгарларга, хәзәрләргә сатканнар. Рус таифәсе, асылда, өч төркем булган: берсе славяннар, икенчесе Бармания, өченчесе Бабармадыр[2]. Болгарга якын төркемнең хөкемдары Киев шәһәрендә иде. Ул шәһре Болгардан зуррак. Өч йөз җитмеш бишенче һиҗри, тугыз йөз сиксән биш – сиксән алтынчы милади елларда дәүләтләре төзелде. Дәүләтләренең башлануы тарихчылар каршында шул еллардан дип йөртелә. Ләкин алар милади Гайса галәйһиссәламнән биш йөз ел үткәч үк чит ил халыкларының һөҗүменнән саклану өчен, башлап, Новгород шәһәрен, аннан соң Киев шәһәрен бина кылып, патша итеп билгеләү өчен Германия мәмләкәтеннән патша булырга яраклы бер кеше сорадылар. Аларга ике йөз кырык сигезенче һиҗри, сигез йөз алтмыш икенче миладидә Рюрик, Синиус, Трувер исемле өч туган килеп, олылары Рюрик, Новгородта утырып, ике йөз илленче (864–865) елда ике туганы үлгәннән соң, Киевны һәм башка җирләрне алып, үзе мөстәкыйль булып калды. Безнең ошбу гасырыбызга кадәр Россия хөкемдарлары өч ханәданнан[3] тора.

Беренче – Рюрик династиясе мең алтынчы һиҗригә (1597–1598) кадәр хөкүмәт тоттылар. Икенче – Романовлар династиясе хөкүмәте булып, дәүләтләре мең бер йөз җитмеш дүртенче (1750) елга кадәр дәвам итә. Өченчесе – Гольштейннар

---

[1] Д.А. Хвольсон кайбер гарәп сәяхәтчеләренең «руслар утрауда яшиләр» дигән сүзләрен дөрес түгел ди. Русларның бер төркеменең башкаласы Киев шәһәре булуы үзе үк шуны күрсәтә. Д.А. Хвольсон гарәп телендә утрау белән ярымутрауның ачык аерылып бетмәве, Европаны аларны гомумән утрау дип санауларын яза.

[2] Д.А. Хвольсон Бармания – Новгород, Бабарма – Пермяклар дип уйлый.

[3] Ханәдан – династия.

династиясе патшалыгы булып, безнең көнгә кадәр сузыла[1]. Башкалалары биш: беренчесе Новгород, икенчесе Киев шәһәре булып, биш йөз кырык икенче (1147–1148) һиҗригә кадәр килә. Өченчесе – Владимир шәһәре җиде йөз егерме алтынчы (1325–1326) һиҗригә кадәр дәвам иткән. Дүртенчесе – Россия хөкемдары Георгий Долгорукий дигән кеше биш йөз кырык икенче ел (1147–1148) һиҗридә Мәскәү елгасы буенда «Күчкәй» авылы урынында бер шәһәр салып, бераз вакыт «Күчкәй кальгасы[2]» исеме белән йөртелеп, соңыннан әлеге су исеме белән «Мәскәү» дип аталды, һәм Россия хөкемдарларының башкаласына әйләнде. Мең бер йөз ундүртенче (1702–1703) елда Пётр I Финляндия җирендә Нева елгасы буенда Петербург шәһәрен бина кылып, аны башкала итеп алганчы һәм аннан соң да, хәзергә чаклы, Россия патшалары барысы да Мәскәүгә килеп таҗ кияләр.

Алар элек, төрле-төрле патшалыклар кебек яшәп, фәкать чит ил дошманнары зарарыннан саклану өчен, бергә җыела торган булганнар. Элек Новгород хөкемдары, соңыннан Мәскәү хөкемдары рәис була һәм аны «Олуг князь» дип атыйлар иде. Хөкемдарның вафаты соңында аның никадәр баласы булса, мәмләкәт шуларга аталарының мирасы итеп бүленеп бирелә, һәрберсе үзенә тигән өлешне, хәтта шунда яшәүчеләрне дә, хосусый милек итеп саный, аларны сатарга да, сатып алырга да хаклы саный, шуңа күрә Россия халкының күпчелеге безнең вакытка чаклы үзләренең олылары – хуҗаларының коллыгында булып килделәр. Кырым сугышыннан соң Александр икенче вакытында мондый хәл юкка чыгарылды.

Элек хөкемдарларына патша исеме бирмичә, фәкать «бик» мәгънәсендә булган «князь» исеме бирәләр иде. Элек Александр Невский, Иван Дуни һәм Иван Калиталар уйлаганча, вак патшалыкларны берләштерүне Иван III Василий углы гамәлгә ашырып, Россия мәмләкәтенә мөстәкыйль патша булды.

---

[1] Бу турыда карагыз: «Большая Советская Энцеклопедия», 2 нче басма.

[2] Кальга – крепость.

Сигез йөз илле җиденче (1453) елда Солтан Мөхәммәд бине Морад әл-Госман әл-Фатихның Константинияне яулап алу сугышында үтерелгән Рум кайсарларының[1] ахыргысы булган Палеолог Драгуҗ исемле кайсарның туганы Томасның Софья исемле кызы Россиягә качып килгәч, рус хөкемдары Иван аңар өйләнде. Шуның белән кайсарларның рәсми галәмәтләре булган ике башлы бөркет сурәтен үз рәсеменә кушып, үзен кайсарларның варисы, аларның урынын тотучы кебек итеп, «кайсар» дигән сүздән бозылган «царь» исемен үзенә тага һәм моннан соңгы хөкемдарлар барысы да шул исем белән исемләнеп китәләр. Мең бер йөз утыз өченче һиҗри (1720–1721) елда Швеция мәмләкәте белән солых ясаганнан соң, Пётр I не мәмләкәт халкы «бөек» һәм «мәмләкәт атасы» һәм «император» дигән олы исемнәр белән зурладылар. Моннан соңгыларга да бу исем мирас булып калды. Гомумән, Россия хөкемдары эчендә безнең гасырыбызга кадәр унөч император, ун царь һәм бик күп санда князьләр булган. Россия халкы мәҗүсияттә яшәгән. Башлап дүрт йөз алтынчы (1015–1016) һиҗри елда вафат иткән Владимир бине Всеволод бине Изяслав бине Ярослав бине Владимир исемле хөкемдар өч йөз җитмеш бишенче (985–986) елда христианлык диненә кереп, кавеме аңар ышанычлык күрсәттеләр, аңа иярделәр. Бу хөкемдар Владимир, мәмләкәтне берникадәр ислах кылып, данын күтәреп, үзе «бөек» кушаматы белән исемләнде. Рум дәүләте белән сугышып, аларның берникадәр җирләрен яулап алды һәм ике император Василиус һәм Константиннарның кыз кардәшләрен алып, солых ясап, яулап алган җирләрен кайсарларга кайтарып биреп, кайтып китте. Әмма ибне әл-Әсир рәхмәтуллаһи галәйһи: «Дошманнарына каршы ярдәм күрсәткән өчен, аңа кыз кардәшләрен бирделәр», – ди. Хатыны башка диндә булуы сәбәпле, үзенә буйсынудан баш тарткач, Владимир христиан диненә керде. Моннан соң аларның сораулары буенча Константиниядән Фотиус исемле патриарх, дин өйрәтү өчен, Михаил исемле епископны һәм башка ике

[1] Кайсар – император.

кешене җибәреп, дин һәм дини гадәтләрне өйрәттеләр. Шулай ук Россия гыйбадәтханәләре барысы да Рум патриархларына буйсынып, гыйбадәтләре грек телендә үтәлде. Тугыз йөз туксан алтынчы (1587–1588) һиҗридә үзләренә махсус патриарх билгеләделәр. Мәзһәбләре – Рум мәзһәбе, ягъни ортодоксаль мәзһәб. Заманыбызда Николай Павлович ахыргы елларында Кырым сугышлары вакытында, үзләренең уйларынча «дөрес мәзһәб» мәгънәсендә булган «Православие» дип атадылар.

Патриарх һәм аның карамагындагы рухани башлыклар дини киемнәрдә, папас сурәтендә, ягъни рухани патша булып, мәмләкәт эшләренә дә бик нык катнашалар иде. Пётр I: «Дин эше бик зур эш ул, бер кешенең генә акылы җитә торган түгел, бер кешегә генә ышану да мәгъкуль эш түгел, бәлки күпләрнең берләшкән уйлары, фикерләренә таяну кирәк», – дигән сылтау белән, Россия мәмләкәтендә патриархлыкны бетереп, берничә әгъзадан гыйбарәт булган махсус руханилар синоды төзи. Синодның рәисен митрополит итеп, дин эшләре буенча шул мәхкәмәгә мөрәҗәгать итәләр. Шуның өстенә ул мәхкәмәдән мөстәкыйльлек алынып, эчке эшләр министрлыгы карамагында калдырылды.

Россия хөкемдарлары – безнең гасырыбыз мең өч йөз өченче (1885) һиҗригә кадәр өч династиядән.

Беренче – Рюрик, аннан соң – хатыны Ольга, аннан – углы Игорь. Аннан – хатыны Ольга – Рум иленә Константиниягә барып, христиан диненә керде. Аннан – углы Святослав; анасы белән бергә христианлыкка керүдән баш тартып, ата-бабасы юлында калды. Аннан соң – Ярополк, аннан соң – Владимир. Владимир заманында Россия халкының даны, дәрәҗәсе артып, кайсарларны җиңеп, аларның кыз кардәшләренә өйләнеп, солых кылды. Дин сайлау мәсьәләсендә икеләнеп калып, шәһре Болгардан ислам галимнәре, муллалар, Истанбулдан папаслар[1] чакырды. Папаслар алтынлаган тәреләр алып килеп, һәркайсысы үз диннәренең хөкемнәрен, тәртипләрен төшендергәч, ислам диненә

[1] Папас – Рум руханилары башлыгы, монах.

күңеле төште, аны кабул итәргә якынлашты, ләкин мөселманга аракы эчү һәм дуңгыз ите хәрам икәнен сөйләгәч, алардан башка тормыш кызык түгел дип, христиан диненә керде, халкының күбрәге шуңа иярде. Унике углы бар иде, алардан берсе атасына каршы чыгып, күп низаг һәм торгынлык килеп чыкты. Дүрт йөз алтынчы (1015–1016) һиҗридә вафат булды. Аннан соң – углы Святополк. Аннан соң – туганы Ярослав, илдәге торгынлыкны бетереп, патшалык законнарын урнаштырып, дәүләтне ислах кылды, дүрт йөз кырык бишенче (1053–1054) һиҗридә вафат булды. Аннан соң – углы Изяслав, соңра – Святослав, соңра – Всеволод, соңра – Святослав, соңыннан – Владимир, соңыннан – Святослав, соңыннан – Ярополк, соңыннан – Всеволод, соңыннан – Игорь, соңыннан – Изяслав, соңыннан – Георгий, соңыннан – Изяслав, аннан – Святослав. Аннан соң – Андрей Иванович, болгарлар белән сугышып җиңде һәм, шул җиңүне билгеләп, рус халкы һәр ел августның беренче көнен бәйрәм итәләр. Аннан соң – Всеволод Егорович, аннан соң – Михаил, аннан – Всеволод, аннан соң – Константин, аннан соң – Юрий Долгорукий. Бу кеше биш йөз кырык икенче (1147–1148) елда «Күчкәй» авылы урынына шәһәр салдырып, бераз вакыт «Күчкәй крепосте» исеме белән йөреп, аннан соң шундагы елга исеме белән «Мәскәү» дип аталды һәм Россия хөкемдарларының башкаласы булып калды. Аннан соң – Ярослав, аннан – Святослав, аннан – Михаил, аннан – Андрей. Аннан – Александр Невский булып, бу кеше Татар хөкүмәте астыннан чыгып, бөтен Россияне бер кулга кертеп, мөстәкыйль патша булу юлына төшкән иде. Россия хөкемдарлары Татар дәүләтенең йомшара башлаганын күреп, баш күтәреп, Нәүруз бик ханга килеп, үзләрен азат итүне таләп иттеләр. Аннан соң – Ярослав, аннан – Василий, аннан – Димитрий, аннан – Данил , аннан – Михаил, аннан соң – Георгий, аннан соң – Димитрий, аннан соң – Александр, аннан соң – Иван Калита; татарлар аны калталы (янчыклы) Иван дип йөртәләр иде. Бу кеше күңелендә дә әлеге азатлык фикере бар иде. Аннан соң – аның углы Семен, аннан – Иван, аннан – Димитрий, аннан соң – Димитрий Иван углы Донской. Бу кеше, үткәндәгеләрдән ике

зат фикерен тотып, Бүләк хан гасырында бөтен рус халкы белән берләшеп, сугыш ачып, татарларны җиңеп, баш тартучы булды. Соңыннан Туктамыш хан аны яңадан үзенә буйсындырды. Рус таифәсе гасырыбызда халык кулында йөргән биш сумлык кәгазь акчада рәсемен һәм исемен язып искә алалар һәм шөкер итәләр. Моннан соң – углы Василий болгар халкын җиңеп, үзенә «Болгарны яулап алучы» дигән исем бирде. Аннан соң – аның углы өченче Василий Олуг Мөхәммәд хан бине Тимер ханның сарайда патшалык иткән көннәрендә атасы үлеп, туганнан туганы белән бозылышып, Мөхәммәд ханның ярдәме аркасында Россия хөкемдары булып утырды. Заманында шәһре Болгарны, Казанны талап, яндырып, халкын үтерде, әсир итте. Соңгарак Мөхәммәд хан Казанга килеп патша булып утыргач, Мәхмүд һәм Ягъкуб исемле ике углын гаскәр башлыклары итеп җибәреп, бик зур сугыш булып, татарлар җиңделәр, Василийны әсир итеп, Мөхәммәд хан кулында бераз вакыт әсир булып калды. Аннан соң – аның углы Иван өченче сигез йөз илле җиденче (1453) һиҗридә Мәскәү хөкемдары булып, Новгород халкын җиңде, аларның хөкүмәтләрен тар-мар итте. Тугыз йөзенче һиҗри (1494–1495) ел ахырында тәмам Россияне бер кулга кертеп берләштерде. Сигез йөз сиксән бишенче (1481) һиҗри тәмамында Сарай патшасы Шәех Әхмәд, ханга түләп килә торган еллык салымны туктатып, түләүне таләп итеп килгән илчеләрне гадәттәгечә олыламыйча, хөрмәт күрсәтмичә, ханның хатын алып ташлап, аяк астына салып таптап, илчеләрне үтереп, фәкать берсен генә кайтарып җибәрде. Хан, бу эштән бик каты ачуланып, үч алу һәм әдәпкә өйрәтү өчен, Россия шәһәрләрен талап, үтереп, әсир алып, Үгрә елгасына барып җитте. Ләкин ахырда җиңелеп, руслар кулына әсир төшеп үтерелде, һәм Сарай дәүләте таркалды. Шуннан соң сигез йөз сиксән тугызынчы (1484) ел һиҗридә Иван өченче, Казан ханлыгын җиңеп, салым алды, Казанга керде, Мәскәүдә зур биналар салдырды. Кайсарның туганының кызына өйләнеп, үзенә кайсар исеменнән бозылган царь исемен тагып, мөстәкыйль патша булды. Үзеннән элек килеп үткәннәрнең уйлаган эшләрен гамәлгә ашырды, ике башлы кош галәмәтен

кайсарлардан алып, үзенә рәсми галәмәт[1] итеп билгеләде. Тугыз йөз унберенче (1505–1506) ел һиҗридә вафат булды. Үзеннән соң углы Василийның да Казан халкы белән сугышлары булды. Аннан соң углы Иван дүрт яшендә Россия хөкемдары булып, вәкил булып әнисе илне идарә итә иде. Чиксез кан түгүче, явыз холыклы кеше иде. Бу кеше Казан, Әстерхан дәүләтләрен бетерде. Илле ел патшалык итеп, тугыз йөз туксан икенче (1584) һиҗридә вафат булды. Аннан соң углы Фёдор, авыру булганга, патша исеме белән генә канәгатьләнеп, дәүләт эшләрен вәзире һәм каенатасы Борис Фёдорович Годунов үз кулына алган иде. Заманында Себер мәмләкәтен Россиягә буйсындырып, тугыз йөз туксан бишенче (1586–1587) һиҗридә Тоболь крепостен бина кылды, мең дә алтынчы (1597–1598) һиҗридә вафат булды, һәм шуның белән Рюрик династиясе патшалыгы тәмам булды.

Иван IV нең патшалыкка лаек булган углы Димитрий, анасы белән бергә, Углич шәһәренә җибәрелгән иде. Мең дә бишенче (1596) һиҗридә Борис аны юк итеп, Россия патшалыгына үзе хуҗа булып калса да, Григорий Юрьевич исемле бер кеше үтерелгән Димитрийга бик охшаган булуыннан файдаланып, «мин Иван IV нең углы Димитриймын», – дип чыгып, Борис белән кат-кат сугышып, аны җиңеп патшалык тажын кисә дә, кем икәнлеге ачылгач, руслар аны үтереп, гәүдәсен яндырдылар. Борис та, мең дә унөченче (1604) елда агу эчеп, үзен үзе һәлак итте. Аның углы Федор тагын сигез атна үтү белән үтерелде. Тагын берничә зат, Димитрий исеме белән чыгып, ялган Димитрийча эшләп карадылар.

Икенче таифә – Романовлар династиясе

Беренчеләре – Михаил бине Фёдор бине Никита бине Роман бине Юрий бине Захар. Рус таифәсе, патшалар арасындагы бер-берсенә каршылык, баш күтәрү һәм үтерешүләрдән гаҗиз булгач, анасы ягыннан элгәреге хөкемдарларга якын булган 15 яшьлек Михаилны патша итеп куйдылар. Ата-анасын Борис

[1] Рәсми галәмәт – дәүләт гербы.

җәберләп, көчләп монахлыкка җибәргән, ә ялган Димитрий аның атасын епископ рәвешендә Польшага вәкил итеп җибәргән иде. Берничә вакыт Польшада төрмәдә калып, углы хөкемдар булгач, Польшалы әсирләрне азат итү бәрабәренә атасын кайтарып алып, аны патриарх дәрәҗәсенә күтәрде. Хөкемдарлык углы исемендә булса да, эш бу затның кулында иде. Гасырыбызда кулда йөргән ун сумлык кәгазь акчада Михаилның исеме һәм сурәте басылган. Мең дә илле бишенче (1645) елда вафат булды.

Аннан соң – аның углы Алексей илгә законнар төзеде, ефәк һәм башка тукымалар эшләү һөнәрен кертте. 25 сумлык кәгазь акчада аның исеме һәм сурәте басылган. Мең дә сиксән сигезенче (1674) елда вафат булды. Аннан соң аның углы Фёдор булып, мең дә туксан өченче (1682) елда вафат булды. Аның ата-ана бертуган ир туганы Иванның авыру һәм ата бер туган кардәше Пётрның ун яшьлек бала булганлыгы сәбәпле, Пётрны патшалык варисы итеп куеп, һәр ике туганны бертигез шәрикләр, ә кыз туганнары Софьяны аларның икесе тарафыннан вәкил итеп, хөкүмәт эшләре белән идарә итү Софьяга тапшырылды, ләкин Софья вакытында күп сугыш-талашлар, күп фетнәләр, кан түгүләр булды. Софья Пётрны һәлак итеп, үзе мөстәкыйль патша булып калуны теләсә дә, Пётр кыз кардәшенең мәкерхәйләсен белеп калып, Мәскәүдәге салкын бер җиргә сөрә. Мең дә бер йөз җиденче (1684) һиҗридә туганы Иван үлеп, Пётр патша булып кала. Рус халкының мактанычы булып, «Пётр I», «Бөек Пётр» исемнәре белән мәшһүр булган кеше. Бик тырыш, эшлекле патша булып, мәмләкәтне ислах кылды. Илгә культура, мәгариф, һөнәр, промышленность, фәннәр кертте. Күп дошманнарын җиңде. Галәмнең барлыкка килүеннән башланган тарихны ташлап, милади тарих белән исәпләүне кертте. Россия мәмләкәтендә беренче башлап үзенә императорлык исемен алды. Петербург шәһәрен салып, аны илнең башкаласы итте. Руханилар башлыгы булган патриархлык вазифасын бетерде.

Мең дә бер йөз егерме икенче (1710) һиҗридә Солтан Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Госмани, өченче гасырында Прут сугышында балтачы Әхмәд паша тарафыннан җиңелеп, бик

кысынкылыкта калып, гаскәре күп авырлык күрде, үзе әсир булудан чак котылып калды.

50 сумлык кәгазь акчада исеме һәм сурәте басылган. Мең бер йөз утыз җиденче (1725) һиҗридә Петербургта вафат булды.

Аннан соң – хатыны Екатерина Алексеевна, Пётрның икенче хатыны; Пётр аны тол килеш алган иде. Мең бер йөз утыз тугызынчы (1727) ел һиҗридә вафат булды.

Аннан соң Пётр I нең Алексей исемле, үтерелгән углының углы, Пётр Алексеевич (Пётр II). Унике яшендә мең бер йөз кырык икенче (1730) ел һиҗридә чәчәк авыруы белән вафат булган.

Аннан соң – атасы белән бертуганның кызы Анна Ивановна бинте Алексей бине Михаил. Мең бер йөз илленче (1738) елда вафат булды.

Аннан соң – аның ир туганының кызы Елизавета Петровна бинте Алексей бине Михаил. Мең бер йөз җитмеш дүртенче (1761) елда декабрь аенда вафат булды.

Аннан соң – аның ата-ана бертуган кыз кардәше Анна бинте Пётрдан туган Дук Гольтштейн углы Герцог Пётр бине Фёдорны тәхет варисы итеп билгеләү белән Романовлар династиясе бетә һәм Гольтштейн нәселе килеп, Россиядә император булды. Пётр III дип мәшһүр иде. Анасы Пётр I нең кызы Анна иде. Аз гына вакыт патша булып торып, мең бер йөз җитмеш дүртенче (1762) ел һиҗридә вафат булды. Аннан соң – аның хатыны (татарлар арасында «Әби патша» дип мәшһүр булган) Екатерина II Алексеевна тәхеткә утыра. Аның вакытында Җаек казахларыннан «Пугач» дип даны таралган Емельян Иванович дигән кеше, «Мин – Пётр» дип, патшага каршы баш күтәрде. Шуңа күрә Петрны берничә көн күммичә – җирләмичә халыкка күрсәтеп тотылган. Йөз сумлык кәгазь акчада аның исеме һәм рәсеме басылган. Кечек Кайнарҗа[1] килешүе буенча, Россия

[1] 1774 елда Солтан Габделхәмит I белән Екатерина II арасында төзелгән солых договорына кул куелган шәһәр.

Кара диңгездә пароходлар йөртү хакы алып, мең бер йөз сиксән алтынчы (1773) елда диңгезгә беренче пароход җибәрде.

Аннан соң – углы Павел бине Петр бине Фёдор мең ике йөз унбишенче (1800) елда дөньядан үтте.

Аннан соң – аның углы Александр I мең ике йөз кырык беренче (1825) елда Таганрог шәһәрендә вафат була. Петербургка китереп күмелә.

Аннан соң – аның туганы Николай. Александр I үлгәннән соң, без авылда чакта[1], энесе Константин патша итеп куелса да, бер атна үтү белән ул төшерелеп, икенче энесе Николай патша булды. Константин мең ике йөз кырык икенче (1825) елда үлде. Николай мең ике йөз җитмеш икенче (1856) елда Кырым сугышы вакытында Петербургта үлде.

Аннан соң – аның углы Александр II мең ике йөз туксан сигезенче (1881) елда Петербургта ихтилалчылар тарафыннан үтерелә. Аннан соң – углы Александр III тәхеткә утыра. Бу соңгы икесенә буйсыну турында Казан шәһәрендәге мөселманнарны беренче олуг мәчеттә ант иттердек.

Хәзәр халкы хәле һәм аның сугышлары, Болгар иле һәм анда исламның керүе турында

Тарих галимнәренең төрле риваятьләре һәм күп сандагы китапларыннан файдаланылган мәгълүматларга караганда, борынгы заманда хәзәр һәм болгар бу мәмләкәттәге барлык халыкка исем булып, соңгырак заманда бу олы мөстәкыйль дәүләт икегә бүленеп, көньягындагы өлеше «Хәзәр» исемендә калып, төньяк өлеше «Болгар» исеме белән мәшһүр булган. Әбү Гали ибне Дастә Хәзәрне: «Күл (яки кечкенә диңгез) артындагы[2] киң ил, аның шәһәрләре «Болгар» һәм «Сәмәндәр» дип, Әбү Исхак әл-Истахри һәм әбү Габдулла әл-Гарнатый: «Хәзәр теленә башка телләрнең катнашы юк», – дигәннән соң, «Болгар теле – хәзәр теле», – диләр. Шулай ук диңгез буенда Әстерхан шәһәре

[1] Ш. Мәржани үзе һәм гаиләсе авылда чактагыны әйтә булса кирәк.

[2] Ибне Дастә Иран ягыннан килә. Шуңа күрә Хәзәрне «күл (яки кечкенә диңгез) артындагы ил» дип атый.

тирәсендә яшәгән халыкны «түбән болгарлар» дип йөрткәннәр. Болгар иле көньякка таба бик ерак Хәзәр диңгезе ярларына, Дагстан чигенә, Кавказ таулары итәкләренә кадәр җәелгән. Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвининың «Әсәрел-билад» исемле китабында: «Болгар халкы исламны кабул иткәч, хәзәр патшасы алар белән бик зур сугышлар алып барды», – ди. Имам Әбү әл-Хәсән әл-Мәсгуди: «Хәзәр патшалыгының башкаласы элек Мәдинәтел-бабтан сигез көнлек ераклыктагы «Сәмәндәр» шәһәре иде, аны Сөләйман бине Рәбигател-Баһили яулап алганнан соң, хәзәр патшасы Әстерхан шәһәренә күчкән», – ди. Икенче бер урында: «Хәзәр һәм Кыпчакка карашлы булган Нитыш диңгезен «Бәхре Болгар» дип атыйлар; Болгар әмиренә «белеквар» дигән шикелле, Хәзәр хөкемдарына да «бик», «белек» диләр. «Хәзәрдән Дунайга бер таифә халык күчте», – дип әйтү, кыпчакны Болгар илендәге кабиләләрдән санау – болар барысы да Хәзәр белән Болгарның якынлыгын күрсәтеп торалар. Уйлап карасак, Болгар мәмләкәте әүвәл диңгез тирәләренә ия булмаса, ул диңгезне Болгарга карату, Болгарны Хәзәр иле дип санау, болгар теле хәзәр теле була торып, «Хәзәр теленә башка телләрнең катнашы юк» дию һәм фәкать исламга кергән өчен генә Хәзәр патшасының чит мәмләкәт белән сугыш алып баруы акылга сыймый торган эш булып кала. Бәлки, Болгар хөкемдары исламны кабул итеп, ислам хәлифәсенә буйсынганнан соң, Хәзәр патшасына баш ими башлагач, аңа түли торган салымны туктаткач, Хәзәр патшасы аны яңадан үзенә буйсындыру өчен, өстенә гаскәр җибәргән булыр һәм шул сәбәпле Болгар «тышкы Болгар» дип аталган булыр. Әхмәд бине Фазланның «Болгар патшасы Моктәдир биллаһ хәлифәдән, дошман патшаларның һөҗүмнәреннән саклану өчен, үзенең шәһәренә крепость салып бирүне сорады», – дигән сүзе дә югарыда әйтелгәннең дөреслегенә дәлил була ала. Болгар патшасының Багдадка илче җибәреп, үзенең ислам кабул итүен белдерүе, Хәзәр патшасыннан аерылып, ислам хәлифәсенә буйсынуын шартнамә белән беркетүе көнчыгыш ягындагы күршеләре арасында атказану һәм Хәзәр патшасы аның өстенә килгән сурәттә

хәлифәгә таяну өчен булыр. Шуның соңында Болгар патшасы, бер тарафтан хәлифәнең мәгънәви ярдәмнәре белән сәяси куәтен көчәйтеп, икенче тарафтан – исламга керү белән тормышларын, холыкларын төзәтеп, гыйлем, мәгариф хасил итеп, сәүдә һәм гүзәл мөгамәлә белән материаль хәлләрен яхшыртып, гарәп гаскәрләре тарафыннан кат-кат җиңелгән хәзәрләр көннән-көн көчсезләнеп, патшалыклары табигый рәвештә тузылып, халкы әкренләп ислам кабул итеп, Болгар әмире тәэсире астында калып, кабиләләренең, кешеләренең күбрәге шул тарафка тартылып, борынгы Хәзәр дәүләте һәм хәзәр дигән исем бөтенләй югалып, «Болгар» исемендә генә калган булалар. Испания, Иран, Сүрия һәм Кобт мәмләкәтләре мөселманнар тарафыннан яулап алынганнан соң, гарәп илләре рәвешенчә үзләренә Әндәлес, Гыйрак, Шан һәм Мисыр исемнәрен алдылар. Шулай ук Болгар мәмләкәте халкының, аларга иярүчеләр һәм аларга күрше булган мөселманнарның күпчелеге, соңга таба татарлар тарафыннан җиңелгәч, һәммәсенә дә «татар» исеме бирелде, иске исемнәр беттеләр, югалдылар. Хәзерге заманыбызда да Казан шәһәрендәге мәчетләр, бер исемдә генә тормыйча, әле бер мулла исеме белән, аннан соң икенче мулла исеме белән йөртеләләр. Гомумән, хәзер Россия мәмләкәте эчендәге, әүвәлдә киң, һәм төрле-төрле халыклы булган һәм Сәкалибә иле, сәкъләб халкы, аннан соң – Дәште Кыпчак иле, кыпчак халкы, аннан соң – Болгар иле, болгар халкы, аннан соң – татарлар һәм Татар мәмләкәте, Җуҗи улусы, Бату урдасы, Бәриятел-Бәркә, Үзбәк иле исемнәре белән танылган бу мәмләкәт кешеләрен, төс һәм кыяфәтләренә карап, гарәпләр «хәзәр» дип, мәмләкәтләрен дә «Хәзәр иле» дип атаганнар, мәмләкәт барлыкка килгән заманнарда Хәзәр патшасы Сәмәндәр һәм Ителдә булып, соңрак «Болгар» патшалыгы үсеп күтәрелеп чыгып, икесе ике вакытта дан тотканлыкларыннан, кайбер китапларда икесен кара-каршы куеп телгә алулар булган, ләкин хәзәр болгарларга башка бер халык түгел. Карагыз! Татарлар күтәрелеп чыгып, бу мәмләкәткә һөҗүмнәре соңында, лан, кыпчак, рус, болгар һәм башка халыклар белән сугышулары турында күп китапларда

әйтелгән, әмма хакан яки Хәзәр патшасы һәм Әстерхан халкы белән булган аерым вакыйгалар турында бер сүз дә юк. Әгәр дә Хәзәрләр болгарлардан башка булсалар, татарларның алар белән мажаралары турында да сүз булырга кирәк иде. Дөресен Хода белә.

Инде без Болгар һәм Хәзәр илләренә бер караш ташлап, бу илләргә мөселманнар килеп яулап алулары турындагы риваятьләрне һәм хәбәрләрне китерәбез. Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими дигән кеше үзенең «Тәварихе Болгария»сендә болай ди: «Һиҗри тарихның тугызынчы (630–631) елында Айдархан бине Тәукый хан Хут йолдызында[1], рамазан аеның тукызынчы көнендә тәхеткә утырып, Болгарда патша булды. Пәйгамбәребез, Хода аңа рәхмәт кылсын, Габдрахман бине Зөбәер, Тальха бине Госман һәм Зөбәер бине Җәгъдә дигән өч сәхабәне Болгарга җибәрде. Ул заманда Волга Иделе Болгар астыннан ага иде. Бараҗ хан заманында, өч йөз туксан алтынчы (1005–1006) елда булып үткән биш йөз егерме хан» дигәннәр, бары да утка табынучылар иде», – ди. Икенче бер җыентыкта[2] Тальха бине Госман урынына Ханзаль бине Рәбигъ дип, Мөхәммәд пәйгамбәр аңа таяк бирде. Зөбәер бине Җәгъдәгә кара савыты һәм Габдрахман бине Зөбәергә чалма биреп, «Сездән кәрамәт[3] таләп итсәләр, ошбу өч нәрсә белән Ходадан ярдәм теләрсез», – диде. Болар Болгарга килеп, табиб сурәтендә йөреп, күп авыруларның савыгуына ярдәм иттеләр. Айдархан кызы Туйбикә паралич белән авырый, табиблар аны дәвалаудан гаҗиз калганнар иде. Вәзир патшага: «Шәһәребездә гарәпләрдән өч табиб бар, дәвалауда тиңдәшсез осталар икән», – дип хәбәр бирде. Патша аларны алдырды. Алар ислам динен патшаның кабул итүен шарт итеп, кызны дәвалап терелттеләр, хан һәм аның халкы мөселман булдылар, мәчет салдылар, хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә имам

---

[1] Хут йолдызы – гыйнварның 20 сендә башланып, февральнең 26 сында бетә торган кырык көн чамасы вакыт.

[2] Сүзнең нинди җыентык турында барганлыгы ачык түгел. Шул ук Мөслими әсәренең икенче бер нөсхәсеме, әллә башка әсәрме.

[3] Кәрамәт – могҗиза.

булып, югарыда телгә алынган таякка таянып хөтбә укыды. Тарих һижри уникенче (633–634) ел – куй елында, рамазан аеның 12 сендә, 24 нче Хутта сәхабәләр халыкны мөселман кылдылар. Унике елдан соң ике сәхабә Мәдинәи Мөнәүвәрәгә кайтып китәләр, Ханзаль Болгарда калып, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда вафат булды, төрки теленә бик оста иде», – диелә. Хисаметдин Мөслими: «Айдар хан кызы Туйбикәне алып, егерме биш ел Болгарда торып калып, шунда вафат булган һәм төрки теленә бик оста булган кеше Зөбәер бине Җәгъдә иде», – ди. Бу фәкыйрь әйтә: югарыда әйтелгән «Тәварихе Болгария» китабы һәм телгә алынган икенче җыентык та һич тә ышанычлы әсәрләр түгелләр, һәр ике китап ачык ялганнар белән тулган. Болгар халкының пәйгамбәр заманында ислам диненә керүенә борынгы һәм соңгы заман галимнәренең әсәрләрендә һичбер дәлил, күрсәтмә юк. Мондый олы бер вакыйга булган булса, хәдис һәм тарих китапларында бу турыда хәбәрләр сөйләнер иде. Шулай ук «Мәгърифәтес-сәхабә» китапларында, мәсәлән, Хафиз ибне Мензә, Әбү Нәгыйм, Әбү Муса, ибне Габделбәр, ибне Дабаг, Гыйззетдин бине әл-Әсир һәм борадәре Мәҗдетдин бине әл-Әсир һәм башка шундый галимнәр сәхабәдән барлык ир һәм хатын-кызларның исемнәрен әйтеп үтү вазифасын өсләренә алсалар да, аларның әсәрләрендә пәйгамбәрнең сәхабәләре арасында Зөбәер бине Җәгъдә, Тальха бине Госман дигән исемнәр телгә алынмыйлар. Ханзаль («Ханзалә» түгел) бине Зыйрар бине әл-Хәсыйм дигән бер сәхабә телгә алынса да, Ханзаль Әбү Робгый, Ханзаль бине әр-Рәбигъ бине Сайфи бине Риях әт-Тәмими әл-Кятиб, икенче бер сүзгә караганда, атасының исеме – Рәбига. Ул «Җәмәл»[1] вакыйгасында Басрада хәзрәте Галидән (Аллаһ аннан разый булсын) баш тартып, Могавия заманында Каркыйсада вафат булды. Габдрахман бине Зөбәер бине Зәйд бине Өмәйя – әл-Корзый – танылган

[1] «Җәмәл» вакыйгасы – Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны Гайшә хәлифә Галигә каршы көч туплап фетнә чыгара. Хәлифә Гали аны әсир алып, Мәккәгә кире җибәрә. Гайшә Җәмәлгә – дөягә атланып килгәнгә күрә, бу вакыйга «Җәмәл вакыйгасы» дип аталган.

сәхабә. Аннан соң аның углы Зөбәер бине Габдрахман, Гарвә бине әз-Зөбәер бине Гавам, Рәфагат әл-Корзыйның аерылган хатынына аның өйләнүен хәзрәт Гайшәдән риваять итәләр. Ләкин «Мәгърифәтес-сәхабә»дә аның чит мәмләкәткә сәфәр итүе һәм шуңа охшаган эшләре турында бер сүз дә юк. Югарыда исемнәре телгә алынган сәхабәләрдән башка, бу исемнәрдә сәхабәдән берәүнең дә исеме телгә алынмый. Шулай ук, һиҗри уникенче (633–34) елда рамазан ае Хутка түгел, бәлки Гакрәбкә туры килгән. Шулай. Дөресен Аллаһ белә. Гәрчә бу рәвештә шәһре Болгарга сәхабәләр килүенең нигезе булмаса да, бу мәмләкәт халкының исламга бик иртә керүе, аларны дингә өндәү өчен гарәп таифәсеннән табиб сурәтендә өндәүчеләр килгәнлегенә дәлил булырлык беркадәр риваятьләр бар. Гыйззетдин Әбү әл Хәсән Гали бине әл-Әсир үзенең «Мәгърифәтес-сәхабә»сендә Гамир бине Әфса әл-Әсләми турында сөйләгәндә болай ди: «Гамир үз кабиләсеннән бер җәмәгать белән пәйгамбәргә килде. Пәйгамбәр аның кулына төрки телендә бер хат язып бирде. Әбү Һөрәйрә ул хатта язган сүзләр турында сөйләде. Ләкин ул хатны риваять итеп сөйләүчеләр гарәпчә сүзләр белән алыштырып, үзгәртеп сөйләделәр, хәтта бу үзгәртүләр нәтиҗәсендә хаталар булды. Шул сәбәптән без ул хатны монда китермәдек...»

Бу риваятьтән аңлашылуына күрә, пәйгамбәр каршында төрки телен белүче булган, һәм бер халыкка төрки телендә хат язган икән. Ул хат гарәпчә сөйләшүче Гамиргә һәм аның юлдашларына язылган булмас, әлбәттә, телләре төркичә булган башка бер халыкка җитештерү өчен язылган булыр. Ул заманда гарәп, Шам илләрендә, Рум мәмләкәтләрендә төрки телендә сөйләшә торган халык юк иде. Кытайга чаклы бик күп мәмләкәтләр, күп тоткарлыклар, озын юллар булу сәбәпле, бу хатның аларга язылмаган, бәлки якындагы, берберсе белән аралашып йөргән Болгар һәм Хәзәр халкына язылган булырга тиешле. Гарәп халкы, ислам дине барлыкка килгәч тә, бу мәмләкәткә аяк баса башлаган. Аларның бер өлкәдә көмеш мәгъдәне табып, билгеле булган зур бер елганы һәм мәгълүм бер өлкәне гарәп лөгате белән

«Нократ[1] елгасы» дип һәм ул өлкә халкын «Нократ болгарлары» дип атаган булулары шуны күрсәтә. Бу өлкә һәм елга хәзердә дә шул исем белән йөртеләләр, бу эш гарәп халкының күптән бу ил белән аралашуын күрсәтә. Шулай ук Болгар халкы телендә бик күп гарәп сүзләре табыла, хәтта хәзерге заманда да бик күбесе онытылып, күбесе үзгәртелеп һәм бозылып әйтелә торган булып калса да, бик ерак авылларда гади халык телендә меңнән артык гарәп сүзләре йөри. Шаять, алар алдагы бер бүлектә китерелер[2]. Аларга гарәп теле керүе сәүдә эше белән аралашу сәбәпле булмаса кирәк, алай булса, фарсы теле дә шулай ук кергән булыр иде; дөрес, фарсы сүзләре керсә дә, бик аз. Якут әл-Хәмәви үзенең «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында болай ди: «Хәзрәти Гомәр хәлифәлегендә унтугызынчы һиҗридә (640) Әбү Муса әл-Әшгари, Исфаһанны яулап алудан бушагач, Габдерахман бине Рәбигател-Баһилине гаскәрнең алдына куеп, Сәрака бине Гомәрне Дәрбәнд тарафын яулап алу өчен җибәрде», – ди. Гыйззетдин бине әл-Әсир «Китабел-камил»дә әйтә: «Хәзрәте Гомәр Габдерахман бине Рәбиганы Сәрака бине Гомәр урынында калдырып, аңа[3] төрек белән сугышырга әмер итте. Ул әзерләнгән чакта шәһрияр[4]: «Нәрсә эшләргә уйлыйсың?» – дип сорады. Ул[5]: «Бәләнҗәр һәм төрекне яулап алмакчы булам», – дип җавап бирде. Шәһрияр: «Без алардан, безне тимер капканың[6] артында торырга тыныч куюларына да риза һәм канәгать булыр идек, дигәч, Габдрахман: «Без аларның йортлары эченә кереп сугышмасак, риза була алмыйбыз!», – диде. Ул Бәләнҗәрне яулап алды. Хәзәрләр, бу хәлне күреп, боларны үлемнән саклый торган

---

[1] Нокрәт – гарәп телендә «эшкәртелмәгән көмеш» дигән сүз.

[2] Ш. Мәржани «Мөстәфадел-әхбар»нең I томы ахырында шундый сүзләрне әлифба тәртибендә китерә.

[3] Аңа – Габдерахманга.

[4] Шәһрияр – дустым. Монда Сәрака бине Гомәр Габдерахманнан сораган булырга тиеш.

[5] Ул – Габдерахман бине Гомәр.

[6] Тимер капка – Дәрбәнд шәһәре. Бу шәһәр гарәпләрнең Европага үтеп керүләре өчен кирәкле юл өстендә торганга күрә, ул заман тарихчыларының телендә күп тапкырлар искә алына.

фәрештәләр булмаса, безнең өстебезгә килергә батырчылык итә алмаслар иде, диделәр, мөселман гаскәре Бәләнҗәрдән ике йөз фәрсәх кадәр җиргә җиттеләр, бер кешеләре дә үлмәде. Икенче мәртәбә хәзрәте Госман хәлифәлегендә сугышканда, хәзәр төрекләре урман эченә качтылар. Аларның берсе аңсыздан гына бер мөселманны атып үтергәч, гарәпләр дә үләләр икән дип батырланып, бик күбесе бергә җыелып, зур сугыш башладылар. Шул сугышта Габдерахман шәһит булды, гаскәрнең байрагын энесе Сәлман бине Рәбига алып, яланга чыгып, Җорҗанга бардылар. Бу эш аларны[1] Габдерахманның гәүдәсен алудан тыймады, алар аның белән әле дә булса яңгыр телиләр», – ди. Якут әл-Хәмәви әйтә: «Хәзәрләр шәһитләр күмелгән урында һәр кичәдә зур яктылык – нур күреп, икенче бер сүзгә караганда, аларны олылап күмеп, әмирләрен алып, табут белән гыйбадәтханәләренә куеп, корылык һәм ачлык заманнарында аны алып чыгып, яңгыр теләүдә файдаланалар иде. Шул турыда Габдерахман бине Җәманәт әл-Баһили Котәйбә бине Мөслим белән икесе хакында болай ди: «Безгә ике кабер: берсе Бәләнҗәрдә, берсе Кытайда; сиңа кайсы кабер кирәк? Кытайда булганын сугыш белән алырга кирәк, ә бусын яңгыр тамчылары сугарачак».

Тәрҗемәче фикеренчә, шул гасырларда ук хәзәр халкы, гомумән, исламга кызыккан һәм мөселманнарга яхшы карап, мәхәббәт иткән була. Һиҗрәттән йөз дә дүртенче (723) елда Сәбит ән-Нәһрани дигән кеше, Хәзәр иленә кереп, бик күбесен җиңде, йөз дә җиденче (725–726) елда Лан мәмләкәте яулап алынып, җизья[2] түләргә риза булып солых ясаганнар. Аннан соң йөз унберенче (729–730) елда хәлифә Фәррах бине Габдулла әл-Хәкәмине Әрмәнстан иленә вәли[3] итеп җибәрә. Шунда Тифлис өлкәсеннән Хәзәр иленә кереп, Мәдинәтел-Бәйза, Дәрбәнд, Бәләнҗәр, Хисан шәһәрләрен яулап алдылар. Соңра хәзәр төрекләре йөз уникенче (730–731) елда Лан өлкәсендә бик күп булып җыелып, Җәррах бине Габдулла әл-Хәкәми үзенең янында бул-

[1] Аларны – хәзәр төрекләрен булса кирәк.

[2] Җизья – салым.

[3] Вәли – губернатор, өлкә башлыгы.

ган бераз Шам гаскәре белән хәзәрләргә каршы торып, бик каты сугыш булган. Хәзәрләр бик күп булганлыктан, Җәррах бине Габдулла һәм янындагы кешеләре Әрдәбилдә яки Бәләнҗәрдә шәһит булдылар. Бу вакыйгадан соң хәзәрләр, мөселман иленә кереп, Җәзирә иленә җитешеп, Мусыйльгә якын килделәр. Хәлифә Сәгыйд әл-Хәрши дигән кешене Әрмәнстан иленә вәли итеп җибәрде. Ул хәзәрләрне куып, Баҗәрванга килеп, хәзәрләр белән сугышты. Бер мәртәбә Баҗәрван өлкәсендә, бер мәртәбә Рәс елгасы буенда, бер мәртәбә Бәйләкан елгасы буенда хәзәрләрне җиңеп, бик күп ганимәт[1] алып, мөселман әсирләрне азат итте. Шуннан соң йөз уникенче (730–31) елда Мөслимә бине Габделмаликне Әрмәнстанга вали итеп, ул икенче елында ук Хәзәр илен яулап алып, берничә шәһәрләрен җимереп, яндырып, әсир алып, хакан углын үтереп, Бәләнҗәр таулары арасындагы таифәләр аңа буйсынсалар да, хаканның чиксез күп гаскәр туплаганын ишетеп, Дәрбәндкә кайтты. Мөслимә гаскәрендә Мәрван бине Мөхәммәд бине Мәрван бар иде. Ул, кайтып, хәлифәнең үзенә кереп: «Җәррах һәлак булганлыктан, исламга зур хурлык булды, кимчелек килде, Мөслимә хәзәрнең бер читенә генә кереп басты, гаскәрнең күплегенә мәгърур булып, хәзәрләргә хәбәр салып, аларның әзерләнүләрен күреп торып һич үч алмастан, кайтып китеп дөрес эшләмәде, шуның өчен минем йөрәгем әрнеп, бу серне әйтергә лаек кеше таба алмаганлыгымнан, туры үзем сезгә килдем. Әгәр миңа йөз егерме мең гаскәр белән барырга рөхсәт бирсәгез, мин алардан үчне алыр идем», – диде. Хәлифә аны Әрмәнстанга вәли кылып, Шам һәм Гыйрак гаскәрләрен кушты. Шуннан соң Мәрван лан халкы белән сугышу хәбәрен таратып, Хәзәр патшасы белән илчеләште, солых ясады. Ләкин үзенә килгән Хәзәр илчесен озак тотып, шул арада сугыш кирәк-ярагын әзерләп бетереп, солыхны кире какты һәм Хәзәр илчесен ерак юлдан кайтарып җибәреп, үзе якын юл белән Хәзәр өстенә килеп җитте. Илче кайтып хәбәрне сөйләгәч, Хәзәр патшасы, бик куркуга төшеп,

[1] Ганимәт – сугышта җиңүче як кулына төшкән мал, байлык.

хәйран калып, халкының өлкәннәре белән киңәш итә башлады. Алар: «Инде йортыңны ташлап илеңнең ерак читенә китмәсең, ул сине отты, синең белән теләсә ни эшли ала», – диделәр. Ул, бу сүзне тотып, иленең ерак читенә качты. Мәрван Хәзәргә кереп чумды, бик күп ганимәт малы һәм әсирләр алып кайтты. Юлында туры килгән «Мәлик әс-Сәрир», «Туман», «Зәригәран», «Әрзы Хәзин», «Согдан», «Ләкәз» һәм болардан башка мәмләкәтләр аркылы үтеп, аларны да буйсындырып кайтты.

Тарихчыларның олысы Әбү әл-Хәсән Гали бине Хөсәен әл-Мәсгуди әйтә: «Хәзәр мәмләкәтендә булган халык Хәзәр патшасына буйсына. Хәзәрнең башкаласы «Мәдинәтел-баб»тан сигез көнлек ераклыкта «Сәмәндәр» шәһәре иде, анда хәзерге вакытта хәзәрдән бер ыруг тора. Аны Сәлман бине Рәбигател-Баһили яулап алганнан соң, Хәзәр патшасы Идел шәһәренә, ягъни Хаҗитарханга күчте, ул шәһәрдә мөселман, яһүд, христиан һәм мәҗүсиләр бар, патшасы һәм аның якыннары Хәзәр яһүдләре нәселеннән. Алар Һарун әр-Рәшид хәлифәлегендә Рум кайсары[1] Әрмирус яһүдләрне үз диненә керергә кысрыклагач, алар кабул итмәстән, кайсар мәмләкәтеннән чыгып китеп, Хәзәр мәмләкәтенә килеп, Хәзәр патшасы үзе якыннары белән яһүдләр диненә керде. Әмма аның күбрәк халкы, вәзире һәм гаскәре – мөселманнар; хәзерге вәзире – Әхмәд бине Күбә исемле кеше. Шуңа күрә Ител мәмләкәтендә өстенлек мөселманнарда. Анда җиде казый бар: икесе мөселман, ислам шәригате, Коръән хөкеме белән хөкем итәләр, икесе яһүди – Тәүрат хөкеме белән, икесе христианнан – христиан хөкеме белән, берсе сәкалибә, рус һәм башка җаһилият[2] халкыннан булып, җаһилият яки казый акылы белән хөкем итәләр. Аларга үзләре белмәгән бер зур вакыйга туры килсә, мөселман казыйлары алдына килеп, ислам хөкеменә буйсыналар. Ул мөселманнар исламның әүвәлге заманында үз мәмләкәтләрендә ваба авыруы һәм ачлык булганнан соң Харәзем ягыннан күчеп килеп, билгеле шарт

[1] Рум кайсары – Рум иле патшасы.

[2] Җаһилият – бу урында мәҗүсилек.

белән Хәзәр мәмләкәтенә кергәннәр. Алар – куәтле, куркуны белми торган, батыр халык, аларны «Ларшия» дип атыйлар. Бәлки, ул мәмләкәттә булган мөселманнарның барысын да «Ларшия» дип атыйлар, Хәзәр хаканы аларга таяна. Аларның шартлары: 1. Ислам динен яшермичә, мәчет һәм мәктәпләр салу, азан әйтеп, җәмәгать белән җомга һәм гаед намазлары уку. Патша тора торган шәһәрдә аларның күпсанлы мәчетләре, Коръән өйрәнү өчен мәктәпләре бар. Җомга укыла торган мәчетләренең манарасы патша сарае өстенә карап тора. 2. Патшаның вәзире «Ларшия»дән булырга. 3. Хәзәр патшасы мөселманнар белән сугышса, болар катышмаячак, башка халык белән сугышканда, болар да сугышачаклар. Мөселманнарда булган сугыш кирәк-ярагы боларда да бар. Ул шәһәрдәге мөселман һәм христианнар берләшсәләр, патшаның һичбер көче-куәте калмый; рус һәм сәкалибәләр – патшаның коллары һәм гаскәрләре. Хәзәр мәмләкәтендә сәүдәгәрләр йөзә торган каек һәм көймәләре белән Бортас елгасында йөриләр. Ул елга тирәсендә Хәзәр мәмләкәте эчендә төрек халыклары бар, шәһре Болгарга кадәр барып тоташкан гыймарәтләре[1] һәрвакыт сәүдәгәрләр белән тулы була».

Шәмсетдин әд-Димәшкый үзенең «Нәхбәтет-дәһер фи гажаибил-бәрри вәл-бәхер» исемле китабында: «Хорасаннан бер гаскәр килеп, Хәзәр илен яулап алды да, алар исламга керделәр», – ди. Гыйззетдин бине әл-Әсир әйтә: «Алар һиҗрәттән ике йөз илле дүртенче (868) елда исламга керделәр. Исламга керүләре вә сәбәп шул булды: алар төректән бер таифә белән сугыштылар. Хәзәрләр Харәзем халкыннан ярдәм сорадылар, харәземлеләр: «Сез – кяферлар, әгәр мөселман булсагыз, сезгә ярдәм бирербез», – дидедер. Алар мөселман булдылар, мәгәр патшалары калды. Мөселманнар ярдәм биреп, дошманны куып качырганнан соң, патшалары да мөселман булды», – ди. Икенче бер риваятькә караганда, Мәәмүн хәлифә, аларны яулап алып, илләренә хуҗа булган да, алар бер йөз туксанынчы

[1] Гыймарәт – төзелеш, биналар, өйләр.

(805–806) елларда исламга кергәннәр. Васикъ биллаһ[1] хәлифәлегендә ислам диненә керделәр дигән сүз дә бар.

Болгар исеме белән бәйле рәвештә китерелгән ачык һәм дөрес хәбәрләр

Ибне әл-Әсирнең «Әсәдел-габә фи мәгърифәтис-сәхабә» исемле китабында әйтүенчә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Гамир бине Әфсага төрки телендә хат язып тапшыруы, Габдерахман бине Рабига әл-Баһилинең Дәрбәндтән үтеп, Хәзәр иленә ике йөз фәрсәх чамасы кергәнлеге, Мәрван бине Мөхәммәднең Хәзәр иленең иң ерак чигенә кадәр барып җитүе, бу мәмләкәттәге барлык төрек халкының хәзәр дип аталулары турында үткән фасылда язылган иде. Инде бу фасылда Болгар турында булган дөрес хәбәрләр, ачык риваятьләр китерелә. Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини үзенең «Асярел-бөлад» исемле китабында болай ди: «Хикәят кылында ки, бер изге кеше Болгарга керде. Болгарның патшасы һәм аның хатыны яман авыру белән авырып, тереклектән өметләре киселгән иде. Бу изге кеше аларга: «Әгәр мин сезне даруласам, сез минем динемә керерсезме?» – диде. Алар: «Керербез», – диделәр. Шулай булгач, ул аларны дәвалап сәламәтләндерде, алар ислам диненә керделәр һәм алар белән шул мәмләкәт халкы да мөселман булдылар. Бу хәбәрне ишеткәч, Хәзәр патшасы зур гаскәр белән боларга һөҗүм итте. Изге кеше Болгар халкына: «Сез курыкмагыз, «Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр» дип әйтегез», – диде. Халык ул кушканча эш итеп, Хәзәр патшасын чигенергә, качарга мәҗбүр иттеләр. Хәзәр патшасы җиңелеп, Болгар халкы белән солых ясады, һәм: «Мин сезнең гаскәр эчендә күк атларга атланган зур-зур ирләр күрдем, алар минем гаскәремне кыралар иде?» – диде. Әлеге изге кеше: «Алар Аллаһы Тәгаләнең безгә ярдәм итәр өчен җибәрелгән гаскәре иде», – диде. Ул изге кешенең исеме «Беләр»[2] иде, аны гарәпләштереп, «Болгар»

[1] Васикъ биллаһ – гарәп хәлифәсе.

[2] Ягъни «белүче, галим» мәгънәсендә. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

дигәннәр», – дип төшендерде шәһре Болгар казыйсы. Ул Болгар тарихын язучы һәм һиҗри белән дүрт йөз илленче (1058–1059) елларда яшәгән кеше иде. Йөз алтмыш өченче (797–798) һиҗридә Болгар патшасы Зөбәер хан бик зур куәт белән Идел елгасы буеннан кузгалып, мәһабәтле йөреш белән йөреп, юлдагы сәкалиб һәм башка бик күп халыкны ияртеп, атлы гаскәр белән Дунай елгасын боз өстеннән үтеп, шул мәмләкәтләрне талап, күп ганимәт[1] малы алып, Константиниядән утыз чакрым җирдә туктады. Кайсар бик куркып, тетрәп, калтырап, малларын һәм кыйммәтле нәрсәләрен крепосте астына яшереп, башкаласы чак кына котылып калды.

Ибне Дасә: «Бортас иле Хәзәр белән Болгар арасында, Хәзәрдән унбиш көнлек юлда, Хәзәр патшасына буйсыналар иде», – ди. «Рисаләтел-интисаб»та: «Болгар халкы Мәәмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәләр заманында исламга керделәр», – диелә. Икенче бер риваятькә караганда, Мәәмүн хәлифә аларга Җурҗания[2] аркылы һөҗүм итте, бу сугыш һиҗрәттән бер йөз туксанынчы (805–806) елда иде, диелә. Кайбер китапта, Мәәмүн хәлифәнең һөҗүме һәм ул илне яулап алуы атасы Һарун әр-Рәшид хәлифәлегендә иде; кайбер кабиләләр яки кайбер ил халкы исламга кереп, хакан салым түләү шарты белән урынында калдырылган. Бераздан соң аларга төрек һөҗүм иткәч, Харәземдәге мөселман гаскәре төрекләрнең һөҗүмнәрен туктатулары Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытына туры килә. Шуннан соң ике йөз илле дүртенче (868) елда патшалары исламга кергән булса, бу, югарыда китерелгән риваятьләр бергә җыелган булалар. «Болгар халкы мөселман булгач, Хәзәр патшасы алар өстенә һөҗүм итеп килде» дигән сүзне дә шуңа кушсак, Болгар патшасының исламга керүе Хәзәр патшасының исламга керүеннән элек булып, Рәшид яки Мәәмүн хәлифәлеге вакытында исламга керүләре исбат ителә; чөнки Хәзәр патшасы ул вакытта мөселман булмаган, әгәр мөселман булган булса иде, исламга кергән

---

[1] Ганимәт – сугышта кулга төшкән мал, байлык.

[2] Җурҗания – Гүргән шәһәре.

өчен, Болгар халкына һөҗүм итмәс иде. Алмас ханның Багдадка илче җибәреп, аннан илче килүе исламга кергәннән соң байтак заман үткәч булуы бик ихтимал, янә Әбү әл-Габбас Әхмәд бине Фазлан бине әл-Габбас бине Рәшид бине Хаммад әл-Багдади – Болгар иле, аның патшалары кем халкының хәле турында ачык хәбәрләр белән китап язучы мөселман галимнәренең иң беренчесе. Аны Габбасия хәлифәләреннән әмирел-мөәминин әл-Моктәдир биллаһ Әбү әл-Фазыл Җәгъфәр бине әл-Могтәзыйд хәлифә хәзрәтләре Сәһсән әр-Расиби һәм Бәдер әл-Хәрәмиләрдән торган һәм Болгарга җибәрелгән илчеләренә секретарь итеп билгеләгән иде. Яшьлегемдә аның китабының кайбер кисәкләрен күреп, берникадәр нәрсә язып алган идем, анда Якут әл-Хәмәви һәм башкалар язганнан күп артык сүзләр бар иде, кызганычка каршы, хәзер дә аны кайда куйганымны белмимен. Ибне Фазлан ул рисаләсендә болай ди: «Сәкалибә патшасы Алмас бине Сәлки Белекварның әмирел-мөәминин хәлифә әл-Моктәдир биллаһ хәзрәтләренә язган хаты килеп иреште. Хатында ул хәлифәдән, иленең барлык шәһәрләрендә һәм төрле якларында торып, ислам дине һәм шәригатен өйрәтерлек галимнәр, мәчет һәм минбәрләр эшләү һәм чит ил патшаларының явыз теләкләреннән саклану өчен, шәһәренә крепостьлар салырга оста эшчеләр җибәрүне сорый. Хәлифә хәзрәтләре, аның бу теләкләрен кабул итеп, галимнәр һәм төрле өлкәдә эшли белүче осталар җибәрде. Дәүләт эше буенча вәкил Бәдер әл-Хәрәми, ә илче Сәһсән әр-Расиби иде» – ди һәм дәвам итә: «Багдад хәлифәлегенең башкаласы булган Мәдинәтес-сәламнән[1] һиҗрәтнең өч йөз тукызынчы елында (921–922), сәфәр аеның унберенче көнендә Болгарга карап юл тоттык. Хорасан һәм Харәзем аркылы килеп, юлда күргән һәм ишеткән вакыйгаларны язганнан соң дәвам итә: «Ниятләп чыккан кешебез Сәкалибә патшасына бер көнлек юл калганда, Сәкалибә патшасы безне каршы алырга үзенең хөкүмәтендәге дүрт патшаны, үзенең туганнарын һәм балаларын чыгарган иде. Алар безне икмәк,

[1] Багдад шәһәре «Мәдинәтес-сәлам» дип йөртелгән.

ит, ат азыгы – тарылар белән каршы алып, үзләре һәм безнең белән бергә йөределәр. Шәһре Болгарга ике фәрсәх калганда, патша, үзе чыгып, безне каршы алды. Безгә күзе төшкәч, Ходага шөкер итеп сәждә итте, җиңендә тәңкәләр бар иде, безгә аны чәчте. Без анда өч йөз унынчы (922) ел мөхәррәм аеның уникесендә якшәмбе көн килеп җиттек. Харәземнең Җурҗания шәһәреннән анда җиткәнче җитмеш көн вакыт үтте. Безгә чатырлар, киез өйләр утырттылар, без аларга кереп җайлаштык һәм чәршәмбе көнгәчә, ягъни хәлифәнең патшага язган хатын тыңлар өчен үз җирендә булган патшалары, мәшһүр кешеләре җыелып җиткәнче, без шунда тордык. Пәнҗешәмбе көн төеннәребезне ачып, киемнәребезне чыгардык, җибәрелгән ияр белән атны иярләдек, Габбасия хәлифәлеге галәмәте булган махсус кара киемне һәм чалманы патшага кидердек. Мин хәлифәнең Болгар патшасына язган хатын чыгарып укыдым, патша хөрмәт һәм олылау йөзеннән аякка басып тыңлады. Моннан соң ул вакытта хәлифәнең вәзире булган Хәмид бине Габбасның хатын укыдым, бу вакытта да аяк өстендә торды, ләкин ул үзе зур гәүдәле, симез тәнле авыр бер кеше иде. Аның якыннары безгә тәңкәләр чәчтеләр. Без бүләкләрне чыгарып күрсәттек. Аның хатынына да бүләк кием кидердек, иренең янында утырган иде, аларның гадәтләре шулай икән. Шуннан соң безне үзенең сараена чакырды. Уң ягында патшалары утырган иде, безгә үзенең сул ягына урын тәкъдим итте. Балалары алдында утырган, ул үзе фәкать Рум дибажы[1] белән генә капланган бер тәхеткә утырган иде. Боерык бирүе белән табын хәзерләнде, алдына кәбаб[2] китерделәр. Патша аннан өч мәртәбә кисеп алып үзе авыз иткәч, тагын бер кисәк кисеп алып, Сәһсән әр-Расибигә бирде. Шулай һәркемгә аерым ашъяулык килде. Рәсми гадәтләре шулай икән. Патша авыз итмичә торып, һичбер кеше ашка кул сузмый, һәркайсыбыз бер савыттан ялгыз ашап, калганын тора торган җиребезгә алып кайттык. Ашап туйганнан соң, эчемлек бал сорап

[1] Дибаж – ефәктән тукылган пәрдә, җәймә.
[2] Кәбаб – кыздырылган ит.

алды, аны «сөжү» диләр, үзе дә эчте, без дә эчтек. Без килүдән элек хөтбәдә аңа дога кылганда «Аллаһүммә әслих әл-мәликә Белеквар Мәликә Болгар[1]», – дип әйтәләр иде. Мин – «Мәлик» дигән сүз Ходаның исемнәреннән берсе булып, чын «Мәлик» фәкать бер Хода, аннан башкаларны «Мәлик» дип, бигрәк тә минбәрдә дога кылганда әйтелергә тиеш түгел, менә синең хуҗаң әмирел-мөэминин көнчыгыш һәм көнбатыш шәһәрләрендәге минбәрләрдә: «Аллаһүммә әслих габдәкә вә хәлифәтәкә әл-Моктәдире биллаһи әмирел-мөэмининә!»[2] дип әйтергә кушты», – дидем. «Инде ничек әйтергә кирәк?» – диде. Мин әйттем: «Үз исемеңне һәм атаңның исемен телгә ал», – дидем. Ул әйтте: «Минем атам кяфер иде, үземнең исемем дә кяфер хәлендә куелган, кяфер куйган исемне телгә алуны яратмыйм мин, ләкин хуҗам әмирел-мөэмининнең исеме ничек?» Мин әйттем: «Аның исеме Җәгъфәр», – дидем. Ул әйтте: «Мин үземә шулай «Җәгъфәр» дип исем куйсам, дөрес булырмы?», – диде. Мин: «Әйе, дөрес булыр», – дидем. «Алайса, минем исемем «Җәгъфәр», атамның исеме «Габдулла» булсын», – диде һәм хөтбә укучыга шулай телгә алырга кушты. Шуннан соң: «Аллаһүммә әслих габдәкә Җәгъфәр бине Габдуллаһи әмире Болгари мәүла әмирел-мөэмининн[3]», – дип телгә ала торган булдылар. Аның шәһәрендә мин хисапсыз күп гаҗаибләр күрдем. Бервакыт Багдадтан килгән бер тегүчене сөйләнеп утырырга үземнең торагыма алып кердем. Ясигъ намазына азан әйтелүен көтеп, без аның белән ярты сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Азан әйткәнне ишетеп тышка чыксак, таң атып, иртә намаз вакыты булган. Мөәзиннән: «Кайсы намаз азанын әйттең?» – дип сорасам, «Иртә намаз азанын әйттем», – ди. «Ә ясигъ намазы кайда?» – дип сорасам, «аны ахшам белән бергә укыйбыз», – диде. «Кич кайда соң? – дип сорасам, «Үзең күргәнчә, хәзер бераз озайды әле, югыйсә

---

[1] Я Хода, патшаны, Болгар патшасы Белекварны, изгелеккә юнәлдер.

[2] Я Хода, үзеңнең колың һәм хәлифәң, әмирел-мөэминин әл-Моктәдир биллаһны изгелеккә юнәлдер.

[3] Я Хода, Болгар әмире, колың Җәгъфәр бине Габдулланы һәм хуҗасы әмирел-мөэмининне изге юлга күндер.

моннан да кыскарак иде, иртә намаз калмасын дип, бер ай чамасы кичләрен йокламадым», – диде. Икенче кичәдә карасам, йолдызлар күрмәдем, анда-монда гына ун-унбишләп йолдыз күренә; шәфәкъ кызыллыгы бөтенләй батмый, кич бик якты, кешене бер ук атымы җирдән танып була; аларны күрдем мин. «Эт улаганнан еллар иркенчелек, бәрәкәтле һәм сәламәтчән була», – диләр. Аларда елан бик күп икән, хәтта бер агач ботагына уннан артык елан чолгана, ләкин алар еланны үтермиләр, елан аларга зарар итми. Аларның бик әче яшел алмалары бар, аны кызлар ашап симерәләр. Ул йортта чикләвек агачыннан күп агач юк, 40 квадрат фәрсәх чамасы урманнары шуның белән тулы. Анда тагын мин бер агач күрдем, ләкин нинди агач икәнен белмим, үзе бик биек, буенда яфрагы юк, башы хөрмә агачы башы шикелле, яфраклары башында җыелып тора. Ул агачның бер җиреннән тишеп, астына бер савыт куеп, суын алалар; балдан да тәмлерәк була, кеше күбрәк эчсә исерә. Тәрҗемәче фикеренчә, бу агач «каен» булмаска кирәк, чөнки «каен» булган тәкъдирдә аны Ибне Фазлан белеп, «хәдәнҗ» дип аңлаткан булыр иде. Тагын болай ди: «Аларның күбрәк ашаганнары тары һәм ат ите, шулай ук аларда арпа белән бодай да күп, һәркөн иген иксә, хасилен үзе ала, патшалыкка бирелә торган хак юк, ләкин алар һәр йорттан патшага үгез тиресе бирәләр». Тәрҗемәченең фикеренчә, бу үгез тиресе дигәннәре, безнеңчә әйткәндә, иләп эшләгән калым, «болгар» дип йөртелә торган күн булырга кирәк.

«Әгәр патша бер тарафка, кайбер шәһәрләргә һөҗүм итеп таларга гаскәр җибәрсә, алар белән бергә аның да өлеше була», – ди. Аларда балык маеннан башка май юк, аны зәйтүн мае урынына тоталар, шуның өчен алар исле булалар. Алар барысы да башларына бүрек кияләр, патша ялгыз үзе генә йөри, базардан үтеп китсә, барлык халык урыныннан торып, башыннан бүреген алып, култык астына кыстыра, узып киткәч, алып кияләр. Патшаның алдына кергән вакытта да, олы һәм кече булсын, хәтта балалары һәм туганнары да, патшаның күзе төшкән вакытта башларыннан бүрекләрен алып култык асларына кыстырып, башлары белән ишарә кылып утырып, янә аягүрә торалар,

патша утырырга кушканчы; һәркем утырганда, тез чүгеп утыра, бүрекне патша алдыннан чыгып китмичә күрсәтми; чыккач кына башына кия. Аларда яшен яшьнәү бик күп була. Әгәр дә берәүнең йортын яшен сукса, үзе янып беткәнче, аңа якын бармыйлар, аны Аллаһның ачуы төшкән җир диләр... «Ибне Фазлан әйтә: «Алар ояда вакытта берсе сугыш коралы, ягъни мылтык, кылыч, сөңге кебек нәрсәләр белән сиергә утырса, үзләренең гадәтләре буенча, аның янында булган коралларын алалар. Әгәр ул коралларны үзе салып бер читкә куеп утырса, аңа һич каршы килмиләр».

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: «Аларның бу эшләре батырлык һәм сугышчанлыкларыннан булырга кирәк, алар сугыш коралын олылыйлар. Шуңа күрә каберләренә куелган ташларның кайберләрендә «альшуари», безнең телебезчә, ягъни алышмак ире, алдынгы сугышчы, кайберләрендә «юари», ягъни сугышчы егет, кайберендә «әлгәҗәс», ягъни дошманга каршы чыгучы шикелле сыйфатлар белән сыйфатланганнар.

«Аларның ирләре һәм хатыннары ялангач килеш бергә су коеналар, бер-берсеннән бер дә яшеренмиләр. Суга кергәндә хатыннар ирләрдән пәрдәләнсеннәр, яшеренсеннәр дип күпме тырышсам да, теләгемә ирешә алмадым», – ди Ибне Фазлан. Аларда зина кылу бер дә юк, әгәр дә берәү зина кылса, кирәк нинди кеме булсын, дүрт казык кагып ике кул һәм ике аягын шул казыкларга бәйләп, ир һәм хатынны муеныннан ботына кадәр пычкы белән ярып, һәрбер кисәген бер агачка асалар. Каракка да шундый ук җәзаны бирәләр.

Тарихчыларның өлкәне Әбү әл-Хәсән[1] бине әл-Хөсәен бине Гали әл-Мәсгуди әл-Багдади әйтә: «Болгар шәһәре Мантыш дәрьясы үзәнендә, мин аларны дөньяның җиденче икълимендә[2] дип беләм, алар – төрек халкының бер төре, алардан Харәзем

---

[1] Әбү әл-Хәсән Гали... – пәйгамбәрнең өлкән сәхабәләреннән Габдулла бине Мәсгуть балаларыннан һәм Багдад галимнәреннән. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

[2] Икълим – климат. Борынгы географлар, климатына карап, кеше яши торган җирләрне җиде өлешкә бүлеп йөрткәннәр.

шәһәрләренә, Хорасан һәм Харәзем җирләреннән аларга бертуктаусыз кәрван йөреп тора. Ошбу вакытыбызда өч йөз утыз икенче (942) елдагы Болгар патшасы – мөселман; ул Моктәдир биллаһ хәлифә вакытында, үзенең күргән төше сәбәпле мөселман булды, аның бер баласы хаҗ кылып, Мәдинәтес-сәлам[1] Багдадка килде, Моктәдир хәлифә аңа олы һәм кечкенә нишаннар[2] һәм кара киемнәр бирде; аларның зур мәчетләре бар. Ошбу патша илле мең кадәр атлы гаскәр белән Константиния[3] шәһәренә һөҗүм итеп, аның тирә-ягын бик каты таладылар, хәтта Рум иленә һәм Әндәлескә[4] барып җиттеләр, Борҗан, Җәлаләка җиренә һәм Европа мәмләкәтләренә кадәр барды. Аларга ярдәмгә диңгез белән бер төркем килеп, патшаларының якын килүеннән хәбәр бирделәр. Болгар гаскәренең кайбер бүлекләре Ак диңгез буйларына барып җитә. Алардан бер төркем Тарәсус халкы көймәләре белән Тарәсуска килделәр. Болгарлар – куркуны белми торган, куәтле, бик гайрәтле олы бер халык, аларга күрше булганнар барысы да аларга буйсынып, баш иеп торалар. Алардан бер атлы мөселман баһадир бер йөз, ике йөз атлы кяфергә каршы торып сугыша[5]. Константиния халкы һәм шул тирә-якта булган башка халыклар да алардан бары тик нык, биек крепостьлары булганга гына сакланып тора ала. Болгарда җәй көне төн бик кыска була». Янә болай ди: «Һиҗрәттән өч йөз елдан (912) соң рус халкы һәр көймәгә бишәр йөз кеше

---

[1] Багдад шәһәрен шул кушамат белән йөрткәннәр. «Сәламәтлек шәһәре» дигән сүз.

[2] Нишан – билге, медаль, орден.

[3] Константиния – Истанбулның борынгы исеме.

[4] Бу урында географик терминнар буталган. «Рум иле» дип, гадәттә, нәкъ Истанбул шәһәре урнашкан тирәләр йөртелә. Кайбер чакта бу исем астында хәзерге Италия – Рим шәһәре күздә тотыла. Ә Әндәлес – хәзерге Испания ярымутравы. Болгар гаскәренең Италия, бигрәк тә Испаниягә барып җитүенә ышануы читен.

[5] Бу дәвердәге сугышларда гади кешеләргә караганда көчле булган аерым батырлар бик кадерле булганнар, алар турында төрле хикәяләр сөйләнгән. Мәсгудинең бу сүзләрендә дә шул хәл чагыла булса кирәк.

утырткан биш йөз көймә[1] белән Хәзәр елгасына тоташкан Кара диңгез тармагына керделәр. Ул урында Хәзәр патшасының шул җирне сакларга куйган гаскәре аларны диңгезгә җибәрмәгәч, Хәзәр патшасы белән килешеп, алачак ганимәтләреннән ярты-сын Хәзәр пашасына бирү шарты белән, елга белән төшеп, Хәзәр диңгезенә керергә рөхсәт алдылар. Кем диңгезнең аргы ягына үтеп, диңгез буйларында урнашкан Җәел, Диләм, Табарстан, Әбскүн һәм Җөрҗан[2] өлкәләрен талап, яндырып, күп каннар түгеп, җимереп, әсирләр, ганимәт маллары алып кайтып, Хәзәр елгасы авызына килеп, патшага шарт кылган малларын биреп юлга керделәр. Бу хәлне Ларшия кавеме һәм Хәзәр илендәге мөселманнар белеп алып, Хәзәр патшасына: «Бу россиялеләр мөселманнарны талап, каннар түгеп, хатын, бала-чагаларны әсир иткәннәр, безне җибәр, без алардан мөселман кардәшләре-безнең үчен алабыз», – дип әйтеп хәзерләнделәр. Хәзәр патшасы аларны тоткарлый алмады, ләкин аларның усал уйларын рус-ларга белдерде. Мөселманнар русларны эзләп чыгып, су белән төшеп киттеләр. Бер-берсенә каршы килеп күзгә-күз очрашкач, руслар көймәләреннән читкә чыгып, кара-каршы тезелделәр. Мөселманнар белән Идел шәһәреннән бераз христианнар да бар иде. Мөселманнар унбиш мең яхшы атлы һәм кораллы иделәр. Өч көн бик каты сугыш булды. Хода мөселманнарга ярдәм биреп, русларны бик яман кырдылар, кайсы үтерелеп, кайсы батырылып һәлак булдылар, аларның утыз мең кадәресе һәлак булып, биш мең кадәресе көймә белән Бортас иле ягына килеп, көймәләрен калдырып, коры җиргә чыктылар, аларның кайсы-

---

[1] М.И. Артамонов моны «һәр көймәдә 200 кеше» дип әйтә дә, «монда Мәсгуди санны артык күбәйтеп күрсәткән, летописьларда күренүенчә, рус көймәләре ул чакта 40 кеше утырта торган булганнар. Шулай итеп, барлыгы 20 000 кеше була. Шундый төзәтмә белән Мәсгудинең санын кабул итәргә мөмкин», – ди. М.И. Артамонов. История Хазар, 371 битнең искәрмәсе. Ленинград, 1962 ел.

[2] Хәзерге тарих китапларында Җәел – Гилан, Табарстан – Табаристан, Әбскүн – Азәрбайҗан, Җөрҗан – Ширван – Каспий диңгезе буендагы өлкәләр.

ларын бортаслар, кайсыларын Болгар мөселманнары үтерделәр. Шуннан соң руслар икенче мәртәбә мондый эш эшләмәделәр[1].

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: «Болгар мөселманнары үтерделәр» дип әйтүдән максат сугышка катышмаганнары булыр, чөнки бу мәмләкәтнең мөселманнары барысы да элек «Ларшия» дип атала торган булганнар».

Бу хикәят Хәзәр мәмләкәтләрендә һәм Болгарда ислам таралып, мөселманнар куәтләнеп, Хәзәр хаканының сүзе үтми торган, хәтта мөселманнарны тыеп, үзенең солых белән бәйләнгән дуслары русларга ярдәм итә алмыйча, фәкать аларга хәбәр итүдән башканы эшли алмаслык хәлгә килгәнен күрсәтә.

Мәсгуди, бу хикәятне сөйләгәндә, үзенең «Мөрәүвиҗаззәһәб» исемле китабының басма нөсхәсендә «Былтыр» дип, «л» белән әйтә. Әмма Якут әл-Хәмәви «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында бу сүзне Мәсгудидән «Быргыр» маддәсендә күчереп: «Мәсгудинең «Быргыр» һәм «Мәдинәтел-быргыр» дигәне, ул, мәшһүр Болгар, бу сыйфатлар барысы да Болгар сыйфаты, моны мин бары икенче төрле әйтелеш дип кенә уйлыйм. Ләкин «Мантыш үзәнендә» дигәне дөрес һәм муафыйк түгел: минем уемча, Болгар шәһәре белән Мантыш диңгезе арасы бик ерак», – ди.

Тәрҗемәче фәкыйрь фикеренчә дә Якут әл-Хәмәвинең бу сүзе дөрес; ләкин Мәсгудинең язуында берәр ялгыш җөмлә калган булырга кирәк, чөнки Мәсгуди үзе дә «Болгар белән Константиния арасында ике айлык юл», – ди һәм Хәзәр диңгезен Мантыш[2] диңгезенә һәм Константиниягә тоташкан дигән сүзне юкка чыгара: «Бу диңгезнең икенче бер диңгезгә тоташуы юк, аның кечкенә бер диңгез икәнен һәркем белә», – ди.

---

[1] М.И. Артамонов. «История хазар» исемле әсәрендә (Ленинград, 1962 ел, 369–372) бу вакыйганы рус дәүләте түгел, бәлки аңа буйсынмаган ярым сәүдәгәр, ярым талаучылар төркеме оештырганлыгын яза. Ул дәвердә мондый төркемнәр төрле илләрдә күп булганнар.

[2] Манзыш, Мантыс, Нитыш – барысы да Кара диңгезнең элекке исемнәре. Камусел-әгълам, I–II т.

Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Болгарлар бер мәмләкәт булып яшиләр, алар – мөселманнар, Моктәдир хәлифә вакытында мөселман булдылар, патшалары Моктәдир хәлифәгә илче җибәреп, ислам кагыйдәләрен өйрәтү өчен галимнәр сорады, хәлифә аның үтенечен үтәде. Шуннан соң Болгардан бер җәмәгать хаҗ кылу теләге белән Багдадка килделәр, аларга хайваннар һәм торыр урыннар белән ярдәм иттеләр. Алардан: «Сез нинди халык? Болгарлар кемнәр?» – дип сорагач, алар: «Без төрек белән сәкалибә арасында туган халык», – дип җавап бирделәр».

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Габдерәхим бине Сөләйман әл-Гарнатый, Болгарга берничә мәртәбә килеп, Болгар казые белән берничә мәртәбә очрашкан. Ул үзенең «Төхфәтел-әлбаб» исемле китабында әйтә: «Болгар ике якка утырган; биналары агачтан һәм камыштан, ул Идел елгасы буена салынган; мәчетләре базарда. Суар да шул ук елга буенда, өйләре киездән, иген җирләре бик киң, бик яхшы», – ди. Болгар һәм Хәзәрләрнең телләре бер, әмма бортас теле һәм рус теле башка. Болгар – шәһәр исеме, анда зур мәчет бар, халкы мөселман. Якында тагын бер шәһәр бар, «Суар» диләр, анда да зур мәчет бар, анда ун меңчамасы ир кеше бар», – ди.

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: «Бу «Суар» шәһәренең хәрабәсе Болгар шәһәренә бик якын, шул тирә-як мөселманнары хәзер дә «Суар» дип сөйләшәләр, хәрабәсендә «Иске Гурсиха» исемле бер рус авылы утыра.

Тагын болай ди: «Бортас – бер кавемнең исеме, аларның җирләре киң, ул җир дә, аларга нисбәт бирелеп, «Бортас җире» дип йөртелә, үзе Хәзәргә чиктәш, араларында икенче кавем юк, Идел буенча җәелеп утырганнар, алар үзләре – мөселманнар, зур мәчетләре бар, телләре төрки дә, хәзәр һәм Болгар теле дә түгел; «Бортас» – шәһәр һәм өлкә исеме; аларда кызыл төсле, калын йонлы бик матур төлке бар, шул төлке тиресеннән «Бортас туны» дип дан тоткан тун тегелә. Иделдән, ягъни Әстерхан шәһәреннән, Болгарга коры юлдан бер айлык, судан менгәндә ике айлык, төшкәндә егерме көнлек юл».

Әбү Хәмид әл-Әндәлеси болай ди: «Болгар һәм Хәзәрләрнең киемнәре озын күлмәк, руслар киеме кыска. Башҗорт[1] халкы Болгарга буйсына, Болгарда сусар, тиен, сурка, карсак, төлке һәм куян тиреләре, шәм, ук, бал, чикләвек, куй, сыер, балык җилеме, балык теше, гәрәбә, саури, кылыч, сугыш киеме һәм каен агачы белән сәүдә итәләр. Руслар өч таифәдән гыйбарәт, берсе – Болгарга якын, хөкемдарлары Киев шәһәрендә тора, ул Болгардан зуррак».

Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Бортас халкы Иделгә коя торган һәм үзләренең исеме белән «Бортас» дип атала торган су буена утырганнар, өйләре киездән һәм агачтан, хәзәр белән аралары 14 көнлек юл, аларның үзләренә хас телләре бар. Әмма кыпчаклар Ширван һәм Дәрбәнд артындагы тауларда һәм Рус диңгезе буендагы иңкүлекләрдә яшиләр. Аларның «Сәрдак» исемле шәһәрләре бар. Диңгез дә шул шәһәргә якын. Аннан азык-төлек китерәләр. Кирәк булган кием-салым һәм башкаларны сату, ир һәм кыз коллар, калдәс аталган дару үләне, әсирләр[2] сатып алу өчен аларга сәүдәгәрләр киләләр. Болардан бер төркемне Аллаһы Тәгалә Мисырда һәм Шамда яшәтә.

Шигырь: «Кавем бу. Әгәр үтерелсәләр, фәрештә булалар; ә сугышканда, гыйфрит кебек сугышалар».

Кыпчаклар барысы да төрек халыклары булып, алар «береква», «туксаба», «исәба», «бәрәү», «әрәс», «тәбәрреҗ углы», «Мәңгү углы», «ямәк» дип аталалар. Болар барысы да хәрәземлек иделәр. Аларның «тыйг», «башкорт», «каләмгү», «бизанга», «Бәҗна», «карабокла», «әз», «җәртан» дигән һәм башкача бик күп исемдә вак кабиләләре бар». Янә «Мәҗмәгыль-әнсаб»та болай дип әйтә: «Болгар көнбатыш белән төньяк арасында төньяк полюска якынрак. Аларның «Суар» һәм «Болгар» дигән ике шәһәре бар, бу ике шәһәрнең арасы ике көнлек юл булып, су-елга да бар, елга буенда бик калын урман; халкы

---

[1] Башҗорт – башкорт.

[2] Бу сүз «әл-бртаси» дип басылган. Төрки телендә «бөртас» сүзе «әсир, кол» мәгънәләрендә йөргән. Шуңа күрә без дә бу сүзне шулай, «әсир» дип тәрҗемә иттек.

барысы да мөселман, ләкин бертуктаусыз кяферләр белән сугышып торалар, аларның урманнарында кеш, тиен, кондыз бик күп була».

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: монда «Суар» дип аталган шәһәр «Сембер» шәһәре түгел микән, чөнки хәзер дә «Суар» дип аталган шәһәр хәрабәсе шәһре Болгарга бик якын, аларның ике араларында андый су юк.

«Раузатес-сафа» китабында әйтә: «Алар – һәммәсе мөселман, хәнәфи мәзһәбендә». Хәнәфи мәзһәбендә булган галимнәрдән фәтва сорау һәм Болгар халкының тырышлык һәм өндәүләре белән исламга кергән башкортларның соңгы дәвердә дә хәнәфи мәзһәбеннән булулары «Раузатәс-сафа» сүзен куәтли. «Фәрһәң»-дә: «Болгар» һәм «Синфар» дигән ике зур шәһәр бар», – диелә. «Рисаләтел-интисаб»та Болгар җире – ислам төрекләре иле, алар Габбасия дәүләтендә Мәәмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытында, тагын әл-Каиме би – Әмриллаһ хәлифәлегендә утыз мең йорт мөселман булдылар», – диелә. Якут әл-Хәмәви: «Хәләб шәһәрендә бер башкорт мулласын күрдем. Ул: «Борынгы заманда шәһре Болгардан җиде кеше килеп, бик тырышып өндәүләре белән безне ислам диненә керттеләр», – дип әйтә, ди. Кайбер тарих китапларында: «Бортас» Болгарга тоташ, алар бер төз җирдә, суын Хәзәр диңгезенә коя торган «Ител» исемле бер елга буена утырганнар, җирләре тугай, бик еш урман, күбрәк агачлары каен агачы. Алар белән Болгар арасы өч көнлек юл, хайваннары, иген кораллары һәм игеннәре бар, патшаларына хайван бирәләр, мөселманнар көймәсе килсә, малдан гошер[1] алалар, киемнәре һәм каберлекләре мөселманнар киеменә һәм каберлегенә охшыйлар. Болгарлар аларга һөҗүм итәләр. Алар Хәзәр белән Болгар арасында; алар белән Хәзәр арасы унбиш көнлек юл; алар Хәзәр патшасына буйсыналар, аңардан ун мең атлы гаскәр чыга; аларның гомуми башлыклары юк, ләкин һәрбер мәхәлләдә бер шәехләре бар, шуның алдына хөкемгә киләләр».

[1] Гошер – малның уннан берен салым итеп алу.

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: Бу исламга керүләреннән элекке хәлләре булырга тиеш, югыйсә Болгар патшасы үзенә якын урында үзенә каршы булган бер халыкны тотмас иде; шуның белән бергә, алар шул вакытта ук мөселманга ияреп, алар рәсеме буенча эшлиләр икән. Аларның мөселман булуларын, зур мәчетләре булганлыкны Әбү Габдулла әл-Гарнатый һәм башкалар да сөйлиләр...

Болгарларның сугышлары турында

Болгар халкы батыр йөрәкле, каты күңелле, сугышчан, диндар, изгелекле булганнар, шуның өчен сугыш коралын олылаганнар, хөрмәт иткәннәр һәм бу сыйфатлары белән мактанганнар да. Хәтта кабер өсләренә куйган ташларында да «сугышчан ир» дигән сүзне аңлата торган «юари», кара-каршы сугыш батыры дигән сүзне аңлаткан «шуари», «фәхес»[1], шулай ук «үкеш» һәы «изгелек иясе» шикелле сүзләр язганнар. Аларның кыскача хәлләре Византия һәм Рум халыкларына, аларның патшаларына, милади белән биш йөзенче ел ахырларында мәгълүм булулары турында хәбәрләр бар. Шул тирәләргә ясаган һөҗүмнәреннән белгәннәр: аларны «һуннар», «утугырлар», «кутугырлар»[2] дип берничә исем белән атаганнар. Аларның юлларын кисү, илләренә ясала торган һөҗүмнәрен туктату өчен, «кайсар Анастасья озын һәм биек койма койдырса да, туктата алмыйча, кайсар Юстиниан гасырында тагын һөҗүм иттеләр, икенче елда янә икенче мәртәбә һөҗүм итсәләр дә, бу мәртәбәсендә үзләре җиңелеп качтылар. Болгар патшаларыннан Зөбәер хан дигән кеше Идел буеннан кузгалып, бик зур куәт белән йөреп, славяннарны һәм башка бик күп таифәләрне ияртеп, атлы гаскәрләре белән Дунай суын боз өстеннән үтеп, мул тарафларда булган мәмләкәтләрне талап, халкын үтереп, үзе Константиниядән утыз чакрым җиргә килеп җитеп, Юстиниан

[1] Мәрҗанидә «әш-шүари», «әл-фәхес» формасында. Без соңгысын «әл-гаҗес» дип укыдык. Бу сүзләр «алышучы, сугышчан» мәгънәләрендә кулланылган булса кирәк.

[2] «Утугырлар», «кутугырлар» – шул вакыттагы кабилә исемнәре.

кайсар бик каты куркып, калтырап, тетрәп, малларын, кыймәтле нәрсәләрен крепосте астына яшереп, башкаласы чак кына котылып калды. Моннан соң Идел елгасының көнчыгыш тарафыннан Бәян хан дигән бер кеше чыгып, Болгар халкын һәм башка шул мәмләкәттә яшәүче таифәләрне үзенә буйсындырды. Аннары Болгар хөкемдары Карабат дигән кеше күтәрелеп, аның үзеннән соң өч улы кала. Берсе, ягъни олылары, Батбай үзенә буйсынучылар белән үз ватанында кала һәм бераз вакыт үткәч, Хәзәр хөкемдарына буйсыналар. Икенчесе Котраг Дон елгасының көнбатыш ягына үтеп, шул җирне үзенә ватан итте. Өченчесе – Асбаруг – халкының күбрәге һәм терлек-туары белән Днестр елгасыннан үтеп, кайбер славяннарны үзенә буйсындырып, «Бөрҗан» мәмләкәтендә нигезләнде. Дунай елгасы тирәягын талаулары сәбәпле, Константиния кайсары коры җир һәм диңгездә зур көчләр белән алар өстенә чыкса да, гаскәре җиңелеп качты. Болгарлылар җиңделәр, кайсарга һәм Дунай буендагы башка мәмләкәтләргә салым салдылар. Шул заманда һиҗринең алтмышынчы (680) елларында болардан бер таифә аерылып, Дунай буенда нигезләнеп, «Кечек Болгар дәүләте» дигән мөстәкыйль бер хөкүмәт төзеделәр. Рум халкы аларны «кечек Болгар» исеме белән, Идел елгасы буендагы «Зур Болгар»дан аерып йөрттеләр. Кайбер тарихчылар Зур Болгарны «Кара Болгар», кайсылары «Ак Болгар» яки «Эчке Болгар» дип аердылар. «Кара» дип исемләү Габбаси хәлифәләргә ияреп, «Ак» дип, культуралы һәм гыйлем ияләре булганлыктан, «эчке» дип, исламга кергән яки хәлифәлек хөкемендә булганлыктан әйтелгән булыр. Дунай болгарларының «Богар» исемле хөкемдарлары йөз сиксән дүртенче (800) һиҗридә, румнарга ияреп, христианлык кабул иткән һәм «Михаил» дип аталган. Аларның Шәмгун исемле мәшһүр хөкемдарлары һиҗри ике йөз җитмеш бишенче (888–889) елдан өч йөз утызынчы (941–942) елга кадәр хөкемдарлык итеп, «бәндәкыя», «серб», «харват» һәм болардан башка барлык күршеләре белән берләшеп, хәтта гарәпләр белән дә солых ясап, тынычлангач, кайсар белән сугышка әзерләнде. Кайсар, болгарлар христианлыкны кабул иткәч, аларның ярдәм һәм булышуын-

нан файдаланырга уйлый иде, ләкин киресе килеп чыкты... Ибне Хәүкаль, ибне әл-Әсир һәм башкалар болай диләр: «Өч йөз илле сигезенче (968–969) елда Россия хөкемдары үзенә ил-күршеләр җыеп, кыпчактан берәр таифә алып, төрекләр ярдәме белән Болгарларга һөҗүм итеп, аларны җиңеп, солых ясадылар, ул сугышта Болгарларга бик зур сыныклык килгән. Таш суда йөзә башлаганчы, колмак төпкә батканчыга кадәр солыхны сакларга тиеш булганнар. Өч йөз җитмеш дүртенче (984–985) елда Россия хөкемдары Владимир, Болгарга килеп, җентекләп тикшереп солых ясады. Ислам динен яхшы дин дип танып, үзе ислам диненә керергә якынлашты. Моннан соң Суздаль җирендә ачлык булганда, болгарлылар россиялеләргә күп икмәк бирделәр. Берникадәр вакыттан соң солыхлары бозылып, дүрт йөз сиксән беренче (1088–1089) елда болгарлылар Россиядән Муром шәһәрен алдылар. Биш йөз илле тугызынчы (1163–1164) елда Андрей Иванович дигән Россия хөкемдары болгарлар өстенә килеп, аларны җиңеп, Болгар әмирен качырып, әләмнәрен алып, Ибраһим шәһәрен һәм башка берничә шәһәрне яндырды. Рус халкы бу җиңүне хәтерләп, әле дә булса һәр ел август аенда бәйрәм итә. Биш йөз алтмыш җиденче (1171–1172) елда әлеге хөкемдар үзенең углын гаскәр башы итеп болгарлар өстенә җибәрде. Бу мәртәбәдә болгарлылар өстен чыгып, Россия гаскәрен тәмам тар-мар итеп җиңделәр, гаскәр башлыклары көчкә генә качып котылды. Биш йөз җитмеш тугызынчы (1183–1184) елда болгарлылар Муром һәм Рязань шәһәрләренә һөҗүм иттеләр. Моннан соң Россия хөкемдары кыпчак төрекләре белән берләшеп, янә шәһре Болгарны чолгап алдылар, ләкин Россиянең олы хөкемдары Всеволод Егоровичның яшь энесе Изяславның яралануы сәбәпле җиңелеп, солых ясап кайтып киттеләр. Биш йөз сиксән икенче (1186–1187) елда россиялеләр тагын Болгар мәмләкәтенә килделәр. Алты йөз унбишенче (1218–1219) елда Болгарлар «Устюг» шәһәрен басып алдылар. Бу вакыйгадан соң руслар, Болгар мәмләкәтенә килеп, биек имәннән ике кат койма белән, коймаларның уртасына канау казып эшләнгән «Ашлы» крепостен яндырып, күп һәлакәт китерделәр.

Ибне әл-Әсир һәм Ибне Халдун әйтәләр: «Татарлар, Дәрбәнд тарафыннан килеп чыгып, шул тирәдә яшәүче мөселманнарны, кяферләрне, бигрәк тә лан, кыпчак һәм русларны үтереп, бик каты талап, яндырып, бөтенләй харап булу дәрәҗәсенә китергәннәр. Болардан бушангач, алты йөз егерменче (1223) елның ахырында Болгар мәмләкәтенә барырга уйладылар. Болгар халкы, бу хәбәрне ишеткәч, алар юлында берничә җирдә дошманнан яшеренеп, посып тору урыннары ясап, аларга каршы чыкты. Татарлар килеп, посып тору урыннарын үткәч тә артларыннан чыгып, һәрьяктан татарларны урап алып, сугыш ачып, аларны үтереп бетерделәр, бик азы гына качып котылып, Сәксин ягына киттеләр һәм Талкан дигән җирдә патшалары Чыңгыз ханга юлыгып, барлык мажараларны сөйләп бирделәр. Бу вакыйгадан соң Дәште Кыпчак татарлардан бушап калды. Юллар тыныч-ланып, сәүдәләр ачылып китте, элеккечә кәрваннар йөри башлады, кыпчакларның һәм русларның да сәламәт калганнары илләренә кайттылар, алты йөз утыз өченче (1235–1236) елда Бату хан гасырында татарларның Субутай дигән гаскәр башлыгы белән зур көчләре Болгарга килделәр, болгарлылар аларга түбәнчелек һәм буйсынуларын күрсәтеп, татар мәмләкәтенең бер өлеше һәм аңа салым түләп торырга риза булдылар. Татарлар аларны бөтенләй үз кулларына алдылар, әмма дәүләтләрен бетермәделәр. Болгарлар дуслык күрсәтеп, акча сугуда, хөтбәләрдә телгә алсалар һәм салым түләсәләр дә, кыргыйлык һәм эчке дошманлык сәбәпле, арада сугыш һәм бәрелешләр булып тора иде. Мәсәлән, Мәңгү Тимер хан бик зур гаскәр белән Болгарга һөҗүм итеп, аны җиңде һәм солых ясап кайтты. Шул ук вакытта Россиядән Новгород халкы да Болгарга кат-кат һөҗүм итеп, талап торды. Җиде йөз алтмыш беренче (1359–1360) елда руслар Жукотин шәһәренә керделәр. Шуннан соңгы елда Россия хөкемдары Дмитрий Константинович һәм башкаларның Болгар җирен талаганнары өчен болгарлылар Үзбәк ханга шикаять язып, рус хөкемдарларын җавапка тарттылар. Руслар, хан хозурына килеп, талаучыларны табып биреп кенә котылдылар. Җиде йөз алтмыш икенче (1360–1361) елда Болгар әмире Пулат Тимер заманында болгар-

лылар Нижний Новгород чигенә һөҗүм итсәләр дә, Мамай мирза ярдәме белән Суздаль хөкемдары Дмитрий Константиновичның углы Василий аларның һөҗүмнәрен туктатты. Җиде йөз җитмеш алтынчы (1374–1375) елда Новгород халкы Болгар мәмләкәтен талады. Җиде йөз җитмеш сигезенче (1376–1377) елда Россия хөкемдары Дмитрий Иванович татар хөкүмәтеннән чыгу теләге белән Болгарның бай җирләрен яулап алу өчен Суздаль гаскәре белән кушылып, Болгар мәмләкәтен талады, берникадәр авыл-ларны, Казанны һәм көймәләрне яндырды. Казан халкы биш мең акча биреп, Мәскәү тамгачысын кабул иттеләр; Болгар әмире Хөсәен һәм аның туганы Мәхмүд түбәнчелек белән солых ясадылар. Җиде йөз сиксән бишенче (1383–1384) елда Туктамыш ханның кыздыруы һәм кызыктыруы белән болгарлылар русларны таладылар, яндырдылар һәм үтерделәр. Җиде йөз туксан өченче елда (1390–1391) Россия хөкемдары Василий Дмитриевич, Болгар мәмләкәтеннән Жукотин, Кирмәнчек һәм башка шәһәрләрне алып, үзенә «Болгарны яулап алучы» дигән исем куйды. Сигез йөз утыз бишенче (1431–1432) елда Василий Васильевичның гаскәр башлыгы Болгарга керде, ләкин Болгарның бөтенләй Россия кулына кайчан кереп бетүе, кайсы заманда аның тәмам харап булуы безгә мәгълүм булмады. Гомумән, Тимер дәвере үткәнче дәүләтләре, мөстәкыйль патшалык сил-силәсе[1] дәвам итте. Гәрчә халык телендә «Тимер Болгарга керде, шәһәрен җимерде, патшасын һәм дәүләтнең олыларын юк итте» дигән сүзләр йөрсә дә, ышанычлы һәм дөресләнгән хәбәрләр түгел. Бәлки, халык аны Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими тарихыннан алып әйтә торганнардыр, ләкин ул китап игътибарга лаеклы түгел. Якут әл-Хәмәви үзенең «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында татарлар Болгарга килеп җиттеләр дип кенә әйтә дә, чолгап алу һәм аны яулап алу турында әйтми. «Раузатес-сафа»да һәм башкаларда Аксак Тимер Туктамыш ханга һөҗүмендә шәфәкъ батмый торган җиргә җитте дип кенә тәмам итәләр, әмма Болгарны алды, харап итте –

[1] Силсәлә – чылбыр, нәсел-нәсәп бәйләнеше.

җимерде, барын да үтерде дигән сүзне әйтмиләр. Аксак Тимер Кытай сәфәрендә сигез йөз җиденче (1404–1405) елда «Утрар» дигән җирдә вафат була һәм шул сүз аның вафаты тарихы була. Аның гасырыннан соң Болгарда татар ханнары исеменә сугылган тәңкәләр күпләп табыла, шулай булгач, Тимерне Болгарны бөтенләй җимерде дигән сүз дөрес булмый.

Болгар халкы әсәрләре һәм галимнәре турында[1]

Алмас хан гасырында Болгарның үзендә һәм читтән килүчеләр арасында дин һәм шәригать хөкемнәреннән хәбәрдар булган галимнәр һәм хәкимнәрнең булганлыгы аңлашыла. Шуның белән бергә, татарларның иске мәкальләре буенча, «Олы казанда кайнаган чи калмас» дип, Багдад хәлифәлегенә илчеләр җибәреп, дин һәм ислам әдәпләрен, кием кию һәм тормыш рәвешләрен өйрәтү өчен, ислам хәлифәсеннән галимнәр, һәрбер эштә оста булган белгечләр сорады. Әмма үзләренә махсус ачык итеп язылган тарих китаплары калмаганлыктан, патшаларның, галимнәрнең һәм башка кешеләрнең күпчелегенең дөрес хәлләре мәгълүм түгел. Болгарның казыйсы булган Ягъкуб бине Ногман әл-Болгари дигән кешенең Болгарга махсус тарих китабы булганлыгы билгеле булса да, ул китапның нөсхәләре хәзерге заманда табылмый. Хәтта үзебезнең гасырыбызда Европа дәүләтләре махсус игъланнар бастырып, төрле ислам мәмләкәтләреннән ул китапны һәм Ибне Фазланның рисаләсен эзләсәләр дә, һичбер җирдә барлыгы мәгълүм булмады. Әбү Хәмид әл-Әндәлеси, биш йөз егерме тугызынчы (1134–1135) елда шәһре Болгарга килгәч, әлеге Болгар тарихы иясе белән күрешеп, аннан күп сүзләр күчереп сөйли. Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини аны Әбү әл-Мәгали Габделмалик бине Габдуллаһ әл-Җөвәйнинең юлдашыннан иде, ди. Биш йөз илле тугызынчы елда (1163–1164) вафат булды.

[1] Бу бүлек кыскартып алынды.

Болгар галимнәреннән берсе Әбү әл-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгаридыр. Бу шәхес биш йөзенче (1106) елларда исән иде...

Тагын алардан – Хуҗа Әхмәд әл-Бырсыры Салават Мәсгуди китабында «Хуҗа Әхмәд Бырсыры» дип язылган, әмма башка урыннарда әш-шәехе Әхмәд әл-Болгари Солтан Мәхмүд бине Сәбектәкин әл-Газнәвинең остазы һәм шәехе дип телгә алына...

Бырсыр дигән сүзнең шәһре Болгар булуы Мәсгуди һәм Якут әл-Хәмәви һәм башкалар китабында әйтелгән...

Мәзкүр шәхеснең бер генә кешеме яки берничәме булганлыгы мәгълүм булмады. «Тарикаи Бырсырия»нең тәмамланган томнарын күргәнебез, ул китапка ия була алганыбыз һәм бу шәхеснең тәрҗемәи хәлен хәзергәчә һичбер тарих китапларында тапканыбыз юк.

Янә әш-шәех Борһанетдин Ибраһим бине Хазар әл-Болгари. «Ысулел-хосами» исемле китабын язып тәмам иткәч: «Бу китап 751(1350) нче елда рабигыль-әүвәл аеның өченче көнендә төш вакытында Ибраһим бине Хазар әл-Болгари кулы белән язылып тәмам булды», – дип язган...

Янә әш-шәех Әбү Мөхәммәд Садыр бине Галәветдин әл-Болгари.

Янә әш-шәех әл-имам Хуҗа Хәсән бине Гомәр әл-Болгари. Икенче бер сүзгә караганда, бу галим Азәрбайҗан мәмләкәтенең Гәнҗә шәһәреннән булса да, Болгар шәһәрендә күп заман яшәгәнлеге сәбәпле, «Болгари» дип мәшһүр булган. Болгар шәһәрендә вакытында кайбер дошманнарының яла ягулары сәбәпле, манарадан ташлап үтерелергә хөкем ителгән булса да, качып китеп котылган.

Әш-шәех Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари...

Әш-шәех Касыйм бине Ибраһим әл-Казани. «Касыйм шәех Газизан» дип танылган. Вәли Газизан әл-Кәүһәзринең мөриде иде. Тугыз йөз туксан сигезенче (1588–1589) елда Бохара белән Сәмәрканд арасында Кирминәдә вафат булган. «Тәварихе Болгария» иясе Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең сүзенә караганда, шәех Касыйм бине Ибраһим яңа Казан кешесе, вафаты да шунда... Хәзер дә Казанда беренче мәчет

мәхәлләсендә бер йортны Касыйм шәех йорты дип, якыннарын да «Касыйм шәехләр» дип йөртәләр. Халык нәзер, садака, тавык, үрдәк, каз кебек нәрсәләрне Касыйм шәехкә дип китерәләр[1].

Әш-шәех әл-галләмә Нәҗметдин Әбү әр-Ражә Мохтар бине Мәхмүд бине Мөхәммәд әл-Казвини, әл-Хәнәфи; «Заһиди» дип исеме таралган.

Әш-шәех әл-Фазыл Әхмәд бине Мәхмүд әл-Җөнди (Аллаһ аңа рәхмәт итсен).

Әл-галләмә Котбетдин Мөхәммәд бине Мөхәммәд әр-Рази, әш-Шәфигый. «Тәхтани» дигән кушамат белән исеме таралган... Җиде йөз алтмыш алтынчы (1364) елда вафат.

Әш-шәех Минһаҗетдин Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи...

Әш-шәех әл-Вагыйз ән-Насыйх Әхмәд бине Шәмсел-өммәт әс-Сараи (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Ибне Гарәбшаһ аның турында: «Гарәп, фарсы, төрки телләренең патшасы, заманның гаҗәеп кешесе иде», – ди торган булган. Бу галимне Аксак Тимер Сәмәркандка чакырып алган.

Әл-галлямә Сәгъдетдин Мәсгут бине Гомәр әл-Хорасани, ән-Нәсаи, әш-Шафигый. «Тәфтәзани» дип мәшһүр булган галим... Җиде йөз туксан икенче (1389–90) елда Сәмәркандта Тимер хозурында аңсыздан үлеп калган...

Әш-шәех Камалетдин әл-Хоҗәнди әз-Заһиди. Сәед Ракыйм әйтә: «Туктамыш хан гаскәренең Тәбриз өлкәсенә һөҗүм итүе вакытында, шәех Камалетдин анда яши торган булган. Бу өлкәне яулап алганнан соң, Туктамыш ханның боерыгы белән, Дәште Кыпчакка Сарай шәһәренә күчерелде. Анда аңар бик яхшы шартларда яхшы тормыш бирелгән. Җиде йөз туксан өченче (1390) елда шунда вафат булган».

Әш-шәех Хафизетдин Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Шиһаб бине Йосыф әл-Харәзми әл-Кәрдәри. Исеме «Ибне әл-Бәззаз» дип мәшһүр булган. Яше сиксәннән үтеп, сигез йөз егерме җиденче (1423–1424) елда рамазан аенда үлде. Башлангыч белемне үз илендә алганнан соң, Болгар, Кырым һәм Рум

[1] Хәзер инде бу йорт һәм Касыйм шәех нәселе дип аталган кешеләр юк.

мәмләкәтләренә китеп, аларның галимнәре, бөек кешеләре белән аралашып, алардан күп гыйлем алган. Күп заман Болгар шәһәрендә, Хаҗитарханда һәм Кырым шәһәрләрендә торган. Татар патшалары, Җуҗи хан балалары алдында кадер, гыйззәте бик югары булган. Аксак Тимерне «кяфер» дип фәтва биргән галимнәрдән...

Госсам бине Габделмалик әл-Мәргыйнани, Тимер гасырында үзе һәм атасы белән бертуганның углы Габделәүвәл бине Гали белән икесе мәмләкәтнең олыларыннан саналалар иде. Үзе галим һәм шагыйрь иде.

Әл-галләмә әл-фазыйль Шиһабетдин Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габдуллаһ әл-Карши әд-Димәшкый. «Ибне Гарәбша» исеме белән мәшһүр. Җиде йөз туксан беренче (1388–1389) елда Шамда туып, сигез йөз илле дүртенче (1450–1451) елда үлде. Галим, фазыл, әдип һәм шагыйрь кеше, халыкның көнкүрешеннән, дөнья тарихыннан, үткән заман хәлләреннән хәбәрдар иде. Болгар илендә, Гыйракта, Хорасанда, Румда, Мавәраэннәһердә, Мангол һәм төрек илендә, Харәземдә сәяхәт итеп, күп нәрсә күрде, күп файда алды һәм күп китап язды. Бәриятел-Бәркәдә (Алтын Урда) озак яшәде. Углы Таҗетдин Әбү әл-Фазыл Габделваһһап сигез йөз унөченче (1410–1411) елда Хаҗитархан шәһәрендә туды. Ул да галим һәм фазыйль кешеләрдән иде. Һәр икесе сөнниләрдән. «Вафиятел-әсляф...»та һәр икесенең озын биографияләре бар. Теләгән кеше шунда мөрәҗәгать итсен. Ибне Гарәбша «Гараибел-мәкъдур фи нәвадири Тимур» исемле китабында әйтә: «Дәштнең башкаласы – Сарай шәһәре. Ул – мөселман шәһәре, биналары төзек булган ил. Бәркә солтан (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) мөселман булгач, шушы шәһәрне бина итте һәм башкала итеп билгеләде, аны төзек, пакь итте. Дәшттә яшәүчеләрне ислам кабул иттерергә өлгерде. Шуңа күрә һәр изгелек һәм бәрәкәтнең урыны кебек, бу шәһәр кыпчак сүзенә өстәлеп йөртелгән кебек, «Бәркә» сүзенә дә өстәлеп йөртелде»[1].

---

[1] «Бәркә сарае» (Сарай-Бәркә) дип йөртелү күздә тотыла булса кирәк.

Тагын болай ди: «Бәркә хан ислам кабул итеп, хәнәфиләр мәзһәбен ихтыяр иткәч, халкына дин өйрәтү, бер Аллаһка ышану юлларын төшендерү өчен, төрле яклардан галимнәр һәм шәехләр чакырды, моның өчен ул зур юмартлык күрсәтте, килүчеләргә бүләк диңгезләре яудырды, гыйлем һәм галимнәрнең хөрмәтен күтәрде, Аллаһы Тәгаләнең һәм пәйгамбәрнең байрагын олылады. Шуңа күрә аның заманында, Үзбәк хан, Җанибәк хан заманнарында һәм алардан соң, Мәүлана Котбетдин әл-галләмә әр-Рази, әш-шәех Сәгъдетдин әт-Тәфтәзани, әс-Сәйеде Җәләлетдин, «Хаҗбия» китабына шәрех язучы һ.б. хәнәфи һәм шафигыйләрдән олы кешеләр булды. Алардан соң – мәүлана Хафизетдин әл-Бәззаз һәм мәүлана Әхмәд әл-Җөнди (Аллаһ аларга рәхмәт итсен). Шушы өлкәннәр аркасында Сарай шәһәре гыйлем урыны һәм сәгадәт чыганагы булып әверелде. Анда галимнәр, олылар, әдипләр, изгеләр, яхшылар җыелды, мондый олылык ияләре мондый аз вакыт эчендә башка һичбер урында тупланмадылар. Болар, чыгышлары ягыннан Болгар кешеләре булмасалар да, Болгарга килгәннәр һәм озак-озак торганнар».

Әш-шәех Мөхәммәд әл-Болгари Вәгазь һәм нәсыйхәт бабында «Хәзинәтел-галләмә вә зиннәтел-фөкаһа» исемле кыскача бер китап язган...

Әхмәд бине Габдулла әл-Кырыми. Габделәүвәл бине Гали әл-Фиргани, Хафизетдин бине әл-Бәззаз һәм Шәрәфетдин бине Кәмалетдин әл-Кырыми аның шәкертләреннән иде... «Әхе Чәләпи» дип мәшһүр Йосыф бине Жөнәед әт-Тукатый – моның шәкерте иде.

Болгар патшалары турында

Хисаметдиннең тарихын игътибарга алганда, борынгы Болгар патшаларыннан безгә билгеле булганнарның беренчесе – Тәүкый хан, аннан соң аның углы Айдар хан булып, аның гасырында сәхабәләр килеп, аның авыру кызын дәвалап сәламәтләндерәләр, шуның өчен хан һәм Болгар халкы мөселман булганнар. Ләкин мин бу хәбәрнең дөреслегенә һич тә ышана алмыйм. Моннан соң Зөбәер хан. Бу хан, күп гаскәр белән барып, Кон-

стантиния кайсарын һәм аның халкын зур куркуга төшерде дип әйтелгән, исламнан элек булмаса кирәк. Аннан соң Сәлки хан, башлап мөселман булып, Багдадка илчеләр җибәреп, исламга керүен хәлифәгә мәгълүм иткән Алмас ханның атасы була ул. Алмас хан үзенә «Җәгъфәр», атасына «Габдулла» дип исем биргән иде. Аннан соң аның углы әмир Җәгъфәр. Моның гасырында Болгар шәһәренә Багдадтан Сәһсән әр-Расиби, Бәдәр әл-Хәрәми һәм Әхмәд бине Фазлан исемле илчеләр җитәкчелегендә дин өйрәтү өчен галимнәр, төзелеш һәм башка эшләр өчен оста белгечләр килде. Өч йөз утыз икенче (943–944) елда әле сәламәт булып, Константиния һәм шул тарафтагы башка мәмләкәтләргә һөҗүм итүе Әбү әл-Хәсән әл-Мәсгуди китабында ачык итеп әйтелгән. Аннан соң аның углы әмир Әхмәд. Бу шәхес Моктәдир биллəh хәлифәлеге вакытында Багдад аркылы хаҗга барып, хәлифәлек диваныннан аңа күп маллар, хайваннар, киемнәр, байраклар, музыка кораллары бүләк итеп бирелде. Аннан соң аның углы әмир Талип. Бу шәхес исемендә өч йөз утыз сигезенче (949–950) елда шәһре Болгарда сугылган тәңкәләр бар. Аннан соң аның углы әмир Мөэмин. Бу кеше патшалык иткән вакытта, ягъни өч йөз илле сигезенче (968–969) елда Россия хөкемдары Владимир кыпчак төрекләренең ярдәме белән Болгар иленә һөҗүм итеп талады, җимерде, үтерде, әсир алды. Болгарлыларга салым салырга теләгәндә, рус гаскәрләре башлыгы үзенең хөкемдарына: «Боларның аяклары итекле, болардан без салым ала алмабыз, без чабаталылар өстенә барыйк, безгә шулар кулай булыр», – дип әйткәнлеге риваять ителә, ягъни алар мәгърифәтле, культуралы халык. Шәһре Болгарда өч йөз алтмыш алтынчы (976–977) елда бу кеше исемендә сугылган тәңкәләр бар, Габбаси хәлифәләреннән әт-Таигы биллəh Әбү Бәкер Габделкәрим бине әл-Мотыйгның замандашы иде.

Аннан – соң әмир Шәмгун, бу кеше Дунай Болгарларыннан булса кирәк.

Аннан соң – әмир Хәйдәр. Аннан соң – аның углы әмир Мөхәммәд. Аннан соң – аның туганы әмир Сәгыйд. Аннан соң – әмир Бараҗ. Аннан соң – әмир Ибраһим. Биш йөз алтмышынчы

(1164–1165) һиҗридә бу кеше исән иде. Болгар мәмләкәтендәге мәшһүр Ибраһим шәһәре бу кеше исеме белән бәйләнгән түгел микән?

Аннан соң – аның углы әмир Сәлим. Габбасия хәлифәләреннән ән-Насыйр әд-диниллəһ Әбү әл-Габбас Әхмәд бине әл-Мөстәзаның замандашы иде. Болгарда сугылган акчалар арасында, ән-Насыйр диниллəһ әмирел-мөәминин» дип язылган тәңкәләр бар. Үзебез дә берничә данәсен таптык. Ләкин соңгырак заманда сугылган.

Аннан соң – углы әмир Илһам. Моның гасырында татарлар Болгарга киләләр. Алты йөз егерменче (1223) елның ахырында шәһре Болгарга килеп, болгарлылардан җиңелеп, исән калганнары Талкан шәһәрендәге патшалары Чыңгыз хан алдына кайтып киттеләр. Шуннан соң юллар ачылып, кәрваннар йөреп, сәүдәләр була башлады. Җужи хан үзенең атасы Чыңгыз ханнан алты ай элек вафат булды. Чыңгыз хан аның өлешен аның икенче углы Бату хан бине Җужи ханга биреп, аңарга «Саин»[1] дигән кушамат бирде. Бату хан, бабасы Чыңгыз хан яныннан китеп, алты йөз утыз өченче (1235–1236) елның ахырында икенче мәртәбә Болгарга һөҗүм итәргә уйлап, Субутай дигән кешене гаскәр башлыгы итеп җибәрде. Бу сугышта Болгарлар җиңелделәр. Болгар әмире татарларга салым түләргә риза булып, алар хөкүмәтенә буйсынып, урынында калды.

Соңыннан – әмир Фулад Тимер, моның гасырында җиде йөз алтмыш икенче (1360–61) елда Болгарлар Нижний шәһәренә бардылар.

Аннан соң – әмир Габдулла. Аннан соң – әмир Хәсән. Җиде йөз җитмешенче (1368–1369), җиде йөз җитмеш алтынчы (1374–1375) һәм җиде йөз җитмеш сигезенче (1376–1377) елларда Болгарда моның исемендә сугылган тәңкәләр бар. Казанда Кабан күле башындагы епископ йортының капкасы алдындагы зур таш бу кешенең каберенә куелган таш түгел микән? Безнең фикеребезчә, ул татар ханнарыннан булмаса кирәк,

[1] Саин – сайланып алынган, хөрмәтле.

чөнки алар мөстәкыйль патшага «хан» исемен ташлап, «солтан» исемен бирү белән генә канәгатьләнмиләр, «солтан» исемен алар шаһзадәләренә бирәләр. Ул ташта: «Әмир вә солтан вә зыйльлуллаһе лил-галәмәйн», – дип язылган. «Зыйльлуллаһе лил-галәмәйн» дигән сүз һәм аннан башка галәмәтләр дә аның мөстәкыйль патша булганлыгын күрсәтәләр, һәм бу исем белән генә канәгатьләнеп, «хан» исемен телгә алмавы татар ханнары җөмләсеннән булмаганлыгын күрсәтә.

Моннан соң – аның кардәше әмир Мәхмүд. Аннан соң – әмир Габдулла. Халык телендә: «Моны Аксак Тимер үтерде, аның Алтынбик исемле тугыз яшьлек, Галимбик исемле җиде яшьлек ике углы калды. Тимер Болгарны ватты, җимерде, халкын таратты», – дип сөйләнә, ләкин бу сүз дөрес түгел, чөнки Тимер Туктамыш хан белән җиде йөз туксан өченче (1390–1391) елда сугышты һәм сигез йөз җиденче (1404–1405) елда Кытай сәфәрендә Утрар дигән җирдә вафат була, «утрар» сүзе аның вафат тарихы булды. Бу вакыйгадан соң сигез йөз утызынчы (1426–1427) еллар үткәч, шәһре Болгарда татар ханнары исемнәренә сугылган тәңкәләр күп. Шәһре Болгарның кайсы заманда Россия кулына керүе, кайчан һәм нинди сәбәпләр белән җимерелүе мәгълүм түгел. Язмыш аркасындамы, берәр дошманлык сәбәплеме – һичберсе ачык түгел. Тимер харап кылды дигән сүз дөрес булса да, аннан, бөтенләе белән җимерелеп, ташландык булып калуы лязим түгел. «Руслар әмир Мөэмин заманында харап кылды», – дигән сүз дә ышанычлы түгел.

Аннан башка тагын: «Болгарны алты йөз җитмеш җиденче (1278–1279) елда татар патшаларыннан Мәнгү Тимер хан харап кылды», – дигән сүзләр дә бар, ләкин һичкайсында тәмам җимерелгәне турында сүз юк. Татар җәмәгатьчелеге телендә «Болгарны Канаш исемле епископ харап итте – җимерде» дигән сүз дә йөри. Әгәр бу сүз дөрес булса, бәлки, үзенең тәгассебе сәбәпле, берничә бинаны җимерсә җимергәндер. Татар халкы авызында Идел күчү сәбәпле җимерелде дигән сүз дә бар, Хода белә, бәлки, руслар Казанны алган чакта, Болгарга да хуҗа булганнардыр. Халкыбызның гаять әһәмиятле тарих гыйлеме белән

кызыксынмаулары сәбәпле, барлык хәл яшерен булып, караңгылыкта калган. Хәтта хәзерге гасырыбызга кадәр сакланып калган ике манарасының зурысы егылгач, шуның кайсы елда җимерелеп төшкәнен эзләп, сорап, байтак вакыт үткәннән соң, Спас өязе Олы Чаллы авылының мәрхүм Фазлулла бине Бохарайның язма җыентыгыннан табып алып тәшәккер кылынды. Ул: «Мең ике йөз алтмышынчы (1844) һиҗридә сишәмбе көн кичәсе рамазан аеның 19 ында ярты төндә җимерелде», – ди. Мәрхүм Ибраһим әфәнде мең ике йөз утыз бишенче (1819–1820) елда җәй көне шәүвәл аенда шәһре Болгарга зиратка барган. Ул вакытта әле манара үз урынында утыра торган булган. Шул кеше үзенең җыентыгында: «Ул манарага җитмәк өч баскыч белән мендек», – ди. Мәрхүм мелла Габделваһһаб бине Иманколый әр-Рәҗәби дә шулай ук хикәя кылган иде. Бу шәһре Болгарның мәчете һәм манарасы борынгы һәйкәлләр икәне ачык, бәлки, Багдадтан килгән илчеләр җитәкчелегендә булган осталар ярдәме белән салынган булгандыр.

Бер фарсыча китапта: «Болгар шәһәре – Мартыс диңгезе буена утырган бик зур шәһәр, аларның биналары нарат, чыршы шикелле агачтан эшләнгән, шәһәрнең ихатасы да агачтан эшләнгән, аларда бик салкын», – дип язылган. Бер борынгы төрки китапта: «Болгар шәһәре бик зур түгел, ләкин биналары гаять төзек, халкы зифа, матур», – дип язылган. «Фәрһәң мәснәвидә»: «Бик зур шәһәр, шулай ук ил исеме; бу илдә өч шәһәр бар, беренчесе Болгар, икенчесе Суар, өченчесе Ислә, Болгар халкы барысы да кяферләр һәм төрекләр», – диелә.

Икенче бүлек

ТАТАР ПАТШАЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ БУ ИЛГӘ КИЛҮЛӘРЕ ТУРЫНДА

Ибне Рәүбә дип танылган Шәмсетдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әбү Талиб әл-Өнсари әд-Димәшкый әйтә: «Халык телендә татар таифәсе дигән сүз юк иде, чөнки алар Кытай мәмләкәтенә чиктәш булып, аларның илләре белән мөселман мәмләкәтләре арасында Кытай халкы бар иде. Төрек хаканнары Самания дәүләтен җиңеп, Мавәраэннәһерне биләп алдылар. Алар татарларның дошманы иделәр, алар арасында һаман сугыш булып тора иде. Хорасанда Сәлҗукыя дәүләте бетерелгәннән соң, Харәзем-шаһлар, хәлифәләр тарафыннан Хорасан әмирләре итеп куелгач, Харәзем шаһларыннан солтан Галәветдин Мавәраэннәһер мәмләкәтенә кул сузып, хаканнарны тәмам бетереп, Мавәраэннәһерне яулап алды. Төркестан буш һәм хуҗасыз калды. Шуннан соң татарлар аңа кул суздылар. Харәземшаһның Сәмәркандны саклау өчен куелган дүрт йөз мең гаскәре аларга каршы тора алмады. Алты йөз уналтынчы (1219–1220) елда алар Сәмәрканд һәм Бохараларны алып, талап, үтереп, Харәземгә юнәлделәр. Харәземшаһ гаять күп гаскәр белән дә аларга каршы тора алмыйча качып китеп, Хәзәр диңгезенең Табарстан тарафындагы бер утравында алты йөз унҗиденче (1220–1221) елда вафат булды. Алты йөз унсигезенче (1221–1222) елда татарлар Харәземне һәм Җурҗанны алдылар.

Бу татарларның төп нәсел-нәсәпләре Яфәс бине Нух нәселеннән Аленҗә хан балаларыннан. Аның берсе – Татар, икенчесе Мангул исемендә ике углы булып, мәмләкәтне икесенә бүлеп бирде. Болар икесе дә үзләренә караган халыкның хөкемдарлары булып, нәсел-нәсәп ягыннан төрле таифәләргә

бүленделәр: алардан уйгур, төрекмән, кыпчак кабиләләре дан тоткан кабиләләр иде. Мәмләкәтләре – көнчыгышта. Көнчыгышында Уйгурстан, көнбатышында Кытай, көньякта Тибет һәм төньякта Себер мәмләкәтләренә тоташкан иде. Болар хәзер дә Магулстан, Кашгар, Алмалык, Алмата һәм Торбан кальгасы дип аталалар. Магул мәмләкәтенең хөкемдары Бисүкә[1] баһадир бине Бәртай бине Кабел бине Түмәнә бине Байсонкар вә татар хакиме Тимучин хан белән сугышып, аны җиңеп чыккач, үзенең бер ир баласы булып, исемен Тимучин куйды. Бала 13 яшькә җиткәндә, Бисүкә вафат булып, углы Тимучин хөкемдар булды. Яшьлеге сәбәпле, халкы аерылышып, дошманнар һөҗүм итәргә уйлый башлагач, магул ханнарыннан Үнәк ханга сыенды. Ләкин күп вакыт үтмәстән, араларына дошманлык төшеп, ул сугышка әйләнеп китә. Сугышта Үнәк хан җиңелеп үтерелгәч, мактау сыйфаты итеп үзен «Чыңгыз хан» дип атады. Шуннан соң барлык магул һәм татар мәмләкәтләре берсе артыннан берсе Тимучинга буйсынып, барлык халкына «татар» исеме өстен булып, «магул» исеме бетерелде, ташланды, ләкин төп нәселләре – татар түгел, магул. Барлык мәмләкәтен мәшһүр дүрт углына бүлеп биреп, Болгар, Себер, Бортас, Харәзем, Кыпчак, Рус, Башкорт, Ләһестан[2], Борҗан һәм Әфлак[3] мәмләкәтләре олы углы Җуҗи хан өлешенә тиде. Мавәраэннәһер, Хорасан, Газнә, Кябил[4] тарафларын икенче углы Чыгтай ханга, төп мәмләкәте булган Кара-корым һәм Алмалык ягын өченче углы Үгдәй ханга биреп, аны барыннан да өстен, гүя мөселманнардагы хәлифә урынына куеп, аңа «Хакан» исеме бирде. Җәбәл, Гилан, Табарстан һәм Гыйрак тарафдарын дүртенче углы Түли ханга билгеләп куйды. Шул сәбәпле элек тә Сәкалибә, Дәште Кыпчак илләре һәм Болгар мәмләкәте булган җирләр Җуҗи патша улусы дип аталды. Улус – өлеш мәгънәсендә. Җуҗи ханның вафаты атасыннан элек булуы сәбәпле, Чыңгыз хан Җуҗинең икенче углы Бату бине

[1] Дөресе: Ясүкәй, Ясүкә булырга тиеш.
[2] Ләһестан – хәзерге Польша.
[3] Әфлак – Валахия.
[4] Кябил – хәзер Әфганстан.

Җужи ханны мөстәкыйль патша итеп билгеләве белән «Бату йорты», аннан соң Бәркә хан патшалыгы вакытында «Бәрият әл-Бәркә» исеме белән, аннан соң Үзбәк хан патшалыгы гасырында «Үзбәк иле» исеме белән йөртелеп, барлык халкы үзбәк исеменә керде, ләкин шунысы гаҗәп: бу исем ошбу мәмләкәт халкы һәм аның патшасының исеме булса да, Әбү әл-Хәер хан балаларына ияреп кереп, Төркестан һәм Мавәраэннәһер төрекләренә исем булып урнашып, алардан «Чыгтай» исеме бетте. Болгар халкында «Үзбәк» исеме бөтенләй онытылып, «татар» исеме генә калды. Чыгтай балаларына, Кашгар, Яркәнд халкына «магул» исеме тагылды.

Татарлар Мавәраэннәһер, Хорасан һәм Харәземнән бушагач, Дәрбәнд аркылы чыгып, Болгарстан, Хәзәр һәм Дәште Кыпчак мәмләкәтләренә аяк бастылар. Башлап «лан» таифәсе белән сугыша башладылар. «Лан» халкы, кыпчаклар белән берләшеп, татарларга бик нык каршы тордылар. Татарлар аларны җиңә алмагач, кыпчакка илче җибәрделәр: «Сезнең динегез лан дине белән бер түгел, нәселегез дә башка, ә безгә кардәшсез, ирек бирегез, без алардан алган малыбызның яртысын сезгә бирербез», – диделәр. Кыпчаклар, шуңа алданып, лан таифәсен сугыш мәйданында ялгыз ташладылар. Татарлар, ланнарны җиңеп, үтереп, яндырып, талап алган малларының яртысын кыпчакларга бирделәр, ләкин кыпчаклар: «Татарлар белән солых кылдык», – дип, гамьсез яткан вакытларында татарлар, аларга һөҗүм итеп, ланнардан да яманрак итеп кырдылар, үтерделәр, таладылар, үзләре биргән малларын ун өлеш итеп кире кайтарып алдылар. Моннан соң алар русларга каршы сугыша башладылар, аларны бик яман кырып, үтереп, тар-мар иттеләр. Шуның нәтиҗәсендә мәмләкәттә юллар бетте, кәрван юллары киселеп, сәүдәләр тукталды. Лан, кыпчак, рус һәм башка таифәләрдән бушап калгач, татарлар алты йөз егерменче (1223) елның ахырында Болгар иленә һөҗүм иттеләр, ләкин болгарлардан җиңелеп, кырылып, аз-маз калганнары Талканга Чыңгыз хан алдына кайтып киттеләр. Шуннан соң гына юллар ачылып, кәрваннар йөреп, сәүдәләр башланып китте. Җужи хан атасы Чыңгыз

ханнан алты ай элек вафат булып, Чыңгыз хан аның өлешен аның икенче углы Бату ханга биреп, аңарга «Саин» дигән мактау исеме бирде. Бату хан бабасы Чыңгыз хан алдыннан кайтып, алты йөз утыз өченче (1235–1236) елда икенче мәртәбә Болгар мәмләкәтенә һөҗүм итте. Болгар әмире һәм аның халкы аңа буйсынып, салым түләү шарты белән үз урыннарында калдылар. Тубыл, Оренбург, Казахстан, Харәзем, Чиркәсстан, Дон җире, Хаҗитархан, Самара, Сембер, Казан, Болгар, Тамбов, Пенза, Рязань, Воронеж, Хәзәр диңгезе буйлары, Кырым, Херсон, Бессарабия, Молдавия, Азәрбайҗан, Венгер һәм Россия мәмләкәтләре һәм өлкәләре Бату хан хөкүмәте кул астында иделәр. Мәскәү һәм башка Россия хөкемдарлары һәркайсы татар ханнарының ярлыгын алмастан мәмләкәтләренә хөкемдар була, аталары тәхетенә утыра алмый иделәр һәм татар ханнарына бик авыр салымнар түлиләр иде. Тәхет бушап калса, хөкемдар булганның гаиләсеннән хөкемдар булырга лаек булганнары Алтын Урдага хан алдына килеп, берсе вәзирне, берсе шаһзадәне, берсе хатынны, берсе шәйхел-исламны ярдәмче итеп уртага куеп, Россия хөкемдары булуны сорый иде. Хан кайсын тиешле дип тапса, шуны билгели, башкалары ул хөкемдарның атларын җитәкләп кайта иделәр. Хөкемдар итеп билгеләнүче белән бергә, Мәскәүгә ханның илчесе, бер баскак[1], бер даруга[2] һәм бераз гаскәр җибәрелә иде. Илче барып җитү белән, олы чиркәүләренә аты белән кереп, тәреләргә арты белән торып, халыкка ханның указын укып, хөкемдарны тәхеткә утыртып кайтып китә иде. Һәр елда ханга бирер өчен никадәр яшь егетләр, яшь кызларны Мәскәүгә җыялар, хан тарафыннан җибәрелгән вәкил боларны бер мәйданда тезеп, күренекле булганнарыннан берникадәресен сайлап алып китә иде. Хәзер дә Мәскәүдә ул урынны «Кызлар мәйданы»[3] дип атыйлар икән. Хан тарафыннан берәү Мәскәүгә килмәкче булса, Мәскәү хөкемдары ерак юлга каршыларга чыга торган булган.

---

[1] Баскак – «наместник» дигән мәгънәдә.

[2] Даруга – шәһәр биләп торучы чиновник.

[3] Мәскәүдә «Девичье поле» дип аталган урын.

Гомумән, татар хөкүмәтенең хөкеме Себердән Хәзәр иленә – Дәрбәндкә кадәр йөри, һәммәсенә «Дәште Кыпчак», «Болгар иле», «Җуҗи улусы», «Бату йорты», «Бәриятел-Бәркә», «Үзбәк иле» дигән исемнәр бирелде. Патша тора торган башкала Саратовтан түбән, Хаҗитарханнан югары, Идел буенда, «Актүбә» дигән урында Иделнең көнчыгыш ягында кырык сигез градус, кырык биш минут төньяк киңлектә, алтмыш биш градус, биш минут көнчыгыш озынлыкта салынган Сарай шәһәре иде. Бу шәһәрне алты йөз илле беренче (1253) елда Бату хан салдыра башлап, Бәркә хан вакытында тәмам булды һәм аның үзенә, гаиләсенә һәм башкаларга «Патша тора торган шәһәр» булды. Ул шәһәр «Сарай»[1], «Олы Урда», «Алтын Урда» дип атала иде. Шәһәр озак яшәмәде, Бату ханнан 234 елдан соң җимерелде, харап булды. Хәрабәсе урынында хәзер дә кечерәк кенә немец шәһәре бар. Исемен бозып, «Царев» дип йөртәләр. Бу мәмләкәттә булган татарларның көнчыгыш белән төньяк арасындагы Җаек һәм Җөм елгалары буйларына утырганнарының башкаласы «Ак Урда», төньякта Россия арасында күчеп йөргәннәренең урыны «Күк Урда» дип атала иде. Бу урдалар берсе дә хәзерге заманда «Хан урдасы» дип йөртелә торган урын түгел: ул исем безнең гасырда Бүкәй хан бине Әбү әл-Хәер ханның Россия кулы астына кергәннән соң бирелгән. Татарның Кыпчак иленә килүенең сәбәбен Бибарс әл-Бандакдаридан күчереп, болай ди: «Кыпчак нәселенең дәрт кабиләсеннән Мәнкуш бине Кәтмәр дигән кеше ауга чыккач, Туксаба кабиләсеннән Аккәбәк дигән кеше очрап, Кыпчакны үтерде. Вакытында кайтмагач, хәлне белер өчен Җылынкар дигән кешене җибәреп, кем үтергәнен белгәч, әзерләнеп сугышканнар. Бу сугышта Туксаба кабиләсе җиңелеп, Аккәбәк, ярдәм сорап, энесе Әкъсарны Җуҗи ханга җибәрде, Җуҗи, шымчылар җибәреп, хәлне белгәч, гаскәр җибәрде. Җуҗи хан гаскәре, татарлар, һөҗүм итеп, кыпчакларны тәмам җиңеп, талап, әсирләр алып, бөтен тирә-якка

[1] Асылда, ике Сарай: «Сарай Бату» һәм «Сарай Бәркә» шәһәрләре була. Ләкин моның шулай икәне Ш. Мәржанидән соң билгеле булды.

таратып, сәүдәгәрләр кулы әсирләр-коллар белән тулды. Аларның бик күбесе Мисырга, Шамга илтеп сатылып, ул мәмләкәтләрдә Әюбия дәүләте бетерелгәч оешкан төрек патшалары әнә шул кыпчаклардан булган. «Аллаһ аларны мөселман булу һәм мәмләкәт, патшалыкны кулларына алу белән өлешләндерде», – диде. Җуҗи патшалары берничә таифәдән тора, алар һәркайсы түбәндә бер-бер артлы сөйләнерләр.

Беренче таифә, Саин[1] нәселеннән килгән патшалар

Аларның беренчесе – Җуҗи хан бине Чыңгыз хан бине Бисүкә бине Бортай бине Кабел бине Түмәнә бине Байсункар – бу тармакның төп һәм нәсел башы. Җуҗи хан атасыннан элек алты йөз егерме жиденче (1229–1230) елда Дәшттә вафат булганнан соң, Чыңгыз хан аның икенче углы Бату бине Җуҗины атасы Җуҗи улусына мөстәкыйль хөкемдар итеп куйды. Ул исә дәүләтнең үзәге һәм башкаласы итеп, «Сарай» шәһәре төзергә керешеп, төгәлләүдән элек вафат булуы сәбәпле, патшалык аның туганы Бәркә ханга күчте. Бәркә хан патшалыгы вакытында «Сарай» шәһәре салынып бетеп, ул кеше Чыңгыз балаларыннан беренче булып мөселманлыкны кабул итте. Җуҗи улусы «Бату урдасы» һәм «Бәрият әл-Бәркә» дип йөртелә башлады.

Аннан соң аның «Саин» кушаматы алган углы, Бату хан. Башкалалары булган «Сарай» шәһәрен төзергә кереште һәм шул вакытта алты йөз илле беренче (1253–1254) елда вафат булды. «Борһане катыйг» тәрҗемәсе «Тәбияне Нафигъ»дә әйтелүенә караганда, «б», «а», «т» һәм «у» белән, «бату» «жакү» үлчәвендә «Шөбанкярә» лөгатендә «тәреж» мәгънәсендә. «Фатү», «мату», «дадү», «каму» үлчәвендә була[2].

---

[1] Саин – югарыда искәртелгәнчә, Бату ханның кушаматы. Бу бүлектә Бату нәселеннән килгән патшалар турында сөйләнә.

[2] «Бату» – «жаку» үлчәвендә, «Шәбанкярә» лөгатендә «тәреж» мәгънәсендә ки, агач кавендер, кабыгыннан варенье ясала. Солтаннарның сөеклесе һәм Чыңгыз нәселеннән бер солтанның исемедер. «Тәбияне нафигъ»дә шулай әйтелгән. *Ш. Мәрҗани.*

Аннан соң – аның углы Сартак хан. Мәнгү хакан аны атасыннан соң «Сарай»га хан кылды, ләкин ханлык тәхетенә утырмас борын вафат булды.

Россия хөкемдары Александр Ярославович Невский моңа буйсыну күрсәтергә килде. Казан шәһәрен шул Сартак хан бина кылды дигән сүз дә бар.

Аннан соң – аның туганы Улакчы хан. Бу кеше дә кыска гына вакыт эчендә вафат булды.

Аннан соң – аның атасы белән бертуган кардәше Насыйретдин Әбү әл-Мәгали Бәркә хан. Әбү әл-Мозаффар Гомәр бине әл-Вәрди, Нәбәкати һәм башкалар. Бәркә ханны Бату хан углы диләр, әмма Ибне Гарәбша, Әбү әл-Гази хан, «Раузатес-сафа», «Мирьател-галәм» һәм «Җамигыт-тарих» бер дә шиксез Җүҗи хан углы диләр. Бу кеше ислам диненә керде. Аңа иярен борадәре Тукай Тимер дә мөселман булды. Асылда аның исеме Бурка Углан дип йөртелә иде, мөселман булгач, «Бәркә» дип үзгәртелде. Абака хан бине Хулагу хан дәүләтенең башлангыч вакытында Бәркә хан Букай исемле кешене гаскәр башлыгы итеп җибәрде. Гаскәр Дәрбәндтән үтеп, сугыш алып барса да, җиңелеп качып, Абака хан «Кәр» елгасын үтсә дә, Бәркә ханның үзенең өч йөз мең гаскәр белән якынлашып килүен ишетеп кире кайта һәм елгадагы күперләрне алдыра. Ике гаскәр ике яктан торып дүрт көн атышканнан соң, Бәркә хан Тифлискә һөҗүм итәргә уйлап киткәндә, юлда кату-чәнчү авыруы белән авырып китә. «Раузатес-сафа»да Бәркә ханны: «Мөселман патша иде, галимнәр һәм шәехләр белән утырышуны ярата иде, Абака хан белән булган вакыйгадан соң Кәр елгасының бер ягына биек дивар һәм тирән канау казырга һәм капка ясарга боерык бирә. Боларны Мангул гаскәрләреннән саклану, аларны үткәрмәс өчен эшли ул», – диелә. Җүҗи балаларыннан булган барлык татар ханнарыннан һәм барлык Чыңгыз балаларыннан беренче булып ислам диненә кергән кеше шул зат була...

Бәркә хан егерме биш ел патша булып торып, алты йөз алтмыш дүртенче (1265–1266) елда кату-чәнчү авыруыннан үлә

һәм Сарай шәһәрендә күмелә. Азәрбайҗан һәм Гаҗәмстан патшасы булган Ибне Гамме[1] Хулагу хан бине Түли хан бине Чыңгыз ханга каршы, Мөстәгъсыйм билләһ хәлифәнең кан үчен алу өчен, ничә мәртәбәләр сугыш ачты. Күбесендә Мозаффар һәм Хулагу хан җиңелеп качты. Аннан соң аның углы Абака хан белән дә шулай булды.

Моннан соң бертуганының углы Мәнгү Тимер хан бине Тукан бине Жужи хан. Шәһре Болгарда сугылган акчада «Мәңгү Тимер хан әл-әгъзам зорибә һазәд-дирһәме фи Болгари сәнәте 673 әл-гыйззе әд-даиме вә әш-шәрәфе әл-каиме тәвәккәлә галәллаһи мөхәррәм 678 сәнә, хәмдән лил-ләһи, лә иләһә иллал-лаһе вәхдәһе лә шәрикә ләһе»[2] сүзләре язылган. Ибне әл-Вәрди: алты йөз алтмыш бишенче (1266–1267) елда татарлардан бер төркем гаскәр җибәрелеп, алар Константиниягә барып җиткәннәр һәм шул тирә-якны талаганнар. Сәлачикат әр-Румиан[3] Кикаус бине Кихсәру бине Кибкад ябылган крепостька барып, аны гаиләсе белән Мәнгү Тимер хан хозурына алып килделәр. Алты йөз егерменче (1223) елдан бирле төрмәдә иде. Мәнгү Тимер хан аны олылады, хөрмәт күрсәтте һәм үзенең кызын бирде. Алты йөз җитмеш җиденче (1278–1279) елга чаклы, үлгәнче, анда торды һәм Сарайда күмелде. Аның вафаты соңында Мәнгү Тимер хан мәҗүсият гореф-гадәте буенча кызын углы солтан Мәсгутькә бирмәкче булды. Солтан Мәсгуть качып китеп, Рум иленә барып керде. Аны тотып алып, Абака хан бине Хулагу хан хозурына алып бардылар. Ул аны гыйззәт-хөрмәт белән каршылап, аңа Сивас, Әрзән әр-Рум, Әрзәнган шәһәрләрен бирде һәм Рум солтанлыгын аның исемендә калдырды. Җиде йөз сигезенче (1308–1309) елларда исән иде. Румда Сәлҗукыя солтаннарының иң соңгысы шул кеше булды. Алты йөз сиксән беренче (1282– 1283) елда Мәнгү Тимер хан Нукай һәм Тукайны гаскәр

---

[1] Ибне Гамме – атасы белән бертуганның углы.

[2] Гали Мәнгү Тимер хан бу акчалар 673 (1274) елда Болгарда сугылды, һәрвакыт хөрмәтле, олылыклы булсын. Ходага тәвәккәл, мөхәррәм 678 (1279) ел. Ходага мактау булсын, ул бер генә, аның шәриге юк.

[3] Сәлачикат әр-Румиан – Рум иле патшасы.

башлыгы итеп, сиксән меңгаскәр белән Аргун хан бине Абака хан өстенә җибәрде. Аргун хан гаскәре башлыгы Тагачарга Карабагда очрап, Мәнгү Тимер хан гаскәре җиңелеп качты һәм шул арада үзе дә үлде.

Аннан соң – кардәше Туда Мәнгү хан бине Тукан. Сарай шәһәрендә сугылган акчада «Туда Мәнгү хан әл-Гадил, алты йөз сиксән беренче (1282–1283) елда Сарай шәһәрендә сугылды, Ходага, аның рәсүленә гыйззәт-хөрмәт» дип язылган.

Әбү әл-Гази хан тарихында: «Бик каты җәбер һәм хаксызлыклар күрсәтергә кереште, Туктагу хан бине Мәнгү Тимер хан аның золымыннан качып китте», – ди. Ибне әл-Вәрди тарихында: «Алты йөз сиксән алтынчы (1287–1288) елда Татар мәмләкәтеннән Мәнгү хан бине Таган, тәхеттән ваз кичеп, изгеләргә кушылды, мәмләкәтнең патшасы кардәшенең углы Талабуга бине Мәнгү Тимер хан булыр дип күрсәтте», – ди. Тарихы Бәнакәтидә[1]: «Тарбуның ике углы – Алгу белән Тогрол, Туканның ике углы – Талабуга белән Күнҗәк Туда Мәнгүне, дивана ул дип урныннан төшерделәр, бергәләп биш ел ханлык иттеләр, Мәнгү Тимер углы Туктайга һөҗүм иттеләр. Ул Нукай бине Татар бине Һәрделнең ярдәме белән аларны һәлак итте», диелә.

Аннан соң кардәшенең углы Талабуга хан бине Мәнгү Тимер хан. Туда Мәнгү ханнан соң Сарай патшасы булды. Ибне әл-Вәрди: «Аны алты йөз туксанынчы (1291) елда Нәгыя бине Магул, бине Татар бине Җуҗи хан үтерде, аңардан соң Тыктыга бине Мәнгү Тимер хан утырды», – ди.

Аннан соң – кардәше Казан хан – Казан шәһәрен салучы; «Казан» хан исеме белән аталган» дигән сүз бар. Бу исемдә Җуҗи хан балаларыннан өч шәхес күренә. Берсе – Казан хан бине Туган бине Җуҗи хан; икенчесе – Казан бине Биян бине Байтимер бине Туктимер бине Җуҗи хан; өченчесе – Казан бине Илче бине Түли бине Әвердә бине Җуҗи хан. Шулай ук Чыгтай хан балаларыннан: Мавәраэннәһердә Казан Солтан хан бине

[1] Бу сүз Ш. Мәржани китабында «Нәбакәти» дип басылган. Дөресе – «Тарихы Бәнакәти».

Ясүр бине Үрктимер бине Тугайтимер бине Кудгай бине Бузай Мутукен бине Чыгтай хан бине Чыңгыз хан. Түли хан бине Чыңгыз хан балаларыннан Казан хан бине Аргун хан бине Абака хан бине Хулагу хан бине Түли хан; Түли хан балаларыннан беренче башлап мөселман булган мәгълүм бер патша.

Аннан соң – кардәше Гыясетдин Туктагу хан бине Мәнгү Тимер хан бине Туган. Әбү әл-Гази хан тарихында әйтә: «Туда Мәнгү ханнан качып китеп, берничә вакыттан соң гаскәр туплап килеп, Туда Мәнгүне басып алып үтерде дә үзе патша булды. Ата-бабасы юлы белән эш итеп, алты ел патшалык иткәннән соң, Сарай шәһәрендә вафат булды һәм шунда күмелде». Ибне әл-Вәрди әйтә: «Кыпчак патшасы Тукыттай җиде йөз уникенче (1312–1313) елда 30 яшендә үлде. Ул тәхеткә 7 яшендә утырган иде. Ул попларча гыйбадәт кылучы кяфер булып үлде. Һәр милләттән хәкимнәрне һәм яхшы кешеләрне сөя иде. Әмма мөселманнарны башкалардан артык күрә иде. Аның яхшылыклар эшләүче бер углы бар иде. Ул мәмләкәттә мөселманнарга башкаларны калдырмаска уйлый иде, ләкин атасыннан элек үлеп китте. Аның бер баласы калды. Аны бабасы үз тәрбиясенә алды. Шулай итеп, аның уе барып чыкмады. Аннан соң кардәшенең углы Үзбәк хан тәхеткә утырды. Аның гаскәре бик күп иде. Дошманнарына каршы сугышты, һәр ун кешедән берәүне аерып алды. Аерып алынган уннан берләрнең саны ике йөз илле мең булды.

Тәрҗемәче фәкыйрь уенча, Туктагу ханны потка табынучы кяфер дип әйтү хата булса кирәк.

Бәнакәти: «Аңа Нукай бине Татар бине Һәрдәл, икенче бер сүзгә караганда, Нукай бине Татар бине Буал бине Җүҗи хан ярдәм итте, дошманнарын һәлак кылды, соңыннан Нукайны да җиңде», – ди.

«Раузатес-сафа»да әйтә: «Җиде йөз өченче (1303–1304) елда Тукай белән Нукай Саксин һәм Болгар чикләрендә бик каты сугыштылар. Тукай җиңде, тәхеткә утырды. Азәрбайҗан һәм Иран мәмләкәтләрен яулап алу уена төште, аларны таләп итеп Газан ханга илчеләр җибәрде: «Чыңгыз хан билгеләве буенча, бу

илләр безнеке булырга тиеш иде, Хулагу хан һәм аның балалары ул илләрне бер дә нигезсез билиләр», – диде.

«Раузатес-сафа»да янә әйтә: «Ул Газан ханга мәҗлескә лаеклы күп кешеләр кушып илчеләр җибәрде. Илчеләр белән җибәрелгән хатының кыскача эчтәлеге түбәндәгечә иде: «Чыңгыз ханның бүлүе һәм билгеләве буенча, Иран һәм Азәрбайҗан Жужи ханга һәм аның балаларына булырга тиеш. Ничә еллар инде Хулагу хан һәм аның атаклы балалары ул җирләрне ясага каршы килеп билиләр. Үткән көннәр турында Газан җаваплы түгел. Әмма бүген инде ул хаклыкны үз урынына куйсын һәм өлкәләрне безгә тапшырсын. Әгәр аңа риза булмаса, сугышка әзерләнсен. Һәм шуны белсен ки, Каракорым чикләреннән алып Дәрбәнд янына хәтле безнең җиңү белән дан тоткан ун төмәннән[1] артык сакчы гаскәребез чатыр өстенә чатыр беркетеп, бау өстенә бау тартып утырганнар. Калган гаскәрне шуларга чагыштырып белергә кирәк. Гаскәрләрнең күплеген күрсәтү өчен, илчеләр белән бергә бер капчык тулы тары җибәрелде.

Хатта каты-каты сүзләр булса да, илчеләр аны матур сүзләр, гүзәл җөмләләр белән йомшартып укыдылар. Падишаһ илчеләрнең саны күплеккә ачуланды һәм: «Мөлкәт – бетә торган нәрсә, шулай булгач, аны даулау да нигезсез», – диде. «Хулагу вакытыннан алып хәзергә чаклы Иран һәм Азәрбайҗан – киң илнең бер кисәге. Ул җирләрне басып алырга теләүчеләрдән без үткен кылыч белән саклыйбыз. Кылыч кулланып, аның бер кисәген тартып алу хәзерге көндә дә мөмкин булмас. Юк-бар белән алдап кына падишаһ кызын кочакка кертеп булмый. Алар китергән бер капчык тарыны исә кошлар күз ачып йомганчы чүпләп бетерәләр», – диде. Һәм илчеләргә Тукайга кайтып китәргә рөхсәт бирде. Алты йөз туксаннан (1291) җиде йөз унөчкә (1313–1319) чаклы аның исеменә сугылган тәңкәләре бар. Аннан соң – кардәшенең углы Гыясетдин[2].

---

[1] Төмән, туман – ун мең.

[2] Гыяс – ярдәмче, «Гыясетдин» – дингә ярдәм итү мәгънәсендә. Үзбәк ханның кушаматы.

Үзбәк хан бине Тогрыл бине Мәнгү Тимер хан. Татар патшалары арасында иң олысы, иң күп яхшылык күрсәтүче һәм динне иң нык тотучысы иде. Ибне әл-Вәрди әйтә: «Атасы белән бертуган агасыннан соң булган бу патша гайрәтле, үзе мөселман, яшь, батыр егет иде, мәмләкәтен алты айлык юлга киңәйтте, шәһрәте зур, ләкин шәһәрләре аз иде». Бу патша, иң асыл кеше, күркәм чаралар үткәрүче, исламны таратуда тиңдәшсез тырышлыгы белән аның дәверендә татарлардан бик күпләр сәламәтлек йорты, тыныч чарасы булган исламга керде, иман китереп, диндә ныгып калдылар. Аңардан элгәреге вакытларда татарлар мөселман хан булганда исламга кереп, мөселман түгел хан булса, күбесе ислам динен ташлый торган булганнар. Шуңа күрә ногайлар арасында «дин Үзбәк ханнан калды» дигән сүз киң таралган. Төрле тарафлардан, ерак шәһәрләрдән аның алдына галимнәр тупланды. Әл-галләмә Котбетдин әр-Рази, Әхмәд бине Мәхмүд әл-Җәнди, әс-Сәед Җәләлетдин кебек зур галимнәр һәм хәнәфия, шафигыя галимнәре күп иде. Шулай ук Гали бине Мөхәммәд бине Диһкан әл-Бикәнди «Мифтахел-голүм»нең өченче томына шәрех язды, җиде йөз унтугызынчы (1319–1320) елда аны Харәземдә тәмам итеп, Үзбәк ханга бүләк итте. Бу аның кереш сүзендә әйтелгән. Әбү әл-Гази хан тарихында әйтә: «Туктагу хан үлгәч, унөч яшендә ата-бабасының гадәте буенча илне кулына алып, һәркемнең мәртәбәсенә лаек хөрмәт кылып, ярдәмнәр бирде, ил-улусны исламга кертте. Халык шул дәүләт иясе сәбәпле исламга керү белән мөшәррәф[1] булдылар, аннан соң барлык Җүҗи илен Үзбәк иле диделәр; кыямәткәчә шулай атарлар. Гаделлек теләүчегә гаделлек күрсәтте, ике мәртәбә Иран йортына Әбү Сәгыйд хан өстенә барса да, ала алмыйча кайтты. Әбү Габдулла бине Баттута «Төхфәтен-нәзар» китабында әйтә: «Синуптан Кырым мәмләкәтенә чыктым. Ул вакыт анда солтан Мөхәммәд Үзбәк хан тарафыннан куелган Тәлек Тимер дигән кеше хаким иде. Ул миңа имам Сәгъдетдин берлә бер ат җибәрде. Ул мәмләкәтнең Шәехе задә әл-Хорасани иде.

[1] Мөшәррәф булу – кадер, хөрмәт иясе булу, лаеклы булу.

Аңарга юлыктым. Өлкән казыйлары – Шәмсетдин әс-Саили әл-хәнәфи, шафигыйлар казыйсы – Хозыр, Насыйр падишаһ[1] исеменә хөтбә укучы имамнары Әбү Бәкер, Хәким Мозаффаретдин, шәех Мозһиретдин әл-Фәкыйһ һәм әмир Теләк Тимергә кердек; ул авырый иде, безнең белән гүзәл мөгамәлә кылды. Сарай шәһәренә солтан Мөхәммәд Үзбәк хан хәзрәтенә барырга ниятләп тора икән. Аның белән һәм борадәре Гыйса, Котлу Тимер, Сарубәк, имам Сәгъдетдин, Хатыйб Әбү Бәкер, казый Шәмсетдин, фәкыйһ Шәрәфетдин Муса һәм Галәветдин әл-мөгарриф белән бергә сәфәр кылдык. Ул мөгаррифнең[2] вазифасы: әмир алдында мәҗлесенә бер казый, яки галим, яки башка бер дәрәҗәле кеше килсә, аякка басып көчле тавыш белән кычкырып: «И безнең хуҗабыз, казыйларның, хакимнәрнең казыйсы, фәтва һәм хөкемнәрне игълан итүче! Фәлән кеше килде», – дип белдерә иде. Мәҗлестәгеләр аны аякка басып каршы ала, урын бирергә хәзерләнәләр. Ибне Халдун әйтә: «Җуҗи хан балалары белән аларның бәнү гамьнәре[3] Хулагу хан балалары арасында һәрвакыт бәрелешләр-сугышлар булып торды. Җуҗи балалары, Мисырдагы терәк патшалары белән дуслашып, һәрвакыт илчеләр җибәрешеп, бүләкләшеп торалар иде. Җиде йөз унөченче (1313–1314) елда Үзбәк хан патша булгач, Мисыр патшаларыннан илчеләр килеп, аны тәбрикләделәр, дуслык артты. Мисыр патшасы әл-Мәлик Насыйрга Тагачы бине Һиндү, бине Бәкер бине Җуҗи хан кызы Толынбашны Үзбәк хан үзенең имамы Борһанетдин һәм татар әмирләреннән бер төркем белән Мисырга җибәреп, мәмләкәтнең олылары, галимнәре, казыйлары алдында җиде йөз егерменче (1320–1321) елда никахлап бирделәр. Бу көн ике вәкил арасында шартнамә төзелеп, бик зур шөһрәтле көн булды.

Үзбәк хан Иран патшасы солтан Әбү Сәгыйд бине Ходабәндәне әмир Чубаннан җиңелүе сәбәпле яратмый иде; шул вакытта Үзбәк хан Хорасан мәмләкәтенең күп өлешен басып алды. Әмир

---

[1] Насыйр падишаһ – шул ук Үзбәк хан.

[2] Мөгарриф – белдереп торучы дигән сүз.

[3] Бәнү гамьнәре – аталары белән бертуган агаларының балалары.

Чубанга һәм Әбү Сәгыйдкә бергәләп каршы чыгарга Үзбәк хан Насыйр патшага тәкъдим итеп, Насыйр патша моны кабул итсә дә, Әбү Сәгыйд тарафыннан җибәрелгән илче әл-Мөхәммәди егерме икенче (1322) елда Мисырга килеп солых ясап, юлларны төзекләндерү, дин өйрәтүне аякка бастыру, дин дошманнары белән сугышу турында бер фикергә килеп шартнамә төзеделәр. Бу хәбәр Үзбәк ханга ишетелү белән, ул, Мисыр илчеләрен бик яман каты хурлап, Мәлик Насыйрны шелтәләде. Мәлик Насыйр: «Алар безне ислам гадәтләре, ислам әдәпләрен бергәләшеп аякка бастырырга чакырдылар, бу эш шәригать белән тыелмаган һәм дөреслеккә каршы түгел бит», – дип гозер итте.

Моннан соң Үзбәк хан, Әбү Сәгыйд хан белән ризалашып, солых ясап, үзе басып алган Хорасан шәһәрләрен Әбү Сәгыйд ханга кайтарып бирде. Җиде йөз унсигезенче (1318–1319) елда Дәрбәнд юлы белән Азәрбайҗанга, икенче мәртәбә җиде йөз утыз алтынчы (1335–1336) елда Иранга сәфәр кылды. Җиде йөз унсигезенче (1318–1319) елда Россия хөкемдары Юрий Данилович, үзенең буйсынуын белдерү һәм дәүләтне тәбрикләү өчен, Үзбәк хан алдына килде. Җиде йөз кырык беренче (1340–41) елда Сарай шәһәрендә вафат булды.

Аннан соң – Тынебәк хан. Моның патшалык вакыты бик кыска булган булырга кирәк.

Аннан соң, җиде йөз кырык өченче (1342–43) елда аның борадәре солтан Җәләлетдин Әбү Мозаффар[1] Мәхмүд Җанибәк хан Сарайда патша булды. Мәскәү хөкемдары Семен Иванович һәм Митрополит буйсыну белдереп, тәбрик итәргә килделәр. Галләмә Сәгъдетдин әт-Тәфтазани «Шәрхе тәлхыйс»[2]не язып, Җанибәк ханга бүләк итте. Кайбер нөсхәләрендә исеме телгә алына. Гаять динле, изге, бик гадел, күркәм йөзле, дәрвиш сыйфатлы, төзек фикерле кеше иде.

---

[1] Җәләлетдин Әбү Мозаффар – ханның исеме түгел, Җәлалетдин – кушамат, Әбү Мозаффар – «Мозаффар атасы» мәгънәсендә.

[2] «Шәрхе тәлхыйс». «Тәлхыйс» – гарәп теле буенча китап, «Шәрхе тәлхыйс» – шуңа аңлатма һәм комментарийлар.

Казый Мохитдин әл-Бәрдәгый Сарай шәһәренә килеп, мәчеттә вәгазь-нәсыйхәт кылды, Азәрбайҗан мәмләкәтендәге Әшрәф бине Тимерташ бине Чубан дигән патшаның халыкка кылган җәбер, золымын бәйнә-бәйнә сөйләп, барлык халыкны елатты. Шуннан соң Җанибәк хан, зур гаскәр белән Азәрбайҗан мәмләкәтенә һөҗүм итеп, Әшрәф залимне үтерде, халыкка җәбер-золым итеп туплаган барлык хәзинәне һәм җиргә күмеп яшерелгән кыйммәтле мал һәм акчаларны, углы Таштимер бине Әшрәфне Сарай шәһәренә алып кайтты. Шул турыда бу фарсы бәетен әйттеләр:

«Бел инде, ишәк Әшрәф нишләде? Ул халыкка җәбер-золым китерде, Җанибәк исә алтын (нур) китерде»[1].

Тәбриздә илле меңгаскәр белән углы Бирдебәк ханны калдырды. Җиде йөз илле сигезенче (1356–1357) елда Сарай шәһәрендә вафат булды. «Раузатес-сафа»да әйтәдер: «Тимерташ углы Мәлик Әшрәф бик күп өлкәләрне басып алды, чиксез күп золым итте. Казый Мохитдин әл-Бәрдәгый, җәбер-золымның күплеге сәбәпле, башкалар кебек Сарай шәһәренә күчеп китте, анда вәгазь-нәсыйхәт белән шөгыльләнде. Ул чакта Сарайда падишаһ гадел Җанибәк хан иде. Мәшһүр галләмәи Тәфтәзани бәян (стилистика) һәм мәган (риторика) фәннәре турында язган «Мохтәсаре-тәлхыйс» исемле әсәрен шушы Җанибәк ханга багышлаган иде. Казый Мохитдин күп вәгазьләре белән Җанибәк алдында танылды һәм кабул ителде. Казый Мохитдин Җанибәк ханны Әшрәф белән сугышка өндәде һәм күндерде. Казыйның күрсәтүе буенча, Әшрәф үтерелеп, башы Тәбризгә китерелде һәм мәрагалеләрнең мәчет ишегенә асып куелды. Халык аны күреп шатланды, нәзерләрен үтәде. Падишаһ Җанибәк хан ике меңатлы гаскәр белән Тәбризгә килде, хөкүмәт йортына төште. Иртәгесен Галишаһ мәчетендә җәмәгать белән намаз укыды. Гаскәре юл белән елга арасына төшеп урнаштылар. Гади кешеләрнең өйләренә аяк басарга берәвесе дә батырчылык итмәде. Падишаһ Уҗанга китте, үзенең углы

[1] Тәрҗемәсе китерелде.

Бирдебәкне илле мең атлы гаскәр белән Тәбризгә җибәрде. Бирдебәк Сарайга кайтырга уйлады. Берничә көннән соң Җанибәк урдасыннан: «Падишаһ каты авырый» дигән хәбәр алынды. Бирдебәкнең ашыгыч рәвештә шунда китүе кирәк табылды. Аның китүе хәбәрен ишеткәч тә, кардәше Чук бик күп кешеләр белән Тәбризгә килде. Мәлик Әшрәфнең иярченнәре аның хезмәтенә ашыктылар, хөкүмәт органнарын үз кулларына алдылар һәм җәбер-золымда Әшрәф юлыннан киттеләр».

Әбү әл-Гази хан тарихында әйтә: «Казый Мохитдин Җанибәк ханга: «Әгәр барып Әшрәфтән безнең үчебезне алмасаң, кыямәт көненда безнең кулыбыз синең итәгендә», – дип әйтте ди. Бу сүз ханга тәэсир кылып, Әшрәфне басып алып, мәмләкәтне үз кулына күчерде, Әшрәфнең дүрт йөз дөя кыймметле асыл ташлары, җәүһәрләре бар иде; аларның барын да гаскәренә бүлеп бирде. Шулай җиңеп, мәмләкәтне кулына алып йортына кайтты. Бу хөрмәтле затка бер авыру тиеп, озак вакытка тартылды. Инде мин бу авырудан сәламәтләнә алмамын дип, углы Бирдебәкне үз урынына калдырырга уйлап, аны Азәрбайҗаннан кайтырга чакырды, бик күп үгет-нәсыйхәтләр кылды, Бирдебәк килеп җиткәнче вафат булып, Сарайда күмелде. Унҗиде ел патшалык итте.

Моннан соң – углы Бирдебәк хан. Атасы вафат булганнан соң, Сарай шәһәренә кайтып өч көн атасының вафаты кайгысын үткәргәч, барлык шаһзадәләр, түрәләр Бирдебәкне хан итеп күтәрделәр. Әбү әл-Гази хан әйтә: «Бирдебәк хан залим табигатьле, бозык, явыз ниятле кеше иде. Ага-эне һәм кардәш-ыруының берсен дә калдырмый үтереп бетерде. Ахыры патшалыгы ике елга да җитмәде, җиде йөз алтмыш икенче (1360–1361) елда үлде. Моннан соң Саин хан балалары саналган патша булмады. Үзбәк халкы эчендә: «Үгез муены Бирдебәктә киселде» дигән мәсәл таралган.

Җиде йөз алтмышынчы (1358–1359) елда Россия таифәсе Болгар мәмләкәтеннән Жукотин крепостен алдылар. Шул турыда Болгар әмире ханга шикаять кылды. Россия хөкемдары Дмитрий Константинович һәм аның борадәре хан илчесе хозу-

рына чакырылып тикшерелеп, каракларны табып биреп кенә җәзадан котылдылар.

Моннан соң – углы Кулна хан. Бу яшь бала иде әле. Алты ай патша исемен күтәрде. Сарайда һәм аннан тышта җиде йөз алтмыш беренче (1360) елда аның исеме белән сугылган акчалар бар.

Аннан соң – атасы белән бертуган агасы Нәүрузбәк бине Җанибәк хан. Кулна ханны үтереп, бер елдан артыграк патша булып утырды. Алтмыш, алтмыш бер һәм алтмыш икенче елларда сугылган тәңкәләре бар. Әүвәлдә Җаек елгасының көнчыгыш ягында иде. Җанибәк углы дип ялганлап, Сарайга килеп хан булды. Аның гасырында Россия хөкемдарлары: «Инде татарлар арасына каршылык төште, дәүләтләре көчсезләнде», – дип, бераз баш күтәреп, татар хөкүмәте идарәсеннән чыгу уена төштеләр һәм килеп теләкләрен таләп иттеләр. Моны Хызыр хан үтерде.

Моннан соң – кардәше Килдебәк хан. Алтмыш, алтмыш икенче елларда Сарайда сугылган тәңкәләре бар. Бу да Нәүрузбәк хан шикелле ялганчы бер кеше булып, ул да Җанибәк углы булмаган, диләр. Ахырда аз гына вакыт патша булып утырганнан соң Сарай шәһәрендә үтерелде. Бату хан балаларыннан дәүләт китеп, башкалар хуҗа булдылар.

Кайбер җыентыкларда Казан ханнан соң аның атасы белән бертуган кардәшенең углы Күнҗәк бине Тарбу бине Тукан, аннан соң – Алгу бине Мәнгү Тимер хан, аннан соң – аның туганы Тогрыл хан дип әйтелгән. Бәлки, болар да Туда Мәнгү хан гасырында хөкемдарлыкка керешкән, катнашкан булганнардыр.

Ибне әл-Вәрди әйтә: «Җиде йөзенче (1300–1301) елда Җәкә үзенең кардәше Тәкә бине Бәгънәне үтерде. Тәкә урынына калган Тайфур белән Җәкә арасында сугыш булды, Тайфур җиңде.

Шуннан соң Туктыгага ярдәмгә барды. Җәкә Улакка качты, чөнки алар арасында кодалык бар иде. Улак Җәкәгә хыянәт итеп, аны Тарбу крепостена япты, соңыннан үтереп, башын Кырымга җибәрде. Шулай итеп, Бәгънә иле Туктыганыкы булды.

Җиде йөз тугызынчы (1309–1310) елда Бәян бине Кыбҗи үзенең кардәше Кетлекнең мәмләкәтен басып алды. Шул арада Кетлек үлеп китте. Шунда аның углы Куштимер, ярдәм алып, агасының туганы Бәянны куып җибәрде, атасының мөлкенә хуҗа булды. Бәянны куып җибәрүче аның кардәше Мангытый бине Кыбҗины да үтерде».

Җуҗи нәселе Шәйбания һәм башкалардан төрле патшалар турында

Саин балалары нәселе беткәннән соң, Җуҗи ханның бишенче углы Шәйбан бине Җуҗи хан балаларыннан Ак Урда ханнары нәселеннән Хызыр хан бине Ибраһим бине Фулад бине Миңтимер бине Бадакол бине Җуҗи Бука бине Баһадир хан бине Шәйбан хан бине Җуҗи хан Нәүрузбәк ханны үтереп, җиде йөз алтмышынчы (1358–1359) елдан җиде йөз алтмыш икенче (1360–1361) елгача бөтен Җуҗи улусына патша булды. Болгар һәм Сарайда сугылган тәңкәләре күп табыла.

Аннан соң – углы Тимерхуҗа хан. Атасын үтереп, җиде йөз алтмыш икенче (1360–1361) елда биш атна кадәр вакыт патша булып торды. Шуның өчен шигырьдә әйтелгән:

Атасын үтергән кеше патша булмас,
Әгәр булса, алты айдан артык тормас, –

бәетнең эчтәлегенә туры килде. Мамай мирза аны җиңеп, әсир итеп, Сарай шәһәреннән чыгарып җибәреп үтертте.

Моннан – соң җиде йөз алтмыш икенче (1360–1361) елда Урда Мәлик хан. Сарайда, Харәземдә, Гөлстанда [сугылган] тәңкәләре бар.

Моннан соң – җиде йөз алтмыш өченче (1361–1362) елда әлгадил Мамай хан. Актүбәдә, Азакта[1] (сугылган) тәңкәләре бар.

Аннан соң – Мөрит хан бине Хызыр хан җиде йөз алтмыш өченче (1361–1362) елда сугылган тәңкәләре бар.

Аннан соң – җиде йөз алтмыш дүртенче (1363) елда Мирфулат хан. Җиде йөз алтмыш өч – алтмыш дүртенче (1362–

[1] Азак – Азов шәһәре.

1363) елларда, аннан соң җиде йөз алтмыш бишенче (1364–1365) елда Фулад-хужа хан. Аннан соң – Җанибәк хан, җиде йөз алтмыш җиденче (1365–1366) елда вафат. Аннан соң – җиде йөз алтмыш алтынчыдан (1365) җиде йөз җитмеш икенче (1370–1371) елгача Газиз шәех хан. Аннан соң Фулад Тимер хан бине Тукан. Җиде йөз алтмыш сигезенче (1366–1367) елда сугылган тәңкәсе бар. Бер тарафында «Мәрхүм Җанибәк хан» дип язылган. Аннан соң Тулун бәк хан. Мамай мирзаның борадәренең углы. Җиде йөз җитмеш өченче (1371–1372) елларда сугылган тәңкәсе бар. Аннан соң Гыясетдин Бүләк хан. Мамай мирза аның вәзире иде. Җиде йөз җитмеш – җитмеш беренче (1370) еллардан җиде йөз сиксән җиденче (1385) елларга кадәр Сарайда, Хаҗитарханда, Харәземдә, Урдада һәм Венгриядә сугылган тәңкәләре бар. Бүләк хан гасырында Мәскәү хөкемдары Дмитрий Иванович Донской җиде йөз сиксәненче (1378)[1] елда барлык рус хөкемдарлары белән берләшеп, зур гаскәр туплап, Дон елгасы буенда зур сугыш алып бара һәм татар гаскәрен җиңә. Бүләк ханның дәүләт эшләрен идарә итүчесе Мамай мирза, шул баш күтәрү вакытында сугыш мәйданыннан качып китеп, Кырымда һәлак булган. Шул арада Россия хөкемдарлары мөселман хөкүмәте идарәсеннән чыгып, Туктамыш хан гасырында яңадан кайтарылып, буйсындырылдылар.

Аннан соң – җиде йөз җитмеш бишенче (1373–1374) елда Алып хан Хужа хан, аннан соң – җиде йөз җитмеш алтынчы (1374–1375) елда Чиркәсбик хан, аннан соң – җиде йөз җитмеш җиденче (1375–1376) елда Гыясетдин Агабик хан, аннан соң – җиде йөз җитмеш тугызынчы (1378) елда Базарчы хан. Ләкин бу ханнарның берсе дә Җужи улусының бөтенесенә хан булмаганнар, кайберсе бер өлкә ханы, кайберсе бик зур байлык иясе булу фикере белән саташып акча суккан булырлар. Бу ханнар белән тагын берничә хан бу мәмләкәтнең татар ханнарыннан саналсалар да, кайберләре Болгар әмирләре җөмләсеннән, кайберсе Ак Урда, кайберсе Күк Урда ханнары булып, кайберсе

[1] Бу сугыш һәм җиңү 1380 елда була.

бөтенләй бу мәмләкәт ханнарыннан булмаганнар. Аларны да бу урында телгә алып китү кирәк табылды. Мәсәлән, солтан Мөхәммәд, әмир Хәсән һәм әмир Габдулла – Болгар әмирләреннән. Сәед Ракыйм (h.б.) Таглык Тимер хан бине Исәнбуга хан һәм углы Ильяс хуҗа ханны Дәште Кыпчак ханнарыннан саный. Алар – Чыгтай хан балаларыннан, Кашгар һәм Мавәраэннәһер ханнары. Таглык Тимер хан Мавәраэннәһердәге баш күтәрүләр сәбәпле, җиде йөз алтмыш икенче (1361–1362) елда Мавәраэннәһергә килеп, ул илне кулга алып, углы Ильяс-хуҗаны Сәмәркандка куйды, Тимерне аның хезмәтендә калдырды.

Җиде йөз алтмыш дүртенче (1362–1363) елда Тоглык Тимер хан үлгәннән соң, Аксак Тимер аның углы Ильяс хуҗа ханны хыянәт итеп үтерә дә, илне үз кулына ала. Мөхәммәд Риза әфәнде «Сәбгы Сәйярә»[1]дә Казан хан бине Аргун ханны кем туганының углы Әбү Сәгыйд ханны, Каганбәк хан һәм углы Мәхмүд Хуҗа хан һәм Әбү әл-Хәер ханнарны Дәште Кыпчак ханнарыннан саный. Бу сүз дә ялгыш. Казан хан һәм Әбү Сәгыйд хан икесе дә Иран шаһлары; Сарай, Болгар һәм башка кыпчак илләренә һичбер катышлары юк, бәлки Туктагу хан һәм Үзбәк ханнарның Иран мәмләкәтенә һөҗүм итүләреннән куркып торалар иде. Каганбәк һәм углы Әбү әл-Хәер ханнар – Ак

---

[1] Чыңгыз ханның углы Чыгтай хан нәселеннән Юныс хан бине Вәес хан бине Ширгали бине Мөхәммәд хан заманында кардәше Исәнбуган хан аны әсир итеп, Сәмәркандтагы мирза Олугбәккә җибәрделәр. Ул Хорасанга атасы Шаһрух мирзага җибәрде. Ул аны Гыйракка җибәреп укытканнан соң, Тимер балаларыннан (нәселеннән) Солтан Әбү Сәгыйд мирза Карабагны алыр өчен юлга чыгарга уйлаганда, гаскәр туплап һәм падишаһлык кирәкярагын биреп, Магулстан ягындагы Исәнбуга ханга каршы тору өчен, шунда хан итеп билгеләде, ләкин шарт куйды: без – мөстәкыйль падишаһ һәм тулы ирекле, ә Аксак Тимер һәм аның балалары (нәселе) безнең ялчы һәм эшебезне башкаручылар дип мактанмаска һәм дәгъва итмәскә. Моңарчы бит Тимер һәм аның нәселе Чыңгыз нәселеннән берәүне падишаһ һәм хан итеп куеп, аның исеменә хөтбә укыталар һәм акчада аның исеме йөри, ә Тимер нәселе кешеләр аларның урынбасарлары, эшләрен башкаручылар була иде. Бу тәртипне солтан Әбү Сәгыйд мирза шушы вакыйгада бетерде. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

Урда хөкемдарлары. Гатаулла бине Яхъя Нәугый задә әфәнде «Хәдаикыль-хәкаикъ фи зәймиш-шикак» китабында әйтә: «Тугыз йөз җитмешенче еллар башында «Кәффә»нең бикләр биге Касыйм пашага берникадәр сакчы гаскәр кушылып, Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй хан белән Казан дигән урында дәрьяны кисәргә җибәрелде. Хәзәр (Каспий) диңгезе буендагы Әстерхан шәһәре якынында Кара диңгезгә коя торган зур елганың ярыннан ике миль кадәре казылса, ике елга тоташып, көймәләр белән чыгып, ул илне баш идерергә, Җиһангир Искәндәр шикелле, караңгылык (төньяк) диңгезенә кадәр булган бөтен халыкны ислам нуры белән нурландырырга мөмкин булганлыгы падишаһ хәзрәтләренә мәгълүм булган, имеш»[1].

Чыңгыз хан балаларыннан (нәселеннән) солтан Мәхмүд Газан хан гасырында мөселман булган зур бер татар төркеме, шул илне сугышып алып, шунда урнашып калган. «Казан татары» дигән сүз «Газан» дигән сүздән бозылган, имеш. Газан гаскәрләре ул якка үтеп кергәнгә күрә, алар ярдәме белән Казан татарларының тирә-яктагы кяферләрне җиңеп торырга көчләре җитә иде. Газания дәүләте беткәннән соң, ул яктан ярдәм тукталды һәм Казан татарлары мәскәүлеләр кул астында калдылар. Сәлам хан гасырында патша хәзрәтләренә мәрхәмәт сорап хатлары килеп торып, югарыда күрсәтелгән урынны казып, ике дәрьяның дулкыннары каршы килеп бәрелешүдән биек тау хасил булганда, Искәндәрчә җиһангирлек тә мөмкин диюләре белән сөенеч бирелә иде. Ләкин Мөхәммәдгәрәй бу турыда хәйләгә керешеп, Госманлы мәмләкәтенең чикләре үз мәмләкәте чигеннән үтеп китсә, Кырым ханлыгы ул зур илнең уртасында чолганып калуыннан куркып, ислам гаскәрен дөя сахрасы шикелле коры, кыргый сахрага төшереп, сусыз калдырып азап чиктерде. Ничә көннәр бер тамчы су таба алмыйча, яфраклардан таң алды чыкларын ялап, телләрен чылаталар иде. Гаскәрнең яртысы сәламәт кайта алды. Мөхәммәдгәрәй бу явызлыгының

[1] Төрекләр XVI гасырда Дон белән Волганы бергә кушу чарасына керешкәннәр. Ләкин башкарып чыга алмаганнар. Бу урында сүз шул турыда бара булса кирәк.

җәзасын солтан Морад дәверендә күреп, ислам патшасының каһәре белән юк ителде». Сүзе шунда тәмам. «Казан» дип аталуга күрсәткән сәбәбе дөреслектән бик ерак тора. Татарларның Газан хан гасырында, аңа ияреп исламга кергәннәре – Иран мәмләкәтендә Илихания хөкүмәтендәге татарлар. Бу илебездәге татар таифәсе Газан ханның олы бабасы Хулагу хан гасырында, Бәркә ханга ияреп, исламга кергән иделәр. Илихания дәүләте патшаларының бу мәмләкәткә үтеп керүләре бер якта торсын, бәлки Бәркә хан, Мәнгү Тимер хан, Туктагу хан, Үзбәк хан һәм Җанибәк ханнарның һөҗүмнәре сәбәпле миңгерәп, калтырап тора иделәр.

Болгар патшалары һәм Җуҗи хан улусындагы татар ханнары үзләренең сугышчанлыклары[1], гаскәрләрен яхшы, тәртипле тотулары белән якыннары арасында мактаулы иделәр. «Казан» шәһәрен «Казан» дип исемләү шуның белән аңлатылса, дөрес булмаганда да, ул кадәр үк килешсез булмас иде.

Ырыс хан нәселеннән килгән патшалар турында

Ырыс хан балаларыннан күп затлар Сарайда хан булганлыктан, аларны аерым бер бүлектә китереп үтү кирәкле табылды. Аларның беренчесе – Ырыс хан бине Бадакол, бине Туккол хуҗа бине Күнҗәк бине Саричә бине Үзтимер, бине Тукайтимер бине Җуҗи хан. Боларның нәсәбен Әбү әл-Гази хан әнә шулай дип язды. «Сәбгы сәйярә»дән дә шулай аңлашыла. Әмма кайберләре Ырыс хан бине Җимтай, бине Ибисан бине Сашибуга бине Баян бине Кубенҗи бине Сартак бине Урда бине Җуҗи хан, диләр. Ләкин, минемчә, бу – уйланмыйча әйтелгән сүз булырга кирәк. Дөресен Аллаһ белә, ышанасым килми. Элек Ак Урда хакиме иде. Җиде йөз алтмыш өченче (1361–62) елдан җиде йөз сиксән беренче (1379–80) елга чаклы бөтен улуста хан булды. Аннан соң – углы Туктагу хан. Аннан соң кардәше Тимер Мәлик хан.

[1] Оригиналда бу сүз «Газәват» дип алына. Сугышчанлык мәгънәсендә. «Газу», «Газан» сүзләре бер үк тамырдан. Ш. Мәрҗани шуңа күрә: «Газават» белән бер тамырдан килә торган «газан» сүзеннән алынган дип аңлатылса, дөрес булмаса да килешә төшәр иде», – ди.

Аннан соң – кардәше Коерҗык хан җиде йөз туксан җиденче (1394–95) елдан җиде йөз туксан тугызынчы (1396–1397) елга чаклы хан булып торды. Шул елда, ягъни Туктамыш ханнан соң булган таркалышта, Россия хөкемдары Василий Дмитриевич Казанга керде. Аннан соң – кардәшенең углы Тимер Котлуг хан бине Мәлик Тимер хан. Аннан соң – кардәше Бикбулат хан җиде йөз туксан сигезенче (1395–1396) елдан сигез йөз икенче (1399–1400) елга чаклы хан булып торды һәм шул елда үлде. Татар теле уйгур хәрефләре белән язылган бер ярлыкны бу урында китерү мөнасиб күрелде[1].

«Тимер Котлыг сүзем: уң кул, сул кул угланнарына, хисапсыз изге башлыкларга, мең, йөз, ун бикләренә, эчке шәһәрләрнең казый[2], мөфтиләренә[3], мәшаех суфыйларына, диван язучыларына, салым җыючыларга һәм тамгачы (таможнячы)*ларга, йөрүчеләргә һәм юлаучыларга, букявылларга һәм тоткавылларга, почтачыларга һәм стансачыларга[4], кошчы, барсчы, көймәче, күперче һәм базарда торганнарга[5] бу ярлыкны тота торган Мөхәммәднең баба-аталары борынгы үлгән Саин[6] ханнан бирле берсе артыннан берсе ярлыкка әсасланган рас тарханлык хокукында тордылар; атасы Хаҗи Бәйрәм хуҗаны безнең хан агаларыбыз мәрхәмәт итеп тархан кылганнарын белдерергә үтенгәнлектән, аның үтенечен кабул итеп: «Мөхәммәд безнең мәрхәмәтебездә булып, тархан булып торсын», – дидек. Бу көннән алып, Кырым белән Кырык җирнең төмәнендә* (өлкәсендә)

---

[1] Гәрчә Мәрҗани моны татар телендә язылган дисә дә, бу хәзерге татар теленә ерак тора торган канцелярия теле белән язылган. Г. Газиз һәм Г. Рәхим төзегән «Әдәбият тарихы, борынгы дәвер» исемле китапта моның В.В. Радлов дешифровкасы китерелгән. Ярлыкны Мәрҗани укуы белән Радлов укуы бертөрле үк булмаса да, эчтәлеген аңлату өчен, без шуны китердек. Кайбер аңлашылмаган сүзгә өстәмә рәвештә астөшермәләр бирдек.

[2] Казый – судья.

[3] Мөфти – фәтва бирүче, читен мәсьәләләрне чишеп бирүче.

[4] Ярлыкта болар: «Ямчы шусунчыларга».

[5] Болар һәммәсе дә мәәмүрләр (чиновниклар дигән сүз) исеме. *Г. Газиз һәм Г. Рәхим искәрмәсе.*

[6] Саин – Бату ханның кушаматы.

Судак атлы ныгытманың җәварында[1] *борынгы заманнан бирле мөтәгаддид*[2] *тарханнар белән мәшһүр булган Ындырчы саласы белән каласыннан шәргый кабала гадәте буенча җирләре, сулары белән Мөхәммәднең угыллары олуг хажи Мөхәммәд һәм Мәхмүд Азат Тархан булсыннар. Боларның җир-суларына, баг-бакчаларына, мунча-тегермәннәренә, тәсаррыф кыла*[3] *торган җирләренә, борынгы заманнан калган азатларына һәм аларның бөтен салаларына, сабанчы-уртакчыларына беркем дә тимәсен; юлсыз, сәбәпсез нәрсәләрен тартып алмасыннар. Йөземлекләреннән алына торган тамга* (пошлина)...[4] *амбар малы, ындыр хакы, арыклардан алына торган ясак, калан дип атала торган салым, бурыч, хәрәҗ алмасыннар. Әгәр ул китсә-килсә һәм керсә-чыкса, Кырымда, Күфәдә нинди генә нәрсә алмасын, сатмасын, тамга һәм үлчәү салымы алмасыннар; тархан һәм хезмәтчеләрдән алына торган юл хакы да, каравыллык та алмасыннар, туар-караларыннан олау алмасыннар, кунак төшермәсеннәр; эчәргә-ашарга сорамасыннар, авырлыклардан, салымнардан һәм фәүкыльгадә*[5] *салымнардан котылдырылсыннар; тыныч торып, тынычлык белән торып, кич вә иртә, шәриф вакытларында безгә һәм безнең ыругыбызга дога кылсыннар дип, [тиешле урында] тоттырырга алтын нишанлы ярлык бирелде, тарих сигез йөз дә барс елы шәгъбан аеның алтынчы көнендә Үзи*[6] *суының буенда мөҗавиранда*[7] *булганда язылды».*

Аннан соң – кардәше Шадибәк хан сигез йөз өченче (1400–1401) елдан сигез йөз унынчы (1407–1408) елга чаклы Болгарда

---

[1] Җәварында – тирәсендә, шуны чолгаган һәм шуңа караган җирдә.

[2] Мөтәгаддид – күп, күпсанлы.

[3] Тәсаррыф кыла – файдалана.

[4] Бу урынны Радлов тәрҗемә кылмаганга, без дә Березинча тәрҗемәгә ышанмаганыбызга күрә тәрҗемә кылмадык. *Г. Газиз һәм Г. Рәхим искәрмәсе.* Тәрҗемә кылынмаган сүзләр болай: Булар тамгасы инкинчи үскү булгурди.

[5] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[6] Үзи – Днепр.

[7] Мөҗавиранда – «изгеләр янында булганда» дип аңладык. Мәрҗанидә исә бу сүз «Мучуранда» дип алынган. Ул чакта бу – урын исеме була.

һәм башка җирдә. Аннан соң кардәшенең углы – Пулат Тимерхан бине Тимер Котлуг хан сигез йөз унынчы (1407–1408) елдан сигез йөз ундүртенче (1411–1412) елгача хан булып торды. Болгарда сугылган тәңкәләре бар. Сигез йөз унынчы (1407) елда Кырымда иде. Аннан соң – кардәше Тимерхан сигез йөз унөченче (1410–1411) елдан сигез йөз унбишенче (1412) елга чаклы исән. Болгарда сугылган тәңкәләре бар. Сигез йөз уналтынчы (1413–1414) елда вафат булды. Корҗык хан һәм аннан соңгы Ырыс хан нәселеннән килгән ханнар, Туктамыш хан заманы үтеп, Идегәй мирза һәм аның балалары ярдәме белән тәхеткә утырып, хөтбәдә һәм акчада исемнәре булып, дәүләтне идарә итү мирзалар кулында булуына риза иделәр. Тимерхан Идегәй мирза белән килешә алмаган: «Мин үзем буйсындыручы бер баһадир булып, ничек буйсынучы булыйм, көтүне җитәкләп йөрүче үгез көтүгә буйсынамыни?» – дип, араларында талаш, кычкырыш чыгып, сугышып, икәве дә һәлак булганнар. Тимерхан гайрәтле, батыр йөрәкле, йомшак табигатьле, бик зирәк һәм гыйлем белән адарынган булуын күрсәтә торган эшләр бар. Бу – Идегәй мирзага ихтыяр бирмәүдән, балаларының күркәм исемнәреннән аңлашыла. Аннан соң – атасының бертуган кардәшенең углы Барак хан бине Коерҗык хан; казах ханнарының бабасы. Аннан соң – углы Дәрвиш хан. Аннан соң – углы Чикәрә хан. Сигез йөз унҗиденче (1414) елда шәһре Болгарда, Олы Урдада һәм Хаҗитарханда сугылган тәңкәләре бар.

Аннан соң – бабасы белән бертуганның углының углы Мөхәммәд хан бине Тимерхан бине Тимер Котлуг. Олы Мөхәммәд хан дип мәшһүр. Сигез йөз егерме икенче (1419) елда падишаһ булып Саинилар (Бату ханнар) тәхетенә утырды. Сигез йөз утыз тугызынчы (1435–1436) елда Сарайдан чыгарылды. Аның гасырында, ягъни сигез йөз утыз бишенче (1431) елда Россия хөкемдары Василий Дмитриевич вафат булгач, аның углы Василийның кечкенә булуы сәбәпле, аның атасының туганы Юрий Дмитриевич үзе хөкемдар булырга теләп, җәнҗаллашып, икәве Сарайга Олуг Мөхәммәд хан алдына килгәннәр. Икенче бер риваятькә караганда, Ирина углы Дмитрийның тәхет варисы

булырга хакы булса да, София углы Василий, рус кайсарлары нәселеннән булу сәбәпле, рус тарафдарлары дәгъвасы буенча Дмитрий хөкемдарлыгы бетерелеп, Олуг Мөхәммәд хан хөкемдарлыкка Василийны билгеләп, үзеннән илче кушып, Мәскәүгә җибәрде. Ул, Мәскәүгә килеп, ханның указын укый. Василийны Мәскәү тәхетенә утыртып, Россия халкы Урда ханнарына салымны һәрвакыт кичектермәстән түләп торырга вәгъдә иткәннәр.

Аннан соң – кардәше Мөхәммәдхан әс-Сәгыйрь. «Кече Мөхәммәд хан» дип танылган кеше. Ак Урда хөкемдары Ядкяр хан бине Тимер Шәех хан әш-Шәйбани ярдәме белән башкала Сарайга һөҗүм итеп, агасы Олуг Мөхәммәд ханны сигез йөз утыз тугызынчы (1435–1436) елда Сарайдан куып чыгарып, сигез йөз җитмеш җиденче (1472–1473) елга кадәр үзе хан булып утырды.

Аннан соң – углы Кечек Әхмәд хан. Аксак Тимер нәселеннән Хорасан патшасы солтан Хөсәен мирза бине Байкараның сеңлесе Бигәй-бигемгә өйләнеп, тугыз углы булган. Сигез йөз җитмеш җиденче (1472–1473) елда Россия мәмләкәтенә барып, Алексин шәһәренә һөҗүм итсә дә, бер тарафтан русларның бик күп гаскәр белән каршы килүләре сәбәпле, икенче тарафтан Ханкирмән хөкемдары Даниал бине Касыйм хан белән борадәре Мортаза килүеннән хәбәр алып, Мортаза һәм Данилларның башкала Сарайга һөҗүм итүләреннән куркып кире кайтты. Аннан соң – углы Сәед Әхмәд хан. Кардәшләренең тавышгаугаларыннан тынычлана алмады. Бер хәбәргә караганда, сигез йөз сиксән тугызынчы (1484) елда Себер ханы Апак хан бине Мәхмүд хан һөҗүм итеп, Әхмәд ханны үтереп киткән, имеш.

Аннан соң – углы Сәед Мөхәммәд хан. Аннан соң – атасы белән бертуганы Шәех Әхмәд хан бине Кечек Әхмәд хан. Бу хан Сарай шәһәрендә булган татар ханнарының иң соңгысы була; аннан соң Сарайда булган татар дәүләте тәмам таркалып, башкалалары харап булды. Әхмәд хан Россия хөкемдары өченче Иван гасырында Мәскәүгә хат язып, илче җибәреп, һәр ел үтәлеп киленә торган салымны түләүләрен таләп итә. Хөкемдар әлеге хатны ачу белән аяк астына салып таптый, илчеләрне үтереп,

фәкать берсен генә кайтарып җибәрә. Бу вакыйгадан соң Россия хөкемдарын әдәпкә кертү нияте белән хан, Россия мәмләкәтенә һөҗүм итеп, йортларын талап, җимереп, үзләрен үтереп, әсир алып, «Угра» елгасы буена барып җитә. Шул җирдә Россия халкы бик күп булып җыелып алып, зур сугыш була, хан гаскәре җиңелеп кача. Хан үзе руслар кулына эләгеп, аннан качып китсә дә, артыннан куып җитеп, тотып үтерәләр. Сарай дәүләте шуның белән бөтенләй юк ителеп, татар дәүләте өч урында: Казанда, Хаҗитарханда һәм Кырымда кала. Бу тугыз йөз сигезенче (1502) елда шулай була.

Туктамыш нәселе патшалары

Аларның беренчесе – Насыйретдин Туктамыш Баһадирхан бине Туйхуҗа бине Туккыл хуҗа бине Күнҗәк бине Сарича бине Үзтимер бине Тукайтимер бине Җүҗи хан. Туктамыш хан нәселен кайберәүләр болай дип әйтәләр: Туктамыш хан бине Туйхуҗа бине Җимтай бине Әбисан. Алай булганда Урда бине Җүҗи хан нәселеннән була. Хода белсен. Туктамыш хан татар ханнарының иң эшлеклеләреннән, көчле, мәшһүр булган. Җиде йөз җитмеш сигезенче (1376–1377) елда Сыгнакны алып, Ак Урда хөкемдары һәм Насыйретдин[1] Баһадирхан исеме белән аталды. Ибне Гарәпша: җиде йөз җитмеш беренче (1369–1370) елда Мавәраэннәһер хөкемдары әмир Хөсәен бине Фулад бине Кызгын әт-Төркине Тимер үтергәннән соң, Туктамыш ханның гайрәте кузгалып, Сыгнак белән Утрар ягында Тимер белән сугышты, ди. Анысын Аллаһ белә. Шуннан соң, Ырыс хан үлгәч, Аксак Тимер заманында Тимернең ярдәме белән Ырыс хан балаларын җиңеп, барлык Җүҗи улусына патша булып, Сарай шәһәрендә тәхеткә утырды һәм җиде йөз сиксән икенче (1380–1381) елда үз исеменә акча суктыра башлады. Бик шәфкатьле, йөрәкле, кирәкле чараларны күрә белүче патша иде. Азәрбайҗанга һөҗүм итеп, Тәбриз һәм аның

[1] Насыйретдин – динне көчәйтүче. Бу – Туктамыш ханның кушаматы булган.

тирә-ягын сугышып алып, галимнәреннән Камалетдин әт-Тәбризине Сарайга алып кайтты. Россияне җиңеп, барысын да яңадан татарга буйсындырды һәм Тимернең сугышларының өченче елында Сәмәркандны барып алды[1]. Шуннан соң Туктамыш ханның әмирләреннән коңгырат кабиләсе башлыгы Идегәй мирза дигән кешедән кайбер сәбәпләр аркылы хәтере калып, аны бераз әдәпкә утырту теләген йөрәгендә сакласа да, уен-көлке мәҗлесендә күңеле ачылып китеп, кәефе килеп; түбәндәге сүзнең мәгънәсе нәрсә дип сораган: «Сиңа да, миңа да бер көн килер, ул көндә синең бәхет кояшың баер, тереклек нигъмәтләреннән тыелырга мәҗбүр итәр. Синең күзләреңне мәңгелек йокы каплар». Идегәй, саташтырып әйтте: «Хыянәттән, ачу саклаудан, дәрәҗә түбәнәю, яшьлек чагы үтү яки салынган нигезнең йомшаруыннан куркып, хуҗам хаканга сыенам». Шулай дип ханны алдалап, тышка гына чыгып керәм дип китеп, бер яхшы атка атлана да Тимер янына качып китә. Тимергә барып, аны Туктамыш хан мәмләкәте өстенә һөҗүм итәргә чакыра. Тимер, бик тиз генә «Бәриятел-Бәркә»не яулап алу өчен, Туктамыш мәмләкәтенә һөҗүм итте. Ике гаскәр очрашып сугыша башлаганда, Туктамышның уң фланг әмирләреннән берсе икенче бер әмирдә ачуы булып, шуңардан үч алуны таләп иткән. Туктамыш хан: «Дошман каршы килгәндә, үч алу вакыты түгел» диюенә карамастан, әлеге әмир үзенең кирелегендә дәвам итеп, үз кабиләсеннән булган гаскәре белән аерылып китә. Шулай итеп, Идегәй белән бу әмир иң кирәк вакытта аерылып китеп, Туктамышның канатын сындырдылар. Шулай булса да Туктамыш Тимер белән сугышты. «Бу заманда мондый сугыш күрелгәне юк иде», – диделәр. Ләкин ахырында җиңелеп качып, Польша мәмләкәтенә керде. Хәзер дә анда яши торган мөселманнар – шул Туктамыш хан гаскәреннән аерылып калган татарлар. Бу вакыйга җиде йөз туксан өченче (1390–1391) елда булды.

Идегәй мирза Тимерне алдап, отып, качып калды. Тимерне алдап отканнарның берсе – бу. Икенчесе – казый, шәех Вәлиет-

[1] Бу вакытта Аксак Тимер Һиндстанны алу өчен киткән була.

дин Габдрахман бине Халдун әл-Мәгъриби әл-Мәлики. Тимер, бу мәмләкәтне талап, яндырып, халкын үтереп, тәмам җимереп, татар дәүләтенә бик зур зарар китерде, бик зур каршылыклар, аерылышулар вакыйг булды. Шуннан соң Идегәй мирза кавем-кабиләсе, ил-күршеләреннән гаскәр туплап, Ырыс хан балаларыннан Тимер Котлуг хан бине Тимер Мәлик ханны патша итеп, Туктамыш хан белән бертуктаусыз сугыш алып барды. Ләкин барысында да җиңелде. Уналтынчы мәртәбә сугышып җиңелгәннән соң, бөтенләй хәбәр-хәтерсез югалды. Туктамыш аны никадәр эзләтсә-тикшерсә дә таба алмады, үлеге-тереклеге беленмичә, ике ел үтеп китте. «Инде үлгәндер» дип уйлап, Туктамыш ханның һичбер нәрсә турында уйламыйча, тыныч кына яшәгән вакытында, аңсыздан һөҗүм итеп аны үтерде дә, мәмләкәтен бөтенләй үзенә каратып, ханнарның бары исемен генә калдырды. Хөтбәдә алар исеме телгә алына, акча алар исеменә сугыла һәм яшәр өчен бераз акча бирелә иде. Тимер хан көннәренә кадәр шул хәл дәвам итте. Туктамыш хан җиде йөз туксан сигезенче (1395) елда үлде. Туктамыш ханның Польша хөкемдары Ягайлага татар телендә уйгур хәрефләре белән язган ярлыгы[1]:

«Туктамыш сүзем.

Ягайлага.

Олуг урынга утырган хәбәрен аңлату өчен, Котлыбуга һәм Хәсән башлыгында илчеләр җибәргән идек. Син дәхи келәнчеңне безгә җибәргән идең. Өченче ел Бикбулат һәм Хуҗамәдин баш булып берничә угланнар һәм Бәкиш Турдуҗан Бирде һәм Давыт баш булып торган бикләр Идегәй атлы кешене астыртын Тимерне чакыртып җибәргәннәр иде. Бу чакыруга ул килде һәм аларның ала күңелләренә муафәкать итеп, хәбәр җибәрде. Ил кырыена җитеп килгәндә, бөлеп, җыелып сугышырга торганда, ул яман кешеләр баш тартканга, илдә тыныч-сызлык булып, ул эш тагы шулай булды: Тәңре безгә мәрхәмәт

[1] Бу текстның хәзергә телгә күчерелгәне Г. Газиз һәм Г. Рәхим төзегән «Татар әдәбияты тарихы, борынгы дәвер» исемле китаптан алынды.

итеп, дошманлык кылган Бикбулат, Хуҗамәдин, Бәкши, Турдуҗан Бирде, Давыт башында торган угланнар, бикләрне җәза кылды. Бу эшләрне аңлату өчен, Хәсән Тулу Хуҗаны баш итеп илчеләр җибәрдек. Тагы исә безгә караган илләрнең чыгышларын[1] *чыгартып, барган илчеләргә бир, хәзинәгә тапшырсыннар. Борынгы гадәтчә, сәүдәгәр артельләрең йөрсеннәр. Олуг Улусның тормышына тагы яхшысы ул булыр дип, алтын нишанлык ярлык нәшер иттек. Тавык елы тарих җиде йөз туксан бештә рәҗәб аеның сигезенче көнендә Ардутанда*[2] *булган чакта язылды».*

Туктамыш ханның сигез углы булып, болар: Җәләлетдин, Җәббарбирде, Кәбәк, Кәримбирде, Искәндәр, Әбү Сәгыйд Кечек, Кадирбирде һәм Туккол Хуҗа исемлеләр.

Аннан соң углы Җәләлетдин хан. Туктамыш балалары аталары вакыйгасыннан соң һәркайсы шикле бер хәлдә калып, ватаннарын ташлап, төрле тарафка таралышып киттеләр. Җәләлетдин Россия мәмләкәтенә качкан иде. Идегәй мирза белән Тимер хан арасында аңлашылмау тугач, Туктамыш хан балалары бу хәлдән файдаланып, патшалык мирасын таләп итеп баш күтәрделәр. Җәләлетдин хан сигез йөз унбишенче (1412–1413) елдан башлап ундүрт ай патша булды.

Аннан соң – кардәше Кәримбирде хан. Биш ай патша булып торганнан соң, туганы Җәббарбирде аны үтерде.

Аннан соң – Җәббарбирде хан. Аннан соң – кардәше Кәбәк хан. Сигез йөз егерме җиденче (1423–1424) елларда булса кирәк, ул Россия мәмләкәтендә иде.

Аннан соң – кардәше Кадирбирде хан. Кырым, Болгар һәм башка кайбер илләргә патшалык итте. Шәһре Болгарда һәм Кырымда сугылган тәңкәләре бар. «Идел туңса, кем кичмәс, Идеге булса, кем китмәс» дигән мәкальне аның мәкале диләр. Кырым ханнары Туктамыш ханның туганы Түләк Тимер балалары булалар.

---

[1] Түләү, ясак.

[2] Ардутан – Азак (Азов) диңгезе буендагы сәүдә шәһәре. *Г. Газиз һәм Г. Рәхим искәрмәсе.*

Казан шәһәрендә оешкан яңа дәүләт турында

Казан шәһәре Казан елгасының Иделгә койган җирендә 55 градус 45 минут төньяк киңлектә, 66 градус 46 минут көнчыгыш озынлыкта, 15 градус көньяк ноктасыннан бик аз гына ким урында урнашкан. Казан мәмләкәте бу тарихтан 400 ел элек бик мәшһүр мәмләкәтләрдән булып, хәзерге заманыбызда безнең татар халкының мактанычы, байлыгы, культура һәм гыйлем үзәге булса да, тарих һәм этнография гыйлеме белән кызыксыну булмаганлыктан, ул вакыттагы хәлләр, вакыйгалар һичкайчан бер кәгазьгә язылмаган, сөйләнмәгән. Борынгы хәбәрләр, гомумән, анда булган патшалар, галимнәр, олы хакимнәр һәм бүтән хәлләр турында үз халкыбызга һәм башкаларга мәгълүм булмастай бөтенләй наданлык пәрдәсе астында калган, бу турыда шул гасыр галимнәре иҗат иткән дөрес, киң күләмле һәм теләкне үти алырлык булган бер тарих китабы табылуны көтеп торсак, Хода белә, теләгебезгә ирешә алырбызмы икән? Чөнки бу мәмләкәткә[1] Аксак Тимер һөҗүм итеп тармар иткәннән соң, Сарай патшалыгының тәртибенә һәм дәүләтенә зәгыйфьлек һәм таркаулык килеп, шаһзадәләр арасында үзара каршылык чыкканнан соң, шул мәмләкәтнең бер почмагында аз гына куәт белән мөстәкыйль дәүләт булып төзелгән һәм бер-ике гасыр гомер иткән булса да, киләчәктә әйтелгәнчә, тышкы дошманнар һәм Россиянең һөҗүм итүләреннән куркып, эчтә берлек юклыгы белән көчсезләнеп, гыйлем вә мәгариф тарата, халыкка тәрбия биреп, аларны яктылыкка чыгара, китаплар язып, тарихтан дөрес бер әсәр калдыра алмаганнар булса кирәк. Бәлки, андый эшләр бервакыт эшләнгән булса да, ул заманда китап басу таралмаганлыктан, нөсхәләр күбәйтелеп таратылмаган, булган нөсхәләре Казан мәмләкәте өстенә килгән бәла-казалар вакытында югалып, һәлак булып беткәннәр. Халык телендә йөргән сүзләргә караганда, Казанда яхшы бер китапханә булган, ләкин руслар алгач, яндырып һәлак иткәннәр.

---

[1] Алтын Урдага.

Ул вакыт Казан ханнарына нәсел-нәсәп һәм дин ягыннан якын, күрше булган ислам мәмләкәтләре дә – Кырым, Мавәраэннәһер, Төркестан, Харәземдәге татар һәм мангул ханнары һәм мирзалары арасында җәнҗәл, ызгыш-талаш күп булганлыктан, гыйлем-мәгариф бик түбәнәйгән. Гәрчә ул мәмләкәтләрнең кайбер галимнәре тарафыннан үзләрендә булган вакыйгаларны бәян иткән китаплар язылгаласа да, Казан мәмләкәте алар өчен Дәште Кыпчак шикелле аерым зур бер мәмләкәткә әйләнә, ил-көндә дәвам иткән тынычсызлык сәбәпле аралашу мөмкин булмаганлыктан, аларга Казан әхвале мәгълүм түгел һәм шулай ук китапларында да Казан турында бер сүз дә юк... Шулай да кайбер китапларда, китап читләрендә күчермәләр, халык телендә ата-бабадан ишетелеп, сөйләнеп килгән хәбәрләр юк түгел. Аларны тикшермичә торып, бердән, ышанып карау бик үк ярамаса да, һичбер дәлилсез ялган дип хөкем итү дә шулай ук дөрес булып бетмәс. Бәлки, заманның әхвален һәм андагы маҗараларның таләпләрен белеп, хәлләрнең агышына, заманының теләгенә туры китереп фикер йөртергә кирәк. Инде Казанга һәм аның тирә-ягындагы хәлләргә күз салсак, Кабан күле башында Архиерей йорты эчендә алты йөз алтмышынчы (1261–1262) һиҗри елда вафат булган Әхмәд исемле мөселманның каберенә куелган борынгы бер таш бар. Һәм капкасының тышкы ягында патша каберенә куелган бер зур таш тора. Болардан башка тагын байтак кына шундый ташларның андагы чиркәү бинасына тотылып һәлак ителүләре дөрес чыганактан алынган дәлилләр белән исбат ителгәнлектән, бу урында шәһәр яки авыл булып, Җуҗи балалары килү һәм аларның исламга керүләреннән элек үк бу илдә ислам таралган була. Ул халыкның мөселман булуы Болгар патшалыгы вакытында булырга кирәк. Чөнки Болгар патшалары һәм аларның иярченнәре Габбасия хәлифәләре шикелле, һәр тарафка өндәүчеләр җибәреп, төрле чаралар кылып, тирә-яктагы төрле халыкны туры юлга күндереп, мөселман итәргә тырышканнар. Җуҗи балаларыннан Бәркә хан алты йөз кырыгынчы (1242–1243) ел башында сәламәтлек йорты булган исламга кереп, мөселман булса да, татар хан-

нары динне солых белән җәелдерүдән бигрәк, Россия, Польша, Әфлак, Богдан һәм башка шундый халыкларны үз кул астында тотарга тырышканнар. Сигез йөзенче (1397–1398) һиҗри ел башында Россия гаскәре шәһре Болгарга, Казанга, Жукотин һәм Кирмәнчек шәһәрләренә һөҗүм иткәнлекләрен югарыда сөйләп үткән идек. Сигез йөз кырыгынчы (1436– 1437) елда Олуг Мөхәммәд хан Сарай шәһәреннән чыгарылганнан соң Казанга килеп, икенче бер сүзгә караганда, аның углы Мәхмүд хан Казанны Гали-бәк кулыннан алып, дәүләт нигезе салып, ханлык тәшкил итте дигән хәбәрләргә караганда, бу тарихтан элек үк Казан шәһәре булган икән. Гомумән, татарларыбыз арасында мәшһүр булган. Казан борында бу урында булмаган, алты йөз сиксән тугызынчы – алты йөз туксан җиденче (1290–1297) елларда бина кылынып, иске Казанда хөкүмәт йөз дә дүрт ел, яңа Казанда бер йөз илле сигез ел булды, дигән сүзләр дә бар.

«Казан» дип аталуның сәбәпләре турында үткән фасылда Нәүгыйзадә сүзләрен китергән идек, ләкин аннан башка тагын берничә төрле сәбәпләр бар, имеш. Мәсәлән, «Казан» дип аталган елга буенда, казан шикелле, түбә өстендә утырганлыктан, Казанны башлап салдыручының исеме Казан хан булганга, Бату ханның җәйләү урыны булып, бервакыт Казан елгасына аш казаннары төшеп, соңыннан бу урынны телләрдә «Казан урыны», «казан төшкән урын» дип йөрткәннәр, ләкин әкрен-әкрен иярчен сүзләрен төшереп калдырып, җиңеләйтеп, «Казан» дип кенә аталып калган дигән сүзләр бар.

Казан арты Алат юлы төбәгенең кайбер кешеләре сөйләвенә караганда, Казан шәһәре борын заманда Алат юлында яңа Казанга караганда төньяк белән җәйге кояш баешы арасында Ашыт елгасының көнбатыш ягында Казаннан алтмыш чакрым җирдә булган, диләр. Хәзердә дә әле ул урын «Кала тавы» дип атала. Ләкин борын заманда шәһәр тирәләрендә табигый саклык корылмалары, мәсәлән, текә ярлы зур сулар яки биек таулар шикелле нәрсәләрнең булуы күздә тотылган. Бу урынның исә гәрчә көньягы биек ярлы Ашыт суы булса да, башка якларында

ышыкланыр нәрсә юк. Көнбатыш ягында Ашыт елгасына туры почмак булып төшә торган «Әйшә» суы булса да, ул су үзе бик кечкенә, яры, тавы юк, төньяк һәм көнчыгыш яклары бөтенләй ачык, тигез басу.

Икенчедән, ул урында соңгы заманга чаклы куе урман булган. Хәзерге заманыбызда да әле чиксез «Илләт» урманы күренеп тора. Шундый зур исем тоткан шәһәрнең, гәрчә харап булса да, урыны һәм тирә-ягы алай тиз бер заман эчендә урман булып китмәскә кирәк иде.

Өченчедән, ул урын – көнбатыш ягындагы мөселман авылларының чиге. Шуннан ун чакрымда чирмеш авыллары башланып китә һәм ул тирәдәге мөселман авылларының исемнәре, мәсәлән, Бәрәскә, Бәрәзә, Өшкәтә, Әтнә, Күәм, Үртәм, Киме, Мамыш төрки телдә түгел. Чирмешчә түгел микән? Әтнә һәм Мамыш авылларының, асылда, чирмеш авыллары икәнлекләренә ачык дәлилләр бар. Мамыш мең ике йөзенче (1783–1786) елда салынган яңа авыл булып, «Мәмеш» дигән чирмеш исеме белән аталган. Моннан ул тирә халкы соңгы заманнарда гына мөселман булганнар дип уйларга мөмкин. Шулай булгач, татар шәһәренең тирә-янында ничек чирмеш авыллары булуы мөмкин? Татар шәһәре булу нәтиҗәсендә байтак җиргә кадәр мөселман авыллары булу кирәк иде. Менә бу сәбәпләргә караганда, ул сүзгә ышанып булмый. Бәлки, ул урын ислам мәмләкәтенең чиге булганы өчен бервакыт чирмешләрдән саклану максатыннан бер кальга төзелеп ныгытылган булып, аннан җимерелгәч тә аның урыны «кальга урыны» дип аталган булып, соңыннан: «Казан борын заманда башка бер урында булган» дигән сүзне саташтырып, «Шәһре Казан борында шунда булган», – дигән нәтиҗәгә киленгән булса гаҗәп түгел. Әмма Казан мәмләкәтендә булган мөселманнарның күбрәге борында Казан шәһәре ошбу яңа Казаннан кырык биш чакрым ераклыкта төньяк белән җәйге кояш чыгышы арасында «Арча юлы» дип йөртелгән районда, Казан суы буенда, «Иске Казан» дип аталган җирдә булган, имеш, диләр. Бу сүз дөреслектән ерак түгел, чөнки әлеге урын һәм мөселманнар, һәм

руслар телендә «Иске Казан» исеме белән мәшһүр. Әлбәттә, һичбер мөнәсәбәтсез алай дип атамаган булырлар, бәлки Казанның әүвәлдә шул урында булганлыгыннан шулай дип аталгандыр.

Икенчедән, бу урын мөселман авылларының үзәгендә, олы Себер юлы патша юлы өстендә[1], Казан суына төшә торган биек тау башында булуыннан, урыны шәһәр урыны булырга бик лаек.

Өченчедән, аның тирә-ягын әйләндереп казып, ихата итеп алган канавы бар һәм якынында каберлекләр, анда иске вакытларда язылып каберләргә куелган ташлар бар. Ул ташларның берсендә болай дип язылган. Башы өчпочмак рәвешендә калкытып эшләнгән хәрефләр һәм бик үк матур булмаган язу белән: «Һу әл-Хәйүү әл-ләзи ля ямүт»; шуннан биш юл итеп, беренче юлда: «Калә Аллаһу тәбәрәкә вә тәгаля: күллү нәфсин заикатүл-мәүт»; икенче юлда: «Калә ән-нәби галәйһиссәлам: Әд-дөнья мәзрәгател-ахирәт»; өченче юлда: «Тарих тукыз йөздә мөбарәк рабигыль-әүвәл аеның ахырында ирде»; дүртенче юлда: «Мелла Сәлам Гали дәрвиш хәлале Назби мәләк»; бишенче юлда: «Хатыны дарел-фәнадин дарел-бәкага рихләт кылды, гафәрә Аллаһ».

«Назби мәләк» дигән сүздә бераз шик бар: «Назби бикә» түгелме? Янә бер ташта оста кеше күфи язуы белән гүзәл һәм бик шәп итеп калкытып язган: «Калә Аллаһу Тәгалә: Күллү нәфсин заикатүл-мәүт. Тарих тукыз йөз утыз тукызда рабигыль-әүвәл аенда Тулун Хужа гаяле кыз Айменгәч дарел-фәнадин дарел-бәкага рихләт кылды».

Кафта нокта юк, ләкин мәркәз тугрысында куйган ике нокта «й» дан, «б»дан башка икенче хәреф юк. «й» астына бер нокта куйган. Сарих анда таләбе нокта[2] булган

---

[1] Казаннан Себер ягына үтә торган олы юлны Екатерина II төзек хәлгә китергән. Шуңа күрә бу юл «Патша юлы» дип атала иде.

[2] Сарих анда таләбе нокта – ноктаны сорый торган хәреф ап-ачык.

һич хәреф юк. «Әлифба» «й»га бу сурәттәй гомүдән[1] сызган[2].

Янә Коркачык авылы турында Казан елгасының төньягында тау башында зур бер иске каберлек бар, һәм шундагы берничә ташның берсен болай укыдым: «Калә Аллаһу Тәгалә: Күллү мән галәйһә фанә вә ябка вәҗһү Раббикә зүл-җәлали вәл-икрам. Калә ән-нәби саллаллаһу галәйһи вәссәлләм: Әд-дөнья мәзрәгател-ахыйрәти. Тарих тукыз йөздә илле өчдә Халид Хәлил углы».

Халид дигән сүздә бераз шөбһә бар, башкалары ачык язылган. Ташның арт ягында: «Бу ташны хатыны Әшлак бикә куйдырды», – дип язылган.

Олуг Мөхәммәд хан килүдән элек, Казанда мөстәкыйль хөкемдарлар булмыйча, әүвәл Болгар патшаларына, соңгылары Сарайдагы татар ханнарына буйсынган бикләр, шаһзадәләр хөкүмәт тоткан булсалар кирәк. Мөстәкыйль хөкемдарлык булганда, тарихларда Болгар, Сарай һәм Хаҗитархан хөкемдарларыныкы шикелле акча сугулары һәм башка әсәрләре күренергә кирәк иде. Шәһре Казанда ханлык тәшкил ителеп, патша тора торган шәһәргә әйләнгәндә, аның халкының күбрәге ханга иярәп килгән Сарай Урдасы, Хаҗитархан, Кырым һәм башка ханлыклардан җыелган татарлар булса кирәк. Сәүдә һәм һөнәр эшләрендә дә күрше мәмләкәтләр халкыннан түбән булмаган булсалар кирәк. Әмма аларда гыйлем агачы кайчан да булса бер вакыт чәчәк аткан булса, никадәр авырлыклар, җәбер-җәфалар күргән булса да, безгә бераз гыйльми әсәрләр калган булыр иде. Без шулай уйлыйбыз. Дөресен Аллаһ белә.

Олуг Мөхәммәд бине Тимерхан бине Котлуг Тимер хан бине Ырыс хан – Казан патшаларының беренчесе. Сигез йөз кырыгынчы (1436) елда энесе Кече Мөхәммәд ханның һөҗүме

---

[1] Гомүдән – югары таба.

[2] Бу аңлатмаларның барысы да гарәп хәрефләренең үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Гарәп әлифбасында «ка» дигәндәге «к» хәрефенең өстенә ике нокта куела. «Й» хәрефенең астына ике, «б» хәрефенең астына бер нокта куела. «Й» ны өсткә таба сузу, «йа» дип әйтү өчен, «й» ның өстенә утыртма сызык куелырга мөмкин. Гарәп әлифбасының шул үзенчәлекләрен искә алганда, Мәрҗанинең югарыдагы аңлатмасына төшенергә мөмкин.

сәбәпле Сарайдан куылгач, Россия мәмләкәтендә Тул[а] тирәсендә Бело дигән урынга барып урнашты. Россия хөкемдары Василий II аның килүен хуш күреп, аны хөрмәт итеп, шул урында торырга рөхсәт һәм халкына күчеп килергә лаек урын бирсә дә, хан карарланып, кыш килгәндә суыктан һәм дә дошман һөҗүменнән саклану һәм бер төрле ышыклану урыны ясау теләге белән, Идел елгасының тау ягында Казанга якынрак бер урында боздан крепость ясап, өстеннән сулар коеп ныгытуын Россия хөкемдары белеп шиккә калуы өстенә, якыннары һәм тирә-янындагы җаваплылары: «Монда крепость ясап, үзебезнең күптән бирле белгән татарларыбызның кышламакчы булулары, акылга муафыйк түгел, хәзер боздан крепость салса, соңрак таштан салыр, аның күрше булуыннан сакланырга кирәк», – дип хөкемдарын куркыткач, ул ханны үз мәмләкәтеннән чыгарырга боерык бирде. Олуг Мөхәммәд хан аркасында, аның ярдәме һәм указы белән Россия хөкемдары булып, ханнан кат-кат күргән ихтирамнарыннан күз йомып, татарларны мәмләкәтеннән чыгарырга зур көч куйды. Хан никадәр гозер итеп, үз дәүләтенә кайта алганда аңардан алган түләүләрне кайтарып биреп, моннан соң һичбер салым алмаска, бәлки үзе салым түләүгә вәгъдә биреп, шуның өчен углын рәһенгә[1] куеп калдырырга тәкъдим итсә дә, ханның гозере-ялваруын һич тә колагына алмастан, агасының углы Шемяка һәм Кызыл Димитрий дигәннәрне гаскәр башлыгы итеп билгеләп, ханны Белодан көчләп куып чыгарырга кушты. Өстенә Россия гаскәре килеп җитеп, бер Ходадан башкадан өметләре киселгәч, хан тәһарәтләнеп, бер агачның күләгәсендә ике рәкәгать намаз укып, җылый-җылый дога кылып, Ходадан ярдәм сорады. Мәһабәтле ханның арслан куәте, каплан гайрәте белән атына менгәнен күргән рус гаскәренең күңеленә бик зур курку төште. Ханның янында үзенә ияреп, бергә килгән өч мең чамасы гаскәренең бер меңендә генә корал, сугыш кирәк-ярагы бар иде. Башкалары балта, күсәк шикелле нәрсәләр белән русларга каршы сугышка керергә хәзер булдылар. Хан шулкадәр

[1] Рәһен – залог.

гаскәре белән тәкбир әйтеп, «бисмилла» дип һөҗүм иткәндә, рус гаскәренең йөрәгенә электән үк татардан курку урнашып калганлыктан, 41 мең гаскәрләре бу кадәр аз санлы татарларга каршы тора алмастан, тәмам җиңелеп качып, күбесе татарларның көчле һөҗүмнәреннән, калганнары ачлыктан, суыктан кырылып һәлак булдылар. Хәтта гаскәр башлыклары да су буендагы яр астына качып кына котылып калдылар. Олуг Мөхәммәд хан бу җиңүе белән зурланмады. Халкы азлыгын бик чынлап хәтеренә алып, корыдан әйләнеп килеп Идел суын кичеп, борынгы Болгар илендә Бату нәселе хөкемдарлыгына буйсынып, соңыннан җимерелгән Казанга килгәч, шул тирәдәге мөселманнар, хан килүеннән бик шатланып, безне Россия җәфасыннан сакла дип, үзләренең тулы рәвештә буйсынуларын белдерделәр. Хан Казан хәрабәсенә якын бер җирдә агачтан бер крепость бина кылып, шунда урнашты. Бу хәбәр тирә-якка таралып, Урда, Хаҗитархан, Азов, Кырым һәм башка мәмләкәтләрдән халык җыелып, шул заманда Казан ханлыгы куәтләнә, Алтын Урда дәүләте акрын-акрын көчсезләнә башлады. Бу вакыйга сигез йөз кырыгынчы (1436) һиҗри елда булды. Шуннан соң кырык өченче елда Олуг Мөхәммәд хан, Нижнийга барып, Россия өстенә гаскәр тартты. Хәзиран руминең[1] өченче көнендә Мәскәү астына барып җитте. Россия хөкемдары Василий, Мәскәүдән качып чыгып, Иделдән үтеп, Логор тарафына китте. Хан, Мәскәүне ун көн чолгап торып, крепостьтан тышта булган олы бер бистәсен яндырып, талап, әсирләр алып, Россияне бик зур куркуга салып, сугыш чыгымнарын түләтеп, бик күп акча алып кайтты. Кырык сигезенче елны Нижнийда кышлап, январь аенда Муром шәһәре өстенә сәфәр кылды. Ләкин Россия хөкемдарының күп гаскәр белән каршы килүен ишетеп, Нижнийга кире кайтты. Икенче елның язында Мәхмүд һәм Ягъкуб исемле ике углын гаскәр башлыгы итеп, Россия өстенә гаскәр күндерде. Россия хөкемдары күп гаскәр белән каршы килеп, Ефимов чиркәве янында тәммүз

[1] Хәзиран руми – хәзергечә июнь аена туры килә.

руминең[1] җиденче көнендә бик зур сугыш булып, мөселманнар тәмам җиңеп, Россия хөкемдары Василийны әсир итеп, Нижнийга Олуг Мөхәммәд хан алдына алып кайттылар. Хан үзе шул сигез йөз кырык тугызынчы (1445–1446) елның 25 августында барлык гаиләсе – өй эче һәм дәүләт кешеләре белән Кормыш шәһәренә күчте. Хан хәзрәтләре, әсир булган хөкемдарны мәңгелек тоткын итеп, Мәскәү мәмләкәтен Казанга буйсындырып, җиңелү салымы түләү шарты белән аның агасының углы Шемяка дигән кешегә тапшыру турында киңәш итеп торганда, Галибәк исемле кешенең Казан шәһәрен яулап алу хәбәре алынгач, бу мәсьәлә өстендә озак уйлап торырлык вакыт калмаганлыктан, берникадәр шартлар, вәгъдәләр һәм җиңелү салымы түләп тору шарты белән хөкемдарны азат итеп, Мәскәүгә кайтарып җибәрде.

Ул вакыттан соң Олуг Мөхәммәд хан хәленнән һичбер нәрсә мәгълүм түгел. Кормышта үлдеме яки берәүнең хыянәте аркасында һәлак булдымы, һичнәрсә мәгълүм булмады.

Бер сүзгә караганда: «Олуг Мөхәммәд хан, Сарай шәһәреннән куылып чыгарылганнан соң, Казанга килмәстән, Нижнийда һәм Кормышта торып калган, имеш. Кырык тугызынчы елда углы Мәхмүд хан Кормыштан килеп сугышып, Галибәкне үтереп, Казанны алып, үзе Казанда торып калып, Казан ханлыгына шулвакытта нигез салынды», – диләр. Икенче бер сүзгә караганда: «Олуг Мөхәммәд хан Мәскәүне чолгап алып торганнан соң, Казанга кайткач, аны углы Мәхмүд хан, кече углы Йосыф белән бергә үтереп, үзе хан булгач, ике туганы Касыйм белән Ягъкуб аннан качып киттеләр», – диләр.

Болгар Һәм Казан җимерелгәннән соң, Галибәк дигән кеше Казанга килеп кереп, мөстәкыйльлек игълан итмәстән генә, хөкүмәт төзи башлаган булып, Олуг Мөхәммәд хан килгәч, ханга буйсынып, хан шунда бер крепость бина кылып, аны ныгытканнан соң, Галибәкне шунда хаким итеп калдырып, үзе Нижнийга китеп, Олуг Мөхәммәд ханнан соң углы Мәхмүд хан Казанга кермәкче булганда, Галибәк каршылык күрсәткәч, Мәхмүд хан шәһәрне

[1] Тәммүз руми – июль ае.

сугышып алып, үзе Казанда торып калган булса кирәк. Шулай булганда, ике сүз дә бер фикергә җыелып, дөреслек табылган булыр.

Аннан соң – углы Мәхмүд хан. Казанда төзелгән яңа дәүләтнең икенче патшасы Мәхмүд хан бине Мөхәммәд ханның патшалыгы заманында күрше патшалар белән нинди мөнәсәбәттә булуы, нинди эшләр кылуы, нинди чаралар үткәрүе мәгълүм түгел. Россиялеләр белән сугышу вакыйгалары да күренми. Шаһзадәлек вакытында россиялеләргә берничә мәртәбә «әдәп» биргәннән соң, тынычланып калган булса кирәк. Сигез йөз илле бишенче (1451) елда җиде йөз кешесе белән Устюг крепостен чолгап алып, салым түләтү шарты белән солых ясап кайттылар. Шуның соңында Муром һәм Владимир тарафларына барып талап кайттылар.

Мәхмүд хан гасырында солтан Мөхәммәд бине Морад әл-Госмани, сигез йөз илле җиденче (1453) елда Рум кайсары кулыннан Константиния[1] шәһәрен яулап алып, «Фатих»[2] кушаматын алды һәм шәһәрне яулап алуның тарихы шуннан башланды. Бу эш Мисырда Габбасия хәлифәләренең соңгысы булган әл-Каим би Әмриллә Әбү әл-Бәка Хәмзә бине Мөхәммәд бине Сөләйман бине Әхмәд әл-Габбаси хәлифәлеге вакытында иде. Мәхмүд хан сигез йөз алтмыш сигезенче (1463–1464) ел һиҗридә вафат булды.

Аннан соң – углы Хәлил хан бине Мәхмүд хан. Атасыннан соң Казан тәхетенә утырып хан булды, ләкин сигез йөз җитмеш икенче (1467–1468) елда туганы Ибраһим тарафыннан җиңелеп, патшалык вакыты аз булганлыктан, аның турында язылган хәбәрләр табылмады.

Аннан соң – кардәше Ибраһим хан бине Мәхмүд хан. Борадәреннән соң Казан тәхетенә утырды. «Атасының туганы Касыйм хан бине Мөхәммәд ханның үги углы иде», – диләр. Гасырында Казан түрәләреннән Габделмөэмин бәк исемле кеше, берничә бәкләр белән берләшеп, дөрес ният белән яки алдапмы, Ибраһим хан өстеннән яшерен шикаять кылып, Россия мәмләкә-

---

[1] Константиния – Истанбул шәһәре.

[2] Фатих – «ачучы» мәгънәсендә. Берәр шәһәр яки илне яулап алучыларга шул исем бирелә иде.

тендәге Касыйм ханны үзләренә ханлыкка чакырдылар. Касыйм хан бу хәбәрне алып, шатланып, үзенә буйсынган татарлардан гаскәр ясап, Россия хөкемдары Иван бине Василий да ярдәм итү юлы белән күп гаскәр кушып, сигез йөз җитмеш өченче (1468–1469) елның сәфәр аенда унынчы әйлүл[1] румида Касыйм хан Казан өстенә юнәлә. Тау ягына килеп, Зөя шәһәре тирәсенә якынлашкан вакытларында, Ибраһим хан гаскәр белән чыгып, Идел буенда көтеп ятып, Россия гаскәрләре кайсы җирдән үтәргә теләсәләр, Казан гаскәре шуннан ук мылтык белән каршы торганлыктан, үтәргә мөмкинлек булмады. Икенче бер сүзгә караганда, алар Иделнең икенче ягына чыгып, руслар белән сугышмакчы булганнар, ләкин россиялеләрнеж кәминдә[2] яшеренеп торуларыннан хәбәрдар булып, бик тиз көймәләренә утырып, бирге якка кайттылар. Русларның бу сәфәрләре үзләре өчен бәхетсез, файдасыз булды. Ул ел көз бик салкын килеп, явым күп булганлыктан, күчеп йөрүләр руслар өчен бик мәшәкатьле булып, азыклары бетеп, атлары ачлыктан кырылып, русларның ит ашамый торган айлары булса да, гаҗиз калганлыктан үлгән атларының итләрен ашарга мәҗбүр булып, һәлаклектән коралларын, сугыш кирәк-яракларын ташлап киттеләр. Бу вакыйгадан бер-ике ел үткәч, Россия гаскәре, тагын килеп, Казанга буйсынган чирмешләрне талап китте. Ибраһим хан унтугыз ел патша булып утырды.

Аннан соң – углы Илһам хан. Аның анасы Суфия исемле хатын иде. Зөя буенда Россия гаскәре белән сугышып, җиңелеп качып кайтып Казан шәһәре капкасына килгәндә, капканы ачып өлгертә алмаганлыктан, руслар килеп җитеп, Казанга кереп, ханның үзен, ир туганын, анасын һәм хатынын әсир итеп алып китәләр дә Вологда шәһәренә илтеп куялар. Үзе һәм анасы шунда үләләр. Илһам хан 9 ел хан булып тора. Бу вакыйга русларның Казанга икенче мәртәбә керүләре була. Кайбер мәҗмугаларда шул гасырда Гали хан дигән бер кеше күренә. Икесе бер кешеме, яки башкамы?

---

[1] Әйлүл – сентябрь.

[2] Кәмин – яшеренеп тора торган урын, засада.

Аннан соң – кардәше Мөхәммәдәмин хан, «Иҗем хан» дип тә йөртелә. Үзе әсирлектә вакытта, үлгән агасы Гали ханның хатынына – җиңгәсенә өйләнә. Ул хатын гайрәтле, эшлекле хатын булганлыктан, ханны руслардан үч алырга кыздырды һәм байтак кына русларның каннарын түгәргә сәбәп булды. Ике тапкыр хан булды. Беренче тапкыр тугыз ел хан булып торганнан соң, төрле вакыйгалар сәбәпле ханлыгыннан читкә кагылып, Ногай урдасыннан Мамык хан дигән кешене китереп хан итеп куйдылар. Ул бер ел кадәр хан булып торганнан соң, Габделләтыйф хан бине Ибраһим хан тәхеткә утырып, биш ел кадәр патша булып утыргач, янә Мөхәммәдәмин хан кайтарылды. Бусында татарлардан кырык биш, ногайлардан егерме, барысы 65 мең атлы гаскәр белән Россия өстенә барып, Дон елгасы буенда руслар белән бик каты сугышып, күп ганимәт һәм әсирләр алып кайттылар. Бу нәүбәтендә унҗиде ел патшалык кылды.

Габделләтыйф һәм Мөхәммәдәмин ханнарның аналары Нурсолтан бикем Тимер кызына, Ибраһим хан үлгәч, Кырымлы Миңлегәрәй хан өйләнде. Болардан Сәхибгәрәй хан дөньяга килде.

Үзбәкия ханнарыннан «Шаһбәхет хан» дип даны таралган Мөхәммәд бине Шаһбидаг бине Әбү әл-Хәер хан әш-Шәйбани, ягъни мәшһүр Шәйбани хан Мөхәммәдәмин ханга үзенең мәшһүр җырчыларыннан Голям Шади Гудине җибәрүе Бабурнамәдә әйтелеп үткән. Үлем авыруында үзеннән соң бертуган кардәше Сәхибгәрәй ханны Кырымнан китереп хан итеп куярга васыять кылды. Тугыз йөз егерменче (1515) ел ахырында үлде.

Аннан соң – кардәше Сәхибгәрәй хан бине Миңлегәрәй хан бине Хаҗигәрәй хан әл-Кырыми. Мөхәммәдәмин хан үлгәч, Россия яклы Шаһгали хан бине Аллаһияр Кирмәннән[1] килеп, бераз вакыт ханлык дәгъва кылса да, Казан халкы риза булмыйча, Кырымнан хан сорадылар, шул арада, ягъни тугыз йөз егерменче (1515) елда Кырым ханы Миңлегәрәй хан бине Хаҗигәрәй үлеп, углы Мөхәммәдгәрәй хан Кырымда хан булып,

[1] Кирмән – Касыйм шәһәре.

борадәре Сәхибгәрәй ханны төрмәгә утырткан иде. Казаннан хәбәр килгәч, төрмәдән чыгарып, Казан ханлыгына җибәрде. Шулвакыт Казан Кырымга бәйләнешле, Кырым Төркия дәүләтенә буйсынган булганлыкларыннан, Казан мәмләкәтендә дә хөтбәләр Төркия солтаннары исеменә укыла иде. Шул сәбәптән булса кирәк, борынгы карчыклар кулындагы китапларда язылган хөтбәләрдә Төркия солтаннары макталып телгә алыналар.

Сәхибгәрәй хан дүрт ел Казанда патша булып, төрле җәнҗәл, бер-берсенә каршылык һәм дәүләт эшендәге башбаштаклыкларга түзә алмастан, борадәренең углы Сафагәрәй бине Мөхәммәдгәрәй бине Миңлегәрәйне үзенең урынына хан итеп куеп, үзе хаҗга бару сылтавы белән чыгып китеп, Истанбулда солтан Сөләйман бине Сәлим әл-Госмани хезмәтендә булды. Бераз вакыттан соң, ягъни тугыз йөз утызынчы (1523–1524) елда рабигыль-әүвәл аенда Кырым өлкәсенә хан итеп җибәрелде.

«Гөлбән ханан» иясе болай ди: «Тугыз йөз егерменче (1514–1515) тарихында Казан ханы Иҗем ханның[1] баласы калмаганга, ул үлгәч, ил халкы Чыңгыз нәселеннән бер солтан куелсын иде дип сораганга, әлеге Сәхибгәрәй Казан хакиме булган иде. Биш ел чамасы хан булып торганнан соң, урынына борадәренең углы Сафагәрәйне куеп, хаҗга бару хәйләсе белән Рум иленә китте». Кырымда хан булып торган вакытта, Мәскәүдәге Россия шаһзадәләреннән берәү ярдәм сорап килгәч, аның белән бергә Мәскәүгә каршы сугышу исәбе белән юлга чыкты. Бер су буена килеп җиткәч, гаскәрендәге кайберәүләрнең хыянәт итәргә теләүләрен сизеп, суны үтмичә кире кайтты. Хаҗитархан шәһәрендәге Ак Кибәк ханны үтереп, аның урынына Ямгырчы хан утырган хәбәрне ишетеп, гаскәре белән Хаҗитарханга һөҗүм итеп, Ямгырчы ханны үтерде. Тугыз йөз илле алтынчы (1549) елда дошманнан хәвеф-хәтәрсез, тыныч кына утырган бер көнендә, Казан шәһәреннән хат белән бер кеше килде һәм Казан бикләренең хатларын тапшырды. Хатның эчендә:

---

[1] Иҗем хан – Ибраһим хан.

«Кардәшеңез Сафагәрәй хан вафат булып, бишектә бер углы калды. Кулыбызга алып тордык. Кяферләр, ханыбызның вафатын белеп, өстебезгә чиксез күп гаскәр җибәрде. Ходаның ярдәме белән сезнең дәүләтегездә кяферләрне кырып качырдык, әмма кяфер тагын килер, диләр. Инде баш китәчәк, аяк җайда. Шуның өчен үтенәбез ки, ханыбызның углы Бүләкгәрәйне безгә хан кылып җибәрсәгез иде», – дип язылган иде.

Сәхибгәрәй хан ханзадәнең[1] яшь бала һәм әле камил кеше булып җитешмәгәнлектән, борадәрзадәсе Дәүләтгәрәйне моңа яраклы күреп, солтан Сөләйман әл-Госман хәзрәтләренә гариза күндерде. Дәүләтгәрәй бине Мөбарәкгәрәй ул вакытта Истанбулда иде. Пашалар Сәхибгәрәй хан Дәүләтгәрәйнең Кырым өлкәсенә хан булуыннан куркып, аны солтан яныннан ерагракка җибәрергә уйлый дип яла ягып күрсәттеләр. Солтанга бу фикер ошады һәм Казанга җибәрү сылтавы белән Дәүләтгәрәйне Кырымга хан итеп җибәрде. Шул вакыйга эчендә Сәхибгәрәй хан һәлак булды. Шулай ук тугыз йөз илле сигезенче (1551–1552) елда Казан ханлыгы да билгесез бер хәлдә калды. Солтан Сөләйманның бу эше аның бик зур хатасы булып санала. Соңыннан аның яман нәтиҗәсе күренде. «Гөлбән ханан» иясе әйтә: «Нурлы күге астында бәхетле тормыш белән яшәп килә торган бер дәүләтне җимерелү, бетүгә якын дип сөйләүче Мирмиран паша белән араларына салкынлык төшеп, әлеге пашаның ялган ялалар кушып гариза бирүе нәтиҗәсендә, дәүләтнең дусларының күңелләре бераз үзгәреп киткән арада, Казан ханы Сафагәрәй үлеп китә. Казан халкы аның Кырымдагы углы Бүләкгәрәйне Казан ханлыгына сораган булсалар да, бәгъзе сәбәпләр белән Бүләкгәрәй тоткынлыкта булганлыктан, Дәүләтгәрәйнең Казанга хан итеп җибәрелүе кирәклеге турында Сәхибгәрәй хан гариза бирде, ләкин аның каршылары булган кайбер өлкәннәр, аның теләге Дәүләтгәрәйне солтаннан ераклаштыру яки үтерү дигән хәбәрне солтанга ишеттерүләре һәм Мирмиранның шул хәбәрне раславы

[1] Ханзадә – хан углы.

нәтиҗәсендә, Сәхибгәрәй ханның үтенечен кабул иткән булып, ләкин яшерен рәвештә Сәхибгәрәй ханны үтерү, аны дөньядан югалту вазифасын йөкләп, Дәүләтгәрәйне Кырымга җибәрәләр. Шулай итеп, югарыда әйтелгән Бүләкгәрәй сәбәпле, Сәхибгәрәй һәм аның балалары юк ителәләр.

Бакчасарайда, хан сарае янындагы Җамигъ шәрифне[1] бина кылудан башка, йөз җитмеш җирдә зур һәм кечкенә мәчетләр, мәдрәсәләр бина кылдырып, дөньяда исемен яхшылык белән калдырды. Дөньяда илле ел яшәде. Алты елга, ягъни Җам, Җаек, Идел, Кубан, Дон һәм Үзи елгалары буенда күчмә хәлдә яшәгән татарларны Кырымга кертеп, аларга җирләр бүлеп биреп, рәхәт тормыш багышлаган кызыл һәм күк төстә язылган милекнамәләр[2] бүләк иткән».

Аннан соң – кардәшенең углы Сафагәрәй хан бине Мәхмүдгәрәй бине Миңлегәрәй хан. Сәхибгәрәй хан Казан ханлыгын ташлап киткәннән соң, ул куеп калдырган Сафагәрәй хан җиде ел хөкем сөрде. Җиде елдан соң тәхеттән төшерелеп, Россиянең ярдәме белән Җангали хан бине Аллаһияр бине Бәхтияр бине Якут бине Мөхәммәд хан Казанны яулап алды. Үзе дүрт ел хан булып торгач, халык аны куып җибәрде, ахырында Мәскәүдә үтерелде. Сафагәрәй яңадан урынына кайтып, унбер ел патшалык иткәннән соң, тагын русларның ярдәме белән Шаһгали хан Казанга килеп керсә дә, бер ай эчендә Сафагәрәй хан, тагын Казанга кайтып, Шаһгали ханны куып җибәрә һәм үзе өченче мәртәбә тәхеткә утырып, өч ел чамасы ханлык иткәч, тугыз йөз илле алтынчы (1549) елда Казанда үлде.

Җәнаби тарихында әйтә: «Ул ханнарның олыларыннан, усалракларыннан иде. 27 ел патша булып торды. Аның заманында патшалык бакчалары рәхәт, мәмләкәте төзек иде. Үлгәч, аның урынына углы Димешгәрәй[3] калды. Ул бер ел чамасы патша булып утырды. Аның вакытында кяферләр, Казанга

---

[1] Зур мәчетне.

[2] Милекнамә – җир биләү өчен документ.

[3] Үтәмешгәрәй.

нәфесләрен сузып, һаман якынлаша килделәр, һәм Шөгъләгәрәй заманында аны яулап алдылар», – ди.

Аннан соң – углы Үтәмешгәрәй хан. Атасы үлгәннән соң хан исеме бирелеп, анасы карамагында булды. Яшь бала иде. Анасы Сөембикә бинте Йосыф бине Муса Сарайчыктагы Йосыф мирза кызы, диләр. Хәзерге татар теленде «Хан мәчете» дип даны таралган Казан крепосте эчендәге манара шул Сөембикә манарасы була. Руслар аны, көчләп, Шаһгалигә хатынлыкка бирделәр һәм Шаһгалине Казанга хан итеп ел ярым торгыздылар. Казанга өч тапкыр хан булып килсә дә, урнашып кала алмады. Бәла-каза китерерлек нәрсәне татар теленде «Шаһгали каргаган» диләр.

Аннан соң – Ядкяр хан бине Касыйм хан бине Сәед Әхмәд хан бине Әхмәд бине Кече Мөхәммәд хан әл-Әстерхани. Казан халкы Хаҗитархан шәһәреннән сорап китерделәр. Россия гаскәре Шаһгали юлдашлыгы белән Казанга һөҗүм итеп, Казан татарлары җиңелеп, Ядкяр хан качкач, ике бистә арасында тотып алганнар. Унтугыз яшьлек егет икән. Ислам динен ташлаган дигән сүз бар. Чар өязендә[1], Ашыт елгасының төньягында Иске Өҗем авылы басуында зиярәт итеп йөрелә торган бер кабер бар. Анда болай язылган:

«Тарих тукыз йөз кырык җидедә (1551) Байморза Даим углы Ядкяр кяфер кулыннан шәһит булды». Күршесендә тагын бер кабер бар. Авыл халкы икесен дә «шәһитләр кабере» дип йөртә; бу каберләр авылдан бер ярым чакрым кадәр җирдә. Дөреслеген Хода белә, монда әйтелгән шул Ядкяр хан булыр микән?

Сәед Мостафа бине Әхмәд әл-Хөсәйни әл-Хәнәфи әл-Җәнаби «Төхфәтел-әдиб вә һәдиятел-әриб» дигән китабында әйтә: «Казан шәһәрен руслар яулап алганнан соң, Кырымнан Сәхибгәрәй хан солтан Сөләйман әл-Госмани хәзрәтләренә язды:

«Кяферләр Казанны яулап алдылар, безгә һәм солтан хәзрәтләренә мөселманнарны бу бәладан коткару лязим. Безгә энем-

[1] Чар өязе – элекке Казан губернасының Царёво-Кокшайск өязе. Бүгенге Йошкар-Ола шәһәре.

нең углы Дәүләтгәрәй бине Мөбарәк солтан бине Миңлегәрәй ханны җибәрегез, без аны, күп гаскәр белән Казанга җибәреп, кяферләр кулыннан коткарырбыз һәм шул шәһәргә хан итеп калдырырбыз», – диде. Ләкин Дәүләтгәрәй Кырымга хан итеп җибәрелде, Казан рус хөкүмәте астында калды. Җәнабинең Шаһгали ханны «Шөгъләгәрәй хан» дип атап, Россия Казанны аның кулыннан алды диюе һәм Үтәмешгәрәйне «Димешгәрәй» дип атавы дөрес түгел. Шаһгали хан исемендә «Гәрәй» юк, Россия Казанны иң ахырда Ядкяр хан кулыннан алды, Шаһгали үзе Россия тарафыннан килеп, Зөя шәһәрен төзеп, руслар яклы булып, Казан халкы белән күп мәртәбәләр сугышты. Казанны иң соңгы мәртәбә тугыз йөз алтмыш беренче (1554) елда октябрьнең 2 нче көнендә алдылар...[1]

«Гәрәй» сүзе Хаҗигәрәй хан бине Гыясетдин бине Таштимер бине Тулатимер һәм аларның нәселеннән килүчеләрнең исеменә теркәлгән. Аннан башка татар ханнарының һичкайсында юк. Атасы Гыясетдин «гәрәй» кабиләсе нәселеннән Дәүләтгилде суфи тәрбиясендә үскәнлектән, әлеге суфи хаҗга барып, аннан кайтышына Гыясетдиннең шушы углы дөньяга килә. Ата бигенең хаҗга баруын һәм аның кабиләсен хөрмәтләп истә тоту теләге белән, углына «Хаҗигәрәй» исемен куша. Шуннан соң дөньяга килгән барлык балалары исемнәре ахырына «Гәрәй» дигән сүзне кушуы бабаларының традициясе булып кала. Шуннан башка һичбер мәгънәсе яки матурлыгы юк.

Кайбер татарларыбыз һичбер мәгънәне, матурлык һәм ямьсезлекне аера белмәстән, ялгыз бер ишетүләренә генә таянып, яки данлыклы, зур, бай кешеләргә ияреп, балаларының исемнәренең алдына я ахырына «җан, шаһ, бик, сәед, мир, хуҗа, солтан, хан» дигән шикелле исемнәрне тагып, яки дөрес исемнәрдән берничәсен бергә теркәп, «Әхмәдгәрәй, Мөхәммәдгәрәй, Әхмәдҗан, Мирмөхәммәд, Хуҗаәхмәд, Сәедхуҗа, Әхмәдхан, Солтанмәхмүд, Солтангали, Мөхәммәдсалих,

[1] Монда бераз ялгышу бар: Казан тугыз йөз илле тугызынчы (1552) елда алынган.

Мөхәммәдьягъкуб, Мөхәммәдйосыф, Мөхәммәдкасыйм, Мөхәммәдгали, Госмангали, Мөхәммәдшакир, Мөхәммәдзакир, Бикмөхәммәд һәм Ишмөхәммәд» дип дөрес исемнәрне бозып, «Бәгыйльбәк» кебек мәгънәсез исемнәр бирәләр. Бу рәвештә исем бирү һиҗрәттән соңгы мең ел эчендә һичбер гасырда булганы юк. Шуннан соң гына Иран, Туран, Һиндстан шикелле җирләрдән күчеп кергән бер әшәкелек ул. Чөнки ислам шәригатендә исемнәрнең күркәм булулары кирәк. Исем дөрес мәгънәле һәм пәйгамбәр, сәхабәләр шикелле олы кешеләр исемнәренә ошаган Мөхәммәд, Әхмәд, Салих, Ягъкуб, Йосыф, Муса, Гайса, Гомәр, Госман, Гали, Хәсән, Хөсәен шикелле исемнәр күркәм булалар, һичберенең исеме «Мөхәммәдсалих, Мөхәммәдьягъкуб, Мөхәммәдйосыф, Мөхәммәдмуса, Мөхәммәдгайса, Мөхәммәдгосман, Мөхәммәдгали, Мөхәммәдхәсән, Мөхәммәдхөсәен» түгел. Болай исем биргәндә, дөреслек тә, матурлык та югалып, исемнәре бер буш сүз һәм төзелеш ягыннан да бозык була. Исемнәрнең мәгънә ягыннан дөреслеген бозмыйча, төрле ләкаб һәм көнияләр[1] кушу борынгылардан калган матур бер гадәт булып тора. Әгәр бу кешеләр без исемнәребезне болай төземибез, безнең исемнәребез бер генә сүздән тора, ләкин без исемебезнең алдындагы бер кисәге итеп түгел, бәлки пәйгамбәргә хөрмәт йөзеннән аның исемен кушып әйтәбез дип дәгъва кылсалар, аларга аның өчен шәригатьнең рөхсәте кирәк, ә ул рөхсәтнең булуы мөмкин түгел, бәс, шулай булгач, бу кешеләрнең дәгъвалары да дөрес түгел.

Шулай ук хатын-кызлар исемнәрендә дә «биби, бану, ханым, аем, бикә» шикелле сүзләрне исемнәренең бер кисәге итеп, «Исемең ничек?» дип сораганда: «Бибифатыйма, Бибигайшә, Мәрьямбану, Хәдичәбикә, Әсмаханым, Рабига аем», – дип җавап бирүләре бик мәгънәсез һәм урынсыз була. Бәлки, бу исемнәр хатыннарга карата «абыстай» дип, гарәпләрдә «сәйидә» дип олылап, хөрмәтләп әйтү булыр, ләкин кечкенә бер бала-

[1] Ләкаб һәм көния – «Әбү әл-Касыйм», «Әбү Гобәйдә» шикелле кушаматлар.

ның исемен сораганда, «Бибирабига», яки «Мәрьямбану» яки «Әсмабикә» дип җавап бирүе замана гореф-гадәтенчә «фәлән абыстаң» дигән мәгънәдә булып, аң-белем ияләре алдында бик ямьсез килеп чыга.

Әстерханда оешкан дәүләт турындагы бүлек

Бу Әстерхан шәһәре экватордан 47 градус 32 минут төньяк киңлектә, алтмыш биш градус кырык дүрт минут төньяк-көнчыгыш озынлыкта Идел елгасының Каспий диңгезенә койган урынына якын урнашкан. Борынгы заманда бу шәһәр, Хәзәр ханнарының башкаласы булып, «Ител» шәһәре дип аталган[1]. Соңрак Әштерхан, Хаҗитархан, Аждерһан дип йөртелә башлаган. Сәмәндәр шәһәре Сәлман бине Рабигател-Баһили тарафыннан алынгач, хаканның Ител шәһәренә чигенүе һәм башкала итеп сайлавы Мәсгуди сүзләреннән ачык билгеле.

Татарлар килеп чыккач, бу шәһәр озак вакыт алар кул астында торды. Тимер белән Туктамыш хан арасында булган сугышлар нәтиҗәсендә Алтын Урда яки Җуҗи улусы яки «Бәриятел-Бәркә» дәүләте, авыр фетнәләр сәбәпле, таркала, бөтенләй көчсезләнә. Татар шаһзадәләре һәм түрәләре арасында үзара көрәш, бүленү, аерылышу чире көчәя. Шул чакта Алтын Урдадагы бер төркем, Җуҗи нәселеннән бер шаһзадәне хан итеп, Хаҗитархан шәһәрендә кечкенә, мөстәкыйль бер дәүләт төзиләр.

Андагы мөстәкыйль татар ханнарының безгә билгеле булганнарының беренчесе – Коерчык хан бине Ырыс хан бине Бодакол бине Туйхужа. Аның жиде йөз туксан сигезенче (1396) – сигез йөзенче (1398) еллар тирәсендә хан булып торуы мәгълүм.

Аннан соң – Котлыг Тимер хан бине Гали Тимер бине Котлыг Тимер бине Тумган бине Абан бине Үзтимер бине Тукай Тимер бине Җуҗи хан.

Аннан соң – аның углы Тимер Баһадир хан. Аннан соң – аның углы Мөхәммәд хан. Аннан соң – аның онытгы Чуак хан

[1] Ител шәһәре хәзерге Әстерхан урынында булмаган, әмма аның кайда булганлыгы әлегә ачык билгеле түгел.

бине Ягъкуб бине Мөхәммәд хан. Аннан соң – аның углы Мангышлак хан. Аннан соң – Әхмәд хан бине Кечек Мөхәммәд хан бине Тимер хан. Ул, Аксак Тимер нәселеннән Хорасан падишаһы солтан Хөсәен мирза бине Байкараның кыз карендәше Бикәй-бикемгә өйләнеп, аңа кияү иде. Аннан соң аның карендәше Мәхмүд хан. Мәхмүд хан исеменә Әстерханда һәм башка урыннарда сугылган тәңкәләр бар. Ул тәңкәләрдә: «Әс-солтане әл-гадиле Мәхмүд бине Мөхәммәд бине Тимер»[1], ә кайберләрендә: «Әс-солтане әл-гадиле Мәхмүд хан бине Мөхәммәд хан бине Тимер хан»[2], – дип язылган.

Аннан соң – аның углы Касыйм хан. Ул сигез йөз җитмешенче (1465–1466) еллар тирәсендә хан булып, шул вакытларда ике туган бергә ханлык иткәннәр. Сигез йөз сиксән бишенче (1480–1481) елларда әле аның исән булуы мәгълүм. Шәйбанилардан Хәйдәр хан бине Әбү әл-Хәер хан үтерелгәч, хан булырга кеше калмау сылтавы белән, Карачин бик Шәйбәк ханны һәм туганы Мәхмүдне алып, шушы Касыйм хан янына килеп сыенган һәм шул арада Җанибәк ханнар Әстерханны чолгап алган булырлар. Аннан соң аның атасы белән бертуган кардәшенең углы Габделкәрим хан бине Әхмәд хан бине Мөхәммәд хан сигез йөз туксан бишенче (1489–1490) елдан башлап, үлгәнче – тугыз йөз унынчы (1504–1505) елгача исән иде.

Аннан соң – Әбү Сәгыйд Җанибәк хан бине Барак хан бине Коерчык хан бине Ырыс хан.

Аннан соң – аның углы Хөсәен хан тугыз йөз егерме өченче (1517) елларда бар. Аннан соң – Алык хан. Аннан соң – Касыйм хан бине Сәед Әхмәд хан бине Әхмәд хан бине Кече Мөхәммәд хан. Ул тугыз йөз утыз сигезенче (1531–1532) елда Әстерханга чиркәсләр һөҗүме вакытында үтерелде. Бу кеше – Казан ханлыгының соңгы хөкемдары, Ядкяр исемле мөртәт бәдбәхетнең атасы.

---

[1] Гадел солтан-патша Мәхмүд бине Мөхәммәд бине Тимер.

[2] Гадел солтан-патша Мәхмүд хан бине Мөхәммәд хан бине Тимер хан.

Аннан соң – тугыз йөз кырык беренче (1535) елдан тугыз йөз кырык дүртенче (1538) елгача – Габдеррәхман хан. Бу кешенең атасының исеме һәм нәсел-нәсәбе билгесез.

Аннан соң – тугыз йөз кырык дүртенче (1538) елдан тугыз йөз кырык сигезенче (1542) елгача шәех Хәйдәр хан бине шәех Әхмәд хан бине Әхмәд хан. Ул тугыз йөз кырык сигезенче (1542) елда ханлыктан төшерелеп, Ак Кибәк хан булып, аннан тугыз йөз алтмышка (1552) кадәр, икенче тапкыр куелып, тугыз йөз алтмыш дүрткә (1556) чаклы торды.

Аннан – Ак Кибәк хан бине Мортаза хан бине Әхмәд бине Кечек Мөхәммәд хан. Моны тугыз йөз кырык дүртенче (1537–1538) елда төшереп, шәех Хәйдәр бине шәех Әхмәд хан куелып, тугыз йөз кырык сигездә (1541–1542) тагын Ак Кибәк хан куелып, аны тугыз йөз кырык тугызда (1542–1543) Ямгырчы хан килеп үтерде. Аннан – Ямгырчы хан бине Бирдебәк солтан бине Мортаза хан бине Әхмәд хан. Бер хәбәргә караганда, хөкемдарлыгы тугыз йөз илле сигездән (1551) тугыз йөз алтмыш берләргә (1553) чаклы дәвам иткән. Ләкин Сәхибзадә хан язмасында: «Тугыз йөз илле алтыда (1549) Сәхибгәрәй хан, Хаҗитарханга барып, Ямгырчы ханны үтерде», – диелә. Моннан башка Хаҗигәрәй хан нәселендә Ямгырчы хан бине Хаҗигәрәй хан исемле кеше бар. Аннан – Дәрвишгали хан бине шәех Хәйдәр хан. Тугыз йөз алтмыш бердән (1553) тугыз йөз алтмыш дүрткә (1556) чаклы. Аннан – Дәүләт-бирде хан. Җуҗи улусында тагын Касыйм хан бине Тимер Котлыг хан бар. Шушы соңгы заманнарда Казахстанда Касыйм хан бине Җанибәк хан бар иде. Ямгырчы хан, Ак Кибәк ханны үтереп, хан булган иде. Моны Сәхибгәрәй хан бине Миңлегәрәй хан, Кырымнан килеп, тугыз йөз илле алтынчы (1549) елда үтерде. Дәрвишгали хан яңадан хан итеп куелды. Кырым ханнары гадәтенчә, Касбулат солтан бине Касыйм хан бине Мәхмүдне «калгай», икенче бер лөгатьтә әйтелгәнчә, «калхани», ягъни тәхет варисы кылды. Тугыз йөз алтмыш дүртләрдә (1556–1557) тагын Дәрвишгали хөкемдарлыгы күренә. Алтмыш дүртенче (1557) елда төшерелгән. Аннан – Дәүләтбирде хан тугыз йөз туксан

бердә (1583)[1]. Тугыз йөз алтмыш дүртенче һиҗридә Хаҗитархан шәһәрен Россиялеләр яулап алды. Шулай итеп, Алтын Урдада Татар дәүләте беткәч, дәүләтләре Хаҗитарханда илле биш ел дәвам итте.

Танылган зур тарихчыларның кайберләре әйтәләр: «Җуҗи нәселе Болгар шәһәрендә һәм Идел елгасы үзәнендә җәелеп хөкем сөргәндә, Россияне төрле салымнар белән йөдәтәләр, аларның эчке эшләренә катнашалар иде. Эчке таркаулык һәм төрле фетнәләр сәбәпле дәүләтләре көчсезләнгәч, Казан ханнарының да нәселе киселгәч, төп таянычлары Кырым ханлыгы булып, Кырымга буйсынган кебек, Кырым шаһзадәләре җибәрелә торган булса да, Казан ханлыгы мөстәкыйль санала иде.

Россия, бу фетнә һәм таркаулыктан файдаланып, әкрен-әкрен көч туплап, солтан Сөләйман Госмани[2] хәзрәтләренең соңгы елларында Казан, Әстерхан илләрен үз кулына алды. Кырым ханнарының моннан соң да әле кулларында күпсанлы татар атлы гаскәре булганлыктан, Мәскәү шәһәренә хәтле килеп, ул тирәләрне талап китәләр иде. Әмма сугышып алган җирләрен кулда тотарга җитәрлек көч аларда юк иде. Россия исә, татарларның бу һөҗүмнәреннән саклану өчен, аларга еллык беркадәр салым түләп, үзләре бу ике зур илне[3] кулга төшереп, мәмләкәтләрен киңәйтте.

Гәрчә Кырым ханнары россиялеләрдән ел саен бераз салым алып килсәләр дә, бу илләрне кайтарып алырга көчләре җитәрлек түгел иде. Төркия дәүләтенең ярдәме белән бу эш мөмкин булса да, Кырым ханнарының табигатьләренә үтеп кергән фетнәчелек һәм бозыклык сәбәпле, аларның Казан һәм Дәште Кыпчак тирәләрендә көчәюләре Төркия өчен файдалы саналмый һәм ил шул мәслихәт буенча идарә ителү яки башка сәбәпләр аркасында бу илләрне кайтарып алу чарасына кере-

---

[1] Бу аңлашылмый. 1554 елда Әстерхан Россия кулына кергәч, 1583 елда «хан» исемен күтәргән бу кеше Россия тарафыннан куелган берәр феодал булса кирәк.

[2] Солтан Сөләйман Госмани – Төркия патшасы.

[3] Казан һәм Әстерхан ханлыклары.

шелмәде. Россиялеләргә ул чакта бертөрле дә әһәмият бирелмичә, немецлар кулындагы өлкәләрне сугышып алуга бөтен уй-көч юнәлдерелгән иде. Хәлбуки, бу ике илне саклау Төркия өчен тагын да әһәмиятлерәк иде. Чөнки бер дәүләтнең көче арту, мәмләкәтнең киңәюе андагы төп элементларның якынлыгы һәм көченә күрә булуы табигый. Төркия дәүләте башлангыч дәверендә бер генә кабиләдән гыйбарәт иде. Сәлҗук төрекләренең таркалуы сәбәпле, Анатолия тирәсендәге барлык төрекләр шул нигез кабилә тирәсенә тупланып, бөтенесе госманлы милләтенә берләшеп, госманлы дәүләте зур куәткә ия булган һәм бу дәүләт, асылда, Төркия дәүләте булып әверелгән иде. Солтан Сәлим хәзрәтләре Гарәбстанны алганнан соң, Госманлы дәүләте гомумислам дәүләте һәм барлык мөселманнарның бу дәүләтнең состав элементы булуы лязим иде. Ләкин Исмәгыйль шаһ фетнәсе килеп чыгу сәбәпле, ислам милләте арасына зур аерылышу төшеп, Иран халкы бу төркемнән читтә калып, Рум иле белән Төркестан арасын аерып торучы булганлыктан, Төркестандагы сөнниләр бу зур төкемгә кушылудан мәхрүм калдылар. Бу хәлдә Төркия өчен иң кирәклесе – көнчыгыш һәм көнбатышта, Һиндстан өлкәләрендә хәлифәлек ягыннан үз дәүләтенең төп көче булып китәрлек куәтләрне бергә туплап, барысын да үз кул астында булдырырга тырышу иде. Бигрәк тә Кавказ халкы белән Әстерхан һәм Казан татарларын кул астына алып, җенес якынлыгы һәм күбесендә дин, мәзһәб берлеге сәбәпле, аз вакыт эчендә барысы да госманлы милләтенә әверелеп, дәүләтнең төп өлеше булачакларында шөбһә юк иде. Болай иткәндә, Кырымның да Төркия дәүләтенең бер өлкәсе хәлендә калуы табигый иде. Солтан Сәлимнең уе менә шулай иде, ләкин аның вафатыннан соң бу сәясәт ташланды. Кулдагы бөтен байлык-чаралар тыштан караганда дәүләтнең дәрәҗәсен күтәрерлек эшләргә юнәлдерелде. Чыннан да, тышкы һәм эчке политикада бик күп шанлы, мактанырлык эшләр эшләнде, күп кенә яңа илләр сугышып алынып, дәүләтнең чикләре күпкә киңәйтелде. Ләкин дәүләтнең төп элементларының бу яңа мәмләкәтләрне кулда тотарлык көче

булмаганлыктан, аз вакыт эчендә барысы кулдан китте, һәм солтан Сәлим гасырында ирешелгән чикләргә кире кайтырга мәҗбүр булынды. Әгәр ул вакыт Әстерхан һәм Казан өлкәләре турыдан-туры сакланса, һәм идарә ителеп, шулар аркылы бөек Татарстан яклары да кулга алынган булса иде, ул тирәләрдә тупланган көч белән Венгрия кебек ничә мәмләкәт алынырга һәм сакланырга мөмкин иде. Кыскасы, әгәр солтан Сәлим тарафыннан алда тотылган юл белән кителгән булса, Төркиянең көче һәм күләме бөтенләй башка булу лязим иде. Россия солтан Сөләйман гасырында эшләнгән сәяси хатадан файдаланды. Казан һәм Әстерханны кулга алып, көчәеп, акрын-акрын Госманлы дәүләтенең үз чикләренә кул сузарлык хәлгә килде. Бөек Пётр гасырына чаклы Россия хөкемдарлары мәмләкәтнең бердәмлеген ныгыту һәм үзәк властьны көчәйтү чаралары белән чикләнсәләр, ул исә Балтик диңгезенә юл ачып, Россия чикләрен Европага якынайтты, тәртипле гаскәр төзеде. Ләкин Кара диңгез һәм Азов диңгезе тирәләренә юл ачмады. Төркия белән Россия арасын аерып тора торган юлсыз һәм халыксыз җирләр бу ике мәмләкәт чикләрен аерып торды, меңбер йөз кырык өченче (1730) елда Польшада Россия тәэсиренә каршы сугыш булып, Россия бераз җир алды. Меңҗиде йөз алтмыш сигезенче – меңҗиде йөз җитмеш дүртенче елларда тагын Польшаны яклау өчен сугыш булып, «Кечек Кайнарҗа» килешүе буенча, Азов, Керчь, Колбрун крепостьлары Россиягә калдырылды. 1787 елгы сугыш соңында Ясса килешүе нигезендә, Кырым һәм аның тирәләре Россиягә кушылды.

1812 елгы сугышлардан соң, Бухарест килешүе нигезендә, Бессарабия Россиягә калдырылды, Сербиягә автономия бирелде.

1828 елгы сугыш нәтиҗәсендә Греция дәүләте төзелде, Сербия, Молдавия һәм Валахия мәмләкәтләренә автономия бирелде, Рум илендә булган христианнар Россия яклавы астында булса, меңике йөз җитмешенче (1853–1854) елгы Кырым сугышы нәтиҗәсендә бу «яклау»га Европа дәүләтләре катнашты. Бессарабиядән Төркиягә бераз җир бирелде, һәм Россия Кара диңгездә сугыш флоты тоту хокукын югалтты.

Кирмән шәһәрендә төзелгән Касыймия дәүләте турында

Ука елгасы буенда илле дүрт градус кырык тугыз минут төньяк киңлектә, илле биш градус кырык дүрт минут көнчыгыш озынлыкта Кирмән һәм Мищар крепостьлары рус телендә «Городец» дип йөртелгән. Хәзерге заманда мөселман телендә «Ханкирмән», ә рус телендә беренче хөкемдар мөселман хан Касыйм бине Мөхәммәд ханга нисбәт белән «Касимск» дип билгеле крепость-шәһәр ике йөз елдан артык вакыт эчендә кайбер татар шаһзадәләре яши торган урын булган. Хәзер дә ул өлкәдә биш мең кадәр мөселман бар. Бу ханлык, безнең татарларыбыз карашынча, Казан, Кырым, Хаҗитархан, Бохара, Харәзем, Хоканд ханлыклары кебек мөстәкыйль падишаһлык булган, диләр. Кайберләре, гәрчә мөстәкыйль ханлык булса да, Казан ханнары белән бергә, союзда булып дус яшәгән, тик соңга таба гына Кирмән ханнарының берсе аерылып, Мәскәү хөкемдары белән дуслашып, бер союзда булып Казанны килеп алып, бераз вакыт соңында россиялеләр форсат табып Кирмәнне дә алганнар, диләр. Кайберәүләр уйлавынча, Кирмән крепостенда руслардан салым алу өчен күп гаскәр белән бер бәк тора икән. Бервакыт руслар котыртып, «я, ни өчен син Казан ханына буйсынасың? Якыннарың һәм гаскәрең күп. Ник мөстәкыйль падишаһ булмыйсың? Күпме вакыттан бирле безнең белән күрше булып эш итәбез. Бер-беребездән зарар күргәнебез юк. Без салымны Казан ханына биргәнче сиңа бирик. Әгәр Казан ханы өстеңә гаскәр җибәрсә, без бар көчебез белән сиңа ярдәм итәрбез, һәрвакыт дусыңа – дус, дошманыңа дошман булырбыз», – дигәннәр. Бу котырту җиңел акыллы бәккә ошаган, үзен мөстәкыйль хан итеп игълан иткән, Казан дәүләте составыннан чыгып, аны кечерәйтеп зәгыйфьләндергән. Моннан соң Россия белән союзга кереп, Казанны алырга сәбәп булган, имеш. Моннан башка, шуңа охшашлы берничә төрле сүзләр йөри. Ләкин халык телендә йөргән бу төрле хәбәрләргә, өч-дүрт гасыр үткәч, тарих фәнендә дәлилсез ышану һәм таяну мөмкин түгел.

Бу китапны төзүче фәкыйрь әйтә: Кирмән ханнары һичбер вакытта, башка татар ханнары кебек, мөстәкыйль хан булмаганнар, анда булган хөкемдарларның барысы да «хан» дип аталмаганнар. «Хан» дип йөртелгәннәрнең күбесе, Россия мәмләкәтенә килгәнче, берәр җирдә хан булган өчен, бу исем белән аталганнар. Кайберләренә Россия мәмләкәтенә килгәннән соң бер-бер сәбәптән «хан» исеме бирелсә дә, бу бары коры исемнән гыйбарәт булып, мөстәкыйль патша икәнлегенә дәлил булырлык эшләр: үз исемнәренә акча суктыру, байрак күтәрү, герб булдыру кебекләрнең берсе дә булмаган. Алар ханлыкны варислык юлы белән алмаганнар. Мәсәлән, бер хан үлә икән, хөкүмәт аның углына яки кардәшенә варислык тәртибе буенча килмәгән. Шундагы шаһзадәләр, мөселман бәкләре һәм морзаларының һичбер ирке һәм катнашы булмаган. Күбесенчә Россия хөкемдарлары, үзләре кирәк тапканча, үлгән ханның балалары һәм якыннарын каратып тотып, бу ханга һич мөнәсәбәте булмаган, бөтенләй ят нәселдән, ә кайчакта ерак җирләрдән чакыртып китереп куйганнар. Болар ханлык тәхетенә утырганда, Россия патшасына үзләренең гаскәрләре белән ярдәм итәргә әзер торырга, аңа тулысынча буйсынырга ант итеп вәгъдә биргәннәр. Ләкин аларга, мирзаларына һәм бәкләренә яшәр өчен күп җир-су һәм урманнар бирелеп, ханнарга эчке эшләрендә беркадәр мөстәкыйльлек биреп, хәзинәче, авыл һәм шәһәр халкыннан салым җыючылар тотарга рөхсәт иткәннәр. Мәсәлән, күптән түгел әле Иран һәм Туран[1] мәмләкәтләрендә падишаһ, яхшылык итәм дип, бер кешене бер өлкәгә хаким итеп куя. Ул хаким анда падишаһның законнары, тоткан юлы нигезендә, өлкәнең керем һәм чыгымнарында һәм башка эшләрдә үз уй һәм карашлары белән эш итә. Бу Кирмән ханнарының хәлләре дә шуның кебек булган. Ул Кирмән ханнары кул астындагы җирләрдә яшәүчеләр мөселман мишәрләр һәм потка табынучы мокшылар булганлыктан, Россия христианнарының дини хисләрен борчымаган,

[1] Туран – иранлылар бу исемне төрки кабиләләр яшәгән өлкәләргә биргәннәр.

ә ханнарга үз мөселманнары арасында яшәү уңайрак булган. Әмма башка өлкәләрдә булган татар шаһзадәләренә ул кадәр ирек бирелмәгәнлектән, аларда, гомумән, «хан» дигән исем һәм мөстәкыйльлек булмаган. Яшәү өчен аларга Звенигород, Серпухов, Гурьев һәм башка өлкәләр бирелгән.

Дошманнары булган татар шаһзадәләре белән бу рәвешле эш итәргә Россия дәүләтен этәргән сәбәп шул: һиҗрәттән сигез йөз ел үткәч, Болгар мәмләкәтенә Аксак Тимер[1] килеп, аның фаҗигале фетнәсе белән ил харап ителгән һәм тапталганнан соң, шаһзадәләре арасында бердәмлек югалып, Җүҗи улусының тәртибе-законнары көннән-көн бозылып, дәүләтләрендә аерылышу, зәгыйфьләнү көчәя һәм мәмләкәт бетүгә йөз тотканда, сигез йөз кырыгынчы (1436–1437) елларда Олуг Мөхәммәд хан, Сарай шәһәреннән куылып, Казан тирәсенә килеп, яңа дәүләт төзеде. Россия патшалары, инде Сарайда татар дәүләте таркалды, татарларга кол һәм әсир булып яшәүдән котылып, тыныч-ланып, эшебезне рәткә салабыз дип торганда, яңадан мондый ханлык килеп чыгудан бик кәефсезләнделәр. Бу ханлык бервакыт татарларның борынгы көчен кайтармасын дип куркып, моны бер дә күздән яздырмыйча әһәмият биреп торганнар, бу турыда төрле чаралар күргәннәр.

Шәригатьтә падишаһлык варислык юлы белән түгел, бәлки хәлифәнең билгеләве яки халыкның гомуми сайлау һәм билгеләве белән булганлыктан, ә ул гасырда булган татар шаһзадәләре беренче бабалары Чыңгыз ханның наданлык һәм мәҗүсилек нигезендә төзелеп, «Түрәи Чынгызия» һәм «Яса» дип аталган гаскәрчелек һәм дәүләтне идарә итү турындагы канунына игътибар итмичә, һәм бу хакта бүтән бер урнашкан тәртип, канун юклыктан, һәрбер шаһзадә хан булырга теләп, төрлесе төрле юл белән үзләренә тарафдарлар җыеп, мөстәкыйль падишаһ булырга тырышканнар. Аларның кайберләре Россиядән ярдәм сорап килгәннәр, кайберләре, җаннарын коткару өчен,

[1] Мәрҗани үзе үк югарыда Аксак Тимернең Болгарга килеп җитмәгәнлеге турында язган иде.

Россиягә килеп сыенганнар. Кайберләрен россиялеләр төрле вәгъдәләр белән үзләре чакырып китергәннәр, аларны олылап, хөрмәт белән каршы алганнар, кунакчыллык күрсәткәннәр, аларга милек итеп җир, яшәр өчен, хөкүмәт итәргә өлкәләр биргәннәр. Казаннан һаман куркып торганга, Россия хөкемдарлары Казан ханы куәтенә каршы –

Миннән шелтәләүне җибәр син,
Чөнки шелтәләү дошманлаштыра;
Син мине чир-зәхмәтнең
Үзе белән дәвала, –

дигәнчә, татарлардан бер куәт төзеп, Казан ханы куәте белән көрәштерергә Россия мәмләкәте эчендә бер кечкенә, формаль төстә генә бер ханлык ясаганнар һәм анда татар шаһзадәләреннән һәрвакыт Казан ханнарына карендәш һәм хан булырга лаек һәм сәләтле, Чыңгыз нәселеннән килгән бер шаһзадәне хан итә килгәннәр. Чыннан да, бу рәвешле эш итү Россия өчен бик матур нәтиҗәләр биргән. Ул ханнар «кеше – яхшылыкның колы» дигәнчә, Россиягә һәрвакыт изге карашта булып, Россия кайсы якка юнәлсә, үз мирза, бәк, хезмәтче һәм иярченнәре белән ярдәмче һәм хезмәтче булып алдан барганнар, табигый батырлыклары аркасында төрле сугышларда Россиягә яхшы хезмәт күрсәткәннәр, татар мәмләкәтендә булган олы кешеләрне яшерен рәвештә төрлечә сатып алып, үз якларына аударырга тырышканнар. Падишаһларның дошманнары күп булганлыктан, үз ханнарыннан гайрәтләре чигеп, бу шаһзадәләр ягына күчеп, ханнарга дошман күбәеп, араларында икейөзлелек, каршылык туган. Аларның шулай ук төрле җирләрдә карендәшләре, дуслары булып, шулар аркылы руслар Казан һәм Әстерхан хәлләрен тикшереп, белеп торганнар, алар Россиягә һөҗүм итәргә уйлаганда, алдан ук белеп, тиешле саклану һәм каршы тору чараларын алдан ук кылып торганнар. Ахырдан Россия тәмам әзерләнеп җитеп, Казанны алырга уйлагач, Ханкирмән хан исемен алган һәм Казан тәхетенә утырырга лаек булган шаһзадәнең бер-ике меңкадәр генә гаскәре булса да, артыннан, аңа ияреп барган рус гаскәре шаһзадә гаскәреннән дистәләрчә артык булса

да, болар әлеге шаһзадә гаскәре саналганнар. Казан һәм Әстерхан халкы: «Бу килә торган шаһзадә үз динебездә һәм борынгы падишаһларыбыз нәселеннән. Безгә кайсы булса да хан булырга ярар, юкка җаныбызны, каныбызны әрәм итмик», – дип, гайрәт һәм батырлыклары кимеп, кирәгенчә сугышмаганнар. Әгәр Россия гаскәре үз падишаһлары исеменнән йөрсә, ул чакта Казан татарлары табигый батырлыклары һәм дини хисләре аркасында соңгы тамчы каннары калганчы сугышсалар кирәк иде һәм бу очракта Казанны алу бик читен булыр иде.

Янә Казанны алганнан соң да ничә тапкыр хөкүмәт шул шаһзадә кулына тапшырылып, аңа «хан» исеме бирелсә дә, ул моңа бик шатланып, киләчәктә аңа каршы кешеләр килеп чыгып, әүвәлге хан яки аның балаларын яклаучы, көч алып, мине кумасыннар дип куркып, үзенең урынын саклауда да шул ук Россия ярдәменә мохтаҗ булган, һәм шуңа күрә һичбер очракта, хәтта үз мәмләкәтенә зарар булганда да, Россия теләгенә каршы килмәгән, һәм хөкүмәт, асылда, Россия кулында булган. Бу хан русларга Казанны, Әстерханны алу өчен файдалы бер көч булып, аннан русларга һичбер зарар һәм куркыныч килмәгән.

Менә шул фикерләрне алда тотканда, татар шаһзадәсе хөкүмәте өчен Россия мәмләкәтенең бер ягында, аны татарлар һөҗүменнән саклап, каравыл булып тору һәм татар мәмләкәтенә керергә дә уңайлы бер урын сайларга кирәк булган. Ул гасырларда Тамбов, Пенза, Нижний өлкәләренең Ука елгасының уң ягындагы өлешләре татар гаскәрләре күп йөри торган урыннар булып, алар, күбесенчә, Рязань һәм Муром тирәләренә һөҗүм иткәнлектән, Ука суы буенда Рязань өлкәсендәге Мещар[1] крепосте бу максатка иң лаек урын итеп табылган һәм татар шаһзадәләренә бирелгән. Гәрчә әүвәлдәрәк татар кунакларына[2] төрле җирләрдә шундый урыннар бирелгән булса да, соңра аларга югарыда әйтелгән максатка иң муафыйк булган шушы крепостьны биргәннәр. Бу ике йөз ел, Россия, Казанны алып,

---

[1] Мещар – Мещерск – Касыйм шәһәренең элекке исемнәреннән берсе.

[2] Кунаклар – татар илләреннән качып килгән шаһзадәләр.

татарлардан бөтенләй тынычлангангача дәвам иткән. Ул крепостьны руслар беренче татар ханы Касыйм бине Мөхәммәдхан бине Тимерхан исеме белән атаганнар, шул исем хәзер дә йөртелә. Әмма шул тирә мөселманнары аны элек тә һәм хәзер дә «Кирмән» һәм «Ханкирмән» дип атап йөртәләр. Чыннан да, Россия хөкүмәтенең бу чаралары дөрес булып, шуның аркылы Казан һәм Әстерханда яшәүчеләр арасына таркаулык кертеп, фетнәләр тудырып, үзләрендәге Кирмән ханнары аркылы, аларны корал һәм көзге итеп, Казанда үзләренең тәэсирләрен көчәйтеп, куәтләрен арттырып, ахырда аларны бөтенләй үз кулларына алганнар, кыскасы, Россия дәүләтенең бу кадәр көч һәм берлек хасил итүенә, Казан һәм Болгар дәүләтенең бетүенә үз татарларыбыз, ә татар дәүләтенең зәгыйфьләнү һәм бүлгәләнүенә Аксак Тимернең килеп талап, үтереп йөрүе сәбәп булган. Әбү Сәгыйд Сәмәркандинең (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) «Аксак Тимернең исламга зарары Чыңгыз, Чыгтай, Хулагу кяферләрнең зарарыннан ике өлеш артык булды» дигән сүзләрен кат-кат ишеттек.

Олуг Мөхәммәд ханнан соң углы Мәхмүд хан Казан тәхетенә утырып падишаһ булгач, туганнары Касыйм белән Ягъкуб, Чиркәс җиренә китеп бер ел торгач, кире кайтып, Россиягә китәләр. Анда Россия хөкемдары Василий III нең Олуг Мөхәммәд хан кулында әсир икәнлеген белгәч, Касыймның үзендә дә хан булырга теләк туа. Шушы теләгенә ирешү өчен, Василий III белән дус булырга һәм бер-беренә ярдәм итешергә сүз бирешеп, Василийның котылуы өчен тырыша һәм аны коткара. Шуннан алар Василий янына китәләр. Мәхмүд хан атасы Мөхәммәд ханны һәм аның кече углы Йосыфны үтерде дигән сүз дөрес булганда, Мәхмүд хан бу фикерләреннән[1] хәбәрдар булып, боларның явызлыкларын булдырмау өчен атасына җинаять кылудан башка чарасы булмыйча, шул юлга баскан һәм туганнары качкан булыр. Шулвакытта Россия хөкемдары сукыр

[1] «Касыймның хан булырга теләү фикере» мәгънәсендә булса кирәк.

Василий[1] белән атасы белән бертуганның углы Шемяка арасында Мәскәүдә патша булу өчен зур дау һәм низаг булып, сигез йөз кырык җиденче (1443–1444) елда Шимаку (Шемяка) Василийны җиңеп, күзләрен сукырайтып, яшәү өчен Вологда крепостен идарә итүне тапшырган булса да, сукырлыгына карамыйча, янә көч туплап, үзенә иярген гаскәр белән Мәскәүгә Шимаку өстенә барганда, шаһзадәләр Ельня дигән урында Литовтан бара торган бер төркем Россия гаскәренә очрап, бу ике төркем бер-берсен дошман дип белеп сугышка әзерләнгәндә, сорашып чын хәлне белеп, бергәләп Василийны эзләп киттеләр, Угличта, икенче бер сүзгә караганда Ярославльдә табып очраштылар. Василий бу шаһзадәләрне шатланып каршы алды. Сигез йөз илле өченче (1449–1450) елда Сарай ханы Сәед Әхмәд хан гаскәре Россия мәмләкәте белән сугышып, талап йөргәненнән Касыйм бине Мөхәммәд хан хәбәр алып, Звенигород дигән урыннан үз татарлары белән килеп, Пухыр елгасы буенда сугышып, аларның Россиядән алган трофейларын кире кайтарды. Икенче елны зөлхиҗҗә аенда Василий үзенең дошманы Шимаку белән Углич крепостенда сугышканда, Касыйм һәм Ягъкуб үзенең иярченнәре белән аңа булышты. Шул ук елда татар гаскәр башлыгы Мәүламбирде углан исемле кешенең Россия өстенә килгәнен ишетеп, Россия хөкемдары шаһзадә Касыймны үзенең татар гаскәре, шулай ук Россиядән күп гаскәр белән җибәреп, Витлуга елгасы тирәсендә очрашып сугыштылар. Сигез йөз илле алтынчы (1451–1453) елда шаһзадә Ягъкуб, Россия хөкемдарының углы Иван белән бергә Шимакуны куып, Кукшинг һәм Даги суы тамагына бардылар. Моннан соң Ягъкуб турында һичбер хәбәр юк. Үлдеме, әллә башка берәр якка киттеме – билгесез. Шушы елларда, икенче бер хәбәргә караганда, сигез йөз җитмеш икедә (1467–1468) Россия хөкемдары Василий бине Василий шаһзадә Касыймны Кирмәнгә хан итеп куеп, Дәүләте Кирмәния төзелде. Касыйм хан Кирмән ханы булганнан соң, Казан шәһәрендә Ибраһим хан

[1] Бу кеше Россия тарихында «Василий Темный» дип йөртелә. Шуңа күрә аны Мәрҗани «Василий мәкфүф» (сукыр Василий) дип атаган булса кирәк, юкса вакыйга вакытында ул әле сукыр булмый.

патшалык иткәндә, Казанны алырга теләп, тәмам кырылып кайтып, бу сәфәр соңында озак тормыйча, сигез йөз җитмеш дүртенче (1470) ел ахырында үлеп, урынына углы шаһзадә Даниал хан булды.

Ханкирмәндә икенче хөкемдар – Даниал бине Касыйм. Сигез йөз җитмеш алтынчы (1471–1472) елда Россия хөкемдары Иван бине Василий Новгород шәһәрен алырга барганда, Даниал һәм иярченнәре аның белән бергә барды. Бу хөкемдар аларга христианнарны әсир алырга рөхсәт итмәде. Шул ук сәфәрдә Шейлонск сугышында Даниал, үз татарлары белән зур хезмәт күрсәтеп, Россия хөкемдарыннан күп бүләкләр алган. Сигез йөз җитмеш җиденче (1473) елда Сарай ханы Әхмәд хан бине Кечек Әхмәд хан Ука елгасы буендагы Алексинск шәһәренә һөҗүм кылганда, Россия гаскәрләре белән бергә иде. Сигез йөз сиксән икенче (1477–78) елда Россия хөкемдары Новгород өстенә гаскәр белән барганда, үз татарлары белән Даниал да барды. Сигез йөз сиксән сигезенче (1489) елда Антон исемле француз Мәскәүгә килеп, врачлык дәгъвасы кылып, Даниал иярченнәреннән Карахуҗа исемле бәкне дәвалап терелтәм дип азаплап үтергәч, хөкемдар ул французны Карахуҗа кешеләренә тапшырып, алар аны, Мәскәү күпере астына алып төшеп, куй бугазлаган кебек суйдылар. Моннан соң Даниал турында хәбәр юк. Аллаһ белә: шул елларда үлмәдеме икән? Сигез йөз туксан беренче (1486) елда Кирмәндә Нурдәүләт хан иде.

Өченче хөкемдар – Нурдәүләт хан. Нурдәүләт хан бине Хаҗигәрәй хан бине Гаясетдин бине Таштимер Кырыми. Кырым падишаһы Хаҗигәрәй хан сигез йөз җитмеш беренче (1466–1467) елда үлеп, углы Нурдәүләт хан Кырым тәхетенә утырып ике ел хөкүмәт иткәч, Кырым шаһзадәләре арасында низаг чыгып, Нурдәүләт урыныннан төшерелеп, туганы Хәйдәр һәм тагын берничә ханзадә бер-бер артлы тәхеткә утырып, берике айдан соң төшерелеп, бу фетнә җиде-сигез айга сузылды. Ниһаять, солтан Мөхәммәд бине Морат әл-Госмани әл-Фатих[1]

[1] Төркия патшасы.

ярдәме белән Миңлегәрәй хан бине Хаҗигәрәй хан Кырым тәхетендә ныгыгач, Нурдәүләт, углы Пирдәүләт, кардәше Хәйдәр хан сигез йөз сиксән дүртенче (1479 –1480) елның көзендә Мәскәүгә килделәр һәм Нурдәүләт хан Даниалдан соң Кирмәндә хан булды.

Дүртенче хөкемдар – Сатлыган солтан. Сатлыган солтан бине Нурдәүләт хан бине Хаҗигәрәй хан.

Бишенче хөкемдар – Җанай солтан. Җанай бине Нурдәүләт хан. Тугыз йөз ундүрт (1508–1509) елларда Кирмәндә хөкемдар булганлыгы мәгълүм.

Алтынчы хөкемдар – Аллаһияр солтан. Аллаһияр бине Бәхтияр бине Мөхәммәд хан бине Тимер хан – Сарай һәм бөтен Дәште Кыпчакның падишаһ әгъзамы Кече Мөхәммәд ханның оныгы.

Җиденче хөкемдар – Шаһгали хан. Шаһгали хан бине Аллаһъяр бине Бәхтияр бине Мөхәммәд хан. Тугыз йөз егерме икенче һиҗридә (1516) Кирмәндә хөкемдар булып, соңыннан өч тапкыр Казанда, дүрт тапкыр Кирмәндә хөкемдар булып, ахыргы тапкырларында «хан» дигән исемне алган, тугыз йөз җитмеш дүрттә (1566) шәүвәл аеның унысында Кирмәндә үлде. Хәзергә чаклы торган мәчетне Шаһгали хан салдырды. Кайбер сүзләргә караганда, ул мәчетне Касыйм хан бине Мөхәммәд хан салдырып, Шаһгали бары яңартып төзәттергән. Хыянәт кылып, Казан шәһәрен Россиягә бирде дигән хәбәр татарлар арасында таралган. Ләкин бу дөрес түгел, чөнки ул үзе Россия тарафыннан Казанны алырга килгәннәр арасында[1].

Тугызынчы хөкемдар – Саин Фулад. Саин Фулад хан бине Бикбулат бине Баһадир бине Әхмәд хан бине Мөхәммәд хан. Сарай падишаһы Әхмәд хан бине Кечек Мөхәммәд хан нәселеннән. Тугыз йөз җитмеш бишенче (1566–1567) һиҗридә тәхеткә утырып, тугыз йөз сиксән беренче (1573) елның башында

---

[1] Җиденче белән тугызынчы арасындагы хөкемдар Мәржанидә әйтелмәгән.

христианлык кабул иткәнлеге, шуннан соң тәхеттән төшерелеп сөрелгәнлеге турында сөйләнә.

Унынчы хөкемдар – Мостафа Гали хан. Мостафа Гали хан бине Габдулла бине Ак Кибәк хан бине Мортаза хан бине Әхмәд хан бине Кечек Мөхәммәд хан. Меңенче (1592) ел тулганда вафат. Бабасы Ак Кибәк хан – Әстерхан ханнарыннан. Өлкән бабалары – Сарай ханнары.

Унберенче хөкемдар – Уразмөхәммәд хан. Насыйретдин Әбү әл-Фәтех Ураз Мөхәммәд хан бине Ундан бине Шигай хан бине Ядик хан бине Җанибәк хан бине Барак хан бине Коерчык хан бине Ырыс хан бине Бадакол. Бабалары Шигай хан, Ядик хан, Җанибәк хан казах ханнарыннан. Аннан югары ханнар – Болгар һәм Сарай ханнары. Мең дә сигезенче (1600) ел зөлхиҗҗә аеның унысында егерме яшендә Кирмән тәхетенә утырып, мең дә унтугызынчы (1611) ел унтугызынчы рамазанда үлде. Атасы үлгәндә унөч яшендә иде[1].

Уникенче хөкемдар – Арслангали хан. Арслангали бине Гали хан бине Күчем хан бине Мортазагали хан бине Абак хан бине Мәхмүд хан бине Хаҗи Мөхәммәд хан бине Коерчык хан бине Ырыс хан. Атасы Гали, бабаларыннан Күчем, Мортазагали, Абак, Мәхмүд, Хаҗи Мөхәммәд – Себер ханнарыннан. Калганнары Болгар һәм Алтын Урда ханнарыннан санала. Арслангали, мең дә егерме өченче (1614–1615) һиҗридә Кирмән тәхетенә утырып, мең дә утыз алтынчы (1626–1627) елда вафат. Христианлык кабул итүе турындагы кайбер хәбәрләр ялгыш һәм бары тискәрелектән килгәнлеге күп фактлар белән раслана.

Унөченче хөкемдар – Сәед Борһан. Сәед Борһан бине Арслангали бине Гали хан. Анасы – сәедләрдән саналган Шаһкол нәселеннән Фатыйма солтан. Өч яшендә чакта «Кирмән хөкемдары» исемен алып, хөкүмәт шуның исеменнән йөртелгән. Мең дә егерме тугызынчы (1619–1620) елда тәхеткә утырган, мең дә алтмыш бишенче (1654–1655) елда христианлык кабул

---

[1] Солтан турында Кадир Гали бәк тарафыннан нәкъ шул елларда язылган «Җамиг әт-тәварих»та да бар. Вакыйга һәм даталар туры килә.

иткән, мең дә туксанынчы (1680) елда үлгән. Үлгәнче хөкүмәт аның кулында булган.

Ундүртенче хөкемдар – Фатыйма солтан. Фатыйма солтан – Ак Мөхәммәд Сәед бине Бүләк Сәед бине Шаһколның кызы, Арслангали ханның хатыны. Углы үлгәч, Кирмән мәмләкәтендә хөкүмәт кылды һәм мең дә туксан дүртенче (1683) елның ахырында үлде. Ул – мәмләкәттәге ислам һәм татар хөкемдарларының соңгысы.

Кырым дәүләте турында

Кара диңгез белән Азов диңгезе арасында 44–45 градус төньяк киңлектә, 52 градус төньяк озынлыкта булган Кырым ярымутравында төзелде.

Әүвәл Алтын Урда ханнары кул астында булып, Хаҗигәрәй хан аны бөтенләй аерып алып, мөстәкыйль дәүләт төзеде. Батый хан вакытында туганы Тукай Тимерне Кырым утравына хөкемдар итеп, үлгәч, углы Үзтимер аның урынын алып, Мәнгү Тимер хан аны үз урынында калдырды, моннан соң бер-бер артлы Мөхәммәд хан, Гыясетдин хан, Әхмәд хан исемнәрендә берничә хөкемдар булып, сигез йөзенче (1398) еллар үткәч, Хаҗигәрәй хан бине Гыясетдин бине Таштимер бине Мөхәммәд хан бине Хәсән бине Хинә бине Түләктимер бине Кәнҗек бине Рутимер бине Тукайтимер бине Җуҗи хан Кырым өлкәсендә падишаһ булды. Матур бакча иясе хөрмәтле атасы Гыясетдин солтан да дөнья буталчыкларына катнашып, атасы белән бертуган кардәшеннән Сәед Әхмәд ханның һөҗүм һәм җиңүеннән соң җиде ел качып йөреп, язмыш кушуы буенча татар дәүләте тәхетенә утырды һәм сигез йөз җитмеш беренче (1466–1467) елда кешегә «чокыр казу»ны ташлады.

Сәед Мөхәммәдриза әфәнде, «Әс-сәбгы әс-сәйяр фи әхбари фи мөлүки әт-татар» исемле китабында: «Хаҗигәрәйнең яшь вакытында хөрмәтле атасы, Олуг Мөхәммәд хан үлгәннән соң, Бәһрам казый сәясәтне бик тиз Сәед Әхмәд хан кулына бирәчәк, атасы белән бертуганның балаларыннан Гыясетдин һәм кардәше Гали бәкне ханлыкта көндәш санап юк итәчәк,

дип уйлап, ә Хаҗигәрәй һәм туганы Җанай углан аның явыз ниятеннән хәбәрдар булганлыктан качып йөреп, алты ел үткәч, бер дә кыенлык күрмичә тагын тәхеткә утырып, сигез йөз җитмеш беренче (1466–1467) елда Бакча-Сарайда үлде» дигән. Моннан соң углы Нурдәүләт хан. Моннан соң кардәше Хәйдәр хан. Моннан соң углы Килдебай хан. Моннан соң кардәше Миңлегәрәй хан. Моннан соң углы Мөхәммәдгәрәй хан. Моннан соң углы Газигәрәй хан. Моннан соң атасы белән бертуганның углы Сәгадәтгәрәй хан бине Миңлегәрәй хан. Моннан соң Исламгәрәй хан бине Мөхәммәдгәрәй хан. Моннан соң Сәхибгәрәй хан бине Миңлегәрәй хан. Элек Казанда хан булып, тугыз йөз кырык тугызынчы (1442–1443) елның рабигыль-әүвәл аенда Кырымда хан булды. Моннан соң аның кардәшенең углы Дәүләтгәрәй хан бине Мөбарәкгәрәй бине Миңлегәрәй хан. Моннан соң Мөхәммәдгәрәй хан әс-Сәмин бине Дәүләтгәрәй хан. Моннан соң, кардәше Исламгәрәй хан бине Дәүләтгәрәй хан. Моннан соң кардәше Бүдә Газигәрәй хан. Моннан соң кардәше Фәтехгәрәй хан. Моннан соң кардәше Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң Җанибәкгәрәй хан бине Мөбарәк бине Дәүләтгәрәй хан. Моннан соң Мөхәммәдгәрәй хан бине Сәгадәтгәрәй хан бине Мөхәммәдгәрәй хан әс-Сәмин. Моннан соң Гыйнияттгәрәй хан бине Газигәрәй хан, аннан соң Бүләкгәрәй хан бине Сафагәрәй хан бине Мәхмүдгәрәй, тугыз йөз илле дүрт (1547–1548). Моннан соң Әхмәдгәрәй хан бине Дәүләтгәрәй хан. Моннан соң Баһадиргәрәй хан бине Сәламәтгәрәй хан. Сугышчан Баһадиргәрәй хан исеме белән танылган. Моннан соң кардәше Мөхәммәдгәрәй хан. Моннан соң кардәше Исламгәрәй хан. Моннан соң Гадилгәрәй хан бине Чупангәрәй хан. Моннан соң Сәлимгәрәй хан бине Баһадиргәрәй хан (хаҗи). Моннан соң Морадгәрәй хан бине Мөбарәкгәрәй бине Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң Хаҗигәрәй хан бине Кырымгәрәй хан бине Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң кардәше Сәгадәтгәрәй хан (сыңар күзле). Моннан соң кардәшенең углы Сафагәрәй хан бине Нуретдин. Сафагәрәй бине Сәламәтгәрәй хан, атасы үлгәч туганга күрә, атасы белән бертуган хөрмәтле агасы, ата-

сының исемен истә калдыру өчен, аның исеме белән атады[1]. Моннан соң хаҗи Сәлимгәрәй ханның углы Дәүләтгәрәй хан. Моннан соң кардәше Газигәрәй хан. Моннан соң кардәше Каплангәрәй хан. Моннан соң кардәшенең углы Дәүләтгәрәй хан бине Гадилгәрәй бине Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң хаҗи Сәлимгәрәй ханның углы Сәгадәтгәрәй хан. Моннан соң, кардәше Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң Сәлимгәрәй хан бине Каплангәрәй хан. Моннан соң, Арслангәрәй хан бине Дәүләтгәрәй хан бине Сәлимгәрәй хан. Моннан соң Хәлимгәрәй хан бине Сәгадәтгәрәй хан бине Сәлимгәрәй хан. Моннан соң Кырымгәрәй хан бине Дәүләтгәрәй хан бине Сәлимгәрәй хан. Моннан соң Сәлимгәрәй хан бине Фәтхегәрәй хан. Моннан соң Максутгәрәй хан бине Сәламәтгәрәй хан. Моннан соң Дәүләтгәрәй хан бине Арслангәрәй хан. Моннан соң, Каплангәрәй хан бине Сәлимгәрәй хан бине Каплангәрәй хан. Моннан соң кардәше Сәхибгәрәй хан[2]. Моннан соң Шаһингәрәй хан бине Әхмәдгәрәй хан. Моннан соң кардәше Баһадиргәрәй хан. Моннан соң Шаһбазгәрәй хан бине Арслангәрәй хан. Матур чәчәкләр бакчасы иясе Хәлимгәрәй әфәнденең атасы. Моннан соң, Бәхетгәрәй хан бине Кырымгәрәй хан. Мәдәлли утравына сөргенгә җибәрелеп, мең ике йөз унбишенче (1801) елда рамазан аеның өченче атнасында илле алты яшендә вафат һәм хөрмәтле күләгәлектә күмелде. Өч ел да сигез ай хан булып торды. Бу кеше – Кырым ярымутравында татар ханнарының соңгысы. Миңлегәрәй ханнан башлап, Төркия идарәсе астында булып, аның тарафыннан куела һәм төшереләләр иде. Ахырдан Россия катнашу сәбәпле ялгыз калдырылып, шартларның таләп итүе һәм кайбер түрәләренең билгеләве буенча, Шаһингәрәй хан бине Әхмәдгәрәй хан, начармы-яхшымы, Кырымга

---

[1] Монда нәрсәдер аңлашылмый: Кырым ханнары арасында бүтән Сафагәрәй күренми. Казан ханнары арасында Сафагәрәй бар, ләкин аның Баһадиргәрәйгә кардәшлеге ачык түгел.

[2] Бу – Казан ханы Сәхибгәрәй түгел, башка кеше булырга тиеш. Чөнки, бердән, Казан ханы Сәхибгәрәйнең атасы – Миңлегәрәй. Икенчедән, бу инде XVIII гасырга карый.

хан булды. Рухи Сөләйман ага ярдәмендә Төркия солтаны тарафыннан кабул ителде, мең бер йөз туксан алтынчы (1782) елда Кырым халкы аңа каршы баш күтәргәч качып китте һәм Россия ярдәмендә яңадан урынына кайтып, мең бер йөз туксан сигезенче (1784) елда Кырым өлкәсенең бөтенләй Россия кулына төшүенә сәбәп булды. Мең ике йөз беренче (1787) елда Россиядән Төркиягә китеп, Родос утравына сөрелде һәм шул елның шәүвәл аенда утрау гаскәр башлыгының кушуы белән юк ителеп, явызлыгының җәзасын алды. Кырык ике яшендә иде. Беренче тапкыр биш ел, икенче тапкыр бер ел да өч ай хан булып торды.

Ак Урда ханнары турында

Җужи хан үлгәч, Бату хан алты йөз егерме җиденче (1229–1230) елда бабасы Чыңгыз ханның рөхсәте һәм тәкъдиме белән Җужи улусында мөстәкыйль падишаһ булып, өлкән агасы Һәрдәм, икенче исеме Әвердә Иҗен, кушаматы Бахинны Ак Урда хакиме итеп, Сыгнак шәһәрен башкала итеп билгеләп, Җәм[1], Җаек[2], Сәйхун[3] елгалары арасында күчеп йөриләр иде.

Моннан соң – углы Сартактай, аннан – углы Куйчы, аннан – углы Бәян, аннан – углы Сашибуга, аннан – углы Әбисан (җиде йөз егерменче (1320–1321) елда вафат), аннан – кардәше Мөбарәк Хужа. Җиде йөз егерме тугыз – утызынчы (1329–1330) елларда аның исеменә сугылган акчалары бар, жиде йөз кырык бишенче (1345) ел ахырына чаклы исән иде. Аннан – кардәшенең углы – Жиматай бине Әбисан, аннан – углы Жиматай, аннан – кардәше Ырыс хан, аннан – углы Туктагу хан, аннан – кардәше Тимер Мәлик хан, аннан – Насыйретдин Әбү әл-Мозаффар Туктамыш хан баһадир. Болай булганда, Ырыс хан һәм Туктамыш ханнар Һәрдәм нәселеннән

---

[1] Җәм – елга исеме.
[2] Җаек – Урал.
[3] Сәйхун – Сырдәрья.

булалар. Ләкин күпчелек тарихчылар карашынча, һәрдәмнең туганы Тукай Тимер бине Җүҗи хан нәселеннән, һәм шунысы дөресрәк булса кирәк. Шулай ук Хызыр хан h.б. Ак Урда ханнарыннан санала. Аксак Тимер Туктамышны җиңгәч, ул мәмләкәтләрне Чыгтай иленә кушты.

Дәште Кыпчакта казах ханнары

Алар, гыйлем-мәгърифәт, культура һәм утраклыктан бөтенләй читтә булып, кыргый һәм күчмә тормыш рәвешендә хакимлек итәләр иде. Башка татар дәүләтләренең күбесе шул ук рәвештә, үзләрендә булган табигый батырлыкларына горурланып, үзара көнчелек, көрәш, һәрвакыт сугыш, каршылык, үтереш, кан түгү, талау, шәһәрләрне харап итү белән яшәп, берләшү, бер бөтен коллектив булып яшәү мөмкинлеген юкка чыгарып, дәүләтләренең бетүенә, башкалар кул астына төшүләренә сәбәп булдылар. Аллаh – варисларның изгесе. Казах ханнары – Барык хан бине Коерчык хан бине Ырыс хан балалары. Әхмәд хан бине Барык хан һәм кардәше Әбү Сәгыйд Җанибәк хан патша була алмый калып, үзләренең кабиләләре һәм яшь-җилбәзәкләр белән бергә, Әбү әл-Хәер ханнан куркып, башлыксыз һәм тәртипсез качып йөреп, туры килгәнне талап, ярым-ялгызларны куркытып, качкын, качып йөрүче мәгънәсендә булган «казак», ягъни «качак» дип аталдылар. Ахырдан Әбү әл-Хәер ханнан куркып, Магулстанда Чыгтай нәселеннән килгән падишаh Исәнбуга ханга сыендылар. Ул – нәсел якынлыгы хакына боларны яхшы каршы алды. Әбү әл-Хәер хан үлгәч, сигез йөз җитмеш өченче (1468–1469) ел ахырында Магулстаннан кайтып, Казахстанны алып, шунда дәүләтләрен төзеделәр. Болар Дәште Кыпчакның көнчыгыш ягында борынгы Ак Урда тирәләрендә күчеп йөреп, хөкүмәтне балаларына калдырдылар. Беренче олы һәм мөстәкыйль падишаhлары Әхмәд хан һәм углы Борындык хан иде. Борындык ханнан соң падишаhлык Җанибәк балаларына күчте. Иярченнәре күбәйгәч, Дәште Кыпчакның көнчыгыш ягындагы башкортларны куып, көнбатышка күчерделәр. Элек барысы да бер хан кул астында булсалар, ахырдан

Казахстанны өч урда, ягъни үзәккә бүлеп, Олуг йөз, Урта йөз, Кече йөз дип исемләп, һәркайсында үз хакиме була иде. Боларның беренчесе – Әхмәд хан бине Барык хан, Гидай[1] хан дип мәшһүр. Аннан – углы Борындык хан. Атасыннан соң хан исемен алды. Сарайчык шәһәрендә яшәде. Иранчы ханы Ядик хан, Касыйм хан, аталары Җанибәк хан кебек, буйсынып тордылар. Тугыз йөз унбишенче (1510–1511) елда Сибран крепостен чолгап алды. Крепость кешеләре Шәйбани ханның туганы Мәхмүд солтанны тотып, Борындык ханга тапшырдылар. Борындык Сибраннан күчеп, Утрарда Шәйбани ханны чолгап алды. Ләкин Мәхмүд хан әл-Магулинең ярдәме сәбәпле, шәйбанилар белән килешергә һәм кайтып китәргә мәҗбүр булды. Тугыз йөз унсигезенче (1512–1513) елда Ташкент шәһәрендә Сөенчек ханны чолгап алды. Тугыз йөз унтугызынчы (1513–1514) елда Әдик хан үлгәч, кардәше Касыйм хан тәмам җиңеп, бөтен илне үз кулына алып, Борындык ханның бары «падишаһ» дигән исеме генә калды. Ахырда мәмләкәттән бөтенләй куылып, ярлыланып, Сәмәркандта үлде. Аннан атасы белән бертуганның углы Касыйм хан бине Әбү Сәгыйд Җанибәк хан. Юмарт, мөрәүвәтле, һиммәтле, акыллы, дәүләтне оста идарә итүче һәм көчле иде. Бөтен Дәште Кыпчакны үз кулында тотты. Хәтта Җүҗи ханнан соң Касыйм хан кебек бөтен мәмләкәтне яулап алган падишаһ булмады, диләр. Шәйбани хан ничаклы көчле, олы падишаһ булса да, Касыйм ханга каршы тора алудан гаҗиз иде. Ахырда Касыйм ханнан куркуыннан Исмәгыйль әс-Сәфәви гаскәре кулына төшеп үтерелде. Касыйм хан тугыз йөз утызынчы (1524) елда Сарайчыкта үлде. Аннан – углы Хакназар хан. Аннан – кардәше Мамаш хан. Аннан – атасы белән бертуганның кардәше Таһир хан бине Ядик хан. Аның заманында мангыт кабиләсе җиңеп, казах дәүләте зәгыйфьләнде, Магулстанга барып ярдәм сораса да, файдасы булмады. Аннан – углы Соламеш хан. Аннан – атасы белән бертуганның углы Тугым хан. Тугыз йөз кырык бишенче (1539) ел ахырында бөтен ияр-

[1] Гидай – юаш.

ченнәре бары егерме мең калды. Аннан – кардәше Буйдаш хан, Магулстанга барып, көч белән өч мең кеше туплады, Дәрвиш хан бине Барык хан белән сугышта үтерелде. Аннан – атасы белән бертуганның углы Шыгай хан. Батыр һәм җиңүче хан иде. Тугыз йөз сиксән сигезенче (1580–81) елда үлде, Көмеш богауда[1] күмелде. Аннан – углы Тәвәккел хан. Габдулла хан гаскәрен җиңеп, Сәмәрканд һәм гомум Төркестанның күп шәһәрләрен сугышып алып, соңыннан Бохарага килеп, Пирмөхәммәд ханны чолгап алды. Сугышта яраланып, кире кайтты һәм мең дә җиденче (1598–1599) елның ахырында үлде. Аннан – кардәше Ишем хан. Мең дә илленче ел чигендә Ташкентта Торсын ханны үтереп, милкен алды. Аннан – углы Җиһангир хан. Бөтен Казахстанны үз кулына алды. Аннан – углы Тәүкә хан. Моның чорында Казахстан үзенең иң югары дәрәҗәсенә күтәрелде. Казахстанны өчкә бүлеп, һәркайсына бер хаким куеп, Тәүкә хан тапшыруы буенча идарә итә иделәр. Олуг йөздә – Түлә-би, Урта йөздә – Кузы-би, Кече йөздә – Әйтә-би хаким булдылар. Мең бер йөз егерме тугызынчы (1716–1717) елда үлде. Аннан – Түлә хан. Мең бер йөз сиксәненче (1776) елда исән иде. Аннан соң һәрбер йөздә аерым ханнар властька килеп, бүлгәләнеп, зәгыйфьләнеп, ханнарның дәрәҗәсе төшеп, ахырда Россия составына керделәр. Ләкин Олуг йөзнең бер төркеме хәзер дә Кытай кул астында[2].

Аннан – Юлбарс хан бине ... Аннан – Иргали хан бине Әбү әл-Хәер хан, бине Ачә, бине Айрыш, бине Айчуак бине Бүләкәй, бине Үсәк бине Әбү Сәгыйд Жанибәк хан мең ике йөз биштән (1790) мең ике йөз тугызга (1794–1795) чаклы бар. Аннан Ишем хан мең ике йөз ун-унике (1797–1798) дә бар иде.

---

[1] (Конд) – «богау» мәгънәсендә килә. «Кәнд» сүзенең шәһәр (авыл) «тирә» дигән мәгънәсе дә булса кирәк. Мәсәлән, «Ташкәнд» – «таш шәһәр» дигән сүз. Бу чакта инде «көмеш» шәһәре (я авылы) тирәсендә мәгънәсендә була. Ләкин сүзлекләрдән «кәнд» сүзенең бу мәгънәсен тапмадык. Мәүла Колыйда бу сүз ике төрле: кенд һәм көннәт. «Көннәт» сүзе – «тирә, тирә-як» мәгънәсендә килүе бар.

[2] Сүз XIX йөзнең соңгы чиреге турында.

Әмма Урта йөздә Калып хан мең бер йөз утызда (1717–1718) бар иде. Аннан – Шәмәкә хан мең бер йөз кырык сигездә (1735–1736) бар иде. Аннан – Әбү Мөхәммәд хан бине Фулад хан бине Тәүкә хан. Аннан – Аблай хан... Аннан – Айхужа хан бине Әбү Мөхәммәд хан мең ике йөз дүртенче (1789–1790) елда бар иде. Әмма Кече йөздә Гаип хан бине Кирәй солтан бине Сардак солтан бине Ишем хан бине Шыгай хан. Әүвәлдә берничә вакыт Үргәнечтә хан булып, соңраклары Кече йөзнең кайбер кабиләләрендә иде. Аннан – углы Баһадир хан Кече йөзнең кайбер кабиләләрендә. Аннан – углы Гаип хан. Надиршаһ аны Харәземгә хан итеп билгеләп, мең бер йөз җитмеш беренче (1757–1758) елга чаклы шунда калды. Аннан – углы Әбү әл-Гази хан – Кече йөзнең кайбер кабиләләрендә. Аннан – углы Урынгази хан. Аннан Нургали хан бине Әбү әл-Хәер хан. Ул, Харәземгә һөҗүм итеп, Таһир ханны үтерде. Мең ике йөз бишенче (1790– 1791) елга чаклы исән иде, шул елда үлде. Аннан – мең ике йөз уникенче (1797–1798) елга чаклы, углы Ишем хан. Аннан – кардәше Айчуак хан. Аннан – углы Җантүрә хан. Аннан – кардәше Ширгази хан мең ике йөз егерме җиденче (1812) елдан кырыгынчы (1824–25) елгача исән иде. Аблай хан, Котлыг[1] мирза бине Тәүкил мирза һәм Бүкәй ханнарның кайберләре Мөхәммәдҗан мөфти, кайберләре башкаларның димләве белән Россия кул астына керделәр.

Әмма Бүкәй илендә: Бүкәй хан бине Нургали хан бине Әбү әл-Хәер хан бине Ачә мең ике йөз утыз сигездә (1822)

---

[1] Китапның кырыендагы мәгълүмат:

Фулад хан бине Әбү Мөхәммәд хан бине Фулад хан мең бер йөз җитмеш сигездә (1774) – Төркестанда хан. Пиргали бине Нургали хан – Төрекмәниядә хан. Арслан солтан бине Җантүрә хан мең ике йөз алтмыш алтынчы (1849) елда казах сахрасының кайбер өлешләрендә хаким иде. Хужа Әхмәд, Гадил, Чыңгыз, Каратай солтаннар – Әбү әл-Хәер хан угыллары. Мелла Юныс бине Иванай Бохарага барган җирендә яхшы файдаланды дигәннәре шушы Чыңгыз булса кирәк. (Аллаһ аңа исәнлек бирсен.) Мең ике йөз җитмешенче (1854) еллар чигендә Урта йөз казахлары, Кытай кулыннан китеп, Россия кул астына керделәр. Капал һәм Алма-Ата шәһәрләре салынды.

вафат. Аннан кардәше Шыгай хан. Аннан – кардәше Вәли хан. Аннан кардәшенең углы Җиһангир хан бине Бүкәй хан. Динле, изге, юмарт, мөрәүвәтле, галим һәм өлкәннәрне сөюче, яхшы ниятле, изге сүзне тыңлаучы иде. Мең ике йөз алтмыш беренче (1845) елда кан алдырып, йоклаганда бәйләгәне чишелеп, күп кан киткәнлектән, үзе де сизмичә үлгән һәм Бурса дигән җирдә күмелеп, дүрт ел һәм дүрт ай үткәч, мәетен Бүкәй хан урдасына күчергәндә, тәне сәламәт, черемәгән дип табылды, мелла Җабир бине Хаммат (Чаллы ягыннан) имамы, ахун һәм казыйсы иде. Аннан – кардәше Гадил хан. Аннан – кардәшенең углы Сәхибгәрәй хан бине Җиһангир Гәрәй хан. Бу – хан исеме белән аталганнарның соңгысы. Мең ике йөз алтмыш бишенче (1849) елның шәгъбан аенда үлде. Әхмәд һәм Гобәйдулла исемле туганнары әле исән.

Казах кабиләләре мең ике йөзенче (1785–1786) елларгача бөтенләй күчмә, чиксез кыргый һәм надан иделәр. Кулларына акча керсә, аны бер игътибарга алмыйча: «Акча сатам, нигә аласың», – дип, кибеткә кереп әйтеп йөри булганнар. Мал, әйбер арасындагы аерманы бер дә белмәгәнлектән, безнең татар халкында: «Казах мал танымас, сарт фәлән танымас» дигән канатлы сүз туган. Соңгы заманнарда, безнең татар халкы белән катнашып, узган-барган, качкан-посканнарны мелла итеп илләрендә саклап, азрак дин-көнне аера, әкренләп күчмәлекләрен ташлый башлап, сабак уку, намаз уку, руза тоту, хаҗга бару, зәкят бирү хөкемнәренә ригая кылу, сәүдә итү юлларына төшенә башладылар. Гәрчә алар боларга җитәрлек игътибар итмәсәләр дә, «ногай да булса, сарт та булса, үземездәй бысырман ау»[1] дигән сүзләре өстенә «инанамыз ногайләрдең мулдасына, кытып-Коръән юлдасына» дигән сүзләре мәшһүр[2].

Кышын Харәзем, Бохара һәм Төркестан тирәләренә, җәен Россия чикләренә киләләр. Аларның төп байлыклары

---

[1] Ногай булса да, сарт (үзбәк) булса да, үзебездәй мөселман.

[2] Инанабыз ногайларның укымышлыларына, китап-Коръәннән торган юлдашына.

хайванчылыктан – куй, дөя, сыер, аларның тиресе, май һәм йоннары, төлке һәм карсак тиреләре. Казах җиреннән Россия мәмләкәтенә ел саен Оренбург, Орск, Кызылъяр һ.б. шәһәрләргә дүрт миллион кадәр хайван керә иде. Алар арасында кайбер байларының биш мең куй, биш мең елкы, мең сыер, йөз атка ия булганнары бар. Гади кешеләре – ярлы. Азыклары күбесенчә, куй, ат ите, катык, сөт һәм кымыз иде. Икмәкләре юк. Үргәнеч тирәсендәге казах кабиләләре: «чекле», «дүрт», «кара», «адай», «кара милныг», «бүзәҗи», «җүдер», «кара калпак» һ.б. Бохара һәм Сәмәрканд тирәләрендәгеләре: «җүмки», «коет», «җыбас», «кыпчак», «җагалбай», кара калпакларның кайберләре һ.б. Ташкент, Фирганә, Хоканд тирәләрендәгеләре: «коңгырат», «һушан», «урта йөз», «кыргыз», «тәмә» һ.б. Тугыз йөз алтмыш дүртенче (1556) елда Җаек тирәләрен Урал казаклары алдылар. Мең җитмеш өченче (1662–1663) елда Россия тарафыннан Иркутск, шул ук елларда Тобольск шәһәр-крепостьлары төзелде. Мең ике йөз җитмешенче (1854) елда Урта йөз казахлары, Кытай кул астыннан чыгып, Россиягә кушылдылар. Капал, Алмата, моннан әз генә элек Ыргыз, Рәхим, Казалы крепостьлары төзелде.

Себер ханнары турында

Себер ханнары – Җүҗи ханның бишенче углы Шәйбан хан нәселеннән. Башкалалары хәзерге Тобольск шәһәреннән унике чакрым ераклыкта Себер, икенче төрле әйткәндә, Искер исемле крепость иде. Аларның беренчесе – Хаҗи Мөхәммәд хан бине Гали бине Биккунлы углан бине Мәнгү Тимер бине Бадакол бине Җүҗи Бука бине Шәйбан хан бине Җүҗи хан. Аннан – углы Мәхмүдәк хан. Аннан – углы Ибраһим хан; бу Абак хан дип йөртелгән. Аннан – углы Тулык Хуҗа хан. Аннан – углы Шамай хан. Аннан – углы Ураз хан. Аннан – углы Баһадир хан. Аннан – бабасы белән бертуганның углы Мортаза хан бине Ибраһим хан. Аннан – углы Күчем хан. Аның гасырында, һиҗрәттән мең дә өченче (1595) елда мәмләкәтләрен Ермак бине Тимофей исемле кеше алып, үз кулында сакларлык көче булмаганлыктан, Рос-

сиягә сатты. Моннан соң Күчем хан башкорт арасына китеп үлде. Мең дә тугызынчы (1601) елда шул тирәдәге татарлар баш күтәреп, бергәләп, углын хан күтәрделәр. Аннан – углы Гали ханга буйсынып хан күтәрсәләр дә, мәмләкәтләрен кайтарып алырга көчләре җитмәде. Аннан – кардәше Ишем хан. Мең дә унҗиденче (1609) елда исән икәнлеге мәгълүм. Ул – мәмләкәттә булган ханнарның ахыргысы.

Шәйбани ханнар турында

Батый хан бине Җуҗи хан, туганы Шәйбанны кайбер кабиләләргә башлык итеп, үз шәһәрләре, агасы Ахин хан шәһәрләре арасында җәен Ыргыз һәм Савык, Ур һәм Илектә Урал тавына хәтле һәм Җаек елгасының көнчыгыш якларында җәйләп, кышын – Араком – Караком һәм Сәйхун[1] елгасының түбәнге агымында кышларга кушты. Үзе һәм балалары бер-бер артлы, мирас юллы, патшалык иттеләр. Фулад хан үлгәч, ике углы Гарәп хан һәм Ибраһим хан хаким булып, икегә бүленсәләр дә, кайчакта дуслашып кушыла, ә кайчакта дошманлашып аерылыша иделәр. Ахыргы гасырларда Гарәп хан балалары Харәземдә, Ибраһим хан балалары Амудәрья – Сырьдәрьяның бирге яктагы өлкәләрендә падишаһлык иттеләр. Араларында, Шәйбан хан, Гобәйдулла хан, Габдулла хан кебек, зур исем казанган падишаһлар да булды.

Әүвәлгесе – Шәйбан хан бине Җуҗи хан. Аннан – углы Баһадир хан. Аннан – углы Җуҗи Бука хан. Аннан – углы Бадакол хан. Аннан – углы Мәнгү Тимер хан. Аннан – углы Фулад хан. Аннан – углы Гарәп хан. Аннан – углы Хаҗи Тули хан. Аннан – углы Тимершәех хан. Аннан – углы Ядкяр хан. Сарай падишаһы Олуг Мөхәммәд ханга каршы, аның кардәше Кече Мөхәммәд хан белән берләшеп, аңа ярдәм итеп, Олуг Мөхәммәд ханның Сарайдан чыгарылуына ярдәм итте. Аннан – углы Имәнәк хан. Аннан – кардәше Әбүләк хан. Аннан – кардәшенең углы Илбарс хан бине Бәркә бине Ядкяр хан. Атасы Бәркә солтан

[1] Сәйхун – Сырдәрья.

Хәйдар хан вакыйгасында дошманнарына ярдәм иткәнлектән, Шәйбан хан аны үтереп, Гарәп хан белән Ибраһим хан арасында дошманлык туды, кан түгелүгә сәбәп булды.

Икенче төркемнәре: Фулад хан үлгәч, кабиләләрнең бер төркеменә Ибраһим хан булды. Аннан – углы Дәүләтшәех хан. Аннан – углы Әбү әл-Хәер хан. Батыр һәм һиммәтле иде. Дәште Кыпчакта сигез йөз илле дүртенче (1450–1451) елда Мәхмүд Хуҗа хан бине Каганбәк бине Әлбәк бине Мәнгү Тимер әш-Шәйбанине үтереп, бөтен Төркестан чигенә һәм Кыпчак иленә исеме таралды. Төркестан чигеннән алып, Болгар чигенә чаклы ислам таралды. Бөтен Дәште Кыпчакка хуҗа һәм мөстәкыйль падишаһ булып, каршы килү яки баш бирмәүдә шикләнеп, Жуҗи нәселеннән күп шаһзадәләрне үтерде. Бөтен халык, Әбү әл-Хәер хан дип, тәмам куркып торды. Яше егермедән узмас борын, Харәземгә һөҗүм итеп, аны Шаһрух мирза бине Тимер кулыннан тартып алды. Сигез йөз илле сигезенчедә (1454) Сәмәрканд хөкемдары Олугбәк мирза кияве һәм туганының углы Габдулла мирза бине Ибраһим бине Шаһрухны үтереп, хатынына өйләнеп, Сәмәркандны солтан Әбү Сәгыйдкә тапшырып, зур дәүләткә ирешүенә сәбәп булды. Сигез йөз җитмеш өченче (1468–1465) елда Әбү әл-Хәер хан параличтан үлде. Аннан – углы Хәйдәр хан. Аз вакыт эчендә Барак хан бине Коерчык хан балалары, Айбак хан һәм Әхмәд хан, шулар белән бергә Бәркә солтан бине Ядкяр хан һөҗүм итеп, Әбү әл-Хәер хан дәүләте тузды.

Харәзем ханнары турында

Гарәп хан бине Фулад хан балаларыннан. Дәүләтләре тугыз йөз унбишенче (1510) ел чигендә башланды. Әүвәлгесе – Илбарс хан бине Бәркә бине Ядкяр бине Тимершәех хан. Аның кардәшенең углы Солтан Хаҗи хан бине Билбарыс. Аннан – атасының атасы белән бертуганның углы Хәсән Колый хан бине Әбүләк хан. Аннан – атасы белән бертуганның углы Сафьян хан бине Имәнәк хан. Аннан – кардәшенең углы Бужга хан. Аннан – кардәше Уаныш хан. Аннан – кардәше Кал хан.

Аннан – кардәше Агатай хан. Аннан – кардәшенең углы Юныс хан бине Сафьян. Аннан – атасы белән бертуганның углы Дусмөхәммәд хан бине Бужга хан. Аннан – атасы белән бертуганның углы Хажи Мөхәммәд хан бине Агатай хан. Бу – Хажим хан дип билгеле. Аннан – углы Гарәп хан. Аннан – углы Хәбәш хан. Аннан – кардәше Әсфәндияр хан. Аннан – кардәше Әбү әл-Гази хан. Бу – тарихчы. Аның Мангул һәм татар ханнары хакында язган тарих китабы басылган һәм билгеле[1]. Мең дә илле дүртенче (1644–1645) елда Амудәрья елгасының түбән агымындагы Арал дип аталган урыннан килеп, Харәземгә падишаһ булды. Егерме өч ел падишаһлык итеп, мең дә җитмеш дүртенче (1664) елда рамазан аенда үлде. Аннан – углы Әнүшә хан. Атасының васыяте нигезендә Харәземдә хан булып, ул төзегән китапны, үзе белгән вакыйгаларны тәфсилләп язып, мең дә җитмеш алтынчы (1665–1666) елда тәмам итте. Бераздан соң тәхеттән төшерелеп, күзләре сукырайды. Аннан – углы Үзбәк хан. Хөкүмәт башлыгы Ярмөхәммәдне Һиндстанга илче итеп җибәргәнлеге кайбер тарихларда әйтелгән. Аннан – кардәше Хужа хан. Аннан – Илбарыс хан бине Хажи Мөхәммәд. Шушы вакытларда Россия гаскәре Хивәгә килеп җитеп, ул гаскәр шул сәфәрендә бөтенләй кырылып бетте. Илбарыс хан Надиршаһның Һиндстаннан кайтуында аңа каршы килгәнгә күрә җәза кылынырга тиеш булып, Әбү әл-Фәез хан шәфәгате белән җәзадан котылса да, Бохарадан барган илче Жуйбари хужаларны үтертте. Варислары Надиршаһтан җәза бирелүен таләп итүләре сәбәпле, мең бер йөз илле сигезенче (1745) елда шәригать хөкеме буенча үтерелде. Аннан – Әбү әл-Хәер хан бине Ачә бине Ireш бине Айчуак бине Бүләкәй бине Үсек бине Жанибәк хан. Харәземдә хан булып биш көн торып, Надиршаһның гаскәр башлыгы Таһирхан бине Рөстәм бине Бәлимөхәммәд хан бине Жанмөхәммәднең килгәнен ишетеп ташлап чыкты. Ләкин углы Нургали хан, һөжүм итеп, Таһирханны үтерде. Әбү әл-Хәер хан мең бер йөз кырык өчтә (1730) Россиягә буйсынган иде.

---

[1] Әбү әл-Гази Баһадир хан – «Шәҗәрәи Төркия».

Надиршаһга язган мәгънәсез бер хатын да күрдек. Мең бер йөз алтмыш бердә (1757–1758) вафат. Аннан – Гаип хан бине Баһадир солтан бине Ишем. Надиршаһ аны Харәземгә хан итеп куеп, мең бер йөз җитмеш бергә (1757–1758) чаклы шунда калды. Аннан – кардәше Габдулла хан. Аның заманында Мангытлы Рәхим хан Харәземне алып, Габдулла хан һәм туганнарын төшереп, халыкның ризалыгы белән Тимергази ханны куеп, хөтбә һәм акчаларда Рәхим хан исеме йөртелде. Аннан – Айчуак хан бине Әбү әл-Хәер хан. Аннан – углы Җантүрә хан. Аннан – кардәше Ширгази хан. Мең ике йөз егерме җидедән (1812) мең ике йөз кырыкка (1825) чаклы Казахстанда бар иде. Әбү әл-Гази ханнан соң килгән бу ханнар фәкать исемдә генә хан булып, кулларында бертөрле дә власть юк иде. Фахишә кебек, аксөякләр сүзен сөйләп, алар теләгәнчә хөкем итеп, шул ук аксөякләр, берничә вакыт үткәч, бер ханны төшереп, Казахстанга сөреп, икенче берсен китереп, ханлык белән сату итәләр иде. Илтөзәр хан заманына чаклы эш шулай барды. Ул исә үзе исеме һәм чын мәгънәсе белән рәсми хан, берүзе мөстәкыйль падишаһ булып, Харәземдә Чыңгыз нәселеннән хан куюны тәмам бетерде.

Мавәраэннәһердә[1] Шәйбани ханнар

Чыңгыз хан Мавәраэннәһер шәһәрләрен икенче углы Чыгтай ханга билгеләп, аның балалары мирас тәртибенчә берничә буынга чаклы мөстәкыйль падишаһ булып килсәләр дә, Казан[2] Солтан ханнан соң, әмир Кызгын, ике углы Габдулла һәм әмир Хөсәен, әмир Тимер кебек көчле кешеләр килеп чыгу сәбәпле, ханнарның мөстәкыйльлекләре бетерелеп, әмир Тимер Кергән[3]

---

[1] Мавәраэннәһер – «елганың теге ягы» дигән сүз. Бу исемне гарәпләр Амудәрья елгасының Үзбәкстан, Казахстан ягына таба, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләре урнашкан урынга биргәннәр. Ираннан килүчеләр өчен бу җирләр «елганың теге ягы» булганнар.

[2] Бу кайбер чыганакларда фарсы теле әйтелешенчә Газан хан исеме белән йөртелә.

[3] Кергән – «кияү» дигән мәгънәдә, ягъни хан нәселенә кияү.

углы Шаһрух мирза, оныгы Олуг бине мирзалар, Чыгтай ханның, ә кайбер чакта аның кардәше Үгдәй хакан балаларыннан Данәшмәндчә-углан һәм углы Союргатмыш, аның углы Мәхмүд хан кебек кешеләрне хан итеп тотып, алар падишаһлыкның коры исеменә канәгатьләнеп, сарайда тоткын кебек ятып, гомерләре озын булмыйча, тиз заман эчендә һәлак ителәләр иде. Үзләренә кирәк тапканча эш итү дәүләтне идарә итүчеләрнең үз кулларында булып, болар шул рәвешчә, Чыңгыз нәселеннән берәүне хан күтәреп, Тимер нәселеннән килгәннәрнең падишаһлык итүләре солтан Әбү Сәгыйд мирза дәверенә чаклы дәвам итеп, ул бу хәлне бетерде. Заман үтү белән, Мавәраэннәһердә Тимер Кергән нәселенә зәгыйфьлек килеп, ул шәһәрләрне яңадан Җуҗи хан нәселеннән шәйбанилар үз кулларына алдылар:

Бу төркемнең әүвәлгесе – Мозаффаретдин Әбү әл-Фәтех Мөхәммәд бине Шаһбидаг бине Әбү әл-Хәер хан бине Дәүләтшәех хан бине Ибраһим хан Шәйбани.

Шәйбан бине Җуҗи хан нәселеннән булганга күрә, гарәп гадәте буенча «Шәйбани» дип нисбәт биреп, шигырендә «Шаһ бәхет галәйһир-рәхмәт» дип атый иде. «Шаһбәк хан», «Шәйбәк хан», «Шәйбани хан» исемнәре белән дә йөртелә. Бабасы Әбү әл-Хәер дәүләте тәмам тузылгач, аз заман эчендә Тимер нәселен һәм магул ханнарын җиңеп, Ташкент, Бохара, Сәмәрканд, Фирганә, Харәзем, Хорасан, Астрабад[1], Җөрҗан[2], Дамиганнарны[3] үз кулына алып, җәй көннәрендә – биек урыннарга корылган чатырларда, ә кышын Мавәраэннәһер шәһәрләрендә яши иде. Үзе көчле, зур гәүдәле, батыр, кыргый табигатьле иде. Мирза Олуг-бәкнең хәзинәсе күмелгән дип уйлап, аның рәсадханәсен[4] җимертте. Тимер нәселен яраталар дип шикләнеп, мелла Әбү

---

[1] Астрабад – Иранның төньягында Эльбрус тавы итәгендә зур гыйлем мәркәзе булган шәһәр.

[2] Җөрҗан – Каспий диңгезе.

[3] Дамиган – Астрабадтан 64 км көньякта.

[4] Рәсадханә – обсерватория.

әл-Мәкяримне һәм хужа Яхъя бине Гобәйдулла Әхрар әл-Кәсанине һ.б. үтертте.

Беренче дәверендә Әхмәд хан һәм Айбәк ханнар, һөҗүм итеп Хәйдәр ханны үтергәч, үзбәк әмирләренең зурларыннан Карачин бине Шәйбани һәм туганы Мәхмүд солтанны алып, күркәм ния белән Касыйм хан хозурына барып сыендылар. Шуңа күрә Әхмәд хан белән Айбәк хан Әстерхан шәһәрендә күп гаскәр белән Касыйм ханны чолгап алдылар. Шул чакта бу ике хан балалары, Карачин би мелла, борынгыдан килә торган кырык кеше белән чыгып китеп котылдылар. Шуннан соң Шәйбани ханга падишаһ булу исәбе төшеп, үзбәкләрдән иярченнәр табып, Сарбан[1] хөкемдары Иранчы хан бине Җанибәк хан белән сугышып, нык җиңелеп, Бохарага килде. Бохара башлыгы Габделгали тархан олылап, хөрмәтләп каршы алды, гаризасы белән Сәмәркандка солтан Әхмәд мирзага җибәрде. Аннан Дәште Кыпчак ягына килеп, Борындык хан, аннан соң Сузактагы вәлисе Мәхмүд солтан белән сугышып җиңелеп, тагын Бохарага килде. Бераздан соң солтан Әхмәд мирза белән бергәләп, Магулстанны кулга төшерү өчен Ташкентка кайтса да, аннан аерылып һәм Мәхмүд ханга кушылып, солтан Әхмәд мирза, күңеле төшеп, Сәмәркандка, Мәхмүд хан Ташкентка кайтты, ә Шәйбанига Утрарны бирде. Төркестан халкы һәммәсе Шәйбани ягына күчәргә теләсә дә, Борындык хан Дәште Кыпчактан Сарбанга килгәндә, Мәхмүд солтан качып, туганы Шәйбанига кушылып, Борындык хан аларны Утрарда чолгап алды. Ләкин Мәхмүд хан бине Юныс хан әл-Магули ярдәм иткәнлектән, килешергә ирекле-ирексез мәҗбүр булып, Дәште Кыпчакка кайтты. Шуннан соң әкрен-әкрен көч җыеп, тугыз йөз алтыда (1500) Сәмәркандны алып, Тимер Кергән[2] нәселеннән солтан Гали мирза бине солтан Мәхмүд мирза бине солтан Әбү Сәгыйдне җиңеп, анасына өйләнде, ә үзен үтереп, дәүләтен алды. Бабур мирзаны

---

[1] Сарбан – Сырьдәрья үзәнендә бер кечкенә шәһәр – заманында сәүдә ягыннан әһәмияте булган.

[2] Тимер Кергән – Тимерлән яки Аксак Тимер.

да җиңеп, тугыз йөз ундүртенче (1508) елда Мәхмүд хан әл-Магулине үтереп, Хөҗәнд, Ташкент һәм тирәләрен үз кулына алды. Ләкин һәрвакыт Касыйм хан бине Җанибәк хан турында шикләнеп, куркып яшәгәнгә күрә, тугыз йез унбишенче (1509) елда «Касыйм хан килде» дигән ялган хәбәргә алданып, Хокандта җиңелеп, Хорасанга кайтты. Шул җиңелеп кайтуында шаһ Исмәгыйль әс-Сәфәви белән сугышып, Мәрү әш-Шаһеҗан өстендә җомга көн тугыз йөз уналтынчы (1510 –1511) елда үтерелде. Башыннан башка гәүдәсе, шаһның рөхсәте белән, Сәмәркандка китерелеп күмелде. Казан хөкемдары Мөхәммәдәмин хан белән хәбәрләшеп, дус яшәде.

Аннан – углы Тимерхан. Атасының тәхет варисы иде. Бабур мирза кайтып, шәһәрләрен тагын яулап алды. Аннан – бабасы белән бертуганның углы Күчкенче хан бине Әбү әл-Хәер хан. Шәйбани хан вакыйгасыннан соң үзбәкләр, бу мәмләкәттә безгә тормыш булмас дип, Дәште Кыпчакка кайтсалар да, тугыз йөз унсигезенче (1512) елда ялгыз Чукрак Гобәйдулла хан һиммәт һәм гайрәт кылып, кайбер союзниклары, аз гына гаскәре белән Бабур мирзаны җиңеп, Сәмәрканд, Бохара һәм Мавәраэннәһердәге башка шәһәрләрне кулга алып, атасы белән бертуганнар һәм аларның балалары арасында бүлде. Көчне һәм бердәмлекне саклау өчен, иң олы яшьтәгесенә хакан, башкаларына хан исеме бирелде. Шулвакыт атасы белән бертуганнар арасында иң өлкәне Күчкенче хан өлешенә Сәмәрканд бирелеп, яшь ягыннан иң өлкәне булганга, хаканлык дәрәҗәсе иң башлап аңа бирелде. Аннан – аның углы Әбү Сәгыйд хан. Аннан – Бохарада Гобәйдулла хан. Аннан – Барак дип мәшһүр Нәүруз Әхмәд хан бине Сөенеч хуҗа бине Әбү әл-Хәер хан – Ташкентта хакан исемендә булдылар. Барак ханның атасы Күчкенче ханның ата-ана бер кардәше, аналары – Олуг-бәк мирза кызы иде. Сөенеч хуҗа гәрчә ханлыкта туганының варисы һәм Ташкент шәһәрендә чын мәгънәсе белән хан һәм хаким булса да, хаканлык дәрәҗәсен алудан элек үлеп китте. Күчкенче хан тугыз йөз утыз алтынчы (1530) елда Сәмәркандта вафат, кабере – мәдрәсәи Ширдар мәйданында. Аннан – углы Әбү Сәгыйд

хан. Бу да хаканлык дәрәҗәсенә ирешкән ханнардан. Тугыз йөз кырыгынчы (1534) елда зөлхиҗҗә аенда вафат. Аннан – кардәше Габдулла хан. Тугыз йөз кырык җиденче (1541) елда рабигыль-әүвәлнең өченче көнендә вафат. Алты ай хан булып торды. Аннан – кардәше Габделлатыйф хан. Тугыз йөз илле тугызда (1552) Сәмәркандта вафат. Аннан – Нәүруз Әхмәд хан. Ул Барак хан исеме белән танылган. Атасыннан соң Ташкентта хөкемдар булып, Мөхәммәдьяр хан вафатыннан соң Ташкенттан Сәмәркандка килеп, үз исеменә хөтбә укытты, акча суктырды, Бохарага барды. Тугыз йөз алтмыш өченче (1556) елда үлде һәм Сәмәркандта Хужа Әхрар каберлегендә күмелде. Углы Бабахан Ташкент дәүләтенә варис булды. Хөсрәү хан бине Ярмөхәммәд бине Җанибәк бине Хужа Мөхәммәд бине Әбү әл-Хәер хан. Тугыз йөз җитмеш дүрттә (1566) вафат: Бабахан бине Барак хан (Ташкентлы) үтерде. Аннан – Сәгыйд хан бине Әбү Сәгыйд хан бине Күчкенче хан. Тугыз йөз сиксән биштә (1578) вафат. Аннан – кардәшенең углы Җәванмәрд Гали хан бине Габделләтыйф хан. Әбү әл-Хәер һәм Мозаффар исемнәрендә ике углы Миянкәлат крепость-шәһәрләрендә хаким иде. Ике туган арасында низаг чыгып, Җәванмәрд Гали хан Мозаффарны якласа да, Әбү әл-Хәер Габдулла ханга сыенды. Шул уңай белән Габдулла хан Сәмәркандка һөҗүм итте, ахырда Җәванмәрд Гали ханны һәм ике углын тугыз йөз сиксән алтынчы (1578) елда Миянкәлатта үтерде. Бу маҗара сәбәпле төрмәгә ябылып, анда бу шигырьне әйтүе мәгълүм.

Шигырь:

Мин бу дөньядан китәм: шаһның бу дөньяда йорты юк.
Моңа Әбү әл-Хәер белән Мозаффар өчен тырышуым сәбәп.

Аннан – Габделмәлик бине Габделлатыйф бине Күчкенче хан. Бу – Әбдал солтан дип танылган. Патша булырга теләсә дә, теләгенә ирешә алмады. Тугыз йөз сиксән сигездә (1580) вафат булды.

Болардан икенче төркеме Бохарада хан булдылар. Аларның әүвәлгесе – Могыйнетдин Әбү әл-Гази Гобәйдулла хан

бине Мәхмүд бине Шаһбидаг бине Әбү әл-Хәер хан. Шәйбанидан соң үзбәкләр, күчеп, Дәште Кыпчакка кайтсалар да, Гобәйдулла хан һиммәт итеп, бераз союзниклары белән кире кайтып, Бабур мирза белән сугышта җиңеп, Мавәраэннәһерне яулап алды. Шул чакларда, тугыз йөз унсигезенче (1512–1513) елда шаһ Исмәгыйльнең Нәҗметдин Икенче дип танылган Ярәхмәд Исфаһани исемле гаскәр башлыгы күп гаскәр белән Мавәраэннәһергә һөҗүм итсә дә, Гобәйдулла хан җиңеп, Нәҗметдин Икенче җиңелеп туздырылды. Гобәйдулла хан, тел берлеген истә тотып, бөтенесен бер хакан хөкүмәте астында берләштерсә дә, ул үлгәч, ике дәүләткә бүленеп, берсе Сәмәркандта, берсе Бохарада карар тапты. Гобәйдулла хан тугыз йөз кырык алтыда (1540) зөлкагъдә аенда Бохарада вафат һәм Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди каберлегендә күмелде. Акыллы, гадел, тугры, дингә ихласлы, күп изгелек кылучы, сугышчан кеше иде. Бөтен Мавәраэннәһерне, Хорасан һәм Харәземне яулап алды. Мелла Габделгали әл-Бәржанди китабында, мелла Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Каһстаниның «Шәрхе Мохтасарелвикайә» исемле китабының кереш өлешендә исеме телгә алынган. Үз чорында тугыз йөз кырык икенче (1536) елда Бохарада ике катлы, йөз унбер бүлмәле, һәммәдән матур һәм гүзәл, кирәк-яраклары һәм вәкыфе төгәл «Мир Гарәб» мәдрәсәсе салынды. Нәҗметдин Икенчедән калган ганимәт малы хисабына бина ителгәнлеге халык телендә сөйләнә. Аннан – углы Габделгазиз хан. Тугыз йөз илле сигез (1551) рабигыльахирдә вафат һәм атасы янында күмелде. Нәкышбәнди ханәкәсен[1], «Мәгак» мәчетен төзәтеп яңадан эшләтү – бу кеше эше. Аннан – бабасының оныгы Мөхәммәдьяр бине Сөенеч Мөхәммәд бине Шәйбани хан. Тугыз йөз алтмышынчы (1552–1553) елда Бохара кремле эчендә аны Барак якыннарыннан Борһан исемле кеше үтерде. Шуннан бөтен Мавәраэннәһердә акча сугу һәм хөтбә уку Барак хан исеменә булып, (Борһан) үзе Бохарага хуҗа булды. Аннан – Могыйсетдин Әбү

[1] Ханәкә – кабер өстендәге бина.

әл-Гази Искәндәр хан бине Җанибәк хан бине Хуҗа Мөхәммәд бине Әбү әл-Хәер хан бине Дәүләт Шәех. Углы Габдулла хан ярдәмендә падишаһлык исемен алды. Аңы төгәл булмаса да, намаз укучан, җәмәгать намазына йөрүчән, кош салуга[1] оста иде. Атасы һәм бабасы да акылсызлык белән танылган иде. Бигрәк тә Хуҗа Мөхәммәдне үзбәкләр «Хуҗгым тинтәк» дип телгә алалар икән. Анасы Бәркә Солтан бине Ядкярнең кол кызы булып, Хуҗгым хан аны йөкле килеш алганга күрә, Җанибәк дөреслектә Бәркә Солтан углы диләр. Барак хан Бохараны алырга теләгәнлектән, Габдулла хан тирә-як гаскәрләре белән катнашуы сәбәпле, Барак хан куйган Сәгыйд хан һәм Дустым солтан, аны кулга төшерергә теләп Фәраб крепостен чолгап алсалар да җиңелеп кайттылар. Моннан соң, Барак ханның үлү хәбәре ишетелү белән, хөтбәне атасы исеменә укыта башлады. Ул [Искәндәр хан] утыз өч ел буена падишаһ исемендә булып, тугыз йөз туксан бердә (1583) вафат булды. Аннан – углы Насыйретдин Әбү әл-Мозаффар мәшһүр Габдулла хан. Дәүләтне яңадан тергезеп, Төркестан, Фирганә шәһәрләре, бөтен Мавәраэннәһер, Харәзем, Хорасан шәһәрләреннән Бәлех, Һират, Нишапур, Мәшһәд, Сәбезварга хуҗа булып, ата ягыннан булган кардәшләренең балаларын тәмам бетереп, мөстәкыйль падишаһ булды. Заманында төзеклек, шәһәрләрендә иркенлек булды. Бохарада зур урамның ике ягында кара-каршы салынган ике зур мәдрәсәсе бар. Берсе – «Габдулла хан мәдрәсәсе», берсе – махсус анасы исеменә салынып, «Мадәр[2] хан мәдрәсәсе» дип танылган. Сөт кардәше һәм вәзире Суфи Колбаба Бохарада һәммәдән зур йөз илле бүлмәле, ике катлы «Мәдрәсәи Күгәлтәш»не бина кылды. Тагын бер мәдрәсә Ташкентта тугыз йөз сиксән бишенче (1578) елда бина кылынды. Тугыз йөз сиксән алтыда (1578–1579) ханның ышанычлыларыннан Касыйм исемле кеше Таждеван шәһәрчеге тирәсендә Кәһек елгасына күпер эшләтте. Бу күпер «пол

---

[1] Кош салу – кош белән ауга чыгу.

[2] Мадәр – ана. «Ханның анасының мәдрәсәсе» мәгънәсендә.

мөһтәр Касыйм»[1] исеме белән танылды. Аның заманында мелла Мирзаҗан Ширази Бохарага кайтып, мелла Садретдин Мөхәммәд әл-Бохари әл-Кәскерани белән ике араларында тугыз йөз туксан тугызынчы (1591) елда уникенче шәгъбанда җомга көн сүрәи «Фәтех» буенча бәхәс булды. Атасыннан соң унбиш ел гомер итеп, мең дә алтынчы (1598) елда шимбә көн рәҗәп аеның икесендә Бохарада үлде. Ахыр гомерендә углы Габделмөәмин каршы чыгып, сугышып, Казах ханы Тәвәккел хан һөҗүм итеп, гаскәре аңа каршы тора алмыйча җиңелеп, борчылып, акылына зәгыйфьлек килеп, түшәккә ятты һәм гомере бетте. Аннан – углы Габделмөәмин хан. Атасына каршы чыгып сугышты, аның ләгънәтен алды. Атасы үлгәч, илнең олыларыннан Суфи Колбаба Күгәлтәшне, атасы белән бертуган Дустым солтанны балалары белән юкка чыгару һәм башка шундый явызлыклары сәбәпле, алты ай үтүгә, мең дә алтынчы (1598) елда үзе дә Габделвасигъ тарафыннан үтерелде һәм дәүләте кулыннан китте. Аннан – бабасы белән бертуганның углы Пир Мөхәммәд хан бине Сөләйман бине Җанибәк бине Хужа Мөхәммәд бине Әбү әл-Хәер. Аннан – кардәше Ярмөхәммәд-регент; оныгы Динмөхәммәд хан бине Җанмөхәммәд бине Ярмөхәммәд, бабасы хаҗ сәфәреннән кайткач, акча һәм хөтбәне үз исемендә кылып, хан исеме белән аталуга иреште. Аннан[2] – оныгы Динмөхәммәд хан. Аннан – кардәше Бакый хан бине Җанмөхәммәд бине Ярмөхәммәд бине Җанибәк бине Хужа Мөхәммәд бине Әбү әл-Хәер хан мең дә унынчы (1602) елда Бәлех шәһәрен алды. Мең дә ундүртенче (1606) елда рәҗәп аеның ахырында Бохарада вафат. Аннан – кардәше Вәли Мөхәммәд хан. Туганы үлгәч, мең дә унбишенче (1606–1607) елда мөхәррәм аенда Бохарага кайтты һәм бөтен Мавәраэннәһергә падишаһ булды. Ләкин мең уналтынчы (1607–1608) ел рабигыль-әүвәл аеның ахырларында Астраханияләр килеп чыгып, солых кылып, Бәлех шәһәренә кире кайтса да,

---

[1] Пол мөһтәр Касыйм – Касыйм эшләткән зур күпер.

[2] Ярмөхәммәддән соң.

мең унтугызда (1610–1611) Имамколый хан икенче кат Нәсефкә килеп, ике гаскәр бергә очрашкач, Вәли Мөхәммәд хан гаскәре җиңелде. Шаһ Габбас әс-Сәфәви ярдәмендә мең дә егерменче (1611–1612) елда яңадан килеп, тагын җиңелде, әсир төште һәм Имамколый хан боерыгы белән Сәмәркандта Багбан күле буенда яклаучысы беткән хәлдә үтерелде. Мавәраэннәһер җирләрен әстерханлылар яулап алды.

Мавәраэннәһердә Әстерхан ханнары турында

Татарларның һәммәсеннән элек ислам кабул иткән Бәркә ханга ияреп мөселман булган туганы Тукай Тимер нәселеннән, Казан, Сарай, казах ханнары һәм Хаҗитархан падишаһлары белән бер нәселдән булып, Хаҗитархан тарафыннан килгәнлекләре сәбәпле, «Астрахания»[1] исеме белән тарихта калдылар.

Беренчесе – Имамколый хан бине Динмөхәммәд бине Җансолтан бине Мөхәммәд бине Мангышлак бине Чуак бине Мөхәммәд хан бине Тимерсолтан бине Тимеркотлыг бине Галитимер бине Котлыгтимер бине Тумган бине Абай бине Үзтимер бине Тукайтимер хан бине Җуҗи хан бине Чыңгыз хан. Нәсәп чылбыры ундүрт буын аркылы Җуҗи ханга тоташа. Әбү әл-Хәер хан нәселенең дәүләтенә торгынлык килеп, төрле җирдә фетнәләр башлангач, баш күтәреп, Вәлимөхәммәд хан белән берничә очрашып сугышып, җиңеп, тәмам Мавәраэннәһерне яулап алып падишаһ булды. Мең дә илленче (1640–1641) елда күзе сукыраеп, падишаһлыктан баш тартты, туганына тапшырып, хаҗга китте. Хаҗ кылганнан соң, Мәдинә шәһәрендә мең дә илле дүрттә (1645) үлде. Утыз ел падишаһ булып торды, мелла Касыйм бине Салих әл-Фәтехабади китабында исеме телгә алынган. Аның заманында әмирләреннән Ялаңтүш баһадир мең дә егерме сигезенче (1618–19) елда Сәмәркандта «Мәдрәсәи тыллакярины», арлат кабиләсеннән Нәдер диван биге Тыгай Сәмәркандта Хуҗа Әхрар кабере янында мәдрәсә бина кылды. Аннан – кардәше Нәдермөхәммәд хан. Туганы үлгәч, мең дә

[1] Мәрҗани «Әштрхания» дип йөртә.

илле икенче (1642) елда тәхеткә утырды... өч елдан соң падишаһлыктан төшерелеп, мең дә илле биштә (1645) углы куелды.

Шигырь:

Тарих бу: әгәр бер шаһ тәхеткә утырса,
икенче шаһдан саклан.

Аннан – углы Гыйззәтдин Әбү әл-Мозаффар Габделгазиз хан. Галимнәрне, төзеклекне яратучыларны сөя торган изге кеше иде. Мәүләви шәриф китабында исеме әйтелә. Мең дә җитмеш бишенче (1665) елда мелла Касыйм үлгәч, мәетен күтәреп күмәргә барды. Бохарада, мирза Олуг-бәк мәдрәсәсенә каршы, урамның икенче ягындагы ике катлы мәдрәсәне, шулай ук Регистанда «Мәдрәсәи Күсфәнд» дип аталган мәдрәсәне бу кеше салдырган. Туганы Сөбханколый хан Бәлех шәһәре башлыгы булып торганда, мең сиксән җиденче (1676–1777) елда араларында каршылык чыгып, сугышка барып җитте. Үргәнеч ханы Әбү әл-Гази хан белән дә араларында күптөрле мажаралар булды. Мең дә туксан өчтә (1682) рамазан аеның ахырында илне туганына тапшырып, фарыз хаҗны үтәгәннән соң, мең дә туксан тугызда (1688) Мәдинәдә вафат һәм «Коббәтел-Габбас» янында күмелде. Аннан – кардәше Әбү әл-Мансур Сөбханколый хан. Туганына каршы килеп сугыш башлаган өчен, Бохара галимнәре гәрчә кяфер дип игълан итсәләр дә, шәһәрләренә килеп падишаһ булгач, вәлилек һәм кәрамәт иясе булуы белән хөкем иттеләр. Ахун шәех китапларында исеме бар. Егерме ел падишаһ булып, Бохарада вафат һәм Нәкышбәнди кабере янында күмелгән. Аннан – углы Гобәйдулла хан. Сигез ел падишаһ булып торып, мең бер йөз егерме өченче (1712) ел чигендә вафат. Аннан – кардәше Әбү әл-Фәез хан. Унике яшьтә сабый чагында падишаһ булып, кырык тугыз ел гомер итеп, мең бер йөз алтмышта (1747) якшәмбе көн җөмадиел-ахирнең унҗидесендә үтерелде. Җиңел карашлы, бозык гамәлле, эшкә тәртипсезлек кертүче кеше иде. Якыннарын, илнең өлкәннәрен бетереп, патшалык эшләрен мангыт кабиләсеннән Хәким аталык бине Ходаяр бине

Ходайколый үз кулына алып, илне үзенчә идарә итеп, Әбү әл-Фәезга фәкать патша дигән исем генә калды. Төрле өлкәләрнең башлыклары үзләренә мөстәкыйль һәм ирекле эш йөртә башладылар. Надиршаһ Һиндстан сәфәреннән кайтканда, Әбү әл-Фәез хан һәм Хәким аталык, чикләрен саклау өчен, Харәземдәге Юлбарыс хан белән бергәләп, алтмыш мең гаскәр каршы җибәрсә дә, Надиршаһ гаскәрләренең бер төркеменә дә каршы тора алмыйча, җиңелеп кайттылар. Әбү әл-Фәез хан һәм Аталык үзләрендә Надиршаһга каршы торырлык көч юклыгын белеп, Әбү әл-Фәез хан тиешле бүләкләр белән Пәшавырга хуҗа Җуйбарины илче кылып, хәлен язып җибәрде. Язуы болай иде:

«Мин әүвәлге солтаннар нәселеннән булсам да, күк шикелле гали һәм көчле падишаһга каршы сугышырлык көчем юк. Бер читтә (сезгә) дога кылып торам. Кайсы вакыт килсәләр дә, кабулым бар, кунак итәчәкмен».

Әбү әл-Фәезнең бу гаризасы Надиршаһга хуш килеп, илчеләрне тиешлечә кадер-хөрмәт итеп кайтарып җибәрде һәм Әбү әл-Фәезга хат язды. Хатның эчтәлеге:

«Сезнең сүзләрегез дөрес, ләкин Илбарысны уятып акылга китерү безгә тиешле эшләрдән булып тора, без аны үз өстебезгә алабыз, ул явызга җәза бирәчәкбез. Аллаһ теләсә, падишалык йорты Һираттан Бәлехкә барып, аннан ата дәрәҗәсендә югары урынлы Сезнең белән очрашып күрешергә һәм кунак булырга дип, Сезгә барырга телим. Кабул итеп каршы алырсыз. Күңелегезгә күтәрмәгез, Сезнең мал-мөлкегездә күзебез юк».

Әбү әл-Фәез шатланып, кунак итү өчен әзерләнә башлады: исәпсез күп ашлык, дөге, арпа, куй әзерләде. Әбү әл-Фәез хан галимнәре, сәедләре – илнең олылары белән кыйммәтле бүләкләр алып Кара Күлдә шаһга җитешеп, аның алдына баргач, шаһ аңарга утырырга кушты һәм Әбү әл-Фәезнең башына кыйммәтле ташлар белән бизәлгән таҗ, өстенә бәһале киемнәр кидерде, «Әбү әл-Фәез шаһ» дип эндәште. Бер кичә үткәч, кайтып китәргә рөхсәт алды. Ике көннән соң Надиршаһ Бохарага килде һәм Чәһаре Бәкергә төште. Әбү әл-Фәезнең кызының

берсенә үзе, берсенә кардәшенең углы Гаделшаһ бине Ибраһим өйләнде. Мавәраәннәһер мәмләкәтен идарә итүне Әбү әл-Фәезгә тапшырды, Үзбәкстаннан алты меңкеше алып, хат язып, аны Рәхим-би бине Хәким бигә бирде.

Надиршаһның Әбү әл-Фәез шәфәгате белән Илбарыска язган хаты:

«Хивә хакиме, батыр егет Илбарыс! Мәгълүмегез булсын, Иран мәмләкәте Адәм, Басра, Мәскат чикләренә кадәр, Хорасан мәмләкәтләре, Һиндстан мәмләкәте – Җиһанабад, Әкбәрабадка кадәр Дәһли, Ләкһеңү, Лаһур, Рутас Бингалә чикләренә кадәр; Кәй, Мәйсүр – Сәрәндип мөлкенең соңына кадәр; Җәмү, Кәшмир, Җисре мирүттә, Сәндү, Талпур, Күҗрат, Мультан, Шикарпур, Кабил, Кандәһар, Бәлех, Бәдәхшан, Кондыз, Хуттәлан һәм Кафир Сияһпуш чикләренә кадәр булган барлык җирләр; Бохара, Сәмәрканд һәм Фәрганә мәмләкәтләре барысы да алындылар. Тирә-якның олылары безгә баш ордылар, итагать күрсәттеләр. Безнең кыямәтне күз алдына китерерлек гаскәребезгә беркем дә каршы тора алмый. Барлык җирдә өстенлек, бәхет, дәүләт безнең белән бергә, безгә яр булдылар.

Харәзем безгә якын күрше, шуның өчен ул батыр егеткә (Илбарыска) тиеш иде: бернәрсәгә дә карамыйча безнең гали тәхетебез алдына килеп, төрле-төрле бүләкләр алып, якыннары, тиңдәшләре арасында мактаулы һәм югары дәрәҗәле булсын иде. Һиндстан сугышларында безнең иттифакчыбыз һәм ярдәмчебез дә булырга кирәк иде, аны эшләмәделәр. Падишаһның мәрхәмәтләреннән өлешсез калдылар; инде ул чакта безгә буйсынмаганнар, безнең белән дус булмаганнар икән, аларның өстенә төшкән нәрсә шул иде: без гаскәребез белән Һиндстанга киткәндә, минем дөрес юлдан баручы акыллы углым, варисым Риза-колый мирза мөкаддәс Мәшһәдтә калдылар; киреләнмичә, дуслык юлы белән барып, аңарга күренергә кирәк иде, аны да эшләмәделәр. Аның өстенә тагы берничә мәртәбәләр безгә каршылык итеп талаучы ямүт халкы белән касд итеп кул күтәрделәр, мөкаддәс Мәшһәд шәһәре тирәләрен таларга килделәр. Һәрбер килүләрендә начар рәвештә бозылып, җиңелеп

куылдылар. Хивә иленә качып киттеләр. Күз нурым Риза-колый мирза аңарга илтифат итмәде; безнең рөхсәтебездән башка Хивә өстенә гаскәр җибәрмәде. Хәзер инде Һиндстанны буйсындырып алып, бәхет, дан белән кайтып килешли, Чыңгыз ханның пакь гаиләсеннән ата дәрәҗәсендә дус тотучы хөрмәтле падишаһ Әбү әл-Фәез шаһ белән очрашып күрешү өчен килдек. Ул [Илбарыс] кыска уйлый; киресенчә, ул камил кунакчыллык һәм хезмәт күрсәтү йөзеннән безнең ишегебезгә килү уенда булырга кирәк иде. Шиксез, үткәндәге гөнаһ-җинаятьләрен гафу иткән булыр идек, күршелек хакын үтәгән булыр идек. Озын гомерле, падишаһлар падишаһының шәфкатеннән өлешле булып, игътибарлы, сүзе үтәр кеше булырлар иде. Берничә көн Бохара тирәләрендә торганда шаять төпсез, асылсыз эшләрдән йөз чөереп, яхшылык белән килеп үзенең мәмләкәтен, илен талатудан һәм мөселманнарның каны түгелүдән саклап калыр иде. Без шул фикердә торганда, ямүт таифәсеннән өч мең кеше төнге баскынчылык итү теләге белән Чаржуйга килгәнлекләре ишетелде. Гаскәриләрдән бер төркем моны сизеп, бердән һөҗүм итеп, аларны Җидегән йолдыз шикелле төрле якка таратты, аларның күбесе үтерелде һәм әсир төште, берникадәресе мең мәшәкать белән безгә килеп юлыктылар. Шушы вакыйга миндә көчле ачу тудырды. Ләкин ата урынында булган Әбү әл-Фәез шаһ ышанып үтенде һәм тынычландырды. Хәзер безнең илчебез бөек дәрәҗәле шаһның [Әбү әл-Фәезнең] ышанычлыларыннан ике кеше белән баралар. Әлбәттә, сез анда-монда карамыйча, кичекмәстән күк шикелле кодрәтле ишегебезгә килегез. Аллаһ теләсә падишаһның мәрхәмәте сиңа да ирешсә кирәк. Юкса кабул итеп ал. Теләк шулай: ул өлешсез, кадерсез мәмләкәтне ат аяклары, тояклары астында таптарбыз, изәрбез һәм синең явызлык белән тулган башыңны алка шикелле элеп куярбыз.

Шигырь:

Сүз золымны тудыра; сүз озак яшәп килгән
илләрне дә һәлак итә».

Илбарыс, хатны укып, уйлап та тормыйча, өч илчене үтерде. Надиршаһ гаскәре Харәземне алырга теләгәндә, ат абзарына качты. Хан яши торган крепостьны чолгап алу турында Надиршаһ боерык биргәч, Илбарыс үзен шунда ташлады. Өч көн камалып торгач, крепостьтагылар һәм Илбарыс әман сорадылар. Надиршаһ кабул итеп, крепостька һөҗүмне туктату турында гаскәренә боерык бирде. Илбарыс хан, кылыч һәм кәфенен тотып, шаһ каршына килде. Шаһ аны исән калдырып, хөрмәт итсә дә, үтерелгән илчеләрнең варислары таләбе буенча, Илбарыс һәм иярченнәре – барысы егерме бер кешене үтертте. Надиршаһ Дагстаннан кайтып, Мәшһәд ризвага тукталганнан соң, Әбү әл-Фәез хан: «Гыйбадулла үзбәк Фирганә һәм Ташкенттан чыгып, Сәмәрканд һәм Миянкәлатне шаһ Нәкышбәнд каберлегенә хәтле талап йөрде», – дип, гариза җибәрде. Надиршаһ Хәсән хан, Бият һәм Бәһбуд хан, Чындавыл исемле кешеләрне унике меңгаскәр белән җибәреп, артыннан тагын Рәхим ханны җибәрде. Гыйбадулла Хокандтан Ташкентка кайтты. Рәхим хан Амудәрья елгасы буендагы Чаржуй крепостена килгәч, Надиршаһның үтерелү хәбәрен ишетте. Бу хәбәрне беркемгә әйтмичә, ашыгыч рәвештә Бохарага, аннан Әбү әл-Фәез хан белән очрашу өчен Гореккә килде. Әбү әл-Фәез күренешханәгә чыкты. Рәхим хан шунда ук ярдәмчеләренә Әбү әл-Фәез ханны тотып алырга, мал һәм коралларыннан арындырырга боерды. Ул, аптырап калып, Җуйбар мәхәлләсенә килде. Мәхәллә кешеләре, укымышлылар, Рәхим ханнан куркып, аны бер генә кич тә кунак итә алмадылар. Чарасы калмагач, гает укыла торган урыннан чыгып, дәрвишләр яши торган йортка килде, хаҗга китәр өчен Рәхим ханнан юл расходына акча сорап, берничә көн шунда калды. Шул арада Хәсән хан һәм Бәһбүд ханнарның килгәнен ишетеп һәм алар Әбү әл-Фәез ханны якларлар дип куркып, аны, дәрвишләр йортыннан чыгарып, мәдрәсәи Мир гарәбнең бер бүлмәсенә япты. Надиршаһ гаскәрләре: «Әгәр Әбү әл-Фәез шаһны азат итеп тәүбә кылмаса, Бохарага кереп, көч белән азат итәбез», – дип хәбәр иттеләр. Рәхим хан: «Сез ахмак булмагыз, Надиршаһ үтерелгән, исән-сау килеш ватаныгызга кайтыгыз», – дип җавап

бирде. Һәм Надиршаһ үтерелүдән биш көн соң, җөмадиел-ахирнең унҗидесендә якшәмбе көн Әбү әл-Фәез хан үтерелде. Бу бозык эштән хәбәр бирүче Габдулла хужа исемле кеше де үтерелде. Соңыннан бу эшенә үкенеп һәм тәүбә итеп, милкеннән бер өлешен Әбү әл-Фәез хан рухына Әбү әл-Фәез үтерелгән бүлмәгә вәкыф итте дип, халык телендә сөйләнә. Чыннан да, бу бүлмәнең вәкыфе башка бүлмәләрнең вәкыфеннән әле дә күбрәк[1]. Рәхим хан Әбү әл-Фәез ханны үтергәч, углы Габделмөэминне аның урынына тәхеткә утыртып, падишаһ исемен бирде һәм унике яшьлек үз кызын аңа биреп, үзенә кияү ясады. Беркөнне бер кавынны сөлгегә төреп, кызга күрсәтте. Кыз: «Ул нәрсә?» – дип сорагач, «Атаңның башы, атамны үтергән өчен, аны үтердем», – диде. Бу сүзне кыз атасына ирештерде. Рәхим хан бу сүзгә кинә тотып шигырь:

Бүрене күпме генә ашатсаң да,
Һаман урманга таба карар.

дип, ачу саклап, Чырых аб исемле коены карарга җибәреп, Габделмөэмин сузылып кое төбенә бөгелеп караганда, Рәхим хан агентлары төртеп төшереп, мәетен генә чыгардылар.

Аннан – Гобәйдулла хан бине шаһ Тимер әл-Харәзми. Әбү әл-Фәез ханнан соң берничә көн падишаһлык исем ягыннан бу кешеләрдә булса да, боерык бирү, идарә һәм сугыш эшләре Рәхим хан кулында иде.

Аннан – Әбү әл-Гази Габделгазиз бине Габдерәхим әл-Чакпути. Бер мең бер йөз җитмеш икенче (1758–1759) елда халык һәм ил олыларының таләбе буенча, Рәхим һәм аның онытгы Фазыл ханнардан соң әмир Даниал падишаһлыкны бу кеше исемендә кылып, гаһед әмир Хәйдәрдән биш-алты ел узганчы дәвам итте. Даниал гәрчә рәсми яктан олылап һәм хөрмәтләп торса да, Шаһморат ул хөрмәттән мәхрүм һәм кадерсез

[1] Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләре һәм аларның аерым бүлмәләре күчми торган, доходлы милек белән тәэмин ителгән. Бу милек «вәкыф» дип атала иде. Әлеге вәкыфтән килә торган доход шул мәдрәсәләрне һәм аның бүлмәләрендәге шәкертләрнең тормышын тәэмин итә иде.

итеп, хәтта өеннән чыгармыйча ябып тотып, тик Тимершаһ бине Әхмәдшаһ Әфганинең куркытуы сәбәпле генә азат итте. Әмма дөньясы тарлыкта үтеп, әмир Хәйдәр заманында, гади кешеләр кебек, урамнарда ялгыз йөргәнен үзләре күреп сөйләүчеләрне күрдек. Аның исеменә сугылган алтын тәңкәләр безнең гасырда кулда йөри иде. Бу кеше – Чыңгыз балаларыннан падишаһ исемен алучыларның соңгысы.

Җуҗи нәселеннән булган ханнар бәянын тәмам итеп, алар беткәннән соң төзелгән өч үзбәк дәүләте бәянына керешелә.

Бохарада Мангытия дәүләте турында

Рәхимханның биографиясе. Алардан безнең көнгә чаклы ун падишаһ булды. Әүвәлгесе – Әбү әл-Мозаффар Рәхимхан бине Хәкимби бине Ходаяр хан бине Ходайколый бине Килдеяр бине Чавыш. Хәзерге көнгә чаклы Карши дип аталган Нәсеф исемле шәһәр тирәсендә яшәүче мангыт кабиләсе үзбәкләреннән. Бабалары нинди сәбәп беләндер, Әштрхания дәүләте хезмәтенә ирешеп, бабасы Ходаяр, «вәзир» мәгънәсендә кушбиге, углы Хәким кушбиге аталык исемен алып, меңбер йөз илле җиденче (1745) елда вафат һәм урынына углы Барат кушбиге h.б. шул ук дәрәҗәне алып, Әбү әл-Фәез ханның дәүләте тәмам болар кулында иде: Надиршаһ килгәннән соң, Үзбәкиядән алты меңкеше сайлап, аларга Рәхимханны башлык итеп, Иран һәм Һиндстан гадәтенчә хан исемен биреп, үзе белән алып китеп, тагын кайтару вакытындагы хәлләр – барысы бу илне тулысынча кулга алып, аңа хужа булуына сәбәп булды. Гәрчә беренче чорында тәхеткә утырып падишаһлыктан сакланып, падишаһ исемен Габделмөэмин, аннан соң Гобәйдулла ханнар исемендә кылса да, көче төгәлләнеп, рабигыль-әүвәл аеның өчесендә дүшәмбе көн тәхеткә утырып, падишаһлык тажы киде. Хөтбәдә һәм акчада үз исемен куйдырып, меңбер йөз җитмешенче (1755) елда мөстәкыйль падишаһ булды. Сәбез, Хәсар, Шадман, Күләй, Харәзем, Хөҗәнд, Төркестан, Ташкентны сугышып алды. Әмма Ташкент аның кулыннан чыкты. Сугышчан, иранлыларча олысыман иде. Вәзире Дәүләт кушбиге

асылы буенча иранлык иде. Мәмләкәткә бәйләнешле эшләр, идарә аның кулында булды. Баш казые Низаметдин Хөсәени, надан булса да, хуш табигатьле, үткен, сәфәрдә киңәшчесе иде. Әхмәдшаһ Әфганигә күркәм мәхәббәт һәм яхшы теләктә иде. Ахыр гомерендә Гаждваннан кайтканда бер дәрвиш ошбу бәетне укый. Шигырь:

Кабызылган ут, әйдә, барсын алга!
Аһ, кайгы мәзлумнар өчен! Кайчан
Яшәү азыгы бирәсе урында,
Аларны дар агачы көтә.

Рәхимхан моннан әсәрләнеп, кайгыга төшеп, мең бер йөз җитмеш икенче (1759) елда җомга көн ундүртенче рәҗәбтә вафат булды. Каберлек ишеге тышында Әбү-Бәкер Тархан кабере янында күмелде. Мең бер йөз егерме җиденче (1715) елда туып, кырык биш ел гомер итте. Унике ел падишаһ булып торды. Чиксез залим һәм җәберләүче булып танылган. Намаз, ураза кебекләр белән күп эше булмаган. Алар урынына хезмәтчеләренең берсенә карап: «Колым, сине азат иттем», – дип әйтү белән чикләнә икән. Янында булган кешеләрнең киеме астына чаян кереп, кат-кат чакса да, Рәхимханнан куркуыннан чыраен сыту, йөз җыерудан башка һичбер хәрәкәт кылмыйча чыдап, Рәхимхан моның сиясе килгән яки башка бер хәл булырга кирәк дип сынау өчен, берәр эш кушып, чыгу белән чишенеп чаянны үтерә торган булганнар. Бу хәл Рәхимханга ишетелү белән мактанып, горурланып:

«Бу урын – шундый урын, монда хәбәр китерергә
Җәбраил юк», –

диюе халык телендә сөйләнә.

Аннан – кызы ягыннан оныгы Фазылхан бине Нәрбүтә-бәк бине Бәдел-бәк бине Хәким аталык. Даниал берничә көн хан исемен алып торса да, берничә көннән соң, ата-анасы белән бергә, Нәсәфкә җибәреп, яшәү өчен җир һәм кирәк кадәр акча билгеләде. Рәхимханның атасы белән бертуганның углыннан һәм үзенең кызыннан туган оныгы иде.

Аннан – [Даниалның] бабасы белән бертуганы Даниал бине Ходаяр бине Ходайколый берничә вакыт Нәсәфтә хаким, Мавәраәннәһердә әмирләрнең әмире, мең бер йөз илле тугызда (1746) Надиршаһ тапшыруы буенча Кирман әмирлеген дә үзенә алды. Мең бер йөз туксан икедә (1778) вафат һәм Нәкышбәнд каберлеге янында күмелде. Аның заманында кушбиге һәм казый Низаметдин, халыкка золым итеп, ап-ачык бозыклыклар һәм тыелган гөнаһлы эшләрдән тартынмыйлар, хәтта падишаһ каршына исерек килеш баралар иде. Бу эш базарларда һәм гомумән халык арасында билгеле, ә әмир Даниал үзе бу эшне тыюдан гаҗиз иде. Беркөнне Шаһморат, яшерен рәвештә, атасына әйтте: «Мәмләкәт һәм аның барлык килере кушбиге кулында. Без мохтаҗ. Бу турыда нинди чара күрәсез?» – дип. Даниал: «Мин дә бу хәлне аңлыйм, ләкин чарасын таба алмыйм», – диде. Шаһморат: «Чарасын мин беләм», – дип, Хокидтән илче килгән чакта, бер сылтау белән кушбигене чакырып чыгарып, яшерен бүлмәдә әзер торган палачлар, үткен пычаклар белән карынын ярып үтерделәр. Бу вакыйгадан бер ел үткәч, казый Низаметдинне да шулай эшләде. Туксанынчы (1777) елларның ахырында булса кирәк, Шаһморат белән Даниалның казыйга тагын бер кинәләре бар иде. Бервакыт Шаһморатның йөк ташып йөргән чакларында, Даниал углыннан казыйга зарланды. Казый: «Әлхәмдүлиллаһ, ничә акыллы, үткен угылларыгыз бар. Бу исә патшалыкка кимчелек һәм хурлык китерә. Бу дивананы юк итсәгез, бер зыян да юк», – диде. Бу сүздән Даниал кайгыга төште, аны Шаһморат та белеп, кинә тотты. Казый да куркып калып, Даниал алдында гафу үтенде, аңа сыенды, ә Шаһмораттан саклана иде. Мәгъсум, Мәхмүд, Гомәр, Фазыл, Солтанморат, Рөстәм, Кәнҗгали, Ягъкуб, Туктамыш, Дәрвиш, Рәҗәпгали исемле унбер углы калды.

Әл-әмир Мәгъсум бине әл-әмир Даниал. Аннан – углы әмир Мәгъсум (Шаһморад би дип танылган). Атасының васыяте буенча Бохарада хөкемдар булды. Суфи кыяфәтле, дәрвиш сурәтле иде. Шәех Сафар исемле кешегә мөрит булды. Шәех: «Син – залим, залим баласы, ничек риазәткә, шәехләргә хезмәткә

чыдарсың?» – диде. Шаһморад, үзенең турылыклы булуына ант итеп, халык каршында түбән һәм хурлыклы санала торган хәммальлек[1] кылыр иде. Атасы гаепләп, тыеп, сиңа кирәк кадәр хәзинәдән дә бирелер дисә дә, кабул итмичә, бер ел хезмәт итеп, шәехе каршында үзен аклады. Моннан соң дәүләт эшләренә катнашып, изгелек белән боеру, начарлыктан тыю йөзеннән кушбиге белән казыйны үтертте. Бу хәл туганнары күңеленә курку салды. Атасыннан соң Бохараның мөстәкыйль падишаһы булды. Вәзире – Уткүр суфи, казыйсы – мирза Фазыл, сакчылары – Мөхәммәдәмин исемле тупчы башы, кызлар агасы хуҗа Садыйк исемле кешеләр иде. Бер елдан соң туганы Туктамыш би кушуы буенча, Фәридун исемле хезмәтчесе бер кичә йөзенә пычак салып, җанына зарар килмичә, Туктамыш Чаржуйга сөрелде, ә Фәридун үтерелде. Мәрвә Шаһҗан хакиме Бәйрәмгали хан һәм Хоканд хөкемдарлары белән Даниал би араларында дуслык, тыныч лык хөкем сөрә иде. Бәйрәмгалине «углым» дип, Бәйрәмгали «атам» дип эндәшәләр иде. Даниал үлгәч, бүләкләр белән кайгы хаты җибәрде. Мәрвәдә Коръән чыгартты, ярлыларга аш өләште. Шаһморадка да дуслык һәм мәхәббәт сакларга теләсә дә, Шаһморад эчендә явыз ният саклап, Мәрвәне яулап алу уенда иде. Бәйрәмгалинең атасы – кажар ыругыннан, анасы Төркмәниядән салур кабиләсеннән, барлык атлы гаскәре бер мең дә биш йөз кеше иде. Шаһморад Мәрвәне алу ниятендә алты мең гаскәре белән Чаржуйга барды. Бер кичәдә Бохарага кайтканнан җасус[2] Бәйрәмгалигә хәбәр итте. Шаһморад би гаскәрләреннән мең данә атлы гаскәрләр, янәшә-тирәне талап йөргәндә, Бәйрәмгали йөз илле атлы гаскәр белән чыгып, Карахуҗаны әсир итте һәм үтертте. Әмма Шаһморад би, ахшам намазын Бохарада укып, тукталып тормастан, ашыгыч рәвештә Мәрвә тирәсенә килде һәм дүрт мең гаскәрен тирән чокыр эченә качырды. Анасы, үзенең күргән төше буенча Бәйрәмгалине тыйса да, Карахуҗаны әсир иткәч, ул: «Мин Бохараның зур кешесе һәм

---

[1] Хәммаль – йөк ташучы, грузчик.

[2] Җасус – шымчы.

Шаһморад бинең кияве», – дип алдап, алдау эшен чын кебек итеп сөйләсә дә – кабул итмәде. Шунда Шаһморад гаскәре яшеренгән урыныннан кинәт күтәрелеп чыгып, Бәйрәмгалине чолгап алды, үтереп, гәүдәсен анасына бирде, ә башы Бохарада дарда асылынып торды. Бәйрәмгалинең углы Кәрим хан аның урынына утырды. Бераздан соң Мәрвә халкының таләбе буенча туганы Хөсәен хан булып, Кәрим хан Мәшһәд шәһәренә барды. Мәрвәнең крепосте нык, әйләнәсендәге канавы тирән иде. Мәрвә шәһәреннән унике фәрсәх ераклыктагы елгага солтан Сәнҗәр Сәлҗукый бина иткән, асфальт һәм кургашын белән ныгытылган буасы һәм аны саклау өчен нык крепосте бар иде. Аны саклау өчен, бер чиновник сакчы тора иде. Көтмәгәндә, ул сакчы Хөсәен ханга ачуланып, Шаһморад бигә хәбәр итте. Ул, дүрт мең гаскәр җибәреп, буаны саклаучы крепостьны алды һәм буаны җимереп, Мәрвә сусыз калды, иген үсмәде, ачлык башланды. Хөсәен хан Кабул шәһәренә Тимершаһга илче җибәрде. Тимершаһ Мәрвәне саклау өчен, Ләшкәри хан җитәкчелегендә биш мең гаскәр җибәрде. Мәрвә өчен кирәк кадәр азыкны Һираттан китерергә кушты. Бу хәлгә Шаһморад би катнашмады. Шуннан, көтмәгәндә, Хөсәен хан белән Ләшкәри хан арасына суыклык төшеп, Ләшкәри хан гаскәре белән кайтып китте һәм Мәрвәдән унике мең гаиләне (йортны) күчерде. Шуның аркасында Тимер шаһның Мәрвә белән бәйләнеше бетүе Шаһморад би өчен зур уңайлык тудырды. Туганы Кәрим ханның Бохарага киткәнен ишетеп, Хөсәен хан да Бохарага барды. Шаһморад, көчләп, гаиләсенә дә Бохарага күчәргә кушып, аннан хат яздырды. Яшертен рәвештә Мәрвәгә биш мең гаскәр җибәрде. Бу гаскәр, Хөсәен хан гаиләсе чыкканнан соң, Мәрвәгә кереп, Шаһморад кушуы буенча, Мәрвәнең өлкәннәреннән биш мең кешене Бохарага күчерделәр. Бераздан тагын берничә мең кешене күчереп, барысы унҗиде меңгә җитте. Болар һәммәсе Бохарада калдылар. Шулар аркасында Бохарада кайбер яңа төр һөнәр – сәнәгать барлыкка килде. Мәрвәдә бары өч мең йорт: ике мең шигыйләр, бер меңе сөннилләр калды. Шаһморад Мәрвәгә туганнары Гомәр би белән Фазыл бине хаким итеп җибәрде. Мәрвә халкы аларны

куып җибәргәннән соң, биш мең кеше белән Мөхәммәд Әмин бине җибәреп, Бәдел мирзаны хаким кылды. Бер елдан соң углы Дин Насыйр бәкне куйды, ә Хөсәен хан, Бохарадан качып китеп, Фәтхгали шаһ хозурына Тәһранга барды. Кабул шаһы Тимер шаһ бине Әхмәд шаһ, Шаһморад бине төрле хәйлә белән Мәрвә халкын таратып, тиңдәшсез шәһәрне һәм борынгы заман әсәре булган буаны болай харап һәм әдәпсезлек кылуына ачуланып, йөз илле мең гаскәр белән Бохараны алу һәм Шаһморад бидән үч алу нияте белән Бәлех шәһәренә килде. Шаһморад һәм Бохара кешеләренә зур курку төште. Утыз мең гаскәр әзерләп, Амудәрья буенда туктап, Тимер шаһга уңыш теләү һәм буйсынырга риза булу юлын тотып, казый Әбү ән-Насыйрны берничә кеше белән берлектә, казый Фәйзуллаһ әд-Дәүләтшаһи хозурына җибәрде: ул исә Тимер шаһның киңәшчесе һәм сүзе үтә торган кешесе иде. Казый Тимер шаһга бу сугыш уеннан кайтырга киңәш бирде, һәм ул солых кылып кайтып китте. Диндар һәм галимнәрне сөя, хөрмәт итә торган кеше иде. Бу вакыйгадан бер ел үткәч вафат булды. Бохаралыларның өлкәннәре дә, гади кешеләре дә – күпчелеге: «Шаһморад би өч мең гаскәр белән Амудәрья буена килеп, Тимер шаһдан бер ай вакытны рөхсәт алып, гаскәрен һәркөн Хорасан ягына күчереп, чатырлар кордырып, кичен яшертен Бохара ягына күчереп, шул рәвешчә унбиш көн дәвам иткәч, Тимер шаһ моңа алданып, Шаһморадның гаскәре чиксез күп икән дип уйлап, куркып кайтып китте» – дип, гадәтләренчә, юк-бар сүз сөйлиләр. Ләкин Мәрхүм казый Әбү Сәгыйд Сәмәрканди: «Бу вакыйгада әмир Шаһморад бәк куркып, Сәед Шәмсетдин бине Миршаһ Бәләхине илче итеп җибәреп, түбәнчелек һәм буйсынучанлык күрсәтеп, бөтен мажараларыннан һәм явыз эшләреннән гафу үтенеп, галимнәреннән ярдәм сорады. Шуның аркасында Тимер шаһ, үз максатын үтәмичә, шәһәренә кире китте», – ди иде. Аның бу сүзе, гомумән, ышанычлы кешеләр сүзенә һәм хәлнең табигый барышына туры килә.

Тимер шаһ үлгәч, балалары арасында каршылык чыгып, углы Мәхмүд шаһ җиңелеп, илен ташлап, Тәһранда Фәтхгали шаһга барды. Аны хөрмәт белән каршы алдылар. Аның

ярдәме белән һират шәһәренә килеп, тагын җиңелеп кайтканда, төнлә адашып, Бохара ягына китте һәм ирекле-ирексез Мәрүгә килеп чыкты. Аннан Бохарага хәбәр алынып, Шаһморад би кушуы буенча Бохарага килде һәм Ак мәчет Хиабан мәхәлләсендә урнашты, һәр көн яшәр өчен дүрт Бохара алтыны бирелеп, сигез ай көткәч, Шаһморадтан бертөрле дә шәфкать булмасын белеп, ярдәм алудан өмете киселеп: «Мин инде падишаһ булу теләген ташладым, Россия һәм Рум аркылы Мәккәгә барам», – дип, мең алтын сорады. Күп көттергәннән соң, төрле илче-ярдәмчеләр аркылы рөхсәт, йөз алтын акча һәм берничә пар йөгерек ат бирде. Мәхмүд, тукталып тормыйча, тизлек белән Хивә шәһәренә барып җитте. Шәһәр башлыгы Гавәз би үзе каршы алып, көнлек алты алтын, печән, арпа, төрле җимешләр биреп, тәмам алты ай хөрмәт итте. Һәр көн үзе Мәхмүд янына барып, аның белән сөйләшә һәм юата иде. Шулчакта Мәхмүд ханның дошманы һәм туганы Заман шаһ һәм аның вәзире Рәхмәтулла ханнардан Шаһморадка ел саен алтмыш янчык акча вәгъдә итеп, шаһ Мәхмүдне таләп итеп илче килде. Шаһморад шунда ук илле атлы гаскәрне ашыгыч рәвештә шаһ Мәхмүдне алып кайтырга җибәрде. Ләкин ул, бу хәлне илчеләр килгәнче белеп, ышанычлы урынга яшеренде, Шаһморад: «Әлбәттә, шаһзадәне Бохарага җибәр, юкса сугышка әзерлән, чиксез гаскәр белән өстеңә барам», – дип, Хивәгә илче җибәрде. Гавәз би сарай кешеләре белән киңәште. Хәрәземнең аксакаллары, бигрәк тә Сәедколый би: «Шаһзадә Бохарада бервакыт кунак булып, рөхсәт белән аннан китеп, бездә кунак булды. Шаһморад үзен суфи һәм динле кеше итеп саный. Кайсы шәригать һәм нинди дәлил белән кунакны җәфа һәм хөрмәтсезлек күрсәтә. Хөкем Аллаһтан. Әгәр мәмләкәтебез тәмам харап була икән, анда да кунагыбызны бирмәбез», – диделәр. Башлык һәм башкалар барысы да моны дөрес табып, җавап язып җибәрделәр. Шуның белән бергә, шаһ Мәхмүд атасыннан соң падишаһ булып торганда, бер тапкыр фил һәм йөз данә кашимир шәл, ә икенче тапкыр унөч мең савыт кургашын, берничә шәл һәм палас, ике данә бик

кыйммәтле кылыч бүләк итеп җибәрсә дә, каршысына бертөрле дә бүләк алмады.

Мең ике йөз унберенче (1796–1797) елда Ага Мөхәммәд хан гаскәре белән изге Мәшһәд шәһәренә килеп, шәһәрне яулап алып, хөкемдары Надиршаһ нәселеннән килгән Шаһрух бине Ризаколый мирза бине Надиршаһны газаплап үтереп, иярченнәрен һәм Надиршаһ хәзинәсен алып, Мазәндранга китте. Балаларының күпчелеге Һират ягына качтылар. Аларны Мәхмүд шаһ бине Тимер шаһ хөрмәтләп кабул итте. Аннан соң, Мәхмүд шаһның рөхсәте белән Надир мирза бине Шаһрух мирза, балалары һәм иярченнәре белән, Кабул шәһәренә Заман шаһ хозурына китеп, ике углы: Имамколый мирза һәм Хәйдәр мирзаны, егерме данә сакчылары белән, Бохарага Шаһморад би хозурына җибәреп, түбәндәге гаризаны язды:

Гыйбәрәсе болай: «Барлык галәмнең ярдәмчесе Аллаһка мактау. Мәшһүр ки, безнең бабабыз Надиршаһ Бохара турында бернинди явызлык эшләмәде, ригая күрсәтте. Әбү әл-Фәез ханның кызына өйләнде. Аның тагын бер кызы Сезнең никахыгызда, әмир Хәйдәр түрәнең анасы була. Туганлык һәм кардәшлек хакыбыз бар. Сезнең атагыз белән бертуганның углы Мөхәммәдрәхим хан шаһлар шаһы Надирның дәүләте аркасында Бохарага патша булу бәхетенә иреште. Аллаһка мактау булсын, бу тәхет һәм бәхет, нәселдән-нәселгә калып, Сезгә килеп иреште. Янә галимнәргә мәгълүм һәм ачык ки, минем бабам Надиршаһ ислам динен тикшереп күргәннән соң, әһле сөннәт вәл-җәмәгатьнең[1] өстенлек алуына булышты. Кызылбаш таифәсен[2] кире кагып, мәзһәбләрен бетерде. Шул сәбәптән кызылбашлар Көрдстанда Хәбүшан дигән җирдә, бер форсат табып, ул яхшы, изге табигатьле Олуг падишаһны шәһит иттеләр. Без исә әһле сөннәт әл-җәмәгать мәзһәбенә һәрвакыт ригая кылабыз.

---

[1] Әһле сөннәт вәл-җәмәгать – ислам динендә иң күп таралган агым.

[2] Кызылбаш таифәсе – ислам динендә бер агым. Күбрәк Иран һәм Әфганстан тирәләрендә таралган. Боларны шигыйлар (шииты) дип йөртәләр.

Эшлексез һәм бозык Мөхәммәд хан Кажар хәзерге вакытта безнең илебезне җәберләп, каһәрләп басып алды, сукыр атабызны шәһит итте. Без ватаныбызны, йорт-җирләребезне калдырып качтык, күршеләребез мөселманнар ягына күчтек. Хәзер бәхетсез, гажиз туганнарым белән бергә Кабулга барабыз. Падишаһлыкның тоткалары, күз нурларым Имамколый мирзаны һәм Хәйдәр мирзаны Сезнең хезмәтегезгә, кунаклыкка җибәрдем, илләреннән аерылган бу ике гарип[1] турында мәрхәмәт-шәфкатегезне кызганмассыз, аларга гаскәр белән ярдәм итәрсез дип ышанам. Бәлки, алар Мәшһәдне Кажар кулыннан кайтарып алырлар. Әгәр Мәшһәд кайтарып алынса, акча Сезнең исемгә сугылыр, хөтбә Сезнең исемгә укылыр иде. Сез галиҗәнабка баш иеп, Сезнең кешегез булырга телибез. Вәссәлам».

Надир мирзага Заман шаһ бине Тимер шаһ үзенә лаек хөрмәт күрсәтеп, Пишавәр шәһәрендә урын бирде һәм тиешле вазифа билгеләде. Имамколый мирза белән Хәйдәр мирза, аталарының гаризасы һәм шаһ Мәхмүднең хаты белән Мәрвә аркылы Бохарага килделәр. Шаһморад би, тиешенчә каршы алырга кушып, төгәл хөрмәт белән Бохарага кертеп, манара астында урын билгеләде. Бер ел көткәннән соң, бертөрле дә ярдәм һәм файда булмасын белгәч, вәзире Үткер суфи аркылы, мең төрле тырышлык белән, Һиратка кайтырга рөхсәт алдылар. Тупчы башы Мөхәммәдәмин кул астында Мәрүгә юнәлделәр. Ләкин Шаһморад би аларны Амудәрьяда батырып үтерергә тупчы башына яшерен боерык биргән иде. Тупчы башы шаһзадәләрне бөтенләй яраксыз иске каекларга утыртты. Алар бу хыянәтне сизеп, ике мәшек[2] табып, шуларны бәйләп кырыйга чыксалар да, тупчы башы аларны Чаржуй шәһәренә җибәреп, хәлне Шаһморадка хәбәр итте. Шаһморад би Харәземдә хан булып торган Илбарыс ханның оныгы – казах түрәсен чакырып: «Надиршаһ синең бабаңны үтерткән иде, син, Чаржуйга барып, аның оныкларыннан үчеңне

---

[1] Гарип – йортыннан куылган мескен кеше.

[2] Мәшек – су тутыру өчен сарык тиресеннән тегеп ясалган капчык, һава тутырсаң суда батмый.

ал, алар янындагы малны сиңа бүләк иттем», – диде. Казах түрәсе, Чаржуйга барып, хәким Җуйбар Аллаколый бәк кулыннан шаһзадәләрне алып, төрле газап белән һәр икесен үтерде. Шаһморад бинең бу эше чиксез кабахәт саналып, бүтәннәр каршында гына түгел, үз шәһәре галимнәре алдында да ризасызлык тудырды. Шаһморад би мең ике йөз унбишенче (1800) елда рәҗәп аеның унөчендә җомга көн кич алтмыш өч яшендә үлде. Күмелмичә өч көн торгач, углы әмир Хәйдәр Каршыдан килеп, җеназасын укып, дүшәмбе көн кич шәһәр эчендә күмелде. Өч углыннан Насыйр би Мәрвә, Хөсәен би Сәмәрканд шәһәре башлыклары иде. Шаһморад би тышкы яктан караганда гаҗәп суфи, изге, һөнәр иясе, ишанга кул биргән, шәригатьне яклаучы иде. Пычак кынын[1] үз кулы белән тегеп, шуларны сатудан килгән акчага туенып яши иде. Бохарада булган мәдрәсәләрнең вәкыфләрен тиешенчә тотып, галимнәргә хөрмәт итте. Үзе дә кечерәк бер мәдрәсә бина кылды. Бу – Гөлабад урамында «Мәдрәсәи әмир» дип йөртелә. Тупчы башы Мөхәммәдәмин «Базар хуҗа» исемле мәхәлләдә тагын бер мәдрәсә бина кылды. Хәзерге көндә гомум Бохараның аның турында карашы бик яхшы, алар Шаһморад бине һичшиксез изге һәм йөз башында килеп, динне яңартучы икәнлегендә шик тотмыйлар. Әмма үз вакытының шәехе ишан хәлифә Ниязкол Төрекмәни әл-Хәлҗи үзе өчен махсус әзерләткән ашны да ашамый торган булган. Мелла Һидиятулла әл-Гадәнани әйтүенчә, казый Торсынбакый бине Габдерәхим Бохари җирдән күләменә карап салым алу бидгатен тормышка ашырды, залим да булган. Казый Әбү Сәгыйд Сәмәрканди әйтүенчә, ишан Муса хан бине Гайса Дәһбиди бервакыт иярченнәре белән бер җиргә барганда, Шаһморад би дәүләт ирләре белән бергә килеп җитә. Шунда Муса хан, ишан җөббәсен күтәреп, йөзен каплап, читкә карап калган. Сәбәбен сорагач: «Залим мине күрмәсен һәм күзем йөзенә төшмәсен», – дип шулай эшләдем дигән. Кайбер саф кешеләр «залим ир» сүзен аның вафат тарихы иткәннәр. Әлеге казый Әбү Сәгыйд

[1] Кын – савыт, пычак тыга торган савыт.

карашынча, пәйгамбәр нәселеннән килгән сәед Низаметдин казыйны үтертүдә дә ул хаклы түгел иде. Шуның кебек бүтән начар эшләре дә булды.

Аннан – углы әмир Хәйдәр. Атасының җеназасыннан соң сарайга кереп, тәхеткә утырып, рәсми рәвештә патша итеп танылды. Атасының ахыр гомерендә араларына суыклык төшеп, Карши шәһәренә башлык ителгән иде. Үткер суфи димләве буенча, тәхет варисы итеп билгеләнде. Үлү белән, Үткер суфи һәм кызлар агасы Хуҗа Садыйк, барлык сарай өлкәннәрен берләштереп, мәетне сарайда саклап, Каршига әмир Хәйдәргә хәбәр җибәрделәр. Җомга көн иртә белән бу хәл шәһәр халкына беленеп, Гомәр би, Мәхмүд би, Фазыл би, коралланган иярченнәре белән Регистанга килеп, Гомәр би җомга вакытына чаклы сарайга һөҗүм итсә дә, тупчы башы Мөхәммәдәмин һәм казый Фазыл җыелган халыкка: «Әмир хәзрәтләре баш күтәрүчеләрне таларга боера!» – дип кычкырып, Гомәр бинең йортын һәм малларын үзе таларга керешсә дә, җиңелеп, Миянкәл ягына китте. Әмир Хәйдәр Үткер суфины кушбигелектә калдырып, углы Хәким бине Карши шәһәре башлыгы итеп билгеләде. Гомәр, Фазыл, Мәхмүд биләр һәм Кирмәния башлыгы Кияү Хуҗа берләшеп, Пәнҗешәмбе һәм Кәттә Курган шәһәрләрен алып, фетнәче булдылар. Сәбез Нияз шәһәре башлыгы Гали бәк тә аларга кушылды. Әмир Хәйдәр алар өстенә баргач, качып, Кияү Хуҗа Сәбез шәһәренә, Мәхмүд би Хокандка киттеләр. Гомәр һәм Фазыл биләр балалары һәм иярченнәре белән кулга алынып үтерелделәр, моннан соң Хөсәен бинең Сәбез һәм хокандлылар белән бер сүздә булганлыгы турында хәбәр таралып, кулга алынып, Бохарага китерелде. Инкяр итеп ант иткәнлектән, берничә хезмәтчесе үтерелсә дә, үзенә шәфкать күрсәтелде, һәм бөтен кешеләрдән аерым урынга куелып, көндәлек азык өчен акча билгеләнде. Аның урынына кушбиге Сәмәрканд башлыгы итеп җибәрелде. Шул арада Хажи Хөсәен хан һәм балаларын, аның туганнары Кәрим хан белән Мәһди ханны, Бәйрәмгалинең туганы Арслан бәкне һәм аларның иярченнәрен «Бабе Имам» тышында куй кебек суйдырды, ә хатыннарын һәм сабый

балаларын үзенең гаскәрләренә бүләк итте. Вә халәнки аларның һичбер гөнаһысы мәгълүм булмады. Кардәше Дин Насыйр бине чакырып китереп, ул һичбер хөрмәт һәм олылау күрмичә кайтып китте. Икенче мәртәбә чакыргач, әмир Хәйдәрнең явыз ниятеннән куркып, бераз сакланганнан соң, Мәрвә кешеләреннән бер төркем белән Мәшһәдкә – Мөхәммәдвәли мирза каршына барды. Мең ике йөз утыз өчкә (1818) чаклы торып, Мөхәммәдвәли мирзаның атасы Фәтхгали шаһка алдан белдереп, һәр ел бер тапкыр аның янына Тәһранга бара иде. Мең ике йөз кырык биштә (1829) Истанбулга, мең ике йөз кырык алтыда (1830) Мәскәүгә барды. Мең ике йөз илленче ел ахырында Петербургта үлде. Батыр, сугышчан, оста атучы иде.

Әмир Хәйдәр мең ике йөз унтугызда (1804–1805) Ура Түбәгә барды. Башлык булып торган би төрле бүләкләр белән каршы алды. Аннан соң котыртып, кеше канын коюда ялган гаеп ташлап үтертте, шәһәрне алып, Үткер суфи углы Кабил бәкне анда башлык итеп билгеләде. Халык аның [әмир Хәйдәрнең] бу эшенә бик рәнҗеде. Шул елны Мир Галәветдин исемле кешене Мәскәүгә илче итеп җибәрде. Мең ике йөз егерме беренче (1806) елда Харәзем хөкемдары Илтөзәр хан Бохара тирәләрен талап, илле мең куй һәм берничә мең дөя алып китте. Тагын килде. Бохарада тынычсызлык һәм таркалыш туды. Әмир Хәйдәр Харәзем өстенә утыз мең гаскәр җибәрде. Илтөзәр хан унике мең гаскәр белән Амудәрьяны үтеп, Бохара ягына чыкты. Ләкин Бохара гаскәрләре килеп җиткәндә, әзер булмаганга күрә, халык буталып, Илтөзәр хан каекка кереп, моны күргәч, һәммәсе каекка һөҗүм итеп, каек батып, һәммәсе һәлак булды. Су өстен кара бүрек каплаган бу вакыйгада Илтөзәр хан үзе, гаиләсеннән Хәсәнморад бәк, Җанморад бәк үлеп, туганы Котлыгморад бәк һәм сарайның башка өлкән кешеләре әсир булдылар. Бер атна үткәч, бик каты ант иттереп, Котлыгморадны Харәземгә башлык итеп җибәрде. Ләкин Харәзем халкы риза булмыйча, туганы Мөхәммәдрәхимне хан кылдылар. Котлыгморад әмир Хәйдәргә: «Мин вәгъдәмә турылыклы һәм антыма хыянәт итмәдем. Әмма халык: бае-ярлысы, галиме-изгесе – бөтен мәмләкәт кардәшем

Мөхәммәдрәхимгә бәйгать биреп, мин кайтканчы хан итеп куйганнар. Мин катнашым, игътибарым һәм чарам юклыктан риза булдым», – дип хат җибәргән. Бу вакыйгадан соң әмир Хәйдәрнең солтан Мәхмүд бине Габделхәмид Госманига күпертеп мактанып язган гаризасыннан бер нөсхә күчереп алган идек, хәзер югалды.

Шаһ Мәхмүд бине Тимер шаһ туганнарын җиңеп, Кабулда падишаһ булганда, Заман шаһ сукырайган, өлкән, акыллы һәм галимнәр белән утырдашлыкны яратучы иде. Туганы Мәхмүд шаһның акыллы тәкъдимен кабул итеп, аңа буйсынды. Мәхмүд шаһ зурлап, тулысынча ригая һәм хөрмәт күрсәтеп, көнлек вазифа билгеләде һәм һәрбер теләге үтәлә иде. Моннан соң, рөхсәт белән, меңике йөз утыз бердә (1816) балалары, хезмәткәрләре, иярченнәре, филләре белән Бәлех шәһәренә Шаһмәрдән каберенә зиярәткә килде. Бәлех хөкемдары Кылыч Нали хан, каршы алып, олылау, хөрмәт белән кунакчыллык күрсәтте. Егерме көн үткәч, әмир Хәйдәрнең чакыруы буенча Бохарага килде. Әмир аңа зурлау һәм хөрмәт күрсәтеп, айлык ике йөз алтын билгеләде. Кичәләрдә янына барып юатыр иде. Шаһзадәнең ундүрт яшьлек кызы бар иде. Аны әмир сорады, ә шаһзадә бирергә теләмәде. Ахырдан әмир: «Кызга кияү кирәк. Миннән артык кияүне кайдан табасың? Буйга җиткән кызны шәһәрдәншәһәргә алып йөрү шәригатькә сыймый. Аның өчен Бәлехне алып сиңа бирермен», – диде. Шаһ Заман әмирнең көчләп алачагын уйлап, урынсызга Бәлехкә кызыгып, борчылып, язмышка буйсынып, кызын бирергә риза булды. Әмир кыз өчен егерме меңә Бохара алтыны торырлык кием-салым һәм бүтән кирәк-ярак әзерләде. Әмма кыз бу киемнәрне кимәде, кирәк-яракка кызыкмады, үзенең киемнәрен, энҗе-мәрҗәнгә баткан әйберләрен чыгарды. Бохаралылар, моны күреп, ис-акыллары китте. Шаһ Заман берничә вакыт Бохарада торып күрде: «Барабан тавышын тыңлаудан кире китү яхшырак» дигәнчә, һичбер ярдәм, яхшылык һәм ригая юк. Өметсезләнеп Һиратка кайтты. Әмир Хәйдәрнең соңгы елларында Харәзем һәм Сәбез ханы Мөхәммәдрәхим хан, Кытай һәм кыпчак кабиләләре, әмир Хәйдәргә каршы союз

төзеп, сугыш булып, зур буталыш, куркуга төшеп, ахырда дошманның һөҗүмен кире кайтарып бераз тынычлангач, күп тормыйча, гомере бетеп, мең ике йөз кырык икенче (1826–1827) елда рабигыль-әүвәл аеның өчесендә чәршәмбе көн вафат булып, җеназасын казый Әбү әл-Хәсән бине Госсам укыды, вәзире Хәким кушбиге бина иткән, «Мәдрәсәи Галия» дип танылган мәдрәсә янында бер бүлмәгә күмелде. Анасы Шәмсемаһ Әбү әл-Фәез кызын, Рәхим ханнан калгач, Шаһморад би алган иде. Шуңа күрә патшалыгының элекке елларында кулланган йөзегендә[1] түбәндәге шигырь язылган иде:

Чыңгыз нәселе, пәйгамбәр гаиләсе, урыны газиз шәһәр Мәгъсумнең[2] варисы, сугышчан падишаһ.

Икенче мөһердә:

«Әбү әл-Фәез хан шәһит булгач, шаһның тәхете Хәйдәр кулына күчкән», – дип язылган иде. Шуңа күрә үзенең Чыңгыз һәм пәйгамбәр нәселеннән булуын дәгъва итеп, Әбү әл-Гази хан исеменә хөтбә укуны һәм акча сугуны туктатып, барысын үз исеменә авыштырды. Тик җомгаларда имам торганда: «Я Аллаһ, мәрхүм бөек әмиргә рәхмәт ит», – дип, атасына дога кыла иде. Ишан хәлифе Ниязколый бине Балта суфи әт-Төрекмәнинең җеназасында әзер булды. Шулай ук мәчеттә үзенең урынбасары хәлифә Базар әл-Миян Кяли үлгәч, җеназасында әзер булып, кабере өстендә «Сүрәи Мөлек»[3] не укыды.

Хөсәен хан, Гомәр хан, Габдулла хан, Насрулла баһадир хан, Зөбәер хан, Җиһангир хан исемле угыллары калды. Әмма алардан риза түгел һәм араларында дошманлык, бер-берсен күрә алмау хөкем сөрә иде. Атасы исән чакта, Карши башлыгы булып торганда, мелла Мирекҗан ән-Нәфәсидән укып, мелла Фәхретдин бине Ибраһим Казанидан Коръәнне дөрес укырга өйрәнде, «Коръәнне күңеленнән белә», – дип, халык телендә сөйләнә. Гәрчә дәүләте кечкенә, чикләре тар, башкаларны

---

[1] Яки ригаятендә.

[2] Мәгъсум – әмир Хәйдәрнең атасы Шәйморат бәкнең исеме.

[3] «Сүрәи Мөлек» – «Тәбарәк» сүрәсе.

буйсындыру өчен көче аз һәм зәгыйфь булса да, эшләрендә Габбаси хәлифәләр, бигрәк тә Һарун Рәшидкә иярә, солтан Мәхмүд бине Габделхәмид Госманине хәлифә дип танып, аңа буйсына иде. Хатыннар белән күп катнашкан. Ишеткән кызларын китертеп, бер кич кунып, иртәгесен талак итә иде. Хәтта Кабулның шаһ Заман, Хәсар шәһәре башлыгы Сәед би, Сәбез шәһәре башлыгы Садыйк би һ.б. шундый дәүләтнең өлкән һәм югары дәрәҗәле кешеләренә карата да шулай мөгамәлә итте. Галимнәргә, шәкертләргә мәхәббәте зур иде. Алар белән утырдаш булырга, катнашырга ярата, зәкят бирә иде. Аларны укыта һәм берничә көннәр шәкертләрне сараена җыеп, аларга дәрес бирә, аралаша, китап укый иде. Мәхзүм казый Гани дип мәшһүр мелла Габделгазиз бине Габделгани, мелла Хаҗи бай бине Сафар әл-Хөҗәнди, Мөэмин Хуҗа әл-Вабикинди, мелла Хөснетдин бине Бәшир Түнтәри, мелла Габделгаффар бине Сәгыйд Шырдани[1] һ.б. шундый галим, пакь һәм үткен зиһенле кешеләрдән дәрес алып, аларның дәресләренә күп кеше җыеп, гыйлем һәм олылык белән мәшһүр булды. Мелла Һидиятулла әл-Голананинең әйтүенчә, дәресләре буш һәм сай булып, шәкертләре авызыннан чыккан һәрбер җөмләне эләктереп алып, киңәйтеп, җәеп, бәхәс һәм җавабын күбәйтеп бәхәсләшә һәм сүз көрәштерә иде...

Үзе бер кечерәк мәдрәсә салдырып, ул мәдрәсә «Мәдрәсәи Әмир» һәм «Галичә» дип танылды. Мең ике йөз егерменче (1805) елда сәүдәгәрләрдән мелла Түр Сәнҗан исемле кеше зур бер мәдрәсә салдырырга керешкәч, вафат була һәм әмиргә мәдрәсәне тәмам итәргә васыять әйтеп калдыра. Мәдрәсә атабыз Бохарага килүнең беренче елларында эшләнеп тәмам була. Шул мәдрәсәдә бер бүлмә биреп, мәгърифәт учагы ясап, мәҗлесендә Хафиз, Сәгъди, Нәваи, Фөзүли һ.б. шундый төрки һәм фарсы шагыйрьләренең диваннарыннан һәм башка китаплардан файдаланып, берничә аңлы кешеләр белән гыйлем мәҗлесләре ясап, китап укып, атабызны үзенә якын итеп, мөдәррис булырга

---

[1] Бу Түнтәри, Шырданилар Казан ягыннан барган укучылар.

тәкъдим итсә дә, ата-анасы риза булмаганлыктан, әмирнең рөхсәте белән элекке урынына кайтты. Әмма әмирнең кайбер ярдәме һаман тиеп торды. Бу илгә кайткач та, аны эзләп табып, бер яхшы бәнарис чапан җибәреп, атабыз Ябынчыда вакытта мең ике йөз утыз икенче (1817) елда тапшырылды. Ул вакыттагы Казан галимнәреннән мелла Габделгаффар бине Сәгыйд Шырдани һәм кардәше мелла Габдессәттар ахуннарга да берәр кием җибәрде. Каргалы галимнәренә, Казан өлкәсендәге мелла Фәхретдин бине Габдерахман Бәхтиярига төннең кыска вакытында да ястү намазы укылырга тиешлеге турында фәтва биреп хат язды. Хөрмәтле атабыз мәрхүм турында мактап дога кыла иде. Һәм өч нәрсәгә: Кияү Хуҗаны үтерүенә, ә мелла Габденнасыйр Курсавины, Галим хан Хокандинең гаскәр башлыгы Рәҗәп Каржәне исән калдыруына әмирнең үкенгәнлеген сөйли иде. Казый Келан Мәүләви үлгәннән соң, «Әмир Сәгыйд» исеме белән аталып, кайбер имамнар хөтбәдә: «Аллаһүммә-әрхәм әл-әмирә-л-кәбирә-л-Мәгъсумә вә-л-әмирә-с-Сәгыйдә-л-мәрхүм»[1], – дип телгә алалар иде.

Әмир Хөсәен бине әмир Хәйдәр биографиясе. Аннан – углы әмир Хөсәен – олы баласы. Анасы ягыннан Сәед Җуйбари хуҗаларга тоташа иде. Әмир Хәйдәр үлгәч, кушбиге Хәким, Баһадир ханга мәхәббәт итеп, яшертен рәвештә Каршига хәбәр җибәрде. Ләкин әмир Хөсәен, Бохарада әзер тәхеткә утырып, падишаһ булды. Баһадир хан Бохарага килеп җитәрәк моны белеп, өметсезләнеп кире китте. Ләкин әмир Хөсәен тиз арада агулап үтерелде. Бу кушбиге Хәким эше дип уйлана. Әмир Хөсәен батыр, һиммәтле, бик юмарт, тумыштан ук үткен, олы җанлы, акыллы, аңлы, сәйяхләрнең дусты, юлчыларны хөрмәт итүчән, халкын сөя торган, китап җыючы кеше иде. Атасы исән чакта бераз вакыт Кирманиядә, бераз вакыт Сәмәркандта башлык булып торды. Яшертен күп изгелекләр кыла, бүләкләр өләшә иде. Мирза Габделкәрим бине Исмәгыйль Бохариның әйтүенчә, биш йөз, хәтта мең данә Бохара алтынын гади

[1] Я Аллаһ, өлкән әмир Мәгъсумгә һәм мәрхүм әмир Сәгыйдкә рәхмәт ит.

кешеләргә бирә иде. Шуңа күрә атасы ризасызлык күрсәтеп, дәрәҗәсен төшереп, Кирмания башлыгы итеп куйды. Ун меңдинар килере чыгымын каплый алмый иде.

Шуның өстәвенә, аңа ачу итеп, Баһадир ханга мәхәббәт итте, аңа өстенлек биреп, үзе урынына тәхет варисы кылды.

Мелла Хөснетдин бине Бәшир Түнтәри, мелла Хөсәен бине Мөхәммәд Каргалый һәм башка күп кешеләрнең сөйләвенә күрә, әмир Хөсәен күркәм холыклы, тугрылыклы, күркәм сыйфатлы кеше иде. Әмма мәрхүм казый әбү Сәгыйд Сәмәрканди: җиңел акыллы, нәшьәгә[1] ияләнгән, эшендә тотрыксыз, куркак, падишаһларга килешми торган бозык тәдбирле иде, хәтта үзбәкләр Сәмәркандны чолгап алгач, куркып, сугышсыз качарга уйлаганда: «Мин саклап калдым», – ди иде. Дөресен Аллаһ белә. Ике ай ярым үткәч, меңике йөз кырык икенче (1827) елда җөмадиел-әүвәл аеның егермесендә Бохарада үлде.

Әмир Гомәр биографиясе. Аннан – кардәше әмир Гомәр. Кардәше исән чакта, Кирмания башлыгы иде. Әмир Хөсәен яшәүдән өмет өзгәч, Баһадир хан әмир булса, бөтен балачагаларын һәм кардәшләрен үтереп бетерер дип куркып, Гомәр ханны чакырып, Баһадир хан һәм Хәким бигә каршы буларак, Бохарага якын бер урында торырга кушты. Әмир Хөсәен үлү белән Бохарага кереп, тәхеткә утырды, таҗ киде. Ләкин патшалык урынында нык тора алмады, һаман аракы эчеп, уен-көлке белән көн уздырып, дәүләт эшләрен башкару һәм патшалыкны саклау турында уйламады. Баһадир хан Нәсефтән чыгып, Сәмәркандка килде, һәм, күп санлы халык белән килеп, Бохараны чолгап алды. Шулчакта да исерек, хәтта мелла Нәгыйм бине Ниязколый Төрекмәнинең әйтүенчә, беркөнне рамазан аеның көндезендә сугышны караргa чыкканда да исерек булган. Хаким кушбиге хәйләсе белән, шәһәрнең бер капкасы ачылып, Баһадир хан Бохара шәһәренә кереп, әмир Гомәр аналарының берсе йортына яшеренде, шуның ярдәме белән үтерелмичә калып, Хуҗа хан дип йөртелгән казый Мөхәммәд Шәриф бине Гатаулла хуҗа

---

[1] Нәшьә – исертә торган үлән, тәмәке кебек тарталар.

бер атка үзенең артына атландырып Гаректән чыкканда, халык кием-салым һ.б. әйберләрен талап алып, бернисез калды. Ике көннән соң чыгып китеп, Һиратка барды, Кямиран шаһ бине Мәхмүд шаһга килеп торып, бераздан соң аның рөхсәте белән Фирганә патшасы Мөхәммәдгали хан янына Хокандка килде һәм мең ике йөз кырык биштә (1830) вабадан үлде. Табуты Бохарага китерелеп, Мәзаре шәрифтә бабасы Даниал би янында күмелде. Фәкать бер кечкенә баласы калып, анысы да тиздән үлде. Әмир Насрулла падишаһның, җеназа укып күмсен дип, мелла мирза Салих бине Нәдер әл-Хөҗәндине җибәргәнлеге халык телендә сөйләнә. Бохараны әмир Насрулла чолгап алгач, әмир Гомәр тарафыннан аны баш тартучы, дәүләт тәртибен бозучы фетнәче, бәлки кяфер дип фәтва төзелгәч, мелла мирза Салих шул фәтвага мәһәр басып, кул куючылардан иде. Шуңа күрә әмир Насрулланың бу боерыгы бер мыскыллау, хурлау һәм кимсетү. Юкса җеназасы укылган, череп беткән мәеткә янә җеназа уку нигә кирәк?

Әмир Насрулла бине әмир Хәйдәр биографиясе. Аннан – кардәше әмир Насрулла Баһадир хан. Анасы – әмир Хәйдәрнең күркәм, үткен һәм сөекле җариясе иде. Әмир Хөсәенгә үч итеп, Баһадир ханны яклаган һәм Бохарада үзенең урынбасары кылган иде. Бохарада падишаһ булгач, туган һәм кардәшләрен тәмам бетерде. Зөбәер һәм Җиһангир түрәләрнең аналары Җуйбари хужалар нәселеннән иде. Аларны Чаржуй ягына җибәреп юк иттерде. Дәүләт олыларыннан кушбиге Хәким, Гыйсмәтулла бәк, Гаяз бәк һәм башкаларны үтертеп, малларын талап алды. Мең ике йөз илле өчтә (1828) Кабул шәһәрен инглизләр килеп алгач, әмир Дустмөхәммәд хан җиңелеп куылып, Бәлехкә килде. Бәлех хөкемдары аларны олылап каршы алды, кадер-хөрмәт эчендә бераз торгач, әмир Насрулла чакыруы буенча, өч мең кешелек юлдашлары, балалары һәм якыннары белән Бохарага килде. Углы Афзал хан күркәм йөзле, төз буйлы иде. Әмирнең моңа күзе төшеп, үз янына алуны сорап кеше җибәрде. Әмир Дустмөхәммәд хан моңа бик нык гарьләнеп, әфганлыларга хас булган гайрәт һәм хәмиятенә таянып бирмәде. Ике арага көчле

суыклык төште. Хәтта Дустмөхәммәд хан үзе белән бергә булган балалары һәм иярченнәре белән көтмәгәндә сарайга һөҗүм итәргә җыеналар дигән хәбәр таралды. Әмир Насрулла Дустмөхәммәд хан бүләк иткән филне кире үзенә кайтарып җибәрде. Дустмөхәммәд хан, хаҗга китәргә рөхсәт алып, якыннары белән шәһәрдән чыгып киткәч, әмир Насрулланың, кешеләр җибәреп, Амудәрьяга батырып үтерергә теләгәнен сизеп: «Безне үтерергә теләсә, шаһидлар каршында шәһәрендә үтерсен, әмма болай хыянәт белән үтермәсен», – дип, Бохарага кайттылар. Бераз вакыт шулай кадерсез, игътибарсыз, хурлыклы төстә Бохарада торып, каны кайнап, рөхсәтсез чыгып китеп, Сәбез шәһәренә җиткәндә, әмир Насрулла җибәргән гаскәрләр куып җитеп, бер бакчага кереп камалып алыналар. Шунда сугыш булып, һәр ике яктан күп кеше үтерелә һәм каһәрләп аны алып кайталар. Моннан соң Дустмөхәммәд хан бик ярлылана, ялгыз кала, Миркян мәхәлләсендә Сахибзадә ишан янында вакыт уздыра башлый. Тагын үзенең кирәк-ярагын, якыннарын әзерләп, хатын-кыз киеме киенеп, кичен, шәһәр капкасы ябылганчы качып чыгып, Сәбез шәһәренә килә. Шәһәр хөкемдары Хуҗәмкол би аны кадер-хөрмәт белән каршы алып, теләгән җиренә озатты. Дустмөхәммәд ханның дәүләте кайтып, Кабулда падишаһ булып, Һират, Бәлех, Кандәһар һәм аларның өлкәләрен яулап алып, инглизләр белән килешкәч, әмир Насрулланы каты курку алды. Әмир Насрулла, Дустмөхәммәд хан җиңелгән һәм әсир төшкән вакытында, гаскәр белән барып Бәлехне алып, хөкемдары Салих хуҗаны тотып, малын талап Бохарага алып кайтып, төрле юллар белән газаплап үтерде. Меңике йөз илле алтынчы (1841) елда Фирганә хөкемдары Мөхәммәдгали хан белән араларында Бишагыйрь исемле крепостьны төзү турында дау чыкты. Ул чакта әмир Насрулла мәмләкәтендә булган берничә йөз Иран әсирләреннән тәртипле гаскәр төзегән иде. Ул тирәдә тәртипле гаскәр Бохарадан бүтән җирдә бер дә булмаганга күрә, җиңеллек белән Бишагыйрьне, аннан Уратүбә, Хөҗәнд шәһәрләрен алып, Сырдәрьяны үтеп чыгып, Фирганәнең башкаласы Хоканд шәһәренә керде. Мөхәммәдгали ханны, туганы Мәхмүд ханны,

аналарын, бала-чагаларын, сарай өлкәннәрен үтертте. Хокандта ун көн торып, Сәмәрканд башлыгы Ибраһим Пәрванече исемле мангытны бик зур, хәтта үлемгә хөкем итү хокукын биреп, Хокандка башлык итеп куеп, рабигыль-ахирдә Бохарага кайтты. Ул [Ибраһим Пәрванече] Хоканд кешеләреннән бик күпләрне үтертте, әрәм итте. Кыскасы, бу вакыйгада бохаралылар табигатьләре теләгәнчә бозыклык эчендә коеныр, гыйффәтле хатыннарны мыскыл итеп, өй эчендәге хатын-кызны кырып, кеше үтерүне тәмам чигенә җиткереп, канга сусауларын канәгатьләндерделәр. Сугыш вакытында кылган вәхшилекләреннән тыш, ничә-ничә сабый балаларны, гөнаһсыз хатын-кызны юк кына сәбәп белән хайван урынына яткырып суйдылар. Әмир горурлык, тәкәбберлек, ерткычлыкның тәмам чигенә чыгып, инде миңа берәү дә каршы тора алмый икән дип, ә Бохара кешеләре дә: «Әмир хәзрәтләре бөтен дөньяны яулап алыр: хәзер рус өстенә, аннан Истанбул өстенә йөрер», – дип колакны тондыралар иде.

Моннан соң Фирганә халкы бохаралыларның ялган шөһрәт белән горурларыннан куркудан уянып, үзләренең җиңел караш һәм кимчелекләренә үкенеп, икенче фикергә килделәр. Элекке дәүләт һәм хәлләрен исләренә төшереп, кыпчак кабиләсеннән Мөселманкол исемле кеше үтерелгән ханның атасы белән бертуганның углы, күчмә тормыш белән яшәүче Ширгали бине Хаҗибәкне хан күтәреп, аның шөһрәт һәм тантанасыннан бөтен Хоканд һәм Фирганә халкы шатланып, берләшеп Хокандка килеп кереп, Ибраһим Пәрванече хур булып качып котылды.

Әмир Насрулла Фирганәнең хөкемдары, сарай халкы, дәүләт кешеләре, хәзинә һәм сугыш кирәк-яраклары төгәл чакта бик ансатлык белән җиңә алганлыктан, хәзер аларны бастыруны бернигә санамый, бөтенләй үтереп бетерү уе белән икенче кат барса да, ул уйны үтәү кайда? Бер ай кадәр ятып, гаскәре бозылып, зәгыйфьләнеп, җиңелеп, бернәрсәсез кире кайтты. Тагын ике мәртәбә шулай барса да, теләгенә ирешә алмады. Ахыргы сәфәрендә Уратүбә өстенә барганда, Мөселманкол (Аксак), дүрт кешене илче итеп, алар янына тагын ике

кеше кушып, аларга тагын ике кеше кушып, кулларына берничә хат тоттырып: «Әмир сорагач бирерсез», – дигән. Әмма дүрт илчегә: әмир Насруллага барып җитү белән: «Без, илче, дүрт кеше. Әмма юлда безгә ике кеше юлдаш булды, кем икәнлекләре безгә билгесез», – дип әйтергә кушкан. Әмир Насруллага барып җитү белән хәлне сөйләп, шунда ук тикшерелеп, хатларның берсе Сәбез шәһәре башлыгына, калганнары әмирнең кайбер гаскәр башлыкларына адресланган булып, «килешү буенча, без арттан Баһадир хан гаскәрләренә һөҗүм итәрбез, сез дә анда вәгъдәгезне үтәгез» дип язылган икән. Бу хатны укып, шунда ук ул ике кешене үтертеп, куркып, ат ташлап чабып, Бохарага кайтты. Моннан соң Фирганә кайгысы бетеп, Сәмәрканд һәм аның тирә-юнен саклау фикеренә төште. Мөселманкол, бу хәйләсе белән теләгенә ирешеп, Ширгали хан исеменә бөтен Фирганәне кулына алды. Шул вакытларда әмир Насрулланың сакалы агарды. «Хоканд картайтты» дигән сүзе халык телендә мәшһүр иде. Шул чакларда Харәзем хөкемдары Аллаколый хан бине Мөхәммәдрәхим хан килеп, Бохара кул астындагы җирләрне талап, күп әсирләр һәм маллар алып китте. Икенче елда әмир Насрулла, Чаржуй крепостеннан үтеп, Аллаколый хан өстенә барып, «Фетнәк» исемле урынны алды, әмма сугышта әсир төшкәннәрне үтермәде, бәлки аларга акча өләште. Моннан Харәземгә курку төште. Ләкин азык-төлек, кирәк-ярагы җитәрлек булмаганга ачыгып, гаскәре таркалып, «Һәзарәсәб»не камалап торуны ташлап кайтты. Кайтканда, артта калган Урда базар кешеләрен күреп, «артыбыздан харәземнәр килеп җитте» дип куркып, бинокль алып карамакчы булганда, куркуыннан биноклен күзенә куя алмаганга, күзенә яшь килеп, «Әҗәлебез монда икән» дигәне халык телендә сөйләнә.

Мең ике йөз илленче (1835) елда Һиндстан ягыннан Габдессамад Тәбризи исемле кеше Бохарага килде. Ул бик галим, олы җанлы, гаять һөнәрле, үткен зиһенле кеше иде. Аның димләве буенча мәмләкәттә булган Иран әсирләрен ияләреннән сатып яки башка юл белән алып, җыеп, ике йөз кешедән инглиз ысулы белән тәртипле гаскәр төзеп, яңа системалы туп һәм

мылтыклар коеп, туп арбалары ясатып, башка кирәк-яраклар әзерләп, атларны өйрәтеп, саны аз булса да, яхшы һәм тәртипле гаскәр төзеде. Бер яктан, шул сәбәпле, икенчедән, фирганәлеләрнең ваемсызлыгы аркасында, Фирганә җирен биләп торган үзбәк дәүләтен пыр туздырып, ахырдан ул дәүләтнең бетүенә һәм читләр кулына төшүенә сәбәп булды. Шушы Габдессамад өйрәтүе буенча шәһәре Сәбез мәмләкәтеннән Чыракчы, Екәбаг исемле крепостьлар һәм әкренләп бөтенесе Бохара кулына керде. Габдессамад «Урынбасар» исеме алып, әүвәлдә хезмәтенә зур бәя бирелде, дәрәҗәсе югары булды. Вакыт үтү белән көнче һәм дошманнары күбәеп, төрле юллар белән әмир Насрулланың мәхәббәтен суытып, Тупханә башлыгы урынын надан бер атаманга тапшырып, Габдессамадны аның кул астына куйды. Габдессамад моңа чиксез кимсенеп, хәтере калып, араларында салкынлык, дошманлык һаман көчәя барып, әмирнең явыз ниятеннән куркып, Бохарадан качу уена килде. Сәбез шәһәре хакиме белән бер сүзгә килеп, әмир Насрулланың Сәбез шәһәренә сәфәренең берсендә иярченнәре һәм тупханәсе белән әмирдән алга китте. Әмир шикләнеп, туктарга кушып кеше җибәрсә дә, тыңламыйча юлында дәвам итеп, әмир бер төркем гаскәрен аның артыннан җибәреп, билгеләнгән урынга җитәрәк куып җитеп, Сәбез шәһәренә кергәндә зур сугыш булып, көчләп алып кайттылар. Шуның аркасында аны төрмәгә ябып, ахырдан үтертте. Мең ике йөз алтмыш сигезенче (1852) елда, ни сәбәптәндер, Ираннан Шаһрух хан бине Ибраһим хан (Мөхәммәд шаһ Каҗарның атасы белән бертуганның балаларыннан) Бохарага килде. Әмир аны әлеге Габдессамад Тәбризи хезмәтенә күзәтүче һәм каракүл бүлеген хәл итүче итеп билгеләде. Әмир Насрулла атасы заманыннан калган дәүләт эшлеклеләрен, мәсәлән, Гаяз би, Хәким кушбиге һ.б.ны юк итеп, ялгыз үзе уйлаганча эш итә, вәзире һәм киңәшчесе юк иде. Яше алтмыштан узып, мең ике йөз җитмеш җиденче (1860) ел рабигыль-әүвәл аенда җомга кичәсендә Бохарада үлде һәм шимбә көн атасы кабере янына күмелде. Үләренә өч көн калганда, Кәшия шәһәре башлыгы Мансур бәкне һәм аның кыз кардәше, үзенең никахлы хатынын

үтертте. Табигый теләкләренә чиксез бирелүчән, тиз үзгәрүчән характерлы, залим, кан түгү, кеше үтерүдә, бушка мал әрәм итүдә гаять батыр, артык дәрәҗәдә үзсүзле булып, хөкем итү яки йомшаклык күрсәтү, күбесенчә, уйламый, тикшерми эшләнә иде. «Хуҗа хан» һәм «Мәүләви хан» дип билгеле булган мелла Мөхәммәдшәриф Хуҗа бине Гатаулла бине Һади – остазы һәм казый Гиляни, олылык иясе, китапны аңлый торган галиме һәм шәхси теләкләренә иң киң юл ачучысы иде. Хәтта «Дөррел-мохтар» китабыннан «Вә нисаә зәманина фиә»[1] дигән гыйбарәне язып фәтва бирүе халык телендә сөйләнә, Кенәр авылының мелла Гатаулла бине Фәез үзенең остазы һәм әлеге казый һәм мөфтинең шәкерте мелла Нияз бине Биньямин әл-Бәләхинең түбәндәге сүзләрен китерә: «Без, – дигән мелла Нияз, – казый һәм мөфтидән сорадык: «Я мәүләна, әгәр без мондый эшкә аяк бассак, сез безне тыярга һәм эшебезгә күрә җәза бирергә тиеш идегез. Ничек үзегез моңа юл куйдыгыз?». Казый моңа бер җавап та бирмәгән. Кайбер үткен кешеләрнең: «Бохарада бу кешедән керпек кенә очыртучы булса да, дүрт аягы белән табутка ятсын, юкса бөтен кешегә шул хәл килер» дигән сүзләре мәсәл урынында йөри. Кешеләрнең малларын талап, тартып алып, шуңа бакча яки кунак өе салдырып, бер-ике мәҗлестән соң ватып ташлатып, әрәм-шәрәм итә иде. Зур галимнәреннән мелла Хаҗибай бине Сафар әл-Хөҗәндидә кунак булып кайткач, һичбер сәбәпсез, өенең югары катын ватып ташларга кушты, үзен урыныннан төшерде, берничә вакытлар дәрес әйтү һәм өеннән чыгудан тыйды. Шулай ук Сәмәрканд казый Гиляни мелла Әбү Сәгыйд хуҗаны урыныннан төшереп, малын тартып алды, үзен Бохарага китереп, өенә ябып куйды. Бохарада булган олы мәдрәсәләрнең күпчелегендә бүлмәләрнең шәкертләргә бирелә торган вәкыф акчалары төрлечә: «Шәрхе мелла»дан[2] «Гакаед»ка

---

[1] Безнең заманыбызның хатыннары – күләгә, табыш, сугышып алынган мал. Гуманизмга каршы булган шушы «караш» деспот патшаларның хатын-кызны сатлык мал урынына күрүенә юл ачкан.

[2] Бохара мәдрәсәсендә дәрес китаплары.

чаклы түбәнрәк, «Гакаед»тан «Мелла Җәлал»га[1] хәтле – уртача, аннан югары дәрес укучыларга иң югарысы бирелә иде. Моның заманында бөтенесе тигезләндерелде. Элек шимбә, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе – дүрт көн дәрес укылып, өч көн буш вакыт калдырыла иде. Ләкин әмир Насрулла чәршәмбе көнне дә уку көне ясады. Әмма мөдәррисләр чирек яки ярты сәгать кереп утырсалар да, шәкертләр дәрескә килмиләр иде. Ничә заманнардан бирле Бохара көтепханәләренә вәкыф ителгән, саклана һәм теләгән кеше файдалана ала торган китапларны теләсә кемгә һичбер язусыз-нисез таратып, югалтып бетерде. Ил кешеләре бу хәлне белсә дә, ул вакыт шәһәрдә мөхтәсиб һәм әмирнең урынбасары булган вәзирнең урынбасары мелла Рәхманбирде бине Ниязбирде Төрекмәнинең начар һәм бозык уйларына сылтап, аны хурласалар да, мелла Хөсәен бине Мөхәммәд бине Гомәр Каргалый һәм башкаларның сүзләренә караганда, мелла Рәхманбирде Мәхзүм гаепсез һәм ул бозык эшләрдән пакь, бәлки фәкать әмирнең үзе турындагысы дөрес, ди иде. Күп вакыт кулланган мөһеренә «Әл-хөкме бил-гадел»[2] дип язылган иде. Акчаны үз исеменә суктырмады. Тәңкәләрнең бер ягында: «Әмир Хәйдәр гакыйбәт мәхмүд»[3], «Зорибә Бохараи шәриф»[4] һәм елы язылган иде. Заманында Һиндстан сәүдәгәрләреннән Бәдретдин исемле кеше кечерәк бер мәдрәсә салдырды. Аннан башка, тагын берничә кечерәк мәдрәсә бина кылынды. Үлгәндә ялгыз бер углы калды. Араларында дуслык һәм татулык юклыктан, кайбер фетнә һәм тынычсызлыклар булды.

Әмир Мозаффар биографиясе. Аннан – углы әмир Мозаффар. Атасы исән чакта Кирманиягә башлык булып, Зәрәфшан елгасын Дәбүсә крепосте ягына агызып, аны һәм тирә-ягын уңдырышлы илгә әйләндерде. Ләкин Каракүл җирләреннән су киселгәнгә күрә, игенлек җирләренең күбесе харап булуга сәбәп

---

[1] Бохара мәдрәсәсендә дәрес китаплары.

[2] Әл-хөкме бил-гадел – гаделлек белән хөкем итү.

[3] Әмир Хәйдәр – соңы мактаулы.

[4] Бохараи шәрифтә сугылды.

булды. Габделмалик исемле углы Карши шәһәре башлыгы иде. Атасына каршы килү һәм низаг чыгаруы сәбәпле, илдән куылды, горбәттә йөрүенә сәбәп булды. Габделфәттах исемле углы мең ике йөз сиксән алтыда (1870) якшәмбе көн кич белән Петербургтан Казанга кайтып, дүшәмбе көн ураза гаетен безнең мәчетебезгә килеп укыды. Аннан башка тагын берничә угыллары бар. Хоканд әмирләре арасында ызгыш башлангач, Ходаяр ханга ярдәм йөзеннән гаскәре белән Хокандка кереп, хөтбәдә аның исеме телгә алынып, дога кылынып, Бохарага кайтты. Хасар крепостен яулап алып, хакиме Габделкәрим бине үтерде. Мең өч йөз өченче (1885) елда сәфәр аеның алтысында җомга көн үлде, урынына әмир Габделәхәд куелды.

Хивә мәмләкәтендә Коңгыратия дәүләте

Мөхәммәдәмин би биографиясе. Харәзем мәмләкәтендә Хивә шәһәрендә Шәйбани ханнар династиясе бетү чорында төзелгән кечерәк бер дәүләт. Харәзем – мәмләкәт исеме. Борынгы, хәлифәләр һәм Харәзем шаһлар вакытында бер мең дә биш йөз авылны эченә алган, ә башкаласы, «Журҗания», гарәпләштереп, «Өркәнеч» дип аталган иде. Утыз капкасы бар иде. Чыңгыз хан харап иткәннән соң, өч йөз авыл калды һәм Үргәнеч исеме белән мәшһүр. Башкалалары Хивә шәһәре булды. Гарәп телендә каф белән «Хыюк» дип атала. Журҗаниядән дүрт тукталыш кадәр ераклыкта. Коңгырат ыругыннан Сәед Нәзар би һәм углы Ишмөхәммәд би, Шәйбания ханнары каршында хезмәт итеп тиңдәшләреннән өстен булып, мең бер йөз алтмыш тугызда (1756) углы Мөхәммәдәмин би бине Ишмөхәммәд «вәзир» мәгънәсендә булган «гонак»[1] дәрәҗәсенә ирешеп, утыз ел хөкүмәт сөреп, мәмләкәтне төзекләндерде һәм тыныч яшәтте, һиҗрәттән мең бер йөз туксан тугызда (1785) вафат булды. Батыр, гайрәтле, аңлы һәм һиммәтле иде. Даниал би вакытында качып Бохарага

---

[1] Гонак – муен дигән сүз. Бу урында патша яки ханның муены – урынбасары дигән төшенчәләрне аңлата һәм ханның беренче вәзире шулай исемләнгән.

барып, Даниал би ярдәмендә үз падишаһлыгын кайтарып алып, Даниалга хөрмәт йөзеннән беркадәр вакыт хөтбәдә аның исемен телгә алдырды. Печатендә: «Би хәмдилләһи Мөхәммәд ра Әмин әст»[1] дип язылган иде.

Гавәз би биографиясе. Аннан – углы Гавәз би. «Гонак» дәрәҗәсендә булып, мең ике йөз унтугызынчы (1804–1805) елда вафат. Олы гәүдәле, тыштан гади, начар тәдбирле иде. Мәмләкәт олылары Харәземне бүлгәләп, Казах ханлыгының бер өлеше кебек булып калды. Ләкин Шаһморад би аны ригая итә иде. Коңгырат ыругы белән башлыклары Түрә суфи аңа буйсынудан баш тартты. Шулай ук төрекмән, коңгырат, казах кабиләләре баш тарттылар.

Илтөзәр хан биографиясе. Аннан – углы Илтөзәр хан. Гавәз би үлгәч, халык һәм ил олылары барысы да Котлыгморад бине Гавәз бине «гонак» итеп куюны таләп итсәләр дә, яшем җитмәү сәбәпле, моны үти алмыйм, күшәншин[2] булып, туганнарымның догасын алам дип, гонак булудан баш тартты. Шуннан Илтөзәр, гонак булып алты ай үткәч, ханлык дәрте кереп, туганнары һәм дәүләт эшлеклеләре белән киңәште. Котлыгморадның яхшы табуы белән, иртәгесен Илтөзәр би хан булуы турында Казахстанга бер пропагандист чыгарып, тиешле хәзерлекне күреп, шәһәр буенча музыка уйнатып, мөстәкыйль хан исеме биреп, хөтбәдә: «Аллаһүммә әббәд дәүләтәл-хакани-л-әгъзами вәл-ханил-мөкәррәми Илтөзәри Мөхәммәдин Баһадир хани, хәлләдә Аллаһу мүлкәһү вә-фаза галял-галәминә биррәһү вә ихсанәһү»[3] гыйбарәсен укып, ямүт ыругыннан башка кабилә кешеләре аны котладылар.

Акчаны да үз исеменә суктырып, түбәндәге шигырьне яздырган иде:

---

[1] Аллаһга хәмед булсын, Мөхәммәдәминнеңдер.

[2] Күшәншин – дөньядан баш тартып, гыйбадәт белән генә яшәүче.

[3] Я Аллаһ, бөек хакан, хөрмәтле хан Илтөзәр Мөхәммәд Баһадир ханның дәүләтен мәңгелек кыл. Аллаһ аның патшалыгын мәңгелек кылса иде, аның изгелек һәм ярдәмен бөтен дөньяга ирештерсә иде.

«Бу акча Харәзем шаһы Илтөзәр тарафыннан алтыннан Аллаһның рәхмәтендә сугылган».

Бу кешегә чаклы Коңгырат хөкемдарлары исемендә хөтбә укылмый, акча сугылмый, казахлардан бер хан исеменә укыла, Иран һәм Бохарада сугылган тәңкә бертигез йөртелә иде. Ханнар, гонаклар фикеренә каршы килмичә, алтынланган киемнәр киеп, якыннары һәм балалары белән падишаһ сараенда ашап ятып, гонак һәм дәүләтнең аннан түбәнрәк дәрәҗәле олылары һәр көн әүвәл ханга сәламга барып, гает һәм җомга намазларына хан белән бергә чыга иделәр. Коңгыратиядә гонак «баш вәзир» мәгънәсендә булып, алардан беренче тапкыр хан исемен алган һәм үз исеменә акча суктырганнарның беренчесе бу кеше иде. Фулад исемле уйгур аталыкны үтертте. Вилдан исемле башлык, үз ыругы белән, баш тартты. Җиңелеп, әмир Хәйдәргә сыенды. Өхтә Хужа исемле сәеднең[1] кызын көчләп тартып алып өйләнде, сәед шуның өчен бик рәнҗеп, явыз дога кылды. Атасы белән бертуган абзасы Фазыл бәк бине Мөхәммәдәмин туры фикерле, акыллы, зирәк кеше иде. Атасы Мөхәммәдәмин, кардәше Гавәз биләр, алардан соң Мөхәммәдрәхим хан аңа хөрмәт күрсәтәләр, аның белән киңәшмичә эш кылмыйлар иде. Әмма Илтөзәр хан аның киңәшен тыңламый, сүзенә игътибар итми иде. Мең ике йөз егерме бердә (1807) Илтөзәр Амудәрья елгасына батып үлде. Тәфсыйле әмир Хәйдәр турында сөйләгәндә әйтелде.

Мөхәммәдрәхим хан биографиясе. Аннан – кардәше Мөхәммәдрәхим хан. Туганы үлгәч, Харәзем кешеләре барысы бергә хан күтәрделәр. Котлыгморад кайтып, риза булып, галимнәр, изгеләр, дәүләт эшлеклеләре – барысы бергә килешеп, Котлыгморад кардәшенең хан булганлыгын, шуңа күрә ханлыкны үз өстенә алмаганлыгыннан гафу үтенеп, әмир Хәйдәргә хат язды. Әмир Хәйдәрнең Котлыгморадны башлык итәргә теләве, шул турыда солтан Мәхмүд[2] хәзрәтләренә хат язуы нәтиҗәсез

---

[1] Сәед – дин башлыгы, изге кеше.

[2] Солтан Мәхмүд – Төркия солтаны.

һәм фактка каршы эш булып чыкты. Мөхәммәдрәхим хан ямүт ыругының олыларын үтереп, аларны үзенә буйсындырды. Гарел утравын алып, алтмыш елдан бирле буйсынмый килгән коңгырат ыругының башлыгы Түрә суфины үтертте, кызына өйләнде. Үзенең кече яшьтән бирле юлдашы һәм якын кәһиясе, ягъни диван бәге Ярмөхәммәдне әлеге кыз белән бәйләнештә шикләнеп, һәр икесен үтертте. Атасы белән бертуганы Мөхәммәдриза бәк, уйгурлар белән берләшеп баш күтәргән иде – җиңелде һәм үтерелде. Баш күтәрүчеләрне үзенә буйсындырды. Бохара әмире кул астындагы күп җирләрне талап, Каракүл һәм бүтән вилаятьләрдән бик күп әсирләр алып кайтып, борынгы Харәзем һәм башка якларга күчерде. Ахыр гомерендә тагын яу булып барып, әмир Хәйдәрне куркуга төшерде. Астәрабад һәм башкаларны алырга теләп барып, Иран шаһы белән дә маҗаралары һаман булып торды. Мең ике йөз кырык беренче (1826) елда үлде.

Мавәраэннәһернең зур кешеләреннән Мир Габделкәрим бине Исмәгыйль әл-Бохариның әйтүенчә, бик гайрәтле, сугышчан, мөрәүвәтле, эше шәригатькә ярашулы, галимнәрне олылаучы кеше булган, Мәрвә, Шаһҗанны яулап алып, тирә-яктагы төрекмән ыругларын буйсындырып, крепость салдырды. Анда берничә туп калдырып, вәзире Хуҗа Нияз бине Мәрвә шәһәренә башлык итеп билгеләде. Ләкин әмир Насрулла Хивәгә сәфәр кылган чакта, төрекмәннәр һөҗүм итеп, Мәрвә башлыгын үтереп, башын әмиргә җибәрделәр. Крепость һәм тупларны үз кулларына алып, вакыт төзеклеге өчен, форма һәм исем ягыннан Бохарага буйсынсалар да, салым һәм килерне һич бирмәделәр. Әмир анда Каракүлдән Гасыйм Хуҗа исемле кешене казый итеп җибәрсә дә, ашарына да тапмыйча, ачыгып, төрекмәннәр башлыгы кунак өендә берничә көн ятып, вакыт үткәреп, аптырап кайтты. Мөхәммәдрәхим хан Хивә шәһәренең төзеклеге өчен күп тырышты: мәчетләр, мәдрәсәләр һәм бүтән зур йортлар салдырды, крепостен ныгытты. Алтын акчаларының бер ягына: «Зорибә дарес-солтанәти Хыюк»[1] яки «Дарел-мөэмининә

[1] Хивә солтанлыгы илендә сугылды.

Харәзем»[1], икенче ягына: «Мөхәммәдрәхим баһадир хан» мөһерендә түбәндәге шигырь язылган иде:

Мөхәммәдрәхим янында урын тапса, Гомәр иярер, Хәйдәр буйсыныр.

Аннан – углы Аллаколый хан. Атасы урынын алды. Хоканд вакыйгасыннан соң, әмир Насруллага каршы, Мавәраэннәһер ягына үтеп чыгып, Бохара кул астында булган Гаждеванга хәтле килеп, талап, күп кешене әсир итеп алып китте. Хивәнең бер кырында «Рәфник» дип аталган тиңдәшсез бакча тездерде. Аннан башка, бик күп зур йортлар, тәбәнәк һәм биек биналар белән бизәде. Мең дә ике йөз илле сигезенче (1843) елның шәүвәл аенда Хивә шәһәрендә үлде.

Аннан – углы Рәхимколый хан. Атасыннан соң Харәземгә хөкемдар булып, мең ике йөз алтмыш беренче (1845) елда үлде. Атасы исән чакта «Бабаҗан түре» дип исем алган, сугышчан һәм халыкка җәбер-золым итүчелек белән сыйфатланган иде.

Аннан – кардәше Мөхәммәдәмин хан. Туганы үлгәч, Харәзем хөкемдары булды. Кайберәүләрнең сүзенә караганда, «Бабаҗан» – шушы кешенең кушаматы. Бу кеше – Үргәнеч ханнарының каймагы һәм династиянең иң олысы иде. Шәһәрне төзекләндереп, күркәм тәдбир, дөрес политика, дәүләт идарәсен яхшырту юллары белән мәмләкәтнең дәрәҗәсен күтәрде, тормышын яхшыртты. Манара, хөрмәтле мәчетләр, күркәм мәдрәсәләр бина кылдырды. Иран дәүләте тарафыннан илче булып килгән, агалар башлыгы мирза Ризаколый Ширази үзенең ильязмасында әйтә: «Хивә шәһәрендә бәнк, чәрс[2] кебек һ.б. шундый кешене кәефләндерә, исертә торган орлыклар, дарулар күп һәм аларны кулланган өчен беркем дә гаепләнми һәм тыелмый. Тәравих вакытында музыка уйнау начар саналмый һәм һичбер галим аннан сакланмый. Шәһәрендә һичбер мунча юк. Күпчелек җәй көне елгада коеналар. Ханнарының ашханәсе

---

[1] Мөселманнар иле – Харәзем.

[2] Бәнк, чәрс – Һиндстанда җитешә торган киндер яфрагыннан әзерләнә торган наркотик, исерткеч әйбер.

өчен расход бик аз тотыла һәм яхшымы-яманмы – ни әзерләнсә дә канәгать, ат итен аеруча сәфәрдә яраталар. Печтергән айгыр ите җенси мөнәсәбәт өчен көч күбәйтә дип уйлана, аны ашау ханга махсус. Бүтәннәргә рөхсәт ителми. Аларда башмак бөтенләй юк: итек кияләр. Алар Иран халкын кяфер һәм аларны үтерү важиб дип ышаналар, «рафизи» һәм «пелид»[1] дип атыйлар. Шигый хатыннарын, күзләренә сөрмә тартып, чәчен үреп, йөзен һәм гаурәтен ачып, сатып алучыга күрсәтәләр. Аларның күпчелек ирләренең, һава юешлектән, җенси мөнәсәбәт өчен көчләре аз, ирлекләре зәгыйфь, ә хатыннары, киресенчә, җенси мөнәсәбәтне телиләр. Шуңа күрә ирләренең кол һәм хезмәткәрләренә күз төшерәләр. Аларда Иран әсирләре бик күп, хәтта төп халкыннан да күбрәк. Бер хуҗаның иллеләп кол һәм хезмәткәре була дип, гади булган хәлләрне санадык, ә начар якларын тулырак итеп яздык.

Шигырь:

Минем гаебемне барын да сөйләдең,
Инде аның һөнәрен сөйлә.
Берничә наданнарга ияреп,
Хикмәтне инкяр итмә.

Ул илдә сугышу-талашу, урлау-ялганлау, үз арадагы эш һәм вәгъдәләрне бозу юк. Һичкем икенче берәү белән сугышмый, хәтта сөйләгәндә тавышын да күтәреп сөйләми. Түбән яки югары дәрәҗәле кешеләрнең һәрберсе теләсә кайсы көндә үзенең гаризасы белән Мөхәммәдәмин хан хәзрәтләре алдына тоткарсыз керә һәм теләген белдерә ала. Әгәр аның эше гадәти, гражданлык эше булса, Мөхәммәдәмин хан үзе карый, үзе хөкем итә. Әгәр шәригатькә бәйләнешле булса, аны карауны олы казыйга – судьяга тапшыра. Зәкяттан башка, беркемнең дә малына кагылмый. Зәкят итеп малның кырыктан бер өлешен ала. Бернинди эштә дә җәбер-золым күрсәтми. Алар өйләренең өске катында яшиләр, аскы каты буш була. Йортның тышында

[1] Рафизи, пелид – динсез, еретик.

юл бар, анда начар ислөр сизелми, чүп-чар, ташландык нәрсәләр күренми. Игенлек, яшелчә һәм җимеш бакчалары койма белән капланган, тыштан килгәндә күренми. Болай итү хуҗалык өчен начар түгел. Аның җимешләре күп һәм яхшы. Аның карбызы, бер дә арттырмый әйткәндә дә, Ком һәм Кашан карбызларыннан яхшырак. Аның туты (ефәк корты ашый торган яфрак) Шомран тутларыннан яхшырак. Инҗирләр Мазандраныкылардан күпкә яхшы. Әмма йөземе башкаларныкыннан күп аерылмый. Бөтен сахра бакча, яшелчә, игенлек, акация агачлары белән капланган, араларында сугару өчен арыклар бар. Хивә ханының үзәне якынайтылган кешеләренә бирә торган җир-сулары бар. Сәфәр вакытында һәркемнең бер аты, сәфәр кирәкләре өчен ике дөясе була. Шуңа күрә аның утыз, хәтта ун меңлек атлы гаскәре дә белмәгәннәргә бик күп булып күренә, читләргә курку сала. Сәфәр вакытында сахрада кичләрен туктап торалар. Хан туктаган урынның тирә-ягы саклык өчен канау белән әйләндерелеп алына. Әгәр сәфәрдә берәүнең аты яки дөясе үлсә, аның бәясе түләнә. Сәфәрдән кайткач, һәр атлыга биш төмән бүләк бирелә. Берәү дә биш төмәннән артык алуны уйламый: бу шулай гадәт булып киткән. Шуңа күрә «Ил тыныч һәм төзек, ә хәзинә бай булды» дип, күркәм холык һәм мактаулы сыйфатларны да сөйли һәм тәфсил итә.

Мөхәммәдәмин хан меңике йөз җитмеш беренче (1855) елда дүшәмбе көн җөмадиел-ахир аенда Сәрхәс янында «Канлы түбә» исемле урында якынча утыз биш яшьләрендә үтерелде. Төрекмәннәр башын кисеп алып, баш киеме, тажы һәм башка кирәк-ярагы белән унбишенче көнендә Тәһранда Иран шаһы хозурына китерделәр. Ләкин Хивә хөкемдарлары – Харәзем ханзадәләре, аларның ата-бабалары Иран шаһларының хезмәткәрләре һәм ислам әдәбе белән тәрбияләнгән, Мөхәммәд пәйгамбәр шәригатенә һәм Хәнәфия мәзһәбенә иярүчеләр булганга күрә, Насретдин шаһ моңа чын күңелдән шатлана, риза була алмады. Тәһранда ханнар күмелә торган каберлектә бина салып, хан җитәкчелегендә башка якыннары һәм дәүләт эшлеклеләре аларны күмүдә әзер булдылар,

өсләрендә Коръән укылып, фәкыйрь һәм мескеннәргә азык өләшенде.

Шигырь:

Харәзем шаһның башы менә Тәһранда.
Аның тәне бер папоротник өстенә
хур ителеп ташланган үлек.

Мөхәммәдәмин ханның ел саен талап йөрүеннән Мәрвә һәм Сәрхәс төрекмәннәре Иран дәүләтенә мәхәббәт күрсәтеп, Кәлат халкын үз хөкемдарлары Җәгъфәр Акай Җәлаерига каршы күтәрделәр. Ул качып, Харәземгә Мөхәммәдәмин хан хозурына барып, Мәрвә, Сәрхәс һәм Кәлатны яулап алырга өндәде. Хан ул илләрне генә түгел, Нишапур һәм Сәбезварны яулап алу дәртенә төшеп, өч мең ат һәм тупханә белән Шаһморад гонак һәм кушбигене Мәрвә өстенә җибәрде. Үзе исә Сәрхәсне алу өчен «Тел Канлы түбә»гә килеп, яшел чатырын кордырып, анда үзенең якыннары һәм әмирләре белән бергә сугышны күзәтеп торып, һәр якка атлы гаскәрләр җибәреп, аларны сыйлау белән мәшгуль булды. Иран шаһы ярдәмендә сәрхәслеләр җиңеп, алты туп, йөз сөңге, биш йөз мылтык алдылар. Икенче мәртәбәсендә Акдәрбәнд исемле урында сугыш булып, харәземлеләр тагын җиңелделәр һәм Сәрхәс шәһәреннән якынча ике мең адымга чигенделәр. Өч меңгә якын кешеләре үтерелде, мылтык, бер туп һәм уналты сафны туздырып, ике байракны иранлылар ганимәт итеп алдылар. Хан, бу хәлне күреп, кайтып китәргә борылды. Үзенә хас ат, алтынлы ияр, койрыгындагы алтын туп, махсус кызыл киеменнән танып, сәрхәслеләр һәм иранлылар, үтерергә теләп, «Канлы түбә»гә менделәр. Иң башлап, Корбангол исемле иранлы, кылычы белән авызына чабып, колагынача ярды. Хан: «Мине бу рафизи[1] явызлыгыннан саклагыз», – дип, үз кешеләреннән ярдәм сорап, дошманнарына: «Мин – хан, кадер-хөрмәт эчендә үскән, мине үлтермичә, Иран шаһы хозурына илтегез», – дип ялынса да, һичкем сүзенә колак салмады. Башын кем кисеп алу турында ара-

[1] Рафизи – динсез, еретик.

ларында ызгыш чыгып, унике кеше үлде. Ахырда Сыйххәтнияз хан бине Ираз хан әс-Сәрхәси, башын кисеп, янындагы әйберләрен талап алдылар. Якыннарыннан барысы утыз ике кеше үтерелде, шулардан ундүрте атасы белән бертуганның балалары иде. Тагын Харәзем казые һәм Бикҗан диван биге, Ходаяр би, Габдулла Мөхәррәм, Дәүләтьяр би, Бикҗан – сәрдар, Ниязкол – мең башы, Аллаколый – йөз башы, Хакназар – мең башы, Дәүләтнияз бәк Хуҗа Нияз – йөз башы, Мәймәнә башлыгы Вәйсбай бине Хөкүмәт хан бине Мәзрап хан мең атлы белән ярдәмгә килгән иде. Бикморад бай текә Фөрьяби, Мөхәммәд шәех Фөрьяби сәрдар[1] ике мең атлы гаскәр белән һаман да Хорасанны талап йөри иде. Ибне Габбас бай текә Фөрьяби – барысы җитмеш кешесе үтерелде. Җәгъфәр Акай – Кәлат хөкемдары, Мирәхмәд Җәмшиди аның вәзире кебек иде, һәр икесе яраландылар. Бу вакыйгадан соң Харәземдә зур фетнәләр, көчле аерылышулар килеп чыкты. Төрекмән ыругы – Атаморад, кара калпаклылар – Җарлык Түрә исемле кешеләрне алдын күреп, олылап, хан күтәрделәр. Бу фетнәләр Хоканд вакыйгасыннан килеп чыгып, андагы маҗараларга бәйләнешле һәм кутыр өстенә чуан, ярага тоз, мәмләкәтнең бетүенә тулы сәбәп иде.

Аннан – бабасы белән бертуганның углы Габдулла хан бине Котлыгморад бине Гавәз гонак. Элекке хан үтерелгәннән соң, харәземлеләр аны хан итеп куйдылар. Аннан соң Габдулла хан бине Мөхәммәдәмин хан бине Аллаколый хан. Аннан – Котлыкморад хан бине Гобәйдулла хан бине Котлыгморад би бине Гавәз гонак. Аннан – Сәед Әхмәд хан бине Мөхәммәдрәхим хан бине Гавәз гонак. Өлкән яшьтә хан булды. Әфьюнчы иде. Мең ике йөз сиксән бердә (1864) борынына тәмәке иснәүдән үлде. Үзе һәм ике туганы Сәед Мәхмүд түрә һәм Сәед Мөхәммәд түрә һаман да Харәземдә хан булырга көтеп торалар иде – теләгенә иреште. Аннан – углы Мөхәммәдрәхим хан. Мең ике йөз туксан биштә (1878) Россия гаскәре, Харәземне алу өчен, Ияр руми[2] егерме

---

[1] Сәрдар – гаскәр башлыгы.

[2] Ияр руми – май.

өчендә Һәзар Әсәбне алып, гаскәр башлыгы белән бергә Хивәгә егерме чакрым ераклыкка килеп җиткәч, ханның якыннары һәм Илтөзәр гонак бүләкләр алып каршы чыктылар. Икенче яктан Оренбург гаскәре килеп җитеп, туплардан ата башлагач, халык каршы җавап бирә башлады. Хан аларны тыйса да, сүзе үтмичә, дошманнары, шуннан файдаланып, туганы Атажан түрәне хан итеп күтәрделәр. Мөхәммәдрәхим хан Хивәдән чыгып, юмат ыругына китте. Россия гаскәр башлыгы Хивәгә өч чакрым калганда, яңа хөкемдарның бабасы Сәед Мөхәммәд хан, диван биге Мөхәммәднияз каршы алырга чыктылар. Шушы елның рабигыль-әүвәл аеның унөчендә, майның егерме тугызында Россия гаскәре Хивәгә кереп, хан һәм аның киңәшчесе диван бигенең акча һәм бүтән маллары Россия хәзинәсе файдасына алынды. Мөхәммәдрәхим хан туганы һәм Баба ханының чакырып язган хатлары буенча, туганы Сәед Морад түрә, Мөхәммәдморад түрә һәм башка якыннары белән бергә, рабигыль-ахир аеның унсигезендә Россия гаскәр башлыгына килеп, шуннан соң Россия кул астына кергән Хивәгә һәм рәхәт тормышына кайтып керде. Мең өч йөзенче (1882–1883) елда император Александр бине Александрның таҗ кию бәйрәменә Мәскәүгә килеп китте. Мең өч йөз икенче (1884) елда Россия гаскәре, төрекмәннәрне буйсындыру өчен, Мәрвә, Сәрхәс һәм тирә-ягын алып, Һиратка караган авыллардан «Пәнҗидә» һәм «Хәмес кора», ягъни «Биш авыл» дип йөртелгән районга килеп җитте.

Хокандта Бабурия дәүләте

Болар үзләренең нәселләрен Аксак Тимер Көргән балаларыннан Мөхәммәд Бабур мирза бине Гомәр Шәех мирза бине солтан Әбү Сәгыйд мирза бине Мөхәммәд бине Мираншаһ бине әмир Тимергә тоташуын дәгъва итәләр. Шуңа күрә бу бүлекне без шул исем белән атадык. Бабур мирзаның Гобәйдулла хан Шәйбанига җиңелеп, Мавәраэннәһерне ташлап Һиндстан ягына китешендә, алтынланган киемле, бик кыйммәтле кирәк-яраклы бер имчәк баласын алтын бишектә килеш бер агач ботагына асып куелган табып, аны Бабур мирзаның юлдашлары күреп

алып, килешенә карап Бабур нәселеннән дип уйлап, «Алтын Бишек» дип исем куйганнар, күркәм һәм яхшы тәрбия итүгә бик зур әһәмият биргәннәр (дөресен Аллаһ белә). Алтын Бишек тәмам үсеп җитеп, үзе һәм балалары кабиләгә башлык һәм би дәрәҗәсен алып, әкренләп эшләре алга китеп, бөтен Фирганә, Ташкент һәм Төркестанга хуҗа булдылар. Хөкемдарлык дәрәҗәсен алучыларның беренчесе Шаһрух хан бине Рөстәм би бине Хуҗи би, бине Шәһмәт би (икенче исеме – Җимеш би) бине Асылзадә бине Әбү әл-Касыйм бине Мөхәммәдәмин бине Ходаяр бине Иләк бине Алтын Бишек. Меҥ бер йөз егерме беренче (1709–1710) елда башлык булып, «Тургавә» исемле урында урнашып, меҥ бер йөз утыз дүрттә (1721–1722) үлде. Алтын Бишеккә ун буын аркылы тоташа.

Габдерәхим хан биографиясе. Аннан – углы Габдерәхим хан. «Карахан» кушаматы бирелгән. Хөҗәнд, Струшнә һәм Сәмәрканд та аның кул астында иде. Меҥ бер йөз кырык алтынчы (1733–1734) елда Хөҗәндтә үлде.

Аннан – кардәше Габделкәрим хан. Меҥ бер йөз алтмыш дүрттә (1750–1751) үлде.

Аннан – углы Габдерахман. Тугыз айдан соҥ төшерелеп Мәргыйнанга башлык итеп билгеләнде.

Аннан – атасы белән бертуганның углы Ирданә хан бине Габдерәхим. Бер елдан соҥ төшерелде.

Аннан – кардәше Баба бәк хан. Туганыннан соҥ хан итеп куелып, бер елдан соҥ үтерелде һәм туганы Ирданә икенче мәртәбә хан итеп куелды, меҥ бер йөз җитмеш алтынчы (1762–1763) елда үлде.

Аннан – атасы белән бертуганның углы Сөләйман хан бине Шадиби бине Шаһрух. Меҥ бер йөз җитмеш җиденче (1763–1764) елда төшерелде.

Аннан – Мөхәммәдәмин хан бине Габдерахман хан.

Аннан – углы Нәрбүтә хан бине Мөхәммәдәмин хан. Меҥ бер йөз җитмеш җиденче (1763–1764) елда ун яшендә хан булып, утыз алты ел хөкүмәт сөрде, меҥ ике йөз унөченче (1798–1799) елда үлде. Үз исеменә хөтбә укытмады һәм акча суктырмады. Бер үк ата-анадан туган һәм яшь ягыннан олырак булган

туганы Хаҗи хан баш тартып, Струшнә шәһәрен алды. Алда исемнәре саналачак Ширгали ханның атасы, Меллә һәм Ходаяр ханнарның бабасы иде.

Аннан – углы Галим хан. Атасы урынына хан булды. Көчле, батыр, залим, җәберләүче, тәсаувыф ияләренә каршы кеше иде. Туганы Рөстәм бәк гаять матур һәм күркәм иде. Аны һәм аңа башка, атасы белән бертуган кардәшләрен һәм аларның балаларын үтерде һәм читкә сөрде. Юныс хуҗаны җиңеп, Ташкент өлкәсен алды, бохаралыларны куып җибәреп, Ура-түбәне кайтарып алды. Хөтбәне үз исеменә укытты, акчаны да үз исеменә суктырды. Мөһере: «Бәндәи хас хәзрәти сөбхан Галим хан бине Нәрбүтә хан»[1], дип язылган һәм мең ике йөз уналты (1801–1802) ел тарихы куелган иде. Ахырга таба халык үзенә ачуланып, риза булмыйча, мең ике йөз егерме дүрттә (1809–1810) сарай кешеләре тарафыннан үзе, углы Шаһрух һ.б. үтерелде.

Гомәр хан биографиясе. Аннан – кардәше Гомәр хан. Атаана бертуган кардәше читкә тибәрелеп, өстен катлау һәм халыкның бигать бирүе[2] турында бөтен Фирганәгә боерык җибәрелде. Зоһур диван биге Ташкент шәһәр башлыгы Шаһрух би бине Галим ханны кулга алды, Хокандка хәбәр җибәреп, Гомәр хан, мәкерле Риза бәк котыртуы буенча, юлда аны үтертте. Гомәр хан белгеч, шагыйрь, олылык иясе, галимнәрне, шагыйрьләр мәҗлесен сөя, олылар белән сөйләшә-киңәшә иде. Гаделлек, күркәм чара һәм политика белән гыйлемне үстерде, мәдрәсә һәм мәчетләр салдырды, аеруча Хоканд шәһәрен һәм, гомумән, Фирганә җирен төзек һәм тыныч лык җире итте. Иленең шагыйрьләре, аның хакында фарсы һәм төрки телләрендә шигырь һәм касыйдәләр чыгарып, исемен бөекләделер. Кайбер касыйдәләрнең һәрбер строфасының соңгы өлеше: Гомәр Хәйдәр дин әфзалдыр, дип тәмамланганга, Бохара әмирен кимсетү дип саналды. Рәҗәп Карчә исемле кеше белекле, тәдбирле, дөрес уйлы, Галим ханның якыны һәм гаскәр башлыгы иде. Бервакыт, аның ачуыннан

---

[1] Аллаһ хәзрәтенең хас (сайланган) колы – Галим хан бине Нәрбүтә хан.

[2] Патша итеп тануы.

куркып, Бохарага качкан иде, ул үлгәч, җаен туры китереп, Бохарадан тагын качты, Гомәр ханга килеп, тагын гаскәр башлыгы һәм Хөҗәнд башлыгы булды. Әмир Хәйдәрнең «үтермәдем» дип үкенгәне – шушы Рәҗәб. Гомәр ханның дошманы Риза бәк, Бакый Такый исемле каракалпаклы белән бергәләп, Гомәр хан белән Рәҗәбне үтерергә уйласалар да, Гомәр хан сизеп калып, һәр икесен үтертте. Гомәр ханның батырлыгы һәм берүзе юлбарысны үтергәнлеге халык телендә сөйләнә. Мең ике йөз кырык беренче (1825–1826) елда үлде.

Аннан – аның углы Мөхәммәдгали хан. Атасы үлгәч, Фирганә хөкемдары булды. Уен-көлкене сөюче, аучылык белән мавыгучы, күп йөрергә яратучан иде. Хатыннарын, җарияләрен арбаларга төяп[1] үзе белән алып, ауга һәм шәһәрдән-шәһәргә йөри иде. Мәмләкәтенең чигендә Бәшагыйрь крепостен салып, әмир Насрулла белән ике арага салкынлык һәм дошманлык төшеп, ызгыш һәм сугышка сәбәп булды. Бохара әмиренең тәртипле гаскәре, әмир урынбасары Габдессамад Тәбризинең сугыш эшендә осталыгы, кирәкле чаралар күрә белүе, Бохара әмирләре турында тугрылыклы, гадел, динне көчәйтүчеләр дигән ялган шөһрәтнең таралуы, Фирганә кешеләренең гадилекләре, тәҗрибәсез һәм бик аз нәрсәдән хәбәрдар булулары, туганыннан куркып әмир янына качкан Мәхмүд ханны үзе белән алып килергә һәм аны агасы урынына утыртырга бик нык горурланулары кебек сәбәпләрнең бергә туплануы хан гаскәренең җиңелүенә, Насрулланың өстенлек һәм җиңүенә көчле сәбәп булды. Әмир гаскәре Хокандка кергәндә, хан качып чыгып китсә дә, тотып китерелеп, шунда ук үзе, кардәше Мәхмүд хан, анасы, гаиләләре – барысы әмир кушуы буенча берьюлы үтерелде. Бары ханның кечкенә бер углы калып, аны Бохарага алып кайтты. Моннан соң бохаралылар талау, кан түгү, яшерен урыннарны хурлау һәм саф кызларны көчләү, яшь балаларны ерт-

---

[1] Бу сүздән Мөхәммәдгали ханга үзенә мәхрәм булган хатыннар кирәк булып, кайбер башкалар кебек чит хатын-кызга күз төшерми, фәхеш һәм гөнаһ эшләргә бармавы, ул яктан саф булуы беленә. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

калау һәм бозыклык, Аллаһ колларын газаплауның иң кабахәт чигенә җиттеләр. Хәтта үзләре алып китә алмаган кытай савыт-сабасын өеме белән урамга ташлап ватканлыклары, халык милке булган зур күләмле, калын китапларны ике ягыннан тотып кылыч белән чабып өзеп бүлгәнлекләре мәшһүр. Бохаралылар, бу әшәкелекләрен аклау, гаепләрен яшерү өчен, төрле ялганнар уйлап чыгардылар. Алар: «Хоканд ханы үзенең атасының җариясенә өйләнде, ачыктан-ачык бозыклыклар эшләде, Аллаһ колларына золым, шәригать хөкемнәрен бозды, дингә хыянәт итте, ә галимнәре һәм халкы аны бу әшәкелекләрдән тыймады, изгелек белән боермады, шуңа күрә алар куркытылырга һәм әдәпкә чакырылырга тиеш иделәр, һәм әмир Насрулла шул начарлыклардан тыю юлы белән үз өстенә вәҗиб булган бурычны үтәүче», – дип, күптөрле ялган әкиятләр, булмаган вакыйгалар уйлап чыгардылар. Бу хәл меңдә ике йөз илле алтынчы (1840–1841) елда рабигыль-ахир аенда булды. Әмир Насрулла Хоканд мәмләкәтендә берничә көн калып, әлеге җария белән йоклап, Мәүләви Җибилли дип билгеле булган казый Гилян-Мәүләви мелла Габделләтыйф бине Шаһ Әмин, әлеге җария һәм башкаларны алып кайтып, җарияне бераздан соң үтертте, казыйны «Мәдрәсәи Ирназар»га мөдәррис итеп куйды. Ул ахырдан Хокандка кайтып, меңике йөз алтмыш өчтә (1846–47) үлде. Асылы Гүһстаннан булып, Һиндстанда укыган иде.

Аннан – атасы белән бертуганның углы Ширгали хан бине Хаҗи бәк хан бине Мөхәммәдәмин бине Габдерахман. Әмир Насрулланың Хокандта эшләнгән мажараларыннан соң Фирганә халкы уянып, аякка басып, кыпчак кабиләсеннән «Чулак Мөселманкол» дип йөртелгән бер аксак кеше үз халкы, кытай кабиләсе һәм башкалар белән берләшеп, кыргызлар арасыннан Ширгалине чыгарып, «шулай, шулай» дип, зур исем белән сахрадан Хокандка китергәндә, һәр яктан халык ияреп, бик күп кеше белән Хокандка килеп кереп, тәхеткә утыртып, хан итеп куйды. Әмма фактик власть тулысынча Мөселманкол кулында иде. Әмир Насрулла куеп калдырган Ибраһим Пәрванәче һәм

якыннары куркып, Сәмәркандка качты. Мангыт ыругы һәм аңа башка бохаралылардан күп кеше үтерелде. Ширгали ханның атасы Хаҗи бәкне туганының углы Гомәр хан сахрага сөргән иде. Моннан соң Мөселманкол бер мөһим сәбәп белән гаскәрен алып, кыргызлар өстенә киткәч, Хокандның сакчысыз калганын әмир Насрулла ишетеп, Ширгалинең атасы белән бертуганның углы Морад хан бине Гали ханны Сәбез шәһәреннән чакырып алып, бераз гаскәр белән сиздермичә Хокандка җибәреп, барып кереп, дүшәмбе көн Ширгали ханны үтереп, бигать һәм башка кирәкле эшләр белән шөгыльләнгәндә, пәнҗешәмбе көн Мөселманкол кинәттән Хокандка кайтып кереп, Морад хан һәм аның якыннарын үтереп, үз янында булган Ходаяр ханны (Ширгали ханның кече углы), әүвәлдән килгән гадәт белән, Фирганә хөкемдары итте. Морад хан бары ике көн хөкүмәт сөреп калды. Ул вакыт Ходаяр хан унөч яшендә, ә барлык власть Мөселманкол кулында иде. Бераздан соң Ходаяр хан, җаен туры китереп, Мөселманколны кулга алып газаплап үтереп, мөстәкыйль хан булса да, аннан файдалана алмады: абыйсы Мәллә хан аны җиңде. Ширгали хан бер елдан артык хан булып торды. Кайбер шагыйрьләрнең:

Хан шәһид мәрхүм аһ кәшид[1] –

дигән юлны тарих итеп санаулары бу кеше вафатына, ягъни меңике йөз илле сигезгә (1842–1843) туры килә.

Аннан – туганы Мөллә хан бине Ширгали хан. Туганыннан яшь ягыннан өлкән, аң һәм карашы ягыннан өстен булса да, Мөселманкол, үз мәнфәгатьләренә яраклы һәм теләгәнен эшләргә уңай санап, Ходаяр ханны тәкъдим иткән иде, ул да Мөселманколны үтергәнлектән, һәр икесе кылган эшләреннән файда итә алмыйча, Мөллә хан Хоканд мәмләкәтенә кул сузып, Мөселманкол үтерелгәч, Ходаяр хан төшерелеп, куып җибәрелде. Мөллә хан берара аптырап йөреп, Сәмәркандта бер мәдрәсәдә Коръән күчереп тамак туйдырып, газап, ялгызлык,

---

[1] Хан шәһид булды, үлде, ни кайгы!

кара хезмәт белән вакыт үткәрсә дә, заман үзгәрешләреннән файдаланып, Ташкент башлыгы дәрәҗәсенә ирешті. Иярченнәренең яклавы аркасында мең ике йөз җитмеш биштә (1858–1859) энесен җиңеп, Фирганә иленә хан һәм солтан Габделмәҗид хәзрәтләренә буйсынуын белдереп, дәүләт төзесә дә, кайбер дошманнарының һөҗүме сәбәпле, мең ике йөз җитмеш сигездә (1861–1862) Хокандта үтерелде. Гәрчә тирьяк, күкнар һәм башка шундый наркотикларга ияләнгән булса да, акча эшен тәртипкә салу һәм башка шундый күркәм эшләргә юл ачты, Хоканд, Ташкент, Уш, Мәргыйнан кешеләре гаделлеге, ярдәмлелеге, тугрылыклы булуы, язуының матурлыгы белән искә алалар, ханлык дәверенең кыскалыгына көенәләр, атасы һәм туганына караганда патша булу өчен лаеклырак икәнен беләләр.

Аннан – углы Сәгыйд хан. Атасыннан соң кечкенә чакта ук Фирганә хөкемдары итеп билгеләнсә дә, Бохара әмире алып китеп, шәһәрдәге сабый балалар белән бергә укытыр өчен, бер мәктәп мөдиренә тапшырып мыскыл итте.

Аннан – атасы белән бертуганы Ходаяр хан бине Ширгали хан. Элек атасыннан соң Мөселманкол ярдәмендә Фирганә башлыгы булып, туганы Мөллә хан өстенлек алгач, Бохара ягына качып, бераздан соң, Мөллә ханның үлеме әмир Мозаффар бине әмир Насрулланың ярдәмендә икенче тапкыр Хокандка кайтып, Корбан гаетендә Хокандта әмир исеменә хөтбә укып, яңадан Фирганә иленең хуҗасы булды. Мең ике йөз туксан икедә (1875) Фирганә илен Россия яулап алып, Ходаярны Оренбургка алып кайтты. Мең ике йөз туксан дүрттә (1877) аннан качып китеп, Хорасан, Һиндстан, Хиҗаз шәһәрләрендә йөреп, Истанбулга килде. Аннан икенче мәртәбә Хорасанга кайтып, бераз вакыт Амудәрьяның Көньяк тирәсендә аптырап йөреп, мең ике йөз туксан тугызда (1882) Һират шәһәре кул астындагы Кәрух[1] исемле авылда үлде. Бу – Алтын Бишек нәселеннән Фирганә

---

[1] Кәрух – кәрех белән бер түгел: боларның беренчесе – Һират өлкәсендә бер авыл исеме, ә икенчесе – Багдадта һ.б. мәхәллә исеме. *Ш. Мәрҗани искәрмәсе.*

ханнарының ахыргысы булды. Беренче тапкыр хөкемдар булып унҗиде, икенче тапкыр ундүрт ел торды...

«Тәварихе Болгария» исемле китаптагы ачык ялгышлар, әшәке ялганнар һәм вакыйгаларның буташтырылулары турында аңлатма

Китап иясенең үз китабында әйтүенә караганда, ул Чистай өлкәсендә Ташбилге исемле авыл кешеләреннән Мөслим баба нәселеннән, һиҗридән меңел үткән вакытларда (1592 нче еллар була) яшәгән Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими дигән кеше. Китапны үзенең дөньяга килүеннән берничә йөз ел элек яшәгән галим Тәфтазанидан укып кайткан елында тугыз йөз илле сигезенче (1551) елда язарга керешкән һәм 92 (1584) елда, ягъни утыз дүрт елдан соң гына тәмам иткән була. Ай-һай бик күп ел тикшерү белән шөгыльләнгән икән! Әмма Болгар һәм Казан хәлләре турында татар һәм башкорт муллалары тарафыннан язылган һәм халык арасына күпләп таралган бу һәм моңа охшаган берничә китап бар. Болар барысы да – ачык ялган һәм вакыйгаларны бозып язылган китаплар. Бу «Тәварихе Болгария» дә шундыйларның берсе булып, әшәке ялганнардан, вакыйгаларны бозып бирүдән читтә кала алмаган.

Халык, хәтта укучылар һәм кайбер аңлы кешеләр карашынча, мөэмин-мөселман кеше турында яхшы уйда булу лязем. Ләкин яхшы уйда булуның лязем чаклары булган шикелле, аның тыелган, начар чаклары да бар. «Иннә бәгъзазззанни исмен»[1].

Бу фәкыйрь кол кайбер иң әһәмиятле ялгышларны һәм ялганнарны ачыклау белән бергә, калганнарына да колак салырлык һәм илтифат итәрлек түгеллеге турында тәнбиһ ясап, шул китапка алданып, хата һәм бозык фикердә булган бик күп кешеләрне шул бозык карашлардан, хата ышанулардан азат итү

---

[1] Уйның да кайберсе начар, гөнаһлы була.

теләге белән, вакыт сыйдырганча, аңлатып бирү эшенә кереште. Тәүфикъ һәм дөреслеккә ирешү Аллаһтан (...)

Рисаләсенең «Хатимә» өлешендә усал, канэчкеч Аксак Тимер турында әллә нинди ялганнар оештырып, төрле-төрле ялган кыйссалар белән китабын тәмамламакчы була. Синнән башка, аның үзенең тәлинкә-сөяк ялаучылары да синең ялганыңа хаҗәт калдырмаганнар.

Ул әйтә: «Бозыкларны, азгыннарны бозыклыктан тыеп, яхшы юлга күндерү өчен, Хода Һиҗрәттән сигез йөз алтмыш икенче (1457) елда Аксак Тимерне җибәреп, ул җир йөзенең кешеләр яшәргә мөмкин булган дүрттән бер өлешендә күп шәһәрләрне җимерде, туздырды. Ул заманда Кытай патшасы Чыңгыз хан иде, аны дингә өндәп һәм күп шәһәрләрне җимереп, үзен үтерде. Кытай халкы буйсынып, җиңелү налогы түләп торырга разый булды, анда Торымтай бине Чыңгыз ханны патша итеп куйды, – ди. И ялганчы! Аксак Тимернең эше сую-кисү, вату, җимерү, җәберләү, җәзалау. Яманлыктан тыеп, яхшылыкка өндәү белән аның һичбер эше булганы юк. Чыңгыз хан алты йөздән (1200) соң баш күтәреп, алты йөз уналтынчы (1219) елда Сәмәрканд, Бохара, алты йөз унсигезенче (1221) елда Харәземне талап, яндырып һәм халыкларын үтереп, шулай ук яулап алырга уйлаган мәмләкәтләрне дүрт углы: Җуҗи, Чыгытай, Үгедәй һәм Түли ханнарга бүлеп биреп, алты йөз егерме җиденче (1229–1230) елда үз түшәгендә авырып ятып үлде. Кайбер тарихчылар «дүзәхи» дигән сүзне тарих башы итеп санадылар[1]. Аның Торымтай исемле углы турында сүз дә булганы юк. Әлеге мәмләкәтләр ул заманда солтан Мөхәммәд Харәзем шаһ хөкүмәте карамагында иделәр, аларны дошманнан сакларга көче җитмәде. Аксак Тимер Чыңгыз вафатыннан соң йөз елдан артыграк вакыт үткәч, ягъни җиде йөз утыз бишенче (1335) елда егерме бишенче шәгъбанда шәһре Сәбездә дөньяга килде. Җиде йөз җитмеш беренче (1369–1370) елда күтәрелеп чыкты, сигез йөз

---

[1] Дүзәхи – тәмугдагыча; «Чыңгыз китергән һәлакәт тәмугда гына булырга мөмкин» мәгънәсендә булса кирәк.

җиденче (1404) елда «Утрар» дигән җирдә вафат булды, вафаты тарихы түбәндәге шигырь белән әйтелә:

Солтан Тимер кебек шаһ дөньяда булмады;
Ул җиде йөз утыз биштә (1335) дөньяга килде;
Җиде йөз җитмеш бердә күтәрелеп чыкты;
Сигез йөз җидедә (1404) дөньядан китте[1] –

дип, кайбер замандашлары тарих башы итеп санаганнан. Кайбер тарихчы зур галимнәр аның чыгуына «газап», вафатына «харап» дигән сүзләрне кушып язганнар.

Янә бу сүзгә ялгап: «Ул заманда кызылбашның[2] «Мәшһәд» исемле шәһәрендә Надиршаһ исемле кеше килеп чыгып, Бохара, Сәмәрканд, Үргәнеч, Хивә һәм болардан башка күп шәһәрләрне яулап алып, ханнарны, галимнәрне үтереп, халыкны үзенең бозык юлына керергә өндәде, Әһле сөннәт вәл-җәмәгать байрагы егылды. Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән Хозыр галәйһис-сәлам аркылы «Надиршаһны үтереп, халыкны коткарсын» дигән хәбәр аның төшенә керде. Шуннан әмир Тимер, чиксез күп гаскәр белән кайтып, Надиршаһ билгеләп куйган бәкне үтереп, Бохарага юнәлде. Надиршаһ качты. Артыннан җитеп, бер ел сугышканнан соң, Надиршаһны үтерде, шәһәрне җимерде. Бохарага Солтанморад исемле бер шәкертне хан итеп куйды, аның атасы Сәлим ханны Надиршаһ үтергән иде, ди. Никадәр ялган һәм дөреслеккә капма-каршы булган сүзләр яза. Тимер белән Надиршаһ бер заман кешеләре түгел: Надиршаһ Тимердән өч йөз ел чамасы соңрак дөньяга килгәнлеге галимнәргә берсүзсез мәгълүм бер нәрсә. Надиршаһның чыгышы, нигездә, Хорасан мәмләкәтендә Әбьйорд исемле шәһәр тирәсендәге «Әфшар» кабиләсеннән. Атасы гади кеше булып, бер вакыт көтүче булганлыгы сөйләнә. Солтан Мәхмүд бине Мостафа әл-Госманның бу хәлне кимсетүенә каршы Надиршаһ: «Әгәр дөньяда көтүчелек гаеп эш булса, ни өчен Муса [пәйгамбәр] Шөгаеб [пәйгамбәр]

---

[1] Шигырь – фарсы телендә. Монда тәрҗемәсе алынды.

[2] Кызылбаш – ислам динендә «Шигыйлар» дип йөртелә торган бер секта.

гә көтүче булган. Әгәр Шаһмәрдән минем эшемне алга җибәрсә, мин Истанбул өстенә байрагымны эләчәкмен», – дип җавап биргәнлеген сөйлиләр.

Сәфәвия дәүләтенең ахыр көннәрендә көчсезләнеп калуы сәбәпле, Әфган халкы өстенлек алгач, Сәфәвия дәүләтен яклау хәйләсе белән баш күтәреп, эше алга китте. Башта Сәфәвия дәүләте исеменнән мәмләкәтне идарә итеп, үзен Таһмасип Колый хан дип атап, әкрен, әкрен Басара чигеннән алып Иран мәмләкәтен, Һиндстанны, Мавәраэннәһер һәм Төркестанны яулап алып, мөстәкыйль патша, бөек бер җиһангир булды. Сугышлары, барлык эше, Тимер Көргән кебек, бозыклык, кан түгү, зыян-зарар китерү генә түгел иде. Башта бераз вакыт шигый мәзһәбенә аркаланып йөрсә дә, үзенә таяныч көч тапканнан соң, илдә халыкны еретикларныкы кебек бозык юлга керүдән тыеп, әһле сөннәт вәл-җәмәгать юлын сайлап, шуны төгәл рәвештә хөрмәт итәр булды. Төркиядән Вәссаф әфәнде һәм аннан башка берничә галим килү белән, үзенең алдында шул мәсьәлә буенча Иран галимнәре белән бәхәсләшү, фикер алышулар ачып җибәрде. Сугыш вакытында Багдад шәһәрен чолгап алгач, кызылбашларның вак-төяк тәртипсез кешеләре Имам әгъзам Әбү Хәнифәнең[1] каберен хурламасыннар өчен, алдан бер төркем гаскәр җибәреп, сак астына алдырды, һәм үзе барып бик олылап, тирән ихтирам белән зиярәт кылды. Шуннан соң Һиндстанга барып, аннан җиңеп кайтып, Бохарага килде. Әбү әл-Фәез хан каршы чыгып алып, аны кунак итте, хөрмәтләде. Ул да Әбү әл-Фәез ханга хөрмәт күрсәтте, аның һичбер кешесенә җәбер-җәфасы тимәде, бер кашык кан түкмәде. Ләкин ахыр гомерендә меланхолия – күңел төшенкелеге, тормышка өметсез карау авыруына дучар булып, үзенең урынына калачак Ризаколый мирзаның күзләрен сукырайтып, гөнаһлы һәм гөнаһсыз булуларына карамастан, башка бик күп кешеләрне азаплады, үтерде. Дагстаннан кайтып Хабушанда утырып калгач,

---

[1] Имам әгъзам – әһле сөннәт вәл-җәмәгать мәзһәбенең иң күренекле галиме.

кызылбашлардан тәмам йөз чөереп, барлык илтифат, мәрхәмәтен әфган һәм үзбәк халкына юнәлдерде. Кызылбашлар бу хәлгә каршы чыктылар. Аларны иртәгә үтереп, кырып бетерү уенда булганлыгын белеп алып, «Вакыйганы булдырмау чарасын аның вакыйг булуыннан элек күрергә кирәк» дигән мәкаль буенча, сиксән кеше киңәшләшеп, патша сараена киләләр. Җитмешләбе куркып керми кала, Салих хан Карахлы Әфшар ун кеше белән чатырына кереп, башын кылыч белән кисеп төшерә.

Бер баш ки, күкләргә чаклы күтәрелгән иде,
Ул хурлыкка төште: җир белән тигезләнде.
Бер баш ки, кичен җимерү-вату турында уйлый иде;
Таңда исә тәндә – баш, башта таҗ юк иде.
Кич белән таң арасында ни Надир, ни надирлек калыр
(һәммәсе бетәр).

Кызылбаш халкының хәзерге заманыбызда яшәүчеләре дә аны дошман тоталар. Надирнең үтерелүе мең бер йөз алтмышынчы (1747) һиҗридә җөмадиел-ахирнең унсигезендә сишәмбе көн кичәсе булды.

Надир дәүләте беткәннән соң, Иранда Кажария, Һиндстанда Әфгания, Мавәраэннәһердә Мангытия дәүләтләре барлыкка килделәр. Әхмәд хан әфганлыларга таянып, Надир гаскәрен тар-мар итеп, Кандәһар ягына китеп, шул якны яулап алды да куәтле бер дәүләт башлыгы булды.

Бохарада һичбер вакыт Сәлим хан һәм Морад хан исемле патшалар булганы юк. Төркия солтаннарыннан Морад хан III һәм аның атасы Сәлим хан II исемнәре бу кешенең колагына төшкән дә, шуны монда китереп ялганлый.

Янә: «Хозыр галәйһиссәлам Аксак Тимернең төшенә кереп, Истанбулга барырга кушты», – дип күп ялган һәм хорафатлар сөйләп: «Истанбул солтаны Мәһди белән җиде ел сугышып, ахырында хәйлә белән Истанбулны алып, солтан Мәһдине төрле азаплар белән үтереп, углы солтан Мәсгудне атасы урынына куйды һәм печтерелгән егермеләп галимне үтерде», – ди. Сүз арасында: «Гали Кошчы яшерен рәвештә Истанбулга кереп,

Дауд әфәндегә очрый һәм элек казый задә әр-Румине туры юлга өндәгәне өчен аның тарафыннан җәберләнде», – дип, озын-озак итеп лыгырдый. Болар барысы да ялган, ачык ялган, боларның һичберсе булганы юк.

Аксак Тимер күтәрелеп чыгуының бишенче елында, ягъни сигез йөз бишенче (1402) елда Рум мәмләкәтенә барды. Ул вакытта ул илнең патшасы «Елдырым Баязид» һәм «Баязид I» исемнәре белән танылган солтан Баязид бине солтан Морад әл-Гази иде. Истанбул әле һаман да алынганы юк, ул вакытта Төркия солтаннарының пайтәхетләре, ягъни патшалары тора торган башкалалары Бруссә иде. Тимер, Бруссәне яулап алып, Күтаһиядә кышлады һәм солтан Баязидны әсир итеп алып, ул шул тоткынлыкта вафат булды. Шигырь:

Тимер коткарса да, кылыч коткармас;
[аңа] урын – җирдә; күк аңа бирелмәс, –

дип, кайбер тарихчылар солтан Баязид турында, Тимер әйтте, – диләр.

Истанбулда солтан Мәһди һәм солтан Мәсгуд исәнендә хәзергәчә һичбер патша булганы юк. Багдадта Габбасия хәлифәләреннән Мөхәммәд бине Габдулла әл-Мәһди, Төркия дәүләте төзелүдән элек Румда һәм Иранда оешкан Сәлҗукия солтаннарыннан Мәсгуд исемле кешеләр бар. Истанбулны бу вакыйгадан илле өч ел соңрак, ягъни сигез йөз илле җиденче (1458) елда солтан Баязидның оныгының углы солтан Мөхәммәд бине Морад бине Мөхәммәд бине Баязид яулап алып, «Фатих»[1] исемен алды. Шуның өчен аны солтан Фатих һәм солтан Мөхәммәд II дип йөртәләр. Казый задә әр-Руми һәм Галлямә Кошчы – ул заман кешеләре түгел, аннан соңрак: Галлямә Кошчы Тимернең углының углы мирза Олуг бәк бине Шаһрух бине Тимернең остазы иде. Ул, Сәмәрканд шәһәрендә яшәп, рәсадханә бина кылырга керешкәннән соң, сигез йөз утызынчы (1426) елда

[1] Фатих – ачучы, мөселман патшаларның мөселман түгел илләрне яулап алуы «фәтх» (ачу), яулап алучыны «фатих» дип исемләү гадәте булган.

вафат булды. «Шәрхел-мөләххәс» китабының керешендә мирза Олуг бәк телгә алып үтелә, аның вафатыннан соң рәсадханә бинасын Галәветдин Гали бине Мөхәммәд әл-Кошчы тәмамлады. Ул «Тәҗрид» исемле китапка яңа шәрех язган мәшһүр Әбү әс-Согуд әфәнденең атасы белән бертуган кардәше һәм Сәед Шәриф Җөрҗанинең шәкерте була. Мирза Олуг бәк сигез йөз илле өченче (1449) елда Габделлатыйф мирза тарафыннан үтерелгәннән соң, Галлямә Кошчы Азәрбайҗанда төрекмәннәрдән Аккуенлы патшасы озын Хәсән янында яшәп, солтан Мөхәммәд әл-Фатихның чакыруы белән Истанбулга барды, сигез йөз җитмеш тугызынчы (1474) елда вафат булды.

Янә әйтә: «Безнең Болгарда бозыклык, үзен үзе үтерү, зина кылу, җомга һәм гает намазларын укымау шикелле начар эшләр күп иде, галимнәре рибаның[1] дөреслегенә фәтва биргән иделәр. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә әмир Тимерне алар өстенә ирекле кылды. Бикчура ханны унике вәзире һәм утыз алты галиме белән үтерде, энҗе шикелле хатын-кызларын кол итеп гаскәр башлыкларына бирде, калган халыкны бер атна эчендә читкә күчеп китәргә боерык бирде, шәһәрләребезне туп белән ватып, җимереп, Идел төбенә салды, сигез йөз алтмыш тугызынчы (1464) ел җәүзәнең[2] егерме җиденче көнендә Болгарны юкка чыгарды, дөньяда фәкать исеме генә калды», – ди. Бу сүзләре дә барысы да ялган булып, Болгар халкына бик зур яла ягып хурлаудан гыйбарәт. Тимернең шәһре Болгарга килеп берәр эш кылганлыгы һичберкемгә мәгълүм түгел. Аның мажарасы Туктамыш хан белән генә булды; Туктамыш хан Идегәй мирзаның хыянәте сәбәпле җиңелеп, гаскәре таралып, үзе Польшага качып сыенды. Бу вакыйга җиде йөз туксан дүртенче (1391) елда булды. Авторның аңлатуына караганда, Тимер бу эшләрне үлүеннән алтмыш ике ел соң эшләгән була. Әүлиядән булгач, бәлки, каберенннән чыгып эшләгәндер. Башка эше булмагач, яхшы шәһәрне ватып-җимереп, Идел төбенә салып,

---

[1] Риба – бераз артык итеп түләү шарты белән бурычка акча биреп тору.
[2] Җәүзә – май числосына туры килә торган йолдыз хисабы.

аның халкын таратып, никадәр начар һәм зарарлы эш эшләгән. Шулай ук мөселман хатын-кызларын кол итү, төш күрү белән кан түгү кайсы шәригатьтә дөрес икән? Олуг гөнаһларны кылучы да кяфер булмый.

– «Фәкыйһ Әбү әл-Ләйс әс-Сәмәрканди сине каберендә көтеп ята, каберең андадыр» диюе дә ап-ачык ялган. Фәкыйһ Әбү әл-Ләйснең чыгышы Сәмәрканд авылларыннан булса да, кабере Бәлехтә. Өч йөз җитмеш өченче (984) елда вафат булды, җөмадиел-ахир аеның унберенчесендә сишәмбе көн кичәсе остазы Әбү Җәгъфәр әл-Һиндеваниның баш очында күмелде: икенче бер сүзгә караганда, өч йөз җитмеш бишенче (985) елда вафат булган...

Янә әйтә: «Аксак Тимер тугыз йөз туксан икенче (1584) елда рамазан аеның 27 нче кичәсендә алтмыш өч яшендә Сәмәркандта, Тәфтәзани гаед көнендә вафат булды», – ди. Аларны бик изге вакытларда пәйгамбәр яшендә үтереп, саваплы һәм гөнаһтан пакь итәсе килгәндер. Тимер, Кытай сәфәренә чыгып, Фирганәдә «Утрар» дигән җирдә сигез йөз җиденче (1404) елда вафат булып, Сәмәркандка китерелеп күмелде. Ибне Гарәпша: «Аракы эчеп, исерек хәлендә үлде», – ди. Казый Әбү Сәгыйд сүзләренә караганда, элек һәм хәзерге көндә дә «Гүрәмир каберлеге» дип мәшһүр зиратта күмелеп, дошманнары мәетен мәсхәрә итәр дип куркып, балалары аннан алганнар һәм яшертен рәвештә икенче урынга күмгәннәр. Шуңа күрә каберенең кайдалыгы мәгълүм түгел. Тәфтәзани исә аңардан унбиш ел элек җиде йөз туксан икенче (1389) елда Тимер алдында утырган вакытта аңсыздан үлеп калды. Гәүдәсен Сәрхәскә илтеп, шәех Әбү әл-Фазыл Хәсән әс-Сәрхәси күршесендә күмелде. Аны: «Тимернең имамы булып, «Тәлхыйс» китабына озын итеп язылган шәрехне Тимер өчен кыскартып язды. Ул [Тимер] үлгәнче дәрес уку, сабак алуны ташламады; үлгән чагында да «Мишкяте шәриф» дигән китаптан хаҗ турындагы бүлектән дәрес ала иде» дигәне һәм шуңа башкалары барысы да ачыктан-ачык ялган. Тәфтәзани «Тәлхыйсел-мифтах» китабына шәрехне Тимер янына килгәнче, дөресрәге, Тимер властьны үз кулына

алганчы җиде йөз кырык сигезенче (1347–1348) елда язды. Кайбер нөсхәләренең кереш өлешендә безнең Сарай патшасы Җанибәк ханга[1] бүләк иткәнлеге әйтелә. Кайбер нөсхәләрдә Һират өлкәсендәге Көрт патшаларыннан берсенә бүләк ителгәне әйтелә. Әмма әмир Тимернең телгә алынганы бер җирдә дә юк.

Тимер җиде йөз туксан дүртенче (1391) елда Дәште Кыпчакка килде, җиде йөз туксан сигездә (1395) Чиркәс һәм Россиягә юнәлде. Сигез йөз бердә (1398) Һиндстан ягына барып, Мәхмүд Мөлү хан белән сугышты. Шул ук елда Сәмәркандта бер мәчет салдырды. Хәзерге көндә бу мәчетнең җимерекләре күмерче һәм утынчыларга урын, арбачыларга базар булган. Бер заман оныгы мирза Олуг бәк күп бүлмәләрдән торган мәдрәсә салдырды. Хәзерге көндә бу «Мәдрәсәи Ханым» дип танылган. Эшләтүченең ялгышы яки хыянәте сәбәпле начар эшләнгәнлектән, салынганнан бирле кирпече һәм ташы коела. Асылда, мөселманнардан, ярлы һәм мескеннәрдән җыелган мал хисабына эшләтелгәнлектән, заманының кайбер намуслы кешеләре мәчетебез хәрам, намазыбызның дөреслеге куркыныч астында дип, ярым шаяртып сөйләгәннәр. Шулай ук Бохараның гаед укый торган михрабы һәм укучыларга бирелә торган кайбер ярдәм, аерым кешеләрнең әйтүенчә, әмир Тимернең вәкыфы дип уйлана. Шуннан башка, аның эшләрендә изгелек юк. Аның җәбер, золым, кан кою, талау, игенлекләрне һәлак итү кебек начарлыклардан башка эше булмады. Үзенең яки балаларының берсенең тәлинкәсен ялаучы, ашын ашаучылар аны шул пычрак эш һәм золымнары белән дә мактыйлар икән, эшнең ничек икәнен һәм Аксак Тимернең нинди кеше икәнен белергә теләүчеләр Бәдретдин әл-Гайни, шәех Шиһабетдин бине Хәҗәр әл-Гаскаляни, Шәмсетдин әс-Сәхави һәм Ибне Шәхнә кебек, Мәккә һәм Мәдинә, Мисыр, Шам, Рум, Гыйракта яшәгән олы галимнәрнең ышанычлы әсәрләренә мөрәҗәгать итсен; канәгать итмәсә, Әхмәд бине Гарәпша әд-Димәшкыйның «Гараибел-

[1] Ш. Мәржани Җанибәк хан турында язганда да бу турыда искә ала.

мәкъдур фи нәвадири Тимур» исемле китабын карасын. Ул да җитмәсә, төрле мажара һәм вакыйгаларга игътибар итсен. Төрле хәл һәм мажаралары турында үзе төзегән «Тәзәккият» исемле төркичә бер җыентыгы бар. Һиндстандагы балалар өчен фарсы теленә тәрҗемә ителгән. Сәмәркандта вакытта күреп, тикшереп чыккан идек.

Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең китабында булган ялгыш-ялганнар чиктән тыш күп. Берсен дә калдырмыйча аңлаткан тәкъдирдә берничә томлык зур китап язарга кирәк булачак. Ул кадәр артык эштән тыелып, аңлатуның бу кадәресе белән чикләнеп, калганын акыл ияләренең үз фикерләренә йөкләп калдырабыз.

ӘЛ-КЫЙСМЕС-СӘНИ МИН КИТАБИ «МӨСТӘФАДЕЛ-ӘХБАР ФИ ӘХВАЛИ КАЗАН ВӘ БОЛГАР»

Россия тугыз йөз алтмыш беренче (1552) ел ахырында татарларны җиңеп, Казан шәһәрен һәм аның тирә-юнен яулап алганда, крепость эчендә сигез манаралы бер җамигъ мәчете[1], «Тажик ермагы» дип йөртелгән урында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә булып, галимнәр, габбасиларның[2] олылары һәм бөек сәедләрдән[3] берничә кеше, ә аларның башлыгы нәкыйбел-әшраф[4] аталган мелла Шәриф Кол[5] исемле бер кеше булып, ислам ханнары һәм шәһәр халкы каршында бик гыйззәтле һәм хөрмәтле зат иде.

Россия князьләре Казан ханнарына илче җибәреп хатлар күндергәндә, мелла Шәриф Колга үзенә махсус хат һәм бүләкләр җибәрәләр иде, диләр.

Ахырда, россиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә, үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә кереп, мәдрәсә түбәсенә чыгып, россиялеләр белән бик каты сугышып, руслар мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшереп шәһид булды.

[Халык уенча, крепость эчендә бер зур китапханә булып, андагы бик күп китапны россиялеләр фанатиклык сәбәпле яндырганнар һәм галимнәрне һәлак иткәннәр. Бу хәлдән соң Казан һәм аның тирәсендәге мөселманнар качканнар; «Боже матери» дигән сурәтләре килгәч, христианнар аны күтәреп чыгып, һәрбер урында дога һәм шөкер итәләр:[6]].

Хәзерге көндә крепость капкасыннан башланып, университетка хәтле сузылган төз һәм киң урам, крепость капкасыннан чыгып, ике якка төшеп киткән урамнар ислам хөкүмәте заманында да шулай булган. Бу заманыбызда борынгы мөселманнардан калган истәлекләрдән бер манара – мөселманнар хан мәчете дип, руслар Сөембикә манарасы дип исемлиләр. Крепость эчендә хәзер банк урнашкан һәм «дом» дип йөртелә торган

---

[1] Җамигъ мәчете – баш мәчет, җомга укыр өчен салынган мәчет.

[2] «Габбаси» – Якын Азиядә габбасилар хәлифәлегенә бәйле галимнәр.

[3] Сәед – башлык, җитәкче.

[4] Нәкыйбел-әшраф – бөекләрнең җитәкчесе.

[5] Мелла Шәриф-Кол – кол – Аллаһ колы мәгънәсендә.

[6] Цензура тарафыннан сызылган.

губернатор сарае янында «Тажик ермагы» исемле ермакта бер мәчет һәм мәдрәсә булган. Болакның көньягында хәзерге «Печән базары» дип аталган урында мөселман зираты икән. Руслар Казанны алганда, Шаһгали хан, гаскәр белән килеп, Зөя тамагында Зөя шәһәрен салып, шул тирәдә булган чуваш, чирмеш, калмык кебек халыкларны Россия кул астына кертеп, Казанга һөҗүмнәрендә Шаһгали хан алар яклы булып килгәндә, Казан мөселманнары хәзерге Җиһанша мәчете каршындагы чиркәү урынында булган нугай капкасыннан чыгып, бик каты сугыштан соң Шаһгали хан Арча кыры ягына чыккан һәм каберләр өстендәге агачларга яшеренеп Болакны үткән. Шәһәрне руслар алганнан соң да, мөселманнар бераз вакыт мәетләрен шул каберлеккә күмгәннәр, Йосыф бине Исхак бине Исәнкол бине Рахманколый бине Рәхмәтулла бине Габдерахманның ике углы Хәсән һәм Хөсәен үзләренең Рахманколый исемле бабаларын Печән базарында Әсәб җәлаб Мохтар бине Әднакол әл-Җәбәлли капкасы төбендә күмелгән атабыз Йосыф кечкенә чакта атасы Исхак белән бергә килеп, зиярәт кылганлыкларын сөйлиләр иде. Тагын Баязид бине Хәмид бине Арслан йортының, хәзер Гобәйдулла бине Габдулла бине Габдерәшид (Кәче авылыннан) йорты, аның бакчасында борынгыдан билгеле бер зират бар. Тагын Апанай Хафиз зәңгәр мәчет каршындагы каберлектә күмелгән, ә углы Исмәгыйль бабай ике бистә арасындагы каберлектә күмелгәнлектән, ике бистә арасындагы зират соңрак оешкандыр дип уйларга мөмкин.

Хәзер Казан шәһәрендә беренче мәчеттә[1] сөннәт бүлмәсендә[2] кабер өстенә куелган бер такта (таш) бар. Уң ягында: «Калә ән-нәби галәйһиссәлам: Әд-дөнья сәгатән фә әҗгальһа тагатән[3]». Сул якта язганы кубып төшкән, тик бер «Калә әл» сүзе генә калган. Алгы якта: «Калә Аллаһы Тәгалә: Күллү мән

---

[1] Беренче мәчет – хәзерге К. Насыйри урамында, Мәрҗанинең үз мәчете.

[2] Сөннәт бүлмәсе – мәчет, гадәттә, ике бүлмәле була. Шуның ишектән керүгә беренче бүлмәсе «Сөннәт бүлмәсе» дип атала.

[3] Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Дөнья – бер сәгатьлек. Сез аны гыйбадәт белән үткәрегез».

галәйһа фан вә ябка вәҗһе раббикә зөл-җәлали вәл-икрам. Тукыз йөз утыз алтыда Шаһмөхәммәд Бикмөхәммәд углы Мөхәммәдгали бәк зөлкагъдә аенда кяфер кулыннан шәһид[1]. Бу ташның аркасында язганы: «Бу ләвехне углы Тәңре Колы бәк бина кылды»[2]. Бу ташның озынлыгы ике кәздән[3] бине аз ким, киңлеге өч чирек, калынлыгы бер чиректән артыграк.

Ул таш Әхмәд бине Исмәгыйль әл-Казани әл-Айбашиның әйтүенә караганда, мең ике йөз утызынчы ел һиҗридә (1814–1815) Казанның югары урамында чәй кибетләре бина кылынганда, шул урында читек-башмак сәүдәсе белән утырганда почмактагы кибет урыныннан килеп чыгуын үз күзе белән күргән. Моннан соң ул ташны мелла Ибраһим әфәнде губернаторның рөхсәте белән беренче мәчеткә китереп, урта бүлмәдә кыйбла (көньяк) ягындагы көнчыгышка караган почмакка куйдырган иде. Ул таш анда торганда намаз укучыларга тарлык һәм шик китергәнлектән, аны төньяк почмакка күчерттем. Шуңа күрә бу таш чыккан урында тагын каберләр булган дип уйларга юл бар. Хәзер дә зәңгәр мәчет[4] урамы һәм яңа урам дигән урыннарда биналар өчен нигезләр, мең ике йөз туксанынчы (1873–1874) елда мунча өчен су юлы казыганда, каберләр һәм кеше сөякләре чыкканлыктан, бер заманда ул тирәләрнең дә зират булганлыгы беленә. Күл башында Әскаф (епископ) яшәгән йортта элекке мөселман каберләре бар. Шунда бина вакытында эшчеләр күп ташларны бина астына салганнар. Аны шул вакыт Казанда Әскаф, ахырдан патриарх булган Григорий күреп, эшчеләрне тыеп, беразы исән калган. Бигрәк тә капкасы төбендә, керүченең уңында бер олуг таш, бу таш гайре ташларга охшамый. Төсе кара, үзе бик каты,

---

[1] Аллаһы Тәгалә әйтте: «Дөньядагы бөтен нәрсәләр бетәчәк, бары олылыкка һәм хөрмәткә лаек Аллаһ үзе генә мәңгелек...» Тугыз йөз утыз алтыда (1529–30) шаһ Мөхәммәд бәк углы Мөхәммәдгали бәк зөлкагъдә аенда (ай хисабынча, 11 нче ай) шәһид (үтерелгән). «Аенда» сүзеннән соң «кяфер кулыннан» дигән сүзне цензор сызган.

[2] Бу ташны углы Тәнре Колы бәк ясатты. (Бу кеше Казан өчен сугышларда үтерелгән булса кирәк.)

[3] Кәз – аршин.

[4] Зәңгәр мәчет урамы – Нариман урамы.

зур. Биеклеге биш аршын ярым, киңлеге биш чиректән артык, калынлыгы ярты аршын чамасы. Язуы яхшы, сөлес язуы белән калкытып язылган. Укырга читен. Бердән, бик еш, чорнап, вак язган. Икенчедән, язучы кайбер сүзләр арасын бүләсе урында бүлмичә, бер ягын казып, икенче ягын казымый һәм әрчеми калдырган; өченчедән, күп кешеләр язу карасы сөртеп карап, шул кара катып калган. Бу кадәр сүзләр укылды. Башта өчпочмак эчендә бик эре язган: «Һү әл-Хәйүү әл-ләзи лә йәмүт»[1].

Моннан соңгы беренче юлда: «Һәза мәркадес-Солтан әл-әкбәре әл-әкраме гаусес-сәлатыйн[2]»;

Икенче юлда: «Әл-әмирел-мөкәррәм»[3].

Өченче юлда: «Әл-мозаффар»[4].

Дүртенче юлда: «Әл-кирам вәл-әҗалилел-гыйзам»[5].

Бишенче юлда: «Иләл-мозаффар»[6].

Алтынчы юлда: «Әш-шәрәфәйни мөфәххәре аль»[7].

Җиденче юлда: «Вәд-дине зыйллуллаһи лил-галәмин»[8]. Әл-әкрәмел-кәрим.

Сигезенче, тугызынчы юлларда: «Хәсән бәк бине Мирмәхмүд».

Укылмаган сүзләр кайбер юлларда азрак, кайберсендә күбрәк. Беренче юлны «Әл-әкрәмел-кәрим»[9] дип укырга мөмкин.

Дүртенче юлдагы «Әл-әҗалил» сүзе, тугызынчы юлда булган сүзләр җитәрлек ачык түгел. Кыскасы, бу таш патшаларның берсенең каберенә куелган. Гасыр һәм исеме ачык билгеле булмаса да, минем уемча, Чыңгыз нәселеннән булмыйча, аннан элек булуы сүз сөреше һәм өслүбеннән беленә. Янә чиркәү янында

---

[1] Ул терек һәм бер чакта да үлмәс.

[2] Бу – иң бөек, иң хөрмәтле һәм күп солтаннарны коткаручы солтанның кабере.

[3] Хөрмәтле әмир, җитәкче.

[4] Җиңүче, өстен булучы.

[5] Хөрмәтләрдән һәм иң бөекләрдән.

[6] Җиңүчегә.

[7] Ике хөрмәтле һәм ... мактанычы.

[8] Дин, галәмгә Аллаһның күләгәсе.

[9] Хөрмәтләрнең хөрмәтлесе.

икегә сынган бер таш бар. Күфи һәм нәсех язуы белән батырып язылган. Беренче юлы – буш. Икенче юлында: «Һү әл-Хәййү әл-ләзи лә йәмүт»[1]. Өченче юлда: «Вә күллү хәййин...»[2] Дүртенче юлда: «Әхмәд». Алтынчы юлда: «Рәхмәтән васигатән фани дөньядин»[3]. Җиденче юлда: «Бакый ахирәт[4] тарих алты». Сигезенче юлда: «Туштан алтыш җал эт». Тугызынчы юлда: «Айх сәкер күән иртә күән эт». Унынчы юлда: «Әл-мәүте бабән вә күллүн-нәси дәхилүһү»[5]. Унберенче юлда: «Бәгъдел-мәүт»[6]. Ягъни бу Әхмәд исемле кеше җомга көн зөлхиҗҗәнең сигезенче көнендә алты йөз алтмыш алтынчы елда вафат[7].

Халык телендә сөйләнүенә караганда, мөселманнар хөкүмәте вакытында яз аенда Болгар шәһәрендә, ул харап булгач, Казан шәһәрендә зур бер базар булып, анда Әстерхан, Кырым, Дагстан, Харәзем, Урта Азия, Кашгыр якларыннан, Россия шәһәрләреннән, Кытай сәүдәгәрләреннән күп кеше килеп, зур җыелыш, кызыклы уен һәм тамашалар булган икән. Шаһгали хан Зөя крепостен төзеп, шундый ук бер базар оештыргач, Казанда тәртипсезлекләр күплектән, Казан базары сүнеп, Зөягә күчеп, Казан руслар кулына күчкәч, Сура елгасының Иделгә кушылган урынындагы Василесурск шәһәренә, аннан Нижний[8] өлкәсендә Исад дип йөртелгән урынга каршы якка күчерелеп, шул урында күренгән дип уйланган Макар исемле изгеләренә нисбәт биреп, ул базар үзе, «Макарья», татарчада шуннан үзгәртелеп, «Мәкәрҗә» дип хәзер дә мәшһүр һәм танылган.

---

[1] Ул (Аллаһ) терек һәм үлмәячәк.

[2] Һәр терек...

[3] Күп рәхмәт, бетәчәк дөньядан.

[4] Мәңгелек ахирәт.

[5] Үлем – ишек һәм барлык кеше ул ишектән керәчәк.

[6] Үлгәннән соң.

[7] Искәрмә: Сүзләрнең тәрҗемәләре, җөмләләре тулы булмаганга күрә, төгәл килеп чыкмады. Мәгънәләре укучыларга яшерен калмасын өчен генә бирелде.

[8] Нижний Новгород.

Мең ике йөз утыз беренче (1815–1816) елгы янгында кибетләр һәм башка биналар янып, мең ике йөз утыз икенче (1816–1817) елда Ука елгасының Иделгә кушылган урынында кибетләр бина ителеп, хәзерге көндә зур биналар һәм башка төрле гыймарәтләр белән бик олы, төзек, йөз миллион, бәлки артыграк мал җыелуы мәшһүр. Ул базар, асылда, Болгар шәһәреннән Казанга күчерелгән. Соңгы заманнарда берничә авыл берләшеп, җәен җомга көннәрендә төрле урыннарда бер-бер артлы «җыен» дип аталган бер бәйрәм ясап, шулвакытта халыкның туган-тумача, дус-ишләренә кунак булып йөрүләре шул Казан базарыннан калган бер үрнәк, имеш.

Мөселманнарның дин һәм дөнья эшләренә катнашу һәм тарлыклар булмыйча, татарлар арасындагы дау, низаг, мәеттән калган малны бүлү, васыятьләрне җиренә җиткерүдә үз муллалары һәм олылары бу эшләрне карап хәл итеп, һәркайда һәм һәрничек үзләре каршында яраклы табылганча, теләгән рәвештә мәчет, мәктәп һәм мәдрәсәләр бина итеп, кемне ихтыяр итсәләр, риза булса имам итеп, имамнарны төшерүдә мәхәллә һәм авыл халкы ирекле булганнар. Балаларга исем бирү, өйләнү, мәетләрне күмүдә һәркем ирекле булып, читтән һичкем катнашмаган, ягъни Россия дәүләте бу эшләргә бертөрле дә тарлык итмәгән. Шуның өстенә, бистә халкы, ягъни шәһәрнең төп халкы булган мөселманнар телендә «йомышлы мөселманнар», россиялеләр каршында «татар сәүдәгәре» исемендә һичбер язусызнисез тулы ирек белән һәртөрле сәүдә эшләре рөхсәтле булып, бу хәл мең ике йөз егерменче (1806–1807) елга чаклы дәвам иткән. Моннан соң йомышлы мөселманнарның бу хокуклары, сәүдә тәртипләре бетерелеп, сәүдәгәрләр өч дәрәҗә, дүртенчесе мещан исемендә тәртип ителде. Беренче дәрәҗә сәүдәгәрләргә Россиядә, хәтта чит илләр белән сәүдә итү хокукы бирелде. Икенче дәрәҗәләләр Россиянең барлык өлкәләрендә, өченче дәрәҗәдәгеләр кайбер өлкәләрдә генә, ә мещаннар исә фәкать үз шәһәрләрендә генә сәүдә итәргә хокуклы булып, һәркайсы дәрәҗәсенә күрә хәзинәгә билгеле күләмдә салым түлиләр, мещаннардан башкалары солдатка алынмыйлар иде. Авыл

халкының исә дворяннарга башкалары ике төркем: берсе казах, берсе ясаклы исемендә булып, ясаклыдан фәкать имана алынып, солдатка алынмый иде. Казах дип аталганнары кирәк чакта солдатка барырга мәҗбүрләр иде. Россия дәүләтенең мәшһүр һәм мактаулы патшасы Пётр бине Алексей бине Михаил бине Фёдор бине Никита – «Беренче Пётр» яки «Бөек Пётр» дип аталган һәм Россия дәүләтендә император исемен беренче алган көне, мең дә туксан дүртенче (1682–1683) елда патша, мең бер йөз егерменче (1708–1709) елда император булып, мең бер йөз утыз җиденче (1725) елда үлде. Күп вакытлар дошманнарына өстен булган һәм һәртөрле фидакарьлек, зур тырышлыклар белән Россия шәһәрләренә күп һөнәрләр, промышленность кертеп, законнар төзеп, илне күп агартып, тәртипкә салган. Ул заманга чаклы Россия мәмләкәтендә ел исәбе дөнья яратылыштан исәпләнә икән. Мең бер йөз унөченче ел һижридә (1700) дөнья яратылышыннан 7208 булганда, милади тарих буенча бер мең җиде йөз иде. Башка христиан илләренә ияреп, дин һәм шәригатьләрендә бөтен эшләре ригая һәм олылау важиб булган хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам тууыннан исәпләп, милади тарихны кулланырга кушып, биш мең биш йөз сигезне ташлап, Гайсә тууны ел-тарих башы исәпләп, 1 нче январьдан башлап, милади тарих белән бер мең дә җиде йөз дә бер дип саный башладылар. Шул заманнан бирле рус халкы милади тарих кулланып киләләр. Айлары рум һәм юнанча (грекча) исемнәр белән гыйнвар, февраль һ.б. дип саналырлар.

Спас өязе Иске Рәҗәп авылының кешеләре игенлек, печәнлек һәм урман җирләрен, күршеләрендәге башка халыкларның чикләрен билгеләп язылып, хәзинә, ягъни печате белән беркетелгән язуларында һәм шул вакыттагы имамнарыннан булган мелла Зәйнелгабидин бине Габделкәрим исемле кешенең тәрҗемәсендә мондый язу күренде. Язу түбәндәгечә: «Тарих җиде мең дә ике йөз өченче, декабрьнең унөченче көнендә указ олуг, бөек падишаһ хәзрәте олуг князь Пётр Алексеевич һәм олуг һәм кечек ак падишаһ Россия йортын үзе тотучы, үзе биләүче, указ көче белән Казан өязенең Рәҗәп авылы татар-

лары югарыда язылган җирләрне сукалау һәм печәнен чабу өчен укадиләр[1] илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән ясак белән тармакка, ягъни түләргә, бу замандагы аңлатуны казнага түләргә яздым» (сүзе тәмам). Әмма мөселманнар һәрбер вакыйгаларда һиҗри тарихны кулланып, айларны мөхәррәм, сәфәр, шәһре рабигыль-әүвәл, шәһре рабигыль-ахир, җөмадиел-әүвәл, җөмадиел-ахир, рәҗәб, шәгъбан, шәһре рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә дип санап, фәкать игенчелек эшләре өчен кояш хисабы белән яз башыннан башлап, «хәмел, сәвер, җүза, сәрәтан, әсәд, сөнбелә, мизан, гакраб, кавыс, җәди, дәлү, хут» дип гарәби исемнәр, ә кайбер чакта мөселман гарәпләрдә йөртелгән Сирьяни исемнәр белән: «азәр, нисан, ияр, хәзиран, тәмүз, аб, илүл, тәшрин әүвәл, тәшрин сани, кянун әүвәл, кянун сани, шыбат» дип саный иделәр. Ул заманнарда Казан мөселманнары унике хайванга бәйле төрки тарихын да белә һәм куллана иделәр. Бу урында Олуг Кавал имамы мелла Сәлимҗан бине Дусмөхәммәд исемле кешенең бер китабында язган сүзе үзгәртмичә китерелде: «Руслар хисабы буенча җиде мең дә ике йөз дә сигез булган. Ул Адәм галәйһиссәлам тарихын ташладылар, ошбу мең дә җиде йөздән алдылар. Имди Гайсәнең тарихын мең дә җиде йөз дә бер дип саный башладылар. Мең дә җиде йөз дә сигез булды печин елында биш мең дә биш йөз дә сигез елы тәмам ташланды. И аңлы кеше, бел, кояш елының өч төрле хисабы бар: берсен фарсылар хисабы диерләр. Аның белән Болгар кешеләре файдаланганнар. Берсенә Румия хисабы диерләр. Христианнар аның белән файдаланганнар. Берсе белән барлык шәһәрләрдәге мөселманнар файдаланганнар. Димәк, хәмел хисабын белү барлык мөселманнарга тиештер, чөнки намаз вакытлары аның белән беленә, төш авышуы аның белән беленә. Тагын белегез: элек фарсы нәүрүзе, ун көннән соң румия нәүрүзе, аннан ун көннән соң хәмел нәүрүзе була. Нитәк шәһәре Болгар галимнәре «бала нәүрүз, карт нәүрүз, эсселек нәүрүз» дип күрсәттеләр. Һәрбер нәүрүз һаваның берәр

[1] Укадиләр – угодиеләр.

үзгәрешен күрсәтүче» (сүзе тәмам). Мәзкүр мелла Сәлимҗанның кайсы елда вафаты билгеле булмаса да, мең бер йөз сиксән икенче (1768–1769) елда 36 яшендә исән иде. Югарыда телгә алынган Беренче Пётр мең бер йөз уналтынчы (1704–1705) елда мәмләкәт халкын тәмам тәфтиш кылып, никадәр халык бар – исемнәре белән детальләштереп, саннарын дәфтәрләрдә беркеттереп, мең бер йөз утыз дүртенче һиҗридә (1721–1722) дөрес сан буенча шул халыклардан имана, ягъни салым алына башлады. Бу тикшерү рус телендә беренче ревизия дип танылды. Икенчесе мең бер йөз илле җиденче (1744–1745) елның ахырында аның кызы Елизавета патша заманында булды. Өченчесе – татарлар арасында «Әби патша» дип йөртелә торган Екатерина II (Алексей кызы) гасырында мең бер йөз җитмеш сигезенче (1764–1765) һәм шуның ук гасырында мең бер йөз туксан алтынчы (1781–1782) елның ахырында барс елында, бишенчесе – һәм сигез ел үткәч, алтынчысы – аның оныгы Александр бине Павел бине Пётр гасырында мең ике йөз егерме алтынчы (1811), җиденчесе – мең ике йөз утыз беренче (1815), сигезенчесе – мең ике йөз илленче (1834–1835), тугызынчысы – мең ике йөз алтмыш алтынчы (1850–1851) ахырында икенче оныгы Николай бине Павел гасырында, унынчысы – аның углы гасырыбызның падишаһы Александр II бине Николай заманында мең ике йөз җитмеш өченче (1856–57) ахырында үткәрелде. Әлеге Беренче Пётр гасырында мең бер йөз уналтынчы (1704–1705) елда берничә кешедән сайлап, беренче тапкыр солдат алынды.

Мең бер йөз егерменче (1708–1709) елда Россия мәмләкәте губерна дип исемләнгән өлкәләргә бүленде. Авыл халкының казак дип аталганнарына, кайбер чакта солдат бирү өстенә сугыш кораблары өчен урманнардан зур имән агачлары кисеп, билгеләнгән урынга ташу хезмәтләре йөкләнеп, солдат бирүдән азат ителгәннәр өчен бу хезмәтләр бик әйбәт саналып, хәтта аларга җан башыннан казнадан бераз хезмәт хакы да бирелгән. Безнең бабаларыбыз шушы казак дип йөртелгән төркемнән, мең бер йөз егерме өченче (1711–1712) елда Беренче Пётр Казанга килеп, иң башлап лашман хезмәтенә җиде йөз мең

кеше билгеләнеп, мең бер йөз утыз өченче (1720–1721) елда штаб ачылып, киметелеп, йөз егерме меңгә калдырылды. Шул гасырларда сугыш көймәләре ясалып, лашман хезмәте беткәнче, имән агачын кисү кискен рәвештә тыелды. Әгәр берәүнең имән кискәне билгеле булса, яман җәза бирелә һәм кеше үтерү хөкемендә була иде. Моннан соң мең ике йөз алтмышынчы (1844) елларда ут көче белән йөри торган көймәләр уйлап табылып, Россия мәмләкәтендә дә ут көймәләре ясалып, агачтан сугыш көймәләре ясау һәм аңа бәйләнешле хезмәтләр бетеп, мең ике йөз җитмеш алтынчы (1859–1860) елларда лашман хезмәтенең атлы һәм җәяүлесе тәмам бетерелеп, лашманчы казактан һәм ясаклыдан бертигез солдат алына башлады.

Башта бер өйдән бер кеше алу, соңыннан, артында булганны һәм күпле барында азлыдан алмау кебек законнар булса да, ләкин эштә күп кимчелекләр булып, ул шартлар тиешенчә сакланмыйча, күп золым һәм җәфалар тудырыла иде. Чиратта торган кеше читтә булса, я качса, чираты булмаган кеше алына иде. Шуңа күрә чираттагы кешеләрне тотып, кулларын бәйләп, каравыллап, бер ун-унбиш көн артыграк та йөртелә иде. Хәтта безнең заманда шул эшләр булып, чираттагы кеше качмасын дип, бер богау белән һичбер гаебе булмаган икенче бер кешенең аякларына богаулыйлар иде. Бөтен эштә, хәтта йоклаганда һәм бәдрәфкә чыкканда, икесе бергә булалар иде. Бу – үз күзебез белән күргән хәлләрдән. Безнең заман хәлләреннән: бер чит кешене бер-бер эштә шаһит дип ерактан, төрле мәшәкатьләргә очратып китертеп, килә алмаса, баш бирмәүче дип җәзалап, әгәр килсә, гаепсезгә ябып куеп, күп кенә яраклы эшләрне һәлак итү кебек.

Сиксән дүртенче набордан башлап, мөселман урынына русны һәм киресенчә алу тыелды, ә бер мең ике йөз җитмеш беренче (1854–1855) елда бу шарт бетерелде. Солдат алу законы тирәсендә вак-төяк үзгәрешләр һаман булып торса да, озынайту һәм детальләштерүдән хөкүмәт һаман сакланып килде. Ниһаять, мең ике йөз туксан беренче (1874–1875) елда чыгарылган яңа закон буенча, һәммә халыктан, гомумән, 21 яшь тулган егетләр

кирәк кадәр алына башлады. Казан сәүдәгәрләреннән мөселманнардан беренче булып, Шәмсетдин бине Сәгъдетдин әл-Күгәрчени углы Җәлалетдин алынды. Юныс бай балаларыннан ике кеше өчен акча түләнде. Ата-аналарының берсе эшкә яраксыз яки ятим, авыру, зәгыйфь кардәшләре булып, башка ярдәм һәм тәрбия итәрлек кешеләре булмаганнар бу законга кертелмиләр. Солдат хезмәте башта егерме биш елга чаклы сузылып, хәзер унбиш ел, ә күбесенчә алты ел хезмәт соңында рөхсәт белән илләренә кайтаралар. (2–12 б.)

Беренче мәчет[1] – безнең хәзер яшәгән мәхәллә мәчете. Мең бер йөз сиксән беренче һиҗридә (1767–1768) Екатерина II Казанга килгәндә мөселманнар мәчет салырга үтенеп мөрәҗәгать иткәннәр. Үтенечләрен патша кабул итеп, бина өчен кирәкле нәрсәләрне хәзерләп, эшкә керешеп, бер мең бер йөз сиксән дүртенче һиҗридә (1770–1771) тәмам булып, намаз укыла башлаган. Бу беренче мәчетнең урыны мелла Әбү Бәкер бине Ибраһим, Ягъкуб бине ..., һәм Мортаза бине Йосыф бине Каныш, мәзин Исхак бине Ибраһимнарның йорт урыннары икән. Бу мәчетне бер генә кеше салдырмаган, бәлки алтмыш ике кешедән җыелган биш мең сум акча тотылган. Бинасы өчен иң күп көч куйган кешеләрнең алдынгысы – мелла Габдерәшид бине Йосыф әл-Каргалы, мелла Әбү Бәкер бине Ибраһим, Мортаза бине Йосыф бине Каныш, Ибраһим бине Ядкяр бине Нияз һ.б. Мелла Габдерәшид мәчет кирәкләре өчен хәтта Әстерхан шәһәренә чаклы барган. Борынгы картлар сөйләвенә караганда, бу мәчет бинасына хәзер «Озыннар»[2] дип йөртелгән мәхәллә байлары Юныс балаларының һичбер катнашлары булмаган, һәм ул заманда алар бай да булмаганнар. Хәтта бер мең бер йөз җитмеш җиде һиҗридә (1763–1764) бабалары Мөхәммәдрәхим бине Юныс, шул мәхәллә кешеләреннән Габдерәшид бине Рәхмәтулладан ваклап алган бурычларын түли алмагач, атасыннан калган һәм үзе яши торган йортны шул бурычны түләү өчен

[1] Мәрҗани мәчете. Каюм Насыйри урамында.

[2] Озын Ибрай, Ибраһим бай Юнысов.

биргән. Йортны сатканлыгы турында төзелгән язуыннан кайбер кисәкләре монда китерелә: «Югарыдагы сәбәпләр өчен мин, Иске Бистәнең йомышлы мөселман, Мөхәммәдрәхим Юнсай углы 1763 нче милади елда саттым мәзкүр йортымны 28 майда егерме биш сумга хисаплап, йомышлы мөселман Габдерәшид Рәхмәтулла углына (тәмам)». Үз кулы куелган ошбу язуны Габделваһһаб бине Габдерәшид исемле карт кулында үзебез күрдек. Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим, борадәре Габделкәрим белән бергә, һәр икесе солдатка китүдән куркып, каенатасы Йосыф бине Исмәгыйльнең очырмасында качып ятканнар. Шулвакытта чиратлары җиткән кешеләрне хәзер тоту һәм тапшыру эшләрен үтәүче мәшһүр «Кәҗә Муса» исемле кеше, угылларыңны табып бир, дип, Мөхәммәдрәхимне «Тәбәнәк Гомәр» дигән кеше белән бергә богаулап, гади адәмнәрне бергә исәпләп алганда, мондый озын кешене икегә хисаплап алмаслар микән дип мыскыллап, авылдан килгәннәргә күрсәтеп йөрткәннәр. Болар, Габделкәрим бине Мөхәммәдрәхим ярдәмендә кеше арасына кереп, күп акчага ия булганнар. Асылда, байлык Габделкәримнеке икән. Гобәйдулла, алдалап, Мөхәммәдрәхимнән калган дип бүлдергән. Гобәйдулла байның «Абзый үз ишләре белән утырганда, без ишек астыннан гына ятып карый идек» дигән сүзләре халык телендә йөри. Чыннан да, дөнья малын берәү табып, туганының шуны үзләштерүе күп. Мәхәллә кешеләреннән Мостафа бине Муса бине Исмәгыйль бине Ибраһим бине Ядкяр бине Нияз бине Фәридун бине Шәех гарәп һәм әтисенең туганының углы Салих бине Йосыф бине Исхак бине Ибраһим әл-Әсвәдләр беренче мәчетне безнең Ибраһим бабабыз бина кылган дип дәгъва кылалар иде. Мостафа мең ике йөз җитмеш бишенче (1858–1859), Салих мең ике йөз сиксән сигезенче (1871–1872) елда вафат булдылар. Салих бине Йосыфның үз дәфтәренә, «Тәварихы Болгария»дән алып булса кирәк, «Олуг бабамыз Зөбәер бине Җәгъдә[1], әбиемез Туйбикә» дип, ышанычсыз бер сүз язганлыгын күрдек.

[1] «Тәварихы Болгария»дә Зөбәер бине Җәгъдә – Мәккәдән X гасырда Болгарга килгән кеше, Туйбикә шул чактагы Болгар патшасының кызы» итеп күрсәтелгән.

Бу нәселдән хәзердә бары Мөхәммәҗан бине Шәриф бине Мостафа бине Муса исән.

Беренче мәчет башта күп кешенең ярдәме белән бина кылынса, заман үтү белән төзәтүләргә мохтаҗ булганда, берәүнең теләк һәм ихтыяры белән кирәк кадәр төзәтелгән һәм өстәмә биналар эшләнгән. Беренче салынганда түбәсе агач тактадан[1] булып, мең ике йөз унынчы (1795–1796) елда Габид бине Габделбакый, бер кеше белән бергәләп, такта[2] белән яптырып, мең ике йөз уникенче (1797–1798) елда янгач, тагын агач белән яптырганнар. Мең ике йөз кырык тугызынчы (1833–1834) елда Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим тимер белән яптырган. Мең ике йөз җитмеш җиденче (1860–1861) елда углы Ибраһим таш койма белән әйләндерде, элек – агач рәшәткә иде. Мең ике йөз сиксәненче (1865–1866) елда михрабны бераз микъдар көнчыгышка юнәлдерә төшеп, биегәйтеп һәм киңәйтеп, бер тәрәзә куеп, ә мең ике йөз сиксән... (186...) елда мәчетнең алды ягыннан канат чыгарып, озынлыкка бер тәрәзә арттырып, баскыч бүлмәсен таштан бина кылдырды. Мең өч йөз өченче (1885–1886) елда хаҗи Зәйнулла бине Госман карамагында манарасын ныклап, яңадан бина кылынды, мең өч йөз бишенче (1887–1888) елда Аты авылыннан күчкән хаҗи Вәлиулла бине Гыйззәтулла бине Төхфәтулла һәм Кушлавыч авылыннан күчкән Мифтахетдин бине Вәлишаһлар тарафыннан ике йөз илле сумга төшереп, азан әйтә торган җиренә нык тимер рәшәткә куелды. (12–14 б.)

Бу мәчетнең аскы катындагы түр бүлмәсе ошбу мәчеттә булган имамнарның кирәкле хезмәтләре, икенче һәм өченче бүлмәсе мәчет кирәкләре, дүртенче бүлмәсе мәктәп өчен билгеләнеп, Ибраһим әфәнде килгәнче мәктәп булып, Бикбау бине Мортаза бине Йосыф бине Каныш бине Биктә бине Бики һәм Габделкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Юныс һәм Гобәйдулла бине Мортаза һ.б. шул мәктәптә мелла Әбү Бәкер бине

---

[1] Агач такта – сүз «дранча» дип йөртелгән һәм балта белән ярылган такта турында булса кирәк.

[2] Такта – пычкы белән ярылган такта булса кирәк.

Ибраһимнан сабак укыганнар. Мәзкүр әфәнде гасырында [Ибраһим бай вакытында] бу мәктәпне бушатып, күл буенда яр астында мәдрәсә бина кылынып, мәхәллә шәкертләре шунда яшәгәннәр. Ул мәдрәсә тузгач, мең ике йөз кырык алтынчы (1830–1831) елда мелла Госсаметдин бине Ибраһим сатып, акчасын үзе тотып бетергән. Икенче мәхәллә мәдрәсәсе мелла Исхак бине Сәгыйд үлгәннән соң буш тора икән, мелла Сәгыйд бине Хәмид шул мәдрәсәгә барып йөргән. Моннан соң мең ике йөз илле өченче (1837–1838) елда мәхәлләнең зур бае Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим бине Юныс мәйданнан килеп, күл буена чыга торган аркылы урамда Габдулла бине Әбү Бәкер бине Ураз Наласави дигән кешенең йортын сатып алып, асты таш, өсте агач ике катлы йорт эшләтелде. Бу йорт урамның көнбатыш ягында, һәр ике чаттан һәм күл буеннан берәр йорт эчтәрәк иде. Йортның икенче катында урам буена караган ягы җиде тәрәзәле, ике башында дүрт тәрәзәдә, асты – яртысы кибет, калган яртысына ишегалды ягыннан ике тәрәзә; йорт такта түбә белән ябылган. Шул йортка мәдрәсәне урнаштырып, мең ике йөз алтмыш дүрткә (1847–1848) чаклы мелла Сәгыйд мөдәррис булып, соңра бу юлларны язучы фәкыйрь мөдәррис булганда, Гобәйдулла углы Ибраһим түбәсен тимер белән яптырып, кызылга буятты. Шул вакытка чаклы Казанда булган мәдрәсәләрнең зиннәтле, гүзәл һәм күркәме булганга, Гобәйдулла бай бер мәҗлестә Бохарадан кайткан меллаларга: «Бохара мәдрәсәләре минем мәдрәсәм кебек булырмы?» – дигәч, берсе: «Бохара мәдрәсәләренең бәдрәфләре дә синең мәдрәсәңнән артык», – дип җавап бирде. Монда сорауучының да, җавапның да чиктән тыш китүләре ачык иде.

Моннан соң ул мәдрәсә тузып, тәмам эштән чыгып, җимерелү, бетү хәленә килгәч, [Гобәйдулла байның] балаларыннан үзем, шулай ук күп кешеләр аркылы, мәдрәсәне төзәтү һәм ремонтлау турында ничә тапкыр мөрәҗәгать итсәк тә, һич илтифат кылмаганлыкларыннан, мәхәллә халкы киңәше белән, Ибраһим бине Гобәйдулла һәм аңа башка бай картлардан унлап кешене үз өемә чакырып, мәдрәсә хакында сөйләшеп, үзем аякка басып үтенгәч: «Әле вакытым юк», – диде. «Вакытыгыз

булмаса, башка берәүгә рөхсәт итегез», – дигәч, «Әле вакытым юк, үз вакытым белән эшләрмен», – дип җавап бирде. Моннан соң мәхәллә халкы, һәрберсе шул ук сүзне кабатлап, зинһарлап: «Вакытыгыз булмаса, без хезмәт итик, хәтерегезгә авыр килмәсә, үз кесәбездән акча тотыйк», – дип үтенсәләр дә, сүзләре үтмәде һәм байның колагына кермәде. Теләге: я мәдрәсә җимерелеп, берничә кеше һәлак булып, фетнә кубып, кызык итеп көлеп карап тору яки шәкертләр тора алмыйча таралып, «укытмады, мәдрәсәгә кермәде» дип, төрле ялганнар кушып, яла ябу, гайбәт тарату иде. Мәхәллә кешеләреннән Шәмсетдин бине Фәйзулла бине Йосыф, Борһанетдин бине Фәхретдин, Габделгани бине Фазыл бине Габид бине Фәйзулла, Габделвәли бине Йосыф, Һибәтулла бине Мортаза, Шаһи Әхмәд бине Хисаметдин бине Салих бине Әбү Бәкер Симетбаши, Хәмид бине Сабид бине Вәлид бине Габдерахман әл-Чуашили, Мифтахетдин бине Вәлишаһ, Исмагыйль бине Тимерфулад, байның бу сүзләренә ачуланып, гайрәтләнеп, баерак кешеләрдән акча җыйдылар. Шул вакытта читкә күчеп киткән хаҗи Габдерахман бине Биньямин бине Ибраһим бине Биккол әл-Казани әт-Төркинең Казан шәһәрендә күл буена төшә торган юлның мәчеткә каршы якта булган йорты, бурычын түләтү өчен, торги белән сатыла иде. Сәүдәгәрләрдән Әхмәд бине Фазыл бине Нигъмәтулла бине Бәшир бине Габдерәхим бине Ураз әл-Буави (ибне Рәхмәтулла дип йөртелгән кеше) исеменә шул йорт өч мең ике йөз сумга сатып алынды, Аллаһы Тәгаләнең көтелмәгән җирдән бирүе, рәхмәте сәбәпле, мең ике йөз сиксән сигезенче (1871–1872) елда сәфәр аеның егерме беренче көнендә яңа мәдрәсә төзүгә ирештек. Бу кадәресе өч мең дүрт йөз илле бер сумга төште. Ләкин бу йорт таркау, берничә кеше кулында булганлыктан, икенче тапкыр сатуга куелып, мең ике йөз туксан беренче (1874–1875) елда рәҗәб аенда җомга көн бер мең ике йөз сиксән дүрт сумга хаҗи Сафа бине Галикәй бине Габделгазиз бине Надиршаһ бине Бикбай бине Исламкол Мәмсәви бер кисәк җирне агач өе белән үз хисабына сатып алды. Янә бер кыйтга җирне шимбә көн кич мең ике йөз туксан икенче (1875) елда әлеге хаҗи исеменә бер

йөз ике сум ун тиенгә алып, мәдрәсәгә кушылды, мәчет һәм мәдрәсәне карап тору мелла Габделгани бине Фазлулла бине Габид һәм Зәйнулла бине Госман бине Җәзи бине Ибраһим бине Арсланнарга тапшырылды. Якшәмбе көн мең ике йөз сиксән сигезенче (1871–1872) елда рамазан аеның җиденче көнендә иртә белән шәкертләр күчеп килделәр. Моннан соң мең ике йөз сиксән тугызынчы (1872–1873) елда Исхак бине Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим, аталары бина иткән иске мәдрәсәне ватып, халыкка зарар һәм фетнә салу өчен, һәр ике катын таштан мәдрәсә итеп эшләтеп, мәхәлләнең яңа мәдрәсәсен юк итәргә теләделәр. Аллаһ бозучыны төзәтүчедән аера. Бу мәҗлестә фәкыйрьдән [миннән] зарланып, мәдрәсәсе белән мактанып утыруына каршы, әлеге Әхмәд бине Фазыл мәдрәсә салу белән мактануына каршы: «Мәдрәсә салу белән мактанма, кулында байлыгы булган кешегә ул берни түгел, бер җәйлек эш. Байлыгы булган кеше сез булмаса, без булмаса, икенче бер кеше аны үти. Менә син мелла, галим булуны кара: утыз ел кирәк, анда да була алмыйлар, булганы аз», – дип, сүздән туктатты. Моннан соң берничә тапкыр начар ният белән ут салсалар да, сизелеп, янмый калып, ниһаять, алтынчы тапкыр... көндә мең ике йөз туксан икенче (1875) ел рамазан аеның егерме җиденче көнендә тәравих вакытында, халык мәчеткә җыелгач, ут салып, мәдрәсә янып юкка чыкты. Бик күп Коръән, китап, башка кирәк-яраклар һәм бик күп күгәрчен һәлак булды. Гәүдәләре янып бетми калган күгәрченнәр генә биш йөз данә иде диделәр. Бу вакытка чаклы мәдрәсәгә ут салып яндыру моңарчы күрелгәне һәм ишетелгәне юк.

Ибраһим бай шул көнне үз мәдрәсәләрен яктырып, җылытып куйган. Тәравихтан чыккач, мәчетне бикләп, шәкертләр кунмасыннар дип, ачкычны алып киткән икән. Шунда әлеге Әхмәд бине Фазыл зур көч куеп, өч йөз алтмыш җиде сум алтмыш җиде тиен акча тотып, тиз вакыт эчендә түшәм, идән һәм тәрәзәләрен өлгертеп, шәүвәлнең унҗидесендә кечатна көн шәкертләр һәркайсы мәдрәсәгә кайтып, шатлык һәм саф күңел белән изге догалар кылынды. Мең ике йөз туксан җиденче (1879–1880) елны

берничә изгелек иясе кешеләр үзара акча җыешып, мәчет һәм мәдрәсәне караучы хаҗи Зәйнулла бине Госман бине Җәзи Корткачыгый исеменнән яңа мәдрәсә салуга рөхсәт алып, ул хаҗ сәфәренә киткәч, хаҗи Сафа бине Галәкәй Мәмсәвине вәкил итеп, шушы «Мәдрәсәи Галия» бинасына керешелеп, иркен, күркәм планлы, ярдәмче биналары булган, озын, ике катлы, урам буенда һәм ишегалды ягында уникешәрдән егерме дүрт, баш-башында бишәрдән югарысы ун тәрәзәле, егерме бүлмәле гаҗәп матур һәм уңайлы булып, мең ике йөз туксан сигезенче (1880–1881) елда тәмам һәм шәкертләр кереп урнаштылар. Барлык расход унсигез мең сум булды. Туксан җиденче елда көнбатыш өлеше тәмам булып, аскы катның көньяк-көнбатыш почмагындагы бүлмәдә Салих бине Муса бине Яхъя әл-Латыйшиның кыйраәте белән дәрес башланып, бераздан соң көнчыгыш ягында да дәрес башланып, мең ике йөз туксан сигезенче (1880–1881) елда зөлкагъдә аеның унөченче көне кечатна көндә төш җитәр алдыннан Фатих бине Хафиз бине Насыйр бине Габдессәлам Бәрәнгәвинең «Фаваиде зыяия»дән, мәрхүм сөекле бала Мәхмүднең «Китабен-никая»дән укып торуы буенча дәрес бирелде[1]. (16–20 б.)...[2]

Алтынчы имам – мелла Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан, бине Габделкәрим әл-Мәрҗани. Анасы Бибихөбәйбә бине Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф мең ике йөз утыз өченче (1817–1818) ел кечатна кичтә рабигыль-әүвәлнең җидесендә, ай күренмәү сәбәпле, ай башларын төгәл итеп исәпләгәндә – бишесендә Ябынчы авылында шәфәкъ баткач дөньяга килде. Мең ике йөз утыз җиденче (1821–1822) елда җомга көн рабигыль-әүвәлнең

---

[1] Ш. Мәрҗанинең бу җөмләсен хәзер аңлау кыен. Элекке мәдрәсәләрдә дәреслек итеп сайланган китаптан бер кисәкне бер шәкерт кычкырып укый да, дәрес бирүче дамелла я хәлфә шул укылган кисәк буенча сөйләп китә иде. Бу җөмләне шушы тәртипне аңлата.

[2] Мәрҗани бу мәдрәсәне салу өчен кемнәрнең күпме акча биргәнлекләрен санап китә. Аннан соң бу мәчеттәге муллалар турында яза. Без Мәрҗанинең үзе турындагысын гына алдык.

унбишендә атасы Баһаветдинне имам булу өчен күчерделәр. Әнисе Бибихөбәйбә мең ике йөз утыз сигезенче (1822–1823) елда үлеп, зур кайгыга сәбәп булды. Моннан соң укырга керешеп, мәрхүм атасы мәдрәсәсендә мелла Әхмәд бине Габделҗәлил Тәрҗемани, мелла Әхмәд бине Зөлхиҗә, мелла Тажетдин бине Габделҗәлил бине Хөсәен бине Сафкол бине Коттый Сәрдәви, мелла Корбан бине Мөхәммәд бине Мансур бине Сәед бине Сөбхан h.б. дан файдаланды. Әткәсеннән «Шәрхе җами»[1], «Шәрхе шәмсия»[2], «Шәрхе гакаид»[3] һәм «Тәүзыйх»[4] дәресләре укып, мең ике йөз илле дүртенче (1838–1839) елда рабигыль-әүвәл аеның дүртенче атнасында шимбә көн Урта Азиягә сәфәр һәм алтынчы шәүвәлдә Бохарага иреште[5]. Бохарада мелла мирза Салих бине Надир бине Габдулла Хөҗәнди, мелла Мөхәммәд бине Сафар Хөҗәнди, мелла Фазыл бине Гашур Гаҗдувани, мелла Габделмөэмин Хуҗа бине Үзбәк хуҗа Әфшәнҗи, хаҗи мелла Ходайбирде әл-Байсүни, мелла Баба Рафиг Хөҗәнди, казый Шәриф бине Гата бине Һади әл-Бохари, ә Сәмәркандка килгәч, мең ике йөз алтмышынчы елда казый Әбү Сәгыйд бине Габделхәй бине Әбү әл-Хәер бине Әбү әл-Фәез бине Гариф Сәмәрканди хәзрәте һәм башкаларның дәрес мәҗлесләрендә хәзер булып файдаланды. Мең ике йөз алтмыш бишенче (1847–1848) ел рәҗәб аеның унынчы көнендә кайтырга чыгып, сишәмбе көн Сәйхун елгасыннан үтеп, шәгъбан аеның унтугызында Имән кальгагә кереп, бер атна анда ял иткәннән соң, тагын алга хәрәкәт итеп, шәгъбан аеның соңгы, шимбә көнендә Оренбургка, анда бер атна торгач, рамазан аеның уникесендә чәршәмбе көн Казанга килеп җитеп, унөчендә иртәнге намаздан соң ияләнгән ватан һәм күнегелгән урын Ташкичүгә кайтып, терек һәм үлекләрне, атаананы зиярәт кылу шәрәфенә ирешелде.

---

[1] «Шәрхе җами» – гарәп теленең синтаксисын өйрәтә торган китап.

[2] «Шәрхе шәмсия» – гарәп телендә мантыйк китабы.

[3] «Шәрхе гакаид» – гарәп телендә кәлям китабы.

[4] «Тәүзыйх» – ислам шәригате методологиясе китабы.

[5] Димәк, Мәрҗани Бохарага 7 айдан артыграк барган.

Җомга көн 14 нче зөлкагъдәдә, Казан шәһәренә килү өчен, Кари Әбү әл-Касыйм бине Йосыф бине Шаһбарди әл-Бохари аргамак һәм кәрвандагы бүтән кешеләр, Мохтар бине Мөхәррәм Мәңгәринең аңлату һәм мактаулары белән, Ибраһим бине Гобәйдулла бине Юныс галимнәр мәҗлесе ясап, безне сынау һәм сайлау өчен шәһәрнең галимнәрен һәм башка олыларын җыеп, мелла Гали ишан Түнтәри, мелла Хәбибулла бине Рәхманколый, мелла Әхмәд бине Сәгыйд, мелла Габделгафур бине Мәхмүд, мелла Хөснетдин бине Гомәр, мелла Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим, мелла Шаһ Әхмәд бине Әбү Язид, мелла Шәмсетдин бине Зөбәер әл-хафиз[1], мелла Әсфәндияр бине Ибраһим, мелла Габделкаһһар бине Габдессәттар, мелла Нурмөхәммәд әл-мөхтәсиб, мелла Шиһабетдин бине Фәхретдин, мелла Габделвәли бине Габделгаффар, мелла Хөсәен бине Әмирхан һ.б., шулай ук мәхәлләдәге тагын кайберәүләр хәзер иде (42–44 б.)[2].

Бу мәҗлес соңында Казан шәһәрендә һәм тирә-ягында сүз күбәеп, олы шөһрәт һәм күп сүзләр чыкты, шул сәбәпләрдән мелла Мөхәммәдкәрим фәкыйрьгә [«миңа» дигән сүз] каты дошман булды.

Мәҗлес беткәч, тора торган урыныбыз Габдулла бине Мәхмүд Казакларый йортына Мохтар бине Мөхәррәм килеп, Ибраһим һәм мәхәллә халкы тарафыннан илчеләр килүе, беренче мәчеттә бу фәкыйрьнең имам-хатыйп һәм мөдәррис булуын үтенүләрен ирештерде. Фәкыйрь атабыздан рөхсәт алу шарты белән вәгъдә бирдем, моннан соң мәхәллә халкыннан иттифакънамә[3] алып, Ибраһим байның корбан ашына чакыру

---

[1] Әл-хафиз – Коръәнне яттан белүче.

[2] Мәрҗани бу мәҗлестә озак бәхәсләрнең нинди темаларга барганын яза. Сүз озын була, мәҗлестәге кешеләр каршында һәр ике як тигез калган кебек тоелса да, мелла Гали ишан, мелла Әхмәд, мелла Хәбибулла, мелла Габделгафур кебек заманының авторитетлары Мәрҗани ягын куәтләгәннәрен әйтә.

[3] Иттифакънамә – мулла сайлаганда мәхәлләдәге барлык йорт башы кешеләре кул куйган кәгазь.

килеп, атабыз белән бергә Казанга килдек. Зур мәҗлес булып, анда да кайбер аңлашу һәм бәхәсләшүләр булып, аннан башка мәҗлесләрдә дә катнашып, соңыннан авылыбызга кайттык, мең ике йөз алтмыш алтынчы (1849) мөхәррәм аеның соңгы ун көнендәге чәршәмбедә шәһәрдән мәзин Халид бине Исхак бине Исмәгыйль әс-Сагати, Ибраһим бине Фәтхулла бине Мөсәгыйд бине Заһид сигез ат җиккән өч чана һәм башка кирәк-яраклар белән Ташкичүгә алмага бардылар.

Мелла Насыйх бине Габделгаффар бине Габделхәмид Түнтәри, Насыйбулла бине Фәтхулла бине Яхъя бине Габделбакый Ташкичүи белән бергә мөхәррәм аеның соңгы тугыз көнендәге җомга көннең таңында Казанга килеп, Чүкиннар урамында Габделмәҗид бине Гобәйдулла бине Биккенә бине Сөбхан әл-кассаптан[1] калган йортка төшеп, беренче тапкыр җомга намазын имам булып укыдым. Чәршәмбе көн беренче тапкыр мәдрәсәгә кереп, дәрес башланды. Дүшәмбе көн рабигыль-ахир икесендә Уфа шәһәренә сәфәр итеп, алтысы көнне төшкә чаклы мөфти Габделвахид бине Сөләйман, казыйлардан мелла Габделҗәббар бине Рәхманколый, Төхфәтулла бине Хәлил әш-Шәмаки, Тажетдин бине Мөштәри әл-Үтәмишләр хозурында имтихан ясалып, «Әлхәм» сүрәсе укып дога кылынды. Сишәмбе көн Казанга кайттым. Егерме җиденче җөмадиел-әүвәлдә чәршәмбе көн мең сигез йөз илленче милади, алтынчы март 2011 номерлы указ белән беренче мәчеттә имам җамигъ, хатыйп һәм баш укытучы булып расландым.

Җөмадиел-ахирнең икенче якшәмбесендә Казанда мәрхүм ахун мелла Габденнасыйр бине Рәхманколыйның кызы Биби Фатыймага өйләнеп, уникенче рәҗәб Әлмәт авылына сәфәр итеп, өченче кичтә кияү булып кердем. Егерме өченче шәгъбан кечатна көнне Казан шәһәренә алып кайттым. Мең ике йөз алтмыш җиденче (1851) елда иртә белән баладан үлеп, җеназасын үзем укып, яңа каберлектә Казанда күмелде. Каберенә таш

---

[1] Әл-кассап – итче, ит суючы. Габделмәҗид, күрәсең, ит белән сату итүче булган.

яздырып куйдым. Мең ике йөз алтмыш сигезенче елда зөлкагъдәнең дүртенче унында кечатна көн Хөсәен бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанайның кызы Биби Нәгыймәгә өйләнеп, шул кичә Ибраһим бине Гобәйдулла йортында кияү булып кердем. Шуннан сигез атна узгач, үз өемә алып килдем. Моннан соң мелла Шәриф бине Сөләйман йортына күчеп, алтмыш тугызынчы елда... көнендә хәзер яшәгән йортны бер мең дә ике йөз сумга сатып алып төзәттердем. Ул йорт элек мәрхүм Мәсгуд бине Габдерәшид бине Габдерәхим Кайбычиныкы булып, ул үлгәч, углы Шафигъка калган, аннан Мөхәммәд бине Йосыф бине Исхак бине Гали Казани милкенә күчкән иде. Йортның түбәнге кат таш бинасы һәм җире генә бар, үзе буш тора иде.

Мең ике йөз җитмешенче (1854) елда зөлхиҗҗәнең сигезендә... көндә вакытлы рәвештә имамлыктан тыелдык. Җиһанша бине Мөхәммәд бине Габдессәлам бине Госман Карили кызы Маһруйны закон яшенә җитмәс борын Мостафа бине Мөхәммәд бине Нәзир бине Габделкәрим бине Митри бине Ишбулдый әш-Шырданыйга, солдат Мортаза бине Искәндәр бине Нияз әл-Килдебикидән калган Зарифә Гатыятулла кызын әүвәлге иренең никахында була торып, Габделвәли бине Хәлилгә никах кылуда гаепләнеп, вакытлы рәвештә имамлык кылудан тыелдык. Ә чынлыкта бу кызның тиешле яшькә җиткәнлеге ачык һәм диванда[1] беркетелгән иде. Әмма тууы атасы юк чакта булып, ике бабасы – Мөхәммәд бине Габдессәлам һәм Мозаффар бине Яхъя имамнарына әйтмичә исем куеп, дәфтәргә язылмыйча ике ел үткәннән соң, бу эш аркасында бер-бер җәзага очраудан куркып, төп авыллары Кариле мулласына әйтеп, дәфтәргә яшен киметеп яздырганнар. Фәкыйрь, шәһәрдәге дәфтәрләрдә булмагач, яшен диване нөфус[2]тән алып эш ителгән, ә хәлнең ничеклеге билгеле түгел иде. Солдат исә үлеп, вафаты Мамадыш мәхкәмәсендә

[1] Диван – мәхкәмә, «учреждение» мәгънәсендә. Мәрҗани, үзен аклау өчен, перепись материалларыннан файдаланган булса кирәк.

[2] Диване нөфус – статистика идарәсе. Мәрҗани бу елларда еш булып торган перепись материалларыннан файдаланган булса кирәк.

дүрт кешенең күрсәтүләре нигезендә исбатланган иде. Шул уңай белән Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итеп, аның боерыгы буенча үз урыны бөтенесе үзенә кайтарылды һәм җитмеш беренче (1854–1855) елда уникенче шәүвәлдә чәршәмбе көн яңадан үз бурычымны үтәргә керештем.

Мең ике йөз җитмеш биштә (1859) Казанда булган зур янгында йортыбыз һәм күп малларыбыз янып, шул ук елны мең ярым тәңкә сарыф кылып, әүвәлгесеннән дә күркәм һәм төгәлрәк йорт салдырдым, мең ике йөз җитмеш алтынчы (1859–1860) елда Казан типографияләрендә басылган Коръәнне чагыштырырга, җир тетрәү сәбәпле, зарарланган Шимахү (Кавказ) халкы өчен акча җыеп җибәрергә, туган, никахланган һәм үлгәннәр дәфтәреннән хисап алып, дәүләт учреждениеләренә тапшырырга боерыклар алдым. Мең ике йөз җитмеш җиденче (1860–1861) елда бөтен гаиләм белән икенче тапкыр Тау ягына[1] сәфәр кылып, Чокалы авылында бабабыз мелла Сәйфелмөлек бине Мозаффар һәм әбиебез Биби Рабига Мөслим кызы, Бизнә авылында бабабыз мелла Мозаффар һәм атасы мелла Мортаза бине Гали һәм башка якыннарыбызның каберләренә зиярәт кылдык.

Мең ике йөз җитмеш җиденче (1860–1861) елда рухани идарә әгъзаларының каршылыгы сәбәпле, Коръәнне чагыштырып бастырудан тукталдым, төрмәдәге кешеләр өчен шәригать эшләрен башкарырга һәм дәфтәрләрдән[2] икенче тапкыр хисап бирергә боерылдым.

Мең ике йөз җитмеш сигездә (1861–1862) мәхкәмәләрдә ант иттерү[3] һәм акча җыю эшләренә боерылдым. Мең ике йөз җитмеш тугызда (1862–1863) 16 нчы июньдә бөтен шәһәр халкының теләге буенча, ике бистә арасында җыелып, корбан гаете

---

[1] Иделнең уң ягындагы авыллар «Тау ягы» авыллары дип йөртелә.

[2] Дәфтәрләрдән – туу, үлү, никах һәм аерылу эшләрен язып бару элек тә руханилар кулында иде. Боларны язып бару өчен, «Метрика дәфтәре» дигән дәфтәр бирелә иде.

[3] Судларда гаепләнүче һәм шаһитләрне ялган сөйләмәү турында ант иттерәләр иде.

намазын укыттым. Мең ике йөз сиксәненче (1863–1864) елда хәзерге йортыбызның өске катын бина һәм түбәсен тимер белән яптырдым. Хаҗи Хөсәен бине Йосыф бине Мөхәммәд бине Сөләйман Казани Чукин мәрхүм үзе бер мең бер йөз илле сум һәм аның димләве белән мәхәллә халкыннан янә бер мең сум җыелып, барысы өч мең ярым сум белән тәмам булды. Әлеге Хөсәен шул елны хаҗга китеп, кайтканда, мең ике йөз сиксән беренче (1864–1865) елда Янбәгыль-бәхер шәһәрендә үлеп, Ибраһим һәм Мөхәммәджан исемле ике углы, өч кызы калды. Аллаһы Тәгалә рәхмәт эчендә йөздерсен, моннан соң мең ике йөз сиксән өчтә (1865–1866) дүрт йөз тәңкә тотып, таш койма койдырдым.

Мең ике йөз сиксән дүрттә (1867–1868) дини идарәне сайлау мәхкәмәсендә член булу турында указ, сәфәр аеның икесендә чәршәмбе көн Коръән бастыруны күзәтү һәм чагыштыру турында икенче тапкыр боерык, жөмадиел-әүвәл аеның уникесендә чәршәмбе көн ахун һәм мөхтәсиблек турында указ алдым. Үзем сорап, үтенеп түгел, бәлки мирза Шаһ Әхмәд Мөхәммәд мәрхүм углының дөрес табуы аркасында.

Мең ике йөз сиксән бишенче (1868–1869) елда рамазан аеның ундүртендә кечатна көн Җиһанша мәчете ачылып, шәһәрнең бөтен галимнәре, байлары җыелып, өйлә намазында имам булып, күпсанлы җыелган халыкка вәгазь-нәсыйхәт сөйләп, патшаның саулыгына дога кылышып, бу вакыйга газеталарда басылды.

Мең ике йөз сиксән алтынчы елда (1869–1870), губернаторның үтенүе буенча, хайваннарга шәфкать турысында өндәмә язылып, казна хисабына бастырылып, шәһәр һәм авыл имамнарына, мәдрәсәләренә таратылды, үземә губернатор имзасы белән рәхмәт язуы, өндәмәнең русчага тәрҗемәсе вакытлы матбугатта басылды.

Мең ике йөз сиксән җиденче (1870–1871) елда рабигыль-әүвәл аеның алтысында сишәмбе көн бөтен гаиләләрем белән икенче тапкыр Болгар шәһәренә барып зиярәт кылып, манарасына бу бәетне яздым. (Бу бәет I томда бар.)

Мең ике йөз сиксән җидедә (1870–1871) зөлкагъдә аеның икесендә дүшәмбе көн кояш баегач, бер кыз бала туып, иртәге-

сен таң вакытында анасы, хөрмәтле иптәшебез Биби Нәгыймә Хөсәен кызы утыз тугыз яшендә вафат булып, җеназасын бик зурлап, үтәп, бистә зиратына күмелде. Хәлебез: шигырь.

Кичтән бакчаның иң матур чәчәге төсле иптәшебез идең.
Таңны иптәшебез бөтенләй булмаган кебек каршы алдык[1], –

дип, тел кабатлады. Кабере Казан зиратында зур капкадан көнбатышта беренче ишектән керүгә шул ишек тирәсендә ишектән ... адым ераклыкта. Каберенә таш куелды. Мәрхүмәнең кабере Биби Фатыйма Габденнасыйр кызы каберeннән алтмыш сигез аршын кадәр көньяк-көнчыгышта, һәр икесенең каберендәге ташларда исем һәм нәсәпләре, вафат еллары язылган. Мең ике йөз кырык җиденче (1831–1832) ел шәгъбан аенда Казан шәһәрендә туган. Анасы – зур байлардан Габдулла бине Габдессәлам Мәчкәрәви кызы Биби Хөснибану. Бу фәкыйрь никахында унсигез ел унбер ай егерме сигез көн гомер итеп, ун бала тапты. Беренчесе – Хәйренниса, Өммел-Хәер Галия. Мең ике йөз алтмыш тугызынчы (1852–1853) елда зөлхиҗҗә аенда туды. Икенчесе – Борһанетдин Әбү әл-Габбас Мөхәммәд мең ике йөз җитмеш икенче (1855–1856) елда рамазан аеның унтугызында кешеләрнең җомга намазыннан Аллаһның рәхмәтен үтенеп таралган чакларында туды. Өченчесе – Фәхренниса Өммесәлимә Мәрьям әл-Көбра; дүртенчесе – Хәйрелбәнат, Өммелхәйрә Мәрьям әс-Сагра; бишенчесе – Фәхренниса Өммегөлсем Габбасә – мең ике йөз җитмеш тугызынчы елда (1862) мөхәррәм аеның дүртенче атнасының өченче көнендә туды; алтынчысы – Бәһаветдин Әбү әл-Касыйм Әхмәд; җиденчесе – Бәһаветдин Әбү әл-Фазыл Мәхмүд әл-Мәәмүн – мең ике йөз сиксән өченче (1870–71) җөмадиел-әүвәлнең егерме җидесендә якшәмбе көн төш алдыннан туды. Сигезенчесе – Ситтенниса Өммелфазыл Гайшә; тугызынчысы – Рәзыетдин Әбү Һашим Салих – мең ике йөз сиксән алтынчы (1869) елда сәфәр аеның егермесендә сишәмбе көн төш алдыннан туды; соңгысы –

---

[1] Шигырь гарәпчә, монда тәрҗемәсе бирелде.

Ситтелбәнат Өммеләймән Хәува – мәрхүмә анасына мәхәббәт йөзеннән бу исем белән аталды[1].

Олы һәм кече Мәрьямнәр, Әхмәд белән Гайшә аналары исән чакта ук кече яшьтә үлделәр. Каберләре мәрхүмә Биби Фатыйма Габденнасыйр кызының аяк очында.

Салих – анасыннан соң, мең ике йөз сиксән сигездә (1871–1872) шәүвәл аеның уналтысында пәнҗешәмбе көн вафат. Кабере – анасыныкы янында төньяк баш очында.

Моннан соң Каганның зур сәүдәгәрләреннән Хөсәен бине Муса бине Ягъкуб бине Ишмәмәтнең Биби Фатыйма исемле кызына өйләндем. Егерме тугызынчы зөлкагъдә якшәмбе көн кич алдым-бирдем ясалып, икенче көнне зур туй ясап һәм никах яңартып, шул кичне кияү булдым, мең ике йөз сиксән җиденче

---

[1] Мәрҗани үзенең балаларының исемнәрен санаганда, көнчыгышта, гарәпләрдә кабул ителгән бик күп кушаматлар китерә. Мәсәлән, аның беренче баласы – Галия, икенчесе – Мөхәммәд, өченчесе – Мәрьям, дүртенчесе – тагын Мәрьям (олы Мәрьям, кече Мәрьям – олысы үлгәч, кечесе шул ук исем белән исемләнә), бишенчесе – Өммегөлсем, алтынчысы – Әхмәд, җиденчесе – Мәхмүд... исемле була. Шул исемнәргә ул түбәндәге кушаматларны өсти. Ул кушаматларның мәгънәләре:

Хәйренниса (хатыннарның изгерәге),

Өммелхәер – изгелек анасы,

Борһанетдин – диннең дәлиле,

Әбү әл-Габбас – Габбасның атасы,

Фәхренниса – хатын-кызларның мактанычы; данлысы; Өмме-сәлимә – сәламәтлек анасы; Мәрьям әл-Көбра – олы Мәрьям.

Хәйрелбәнат – кызларның изгесе.

Өммелхәйрә – изгелек анасы Мәрьям әс-Согра – кече Мәрьям.

Габбасә – чытык йөзле хатын-кыз.

Бәһаветдин – диннең күрке.

Әбү әл-Касыйм – күркәмлекнең атасы.

Әбү әл-Фазыл – олылыкның атасы.

Әл-Мәәмүн – ышанычлы.

Ситтенниса – хатын-кызларның олысы, Өммел-фазыл – олылыкның анасы.

Рәзыетдин – диннең ризасы, Һашимның атасы.

Ситтелбәнат – кызларның олысы, Өмме-әймән – турылык анасы. Балаларына бирелгән бу кушаматлар бер традиция генә түгел, бәлки аларның шулай булуларын теләүне белдерәләр.

(1870–1871) ел сигезенче зөлхиҗҗәдә дүшәмбе көн кич үз өемә алып килдем, ә егерме бишенче зөлхиҗҗәдә пәнҗешәмбе көн кичен бөтен әйберләрен алып килдем. Анасы Казанның мәшһүр байларыннан Чукрак Бәсыйр бине Габид бине Заһид кызы Биби Мәхбүбә.

Мең ике йөз туксан беренче елда көнчеләр һәм дошманнарның ачулары кабарып, һәртөрле ялганнар, яла ягулар өчен сәбәп эзләп, уразага бер көн алда керде дип гаепләп, вакытлы рәвештә имамлыктан мәхрүм иттеләр. Бер ел үткәч, мең ике йөз туксан икенче елда унынчы зөлкагъдәдә пәнҗешәмбе көн яңадан үз урыныма кайтып, эшләремне башкарырга керештем. Чынлыкта исә Казан тирәсендәге Кәче, Пошалым һ.б. кайбер урыннарда, Истанбул, Шам, Мәккә һәм Мәдинә, Гыйрак, Бохара, Сәмәрканд, Ташкент һәм Харәземнәрдә – барысында да безнеңчә, чәршәмбе, хәтта Мисырда бездән бер көн элек, тугызынчы октябрь сишәмбе кергәнлекләре билгеле булды.

Хөкем көнчеләр кулына тапшырылгач,
Заманның көнчеләре гөнаһ өчен тилермәсләрмени?[1]

Мең ике йөз туксан өчтә (1876) Казан шәһәрендә хөкүмәт мәктәбе ачылып, дин дәресләре укытырга һәм педагогик советка член итеп билгеләндем. Шимбә көн дүртенче рамазанда «Мохтасар әл-Кодури» китабыннан дәрес башладым. Алтынчы рамазан дүшәмбе көн унөченче сентябрьдә зур җыелыш булды, мәктәп рәсми төстә ачылды, кагыйдәләре укылды[2].

Мең ике йөз туксан өчтә (1876) Казан университеты каршында бер гыйльми җәмгыять ачылды[3], аның члены булып кереп, бишенче шәүвәл, унберенче октябрь кич сәгать җидедә беренче тапкыр шул җәмгыять утырышында хәзер булдым[4].

---

[1] Шигырь – гарәп телендә.

[2] Сүз – учительская школа ачылуы турында. Бу җыелышны ачканда, беренче сүз Мәрҗанигә бирелгән.

[3] Сүз Казан университеты янында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте турында.

[4] Ш. Мәрҗани моннан соң үзенең нинди китаплар язуын санап китә.

Авыллар турында[1]

Ташкичү. Күптән түгел оешкан авыл. Халкының күбрәге Ашыт, кайберләре Пимар авылыннан һәм башка яклардан килеп урнашкан. Әмма харап булган «Ходай колы»[2] исемле авыл урынына утырганлыктан, бу урында элегрәк тә кешеләр яшәгәнлеге аңлашыла.

Ташкичүгә беренче килеп урнашкан кеше Ашыт авылы кешеләреннән Туйхужа бине Туйкә исемле. Бу кешенең туу, килеп урнашу, үлү тарихлары ачык билгеле булмаса да, якынча безнең тарихтан йөз илле еллар чамасы элек, ягъни мең бер йөз утызынчы еллар (1717–1718) ахырына булыр. Чөнки Туйхужаның оныгы Габделгаффар бине Иштирәк бине Туйхужа мең ике йөз утызынчы (1814–1815) елларда үлеп, яңа каберлеккә күмелгән. Ихсан бине Иштирәк бине Туйхужа безнең гомеребездә картаеп, мең ике йөз утыз тугызынчы (1823–1824) елда үлеп, җеназасын мәрхүм әткәбез үтәп, яңа каберлектә күмелде. Хәзер Ташкичүдә иске һәм яңа зират дип йөртелә торган ике каберлек бар[3]. Искесе – Ашыт ягында, Ташкичү басуының чигендә, елга буенда. Анда күмелгәннәрдән: юл буенда Яхъя мулла атасы Габделбакый мәзин. Тагын юл буенда зират уртасында Дәүләттшаһ бине Иштирәк бине Туйхужа; баш һәм аяк очларында ике зур каен агачы бар. Иштирәк бине Туйхужа кабере юл буенда. Елгага якын – Муса бине Гали бине Әбүбәкер кабере. Эчкәре, зират уртасында бер кабергә куелган таштан мең ике йөз сиксән тугызынчы (1872–1873) ел җөмадиел-әүвәл аенда укыдык: Аллаһны искә алудан соң язган сүзе: «Тарих мең дә ике йөз тугызынчы (1795) сәвернең тугызынчы көнендә (24 рамазан) Муса бине Биккол вафат».

---

[1] Бу бүлекчә Ш. Мәржәнидә бу исем астында түгел.

[2] Октябрь революциясенә чаклы бу авыл русча «Кудайголово» дип атала иде. Хәзер Татарстанда Арча районында.

[3] Мин яшь чакта бу иске зиратны «Чирмеш зираты» дип атыйлар һәм әгәр ат авырып, сия алмаса, шул зиратка алып барып, зират әйләнәсеннән йөртәләр иде.

Әмма яңа каберлеге авылга тоташ. Авылдан чыккач уң якта. Әүвәлге коймасы беткәч, мең өч йөз өченче (1885) елда ике йөз алтмыш сумга төшереп, имән баганалар утыртып, койма тоттырдым. Бу каберлек бер мең ике йөз егерме бишенче (1810) елда башланып, иң элек – бер гарип шәкерт, икенче – мелла Габделхәкимнең кызының кызы бер бала, өченче – әлеге мелла Габделхәким бине Габбас үзе күмелгән. Бу кеше Балтач авылыннан булып, бераз вакыт Ашытта мулла, соңрак муллалыктан китеп, Ташкичүдә яшәгән. Балалары анда бар. Шул каберлектә күмелгәннәрдән: хаҗи мелла Габдессәлам бине Габдерахман, хөрмәтле атабыз мелла Баһаветдин бине Сөбхан; хөрмәтле әнкәбез Биби-Хөбәйбә Габденнасыйр кызы мең ике йөз утыз сигезенче (1823) ел сигезенче зөлхиҗҗә аенда вафат. Әнкәбез ягыннан кардәшебез, кадерлебез Биби Хәбибә Габденнасыйр кызы мең ике йөз сиксән тугызынчы (1872–1873) елда жөмадиел-әүвәлнең тугызынчы кичәсендә таң алдыннан вафат булып, җеназасын бу фәкыйрь үтәп, яңа каберлектә күмелде. Тагын бер ташта язган: «Биби Хәдичә Хөсәен углы хаҗи Мөхәммәд кызы мең ике йөз утызынчы елда вафат» (1814–1815). Тагын Насыйбулла бине Фәтхулла бине Яхъя бине Габделбакый мең ике йөз сиксән алтынчы (1869–1870) елда егерме икенче зөлкагъдә пәнҗешәмбе көн вафат булып, җеназасын энебез мелла Садретдин үтәде. Капка янында юл буена якын, атасы белән бабасы мелла Яхъя бине Габделбакый янында күмелгән. Казан шәһәренә беренче килүебездә юлдаш булып, өйләнгәнче биш-алты ай бергә яшәдек. Үткен, аңлы, яхшыны яманнан аера белүче иде. Балаларыннан читекче чукрак Зәйнулла, Гыйсмәтулла, Габдулла һәм аларның балалары бүгенге көндә Ташкичүдә бар. Тагын Фәез бине Гадел бине Әбүбәкер мең ике йөз кырыгынчы ел (1824–1825) чигендә вафат. Җеназасын әткәбез үтәде. Әткәбезнең Ташкичүгә башлап килгән вакытында, аны теләп, яратып үз өенә алган. Бераздан соң, якыннарыннан Габделкәрим исемле кешедән калган йорт урынына бер өй салып бирде.

Әлеге Туйхуҗаның тугыз углы Ташкичүдә туган. Исемнәре: Йосыф, Хөсәен, Әбек, Иштирәк, Ишми, Туйкилде, Ишем,

Әрмәк һәм Ярмәк. Кайберәүләрнең сүзенә караганда, Ишми белән Ишем бер кешегә исем. Әрмәк, Ярмәк, Туйкилде балаларыннан мәгълүм кеше юк. Гыйбадулла бине Гыйззәтулла бине Гали бине Госман бине Хөсәен Сафа бине Габделгалләм бине Габделлатыйф бине Габдессәлам бине Яхъя бине Йосыф; Габдерахман бине Габдессәлам бине Гаделша бине Вәлит бине Хәмид бине Ибраһим бине Әбәк; Габдерахман бине Ширъяздан бине Шәрәфетдин бине Ибраһим бине Әхмәр бине Иштирәк; Фазыл бине Әхмәд бине Әбү әл-Фәез бине Дәүләтша бине Иштирәк; Гатаулла бине Әхмәтша бине Гобәйдулла бине Фәез бине Гадил[1]; Әхмәд бине Гобәйдулла бине Муса бине Гали бине Әбүбәкер[2]; Габдерахман бине Бәйрәмгали бине Корбангали бине Шәехморат бине Рәфикъ бине Ишми; Габделхәким бине Шаһәхмәт бине Нигъмәтулла бине Хәбибулла бине Давыт бине Ишми; Хәсән бине Вәлит бине Габит бине Давыт исемле кешеләр хәзерге көндә Ташкичүдә бар. «Давыт чишмәсе» дип йөртелә торган бер зур, яхшы чишмә ошбу Давытка нисбәт бирелгән.

Хаҗи Мөхәммәҗан бине Исмәгыйль бине Мохтар бине Иштирәк; Хәсән бине Ибраһим бине Исмәгыйль; Садыйк бине Исмәгыйль – Шимай шәһәрендә[3].

Әмма Ашыттан килеп, Туйхуҗа нәселеннән булмаганнар: Насретдин бине Фәхретдин бине Хәмит бине Мәскәү бине Кикә бине Сәркә; Садыйк бине Гаделша бине Габбас бине Мәскәү; Гобәйдулла бине Гайнулла бине Габдессәлам бине Мохтар бине Әхмәр бине Сәфәр исемле кешеләр бар.

Әмма Пимардан килгәннәрдән Әхмәтша бине Баһадиршаһ бине Габит бине Мөхәммәд бине Заһит – Ташкичүдә, Габдерахман бине Габдулла бине Сәйфулла бине Мөхәммәд бине Заһит – Казанда, Сәйфелмөлек бине Вәлит бине Мөсәгыйд бине

[1, 2] «Гатаулла бине Гобәйдулла...», «Әхмәд бине Гобәйдулла...» исемле, ләкин Туйхуҗа балаларына тоташулары күрсәтелмәгән кешеләрнең кертелүен аңламадык.

[3] Шимай – Семей.

Мөхәммәд бине Заһит һәм балалары, туганы – Йосыф, атасы белән бертуган Мохтарның балалары – Кызылъярда.

Әмма Мортаза бине Исмәгыйль бине Ибраһим бине Сәгыйд бине Мөнасип, һәм Сәмигулла бине Гобәйдулла бине Хәмит бине Мортаза, һәм Габдулла бине Хәбибулла бине Вәлит бине Мортаза – Ташкичүдә; Габделлатыйф бине Габделвәли бине Габдерәшид бине Габделгазиз бине Габдерәшид – Трой[1] шәһәрендә. Боларның Ашыт, Пимар яки башка яклардан килгәнлекләре билгеле түгел.

Яшьлек һәм сабыйлык дәверен үткәргән шәһәрем, анда мин тормышымның яңа киемнәрен кидем;
Анда мин яшерен уйларымның чагылышын күрәм, анда минем яшьлегемнең ботаклары тирбәлә.

Мәрҗән авылы. Казан шәһәреннән ике станция төньякта тау арасында бер кечерәк авыл. Бабаларыбыз шул авылдан чыккан, үзебезне шуңа нисбәт бирәбез[2]. Асылы «Гомәрхужа» яки «Камәрхужа», үзгәртелгәне – Комыргужа авылыннан безнең бабабыз Габделкотдус килеп утырып, үзенә бер авыл башланып китте.

Үзе кечкенә һәм күптән түгел оешуына карамастан, аннан күп укымышлылар чыккан. Безнең бабабыз һәм атабыз, Бәрәзә имамы мелла Сөләйман бине Әбүбәкер бине Ибраһим бине Ирмәш бине Габделгани һәм углы Мәтәскә иманы мелла Хәләф бине Сөләйман, Бәрәзә имамы мелла Ногман бине Сөләйман, мелла Әбү әл-Хәер бине Әбүбәкер бине Ибраһим бине Ирмәш; паралич булып Күшәр авылында вафат булган Мәңгәр имамы мелла Габдессәттар бине Исмәгыйль – аның каенатасы. Мелла Зөбәер бине Габделгазиз бине Әмир бине Габделкадыйр бине Габдеттәүвап, туганы мелла Һибәтулла бине Габделгазиз әл-әшәл[3] Әстерханда вафат – һәммәсе бер нәселдән. Габделгани бине Габделкотдус бине Ядәш бине Ядкяр әл-Мәрҗанинең

---

[1] Трой – Троицк шәһәре.

[2] «Мәрҗани» дип йөртү шуннан килә.

[3] Әл-әшәл – чулак яки куллары ихтыярсыз калтырый торган кеше.

мәгълүм булган балалары – Габдеттәүвап белән Ирмәш. Габдеттәүваптан – Габделкадыйр, Габделкәрим һәм Ишмөхәммәд. Габделхаликъ бине Исхак бине Салих бине Ишмөхәммәд – Казанда. Габделкадыйр «Кадермәт» дип йөртелә иде. Мең ике йөз җиденче (1792) елда йөз дә дүрт яшендә Мәрҗәндә вафат булды. Өч углы: Габделхәмит, Әмир, Корбангали. Шулардан Габдерәхим бине Габделхәмит бине Габделкадыйр мең ике йөз туксан дүртенче (1877) елда җомга көн...[1] мөхәррәм аенда Казанда вафат булды, Сәгыйд бине Корбан гали Мәрҗән авылында әле исән.

Мәрҗән мәчетләре арасында мәгълүм булган мәчетләрнең иң борынгысы – безнең бабабыз Габделкәрим бине Габдеттәүвап бине Габделгани бине Габделкотдус бине Ядәш бине Ядкяр әл-Мәрҗани бинасы. Ул җимерелүгә якынлашкач, мәшһүр сәүдәгәрләрдән билгеле бай, Ябынчы авылының Габделкәрим бине Әбүбәкер бине Габдулла бине Хәбибулла бине Ишбай төзәттереп, аннан соң хаҗи Сабит бине Хәмит бине Сәлим әл-Мәңгәри төзәттерделәр. Ахырдан Казан кешеләреннән хаҗи Мифтахетдин бине Вәлишаһ бине Габделкәрим бине Ситә Кушлавычи, искесеннән дә файдаланып, мең ике йөз туксан өченче (1876) елда яңадан эшләтте. Мәчетне беренче эшләтүче мелла Габделкәрим әл-Мәрҗани мең ике йөз бишенче (1791) елда рамазан аеның унҗиденче көнендә төгәл йөз яшендә вафат булып, Мәрҗән каберлегендә күмелде. Рәсми рәвештә муллалык, укыту эшләре белән шөгыльләнмәсә дә, игене, мал-туарлары күп булып, дөньясы иркен, байлыгы зур иде. Олы Мәңгәр авылына мулла булырга өндәлсә дә, кешеләргә баш июдән гарьләнеп, имамлык һәм хатыйплыкны кире кагу һәм кабул итмәвеннән гыйлем һәм олылыктан өлешле, кадере сакланып калганлыгы билгеле була. Янә шушы бабабыз мелла Габделкәрим әл-Мәрҗанидән мирас булып калган бер Коръәнебез бар. Әүвәленнән ике кәгазь, ә ахырыннан Әфтияк өлеше төшкән; бу – иске, төскә матур почерк

[1] Оригиналда буш калган.

белән, шушы илдә борынгыдан кулланыла торган кәгазьгә мазу[1], күкфәраз[2], сәмгыдан[3] ясалган кара белән язылган.

Һәр кисәк башындагы беренче юлы, чирек башында бер сүз куе кара, калын каләм белән язылган. Гәрчә Госмани рәсеме[4] тәмам сакланмаган булса да, язган кешенең гыйлем-мәгъриф ә ттән өлешле, күркәм сыйфатларга ия булуына дәлил булган билге һәм галәмәтләр ачык сизелеп тора. Шул Коръәнне бабабыз мелла Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗанинең атасы белән бертуган кыз кардәше язган дип сөйләгәнлегән кат-кат ишеттек. Ләкин ул вакыт яшьлек ваемсызлыгы сәбәпле, ул кызның исемен, табигый сыйфатларын, башка хәлләрен җентекләп тикшереп язып алмаганлыктан, андый файдалы эшнең онытылуына үкенеч белдерәм.

Биографиясе сөйләнә торган мелла Габделкәримнең олы хатыны Биби Фатыйма Мөслим кызы Олы Әтнәдә туган. Ул хатыннан Рәхмәтулла, Сөбхан, Госман исемле балалары булган. Икенче хатыны Ашыт елгасыннан төньякта урнашкан Саб башы авылыннан мәшһүр Габдерәшид бине Әбүбәкер бине Йосыфның атасының туганы Рөкыя Йосыф кызыннан Габдулла һәм Габдерәшид исемле угыллары туып үстеләр. Өченче хатыны Гөлбадамны үлем авыруында талак кылган.

Габдерәшид юкка чыккан. Габдулла мең ике йөз икенче (1788–1789) елда вафат булып, Габдерәхим бине Габдулла исемле бер углы гына калып, ул да урманда өстенә имән агачы төшеп, мең ике йөз бишенче (1790) елда сәфәр аеның унында бабасыннан элек вафат булган. Госман шулай ук мең ике йөз беренче (1786) елда яшьләй үлеп, Әсхапҗамал исемле бер кечкенә имчәк баласы калды. Бу кыз, озын гомерле булып, Җөлби авылының

---

[1] Мазу – язу карасы ясауда кулланылган чикләвек төше.

[2] Күкфәраз – купарос, кара төсле буяу.

[3] Сәмгы – агачтан алына торган клей. Элек шул өч нәрсәне кушып, бик яхшы кара ясала иде.

[4] Госмани рәсеме – Мөхәммәд пәйгамбәрнең өченче хәлифәсе Госман Коръәнне беренче тапкыр җыйдырып, системага куйган дип уйланыла. Шул Коръәннең язу рәсеме булган. Бу урында Мәрҗани шуны истә тота булса кирәк.

Таһир бине Ишморза бине Габдулла никахында сиксән алты яшь тулганда мең ике йөз сиксән алтынчы (1869–1870) елда, ире Таһир исә туксан биш яшендә мең ике йөз сиксән сигезенче (1871–1872) елда вафат булып, Җөлби зиратында күмелделәр. Әсхапҗамал Иске Җөлбидә туган. Анасы Гөлбөстан Муса кызы Әсхапҗамалга ике яшь тулганда үлеп, кыз бабасы Муса кулында тәрбияләнгән. Мөхәммәди һәм Әхмәди исемле угыллары, аннан башка кызлары һәм балаларының балалары бар.

Кыскасы: Габделкәримнең ахыр гомерендә үз янында олы угыллары Рәхмәтулла белән Сөбханнан башка балалары калмады, мелла Сөбхан Кысна авылына мулла, Рәхмәтулла исә Мәрҗән авылында үзе бер йортта тора башлагач, ялгыз калып, безнең бабабыз мелла Сөбханны төп йортка кайтарырга теләгән. Ләкин бабабыз, күп гозерләр күрсәтеп, хезмәтне агасы Рәхмәтуллага тапшырган. Габделкәрим моны бары шәфкате йөзеннән генә кабул иткән, чөнки Рәхмәтулланың хатынын ул яратмый икән. Агабызның төп йортка кайтуына карар биреп, күрешеп кайтырга чыкканда, өй алдына хәтле чыгып, култыксасына таянып, мине чакырып китереп: «И углым, минем яратмаган кешемне минем йортыма китереп керттең. Аллаһы Тәгалә сиңа да яратмаган кешеңне кайтарып өеңә кертсен», – дип әйтте. Атамның бу догасы кабул булып, ахыр гомеремдә углым Сираҗетдин миңа да хатыны һәм балалары белән кайтып керде дип, бабабыз һәрвакыт сөйли иде.

Рәхмәтулла бине Габделкәрим мең ике йөз утыз алтынчы (1820–1821) елда Мәрҗән авылында вафат һәм шуның зиратында күмелгән. Фәйзулла, Хәбибулла, Фәез исемле угыллары, Ганбәр, Мөхиббә, Зөбәйдә исемле кызлары калды.

Кече углы Фәез мең ике йөз сиксән өченче (1866–1867) елда, яше сиксәннән үтеп, Мәрҗәндә вафат һәм шуның зиратында күмелгән. Мифтахетдин исемле углы Мәрҗәндә, Сираҗетдин исемле углы Казанда. Рәхмәтулланың олы кызы Ганбәр Олы Әтнә авылында Рәхмәтулла бине Мостай исемле кешенең никахында. Мөхиббә – Хөсни [Кысна] авылында Тыкан төркеменнән Габдессәттар бине Габит бине Мәхмүд никахында

вафатлар. Ташкент шәһәрендә углы Мозаффар һәм аның балалары бар. Зөбәйдә Рәхмәтулла кызы Иске Җөлби авылында Хәмит бине Ишморза бине Габдулла никахында. Шаһ Әхмәд һәм Зөбәер исемле угыллары сәүдә белән шөгыльләнәләр. Хәмит үзе мең ике йөз алтмыш сигезенче (1851) елда Җөлбидә вафат. Әмма Габделкәрим бине Әбүбәкер Ябынчуый элек бик зур, мәшһүр бай иде. Ахыр гомерендә байлыгы бетеп, тәмам мохтаҗлыкта, фәкыйрьлектә мең ике йөз кырыгынчы (1825) ел ахырында Ябынчы авылында вафат. Хаҗи Сабит бине Хәмит мең ике йөз җитмеш җиденче (1861) елда хаҗ сәфәрендә Гарәфатта[1] вафат булды. (140–144 б.)

Ашыт авылы – Ашыт елгасы буенда иң борынгы авыл. Хәтта ислам хөкүмәтләре (Казан ханлыгы) көннәрендә бар һәм төзек иде. Әмма заман үтү белән бер урыннан икенче урынга күчеп йөреп, шул тирәдә дә дүрт урында булганлыгы мәгълүм. Әүвәл – Шаһкол елгасында, аннан күчеп, хәзер күчмә дип танылган елгада; зираты хәзер дә «Күчмә зират» дип мәшһүр. Аннан хәзерге урынына күчкәч тә, өч зиратка күмеп, «иске зират», «яңа зират», «йорт өсте зират» дип танылган. «Ашыт зиратларында әүлия кабере бар», – дип, халык телендә сөйләнсә дә, ачык бер хәбәр яки берәр китапта булмаганлыктан, ана ягыннан бабабыз мелла Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек үлгәч, мәрхүм атабыз: «Инде Ашыт зиратында вәли[2] күмелгәнлеге мәгълүм булды», – диде.

Ашыт кешеләреннән Мәкәләй[3] бине Ак Суфи исемле чиксез көчле һәм бик батыр кеше булган. Хәзер дә Ашытта искедән

---

[1] Гарәфат – Мәккә тирәсендә бер тау исеме.

[2] Вәли (күплек формасы – әүлия) – «изге кеше» мәгънәсендә.

[3] СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында озак еллар гади хезмәттә торган Сафа Вафин (Ашыт авылы кешесе) Ашыт тирәсендә «Шаһкол», «Сәедкол» һәм аңа коя торган «Күчмә елга» исемле елгалар барлыгын һәм Ашыт авылының элек шул «Күчмә елга» буенда булганын сөйләде. С. Вафин Мәкәләй батыр һәм аның үтерелүе турындагы истәлекне дә хәтерли. Аның сөйләвенчә, Мәкәләй батырны Мәмсәләр үтереп, Ашыт суындагы бәкегә ташлаганнар. Соңыннан мәетен табып, елга буена күмгәннәр. Чардуганы да булган.

калган бик калын, чиксез юан, ике ат көчкә тартырлык имән баганалар бар. Мәкәләй шул баганаларны ялгыз үзе күтәреп утыртканган дип мәшһүр. Бер җирдә туй яки зур җыен һәм мәҗлесләргә чакырылып, мәшһүр байларга катнаша икән. Туйларга барганда, атын калын чи имән агачыннан кисеп бөккән дуга белән җигеп, башкалар туарып ала алмагач, «Без фәкыйрь кешене игътибарга алмыйлар, атыбызны тугармыйлар, китәм», – дип, мәҗлес иясенә үпкә белдереп, ялынып, гозер итеп, үзенә туарталар икән. Эчке мәҗлесләрендә сугыш чыгарып, кешеләрне кыйнап, күп вакытларда киштә аркылы атып ташлап җибәрер икән. Ахырда Кышкар байлары – Габдерәшид бине Госман бине Габделкадыйр һәм туганнары Сәгыйдләр, Мәмсә авылында бер мәҗлес ясап, явыз ният белән аны чакырып, бал эчертеп исертеп һәм авырайтып, сәндерәдән муенына бау төшереп үтереп, Ашыт суына чыгарып ташлаганнар. Берничә көннән соң мәете чыгып, Ашыт кешеләре Ашыт суы буенда «авыл асты тегермән» дип йөртелә торган тегермәннән югарырак, елганың көньягында күмгәннәр. Хәзергә чаклы кабере мәгълүм, агачтан чардуган корылган. Бу вакыйга мең бер йөз җитмешенче (1756–1757) еллар чигендә булган. Мең ике йөз егерменче (1805–1806) еллар тирәсендә Ашытта базар ачылды һәм кибетләр төзелә...

Ашыт имамнарының тугызынчысы – мелла Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф әл-Җәбәлли[1] (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Асылы Җәбәлстанда[2] Сембер[3] тирәсендә Иске Чыккали исемле авылдан. Анасы – Шатыршан исемле авылдан Биби Рабига Мөслим кызы. Ата-бабалары һәркайсы имам-хатыйп һәм мөдәррис булганнар. Бабасы мелла Мортаза бине Гали мәшһүр хаҗи Мортаза бине Кытлыгыш Симети иярченнәреннән. Гарәп теленең синтаксисы турында «Мохтәсарез-зәнҗан» исемле китапны язып тәмам иткәннән соң: «Мең бер йөз икенче елда шәүвәл аенда җомга көн кояш баер алдыннан тәмам булды. Моны үзенең фани

[1] Жәбәлли – Тау ягыныкы.

[2] Җәбәлстан – Тау ягы (Иделнең уң ягы).

[3] Сембер – Ульяновск.

кулы белән фәкыйрь Мортаза бине Гали Болгари язды. Аллаһ аны, ата-анасын һәм барча мөселманнарны ярлыкасын»[1], – дип язган сүзләрен үз күзебез белән күрдек.

Шулай ук мәдрәсәсендә бер шәкерт «Фәраизе сиражия» язып бетереп, болай теркәп куйган: «Бу китапны Казан галимнәре арасында иң атаклы галим һәм остаз Мортаза бине Мөхәммәд Гали хөрмәтенә Мөхәммәд бине Солтангали язды. Аллаһ аларның һәр икесенең һәм ата-аналарының гөнаһларын ярлыкасын»[2].

Хәзерге көндә ул нөсхә бу китапны язучы фәкыйрьнең кулында. Бизнә авылында имам һәм мөдәррис булып вафат; углы Мозаффар белән каберләре якын һәм бергә.

Мелла Мозаффар якынча һижрәттән мең ике йөз унынчы (1795–1796) ел чигендә вафат. Аның урынына калган мелла Хисаметдин исемле кешенең мең ике йөз уналтыда (мең дә сигез йөзенче миладиядә) закон буенча тиешле указ алуыннан шулай икәне билгеле була. Мең ике йөз җитмеш җиденче (1860–1861) елда Тау ягына сәяхәт вакытында каберләрен зиярәт иттем.

Мелла Габделмәҗит бине Мозаффар Борнаг иле авылында, мелла Зәйнетдин Нугай Иле авылында, мелла Бәрхия бине Мозаффар Боклавыш авылында имам булып, мелла Зөбәер бине Мозаффар яшьләй вафат булдылар, мелла Гомәр бине Зәйнетдин атасы урынында. Атасы мелла Сәйфелмөлек Казан өлкәсендә Бай Уланнары авылында язып тәмам иткән «Гөлстан Сәгъди»нең ахырында: «Шәкертләрнең иң түбәне, Аллаһ рәхмәтенә мохтаҗ Сәйфелмөлек бине Мозаффар кулы белән төш вакыты авышкач, чәршәмбе көн, ураза гаете алдындагы гарәфә көн мең бер йөз җитмеш беренче елда (1758) рамазан аеның егерме тугызында Казан өлкәсе Арча юлы Бай Уланнары авылы хуҗабыз һәм остазыбыз Габдерәшид бине Мөхәммәд мәдрәсәсендә язылды»[3], – дип язып, тарихын, нәсел-нәсәбен күрсәткән. Озын

---

[1] Текст гарәпчә. Тәрҗемәсе бирелде.

[2] Текст гарәпчә. Тәрҗемәсе бирелде.

[3] Текст гарәпчә. Тәрҗемәсе китерелде. «Гөлстан Сәгъди»нең татарлар арасында бик борынгыдан ук таралганын күрсәтә.

гомерле булып, Иске Чыккали авылында имам-хатыйп, мөдәррис булып, йөз яшенә җитеп үлде һәм Иске Чыккали авылы зиратына күмелде. Хатыны Биби Рабига Мөслим кызы мең ике йөз икенче (1787–1788) елда вафат. Каберләре бер-берсенә якын; һәр икесен зиярәт кылдык. Мелла Габденнасыйр, мелла Габделмәннан, мелла Хәмди һәм Мөхәммәдьяр исемле угыллары калып, мелла Хәмди атасыннан соң Иске Чыккали авылында имам һәм хатыйп булып, мең ике йөз сиксән сигезенче (1871–1872) елда җөмадиел-ахирдә вафат һәм шул авыл зиратында күмелде. Мелла Баһаветдин һәм мелла Шиһабетдин исемле угыллары калды.

Биографиясе сөйләнә торган бабабыз Габденнасыйр Урбарда мелла Габдерәшид бине Йосыф, Ашытта мелла Сәгыйд бине Әхмәд, Орыда мелла Хәбибулла бине Хөсәен һәм гасырыбызның башка олы һәм галим кешеләреннән укып һәм тәрбияләнеп, мең ике йөз җиденче (1792–1793) елда Ашыт авылында имам хатыйп һәм мөдәррис булып, олы байлардан Иске Коллар авылы Туктамыш бине Габделкадыйр бине Идрис бине Юныс кызы әбиебез Биби Мәхбүбәгә өйләнеп, олы баласы һәм безнең анабыз Биби Хөбәйбә мең ике йөз тугызда (1794–1795) рәҗәп аеның өченче көнендә төш алдыннан туган. Аннан соң Габделлатыйф, Габделмалик, Габдерәкыйп (олысы), Габделбасыйр, Зөбәйдә, Габдерәкыйп (кечесе), Биби Хәбибә, Биби Сәйедә, Биби Сәгыйдә, Биби Гайшә исемле балалары булып, Габделлатыйф, Габделмалик, Габдерәкыйп (олысы), Зөбәйдә, Сәгыйдә бала чакта ук үлделәр.

Ашыт авылында озак еллар зур мәдрәсә тотып, күптөрле фәннәрдән дәрес әйтеп, күпләр көчләре бар кадәр гыйлем һәм кәмаләтеннән файдаландылар...

Мең ике йөз кырык тугызынчы (1833–1834) елда җөмадиел-ахирнең унбишендә чәршәмбе көн Ашытта вафат, пәнҗешәмбе көн җеназасын ахун мелла Фәтхулла бине Хөсәен үтәп, яңа зиратта күмелде. Хатыны, безнең әбиебез Биби Мәхбүбә мең ике йөз илле сигездә (1843) зөлкагъдә аеның сигезендә якшәмбесендә үлде. Кабере – бабабызның аяк очында, җеназасын баба-

быз укыды, яңасы Иске Мәңгәр мирзалары нәселеннән Зөбәйдә бинте Гашур бине Мөхәммәд бине Ясни бине Утай. Кызлары Бибисәйдә, мең ике йөз кырык тугызынчы (1833–1834) елда әткәсеннән өч ай элек вафат булып, рабигыль-әүвәлнәң икесендә шимбә көн үлде. Кабере анасы янында төньякта, җеназасын әткәсе үтәде, һәр өчәвенең исем һәм вафат тарихларын яздырып, бабабыз баш очында мин, фәкыйрь, бер таш куйдым. Аллаһ аларга үзенең киң рәхмәтен иңдерсен.

Биби Хөбәйбә һәм Биби Хәбибә һәр икәве бер-бер артлы мәрхүм әткәбез никахында булып, Ташкичү зиратында күмелделәр. Мелла Габдерәкыйп (кечесе) мең ике йөз сиксән икенче (1865–1866) ел шәүвәләндә Ашытта вафат. Җеназасын туганы мелла Габденнасыйр үтәп, ата-аналары янында күмелде. Габдерәүф, Гариф һәм Әшрәф исемле ике углы һәм бер кызы калды... (144–151 б.)

Мәчкәрә авылы – Ишмән иле дип исем алган, байларының һәм шәкертләренең күплеге белән билгеле бер авыл. Асылда, ар[1] халкыннан бер төркемнең урнашкан авылы иде. Башлап, Бөрбашы авылыннан Ишмән бине Туктар Гали бине Көчек бине Тәбеҗ исемле кеше, хайваннары һәм йорт-җирләре белән килеп, ул авылда утар ясап урнашты. Бераздан соң Бөрбашында Әшмәкә исемле кеше белән дошманлашып, шул Әшмәкәнең җәбер һәм хурлауларына түзә алмыйча, үз утарыннан бөтенләй күчеп, Мәчкәрәдә урнашты. Бөрбашы авылына салган мәчетен сүтеп, бүрәнә һәм агачларын хайваннарының муеннарына һәм койрыкларына тагып, Мәчкәрәгә күчергән. Бераздан соң ул мәчетне Туймыҗ бине Туйкә исемле кеше Бөрбашы авылына яңадан кайтарып, авыл халкына һәм имамнарына биргән. Хәзер дә мирас юлы белән мулладан муллага күчеп килә. Өлкән бабалары Тәбеҗ Бөре суы башында йорт һәм алачык салып, тимерчелек белән кәсеп итеп вафат булган. Хәзергә чаклы ул урыннан күмер, тимер калдыклары, иске дагалар чыга һәм Бөрбашы кешеләре аны йорт-елга дип

[1] Ар – удмурт.

атыйлар. Ләкин ул елга тирәсендә булган агачлар бетеп, суы корыгач, Тәбеҗнең углы Көчек ул урыннан ярты мил кадәре җиргә, елганың югары агымына күчеп, йорт салган һәм аның тирәсенә кайбер авыллардан кешеләр күчеп килеп, шуннан Бөрбаш авылы оешкан. Шуңа күрә ул авыл хөкүмәт документларында әлеге Көчеккә нисбәт бирелеп исемләнә. Көчекнең углы Туктар Гали Оренбург һәм Каргалы тирәләрендә сәүдә белән гомер итеп, мең дә сиксәненче (1669–1670) елда үлеп, шуның зиратында күмелде. Зиратның уртасында кабере өстендә исемен һәм үлү тарихын язган ташы бар. Өч углыннан Мәмәт исемлесе Бөрбашында калып, авыл халкының күбрәге шул Мәмәт нәселеннән. Байморат бине Ишморат бине Ишмән бине Корбанай бине Бикәш бине Мәмәт бине Туктар хәзер дә исән. Туктар Галинең ике углы Ишмән һәм Ишкәй Мәчкәрәгә күчеп, балалары анда. Бер хәбәргә караганда, Ишмәннең Габит, Габдессәлам, Габделмәннан, Сәгыйд, Бәшир, Нәзир, Үтәмеш исемнәрендә җиде углы булды. Икенче бер хәбәргә караганда, Ишмәннең Габит һәм Үтәмеш исемле ике углы калып, Үтәмештән Габдессәлам, аннан Мөхәммәдрәхим һәм Габдулла туды. Үз балалары бу заманда үз нәселләрен Габдулла бине Габдессәлам бине Хәлил бине Йосыф бине Ишмән бине Туктар Гали бине Көчек бине Тәбеҗ бине Кадеш бине Сөләйман Кирмани дип билгеләп, россиялеләр Ханкирмән шәһәрен алганда, ар халкыннан бер солдат бер йортка кергәндә, өй эчендә бер кеше юк, фәкать бер бишек белән бер бала күреп, баласы юклыктан аны яратып, чирмәсенә салып сәламәт алып кайткан һәм яше җиткәч, Алабуга ягындагы мишәрләрдән кыз алып биреп, ахыр гомерендә Ядкяр иленә[1] китереп куйган дип сөйлиләр. Ләкин Габдессәламнең атасы Хәлил бине Йосыфмы, әллә Йосыф бине Хәлилме икәнлегендә шөбһә бар.

Бу фәкыйрь әйтә: әлеге Габдулла байның Мәчкәрәдә мелла Габделхәмит мәдрәсәсендә укыган вакытында «Гыймаделислам» китабын үз кулы белән язып илткәндә бу сүзләрне

---

[1] Казан ханлыгы булса кирәк.

язганын күрдек: «Бу китапны Габдулла бине Габдессәлам бине Үтәмеш Мәчкәрәдә мелла Габделхәмит бине Үтәгән мәдрәсәсендә мең бер йөз җитмеш икенче (1758–1759) елда язды»[1]. Сүзе тәмам. Мәгәр «Үтәмеш» сүзе бабасының кушаматы булса гаҗәп түгел.

Янә, Россиянең ул шәһәрне мөселман ханнары кулыннан бу рәвешле сугышып һәм җиңеп алулары булмавы бу сүзләрне хикәят кылганда кертелгәннәрнең дөрес түгеллегенә ачык һәм җитәрлек дәлил була. Ханкирмәндә мөселманнардан мөстәкыйль ханнар булганы юк. Ул шәһәр борынгыдан Россия кулында һәм русча «Городец» дип атала икән. Казан ханнарыннан Олуг Мөхәммәд хан үлеп, аның урынына углы Мәхмүд хан утыргач, Касыйм исемле углы агасыннан куркып Мәскәүгә качып китеп, Россия патшасы аны хан исеме белән шул шәһәргә җибәрде. Казан, Әстерхан h.б. урыннардагы татар ханнарыннан качкан кешеләр Касыйм тирәсенә тупланып, алардан гаскәр ясады. Касыйм ханнан соң тагын күп хан балалары шул рәвешчә Ханкирмән шәһәренә хан итеп куелды. Ахырлары һиҗри тарихның мең елы тулганда (1591–1592) Уразмөхәммәд хан бине Уңдан хан Россия хөкемдары Борис бине Фёдор тарафыннан хан булды, ә бер мең дә унтугызда (1610–1611) вафат, аның соңында Себер ханнарыннан хаҗи Мөхәммәд хан балаларыннан тагын өч кеше бераз вакыт шушы исемдә хан булып, мең дә сиксән бишенче һиҗридә (1674–1675) тәмам бетерелде.

Россия патшалары татар хан балаларын шул рәвешчә хан итеп куеп, үзләреннән гаскәр җыйдырып, шул тирәдә булган мокшы, чуваш, ар кебек халыклардан алына торган салымны аларга биреп тәрбия кылуы белән, ул хан балалары чын күңелдән һәм табигый батырлыклары сәбәпле, зур хезмәтләр күрсәтеп, Россия патшаларына Казан һәм Әстерхан халыкларын алуга бик зур һәм бик яхшы ярдәмче булдылар. Шушы сәбәптән Россия телендә ул шәһәр Касыймга нисбәт белән танылып килә.

---

[1] Текст гарәп телендә. Тәрҗемәсе бирелде.

Моннан соң россиялеләр татарларны тәмам җиңеп, илләрен алып тынычлангач, Ханкирмән ханлыгы бөтенләй бетерелеп, исеме дә калмады. Дөресен Аллаһ белә, без аңа кайтырбыз. (156–158 б.)

Ор (Оры) авылы. Ашыт елгасының Төньяк ягында «Түбән Оры», «Байлар Орысы», «Казан Орысы», «Морзалар Орысы» дип йөртелгән, Борынгы зур авыл. Хәтта зиратында бер кабердә Йосыф бине...[1] исемле кешенең...[2] сигез йөзенче һиҗридә (1397–1398) еллар вафаты язылганын күрдек. Бик борынгыдан сәүдәгәрләре күп булып, байлык, горурлык, исрафчанлык белән танылган; хәзер дә ике мәчете бар: таш мәчетне авылның зур бае Нәзир бине Туктамыш бине Мөслим бине Котлыг бине Җан мирза бине Хуҗа Сәед бине Җансәед бине Синтәк бине әл-Суфи бине Кара бәк бине Калдыр-бәк бине Балым бине Пачман солтан бине Сынкырат салдырган. Мелла Хәбибулла ишан, Бохарадан кайткач, мең ике йөз икенче ел (1787–1788) ахырында бина кылды. Таһир, Мостафа, Сөләйман, Муса һәм Мәхмүд байларның бабасы. Үзе мең ике йөз егерме дүртенче (1809–1810) ел ахырында вафат. Атасы Туктамыш ага мең бер йөз туксанынчы (1776–1777) елда вафат. Иң борынгы бабалары Сынкырат исемле кеше, асылда, Истанбул грекларыннан булып, Истанбул төрекләр тарафыннан алынгач мөселман булып, бу тирәләргә сәүдә эше белән килеп, шушы илдә утырып, нәсел-нәсәбе бу мәмләкәттә калды. Дөресен Аллаһ белә.

Оры авылы янында Ашыт суының көнбатышында Печмән авылы исемле авыл шуның углы Пачман солтанныкы түгелме икән? Балалары кулында нәсел-нәсәпләре язылган шәҗәрәләр бар һәм билгеле. (185–186 б.)

[1, 2] Күп нокталар автор ачык калдырган урыннарны күрсәтә.

Соңгы дәвер татар һәм башка галимнәрнең бер төркемен Казан яки Болгар шәһәрләренә бәйләнештә искә алучы фасыл[1]

Болардан – мелла Илкәй бине Мостафа бине Үзи бине Бугай бине Борсай бине Тугай Өшкәтәви (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Нәселләренең шулай икәнлеге үзеннән күчереп алган кәгазьдән китерелде. Карт бабалары, Тугай исемле кеше, Кече Шөнкәрдән башта Ует авылына килгән, аның дүрт углы булган. Исемнәре: Борсай, Бурис, Нимеч, Айтуган. Борсайдан дүрт угыл: Бикәш, Бугай, Юныс, Ирыс. Бугайдан өч угыл: Юбай, Мамай, Үзи. Юбайдан – мелла Сәфәргали һәм Солтанай. Мамайдан – Моратгали. Бикәштән ике угыл. Тимаш агачы: Әмин бине Юныс бине Борсай. Ишмөхәммәд бине Мөхсин бине Муса бине Ирыс бине Борсай. Рәхимкол бине Бохармәт бине Ксадик бине Бурис бине Тугай. Мөхәммәд бине Тукач бине Нимеч бине Тугай һәм аның кардәше – Үтәмеш бине Тукач. Морат бине Шыгай бине Айтуган бине Тугай һәм аның кардәше Гаит.

Без сөйли торган мелла Илкәй мелла Габделбакый бине Мөслим Бәрәскәви кызы Гөлемзәгә өйләнгәнлектән, бабабыз мелла Сөбхан бине Габделкәрим Мәржанинең бажасы һәм остазы иде. Казан өязендә Өшкәтә авылында мәдрәсә тотып, дәрес әйтеп, Илкәй мелла исеме белән дан тоткан. Гади табигатьле, юләрсыман кеше икән. Остабикәсе[2] бик гайрәтле булган. Бервакыт мелласын каз бәбкәсе сакларга су буена төшергән. Ни сәбәп беләндер казга ачуы килеп, мелла аны таяк белән сугып үтергән дә: «Казыңны ал, бер сугарга чыдамады», – дип, остабикәсенә китереп биргән. Тагын бер өенә кайтып кергәндә, остабикәсе өйдә юк, Казан астында ут күргән дә, актарып карап, «Һай остабикә ит-өйрә салган икән», – дип, мәдрәсәгә барып, ит-өйрә ашарга шәкертләрен алып килеп, ашны бушатып китереп, Алларына куйгач карасалар, ит дигәне – гөмбә,

---

[1] Бу бүлектә Мәржани барлыгы 81 кеше турында яза. Без барысын да алуны хәзергә кирәк тапмадык.

[2] Остабикәсе – хатыны.

өйрә дигәне – селтә суы, остабикәсе ку кайнатырга салган икән. Ул вакыт, хәтта безнең яшь вакытларыбызда, корычтан ясаган чакма белән ут чыга торган каты таш арасына каты агач гөмбәсен кайнатып, ку ясап, шул куны ике арага кыстырып, чак-чак итеп чакманы ташка сугып, чагып ут төшерә иделәр.

Янә бер мәҗлестә галимнәрдән Хәбибулла ишан, туганы Фәтхулла ахун h.б. булып, бер мәсьәләдә бәхәс күтәрелгән. Бу кеше ул мәҗлестә түбән, аяк салындырып урындыкта гына утыра, башында начар гына колаклы бүрек, кулында бияләй икән. Әлеге галимнәр моны бер дә игътибарга алмыйча сөйләшеп утырганда, бу да башын күтәреп: «Ул мәсьәләне «Һидая» хашиясе «Ниһая»[1] дә болай аңлаткан һәм сез искә алганнарны «ышанычлы түгел» дип әйткән» дип, аңсыздан исләрен китәргән.

Ул вакытларда шәех Сәгъдинең «Бостан»ын укытканнар. Бу кеше үз «Бостан»ында Сәгъдинең:

Морадыр Низамия әдрар бүд,
Шәб-руз тәлкыйн вә тәкрар бүд.
Сәфәр кәрдә бүдәм зе Бәйтел-хәрам,
Дәр әйяме насыйр би Дариссәлам, –

дигән бәетләрендә «бәйтел-хәрам» сүзенә таянып, «Дарессәлам»не Мәдинәи Мөнәүвәрә, «әйяме насыйрны» «носрәтле көннәрдә» дип, башкаларны да шул рәвешчә ялгыш мәгънәләр белән ике юл арасына «аңлатма» итеп язган. Сәгъди (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) шигыренең мәгънәсе: «Хәлифәлек үзәге – Багдадта «Низамия» (ягъни Низамел-мөлек исемле вәзир салдырган) мәдрәсәсендә минем үземә тиешле, вәкыфтән килә торган вазифам бар иде. Кичен дә, көндезен дә гыйлем тарата һәм кабатлый идем. Мәккәи Мөкәррәмәдән «Дарес-сәлам»га, ягъни Багдадка ән-Насыйре ли-динил-лаһ хәлифә вакытында сәфәр кылган идем».

---

[1] Һидая – китап исеме. Хашия – китапка аңлатма рәвешендә тәфсилләп язылган китап. «Ниһая» китабы «Һидая» китабының хашиясе, ягъни андагы фикерләр төгәлрәк, озынрак итеп язылган китап.

Тагын китапның кырыенда – «Бер гүзәлне күргәндә, язмыш аңа кол итеп баш идерә ки, күз алларым ирекле-ирексез пәрдәләнә» дигән бәетне, бөтенләй ялгыш мәгънәләр биреп, «Бикчәнтәйдән ишеттем» дип язып куйган.

Гәүһәр исемле кызы Киме мелласы Ибраһим бине Арслан бине Туйчы бине Темә бине Иртуган Кимеви никахында булып, мелла Ибраһим мең ике йөз илле тугызынчы ел (1843) рабигыль-ахир аенда, ә хатыны мең ике йөз илле җиденче (1841–1842) ел жөмадиел-әүвәл аенда Киме авылында үлгәннәр.

Олы углы мелла Фәхретдин, Сары Кокшай[1] өязендә Югары Киек авылында имам булып, мең ике йөз туксан беренче (1874–1875) елда шимбә көн өченче зөлкагъдәдә үлде. Мелла Габдерахман Каргали, хаҗи Вәлиетдин Багдадиларның шәкерте булды. Хәзерге көндә угыллары мелла Мөхәммәдҗан һәм Әхмәдхан хаҗи югары Киектә берсе – мелла, берсе мөәзин, өченче углы мелла Хәйрулла Казанда сәүдә итә. Икенче углы мелла Фәзлулла Кимедә мулла булып, мең ике йөз сиксән тугызда (1872) рабигыль-әүвәл аеның урталарында чәршәмбе көн Кимедә үлде. Мелла Габдерахман Каргали, хаҗи Вәлиетдин Багдадидән укыган һәм Коръәнне дөрес укырга өйрәнгән. Безнең анабыз белән бертуган Бибигайшә Габденнасыйр кызына өйләнеп, угыллары мелла Сибгатулла һәм мелла Гыйниятулла хәзер дә Киме муллалары. Икенче бер хатыныннан Габделгалләм исемле углы калды. (217–219 б.)

Шәмвил бине Гомәр[2] бине Гали бине Әхмәд бине Мөхәммәд әд-Дагстани әш-Шафигый әл-Гази (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) «Шәех Шамил» дип, безнең илебездә дә билгеле булганга, бу урында биографиясе китерелде. Хали гази Мөхәммәд үлгәннән соң Дагстан халкына житәкче булып, Россия һәм аның союздашлары[3] белән күп тапкырлар сугыш һәм бәрелешләре

---

[1] Сары Кокшай – хәзер: Йошкар Ола.

[2] Шамилнең атасының исеме Гомәр түгел, Мөхәммәд икәне хәзер ачыкланды.

[3] Көньяк Россия территориясендә яшәгән, әмма ул чакта Россия дәүләте составына кереп өлгермәгән халыклар.

булды; һиммәте, тырышлыгы һәм батырлыгы, алдан күрүчәнлеге һәм күркәм сәясәте, изгелек һәм ярдәмлелеге, гыйлеме, олылык һәм динлелеге сөйләп бирүгә мохтаҗ түгел.

Россия дәүләтенең Шамил әфәндедән күргән зарарының башка олы дәүләтләрдән күрмәгәнлеген кайбер төрек газеталарыннан укып белдем. Кырык ел буена шул хәл дәвам итеп, кайбер сатлык якыннарының хыянәте сәбәпле, мең ике йөз җитмеш алтынчы (1859) елда Россия кулына әсир төшеп, Петербургка китерелеп, соңра Калуга крепостенә ябылып, бераздан соң хаҗга китәргә рөхсәт сорады. Ныклы вәгъдәләр алганнан соң рөхсәт бирелеп, хаҗ кылу һәм пәйгамбәрнең, шулай ук башка хөрмәтләләрнең каберләрен зиярәт итү шәрәфенә ирешті, Мәдинәи Мөнәүвәрәгә урнашып, сиксән дүрт яшендә мең ике йөз сиксән җиденче (1871) елда Мәдинәи Мөнәүвәрәдә үлде, «Раузател-бакый»да «Коббәтел-Габбас» янында күмелде. Без фәкыйрьгә ерактан сәламнәре һәрвакыт ирешеп торды, ләкин язышу, күрешеп сөйләшү һәм очрашуларыбыз булмады.

Бер кичәдә үз өебезгә үтеп баручы бер чиркәс: «Күрешеп китәр идем», – дип хәбәр бирде. Вакытсыз чак булганга күрә: «Шунда күрешеп кенә озатыйм», – дип чыктым. Ләкин гади кешеләрдән түгел иде: киеме тәкәллефсез, билендә кылыч һәм шуңа охшашлы нәрсәләре бар. Элек сәлам биреп, гарәпчә сөйләшеп хәлен белгәч, өйгә алып кердем. Таңга чаклы утырып: «Хәзер Дагстанга китәм, юл кешесе мин», – дип, саубуллашып чыгып китте. Гарәпчә сөйләште. Үзен: «Шәех Шамилнең кияве һәм шәкерте, атам шәех Җәмалетдин хәзерге көндә исән, Истанбулда шәех булып яши, исеме Габдерахман бине Җәмалетдин, ә шәех Шамилнең дөрес исеме Шәмвил, яһүдләрнең пәйгамбәре исеме белән аталган, әмма Шамил түгел; Шәмвил әфәндемезнең хәле һәм эшләре турында «Холасатет-тәфсыйль фи әхвали Шәмвил»[1] исемле бер әсәрем бар» – дип аңлатты.

---

[1] «Шәмвил (Шамил) хәлләре турында озын итеп язылганның кыскартмасы» дигән сүз.

Безгә нинди максат белән килгәнен сөйләмәде, фәкать: «Дагстанга барабыз», – диде. Әмма хатыны, Шамил әфәнденең кызы үлеп, мәетен Дагстанга алып китеше икәнен соңыннан ишеттем. Ләкин Шамил әфәнденең кайбер язмаларында «Шамил» дип язганын да күрдек. Шамил әфәнденең исемен «Шамил бине Гомәр» дип электән үк ишетә идек. Кияве Габдерахман әфәнденең сөйләвенә караганда: Шәмвил бәни исраил (галәйһиссәлам) пәйгамбәрләренең исеме икән. Казан сәүдәгәрләреннән мәрхүм хаҗи Ибраһим бине Исхак бине Мостафаның Мәрьям исемле кызына өйләнгән кияве Шафигый бине Шәмвил меңөч йөз өченче (1886) ел җөмадиел-ахир шимбә көн булган бер мәҗлестә безнең соравыбызга каршы: «Шәмвил бине Мөхәммәд бине Гали бине Әхмәд бине Мөхәммәд», – дип сөйләде. Атасы исеменең Гомәр булуын инкяр итте. «Шәмвил» дигән исем Дагстанда яһүдләргә хас икән. Шәех әфәнденең бу исем белән аталуының сәбәбе: анасы элек берничә бала китереп тә, һәркайсы яшьтән үлгәнгә борчылып, йөкле чакта төшендә аңа әйткәннәр: «Син шушы хәлеңдә мәчет һәм тәһарәт ала торган урын бина иттер, араларында юл калдырып, шул юлдан бар. Каршыңа иң элек кем очраса, балаңа шуның исемен бир». Шушы төштә әйтелгәнчә эшләгәндә, «Шәмвил» исемле яһүд каршы очраганнан нәфрәтләнеп, кайгырып, гази Мөхәммәд әфәнде белән киңәшкәч, «Ул – зур дәрәҗәле яхшы пәйгамбәр исеме, яһүд үзе яман булса да, исеме яхшы», – дигән. Шулай да төштә әйтелгәнне кабул итмичә, икенче кат төшлек салгач, тагын шул ук исем белән атауга ишарә ителгән. Шуннан соң әлеге исемне кабул иткән.

Шәмвил әфәнде Мөхәммәд әл-Ерагый һәм Хали Мөхәммәд әл-Гази шәкертләреннән.

Казанда яшәп, алтынчылык һөнәре белән шөгыльләнүче чиркәс Мөхәммәд бине Сабанчы бине Мәһди әл-Эндраи әфәнде исемле кеше: «Шамил әфәнде миннән: Казан халкы, дагстанилар кебек, намазларын җиренә җиткереп укыйлармы, әллә нугайлар кебек, өстән-өстән генәме?» – дип сорагач: – «Әфәндем, казанлылар намазны һәм Коръәнне бездән

дә яхшырак укыйлар», – дип җавап биргән идем, ул бик шатланды» – дип сөйләде[1].

Болардан – мелла Үтәгән бине Уразмәт Урбарый (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) Малмыж өязе Урбар авылы кешеләреннән. Халык арасында исеме һәм даны таралган иде. «Мелла» исеме белән йөртелеп, галимнәр рәтендә саналса да, мулла булып торган кеше түгел: мәмләкәт кануннарын, дәүләт тәртипләрен яхшы белде, тирән акылы белән танылган, дөньясы киң һәм тормышы бай булган. Авырлыкка очраган кешеләр аңа киңәшкә килә булганнар. Гомеренең ахырында хаҗ кылырга кызыгып, берничә бәет язган. Хәзерге көндә сакланып калганы шушы кадәр:

Кичкел инде, и Үтәгән
Айрык[2] сүзне сөйләмә!»

Берзаман Ташкичү авылында тегермән тотып, Ашыт суын «Давыт» чишмәсәнә байтак җирдән ерып китереп, башлап шул урынга тегермән салучы бу кеше икәне халык арасында билгеле. Меңике йөз егерме беренче (1806) елда Урбарда вафат. Гобәйдулла исемле углы сабан туенда ат килгәнне каршы алганда, мәйданда аты белән каен агачына бәрелеп, кинәт үлгән. Оныгы Габделхалыйк бине Гобәйдулла утыз биш ел тоташтан өяз башлыгы, ягъни глава булып, исеме танылган кеше. Мелла Фәйзулла бине Габделгазиз Кышкариның углы мелла Закирның кайнатасы. Вафаты, якынча, меңике йөз илленче (1834–35) елда булса кирәк. Дөресен Аллаһ белә. (230 б.)

Болардан – Хәмзә бине Мөхәммәд бине Хәсән бине Җиһан Мөхәммәд әл-Казани әл-Бирәзәви. Үз шәһәрендә укыганнан соң Бохарага һәм Кабулга китеп, Кабулда мелла Фәезхан хәзрәтләреннән укып, Бохарада бер мәртәбә өч ел, икенче мәртәбә җиде ел яшәгән. Кабул галимнәреннән математика укып, хисап гыйлеменә бик оста булганлыктан, «Йолдызчы мелла Хәмзә»

---

[1] «Мөстәфадел-әхбар», II кисәк, кулъязма, 377–380 б. Цензура тарафыннан төшерелгән. К.Д. ун-ты китапханәсе Кулъязмалар бүлегендә т. 1590.

[2] Айрык – булмастай.

дип танылган иде. Муллалык һәм мөдәррислек белән эше булмады. Сату эше белән Бохарага кат-кат барган...

Бохарада әмир Хәйдәр бине Мәгъсүм белән якынлашып, аның хас мәҗлесенә кергәнлеге сөйләнә. Мөндеш мулласы мелла Мостай белән араларында дуслыклары көчле иде. Математикада кардәше мелла Фәйзулла бине Мөхәммәдкол бине Мөмтай бине Тутик шәкерте иде. Бирәзә авылында меңике йөз кырык икедә (1826) үлде. (231–232 б.)

Болардан – Җәгъфәр бине Габид бине Исхак бине Котлыг-Мөхәммәд бине Нариман ас-Сафари (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Асылы Уфа тирәсендә Сафар исемле авылдан. Бала чакта атасы үлгән. Анасы, Хәлим бине Асылхужа, бине Әмирхан бине Шәриф кызы Рәҗәп исемле хатын, Арслан исемле авыл кешеләреннән Балтач бине Гакәшә бине Гали бине Сөбхан никахында булып, бала шуның йортында тәрбияләнгән. Бохарага китеп, аннан Кабулга барып, ишан Фәезхан бине Хызырхан кулында укып-тәрбияләнеп, бу шәһәргә кайтты. «Уфа өязе Җәгъфәр ишан» дип мәшһүр кешеләрне үзенә якынайта, дулкынландыра һәм шаярта белә иде. Кәрамәтләр – гадәттән тыш хәлләр эшләве, төрле-төрле хәлләре турында каршылыклы хикәятләр дә сөйләнә. Күп вакыт тамбур[1] һәм башка уен кораллары алып, иярченнәре белән бергә, Казан өязләрендә, Уфа тирәләрендә байларга һәм иярченнәренә кунак булып йөри иде. (...)

Хаҗ сәфәрендә диңгездә көчле җил һәм тулкын күтәрелеп, көймәдәгеләрдә исән калу өмете бетеп, һәммәсе елый-елый Аллаһтан үтенгән һәм тәүбә иткән чакта, бу кеше мөритләрен үз тирәсенә җыеп, тамбур һәм башка уен коралларын алып, иярченнәренә өләшеп, кайберсен биергә кушып, шау-шу, шатлык белән вакыт үткәрергә керешкән. Башкалар моны күреп, кайберләре янына килеп: «Сез мөселман түгел, бәлки зиндикъ, динсез кеше икәнсез. Мондый чакта болай эшлиләрме?» – дигәч, ишан, елмаеп: «Һай, тәүбә һәм Аллаһка ялыну тыныч чакта

[1] Тамбур – тәнбур – борынгы музыка коралы.

булырга тиеш. Артыңа төшкәч кенә, тәүбә һәм ялынудан күпме файда табарсың? Хәзер тәүбә тәүбә түгел, кәеф кылып калырга кирәк», – дип җавап биргән. Бохарадан йөреп кайткач, якыннары, иярченнәре күрешергә килеп, кайберләре: «күп җирләргә йөрдегез, безгә күргән гаҗәп хәлләрегезне сөйләгез» – дигәч: «Бохарада хатыннар өй түбәсенә бәдрәфкә чыгалар икән, шул хатыннарның артын күреп кайттым, аннан гаҗәп нәрсә күргәнем юк», – дигән.

Тагын бер мәҗлестә морзалар белән бергә булып, алар, мактанып, һәркайсы: «Безнең фәлән бабабыз фәлән хезмәтне итеп, фәлән дәрәҗәне алып мирза булган», берсе: «Безнең фәлән бабабыз шул булган», – дип һәммәсе сөйләп бетергәч, бу да: «Безнең атабыз да үләр алдыннан мирза булып үлде», – дигән. Мирзалар аны, үләр алдыннан гына мирза булып, элегрәк була алмавына офтанып: «Ничек алай?» дип сорагач, «тәмам картайды, акылы зәгыйфьләнде, намаз укымады, аягүрә сиде, тәмәке тартты – шуннан артык мирзалык булырмы?» – дип җавап биргән.

Бервакыт әүвәл Орга[1] килеп, Хәбибулла ишан һәм Фәтхулла ахуннарга бераз бүләкләр биргән. Соңра Казанга килгәч, мелла Габделгаффар, мелла Габдессаттарлар, моңа бәйләнеп: «Ник бүләкләреңне орларга биреп, безгә буш килдең?» – дигәч, «Ормасыннар дип әйттем», – дип җавап биргән. Авыруларның савыгуы өчен дога кылуын үтенеп килүчеләр белән: «Бер пот яки бер кисмәк бал, я акча китер» дип сатулаша икән. «Көчем җитми» диючеләргә: «Адәм тергезәсең килсә, табарсың», – ди икән. Чыннан да, дога кылган кешесе сәламәтләнә икән...

Болардан – хаҗи Госман бине Рәхмәтулла Сәрдәви (Аллаһ рәхмәт итсен) – Казан өязендә Түбән Сәрдә авылында имам-хатыйп, мөдәррис булып, Мәккәгә барып хаҗ кылганлыктан, Госман хаҗи дип йөртелә иде. Әйшә авылында әүлия каберләре бар дип, аларны зиярәт кылырга баруны башлап җибәрде һәм гади халыкны шул эшкә юнәлдерде, юкса һичбер ышанычлы

[1] Авылның исеме – «Оры». Авылның исемен «Ор» дип үзгәртү «Ормасыннар» сүзенә тапкыр килсен өчен алынган.

хәбәр юк. Мелла Шәрәфетдин бине Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы»[1] ялган һәм ап-ачык хаталар белән тулган. Мең ике йөз кырык җиденче (1831–1832) елда Сәрдә авылында вафат. (234–237 б.)

Болардан – мелла Тажетдин бине Ялчыгыл әл-Башкорти. Асылы чит шәһәрдән булып, бу илгә кайтып, башкорт исеме белән әсәрләрендә язылган. Күп китап язды, күп сәяхәт итте. Ләкин язган әсәрләрендә тупас ялгышлар күп. «Сөбател-гаҗизин»гә төрки телендә аңлатмалы тәрҗемә биреп, Газизә исемле кызы файдалансын өчен булганга, исемен «Рисаләи Газизә» дип атаган. Үзе «Сөбател-гаҗизин»не бер дә белмәгән, ялгыш аңлаткан. «Әл-Касыйдәтел-кафия», «Тәгаллимес-салат», «Шорутес-салат» исемле китапларга да шәрех язган.

Сәяхәт вакытында дусларыннан берәүнең өенә кереп эчәргә су сорагач, йорт хуҗасы бал китереп биргән, шуны эчкәч кинәттән үлгән. Мең ике йөз илле өченче (1837–1838) ел ахырында Имәнле авылында үлеп, шуның зиратында күмелде. Һәркая җәяү йөри торган булган. Әмма атасы Ялчыгыл Кече Сон тавында вафат булды. (250–251 б.)

Болардан – мелла Фәйзулла бине Мортаза бине Мөхәммәдкол бине Мөмтай бине Туйтик Казани, Мөндеши (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) галим, фазыйль булуы өстенә математика һәм астрономия фәненә оста иде. Буяучылык һөнәренә оста булганлыктан, төрле әстырлаб[2], шар ясап, бакыр һәм җиздән ясалган төрле буяулардан файдаланып, календарьлар төзеп, кояш һәм ай тотылу, тууларыннан хәбәр биргәнлектән, «Йолдызчы Фәйзулла мулла» дип танылган иде. Хәзерге көндә үзе ясаган бер шар һәм бер әстырлабы бездә бар. Кайбер календарьлары басылып таралган. Үзе ясаган сәгатьне үз күзебез белән күрдек. Мостай хаҗи, Сәйдулла казый, Сәгыйд, Вәлид исемендә булган меллаларның

---

[1] Сүз Шәрәфетдин бине Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» исемле китабы турында. Шул китапта Әйшә авылында изгеләр күмелгән булуы турында язылган.

[2] Әстырлаб – астролябия – җир үлчи, план төшерә торган корал. XVIII гасырда күк һәм йолдызларны өйрәнү өчен дә файдаланылган.

бертуганнары иде. Ахыр гомерендә чукрак булып, бик мәшәкать белән бик аз ишетә икән.

Математиканы мелла Хәмзә бине Мөхәммәд Бирәзәвидән укыды. Мелла Гатаулла бине Мөхәммәд Курсави аның шәкерте иде. Җитмеш яшьтә чакта мең ике йөз алтмыш җиденче (1850–1851) елда Арча юлы Мөндеш авылында вафат. Углы мелла Гобәйдулла – Олы Кавалның кече ягында мулла.

Болардан – мелла Сәйфулла бине Үтәгән бине Нәдер бине Сәбкә бине Сафар бине Уразай бине Гаидхуҗа бине Шәмсихуҗа Сәрдәви (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Асылы Казан тирәсендә Комыргуҗа авылыннан. Югары Сәрдә авылында имам-хатыйп, мөдәррис булып, соңра Кызылъярга күчеп, түбән мәчеттә имам-хатыйп, мөдәррис булып, озын гомер сөреп, картлыкның чигенә җитеп, мең ике йөз алтмыш тугызда (1862–1863) егерме икенче зөлкагъдә аенда шимбә көн төн уртасында вафат булды. Үзе бик картайгач, углы мелла Сираҗетдин Кызылъярда имам һәм хатыйп булып, шәһәрнең югары өлешенә күчеп, зур эшләргә катнашып, Миңлегол исемле кеше фетнәсе аркасында бераз вакыт ябылуда булды. Котылгач, ... елда хаҗ кылып вафат булды.

«Комыргуҗа» – «Гомәрхуҗа» булуына карап, үзләрен хәзрәти Гомәр бине әл-Хәттап[3] (Аллаһ аңа разый булсын) балаларыннан дип уйлыйлар. Кайбер наданнары икенче бер яктан килеп шул авылга мулла булсалар да, исемнәренә «хуҗа» сүзен өстәп, шул ук хәзрәти Гомәр нәселеннән булуны дәгъва итәләр. Гаҗәп! Һәр Гомәрхуҗаның хәзрәти Гомәр булуы ник лязим? Урта Азиядә «хуҗа» сүзен исемнәренә кушуны хәзрәти Гали[4] (Аллаһ аңа разый булсын) яки башка берәр сәхабә[5] нәселеннән булу белән бәйләсәләр дә, безнең бу илебездә дөньясы иркен, тормышы мул булган кешеләргә «хуҗа» исеме бирелгән. Кайберәүләр гәрчә нәселләре билгесез һәм яңа гына ислам кабул

---

[3] Гомәр бине әл-Хаттап – Мөхәммәд пәйгамбәрнең икенче хәлифәсе.

[4] Хәзрәти Гали – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүртенче хәлифәсе.

[5] Сәхабә – Мөхәммәд пәйгамбәрне күргән мөселман.

иткән булсалар да, һичбер нәрсә уйламастан, бары үзләрен гарип күрсәтү[1] теләге белән, күпләр «хуҗа», ә кайберәүләр «мир», «җан», «мирза» «гәрәй» сүзләрен кушып, пакь юлдан читкә китәләр, исемнәрне бозалар.

Болардан – мелла Габбас бине Габдерәшид бине Әхмәд бине Шөкер бине Хәсән бине Хөсәен бине Котлыгмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Дусмөхәммәд бине Багыш бине Явыш Күшәри (Аллаһ аңа рәхмәт итсен), Күшәр мирзалары нәселеннән. Мелла Габдерахман Каргали, Җәгъфәр бине Габит Арслани һәм башкалардан укып, үз авылына имам-хатыйп, мөдәррис булып, мелла Габделваһһап бине Имәнколый Рәҗәби, Байморат бине Мөхәррәм Мәңгәри һәм мөфти Габдессәлам бине Габдерәхим – аның шәкертләре. Байлар белән эш иткәндә, язышканда юләрсыманлык, алдау катнаштырып, алар, моңа ихлас куеп күп файда күрә иде. Байларга бербөтен табак кәгазьнең дүрт почмагына дүрт сүз куеп, мәсәлән, «Госман бай», «Бер кадак яшел чәй», «Күшәр», «Габбас» дип, яки Муса байга шулай язып, кирәк нәрсәсен сорап ала икән. Байлар бер кирәк нәрсәсен бина яки йортын койма белән әйләндереп бирсәләр, хәзер икенче яктан сүтеп алып, кирәк булганда, мичкә, я учакка яга икән. Шул турыда берәү бер сүз әйтсә, «аның агачы Мәдинәдән яки Мәккәдән килмәгән, шушы урманнардан килә ич», – ди икән. Габделваһһап Казакларый никахында бер кыз туганы баласыз үлгәч, кырык мең сум мирас даулап, бик кыенлыкка калдырган. Шулчакта Ташкичүнең мелла Шәмсетдин: «Галимнәр байлар белән даулашырга тиеш түгел», – дигәч, «Тиешме, түгелме, аны сукыр сыерның үксез бозавы да белми», – дип җавап биргән. Казанга килеп, Йосыф бине Әхмәр Кавалиның өенә кергәндә, Йосыф бай тәрәзәдән күреп:

– Агай, син кайсы авылдан? – дигәч,

– Күшәрнеке.

– Ни исемле? – дигәч,

---

[1] Гарип күрсәтү – мохтаж, дин юлында йөрүче итеп күрсәтеп, ашарга эшләмичә генә табу.

– Габбас дип әйтәләр, – дигәч,

– Әйдә, кер, хуш килдең, хәзрәт, мәрхәмәт итәсез, – дип, өенә алып кереп чәй эчергәндә, бай, әлеге дәгъвадан сүз чыгарып:

– Хәзрәт, ул кадәр мал дәгъва итәсез, кардәшегезне никадәр мал белән биргән идегез, ул кадәр мирас калдырырга? – дигән. Байның шул сүзенә каршы:

– Аллаһы Тәгалә бирсә була ул. Сезне дә «Кавал Йосыф», «Кавал Йосыф» дигәч тә, атагызны «Чирмеш Әхмәр» дип әйтәләр иде, – диюенә, Йосыф бай бик ачуланса да, түзеп, бер тәңкә садака биреп озаткан, ләкин аңа каршы хәрәкәт итеп, дәгъвасын юкка чыгарткан.

Энесе Корбангали бай: «Һай, муенны абзый кисте, мин аны ватып чыгармакчы идем», – дигән.

Бервакыт Гата исемле углы Казанга килеп, бөтенләй эштән чыгып бозыклык эчендә йөргәндә, дус-ишләре: «Хәзрәт, үзең барып табып аны алып кайтмасаң, харап була ул», – дип әйтеп, үзе барып алып кайткан.

Габдессәлам мөфти Казанга килгәч, «углың хакында төрле хикәят һәм гаризалар бар» дигәч: «Булыр, кеше әйтер, Әпсәләм углы турында да шулай дип сөйлиләр», – дигән. Каргалыда торганда Габдессәлам мөфтигә хәлфә булганлыктан, мөфти булгач та, кимсетеп, «Әпсәләм» дип эндәшә икән.

Муллалыкка шәһадәтнамәсе булмаганга күрә, Габдессәлам мөфти имтиханга җибәрүне сорап, Казан мәхкәмәләренә язса да бармаган, Мөхәммәдҗан мөфтинең «бу кеше авыл мулласы булырга яраклы» дип, бер кисәк кәгазьгә язган хатын кушып, Казан мәхкәмәләренә гариза биреп, указ алган һәм имтиханга бармый калган.

Бервакыт Шашы мәчетендә намазлыкларны кыйбла ягыннан көнбатыш почмакка каратып салганны күреп, мулласыннан ник алай икәнен сорагач, мулла: «Хәзрәт, безнең эш харап икән, «Җамигыр-рөмүз»дә «безнең кыйблабыз көнбатышлар арасында» дип әйткән» диюенә каршы: «И ахмак, «Җамигыр-рөмүз»не сезнең Шашыда язганнармыни?» – дигән. Бервакыт

Казанда мелла Сәгыйд Бәрәскәви, сүзгә керешеп: «Миңа кызыңны бирмәдең» дигән сүзенә каршы: «Сартны алдап алып, качып кайткан алтмыш мең акчаң бетмәгән булса бирер идем», – дигән.

Углы мелла Габделбари Бохарада укыганда, «Расходка акча җибәр» дип язган хатына каршы: «Иза вакыйгатин» сүрәсен һәр кич укы, мохтаҗ булмассың», – дип, бер тиен акча җибәрмәгән. Һәр кәрванда[1] кешегә азмы-күпме акча килгәндә, моның углына: «Иза вакыйгатин» сүрәсен укы, дип, хат килә иде. Гомерендә атка, я чана яки арбага утырып күпердән чыкмаган: җимерелер дип курка икән. Гел җәяү чыга торган булган. Башны кыса дип, бүрек кимәгән: бәрән тиресен салып кына куя икән. Башка киемнәре дә бик гади була икән. Эчкәне – яшел чәй, ашаганы, күбесенчә, тавык ите. Йортына һичбер мәче кертмәгән. Ялгыз бер өйдә торып, күгәрчен асрый икән. Җәй көне печән чаптырып китереп, шуның өстендә утыра яки ята икән. Чәйгә суны үзе алып кайтып, кунак килсә, тавык алырга акча алып чыгып китә икән.

Бервакыт, хатыннары кычкырышуыннан качып чыгып, буранда капка төбендә утырганын берәү күреп: «Хәзрәт, буранда торасыз», – дигәч, «Өйдә буран моннан да шәбрәк», – дигән. Озын гомер сөреп, туксан яшендә мең ике йөз җитмешенче (1853– 1854) елда Күшәр авылында үлгән. Урынына әлеге углы мелла Гатаулла имам булып, ул үлгәч, углы Гали бине Гата, аннан соң углы мелла Гадел имам булды.

Икенче углы мелла Габделбари Кызылъярга барып, түбән мәхәлләсендә имам-хатыйп, Кызылъяр шәһәренә һәм тирәсенә ахун булып, ничә тапкыр Эрбет базарына имам булып килеп, мәчет өчен дип кат-кат акча җыеп, мәчеткә бер өй алып манаралар ясатып, әйләнәсен койма белән тотып алып, үзе дә файдаланды. Хәзер ул хезмәт өчен Эрбеткә килүдән тыелып,

---

[1] Кәрван – Бохара Россиягә кушылмаган һәм тимер юллар юк чакта, мал һәм кешеләр Бохарага (шулай ук башка ерак шәһәрләргә) төркем булып барганнар. Шул төркем «кәрван» дип аталган. Хатлар, акчалар да шул кәрванда йөртелгәннәр.

мәҗмәгъ[1] анда башка кешеләр җибәрә. Шулай да сәбәбенә керешеп, яңадан мең ике йөз туксан тугызынчы (1881–1882) елда өстенлек алуга иреште. (261–263 б.)

Болардан – мелла Мәхмүд бине Мөхәммәд бине Садыйк бине Мостафа бине Гали бине Садыйк әш-Ширвани әл-Хәнәфи әз-Заһид (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) – асылы Ширван илендә Шимаха тирәсендә бер авыл кешеләреннән булып, Россия дәүләте каршында ышанычсыз саналып, Пермьгә сөрелде. Мең ике йөз җитмеш алтынчы (1859–1860) елда азат ителеп, Казанга килде, бераз вакытлар яшәгәч, Әстерханга күчеп, дәрәҗәсенә яраклы яхшы йорт бина итеп, мең ике йөз туксан дүртенче (1877) елда мөхәррәм аеның сигезендә дүшәмбе көн вафат булды...

Мелла Мәхмүд әфәнденең Болгар һәм Болгар халкын мактап язган бәетләре булды. Бәет:

Шәһре-Болгарә күңел шөйлә улыптыр моштак,
Җөмлә Болгар күренер күземезә якын ерак.
Шәһре Болгарә күңел кылма бәрабәр аслан
Мисыр, Шам, Ямәни, шәһре Хорасан, Гыйрак.
Мәккә тавафына дезәр һәр сәнә хөҗҗаҗ низам,
Мәккәй Болгари һәр ан таваф әйләмәк гайре морак.
Хазир ул вәҗһелә серештә улып Болгарә,
Тышы зольмәт, эче нур, абе хәят.
Димә: Болгар ки ул сәр ходадыр әл-хәкъ,
Нур тәҗәллада ясанып так-әтъвак.

Болгар шәһәрен күрергә күңел шулай омтыла,
Бөтен Болгар ерак булса да, күзебезгә якын күренә.
И күңел, Мисыр, Шам, Ямән, Хорасан, Гыйрак
шәһәрләрен Болгар шәһәре белән һич тә бертигез куйма.
Мәккә ягына һәр ел тәртипле рәвештә хаҗилар төзелә;
Болгар шәһәрен һаман карап әйләнү хыял түгел.
Яшеллек шулай Болгарның табигате булып,
Тышы караңгы, эче якты, тереклек суы балкытучы.
Болгар ул Хак Тәңре тарафыннан бетерелгән димә:
Нур иңеп, яңадан көч-куәт чолгап алыр.

[1] Духовное собрание истә тотыла булса кирәк.

Өлкән бабасы мелла Гали бине Садый Ширвани Иран падишаһы Надиршаһ янында булып, бер яхшы эшләнгән Коръән һәм шәл бүләк ителеп, «Ясин шәриф» сүрәсен тәрҗемә итүне (падишаһ) аннан үтенгән... (274–276 б.)

Болардан – иң кадерле, иң хөрмәтле, диннең нуры, олылыкның атасы Мәхмүд бине Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим Казани Мәрҗани әл-Мәәмүн (Аллаһның рәхмәте һәм бәрәкәте аңа булсын) мең өч йөз икенче елда (1885) күңел ачу теләге белән рабигыль-әүвәлдә сишәмбе көн иртән мелла Заһиретдин Әбү Сәлим Мөхәммәд бине Фәйзрәхман бине Габделгаффар бине Габделхәмит Түнтәри белән бергә Яңа Тазлар[1] авылына китте. Юлда кышкы каты суыкка очрап, туңып, бер атна үткәч, аягы авыртып, шешеп, рабигыль-ахирнең алтысында пәнҗешәмбе көн безгә хат аркылы хәбәре килеп, рабигыль-ахирнең унынчы көнендә Тазлар авылына барып җиттем. Сәламәт, ләкин аягына баса алмый иде. Әд-душыс[2] мае дигән бернәрсә алып барып аягына сөрткәч, бераз шеше кайткан кебек булгач, юлга алып чыксам, авыруы көчәюдән куркып, калдырып кайттым. Һичбер файда күрмичә, рабигыль-ахирнең егерме дүртендә сишәмбе көн өйгә кайтты. Атаклы докторлардан бер-бер артлы җиде кешене китереп күрсәттек, һәммәсе дә: «Кисмичә төзәлмәс», – диделәр. Җәй көне булгач, рамазан аеның сигезендә якшәмбе көн Бәләбәй өязе Дәүләкән авылына кымыз эчәргә китте. Аннан корбан гаете алды якшәмбе көн кич белән кайтты. Тәне куәтләнгән, симергән, ләкин аякта шеш ике өлеш арткан иде. Чарасыз, Николай бине Иван Боголюбов исемле хирург чакырылды. Ике йөз сум хак белән биш кеше – өч ир, бер хатын килеп, зөлхиҗҗәнең соңгы, егерме өченче көнендә якшәмбе көн уң аягын тездән югары җиреннән кисеп алдылар. Гәрчә 12 сәгать эчендә аннан савыгып җитсә дә, күкрәгендә туберкулез көчәеп, озак вакыт авыру булып, мең өч йөз өченче (1886) елда рабигыль-әүвәлнең соңгы унысында пәнҗешәмбе

[1] Татарстанда Арча районында. Хәзер – Байкал исемле.

[2] Әд-душыс – нинди май икәнен таба алмадык.

көн таң вакытында үлде. Шул ук көнне декабрьнең бишесендә төштән соң күп халык белән җеназасын үзем укыдым. Казанның Яңа зиратына күмелде. Аллаһ аның каберен якты һәм оҗмах итсен, мең ике йөз сиксән өченче (1867) ел егерме җиденче җөмадиел-әүвәл аенда якшәмбе көн туган иде. Гаять акыллы, сабыр, укырга бик ярата, яхшы хәтерле, күп нәрсәне яттан белә, бик күп яхшы сыйфатларны үзендә туплаган, нечкә билле, матур йөзле, төз һәм озын буйлы, кара кашлы, кара күзле, кара чәчле кеше иде. «Кәшшафет-тәнзил», «Фәтхел-Кадир», «Һидая», «Кяфия» һәм «Тәфсирел-Бәйзави»ларның күп өлешләрен күңеленнән белә идә. Шулай ук гарәп шигырьләреннән күп нәрсә, фарсы һәм төрки шигырьләрдән кайбер нәрсәләр хәтерендә иде. Читен нәрсәләрне дөрес аңлый, төшенә белә, табигате сәламәт, зиһене туры иде. Дәвани[1], Мирза Заһид, Казый Мөбарәк[2] әсәрләрендәге методологияне куллана белеп, күп хакыйкатьләрне ача ала иде. Мир Бакыр Дамад әсәрләреннән «Өфкыл-мөбин», «Имазат», «Тәкъвимел-иман», Садре Ширази әсәрләреннән «Әсфаре әрбәга» һ.б. күп нәрсәләрне тикшергән иде. Моннан башка, тарих, генеалогия һәм география фәннәре белән таныш иде. Вафаты бу фәкыйрьгә чиксез зур кайгы булды. Шигырь:

Картаеп гомерем җитмешкә җитү белән,
Өметләрем шунда ук юкка чыктылар.

дип әйтүгә лаек[3]... (279–281 б.)

Мөселманнар өчен төзелгән мәхкәмәләр турында фасыл

Казан шәһәрендә мөселманнарның милекләре өчен үзләреннән сайланган рәис һәм мәҗлес әгъзалары булган өч мәхкәмә бар иде. Берсе – мөселманнарның ятим балалары һәм мәеттән калган малларын саклау өчен; берсе – мөселманнардан алына

[1] Дәвани – Җәләлетдин Дәвани (1502) – көнчыгышның зур галиме.

[2] Казый Мөбарәк – Төркиядә зур галим һәм казыйлардан (1511–1556).

[3] Мәхмүд үлгән чакта, Ш. Мәрҗанигә җитмеш яшь була. Шигырь фарсы телендә.

торган имана (салымнарны җыеп, тиешле урынына тапшыру өчен); берсе – башка эшләрне карый торган ратуша мәхкәмәсе. Мең... елда ачылып, Кырым сугышы вакытында мең ике йөз җитмеш беренче (1854) елда бетерелеп, Казан шәһәрендә мөселманнардан рәисләре булу юкка чыгарылып, барлык мөселман һәм христиан бер рәис кул астына җыелды.

Бу өч мәхкәмәнең һәркайсына махсус бер шәехе[1] һәм аның ярдәмчеләре, ә һәммәсенең өстендә глава исемле бер сайланган рәисе бар иде. Бигрәк тә «Ратуша» дип аталганы һәммәсеннән олысы һәм шанлысы иде. Өч ел мөддәт белән сайланып, әгъзалары ике булгамистер[2] һәм ике ратмал[3] – барысы дүрт кешедән төзеләп, бер рәис каравында иде. Ул рәисләрнең безгә билгеле булганнары бу урында сөйләнә.

Беренче рәис – Ягъкуб бине Солтангали бине Кадер бине Биктә бине Биги (бине Нугайчык бин Турайчык)[4] Казани... «Нижний өлкәсе Намика авылы Котлыг Мөхәммәд мирза бине Ягкуб» дип язылган мең ике йөз (1785–1786) тарихлы кәгазьне үз күзебез белән күрдек.

Икенче рәис – Исмәгыйль бине Апанай (Аллаһ аңа рәхмәт итсен) Лаеш өязендә Чынбылат авылының Айтуган бине Җанбылат бине Җамыш исемле кешенең оныкларыннан. Бабалары Ханбылатның Ашыт елгасының төньягында Чынбылат авылы кешеләренең бабасы Чынбылат белән бертуган икәнлеге халык телендә сөйләнә. Атасы Казан шәһәрендә яшәп, «Апанай Хафиз» исеме белән танылган. Кабере Зәңгәр мәчет янындагы зират уртасында. Үз балаларыннан Исмәгыйль, Бикмөхәммәд, Зәгыйфә һәм Хәнифә исемлеләренең яшәгәнлеге мәгълүм. Хәзер балалары исән һәм үзенә нисбәт бирелеп, аның фамилиясе белән йөртеләләр. «Хафиз» дип, асылда, хәдис галимнәре телендә йөз мең хәдисне күңелдән белүчегә әйтелә иде. Шуннан алынып,

---

[1] Шәехе – өлкән кешесе, башлыгы.

[2] Булгамистер – «Бургомистер»дан үзгәртелгән булса кирәк.

[3] Ратмал – элекке Россиядә ратуша членнары.

[4] Нәсәпнең җәя эчендәгеләре «Мөстәфад...»ның 61 нче битеннән алынды.

гомумән галим кешегә, ә заман үтү белән, бу мәмләкәттә, һәрбер язу таныган кешене атаганнар: «Галим хафиз, Җансарый хафиз, Кадер хафиз» дип, хәзер, үзгәртелеп, «абыз» диелә. Хосусан, Кысна авылында бабабыз мелла Сөбхан бине Габделкәримнең беренче килгән елларында Әмир абыз, Багыз абыз, Бәшир абыз, Бәкри абыз, Гаед абыз, Габдеки абыз, Гомәр абыз дигән тугыз кеше булган. Хәзерге көндә телебездә калган «абыз агай», «абызтай», «абзый» сүзләре шуннан алынган. Хәтта олы яшьле, я чын-чыннан яки чама белән алганда нинди дә булса артыклыгы булган кешегә, гомумән, бертөрле олылау теләге белән әйтелә башлавы бу сүзнең әһәмиятен бетергән.

Хатыны Җанай исемле булып, Галәҗ өязендә Сая авылында туган. Озын гомер итеп, ике оныгы Йосыф һәм Муса гасырына ирешкән. Без сөйли торган шушы Исмәгыйль бабай укый-яза белми торган кеше булган. Казан кешеләреннән иң беренче акча түләп сәүдәгәрлек исемен алып, «купец» дип аталучылар шушы Исмәгыйль белән Бикүш исемле кешеләр булганнар. Якыннарыннан Исай карт һәм башкалар: «Чукындылар, керәшен булдылар», – дип, аларны шелтәләгәннәр. Казанның зур байларыннан булган. Казанда рәис булып торганда Йосыф бине Динмөхәммәд исемле кешедән коллар алуы турында мелла Мортаза бине Габделгазиз кулы белән язылган документ бу урында үз гыйбарәсе белән китерелә: «Тарих мең дә җиде йөз сиксән сигезенче елда январьның сигезенче көнендә Казан өязенең Арча округының Иске Бистәнең йомышлы кеше Йосыф Динмөхәммәд углы саттым үземнең хыйссама[1] тигән колымны Казанның Иске Бистәсенең Исмәгыйль Апанай Хафиз углына йөз сум хак берлә ошбу мәзкүр колларым Алат юлында Арча округында Күшәр илендә йорт берлә торгучы мәзкүр колларым: әүвәл Бикбау Сәедкәй углыны хатыны Нәсыйха, бер кызы, сабый углы Бикчәнтәй берлә; икенче колымның углы Мортаза Мөәмин углыны, вә дәхи шул Күшәр илендә, кайсы кем Бик-

[1] Хыйссама – өлешемә.

бау били торган җирләрем һәм печәнлегем көлләсе[1] Исмәгыйль агайгадыр».

Россия дәүләте белән Төркия арасындагы бер сугышта әсир ителгән Гайшә исемле хатынны шул вакыттагы Казан губернаторы, Исмәгыйль бабайга әйтеп, үзе туй итеп никах кылдырып биргән. Ул хатынның аристократлар нәселеннән икәнлеге халык телендә «мәзкүр турчанка» дип мәшһүр. Аннан Исхак һәм Хәбибелҗамал исемле балалары туган. Хәзерге көндә аның нәселеннән Хөсәен бине Шаһиәхмәд бине Исхак бине Исмәгыйль бар иде. Исмәгыйль үлгәч, ул хатынга мелла Мөхәммәҗҗан мөфти өйләнгән. Мең ике йөз тугызынчы (1794) елда җитмеш тугыз яшендә үлеп, ике бистә арасындагы зиратка күмелгән. Каберенә оныгы Хәсән бине Муса куйдырган ташта шулай.

Йосыф, Муса, Исхак, Миһербан, Бәдигыльҗәмал, Хәбибелҗәмал исемнәрендә өч углы һәм ике кызы калды. Казан тирәсендә Әлдермеш авылында олы яктагы мәчетне бина итеп, мең ике йөз кырык биштә (1829–30) тәмам төзеп бетергәч, янып, мең ике йөз кырык сигездә (1832) оныгы Хәсән бине Муса яңадан бина кылдырды.

Олы улы – Йосыф бине Исмәгыйль, анасы Өмме Рахил Мортаза бине Туктамыш бине Узатай кызы, ә Өмме Рахилнең анасы Хәдичә исемле; мең бер йөз җитмеш беренче ел (1758) җөмадиел-әүвәлнең унсигезендә җомга көн туды. Вакытында мәшһүр байлардан Исхак бине Солтангали бине Кадер бине Биктә кызы Хөбәйбәгә өйләнеп, ул үлгәч, мең бер йөз туксан дүрттә (1780) углы Мортазага мирас булып калган...[2] кызы... ка өйләнеп, мең ике йөз (1786) дә Габдерәшид бине... исемле кешедән йорт алып, мең ике йөз бердә (1787) мәшһүр мелла Үтәгән Уразмәт Урбари кызы Хәнифәгә өйләнеп, йорты янып, алты мең сум зарар күргән. Мең ике йөз өчтә (1788–1789) Үтәгән мелла кызы баладан вафат булып, мең ике йөз дүрттә (1790) мөхәррәм аеның беренче көнендә Мазар башы авылы Мөнасип

---

[1] Көлләсе – бөтенесе.

[2] Күп нокталар оригиналдагы буш калган урыннарга куелды.

бине Максут бине Мөхәммәд кызы Миһервафага өйләнеп, тугыз бала туып, Хөсәен, Сөләйман, Салих, Исхак, Шәрифелҗәмал, Сахибелкәмал гомерле булып, аналары Миһервафа мең ике йөз утыз өченче (1817–1818) елда кырык биш яшендә үлеп киткән. Анасы – Сәгыйд бине Госман бине Габделкадыйр әл-Кышкарый ибне Камай кызы Зөһрә...

Өченчесе – Муса бине Селиш Казани. Тутырмалар балалары дип танылган. Башкалардан хезмәт хакы алып, бу эшне күп еллар башкарып, мең ике йөз кырык өчтә (1828) үлде. Аның нәселеннән Мәхмүд бине Муса, Исмәгыйль бине Мостафа бине Ягъкуб бине Муса Казанда бар. Углы Ягъкуб әтисеннән җиде ай соң үлде. Без Казанга кайтканда, Әхмәд һәм Мостафа исемле угыллары бар иде, яшьли үлделәр.

Дүртенчесе – Гобәйдулла бине Мөхәммәдрәхим бине Юныс Казани. Казан шәһәренең атаклы байларыннан. Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанайның Фатыйма исемле кызын алып, аңа кияү иде. Ибраһим, Исхак, Бәдигылькәмал, Фәхрелҗәмал, Гайшә исемле балалары калды. Мең ике йөз кырык ... ел чигендә шушы хезмәттә булып, мең ике йөз илле сигезенче (1842–1843) елда икенче кат сайланды, әмма мең ике йөз илле тугызда (1843) мөхәррәм аенда үлеп, калган срогын углы Ибраһим тәмам итте: үзе яшәгән беренче мәхәлләнең имам һәм мөәзиннәренә Печән базарындагы кибетләреннән берсен уртак файдалану, бер кибетен мәчетнең шәм һәм тәрәзәләренә дип вәкыф иткән. Карагыз татар халкыбызның үткенлек, аңлылык һәм һиммәтлелек дәрәҗәсенә! Гыйлем һәм олылыкка ия булган кешеләрне никадәр түбән, хурлыклы итеп саныйлар. Дәрес укыту, имам булу, вәгазь сөйләүче булу – өч бөек дәрәҗә. Шуларны һәм алардан башка бик күп хезмәтләрне йөкләгән галим, диндар, игътибарлы кешене надан һәм юләр мөәзиннәр белән бер дәрәҗәгә куялар!

Угыллары ул кибетләрдән кырык елдан артык файдаланып, хәтта мәчет амбарларының килерләрен үзләренә алып, имам һәм мөәзиннәргә бер тиен бирмәделәр. Шулай булгач, гыйлемнең нинди кадер-хөрмәте булсын, ул ничек күтәрелсен! Шуңа күрә

меллалары дәгъва вәкиле – адвокат булып мәхкәмәгә йөрүне, хатыннары исә яучы булуны ихтыяр итәләр.

Тагын бер ямьсез күренеш: үги анасы Мәликә Хәсәнҗан кызын Исмәгыйль Исхак углына бирергә булып, үзара вәгъдәләр тәмам булуга якынлашып, киңәшләр барганда, кинәт «юк, алай булса, мин үзем бирәм», дип кире кайтарып, Гайшә исемле кызын биргән. Балаларының эш һәм әхлакы нәселдән түгел икән, хәтта мәхәлләнең барлык кешеләре алардан кул селтәде.

Бишенчесе – Хәсән бине Муса бине Исмәгыйль бине Апанай – Казанның мәшһүр һәм атаклы сәүдәгәрләреннән, мең ике йөз уналтынчы (1801–1802) елда Казанда туды. Анасы Сәхипҗамал Габдерәшид бине Гали кызы булганга, Мирза Шаһиәхмәд бине Мөхәммәд бине Габдерәшиднең атасы белән бертуган кыз кардәшенең кызы була. Мең ике йөз кырык тугыздан (1833–1834) башлап бу урынны алды. Мең ике йөз сиксәненче (1863–1864) елда сәфәр аенда вафат булды. Җеназасын мелла Салих укып, Яңа зиратта күмелде. Мөхәммәҗан, Мөхәммәдша, Әхмәтша исемле угыллары калып, Мөхәммәдша мең ике йөз туксан алтынчы (1878–1879) елда үлде, җеназасын мелла Тажетдин бине Бәшир укып, Яңа зиратта күмелде. Атасы Муса бине Исмәгыйль Казанның олы байларыннан. Мең ике йөз кырык икенче (1826–1827) елда алтмыш биш яшендә рәҗәп аеның унтугызынчы көнендә вафат булып, Казан шәһәрендә Яңа зиратта күмелде. Мортаза, Хәсән, Мөхәммәд, Гобәйдулла, Габделкәрим, Миңлебай исемле угыллары калды...

Алтынчысы – Исхак бине Мостафа бине Мортаза бине Давыт бине Йосыф бине Мөхәммәд Казани, ибне Афак. Казанның мәшһүр байларыннан. Үлгәннән соң миллион сум акчасы барлыгы беленде. Хәсән байдан соң мең ике йөз илле... (1835) елларда бу урынны алды. Мең ике йөз җитмеш... (1884) елларда кинәттән үлде...

Җиденчесе – Ибраһим бине Гобәйдулла бине Мөхәммәд Рәхим бине Юныс Казани. Мең ике йез егерменче (1805) ел чигендә туды. Анасы Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай

кызы Фатыйма, аның анасы – Исхак кызы Хөбәйбә. Казан байларының иң мәшһүре. Шигырь:

Кеше күпме генә ярдәм итсә дә, артык мактамагыз:
Оялып кызарырлык булса, бик җитә.
Чөнки аның ярдәме яки ярдәмнән баш тартуы юмартлык яки
саранлыктан түгел,
Бәлки котырынып китүенең бер минутлык күренеше генә»[1] –

дигәнчә, юләр юмартлык, аш-суының күплеге белән бергә, начар һәм яраксыз эшләре белән бик мәшһүр. Мең ике йөз илле тугызда (1843) атасы үлгәч, рәислекнең икенче кабатын төгәлләгәч, мең ике йөз алтмыш тугызда (1853) тагын сайланып, Кырым сугышы вакытында Казан шәһәрендә бу урын һәм мәхкәмә бетерелеп, һәр ике чиратта эше кимчелекле иде; башлыкларның соңгысы булды.

Сигезенчесе – Миңлебай бине Габдерәшид бине Йосыф Казани. «Ибне Әхмәд» дип танылган. Ибне Юныстан соң ук мең ике йөз алтмыш беренче (1845) елда сайланып, мең ике йөз җитмеш биштә (1858–1859) вафат булып, Яңа зиратта күмелде...

Тугызынчысы – Мостафа бине Нәзир бине Әҗем бине Колмәмәт Казани. Хаҗи Миңлебайдан соң бу эшкә кереште...

Унынчысы – Ибраһим бине Гобәйдулла. Бу – рәисләрнең ахыргысы[2]. Мең өч йөз өченче (1886) елда рәҗәб аеның унысында, нисан руминең[3] икесендә төш җитәр алдыннан вафат. Икенче көнне Казанда Яңа зиратка күмелде. Сиксән өч яшендә, җеназасын бу фәкыйрь үтәп, балалары калмады. Малы кардәшенең угыллары Мөхәммәдрәхим, Габделкәрим, Габделвәли һәм хатыны арасында бүленде.

---

[1] Гарәпчә. Тәрҗемәсе бирелде.

[2] Бу урында Ш. Мәрҗани беркадәр буталчык керткән. Ул «җиденче» дигән бүлекчәсендә шушы Ибраһимның ике тапкыр ратушада рәис булуы, аннан соң бу мәхкәмәнең бетүе турында сөйли дә, Ибраһимның беренче һәм икенче тапкыр мәхкәмәгә җитәкчелек иткән вакытлары арасында Миңлебай бине Габдерәшид һәм Мостафа бине Нәзир турында язып, тагын шул ук Ибраһимга кайта.

[3] Нисан руми – апрель.

Мирза Шаһиәхмәд бине Мөхәррәм бине Габдерәшид бине Гали бине Рәскә Казани әш-Шәмәки. Асылы Тәтеш өязендә Шәмәк исемле авылдан. Ләкин монда сөйләнгән балалары һәммәсе Казан шәһәрендә Яңа Бистәнең төньяк-көнбатыш өлешендә хәзер Наласа пулаты дигән зур таш йорт урынында яшәп, кайбер җыентыклардан күренгәнчә, карт бабалары рабигыль-әүвәл аенда мең бер йөз кырык җиденче (1731–1732) елда, углы Габдерәшид мең ике йөз алтыда (1791–1792) җомга көн рамазан аеның егерме өченче көнендә вафат булганнар.

Мирза Шаһиәхмәд Казан шәһәрендә туып, мөселман һәм рус мәктәпләрендә укыган, Казан һәм Уфа шәһәрләрендә хөкүмәт хезмәтләренә кереп, аеруча Казанда полиция идарәсендә[1] һәртөрле хезмәтләрне башкарып, ахырда полицмейстер киңәшчесе, ә мең ике йөз илле дүрттә (1838–1839) полицмейстер урынбасары урынын алып, бик гайрәт һәм тырышлык белән, Казан халкын дер селкетеп торып, бөтен полиция эшләрен гаделлек белән башкарды. Бөтен эш моның кулында иде. Егерме ел тоташтан шушы эшне башкарып, меңбашы дәрәҗәсен алып, мең ике йөз җитмеш дүртенче (1857–1858) елда үзенең үтенүе белән хезмәттән коткарылды. Мең ике йөз туксан икенче (1875) ел мөхәррәм аеның унҗидесендә якшәмбе көн кинәттән үлде. Җеназасын Мостафа мөәзин сишәмбе көн үтәде. Күмәргә бик күп кеше җыелды. Яңа зиратта күмелде. Яше җитмешкә якын иде. Корбангали бине Әхмәр бине Арсай кызы Хөсни исемле хатыныннан Биньямин, Сәедгәрәй, Бәһрам, Сәргаскәр, Хәдичә, Фәрхессорур исемле дүрт углы һәм ике кызы, Ибраһим бине Әхмәр кызы Габидә исемле олы хатыныннан Мәрьям исемле кызы калды. Холкы каты, саис[2], үткен, кайгыртучан кеше иде. Намазы дөрес булырлык дәрәҗәдә, Коръәнне дөрес укый белә, имлясе һәм мәгънәсе ягыннан шома һәм дөрес каләме – язуы

---

[1] Мәржани моны «Кутуал» дип атый. В.В. Радлов аны, «көтү» сүзеннән алып, «сакчы», «хәрби милекне саклаучы учреждение» дип аңлата. Безнеңчә, бу урында ул «полиция идарәсе» мәгънәсенә якынрак.

[2] Саис – кайбер сүзлекләрдә моны «вәли» – «башлык», «губернатор» дип аңлаталар. Безнеңчә, монда ул русча «властный» сүзенә туры килә.

бар иде. Давыт бине Җәгъфәрнең әйтүенә караганда, полициядә хезмәт иткәндә дә тәһарәтсез булмаган, намазын калдырмаган. Игенлек, урман, печәнлек җирләре, балалары, байлыгы һәм хайваннары күп иде. Дошманнар бик күперенеп, котырынып, тәмам җиңүгә ирешкән вакытта, һичкем сорамыйча, үтенмичә, бары дөреслекне яклау йөзеннән бу фәкыйрьгә зур ярдәм күрсәтте. Хак Тәгалә моны ахирәт өчен азык итсен, амин.

Тәрҗеман – Рәхмәтулла бине Әмирхан бине Имәнколый бине Заһид бине Нурсәед әл-Кишети[1]. Асылы Казан тирәсе Яңа Кишет авылыннан. Кечкенә чагында атасы белән Казанга килеп, Пороховойда һәм Бишбалтада яшәп, бераздан соң шәһәрнең үзендә беренче мәчет янында йорт алып, бераздан соң күл башында Болак буенда йорт алып күп еллар яшәгән, Казанда булган зур янгын вакытында йорты янып, хәле начарланды. Ахырга таба йортын сатып, дөньясы тараеп, Яңа Бистәгә барып бер йорт алса да, ул йортта икенче берәүнең хакы булганлыктан, квартирага күчте, йорт өчен биргән акчасы да югалды. Үзе шеш авыруына дучар булып, меңике йөз туксан икенче (1875) ел чәршәмбе көн егерме өченче зөлхиҗҗәдә үлде. Яше җитмешкә якын иде. Җеназасын мелла Шаһиәхмәт үтәп, Яңа зиратта күмелде, сәүдәгәрләрнең белгеч һәм олылары кадәр гарәпчә һәм фарсыча китаплардан күп кенә мәгълүмат туплау өстенә рус теле һәм рус язуы белгәнлектән, Казан өязе полиция идарәсенә тәрҗеман булып, аннан башка Россия дәүләтендә кайбер башка хезмәтләр итеп, күп кенә медальләр алды. Яхшы кәгазь һәм кара, яхшы хәрефләр белән хәзинә типографиясендә Коръән һәм башка күп китапларны ялгызы яки икенче берәүләр белән бергәләп бастырып сәүдә итеп, башта дөньясы-торышы иркен иде. Казыйлы авылына мәчет салдырды. Меллаларга Коръән һәм әфтияк, бала-чагаларга укырдай китаплар бирә иде. Каләме шома, имлясы дөрес, язуы матур, эчтәлеге бай булып, меллалар язуы кебек яза иде. Гәүдәсе төгәл, әгъзалары төзек, калын һәм

[1] Әл-Кишети – Кишет авылыныкы. Кишет – Татарстанда Арча районында бер авыл.

күркәм тавышлы, батыр, исерткеч эчәргә һәвәсләнгән, эш һәм сүзендә куркуны белми, ваемсыз кеше иде. Исерткечтән кәефе бик күтәрелеп китмәгәндә, тирәнтен уйлап, килештереп, табигый рәвештә ачык һәм һәр тыңлаучыга ярарлык, күркәм һәм матур гыйбарәләр белән саф сүзләр әйтә иде. Әмма исерсә, сүгенеп, начар, кешене рәнҗетә торган сүзләр сөйли иде. Шулай да һичкемне, исерек чакта да, ата-анасы белән сүккәнем юк ди икән. Тәкәббер, явыз холыклы олы байларга турыдан-туры яки читләтеп авыр сүзләр әйтеп дәгъваларын сындырса да, сүзгә батыр, сөйләве күркәм булганлыктан, каршы тору яки кире кагудан гаҗиз булып, туктап калу һәм көлүдән башка бернәрсә эшли алмыйлар иде. Юныс балалары һәм мелла Сәгыйдләр белән дус һәм якын булганлык сәбәпле, алар белән бер эздән барып, бу фәкыйрьгә дә кайбер зарары тиде. Шулай да аңлы ир, яхшыны яманнан аера белүче, дөнья хәленнән хәбәрдар кеше китап алу, уку белән шөгыльләнә иде. Шулай күп ягы белән мәшһүр булганлыктан, бу урында язылды. Үлгәндә, Габдулла исемле углы һәм өч кызы калды. Урынына Биньямин бине Йосыф бине Арсай тәрҗеман булды.

Иститраф[1]. Сәед әфәнде кебек, сүзе, күбесенчә, ачы һәм күңелгә авыр китерерлек була иде. Шуларның кайберләре китерелә: бервакыт Истанбулдан мелла Мөхәммәдкәрим байларны Төркиягә күчәргә чакырып язгач, Ибраһим бай аңа каршы: «Безнең бу шәһәребездә дә дин тотарга бер дә тарлык юк. Без ратушада глава булып торганда, өч кенә көн мәхкәмәгә керә идек; кайда ул җомга калдыру! Хәзер тоткыннарга да җомгага чыгарга рөхсәт булган», – дигәч, «Һай, ул рөхсәт әүвәлдән бар, син гомерең буенча беренче дәрәҗә бай, аның өстенә рәис тә булып, җомгага бару белән мактанасың. Унбиш көн ристан булып торып, җомгага бару белән мактан», – диде.

«Бервакыт корбанлык алырга дип базарга чыктым, бер кара, бер кызыл яшь сыер бар икән. Карасы бик яхшы симез, ләкин ике яше тулып, өчкә чыккан. Кинәт бу, бәлки, ярамас, дүрткә

[1] Иститраф – өстәмә.

чыккан кирәктер дигән шик килде. Өйгә кереп карасам, ике тулган да ярый икән. Чыгып карасам – алып киткәннәр: бик яхшы, кап-кара, җылык-җылык итеп тора иде. Нәкъ менә Ибраһим абзый кебек суярлык кына иде», – диде.

Бер мәҗлестә Ибраһим байның «Бохараларда мәетне җиргә күммичә, согнә[1] ясап кына куялар икән» дигәненә каршы: «Мин дә сиңа әйттем бит, Сосновка тау башына ясат, ыржаеп карап ятарсың дип», – диде.

Бервакыт эт балаларын туйдырганын күргән: «Адәмнән туган балаң булмаса да, эттән туган балаларың бар икән», – дигән.

Бервакыт килеп кереп: «Һай, Ибраһим абзый, мин сине авырый дип ишетеп, бу йөзе кара кадала икән дип шатланган идем, терелгәнсең икән ләбаса», – дигән.

Бервакытта Ибраһим бай: «Безнең Шиһаб мелла шәкертләре урыс язуы гына укыйлар, мәдрәсә шүрлекләрендә урыс китабы» дигәч тә: «Аны буш бирәләрме шүрлек тутырырга, сүзең бик рас булса, бер-ике тәрҗемә булыр» диюенә, Ибраһим бай, кайтарып: «Юк, мин аны меллалардан ишетеп әйтәм», – диюенә каршы: «Ялган! Үзеңә дә ышанмыйм, мулларыңа да, Шиһаб хәзрәттән башкасына ышанмыйм. Ул ялган әйтсә дә ышанам», – дигән...

Байларга карап: «Фәлән рус авылга чиркәү салганы, ә берсе фәлән чиркәүдәге тәреләрне алтынлатканы өчен орденнар килде. Аны үзләре әйтмәделәр, мин газеталарда укыдым», – дип сөйләгәнен үзем кат-кат ишеттем. Ул бу сүзләрне Ибраһим байның бик бай, хуҗа, тырыш булып, горурлыгы сәбәпле башкалар кирәк сүзләрен дә әйтә алмаган чакта әйтә иде. Вә илла ахыр гомерләрендә Билал Суфи һәм үз хадимнәре дә тәмам хәкарәт итәр улдылар. Бер мәҗлестә берәүгә, Аллаһ белә, Вафа иде шикелле, шуңа бәйләнеп, симезлегеннән көлеп, «Сез ашауэчүдән башканы белмисез», – дип шелтәләвенә Казаков бик кәефләнеп утырганда: «Менә син Казаков кебек булып елан йот

[1] Согнә – мәгънәсен таба алмадык. Якынча өсте ачык табут (гробница) күздә тотыла булса кирәк.

та, кип тә, коры да, ике тиен акча өчен җаның чыксын да үл» – дип, Казаковны бик каты мәсхәрәләде.

Бервакыт нәрсәне танудан сүз чыгып, «Һәркем үзе тоткан нәрсәсен белә. Менә китапны хәзрәтләр генә белә, ә байлар китап кадерен белмиләр, китап алмыйлар, бары Әҗем Мортаза гына байтак китап алып, баскыч астына өеп куйган», – диде.

Бервакыт Рәхмәтулланың үз өендә Мәңгәр авылының Мохтар бине Мөхәррәм, икенче табыннан безгә карап: «Бу заман хәзрәтләре бер дә китап сөйләп, халыкка вәгазь-нәсыйхәт итмиләр, менә итсәләр, без дә файдаланыр идек, борынгы муллалар халыкка китапны бик күп сөйлиләр иде, аеруча безнең абзый бик күп сөйли иде», – диюенә каршы, Байморат хәзрәткә: «Мин егерме биш ел катнашып йөрдем, барлык киңәшләре, серләре минем белән иде, китап сөйләгәнен гомеремдә бер тапкыр да ишетмәдем», – диде.

Тагын бер мәҗлестә: «Кукобин типографиясендә Коръәнне рус бастыра», – дип сөйләгәч, Кавалның Фәйзулла бине Әхмәр, бик гаҗәпләнеп: «Әллә укый да беләме?» – дип соравына каршы: «Безнең Сәгъди мулладан бик күп артык укый», – диде.

Мулла Ганинең намазны бик тиз укуыннан зарланып: «Рөкүгъ, сәҗдәдә тәсбихене бер тапкыр да дөрес әйтеп булмый, башкалар ничек икән дип тыңлап карасам, «сепелхыр», «сепелхыр»[1] дип кенә әйтәләр икән», – диде.

Габдерахман хаҗиның Истанбулдан хаты килгәч, иртә намазыннан чыккан чагында, хатны тотып алып килеп: «Менә Габдерахман абзыйдан, хатта сәлам әйткән», – диде. «Кая, яшерен сүзе юкмы, миңа күрсәтергә ярыймы?» – дигәч: «Ярый ла яравын, ләкин юньсез кеше генә укый алмаса, юньле кеше укый алмас», – диде.

Болардан – Әбү Салих Мостафа бине Йосыф бине Давыт Казани. Заманының төш юраучысы (Аллаһ аңа рәхмәт итсен). Мең ике йөз җитмешнең (1853–1854) ахырында җитмеш яшендә

[1] Рөкүгъда өч тапкыр «Сөбханә рәббияль-газыйм», сәҗдәдә «Сөбханә рәббияль-әгъла» сүзләре әйтелергә тиеш. Ашыгычта шул сүзләр «сепелхыр» дип әйтелә, дигән сүз.

вафат. Җеназасын мелла Шаһиәхмәд үтәде, Яңа зиратта күмелде. Төш юраганда, кызыклы юрау һәм оста туры китерүе белән халык арасында мәшһүр, бераз гыйлеме дә бар иде. Бервакыт Салих бине Йосыф Мәкәрҗәдә вакытта төшендә өенә сарыклар кергәнен күргәнлеген сөйләгәч: «Хатының хатыннар мәҗлесе җыйган», – дигән. Салихның туганы Исхак бер төш күреп, юравын сорагач: «Садака бир!», – дигән. «Әйтсәнә!» дигәч, «Салих абзаң белән кычкырышырсың», – дигән.

Тагын мелла Исхак бине Сәгыйд үлгәч, мәхәллә кешеләреннән берәү Мәчкәрә авылы дамелла Габдулланың мәчетләрендә имам торганын төшендә күреп, шул кеше сезгә мулла булып килер дип әйтүенә каршы: «Юк, үзе булмас, бер шәкерте булыр», – дигән. Чыннан да, шәкерте Мөхәммәдкәрим мулла булып килде. Шулай, аның юраулары күп вакыт дөрес килә икәнлеге халык телендә сөйләнә. Күп кешеләрнең: «Мин аңа төш сөйләргә куркам, әллә ни яман нәрсә әйтер», – дип, төш сөйләмәүләре дә мәшһүр. (333–347 б.)

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ БУ ҖЫЕНТЫГЫНДА ТЕЛГӘ АЛЫНГАН КЕШЕЛӘР ҺӘМ ӘСӘРЛӘР

Анбаз-Кылыс – безнең эрага чаклы яшәгән грек хәкиме. Милет фәлсәфә мәктәбе кешеләреннән Эмпедокл (490–430) күздә тотыла булса кирәк.

Анаксагорс – Анаксагор. Безнең эрага чаклы яшәгән грек хәкиме (500–428). Ш. Мәрҗани бу хәкимне Милет мәктәбе кешесе дип атый. Ләкин хәзерге галимнәр аны Афина фәлсәфә мәктәбе вәкиле буларак өйрәнәләр.

Анкимаес – фәлсәфә тарихында Анаксимандр, Анаксимен дип йөртелә торган ике борынгы грек хәкиме бар. Алар безнең эрага чаклы VI гасырда яшәгәннәр. Милет мәктәбе кешеләре. Ш. Мәрҗанинең Анкимаес дип шуларның кайсын атаганы ачык билгеле түгел.

Арасту – Аристотель – безнең эрага чаклы яшәгән грек хәкиме (384–322), Сократның шәкерте.

«Асарел-билад вә әхбарел-гыйбад» шәһәрләр һәм халыклар турында З. Казвини әсәре.

Әбү Бәкер Хәтыйб Багдади (Хафиз Әхмәд бине Гали – 1001–1070) Багдад шәһәрендә яшәгән. 100 дән артык китап язган. Иң мәшһүре – «Тарихе Багдад» исемле әсәре.

Әбү Вәлид бине Җәһвәр – Мөхәммәд бине Әбү әл-Хәзем. Әндәлестә Кортаба шәһәрендә яшәгән. 1070 елда үлгән.

Әбү Габдулла әл-Мазини – кара: әл-Гарнатый.

Әбү Гали ибне Мокаллә – Әбү Гали Мөхәммәд бине Гали. 1370 елда Багдадта туган, гарәп хәрефләре нигезендә «нәсех» язуын уйлап чыгарган кеше. Аңарчы гарәпләрдә «күфә» язуы йөртелгән.

Әбү Гали Сина – кара: Ибне Сина.

Әбү Гобәед Габдулла әл-Бәкри әл-Кортаби (1094). «Китабел-мәсалик әл-мәмалик» («Гаҗәп төрле хәлләр турында китап») исемле хезмәтнең авторы.

Әбү Госман Бәкер бине Мөхәммәд әл-Мазини – тел галиме һәм шагыйрь. 863 елда Басра шәһәрендә үлгән.

Әбү Исхак Истахри – Ибраһим бине Мөхәммәд. Иранда Истахар шәһәрендә туган (X йөз), сәйях һәм географ. «Китабел-әкалим» («Җирнең төрле климатлары турында») һ.б. әсәрләре бар.

Әбү Касыйм Гали бине Хәсән – «Ибне Гасякир» дип мәшһүр (1105–1175). Кушаматы «Сикатетдин» һәм «Нуретдин». Димәшкъта яшәгән, шул шәһәрнең 80 томлык тарихын язган.

Әбү Мөслим бине Мөслим – Мәгазел-һөраэ. Тел галиме һәм сатирик шагыйрь. 802 елда үлгән.

Әбү Мөхәммәд Габделмәлик бине Һашим бине Әюб әл-Химьяри. «Химьяр» – гарәпләрнең бер кабиләсе.

Әбү Насыйр әл-Фараби (874–951) – Аль-Фарабиюс. Мөхәммәд бине Тархан бине Әвезләгъ. Зур галим, антик философлар язган күп китапларны тәрҗемә иткән һәм философияне үстерү өлкәсендә күп көч куйган.

Әбү Нәгыйм әл-Әсфәһани – Әхмәд бине Габдулла. 1012 елда үлгән. «Мәгърифәтес-сахабә» һ.б. исемдә китаплары булган.

Әбү Сәһел әл-Мәсихи – «Әллия» исемле китапның авторы.

Әбү Сөләйман Фәхретдин Дауд – Урта Азиядә Илханилар династиясеннән Газан ханның сараенда шагыйрь һәм елъязмачы. Газан ханның углы солтан Әбү Сәгыйд исеменә «Рәузате үлил-әлбаб фи тәварихел-әкябири вәл-әнсяб» исемле китап язган. Бу кеше үзе Бәнакәт шәһәрчегеннән булганга күрәдер, аның бу әсәре «Тарихе Бәнакәти» дип аталып киткән. Ш. Мәрҗани әсәрендә ул «Тарихе Нәбакәти» дип басылган. 1330 елда Бәнакәт шәһәрчегендә үлгән.

Әбү Фәтех Мөхәммәд бине Әбү әл-Касыйм Габделкәрим бине әби Бәкер Әхмәд әш-Шәһрестани (1086–1153) – зур галим, философ.

Әбү Хәмид әл-Әндәлеси – кара: әл-Гарнатый.

Әл-Бәкри – бу исем астында Әндәлес дәүләтенең ике галиме билгеле: 1) Әбү Гобәед Габдулла бине Габделгазиз – биолог һәм врач; 2) Бәкри дип кенә йөртелә. Бусы – географ һәм сәйях. Һәр икесе – XI йөз кешеләре.

Әл-Гарнатый – Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Габдерәхим (1080–1170). Шул ук кеше – Әбү Хәмит әл-Әндәлеси һәм Әбү Габдулла әл-Мазини. Әндәлеснең зур галиме һәм сәйяхе. «Төхфәтел-әлбаб» һ.б. исемдә әсәрләр язган.

Әл-Җөвәйни – кара: Хуҗа Галаэтдин...

Әл-Мәсгуди – Гали бине Хөсәен бине Гали әл-Мәсгуди әл-Багдади. Зур галим һәм сәйях. Күп китаплар язган. Сирәк очрый торган хәлләр турында «Мөрәүвиҗез-зәһәб вә мәгадинел-җәүһәр» («Алтыннар таратучы җәүһәрләр чыганагы») исемле әсәре бар. 346 (958) елда үлгән.

Әл-Хаңадани – Ибнел-Фәкыйһ Әбү Бәкер Әхмәд бине Мөхәммәд. IX–X йөзләрдә яшәгән географ.

Әсатыйн – әстунәләр – колонна, әйдәп баручы. Борынгы җиде хәкимне шулай «әсатыйн» – әйдәп баручылар дип атаганнар.

Әсинә – Афина шәһәрен гарәпләр шулай «Әсинә» дип йөрткәннәр.

Әфләтун – Платон – безнең эрага чаклы V йөздә яшәгән. Идеалист, Тәңренең барлыгын исбат итәргә тырышкан хәким, Сократның шәкерте. Аны «илаһи» дип атау да үз чорының атеист-материалистларына каршы якта булуында дип уйларга кирәк.

Әш-Шәриф әл-Идрриси (1100–1165) – Әндәлес галиме, сәйях. «Нөзһәтел-мөштак фи ихтиракыйл-афак» исемле китабы билгеле. Бу китапта барлык илләр турында язылган һәм 71 географик карта теркәлгән. Бу әсәрнең кыскартмасы 1593 елда Римда латинчага, 1836 елда французчага тәрҗемә ителгән.

«Башлагали» – Болгар әдәбияты әсәрләреннән. Гали исемле авторның поэмасы. Безнең әдәбиятта «Кисекбаш» дип йөртелә. Шуның үрнәгендә XX йөздә берничә «Кисекбаш» исемле әсәрләр язылды. Шуларның иң мәшһүре – Г. Тукайның «Печән базары, яхут Яңа кисекбаш» исемле сатирик поэмасы.

«Бәдәвам» – Болгар ханлыгы чорында язылган дини-әхлакый, көйле китап.

Бәдел-хәрәми – Багдад хәлифәсе әл-Моктәдир биллаһ (X гасыр) дәверендә зур дәрәҗәле кеше. Ибн Фазлан катнашы белән Болгарга 921 елда килгән һәйәтнең төзелүендә катнашкан. Үзе Болгарга килгәнме-юкмы – ачык түгел.

Бәриятел-Бәркә – Бәркә (Бәрәкә) Алтын Урданың икенче ханы – Бәрия – сахра дигән сүз. Алтын Урда дәүләтен шулай «Бәриятел-Бәркә» («Бәркә сахрасы») дип тә атаганнар.

Бәтъләмиюс – Птолемей – II гасырда Искәндәриядә (Мисыр) яшәгән хәким. Аның Җир йөзе һәм галәм төзелеше турында китабы «әл-Мәҗсәтый» исеме белән гарәп теленә тәрҗемә ителгән. Рус телендә «Альмагест» дип йөртелә.

Габденнасыйр әл-Курсави (1770–1813) – Татар дөньясында азат фикер идеясен беренче күтәрүчеләрдән. Аның фикерләре, уйлау методы Ш. Мәрҗанигә көчле тәэсир ясаган.

Газали – Хөҗҗәтел-ислам Зәйнетдин әбү Хәмид Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Әхмәд әт-Туси. Хорасанда Гуси шәһәре янындагы бер авылда туган зур галим һәм философ (450–505 = 1058–1112).

«Гажаибел-мәхлүкать...» – кара: З. Казвини.

«Гараибел-мәкъдур...» (яки: «Гажаибел-мәкъдүр...») – кара: ибне Гарәпша.

Гөлбән-Ханан – Бабур шаһның кызы, шагыйрә.

Гөлгәнеч – 1000 нче елларда Бохара дәүләтенең зур шәһәре.

Дара бине Дара – безнең эрага чаклы VI гасырда яшәгән Иран мәмләкәте патшасы.

Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини (1208–1283) – тарих һәм география галиме. «Гажаибел-мәхлүкат вә гараибел-мәүжүдат», «Асарел-билад вә әхбарел-гыйбад» исемле әсәрләре белән танылган.

Зирьяб Моганни (1414 елда үлгән) – талантлы музыкант. Димәшкъта үсә, аннан Әндәлескә (хәзерге Испания) китеп, зур шөһрәт казана. «Үд» дип йөртелгән биш кыллы уен коралы уйлап чыгарган.

Иберхс – Гиппарх – безнең эрага чаклы икенче гасырда яшәгән грек хәкиме. Астрономиягә һәм географик математикага нигез салучылардан.

Ибне әл-Әсир – Гыйззетдин Әбү әл-Хәсән Гали бине Мөхәммәд. XIII йөз тарих галиме. «Китабел-кямил», «Әсәдел-гаяти фи мәгърифәтис-сахабә» исемле әсәрләре әһәмиятле.

Ибне әл-Әсир – Әбү Сәгадәт Мәждетдин Мөбарәк бине Әбү әл-Кәрәм әл-Җәзди. Мусыл (Массул) шәһәрендә яшәгән зур галим (1149–1209). Гыйззетдин ибне Әсирнең туганы.

Ибне Баттута – Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Мөхәммәд. 1307 елда Африкада Танжир шәһәрендә туган. Россиядә һәм Идел буйларында сәяхәт иткән. «Төхфәтен-наззар» («Күзәтүченең бүләге») исемле әсәре мәгълүм.

Ибне Вәрди – Сиражетдин Әбү Хәфас казый Гомәр Фәхретдин (1348–1388). Тарих һәм географиягә бәйле «Хәридәтел-гажаиб» һ.б. әсәрләре булган.

Ибне Гарәпша – Шиһабетдин Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габдулла әл-Карши әд-Димәшкый (1388–1430). Болгар һәм Алтын

Урда галимнәреннән. Тимерлән турында язган әсәре бар. Бу әсәрне Ш. Мәрҗани «Гараибел-мәкъдүр фи әхвали Тимур» дип, «Кәшфез-зонун... иясе «Гажаибел мәкъдүр фи әхвали Тимур» дип атап йөртәләр.

Ибне Гасякир – кара: Әбү әл-Касыйм...

Ибне Дасә (Ибне Дастә, Ибне Рөстә) – Әбү Гали Әхмәд бине Гомәр. X йөздә яшәгән, Көнчыгыш Европада сәяхәт иткән иранлы галим.

Ибне Рәүбә – Шәмсетдин әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әбү Талиб әл-Әнсари әд-Димәшкый. «Нохбәтет-дәһер фи гажаибил-бәрри вәл-бәхер» («Коры җир һәм диңгезләрдәге хәлләр турында сайлап алынганнар») исемле әсәре бар.

Ибне Рөшд – Аверроэс (1126–1198) – казый Әбү әл-Вәлид Мөхәммәд бине Әхмәд. Әндәлестә яшәгән зур галим, философ.

Ибне Рөшд – Әбү Мөхәммәд Габдулла бине әбү Вәлид – алда әйтелгән Ибне Рөшднең углы. Врач һәм философ.

Ибне Сина – Әбү Гали Сина, Авиценна – Әбү Гали Хөсәен бине Габдулла (980–1037). Атаклы врач, философ һ.б., ул «Шәйхе рәис» – «Шәехләрнең башлыгы» дип йөртелгән. Бик күп әсәрләр калдырган кеше.

Ибне Халдун – Әбү Язид Габдерахман бине Мөхәммәд Хазәрми. 1331 елда Әндәлестә туган. Зур философ һәм тарих галиме. Ш. Мәрҗанинең «Мөкатдимәте вафиятел-әсляф» исемле әсәре Ибне Халдунның «Мөкатдимәте тарихы ибне Халдун» исемле әсәре үрнәгендә язылган.

Ибне Хәүкаль – Әбү Касыйм. X йөздә яшәгән сәйях һәм географ. Әл-Истахри әсәрләренә төзәтмәләр керткән кеше.

Ибне Хиллякян – Әбү Габбас Шәмсетдин Әхмәд бине Ибраһим (1211–1272) – галим һәм тарихчы. Күп телләргә тәрҗемә ителгән иң мәшһүр китабы «Вафиятел-әгъян вә әнбаэ эбнаэз-зәман». Ш. Мәрҗани «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» исемле зур әсәрендә бу китаптан файдаланган.

Икълидес – Эвклид – безнең эрага чаклы өченче гасырда яшәгән грек хәкиме.

Ихвадес-сафа («Чисталык туганнары» дигән сүз) – шул исем белән аталган галим һәм әдипләр төркеме. Болар, X–XI йөзләрдә әдәбиятта халыкчанлык идеяләрен яклап, аристократизмга каршы чыгалар.

«Йосыф китабы» – «Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха» – мәхәббәт поэмасы. Төрки халыклары арасында берничә варианты бар. Шулардан Гали Кашани тарафыннан язылганы – иң борынгы (1213 ел) һәм Болгар әдәбияты әсәрләреннән.

Кабус әмире – Шәмсел-мәгали Әбү әл-Хәсән бине Әбү Таһир – Жөрҗан, Рәй, Гарәбстан тирәләрендә өч йөз сиксән сигезенче (998) елдан алып 15 ел патша булып, соңыннан әмирләре тарафыннан төшерелеп, дүрт йөз өченче (1012) елда үлә.

Кәлданилар – Кече Азиядә Гыйракның көнбатышында борынгы заманда яшәгән кабиләләр.

«Китабел-кямил» – кара: Ибне Әсир.

«Китабел-мәсялик вәл-мәмалик» – кара: ибне Әсир.

Кыйбтыйлар – кобытлар – Мисырда яшәүче халык.

«Мәгазел-һәраэ» – кара: Әбү Мөслим...

«Мәгърифәтес-сахабә» – кара: Әбү Гобәед Әсбәһани.

Мәждед-дәүлә – Әбү Талиб Рөстәм бине Фәхред-Дәүлә – Гыйрак – Иран тирәләрендә оешкан «Ал-Бүя» дәүләте әмирләреннән. Ибне Сина аның вәзире була, Мәждед-Дәүлә дүрт йөз егерменче елда Мәхмүд Газнәви тарафыннан үтерелә.

Мәлтыя – борынгы Грециядә «Милет» дип йөртелгән һәм гыйлем үзәге булган шәһәр. «Мәлтыя мәктәбе» – борынгы грек философиясендә мәгълүм бер мәктәп, юнәлеш.

Мәхмүд Газнәви – Якын Көнчыгыш Азиядә оешкан Саманидлар дәүләтенең көчле патшасы. Дүрт йөз егерме беренче (1030) елда үлгән.

«Мифтахес-сәгадәт вә мисбахес-сәядәт фи мәүзүгатил-голүм» – Мостафа Ташкибризадә (1556 елда үлгән) әсәре.

Мөвәххидин – «Мөрабитыйн»нар дәүләте тузылгач, якынча шул җирләрдә яшәгән дәүләт. Ибне Рөшднең улының улы – Шәмсетдин Саминең күрсәтүенчә, Ибне Рөшднең үз улы – Мөхәммәд Габдулла шул ук Ибне Рөшд исеме белән тарихта билгеле һәм «Мөвәххидин»нәр дәүләтендә казый булган.

«Мөгъҗәмел-бөлдан» – кара: Якут әл-Хәмәви.

Мөрабитыйн – V гасыр һиҗридә (XI гасыр) төньяк-көнбатыш Африка һәм Испания җирләрендә төзелгән дәүләт. Тарихта атаклы галим Ибне Рөшд – шул дәүләттә Кардова h.б. шәһәрләрдә казый булган.

Мөхәммәд бине Исхак бине әл-Кәләби – VIII гасырда Мәдинә шәһәрендә яшәгән тарих галиме.

«Нәүруз бәете» – Болгар чоры халык әдәбияты әсәрләреннән. Яз җитү (Нәүруз – яз ае) уңае белән сөйләнә торган бәет.

«Нәһҗел-фәрадис» – Мәхмүд бине Гали Болгари, Сараи, Кәрдәринең зур күләмле әсәре. 1358 елда Сарай шәһәрендә язылып бетә. Мәхмүд бине Гали 1361 елда Сарай шәһәрендә үлә.

«Низһәтел-моштак...» – кара: Әш-Шәриф әл-Идриси.

Пифагор – кара: Фисагурс.

Платон – кара: Әфләтун.

«Раузатыс-сафа фи сирәтил әнбия вәл-мөлүк вәл-хөләфа» – фарсы телендә Мөхәммәд бине Хавендшаһ бине Мәхмүд (1427 елда үлгән) әсәре.

Рәй – Иранда Тәһраннан ерак түгел кечкенә бер шәһәр. X йөзләрдә зур гыйлем мәркәзе булып, Чыңгыз гаскәрләре харап иткән. Мәшһүр галим Фәхретдин әр-Рази – шул шәһәрдән.

Рум – хәзерге Анатолия (Төркия) греклар кулында чакта Рум, Рум иле дип аталган.

Салис – Фалес – безнең эрага кадәр 624–548 елларда яшәгән грек хәкиме.

Самия – бу исем астында борынгы Грециядә Самос утравы күздә тотыла булса кирәк.

«Сәбгы Сәйярә фи әхбари мөлүкятит татар» – татар патшалары һәм илләре турында Мөхәммәд Риза әфәнде әсәре.

Сәлман бине Рәбига әл-Баһили – Гомәр хәлифә заманында гаскәр башлыкларыннан. Азәрбайҗан тирәләрендәге сугышларда 650 елда үтерелә.

Сәһсән әр-Расиби – Әхмәд бине Фазлан сәяхәтнамәсенең акад. Крачковский редакциясендә чыккан нөсхәсендә (1939) бу кеше «Сүсен әр-Раси» дип йөртелә. 921 елда Болгар иленә хәлифә әл-Моктәдир биллаһ җибәргән илчелекнең җитәкчесе.

Ш. Мәрҗани «сәһсән» – төрки сүзе ди. Әмма без кулыбызда булган сүзлекләрдән мондый сүзне таба алмадык. Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» исемле әсәрендә «Сүсен» – кеше исеме итеп күрсәтелә. Акад. Крачковский һәм проф. Ковалевский тарафыннан чыгарылган Ибне Фазлан китапларында да ул шулай «Сүсен» итеп йөртелә. Гарәп язуында «Сүсен» сүзенең «Сәһсән» булып укылуы мөмкин.

Сирьяни – Кече Азиядә хәзерге Сирия республикасы тирәсендә яшәгән кабиләләр.

Сиуттый – Җәләлетдин Әбү әл-Фазыл – Мисырда Сиут шәһәрендә туган, йөзләрчә китап язган, 911 (1505) елда үлгән.

Сократ – безнең эрага кадәр 469–399 елларда яшәгән грек хәкиме, Платонның остазы. Демократиягә каршы көрәшкән өчен үтерелгән.

«Тарих Бәнакәти» – кара: Әбү Сөләйман.

«Төхфәтел-назар» – кара: Ибне Баттута.

«Төхфәтел-әлбаб...» – кара: әл-Гарнатый.

Фараби – әл-Фараби кара: әбү Насыйр...

«Фәрһәңнамә» – фарсы телендә язылган борынгы әсәр.

Фәһләви (пәһләви) – борынгы Иран, Көрдстан һәм Гыйрак тирәләрендә кулланылган тел. VII гасырларда бу тирәләрдә гарәп теле өстенлек алу нәтиҗәсендә онытылган. (Мәрҗанидә сүз шул телдә язылган әсәрләр турында.)

Фисагурс – Пифагор – безнең эрадан элек алтынчы гасырда яшәгән грек хәкиме.

Хаҗи хәлфә – Мостафа бине Габдулла Кятиб Чәләби (1609–1657) «Кәшфез-зонун ган әсамиел-көтеби вәл-фөнүн» («Китаплар һәм фәннәрнең исемнәре турында шикләрне ачу») исемле библиографик әсәре белән танылган.

Хәким Синаи – Хәким Әбү әл-Мәҗд бине Адәм – Иранның бөек шагыйрьләреннән. 1180 елда үлгән.

Хуҗа Галаэтдин Гатаэл-мөлек бине Хуҗа Баһаветдин Мөхәммәд әл-Жөвәйни – зур галим һәм Иранда Илханилар династиясенә якын торган олы дәрәҗәле чиновник. 1283 елда үлгән.

Шәмсетдин әд-Димәшкый – кара: ибне Рәүбә.

Якут әл-Хәмәви – Әбү Габдулла Якут бине Габдулла әл-Багдади әл-Хәмәви. 1228 елда үлгән. Тарих, әдәбият белеме һәм география фәннәреннән әсәрләр язган. Шулардан «Мөгъҗәмелбөлдан» әсәре мәшһүр.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш (*И. Гомәров*) 5

Шиһабетдин Мәрҗани (Тормышы һәм иҗаты – *Х. Хисмәтуллин*) 5

«Мөкатдимәте китабе «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф»тан кыскартылган тәрҗемәләр *(Х. Хисмәтуллин; тәрҗемәне әдәби редакцияләүче С. Ногманов)* 35

«Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» әсәреннән тәрҗемәләр *(тәрҗемәләүче З. Максудова; тәрҗемәне әдәби редакцияләүче Х. Хисмәтуллин)* 89

Әл-кыйсмел-әүвәле мин китаби «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» *(хәзерге телгә күчерүчеләр: Х. Хисмәтуллин, С. Исәнбаев, В. Ильясов; фарсыча текстларны тәрҗемәләүче С. Ногманов)* 127

Әл-кыйсмес-сани мин китаби «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» *(хәзерге телгә күчерүче – Х. Хисмәтуллин)* 371

Шиһабетдин Мәрҗанинең бу җыентыгында телгә алынган әсәрләр һәм аерым кешеләр *(Х. Хисмәтуллин)* 441

Шигабутдин Марджани

ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ

(на татарском языке)

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 26,2. Уч.-изд. л. 20. Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12